# Мәҗит Гафури

Фәнни-популяр җыентык

Казан
«Җыен» нәшрияты
2021

ББК 83.3(2Рос=Тат)
Г26

*Китап «Татнефть» ААҖнең (генераль директоры Н.Ө. Мәганов)
матди ярдәме белән нәшер ителде*

*«Шәхесләребез» сериясенә нигез салучы:*
Татарстан Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы
М.Г. Госманов

*Редколлегия:*
Р. И. Вәлиев (җаваплы мөхәррир), М. Б. Галиев,
Р.К. Гатауллин (Гаташ), Х. Й. Миңнегулов, Ф. М. Рафиков,
Ф. Ш. Сафиуллин, И. Г. Һадиев

*Фәнни мөхәррире:*
Дания Заһидуллина,
филология фәннәре докторы

*Төзүчеләр:*
Айгөл Ганиева, филология фәннәре кандидаты,
Алсу Хасавнех, филология фәннәре кандидаты

Г26 **Мәҗит Гафури: фәнни-популяр җыентык** / Төз.: Ганиева А.Ф., Хасавнех А.А. – Казан: Җыен, 2021. – 560 б. – («Шәхесләребез» сериясе). – илл.

ISBN 978-5-902783-54-1

Китап XX йөз башында һәм совет дәверенең башлангыч чорында татар әдәбиятының күренекле әдибе һәм шагыйре булып танылган Мәҗит Гафуриның (1880–1934) тормыш юлына һәм иҗатына багышлана. Җыентыкта әдипнең укучыга моңарчы таныш булмаган кайбер әсәрләре, хатлары, мәкаләләре дә урын алу, шулай ук төрле чор каләм әһелләренең, галимнәренең аның турындагы истәлек һәм фәнни-публицистик язмалары бирелү М. Гафури иҗатына һәм шәхесенә карата яңача – объектив караш булдыруга ярдәм итәр дип ышанабыз.

Китап киң катлам җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-902783-54-1

© «Җыен» фонды, 2021
© Ганиева А.Ф., Хасавнех А.А., төзү, 2021
© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2021

*Дания Заһидуллина*

# «Гасырларча хөкем сөргән җиһангир без татарлардыр…»: татарның талантлы улы Мәҗит Гафури

Башкортстанның гүзәл, шифалы туфрагында туып үскән талантлы һәм тыйнак шәхесләребездән ул... Мәҗит Гафуриның татар әдәбияты үсешенә, сикерешенә ясаган өлеше гаять зур булса да, кайчак без югары бәяне әйтеп тә бетерә алмыйбыз кебек. Моның сәбәпләре дә берәү генә түгел.

XX гасыр башында караңгылыкны ярып «беренче атылган йолдыз» – юл күрсәтүче, кыйбла билгеләүче, күтәрелер биеклеккә нур төшерүче шагыйрь янына аның артыннан ук «сикергән» шигърият йолдызлары әдәбият күген яктырта, дөньяви поэзиянең тулаем үсүенә китерә. Бу хакта әдәбият галиме Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (1926) китабында төгәл әйтелгән сүзләре бар: «Бездә 1905 ел революциясе белән бик кызу күтәрелгән әдәби хадисәләр матур әдәбиятыбызның лирика өлеше булды. Бу юлда беренче адым Мәҗит Гафури белән башланган хәлдә, аның белән бергә Тукай, Думави, Зариф Бәшири, Укмасыйлар йөрәге дулкынланып китте». «Бу юлда беренче адым» ясаган, тумышы белән тыйнак, холкы белән укытучы Мәҗит Гафури була, әмма ул үзе әлеге якты йолдызлар янында күләгәдәрәк торырга омтыла!

1905 елгы ирек авазын беренчеләрдән булып ишеткән, шуны шигырьләрендә яңгыраткан Мәҗит Гафури 1917 ел инкыйлабын да – үз халкы өчен яңа киң мәйдан, тарихи дөреслекне торгызу юлы дип кабул итә. Бу омтылышында да ул – беренчеләрдән, ул – әйдаман. Әмма советчыл идеологияне данлап язылган шигырьләренең көче, тәэ-

сирлелеге аның иҗатын бәяләүдә көтелмәгән борылыш китереп чыгара: язучының инкыйлабка кадәрге иҗаты, асылда, «оныттырыла», үзе исә совет әдәбиятының социалистик үзгәрешләр җырчысы итеп карала башлый. Озын-озак совет заманы Гафуридан инкыйлабчы ясый!

Дөрес, М. Гафурины таныту юлында галимнәр Г. Халит, С. Кудаш, Ә. Нигъмәтуллин, М. Мәһдиев һ.б. зур хезмәт күрсәткәнне дә онытырга ярамый. Бигрәк тә 1980–1983 елларда шагыйрьнең 4 томлы «Әсәрләр»е (төзүчеләре З. Рәмиев һәм Ф. Ибраһимова) аның иҗатын тулысынча диярлек фәнни әйләнешкә кертергә, үз васыятен үтәп Казанга китерелгән фондындагы күп материалларны укучыга җиткерергә ярдәм итә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең, үзләре әзерләгән 4 томлыкка кермәгән материалларны да исәпкә алып, М. Гафуриның тууына 130 ел тулуга чыгарган «Сайланма әсәрләр» (2010) шушы эшнең дәвамы кебек кабул ителә. Башкортстан галимнәре дә бу юлда зур хезмәт куя: әдипнең әсәрләре даими басылып, күптомлыклар, монографик хезмәтләр рәвешендә дә туплап бәяләнә.

Әмма «Шәхесләребез» сериясеннән менә шушы «Мәҗит Гафури» җыентыгын әзерләгәндә, без тагын бер кат әдипнең иҗат мирасы тулысынча халыкка җиткерелеп бетмәгән, димәк, аның әдәбият тарихындагы югары урыны хакындагы фәнни эзләнүләр дә төгәлләнмәгән икәнлеккә игътибар иттек. Шуңа күрә укучыга тәкъдим ителә торган бу хезмәт язучы тормышы-иҗатына караган аз билгеле материалларны барлау, аның Казанда саклана торган бай фондындагы моңа кадәр билгесез кала килгән текстларны халыкка җиткерү, иҗатына әдәби-эстетик ноктадан караш ташлау максаты куеп эшләнде. Бу сериядә китаплар нәшер итүнең башында торган Миркасыйм ага Госмановның җыентыкка кергән язмасы әлеге эшнең моннан 30 ел элек планлаштырыла башлавы турында сөйли.

Әсәрләрен кабат бастырып чыгару, аның хакында фәнни хезмәтләр, истәлекләр, аңа багышланган әдәби әсәрләр

язылу, исемен мәңгеләштерү ягыннан татар мәдәниятендә дә, башкорт мәдәниятендә дә М. Гафури — иң билгеле шәхесләр рәтендә булса да, аның иҗатына карата берьяклы карашның да җуелып беткәне юк әле. Шиксез, совет чорының милли сәясәтендә М. Гафурины, милләтен күрсәтми генә, башкорт әдәбиятының классигы дип бәяләү бу иҗатка карата нindидер саграк — салкынрак дип әйтергәме, бәхәсле өлкәгә керергә теләмәүме — мөнәсәбәт китереп чыгара. Татар әдәбиятының әдип-шагыйрьләргә бай булуы да, әдәбият-мәдәният өлкәсендә бәйләнышларның зурлыгы, 1924 елда гына үз рәсми язуын булдырган тугандаш халыкның әдәбият тарихын тудыру омтылышларына аңлап карау үз өлешен керткәндер: М. Гафурига карата рәсми рәвештә «татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы» дигән бәя урнаша. Монда хилафлык юк, Татарстанда чыккан академик басмаларда да ул шулай күрсәтелә. Төгәлләштергәндә, бу бәяне: «башкорт классик әдәбиятын нигезләүчеләрдән булган татар шагыйре» дип ассызыкларга мөмкин булыр иде. Хилафлык — аның шигырьләрен башкорт теленә әйләндереп тә, татарчадан күчерелгәнен күрсәтмәүдә, шагыйрьнең милләтен телгә алмауда, аның эшчәнлеген башкорт җәмәгать эшлеклеләре, зыялылары белән аралашуга басым ясап шәрехләүдә, инде килеп — бернинди нигезсез аны башкорт милләтенең улы итеп күрсәтергә омтылышларда. Башка мәсьәләләрдә дә булырга мөмкин.

Шушы сәбәпләр — Мәҗит Гафуриның иҗатын бүгенге укучыдан ераклаштыра, анда үз күңеленә якын авазларны, аһәңнәрне тоярга, аңларга комачаулый кебек. «Без Мәҗит Гафурины кем буларак беләбез, таныйбыз?» дигән сорау куйсак, аңа җавап мәктәптә дә, вузда да, әдәбият белән кызыксынучылар даирәсендә дә һаман советчарак яңгырый, «Кызыл йолдыз»ларны, «Юктырсың ла, Алла»ларны искә төшерә. Күрәсең, Гафури иҗатындагы татарлыкны, фәлсәфәне, гыйльми һәм фикри тирәнлекне, эстетик эзләнүләрне яңа шартларга туры китереп, идеологик тенденцияләргә бәйсез рәвештә өйрәнәсе бар әле.

Шуңа да без күренекле шагыйрь, прозаик, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче һәм философ Гафури иҗатының күләгәдәрәк калдырылган якларына, сыйфатларга игътибар итүне мәгькуль күрдек. Чыннан да, җыентык аны шәхес буларак та яңа яклары белән ача, иҗатының гаять киң колачлы, күп тармаклы булуын чагылдыра. Бигрәк тә шагыйрь хакында истәлекләр аның зыялы-гыйлемле асылын, һәр хаксызлыкка сизгер холык-фигылен дә, дөньяга үзендә аны үзгәртерлек көч тойган карашын да, затлы-зәвыклы иҗат кешесе булуын да бик ачык күрсәтәләр.

Истәлекләр бәйләмен ачып җибәрә торган, М. Гафуриның илһамчысы, хатыны Зөһрә Гафуриның «Безнең тормыш» дигән язмасы шагыйрьгә олы мәхәббәт, тирән хөрмәт белән сугарылган. Танышу, яратышу, гаилә кору, тормыш тарихы Гафурины акыллы, тыйнак һәм тәрбияле, шул ук вакытта гаять максатчан, халык кайгысы-шатлыгы белән яшәгән намуслы, олы йөрәкле шәхес итеп күз алдына бастыра.

Миргазиз Укмасый, Сәйфи Кудаш, Гата Исхаков, Хәлил Маннан, Кәрим Әмири истәлекләрендә М. Гафуриның тормышы-көнкүреше, кешеләр белән мөгамәләсе, яшь иҗатчыларга мөнәсәбәте, иҗатка карашы төрле ситуацияләрдә ачылып китә. Болар аның иҗат эшенә – халыкка хезмәт итү чарасы итеп каравын да, үз мәсләгенә тугры, үз юлыннан тайпылмас көчле шәхес булуын да, гыйлемле, зыялы, кече күңелле, гомеренең соңгы көннәренә кадәр балаларча ихласлыкны саклаган шигъри зат икәнлеген дә ассызыклыйлар.

Җыентыкка әдәби әсәрләр сайлаганда да әдипнең күптармаклы иҗатын бөтен тулылыгында күрсәтү максаты алга куелды. Мәгълүм ки, әдәби иҗатка берничә ел алдарак, 1902–1904 елларда килсә дә, М. Гафуриның шагыйрь булып танылуы 1905 ел революциясе белән бәйле була. Бер яктан, демократик үзгәрешләр дулкынында иҗат җимешләрен халыкка җиткерерлек газета-журналлар, нәшриятлар ачылса, икенче яктан, шагыйрь бу яңалык-

ларны – татар милләтен алга җибәрү мөмкинлеге; халык аңын уятуны, аның фикер хәрәкәтен кузгатуны иң мөһим гамәл дип карый. 1905 елның 24 ноябрендә «Казан мөхбире»ндә басылып чыккан «Алмашыну» шигырендә ул үзенең каләмен кузгаткан максатны күрсәтә:

*Караңгы бары бетеп, таңнар атар,*
*Ни сәбәпле безнең халык гафил ятар?*
*Һәрничек гафил яту ярамас дип,*
*Шигырь язды Габделмәҗид – ибне татар.*

Ягъни *татар улы Габделмәҗит*нең халыкны йокыдан, ваемсызлыктан уяту, аны үсәргә-камилләшергә өндәү максаты белән шигырь язуын хәбәр итә. Шуннан соң иҗат ителгән күпсанлы шигырьләренең һәркайсында диярлек үз халкы белән сөйләшә:

*Йә татар! Вакыт йитте кузгалырга,*
*Мәгариф шәмгыданын кулга алырга;*
*Тәфәккерсез, гафил булып карап ятмый,*
*Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!*

(«Өндәү», 1905);

*Кояш чыкты, эш башланды ушбу көндә,*
*Инша Алла, инде татар карап ятмас.*

(«...Ничә йөз ел изелгәнгә татар юаш...», 1906) һ.б.

Бигрәк тә 1907 елны басылып чыккан «Милләт мәхәббәте» дигән күләмле җыентыкка тупланган шигырьләрдә ике кабатлана торган ачкыч-образ пәйда була – милләт (татар) һәм ватан: «Мәкъсуд», «Безнең хәл», «Татар милләтенең лисане хәле илә шикаяте», «...Сән күренден күзләрә...», «...Милләтем улганга татар, бән дә улдым бер татар...» һ.б. Шагыйрь үзенең татар милләтен мәгърифәткә, уяныргa, башка милләтләр кебек үсәргә генә чакырып калмый, ул, шигъриятебездә беренче буларак, мәгърифәтчелек мотивларын милли мотивларга буйсындыра. Әйтик, «...Алар бездән оялганнан...» (1907) шигырендә милләтнең алгарышы «татарлык» дигән хис, тойгының булуы белән бәйләнә. Күп кенә шигырьләрдә шушы «татарлык»ны үстергән сыйфатлар барлана: тарих

(«Бер татар шәкертенең Казанда мәшһүр хан мәсҗеденең манарасыны күргәндәге иншад итдеге шигыредер»), дин («...Алар мәгъбүд дигән бәндә...»), акыллы әйдәманнар («...Милләткә хадим улган яхшыларга...»), милли мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьләрдән өстен кую («...Һәр кешенең үз нәфсенә йитсә көче...»), әдәбият («Күңел»), туган тел («Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь») шундыйлардан.

Соңгы әсәрдәге «*Телләре югалмадисә, мәңге югалмас татар*» дигән сүзләр гаять актуаль, бүгенгечә яңгырый. Шагыйрь шәхесе белән тәңгәл килгән лирик герой монологы (үз-үзе белән сөйләшүе) кебек язылган «...Гафури, сән онытма милләтеңне...» (1907) шигырендә риторик эндәш ярдәмендә үзен милләткә хезмәт итәргә, бу юлда тырышырга, татарның авыр хәлдә булуын үзенә күрсәтергә чакырып, суфи шигырьләрдәгечә, милләт юлында корбан булу мотивы («*Тәләф улсаң тәләф ул ушбу юлда*») калкуландырыла, милләткә хезмәт идеясе әйтелә. «Икенче сада» (1907) шигырендә милләтне ярату халәте тасвирлана, үзенең милләткә хезмәтне изге юл дип санавы хакында сөйләүче лирик герой укучыга, милләттәшләренә дә чакыру белән эндәшә:

*Безләр, и туган, анадан туган*
*Булырга корбан милләт юлына.*

«...Һәр кешенең үз нәфесенә җитсә көче...» (1907) шигырендә М. Гафуриның бөтен иҗаты буйлап сызылып барачак, кеше өчен кирәкле, мөһим сыйфатлар төсендә аерылган – хаклыкка хезмәт итү, уйлап эшләү, башкалар мәнфәгатен кайгырту мотивлары алга чыга.

*Иң әүвәл үз-үзеңне яхшы саклап,*
*Шуннан соң милләтеңә бул көтүче,* –

дип, милләтне әйдәп бару өчен, кеше үзе көчле шәхес булырга тиеш, дигән иҗтимагый характерлы идея әйтелә.

Бу яктан шагыйрьнең иң көчле шигырьләреннән берсе – «Үзем һәм халкым» (1912). Халыктан алда, аны ияртеп баручы пәйгамбәр-герой болай дип белдерә:

*Бер адым алга басам да*
*Әйләнәм мин артыма,*
*Кайда басканнар икән дип*
*Күз саламын халкыма.*

Аның борчылуы халыкның артыннан ияреп бара алу-алмавы белән бәйләнгән:

*Шул вакыт мин бик югары*
*Кош кебек очсам әгәр,*
*Ә алар һаман шулай*
*Баскан урнында торсалар...*

Милләт мәнфәгатьләрен кайгыртучы шагыйрь аның үз артыннан җитешеп баруын тели.

Шагыйрьнең күп кенә мәгърифәтчел шигырьләрендә чор өчен традицион символларга мөрәҗәгать итү иҗтимагый яңгыраш көчен арттыра. Әйтик, Гафуриның «Таң яктысы» (1913) шигыре татар поэзиясендә үтәли күзәтелә торган таң ату мотивын үзәккә куя. Шагыйрь таң символын иҗтимагый яссылыкта аңлауга юл күрсәтә: «якты таңны көтә безнең ил». Нәтиҗәдә төн – милләтнең торгынлык вакыты, таң яңарыш вакыты кебек шәрехләнә. Шигырь милләтнең яңарыш вакыты җиткәнлекне раслый. Хаклык нурын күрсәтмәгән, адаштырган, яктылык һәм яхшылыкны, тугрылыкны каплап торган, гөнаһ эшләткән кебек сыйфатлар төнне характерлый. Лирик герой таңның тууына ихлас шатлыгын белдерә:

*Күренә күкнең бер читендә нинди бер нур чаткысы?*
*Арта аз-маз без көтеп торган саен таң яктысы».*

Шулай итеп, М. Гафури – татар әдәбиятында милли проблематиканың беренче планга чыгуын тәэмин иткән шагыйрьләрдән була. Аның «*Гасырларча хөкем сөргән / Җиһангир без татарлардыр*» («...Сәгадәткә ирешмәк...») кебек тезмәләре халыкка барып ирешә, үзеннән соң мәйданга атылган яшьрәк шагыйрьләрне рухландыра. Татар булуың белән горурлану, татарлыкны сакларга һәм ныгытырга чакыру милли шигърияттебездә иң гүзәл фикерләрдән берсе булып ныгый. Татар әдәбиятында

милләт мәсьәләсе XX гасыр башында төп темага әверелә.

Беренче җыентыкларында ук М. Гафуриның фәлсәфи фикерләүне, аллегорик сурәтлелекне яңа әдәбият тудыру, заманча шигърият булдыру юлы итеп караганлыгы күренә. Шагыйрь мәгърифәтчелектән – милли проблематикага, үгет-нәсыйхәттән – фәлсәфәгә борыла, бу үрләрне бик тиз арада яулап ала! Шуңа да аның үгет-нәсыйхәтчелек рухындагы шигырьләрендә дә фәлсәфи гомумиләштерүләр ясала. Әйтик, «Нәсыйхәт» (1909) шигырендәге: тикшереп, уйланып, эзләнеп яшә; хакыйкать өчен көрәш, хәтта үлемгә бар; матди байлыкларга кызыкма; кешегә, кеше мәнфәгатенә хезмәт ит, дигән өндәүләр, кешенең тормышы тулысы белән башкаларга багышланган булырга тиеш, дигән фәлсәфә белән йомгаклана:

*Тугърысы: кеше чөн[1] ту, кеше чөн тор,*
*Кеше чөн хезмәт итеп, дөньядан кит!..*

Ул укучыны шәхес буларак үз-үзе белән горурланырга, үз көченә ышанырга, көрәшергә чакыра («Хәят юлында», 1913). Бу вакытта шагыйрьгә символлар ярдәмгә килә. Татар шигъриятендә традициягә әйләнгән төн-таң («Таң яктысы», 1913), йолдыз («Йолдыз», 1912) һ.б. шундыйлардан.

«...гә (Бер хатирә)» (1911), «Беренче мәхәббәт» (1918), «Гаҗәп эш», «Шәүләсе», «Бер истәлек» кебек шигырьләр шагыйрь иҗатында гаять нечкә, самими-хисле мәхәббәт шигырьләре булуны раслый. Мәхәббәткә илаһи табигатьле изге бер хис итеп караган лирик геройның мәгъшукасына сөю хисләрен аңлатуы бүген дә күңелләрдә яңгыраш таба.

Иң кызыклы эзләнүләр шагыйрьнең дини-суфичыл сурәтләрне дөньяви максатларга буйсындырган әсәрләрендә күренә. Еш кына алар ике төрле укылу мөмкинлегенә дә ия булып чыга. Мәсәлән, «Түгелгән яшь» (1912) шигырендә дини-суфичыл әдәбиятка аллюзия булган яңгыр символының берничә укылышы күренеп тора. Күз

[1] Чөн – өчен.

яше – мәхәббәт билгесе дә («*Мәхәббәт белән тулган саф күңел аһ итсә-сызланса*»); яшәешне камилләштерергә ихлас омтылыш символы («*Чын ихлас белән аккан яшь өмид бакчасына тамса*») да ул. Күз яше мәңге җиргә сеңмәс, өмет бакчасында гөлләр үстерер дип, янәшәлек ярдәмендә илаһилаштырыла. Шул ук вакытта биредә хакыйкый мәхәббәт турында түгел, кешенең башка кешеләргә, кешелек җәмгыятенә мәхәббәте турында сүз бара:

*Әгәр дә бу мәхәббәт бәндәләргә чын урынлашса,*
*Хакыйкатькә восүл өчен үзенә яхшы юл ачса,*
*Җиңә алмас моны һич башка куәт, чөнки бу көчле –*
*Булыр шунда кешеләр һәммәсе нәкъ бертуган төсле.*

Кешеләрнең башкаларга мәхәббәтен шагыйрь «чын инсанлык» дип атый. Мәхәббәт үзе көнчелеккә, икейөзлелеккә, дошманлыкка, көрәшкә каршы куела. Фәлсәфи-мәгърифәтчел фикер болайрак яңгырый: кешеләр бер-берсен яратса, дөньяда мәхәббәт хөкем сөрсә-бәхетле вакыт килер. Аллюзияләр күз яше һәм мәхәббәтнең ролен югары күтәрүгә, аларның гомумкешелек өчен илаһи кыйммәт булуын ассызыклауга хезмәт итә.

М. Гафуриның «...Бәңа бу көн мәхәббәт булды михнәт...» шигыре (1907) дә һәм илаһи, һәм җир мәхәббәтен сурәтләүче әсәр буларак шәрехләнә ала. Төп фикер мәхәббәтнең дөньяда иң олы көч булуын раслый:

*Мәхәббәтсез җиһанда тормак булмас,*
*Бу дөньяны тотып торган мәхәббәт.*

Шул ук вакытта шагыйрь җир кызына сөю хакында сүз баруны аңларга ачкыч калдыра: «*Җәһәннәм чыкты истән, дәхи җәннәт*». Ягъни гыйшыкның теге дөньяны, җәннәт–җәһәннәмнәрне дә оныттыруын әйтеп, дини аллюзияләр ярдәмендә дөньяви укылыш варианты калкытыла.

Яки «Кояш баеганда» (1909) шигырендә беренче тезмәләрдән үк «ахшам», «яшел чирәм», «җир, күк», «анда булган нәрсәләр» гыйбарәләре дини-суфичыл әдәбият белән ассоциацияләр уята: «*Кояш кебек батабыз без, бетәбез / Диеп, ике күзем яшькә чылатсам»; «Болытка гаксе*

*төшкән сары нурны / Хыял белән тотам дип кул озатсам»; «Диңгез кебек ниһаятьсез сәманы / Күреп, гыйбрәт алып, мин уйга батсам»; «Гаҗиз бәндәлегем исмә төшерсәм»; «Чиге юк бу галәмнән бер кисәкмен»* кебек юллар да таныш тоела. Шагыйрь кеше гомерен баеп баручы кояш белән чагыштыра. Тормыш чикле, күк чиксез, галәмдә кеше кечкенә генә бер кисәк, дигән фикерләрнең кешегә һәм сагыш, һәм бәхет китерүен раслау дөньяви позициядән караганда каршылыклы яңгырый. Шул ук вакытта бу каршылык шигырьне суфичылык рамкаларында укырга ачкыч бирә. М. Гафуриның «Тәрәддед» («Икеләнү», 1914), «Мәхәббәт» (1914), «Халәте тәәссердә» (1914) һ.б. шигырьләрен шушы яссылыкта карарга кирәк. Аларның лирик герое – салик, ягъни юлчы, Алланың көче алдында баш ия, шул ук вакытта кеше гомеренең чикле һәм кечкенә булуы аны борчуга сала. Бер үк вакытта шагыйрь «Алла», «илаһи» дигән гыйбарәләрдән кача, кешегә каршы куелган макрокосмос төсендә «мәгънәви көч» оппозициясен билгели («Кайвакытта», 1910) һ.б.

Шагыйрь иҗатында дини-рухани шигырьләр дә аз түгел. «Үз мөселманым» (1909) шигырендә «*Минем өйдә бар Коръәнем*» дигән лирик герой мөселманлыкны – иман ныклыгында, күңел сафлыгында дип белдерә. «Дин вә ислам» (1910), «Алладан сорау» (1914), бигрәк тә «Итагать» кебек шигырьләр Гафури иҗатын бу яктан өйрәнәсе барлыкны да, «Юктырсың ла, Алла» (1915) кебек шигырьләренә сәяси үрнәкләр буларак карарга кирәклекне дә тагын бер кат искәртә.

Аерым бер шигырьләрдә лирик герой – гомумкешелек проблемалары белән янган философ булып аңлашыла: «Ачы!» (1912) шигырендә ул – «хәятның мәгънәсе нәрсә» икәнне белергә теләүче, аның ваемының, хәсрәтенең сәбәбе исә – кешеләрнең мәхәббәтне юк итүе. Мондый шигырьләрдә шагыйрьне иң нык кызыксындырган мәсьәлә – хакыйкать! «Кызык заман» (1907) исемле кыска шигырьдә ул дөньяда хакыйкать юк (*«Табылмады бу дөнья-*

*да һич заман хак»*) дип белдерсә, «Хакыйкать» шигыре (1911) башта бу кыйммәткә кагылышлы легенда тәкъдим итә: имеш, элек дөньяда хакыйкать баш булган, зур урын тоткан. Ләкин алтын-көмеш аны оныттырган, шуңа күрә хакыйкать кешеләрнең күңелләренә кереп яшеренгән. Шуңа нигезләнеп берничә фәлсәфи фикер белдерелә: хакыйкать дөньяда юк; аны сөйгән кешеләр бәхетсез килеш гүргә керә; матди һәм рухи байлыклар бергә яши алмый; хакыйкать кешенең күңелендә ул. Шуларга нәтиҗә төсендә төп фикер килә:

*Җир өстендә кайчан алтын бетәр, шунда чыгар хаклык,*
*Түгел мөмкин боларның икесен бер җиргә җыймаклык.*

Бу фикерләр шагыйрьнең башка фәлсәфи әсәрләрендә дә кабатланып тора.

«Тәрәддед» (1914), ягъни «Икеләнү» исемле шигырендә яшәеш ике якка: тормыш һәм ахирәткә аерыла. Тормышның газап чиктерүе (*«Дөньяда тормыш — кешеләргә, ниһаять, зур газап»*), яшәүнең максаты юклык, киләчәкнең билгесезлеге, «яхшылык», «хаклык» дигән сүзләрнең ялган икәнлеге, киләчәктән якты көн көтүнең рәшә булуы чынбарлыкка, тормышка бәя кебек яңгырый. Шигырьдә тормыш авырлыгыннан котылу юлы итеп суфилар күрсәткән ике юл телгә алына:

*Шатланырга юл табалсаң — шатланып кайгың тарат,*
*Гыйш-гыйшрәт сөр җиһанда, алга килсә — эч шәраб...*

Суфи тәгълиматтагы шатлану һәм исерү халәтенең физик шатлану-исерүдән аерылуын, аларның Аллага якынаю (Хакк әл-йакын) белән бәйле булуын исәпкә алсак, әлеге мотивның җир тормышын газап оясы итеп раслау өчен кертелүе, экзистенциаль характерлы булуы аңлашылыр.

Кайбер шигырьләрдә суфичылык фәлсәфәсе — гомумкешелек фәлсәфәсенә, милли мотивка тоташып китә. Әйтик, «Кызык заман» (1907) исемле кыска шигырьдә үзенчәлекле фәлсәфи фикер әйтелә: үткәндә дөрес дип башкарылган эшләр бүген ялган буларак бәяләнә. Баба-

лары башкарганга балалары тискәре мөнәсәбәттә – моны М. Гафури яшәеш кануны дәрәҗәсенә күтәрә. Заман узар, балалар башкарганга да киләчәк буыннар шундый ук бәя бирерләр, дигән соңгы юлларга сыйган сүзләр:

*Бара торгач, шундый кызык заман килер:*
*Вакыйг булыр боларга да тел озатмак,* –

дәлил булып килә. Сәләф (бабалар) – хәләф (балалар); хак (дөрес) – батыйль (ялган); камил – ахмак антиномияләре суфичыл эчтәлеккә ишарә ясап, шагыйрь тагын да зуррак гомумиләштерүгә китерә: дөньяда хакыйкать юк (*«Табылмады бу дөньяда һич заман хак»*), бер заманда дөрес дип уйланганнар кешелек тарихында тискәре бәясен ала.

Шагыйрьнең «Үткәннәр» (1909) шигыре, беренче карашка, башланган сүзне дәвам итә. Әсәрдә шул ук «сәләфләр», «хәләфләр» гыйбарәләре кулланылган:

*Сәләфләр урнына калган хәләфләр*
*Туганда ук сукыр булып туганнар.*

Шагыйрь үткәннәргә (бабалар) һәм килгәннәргә (балалар) бәя бирә. Шулай ук антиномияләр чылбыры китерелә: арысланнар – куяннар; хөрмәтле җаннар – начарлар; каһарманнар – ишаннар; гөлләр – кыр, шалкан, суганнар. Әсәрдә идея белдерелгән соңгы юллар сүзне милләт тарихына, татарларның бабаларына алып китә:

*Фикер кыйл син! Аларның урны булды*
*Алынган җир – түгеп кап-кара каннар!..*

Шушы сүзләре белән, шагыйрь яшь буын (хәләф) укучыга мөрәҗәгать итә, анда бабалары белән горурлану хисе уятырга омтыла. Татарларның бабалары – каһарманнар, хөрмәтле кешеләр иде, дигән фикер иҗтимагый-тарихи эчтәлекле.

М. Гафуриның «Күңел» (1909) шигырендә дә охшаш күренеш күзәтелә. Шигырь күңелгә риторик эндәш формасында язылган. Каләм милләткә хезмәт итү, көрәшү, уяту, күңелләрне кузгату көченә ия. Шагыйрь каләмнең меңләгән гаскәрне җиңә алуына ышана:

*Залимы — телсез, сине галиб итәр тугъры каләм,*
*Ничә йөз мең гаскәри мәгълүб итәр үткен каләм.*
*Чык сугыш мәйданына тиз шул ике корал илә,*
*Чын, ышан! Куәт шуларда, башканы эзләп чикмә гамь.*

Шигырьдәге төп фикер дә каләм-сүзнең дөньяга баш булуын дәлилләп яңгырый:

*Хакыңы исбат итәм дисәң, каләм-сүзгә сарыл,*
*Ушбу көндә дөньяга болар хаким, болар король.*

Шул рәвешле, милләтнең киләчәге, бүгенгесе язма сүз, әдәбият белән бәйләп куела.

М. Гафуриның күп кенә шигырьләрендә гыйсъянчылык билгеләре, чаткылары күренә башлый («Хәят юлында» (1913) һ.б.). Бу яктан, «Көч» (1916) шигыре аеруча кызыклы. Ул ике кисәктән тора. Беренчесе көч исеменнән сөйләнә, көч үзен «*хакиме мотлак», «җир йөзендә Ходай*» дип белдерә. Икенче кисәк лирик геройга сүз биреп, көчнең шартлавын, вак-вак көчләргә таркалуын әйтә. Бу өлештә фәлсәфи фикер көчнең хаклык исеме белән эш йөртүен, кешелекне алдап яшәвен белдерә. Шагыйрь «кара көч» — татар әдәбиятындагы мәгълүм искелек символына мөрәҗәгать итә. Искелек һәм мәңгелек хакимлеккә омтылу янәшәлеге тудырыла. Лирик герой исә бу көчнең кайчан да булса бер юкка чыгачагына ышана, җәмгыятьне үзгәртү, киләчәкнең матурлыгы кешенең үз кыйммәтен аңлавы аша мөмкин, дип шәрехли.

Фәлсәфәгә омтылу, аллегорик фикер сәләтенә ия булу М. Гафуридан мәсәлче ясый. «Ике кош» (1906), «Әтәч белән Сандугач» (1907), «Алмас ташы» (1910), «Сарыкны кем ашаган?» (1912), «Үгез белән Бүре» (1913) кебек күпсанлы мәсәлләре татар әдәбиятындагы әлеге жанр хәзинәсендә иң матур үрнәкләрдән санала.

Шулай итеп, «без белә торган инкыйлабчы-шагыйрь» М. Гафури иҗатында 1917 елга кадәр бөтенләй башка мотивларның, үзгә моңнарның өстенлек иткәнлеге күренә. Ул чын мәгънәсендә милли шагыйрь, философ-шагыйрь булып таныла. Замандашларының җыентыкта урын алган

язмалары татар иҗтимагый-мәдәни тормышының әйдаманнары – Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Сәгъди, К. Тинчурин, М. Җәлил каләме белән язылу факты үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. М. Гафуриның әдәби талантын хөрмәтләү, аны татар әдәбиятының алгы сафындагы каләм иясе итеп тану белән беррәттән, әлеге язмалар Гафури иҗатын төрле яклап бәяләве белән дә кадерле.

Г. Тукайның «Мәкаләи махсуса»сында Казаннан килгән талант иясенең Уфада яшәп иҗат итүче милләттәшен-каләмдәшен үзе белән бер дәрәҗәгә куеп язуын күрмәү мөмкин түгел! Ф. Әмирхан да үз язмасында, әйтерсең лә, шушы ике шагыйрьнең абруен янәшә урнаштыра; шагыйрьнең коры нәсыйхәтче яки милләтче булмавын дәлилли; мисаллар китереп, М. Гафури иҗатының зурлыгын, тирәнлеген исбатлап бара.

Г. Исхакыйның «Үги балалар» (1908) басылу уңае белән язылган тәнкыйть мәкаләсе Гафурига иҗади камилләшү юлларын сыза! Чыннан да, язучының проза каләме Исхакый күрсәткән, психологизмны, типиклаштыру-гомумиләштерү мөмкинлекләрен тулырак файдалану, геройларның сөйләмендә чынбарлыктан ераклашмау, жанрлар ачыклыгына ирешү юлы белән үсеп китә.

Күренекле әдәбият тарихчысы һәм теоретигы Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (1926) һәм «Символизм турында» (1932) хезмәтләреннән алынган ике язмасы М. Гафури иҗатына концептуаль фәнни бәя буларак кызыклы. Аларда М. Гафуриның шигырьдә иҗат эволюциясе: мәгърифәтчелектән милли шагыйрь булып үсүе, символизм агымында эзләнүләре – кебек тезеп күрсәтелә.

К. Тинчуринның мәкаләсе Мәҗит Гафуриның драматургия өлкәсендә иҗатын, эшчәнлеген, татар операсы тудыруга керткән зур өлешен шактый тулы, әтрафлы анализлый, күз алдына бастыра. М. Җәлилнең күләмле хезмәте исә М. Гафури иҗатын тулаем күзәтүе, бу иҗаттагы төп мотивларны, темаларны, жанрларны аерып чыга-

руы, язучының омтылышларын ачык күрсәтә алуы белән аерылып тора.

1917 ел инкыйлабына шигарь, гимн булырлык текстлар иҗат иткән талант иясенең бу сәяси үзгәрешләргә мөнәсәбәте тиз үзгәрү хакында без соңгы арада гына сөйли алдык. «Татар байрагы» (1917) шигырендә инкыйлабны – 400 ел элек ауган татар байрагын кабат элү, милләтнең киләчәген мәңгелеккә юнәлтү дип санаган («*Тәкърар эленгән / Байрак инде аумас./ Татарның исеме / Мәңге югалмас*») шагыйрь 1921 елдан тирән борчулар, төшенкелек халәтенә керә. Ачыктан-ачык фикер белдерү инде мөмкин булмаган бер чорда аның:

*Күп кешеләрне тереләй җиргә тыкты Октябрь,*
*Октябрьне сөймәгәннәргә казылды зур кабер.*

(«Сәйфи Кудашка», 1922)

кебек юллары, кайбер башка («Яңа көчләр», 1923) шигырьләре гражданлык батырлыгы да, үз ялгышуын тануы булып та ишетелә. Шул ук вакытта 1933 елны иҗат иткән «Ленинизм минем маягым» шигыре асылда Гафуриның үз мәсләгенә тугры калуын, гаделсезлекләргә, тарихи хаталарга ачынып-сызланып, үкенеп алса да, инкыйлабны милләтләр өчен тормышны үзгәртү мөмкинлеге итеп санаудан туктамавын исбатлый.

Шигърияттә генә түгел, прозада да ике төп магистраль юнәлеш буйлап хәрәкәт иткән М. Гафуриның совет дәверендә бер юлын гына пропагандалау булганлыкны әйтергә кирәк. «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» (1902), «Ачлык, яки Сатлык кыз» (1907), «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» (1907), «Исәпсез байлык» (1912), «Кара йөзләр» (1926), «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1931) кебек тәнкыйди-мәгърифәтчел, күбесе сентиментальлек яки натурализм белән өретелгән, 1917 ел инкыйлабына кадәр татарларның авыр, караңгы тормышын сурәтләгән повестьлары XX гасыр дәвамында кабат-кабат нәшер ителә, анализлана. Дөрес, алар турында сүз алып барылганда да сентиментальлек яки натурализм алымнарына «күз йо-

мып», әсәрләрне кырыс реализм кысаларына утырту тенденциясе хөкем сөрә.

Җыентыкка М. Гафури иҗатына карата 1920–1930 елларда, аеруча аның юбилей мөнәсәбәте белән 1923 елны әзерләнгән мәкаләләрне үзгәрешсез урнаштыру чор атмосферасын, аерым бер язучылар иҗатына тенденциоз бәя урнашуның җирлеген күрергә ярдәм итә. Кызганычка каршы, кайбер язмаларда (М. Йосыпов, Г. Баймбәтов), М. Гафури иҗатындагы эшче-крестьян, сыйнфый тигезсезлек мотивларын калкуландыру белән бергә, аның әдәби эшчәнлеген Гаяз Исхакыйлар, Ф. Әмирханнар талантына каршы кую, татар әдәбияты классиклары иҗатына кизәнү аяныч бер тәэсир калдыра.

Мондый төгәлсезлекләр XX–XXI гасыр чигендә, яңа буын әдәбият галимнәре тарафыннан төзәтелде. Хәер, М. Гафурины яңача өйрәнү совет чорында ук башланган иде. Җыентыкка кертелгән М. Мәһдиев хезмәте шуның ачык дәлиле булып килә. Анда М. Гафуриның иҗади фикерләве, дөньяга карашы формалашу да, цензура белән катлаулы мөнәсәбәтләре дә игътибарга алына. Чәчмә иҗатына күзәтү ясап, М. Мәһдиев «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» повестен Европа әдәбиятлары югарылыгындагы әсәр дип бәяли. Шигърияттә урынын барлап, Тукайдан соң икенче реалист-шагыйрь икәнлеген ассызыклый.

Ф. Галимуллин, Х. Миңнегулов язмаларында инде М. Гафуриның тормышы-эшчәнлеге, күпкырлы олы иҗаты идеологик чикләүләрдән арынып, җентекләп, тирәнтен анализлана.

Р. Рахманиның татар балалар әдәбиятында М. Гафуриның урынын барлавы, Г. Азаматованың язучының иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген, карашларын анализлавы, Р. Хөснетдиновның «Шура» журналында уздырылган «Кәлям мөсабәкасы – Тел ярышы» турында язмасы да укучы өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Әлбәттә, М. Гафуриның «Болгар кызы Айсылу» (1910), «Тәэссорат. Җәй көненең төнге ай яктысында» (1913), «Бу

кемнең кабере?» (1913), «Хан кызы Алтынчәч» (1913) кебек әсәрләрендә татар әдәбиятын эстетик, яңгыраш, образлылык ягыннан үзгәртү, милли проблематиканы эмоциональ-тәэсирле формага төрү омтылышы совет чорында игътибардан читтә калып килде. Әдипнең иң матур һәм мәгънәле әсәрләреннән, яшь кыз күңелендә егет хатлары тәэсире белән мәхәббәт туу процессын күзәтеп барган, XX гасыр башы яшьләренә үзара мөнәсәбәтләрнең, сөю һәм гаилә коруның акыл белән, бер-береңнең холыкфигылен сынап башкарылырга тиешле гамәлләр булуын күрсәткән, гомумән, гашыйклар аралашуының өр-яңа бер үрнәк моделе кебек кабул ителә торган – романтик «Мәхәббәт хатлары» (1912) да хәзергә мәктәп һәм вуз дәреслекләрендә үзенә лаек урынны алмаган әле. Җыентыктагы тәнкыйди, аналитик материаллар арасында әдипнең мондый эзләнүләренә кагылышлы күзәтүләр дә байтак. Алар бу иҗатка кабат-кабат әйләнеп кайту сукмакларын да күрсәтәләр.

Әйтик, М. Гафуриның «Тәэссорат. Җәй көненең төнге ай яктысында» (1913) фәлсәфи нәсере, гомумән, татар әдәбияты өчен гаҗәеп бер әсәр була. Беренче карашка тулысы белән табигать матурлыгын күрсәтүгә багышланган, хикәяләү «без» исеменнән алып барылган нәсердә җентекләп кичке рәхәтлек-гүзәллекне тасвирлау шулкадәр тәэсирле килеп чыга, аны татар әдәбиятындагы беренче шигъри проза үрнәге итеп тә карау мөмкин.

Әсәрдә чын матурлык табигатьнең тынлыгы тудырган илаһи, серле, матур халәт итеп күрсәтелә. Әйтерсең лә бар табигать, шушы тынлык алдына тез чүгеп, аны бозарга җөрьәт итмичә тора. Шушы халәт иң югары ноктасына җиткәч, әсәргә сандугач образы килеп керә. Дини-суфичыл күзаллауда сандугач – Аллага якынаю юлына чыккан кеше символы; әдәбиятта илаһи гыйшык җырчысы да, җирләшкән сөюне җырлаучы да булырга мөмкин. Әсәр эчендә символның төрле модификацияләре бер-берсенә каршы килми. Язучының фәлсәфи фикере гүзәл-

лекне күрә белүче кешеләрнең җир тормышын чистартуын искәртә: кош сайраган саен, җир йөзе матурлана, илһам белән тула бара һәм «*һичбер җинаять вә усаллык эшләнмәгән арзы мөкаддәс сурәтен*» ала. Кош тавышы туктаганнан соң, агач яфраклары, ай, йолдызлар, Агыйдел суы хәрәкәткә килә, бу күренештән дулкынланган сандугач тагын сайрап җибәрә. Яшәештә һәр җан иясе мәхәббәт булганга тере, диюче хикәяләүче монологын мондый сүзләр белән төгәлли: «*Бу минутта һәрбер нәрсә тәэссернең иң ниһаясенә җиткән иде. Чөнки бу минутта җир өстендә чын мәхәббәт белән чын гыйшык хөкем сөрә иде... Аһ, чын мәхәббәт белән чын гыйшык...*».

Мәхәббәтне җирдәге иң олы матурлык дип белдергән хикәяләүче суфичыл сурәтләр ярдәмендә аны табигатькә яңа, мәрхәмәт белән сугарылган гүзәллек бирү сәләтенә ия көч, яшәештәге хакыйкатьне сиземләү итеп карый. Мәхәббәт нинди хакыйкатьләрне сиземләргә ярдәм итә соң? Җир тормышыннан тыш, нindидер өстен көч, куәт барлыкны; искиткеч матур бу дөньяның борынгыдан бернинди җинаять һәм усаллык эшләнмәгән изге җир булганлыгын; җир йөзендәге һәммә нәрсәнең җанлы һәм бербөтен организм икәнлеген; шушы һәммә нәрсәләрнең: табигать һәм кешенең, җир һәм күкнең бер-берсен яратып яшәргә тиешлеген, ягъни яшәешнең төп кануны – мәхәббәт икәнлекне! Әшьялар – феноменаль дөньядагы әйберләр, ай – пәйгамбәрлек хакыйкате, аның хиҗабсызлыгы серен ачуы символлары, сандугач, су, ай, тынлык, сер, гыйшык кебек дини-суфичыл әдәбиятта танылган сурәтләр әсәрнең ике төрле укылышын, традицион динисуфичыл һәм аның трансформацияләнеп дөньяви фәлсәфә, идеализм фәлсәфәсе төсендә белдерелүен тәэмин итә. Илаһи мәхәббәт хакыйкатькә төшенү, хәтта шуның аша тормышны, яшәешкә мөнәсәбәтне һәм, ахыр чиктә, кешене үзгәртү юлы дип билгеләнә.

М. Гафуриның «Болгар кызы Айсылу» (1910) хикәясе чибәр, акыллы, нәзакәтле Айсылуның авырып үлүен

сөйли, кызны матурлык идеалы итеп күтәрә. Аның болгар кызы булуын әсәр исеменә чыгару башка бер эчтәлек хасил итә: кыз образын милләт символына әйләндерә. Язучы үлемнең яшәүне, матурлыкны, мәхәббәтне юкка чыгарырлык көче аны башкалар өчен сызлану чыганагына әверелдерүен калкуландыра. Үлем — котылгысыз, дигән фикер кешегә, матурлыкка, мәхәббәткә, хәтта милләткә карата әйтелгән булып аңлашыла.

Халык авыз иҗатына, мифлары-легендаларына нигезләнеп, М. Гафури берничә әсәр иҗат итә. «Хан кызы Алтынчәч» (1914) шундыйлардан. Ул Агыйдел буена балык тотарга килгән егетләргә балыкчы бабайның хикәят сөйләве кебек язылган. Имеш, борын заманда ханның Алтынчәч исемле кызын сорап яу килгән. Кыз риза булмагач, сугыш башланган. Ләкин хан гаскәре җиңелеп, сугышта яраланган Алтынчәч белән дус кызы Каракүз, алар белән бергә хан казнасы тау тишегендә югала. Шул рәвешле, карт өчен дә, хикәяләүче һәм егетләр өчен дә узган, милли тарих — сокланырлык һәм горурланырлык кыйсса. Символга әверелгән Алтынчәч образы азатлык өчен көрәшүгә дан җырлый, иреген яклап үлемгә барырга җөрьәт иткән кыз идеалга әйләнә. Димәк, азатлык хакына көрәшүче халык хәтерендә саклана, онытылмый, җуелмый.

М. Гафуриның «Бу кемнең кабере?» (1913) нәсере охшаш фикер белдерә. Билгесез кабер ташына риторик эндәш кебек язылган әсәр узгандагыларның онытылуына олы үкенеч белән тулы. Вакытларны тоташтыручы кабер ташы — илаһи, үткәннән калган бердәнбер шаһит һәм истәлек. Әсәр исә укучыга татарларның данлы вакытлары, кыю бабаларның шанлы дәүләт төзү хыяллары хакында сөйләү, милләтнең хәтерен яңартып, онытылганнарны хәтергә төшерү максаты белән язылган. Хикәяләүче тарих сөйләп кенә калмый, билгесез кабергә чәчәк сала. Чәчәк идея-символны — кабер ташына салынган мәгънәне көчәйтеп, узганы барның киләчәге булырга тиеш, дип раслый. Автор белән тәңгәлләшкән хикәяләүче исә, үз

гомерен шул фикерне ишеттерүгә багышлаган шәхес булып гәүдәләнә.

Шулай итеп, М. Гафуриның прозадагы бу сукмагы романтизм, модернизм, символизм алымнары белән тәҗрибәләр ясавы, милли сүз сәнгатебез өчен кулай әдәби техника булдыру омтылышлары, шуның белән татар әдәбиятын үзгәртү юлларын барлавы хакында да сөйли. Язучының әлеге әсәрләре — бүген аны прозаик буларак ачу, укучыга күрсәтү өчен мөһим текстлар булуын да искәртергә кирәк.

М. Гафури иҗатындагы, эшчәнлегендәге тагын бер шөбһәсез сыйфат — ул аның Башкортстанны, туган җирен, мондагы мохитне яратуыдыр, мөгаен. Аның «Тугайда» (1914) шигырендәге юлларны укыганда бу яратуны տоймау, күрмәү мөмкин түгел:

*Безнең авыл тугаенда үсеп тора бер каен,*
*Җаннан артык бу җирләрне безгә биргән Ходаем.*
*Матур кара түбәтәем җомга көнне киямен,*
*Үз илемне, үз җиремне җаннан артык сөямен.*

Яки «Юлдан (Туган җиргә)» (1922) шигырендә:

*Кырымны мактаган чакта, «Бу — дөнья җәннәте!» диләр,*
*Шулай да юктыр анда Агыйдел, Дим, Ашказар, Инҗәр,* —
кебек тезмәләрдә шагыйрь үз хисләренең ихлас һәм саф булуын сөйли.

Шуңадыр, 1924 елда башкорт әлифбасы рәсми кабул ителгәч, башкорт язуында классик әдәбият туган вакытта, М. Гафури бик теләп бу барышка катнаша. Әлбәттә, Башкортстанда туып-үскән, шул җиргә хезмәт иткән татар улының иҗтимагый-мәдәни эшчәнлеге дә, башкорт әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше дә хуплауга һәм горурлануга лаек. 1923 елда М. Гафурига, иҗатының 20 еллыгы уңае белән, «Башкортстан АССРның халык шагыйре» дигән шәрәфле исем бирелә.

Җыентыкка әдәби әсәрләр сайлаганда, аларның язучыны төрле яклап, моңа кадәр укучыга билгеле булмаган яклары белән күрсәтә алу мөмкинлеге алга куелды, дидек.

Шуңа күрә дә М. Гафуриның 1912 елда Уфаның «Шәрык» матбагасында 41 бит булып басылган «Хәзрәте Рәсүлуллаһ галәйһи вәссәлләм вә дүрт хәлифә» дәреслеген дә җыентыкка кертергә кирәк таптык. Аны 1991 елны басмага Шәрык һәм исламият белгече Равил Үтәбай-Кәрими әзерләгән була. Татарның иң көчле дини уку йортларында белем алган М. Гафуриның пәйгамбәр һәм хәлифәләр турында гаять матур-йөгерек тел белән язылган бу хезмәте үз чорында мәктәп-мәдрәсәләрдә дә, халык арасында да яратып укыла, бүген дә мәгълүматлы, кызыклы, актуаль булып кала. Ул инде – М. Гафуриның дин нигезләрен тирәнтен белүе, ислам тарихына олы хөрмәт белән каравы турында сөйләүче чыганак.

М. Гафуриның «Адәм вә Иблис» поэмасы (1910) да гаять үзенчәлекле: ул кеше яратылу, аның оҗмахтан куылуы хакындагы мифны шәрехләү рәвешендә язылган. Ф. Ш. Сибагатов фикеренчә, М. Гафури Изге китаптан ук килә торган 4 легенданы: дөнья яратылу; Иблис һәм аны оҗмахтан тәмугка куу; Иблиснең Адәмне вәсвәсәгә салуы, кешеләрнең җиргә төшерелүе; Кабил һәм Һабил фаҗигасен файдалана; сюжетлардан ерак китми, кайбер урыннарда хәтта Коръәннән өзекләр кертә (мәсәлән, Иблис монологы «Әл-Хиҗр» сурәсе белән тәңгәл).

Шул ук вакытта автор аерым бер фәлсәфи фикерләрне калкытып бара. Җирне Алланың яратуы, аның Адәмгә тән, рух һәм акыл бирүе, аны зурлавы кабатланып, Иблиснең оҗмахтан куылуы исә, аның Адәмгә баш ияргә теләмәве белән бәйләп куела. Иблиснең тыелган җимешне Адәм һәм Хаувага ашатуын тасвирлаганда, язучы беренче гөнаһны кешеләрнең гомер чиклелегеннән котылырга омтылышында таба. М. Гафуриның Иблисе Хаувага болай дип эндәшә:

*Вакытча булмаса иде бу җәннәт, бу матурлыклар,*
*Булып тиздән бетә торган бу тормышта ни ләззәт бар?*
*Күз ачып йомган чаклы ләззәт яки төш төсле,*
*Кире килмәс булып беткәч, бу тормыш иң зур үкенечле.*

Шул рәвешле, җир тормышының чиклелеген ялгыш санау гөнаһ, дигән фәлсәфә белдерелә. Шуннан соң ук кеше фәлсәфәсенең берничә аспекты күренеп китә: гаепне башкалардан күрү («*Адәм баласы да шулай кыла бер-бер гөнаһ эшне, / Үзе саф, тап-таза кала, гаепле итә Иблисне*»); бәхетне хезмәт ярдәмендә тату – Алла кушкан эш булу («*Эш эшләү һәм гамәл берлән булыр бәндәләрем мәсгуд*») шундыйлардан. Поэмада дини фәлсәфәне кабатлап килгән урыннар да күп. Мәсәлән, VI бүлек тулысы белән оҗмахка керү өчен рухның сафлыгы кирәк булу, гөнаһлардан арынган очракта кешенең күккә ашу мөмкинлеге хакында сөйләүгә багышланган. Әсәр җир тормышын «авырлык дөньясы» (VIII бүлек) буларак бәяләп уза. Кешеләрне ялгышлардан тыю өчен, дин һәм закон уйлап табылганлыкны искәртә:

*Адәмнәрнең арасыннан яманнар бергә ун чыкты,*
*Шуңа карап заруратән шәригать һәм канун чыкты.*

Поэманың IX–X бүлекләрендә Кабил һәм Һабил хакындагы дини миф файдаланыла. Җирдә кеше каны коелу, туганны үтерү тарихын сөйләгәннән соң, хикәяләүче мәгърифәтчелек рухында нәтиҗә ясый:

*Бозыклык эшләмәс өчен, боларга дин генә җитми,*
*Күңелне чын гыйлем-вөҗдан белән бик ныклы беркетми.*

Шулай итеп, поэма дини миф ярдәмендә тормышка һәм кешегә бәя бирә. Авторның кешегә мөнәсәбәте шактый тискәре: гөнаһлы, кан коючы, усал кавем сурәте тергезелә. Кешене бозган, аны гөнаһка батырган нәрсә – нәфес, дигән фикер әсәрне үтәли кисеп үтә. Поэманың соңгы юллары Алланың үзе барлыкка китергән кешедән канәгать түгеллеген белдерә. Әйтерсең лә шагыйрь, дини-тарихи материалны тергезеп, аңа реконструкция ясап, үз заманы кешеләрен «адәм» дигән бөек исемгә лаек булырга, туктаусыз камилләшергә чакыра.

Фәнни язмалар арасында «Госманлы төрекләрнең әдәбиятларында кафияләр» дигән, төрки әдәбиятлардагы рифмалашу күренешен чагыштырма рәвештә тикшерүгә

багышланган хезмәт игътибарга лаек. Төрки халыклар, гарәп-фарсы, төрек әдәбиятлары тарихын яхшы үзләштергән, әдәбият теориясеннән мәгълүматлы автор бу очракта төрки халыклар әдәбиятлары контекстында татар поэзиясенең үзенчәлекләрен барлый. Әлеге язма каләм тибрәтә башлаган яшьләр өчен дә, әдәбият белән кызыксынучылар өчен дә игътибарга лаек.

Гафуриның публицистикасында да аның дин фәлсәфәсен, гыйлемнәрне тирәнтен белүе күренеп тора. «Үрмәкүчтән гыйбрәт алмалы» (1907) язмасы – милли рухлы, халыкны үзе сайлаган үсеш юлы буйлап һич туктамый хәрәкәт итәргә чакырган булса, «Гаҗәпләнмәгән идем, гаҗәпләндем» (1910) мәкаләсе сәяси-иҗтимагый эчтәлекле булып чыккан: милләт дип сөйләп йөреп тә, үз тормышында башка кыйммәтләргә йөз тоткан кешеләр сәяси тәнкыйть утына тотыла. «Бер милләтнең теле югалса (...) ул милләт үзе дә югала» дип башланган «Чуар тел» (1911) – Гафурины тел хәле, лексикология мәсьәләләрен яхшы белүче, телнең сафлыгын кайгыртучы каләм иясе итеп таныта. «Уфада кызларга махсус мәдрәсә салыну мөнәсәбәте белән» (1911) – әдипнең уку-укыту хәл-әхвәленнән хәбәрдар булуы турында гына сөйләп калмый, бәлки аның, кызларга нинди күләмдә, нинди эчтәлектә белем бирергә кирәк, дигән сорауга төпле җавабы булып та аңлашыла. Гафури татар кызларын тормышка әзерләргә, аларга XX гасырда көндәлек тормыш, иҗтимагый хәят өчен мөһим булган гыйлемнәрне җиткерергә кирәклеген алга куя. «Авыл халкы өчен файдалы китаплар вә земстволар» (1912) күләмле язмасы шулай ук халыкны агартуның бер юлына – китаплар, җыентыклар, вакытлы матбугатны мөмкин кадәр киңрәк тарату, халыкка җиткерү мәсьәләләренә багышланган. «Гомумән, авыл халыклары өчен файдалы булган рисалә вә китаплар – аларның тормыш вә хәрәкәтләренә якыннан тәгаллекъ иткән, тугърысы, аларның үзләренең тормышлары хакында, кәсепләре тугърысында язылганнарыдыр. Игенчелек, умартачылык,

бакчачылык, мал асрау, аларны үрчетү, нәселләрен яхшылату, үзләренең сәламәтлекләрен саклау, малларыны төрле авырулардан саклау хакында язылган рисалә вә китаплар авыл кешеләре өчен иң файдалы рисаләләрдән булырга тиешле дип беләм» дип язган журналист Гафуриның бу очракта да халык хәлен кайгыртуы, аның гыйлем даирәсен киңәйтү юлында төгәл күзаллавы күренеп тора. Бер яктан, ул земстволарны авыл хуҗалыгы турында китапларны күпләп таратуы өчен мактаса, икенче яктан, үз милләттәшләренең шуларга игътибарсызлыгы өчен сызлана. Муллаларга, имамнарга мөрәҗәгать итеп, аларның үз мәхәллә халкы өчен җаваплы булуын, халыкның карашын киңәйтү белән шөгыльләнергә тиешлеген, мондый файдалы китапларны популярлаштыру алар өстендә булганлыкны ассызыклый.

Язучының «Хатирәләр дәфтәреннән» дип исемләнгән көндәлек язмалары аның дөньяга хисси-сызланулы карашын, иҗатка һәм тормышка мөнәсәбәтен шактый тулы күзалларга ярдәм итә. Алардагы шигырьләр, кәеф-халәткә бәйле язып куйган парчалар, хәтта Гомәр Хәйямнан тәрҗемәләре шагыйрьне нечкә күңелле, һәр гамәлгә рухы кузгала торган эмоциональ шәхес буларак ача. М. Гафуриның үзе тарафыннан җыентыкларына кереш сүз итеп язылган материаллар да гаять кызыклы, шул ук вакытта алар каршылыклы фикер калдыралар. Язучы өйрәнчек әсәрләренең билгеле бер тарихи ситуациягә бәйле иҗат ителгәнен ассызыклый. Болардан аның үз иҗатына гаять нык таләпчән булуы күзгә ташлана. «Бер-ике сүз» (1920) язмасындагы: «Яшь вакытларымда язылган бәгъзебер нәзыймләрне, үзем артык яратып бетмәгәннәрен дә калдырмадым. Тугърысын әйткәндә, хәзинәмдә барын – шул көенчә халык алдына чыгарып салуны тиешле таптым. Нинди генә нәрсә булса да, үткән хәятнең бер тәэсире астында язылуында шөбһә юк, шулай булгач, аның бөтенләй югалмавы мәтлуб табылды»,– диюе шул хакта сөйли. Шушы ук юнәлештәге «Себер тимер юлы» дигән

әсәрем хакында берничә сүз» (1926) шагыйрьнең тәэсирле күңеленә, нечкә тойгылы холкына штрих булып та ята. Нәшриятка адресланган «Тәрҗемәи хәлемнән өземтәләр» (1930), шулай ук, гомер кичкән әдипнең үз тормышы-язмышы хакында уйланулары төсен ала. Алардагы төп фикер – әйләнеп кайтып була торган булса, шулай ук яшәр идем!

Шулай итеп, Мәҗит Гафури шигъриятендә дә, прозасы, публицистикасында да – шиксез, үз милләте, татар милләте хәлен, ваемын, кайгыларын һәм өметләрен җырлаучы, аның киләчәген кайгыртучы, XX йөз башындагы милли яңарышка юл күрсәтүче, татар әдәбиятының әйдаманы иде. Ул – милләте белән дә, иҗаты белән дә, иң беренче чиратта, татар язучысы, татар зыялысы, татар фикер иясе. Күпчелеге – моңа кадәр күләгәдә калган материалларга, М. Гафури фондындагы аз билгеле текстларга таянып әзерләнгән бу җыентык шушы фикерне ассызыклый.

Бу иҗатта шәрык һәм гареб әдәбиятларының тәэсире дә, татар әдәбиятында барган үзгәрешләр дә көзгедәге кебек чагылыш таба. Җәмгыятьнең яшәп килүче хәле белән риза булмыйча, һәрчак аны камилләштерергә омтылуы ягыннан аның иҗаты XX–XXI гасыр чигендә әйләнеп кайткан мираслар яктылыгында кабат тикшерүне көтә. Китап шушы юлда бер адым булып хезмәт итсен иде.

*Диләрия Абдуллина*

# Мәҗит Гафури: иҗатка багъланган тормыш, халыкка багышланган иҗат (1880–1934)

Мәҗит Гафури – татар һәм башкорт халыклары әдәбияты классигы, XX йөз башы татар милли шигъриятен һәм прозасын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән, тормышчан әсәрләре белән халык күңеленә уелып калган күренекле әдип. Гасыр сынауларын үтеп, үз бәһасен дәлилләгән иҗатының көче – халыкчанлыгында, милли азатлык, кешелеклелек идеалларын чын күңелдән яңгырата алуында. М. Гафури, замандашларының бик күбесе кебек,– үз тырышлыгы белән талантына юл ярган, шуның аша гадилектән галилеккә ирешкән шәхес.

Олы әдипне зур юлга алып чыккан сукмак башы халкыбызга шактый күп талантлы шәхесләрне биргән уңдырышлы Башкортстан туфрагыннан.

Мәҗит Гафури (Габделмәҗит Нургани улы Гафуров) 1880 елның 1 августында (иске стиль белән 20 июль) Стәрлетамак өязе Җилем-Каран авылында (хәзерге Башкортстан республикасы Гафури районы) гади крестьян тормышы белән яшәгән Нургани хәлфә гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә.

Җиде-сигез яшьләрендә авыл мәктәбенә укырга йөри башлый. 1893–1895 елларда күрше Үтәш авылы мәдрәсәсендә сабак ала. Әлеге мәдрәсәдә укуының беренче елында ук кыш көне – әтисе, март айларында әнисе Мәрзия дә үлеп китә. Унөч яшеннән тулы ятим булып калганлыктан, аңа тормыш итү һәм белем алу бик авырга туры килә.

1896 елның сентябрь айларында ул, укуын алга таба дәвам иттерү максаты белән, Уфага юл тота. Әлбәттә, яр-

лы егеткә «Госмания» мәдрәсәсендә уку насыйп булмый, белеме андагы шәкертләрнекеннән һич тә ким булмаса да, туган йорттан ярдәмчесез, акчасыз хәлдә монда уку мөмкин түгеллеген аңлап, кире борылырга мәҗбүр була. Кайтышлый Уфадан ерак булмаган Кыешкы (хәзерге Кырмыскалы районы Иске Кыешкы авылы) мәдрәсәсенә туктала һәм декабрь аена кадәр шунда укый.

Тормышының матди ягы бик авыр булганлыктан, монда да артык кала алмый, яңадан авылга кайтып, Уфадан килгән Җамалетдин исемле яшь мулладан дәресләр ала һәм үзе дә аңа балалар укытуда булыша. Шуннан кергән акча белән өс-башын да карый, бераз матди ягы да рәтләнеп китә.

1897–1898 елларда, балалар укытудан тыш, төрле урыннарда яллы хезмәттә, Лапашты кирпеч заводында эшли.

1898 елның җәендә, 450 чакрым чамасы араның күбрәген җәяүләп үтеп, Рәсәйнең иң мәшһүр мәдрәсәләреннән берсе булган Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсенә укырга килә (мәдрәсәгә нигез салучы һәм аның мөдәррисе — күренекле зыялы, Рәсәй мөселманнарының атаклы дин эшлеклесе Зәйнулла ишан Рәсүли). Бу уку йорты яшь шәкертнең шәхес буларак өлгерүенә зур гына йогынты ясый, аның иҗади эшчәнлеге дә нәкъ шушы чорда башлана. 1902 елда ул «Ишан шәкертләренә» исемле сатирик шигырен яза, әмма ул әсәр сакланмаган.

М. Гафури Троицк мәдрәсәсендә укыганда олы хезмәт мәктәбен уза: җәйләрен казакъ-кыргыз даласына чыгып бай балаларын укыта, Рәмиевләрнең алтын, Яушевларның торф приискаларына сезонлы хезмәткә яллана, тиречедә чыра очлый, байларга ялланган кешеләргә ашарга әзерли, икмәк сала, урак ура, мәдрәсәдә сукыр суфиларга китап укый, бай балаларына ашарга пешерә. Шулай итеп ул үз тормышын тәэмин итәрлек мөмкинлекләр таба.

Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укуының соңгы елларында «Хезмәт» көтепханәсе аша яңа басылган китаплар, көндәлек матбугат белән танышып бара, «Тәрҗеман»

газетасының һәр санын калдырмый укый, махсус рәвештә өч ай рус телен өйрәнә. Казакълар арасында мөгаллимлек иткәндә заманына күрә аңлы, яңалык тарафдары булган, үзе дә шигырьләр язарга яратучы Урынтай хаҗи белән аралашу, шәкертләр арасында да искечә укытуга каршы тору, надан хәлфәләрне кире кагу рәвешендә башланып киткән хәрәкәтләрне күрү яшь Мәҗиткә тормыш каршылыкларын тирәнрәк төшенергә ярдәм итә.

Алда искәртелгәнчә, аның иҗат эшенә тартылуы да «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыган елларда башлана. «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» (1902) хикәясе һәм «Себер тимер юлы, яки Әхвәле милләт» (1902), «Вә иннә мин әш-шигъри ли хикмәтин» (1903), «Яшь гомерем» (1903) кебек күләмле шигъри әсәрләре мәдрәсәдә укыган, казакъ даласында мөгаллимлек иткән елларда языла.

1905 елның яз һәм җәй айларын М. Гафури казакълар арасында уздыра. Август башларында Троицкига кайта, әмма монда да уку-укыту эшләрендә бер дә яңалык сизелмәгәнлектән, Иж-Буби мәдрәсәсенә юл тота. Бу уку йорты да аны канәгатьләндерми: бер атна чамасы торуга ук Казанга китә. 1905 елның августында килеп, кышны Казанда уздыра.

М. Гафуриның Казанда «Мөхәммәдия»дә укыган чоры революцион көрәшнең киң җәелгән көннәренә туры килә. Татар халкының милли азатлык хәрәкәте, Рәсәйне тетрәндергән Беренче рус революциясе үсмер егеткә көчле тәэсир ясый. Күңелендәге хисләр өермәсе тышка бәреп чыга, ул илдә барган сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә туган хыялларын, рухи куанычын халык белән уртаклашырга, бу көрәштә үз авазын ишеттерергә омтыла. «Яшь гомерем» исемле шигырь мәҗмугасын тәмамлап нәшриятка бирә. Моннан тыш, яңа ачылган «Йолдыз», «Казан мөхбире» кебек газеталарда шигырьләр, мәкаләләр бастыра.

1905–1906 еллардагы иҗади эшчәнлеге тулысы белән Казандагы мохит, иҗтимагый-сәяси, мәдәни шартлар белән бәйле. Болар М. Гафуриның дөньяга карашын-

да тирән үзгәрешләр тууга, шагыйрьлек сулышы ачылуга сәбәп була. Шул тәэсирләр йогынтысында язылган «Милләтемә шатлык шигыре»ндә (1905) ул халкыбызның киләчәген оптимистик рухта сурәтли.

1906 елда Уфаның «Галия» мәдрәсәсенә күчә. Анда бер ел – рәсми, ике ел ирекле тыңлаучы буларак укып йөргәннән соң, 1909–1912 елларда бары иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

1907 елда ул ахыргы тапкыр казакълар арасында балалар укыта. «Милли шигырьләр» циклына кергән әсәрләрен иҗат итә. «Мәктәпләрдә шәкертләр укырлык төрле шигырьләргә бик зур ихтыяҗ күренә, һәм күргән бер мөгаллим мәктәп балалары өчен махсус шигырьләр язылуын миннән сорыйлар. Шул тәэсирләр аркасында «Милли шигырьләр» исемендәге шигырьләрне яздым»[1],– дип искәртә ул үзе бу хакта.

1909 елның августында М. Гафури үзе кебек үк ятимлек аркасында тормыш авырлыгын шактый күп күргән Зөһрә (1891–1938) исемле кызга өйләнә. Аларның ике уллары: Әнвәр (1910–1977) һәм Халит (1919–1935) туа.

1907–1909 еллар – М. Гафуриның тыныч һәм актив иҗат иткән чоры. 1908 елда Оренбургта чыккан «Шура» журналының тәүге санында да, Уфадагы «Шәрык» типографиясендә дә, басмаханәләрнең беренче китабы буларак, аның шигырьләре («Милли шигырьләр») басыла. Бу елларда Казан, Оренбург, Уфа нәшриятларында дистәгә якын шигырь китабы, тугыз хикәя җыентыгы, газета-журналларда күп кенә публицистик мәкаләләре дөнья күрә.

Беренче рус революциясеннән соң туган эзәрлекләүләр белән М. Гафури 1911 елда очраша башлый. Шагыйрьнең 1907, 1911 елларда Казанда «Шагыйрь Мәҗит Гафуриның милләт мәхәббәте нам әшгаре» исеме белән басылган шигырьләре патша цензурасы кулына килеп керә. Жандарм чиновниклары китапның юлга-юл тәрҗемәсен өйрәнәләр

[1] Мәҗит Гафури.– Әсәрләр: Дүрт томда. Т. 4. Совет чоры прозасы.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1981.– 473 б.

(тәрҗемәне профессор Н. Ф. Катанов эшли.) Әлеге китап, бигрәк тә андагы «1906 елдан 1907 елга васыять», «Җиденче елның җавабы» дип аталган ике шигырь, цензура хезмәткәрләрендә ризасызлык тудыра.

1911 елның 11 февралендә Уфадагы «Шәрык мәтбагасы»нда уздырылган жандармерия тентүе дә М. Гафуриның «Үги балалар» һәм «Яшь гомерем» җыентыкларын «аеруча хәтәр китаплар» исемлегенә кертеп конфискацияли.

1912 елда ул Кәримовларның Уфадагы «Шәрык» матбагасына корректор булып урнаша, анда 1917 елның октябренә кадәр эшли. Бу елларда актив иҗат эше белән шөгыльләнә. Илдәге иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны, империалистик сугышны, халык күңелендәге ризасызлыкның артканнан-арта баруын, революцион киеренкелек дәверен реалистик гәүдәләндергән «Ирек өчен көрәш», «Үзем һәм халкым» (1912), «Фитрәт заманы», «Кыямәт» (1914), «Юктырсың ла, Алла», «Язмыш» (1915) шигырьләре, изгелек белән явызлык, гаделлек белән ялган һәм тормыштагы күп кенә башка каршылыкларны хөкем итүгә юнәлдерелгән күпсанлы мәсәлләре, сугышның авыл халкы өчен тудырган фаҗигаләрен гәүдәләндергән «Солдат хатыны Хәмидә» повесте (1915) һәм тарихи үткәнебезгә, яшәеш фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итеп, романтик рухта иҗат ителгән «Тәэссорат», «Бу кемнең кабере?» (1913), «Хан кызы Алтынчәч» (1914), төрекчәдән ирекле тәрҗемә булган «Бер чәчәкнең наләсе» (1911) кебек укучы күңелен кузгатырлык нәсерләрен һәм хикәяләрен яза.

Октябрь инкыйлабыннан соң иҗат ителгән «Бир кулыңны» (1919), «Урак белән чүкеч» (1921), «Беренче май» (1922), «Кызыл гаскәрләр җыры» (1928), «Мин – ватанчы» (1932), «Ленинизм – минем маягым» (1934) кебек бик күп шигырьләре шул рухта язылган. «Эшче» (1920) поэмасы, «Кара йөзләр» (1926), «Тормыш баскычлары» (1927) повестьлары һәм «Тәрҗемәи хәлем», «Баштан үткәннәр» (1923), «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1930) кебек автобиографик әсәрләре әдәбиятыбызда гади ха-

лыкның революциягә кадәрге тормышын чагылдырган үзенчәлекле бер катламны тәшкил итәләр. Язылу вакыты күрсәтелмәгән, романтик рух белән сугарылган «Серле бер мәхәббәтнең тарихы» әсәрен дә революциядән соң (1919–1920) язылган дип исәпләргә нигез бар.

Язучының әдәби тәнкыйтьтә уңай бәя алган «Кызыл йолдыз» (1926) пьесасы һәм «Эшче» поэмасын эшкәртеп иҗат ителгән шул исемдәге либреттосы да драма жанрын үстерүгә керткән өлеше буларак бәяләнә ала.

М. Гафури заманының әһәмиятле темаларын яктыртып, чор сулышын тоеп, халык, милләт җанын аңлап иҗат итүче шагыйрь-гражданин булу белән бергә, хыял канатларында илаһи биеклекләргә күтәрелгән романтик һәм кеше күңеленең иң тирән төпкелләрен ача алган лирик шагыйрь буларак та танылa. Татар, башкорт халыкларының иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышына үз өлешен кертеп, ил сәясәтен рухы аша кичереп яши. М. Гафуриның фидакарь хезмәте халкыбыз һәм дәүләт тарафыннан югары бәяләнә. 1923 елда Уфада һәм Казанда әдипнең егерме еллык иҗат бәйрәме үткәрелеп, аңа Башкортстан АССРның халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелә. Бу зур шәхесне олылап, РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты һәм Халык Комиссарлары Советының карары белән үткәрелә торган юбилей татар һәм башкорт халыкларының мәдәни тормышларында беренче зур бәйрәм була.

М. Гафури 1928 елга кадәр Уфада чыккан вакытлы матбугат редакцияләрендә эшли. Соңыннан бары язучылык эше белән генә шөгыльләнә. 1934 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

Танылган халык шагыйре М. Гафури 1934 елның 28 октябрендә Уфа шәһәрендә туберкулёз авыруыннан үлә. Уфа шәһәрендәге бер урам һәм Башкорт академия драма театры аның исемен йөртә. Уфада М. Гафуриның музей-йорты эшли һәм шагыйрьгә һәйкәл куелган.

***

М. Гафуриның башлангыч чор шигърияте милләтне гыйлемле булырга өндәү, тәрәккъыять, гомумкешелек идеалларына теләктәшлек күрсәтүе белән характерлы. 1902–1904 елларда басылып чыккан шигырьләре һәм «Себер тимер юлы», «Вә иннә мин әш-шигъри ли хикмәтин», «Яшь гомерем» кебек беренче поэмаларында ук инде шагыйрьнең күңел халәте, иҗат идеаллары шактый тулы гәүдәләнеш алган. Бу әсәрләрендә аның җәмгыятьтәге һәр кимчелекне наданлыктан күрүе, мәдәни үсеш барлык кешеләргә дә бәхет китерер дип чын күңелдән ышануы сизелә. Шунлыктан аларда үгетләү, коры дидактика өстенлек итә, шагыйрь тәрбиялелек, белем, һөнәр, әдәплелек, милли тәрәккъыять мәсьәләләрен күтәрә һәм әлеге камиллеккә ирешү юлларын шәхеснең үз тырышлыгына һәм Алла кодрәтенә бәйлелектә карый.

Аурупа яңарыш юлына кереп барганда, Рәсәй дә шул агымга кушылганда, мөселманнарның бу күтәрелештән читләшүләре аны борчуга сала, аның сәбәпләренең шәригать кануннарына бәйлелеген күреп, тәрәккъыять һәм шәригатьнең каршылыкка кермәвен мөселманнарга да аңлатырга, шул ук вакытта һөнәрсезлек, наданлык, дөньяви үзгәрешләрдән читләшүнең милләтнең бетүенә китерәчәген искәртергә тырыша.

«Себер тимер юлы, яки Әхвәле милләт», «Яшь гомерем» кебек әсәрләренең дә төп идея эчтәлеге шуңа кайтып кала. «Себер тимер юлы» поэмасы Рәсәй дәүләтен мактау рухында язылган. М. Гафури бу юлның үзе үк җаны-тәне белән яклаган гади халыкның кан-яше һәм сөяге өстенә төзелүе турында уйлап тормастан, тәрәккъыять яссылыгыннан карап, Рус дәүләтенә никадәр мактау укыса да, әсәр тарихи яктан заманга объектив бәя бирүе белән дә әһәмиятле. Поэмада XIX йөз ахырындагы Россиядә яшәүче халыкларның хәле, дәүләтнең тышкы сәясәте шактый тулы гәүдәләнеш алган.

«Яшь гомерем» поэмасы – гомер баскычлары, яшьлек бәһасе, яшәү мәгънәсе турында уйланулар рәвешендә язылган фәлсәфи-дидактик әсәр. Автор күзаллавында, яшьлек – җиһанда тиңе булмаган кыйммәт. Шул кыйммәтне аңлый белгән кеше – «хәйрел-әнам» (тиңдәшсез энҗе). Тәвәккәллек, иҗтиһад итү – максатка илтә, ә иң зур максат – гыйлем һәм һөнәр.

Иҗатының тәүге адымнарыннан ук шагыйрь гаделлек булмаган, бөтен нәрсә капиталга корылган тормыштан ризасызлык белдерә, мәдәни инкыйлаб, милли тәрәккыять тарафдары буларак чыгыш ясый, мәгърифәтчеләрдән килгән акыл культын олылауның чикләрен киңәйтеп, техник прогресска дан җырлый.

Шәкертлек елларында ук М. Гафури каләм көчен проза өлкәсендә дә сынап карый. «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясе – 1902 елда язылган беренче проза әсәре. Бу хикәя үзенең темасы, эчтәлеге ягыннан да, ярлы халык тормышын бөтен чынбарлыгы белән натуралистик гәүдәләндергән әсәр булуы белән дә татар прозасына көтелмәгән яңалык кебек килеп керә, моңа кадәр шәрыкның романтик әсәрләрен укып яшь түккән, я дини-дөньяви эчтәлекле әсәрләр белән генә таныш булган татар укучысына үз яшәешенә читтән күз салырга ярдәм итә.

Әсәрдәге вакыйгаларда, капиталистик җәмгыять һәм шәхес арасындагы каршылыкка караганда, геройларның үзара мөнәсәбәтләрендәге әхлаксызлык һәм тәрбиясезлекнең фаҗигагә юл ачуы калкурак бирелгән.

М. Гафуриның, шигъриятендәге кебек үк, беренче проза әсәрендә дә: «Иҗтиһад юк, әдәп юк – бу фәкыйрьлеккә китерә, һәр фаҗиганең башы шунда»,– дип әйтергә теләве ачык аңлашыла. Әле ул бу әсәрендә гыйлем алу мәсьәләсенең турыдан-туры социаль тигезсезлек белән бәйлелеген ачуга ирешә алмый. Бу хакыйкать соңрак, беренче рус революциясе сынауларын узганнан соң язылган «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» повестенда гына гәүдәләнеш ала.

***

Беренче рус революциясе М. Гафурига көчле тәэсир итә. 1905 елда язылган «Шатлык шигыре»ндә аның бу хисләре ачык чагыла:

*Алынды авырлыклар кулымыздан,*
*Манигъ юк бара торган юлымызда.*
*Хөррият заманнары каплап алды*
*Алдан, арттан һәм уң илә сулымыздан,—*

дип, шагыйрь революциянең бер талпынуда һәммәсен хәл итүенә ышана. Икътисади, рухи артталыкка, матди тигезсезлеккә, милли изүгә чик куярга тиеш дип санаган бу алмашынуны М. Гафури бөтен күңеле белән яклый, 1905 елда язылган «Алмашыну», «Хөррият дәверендә», «Инсаф вә иттифак», «Өндәү», «Вакыт йитте» кебек шигырьләрендә әлеге хәрәкәтне күтәреп алырга, берләшергә, мөмкинлектән файдаланырга чакыра.

Сәяси торышны бик нечкә тоемлаучы, яшь булса да тормыш тәҗрибәсе тупларга өлгергән шагыйрь тиз арада вакыйгаларның катлауланууын, халык көткән ирек һәм матур тормышның бер омтылышта гына корылмаячагын, искене җимереп, яңаны төзү өчен көрәшергә кирәклеген дә тиз төшенә. Дөрес, мәдрәсә белеме генә алган, артык зур сәяси әзерлеге булмаган М. Гафури өчен иҗтимагый шартлар гаять катлаулы, буржуаз революциянең ахыр максатларын ул тулысынча күзаллап бетерми, хөррият тә аның аңлавында дини, милли бәйсезлек буларак гәүдәләнеш ала. Дуслык, бердәмлек, тигезлек төшенчәләренә сыйнфый күзлектән чыгып караса да, иҗтимагый-сәяси каршылыкларны чишүдә, көрәш юлына басудан бигрәк, хезмәт кешесе булган күпчелек һәм өстен катлау вәкилләрен татулаштыру, сыйныфларны тигезләү турында хыяллана.

1905 елның канлы вакыйгалары, сәяси фикер ягыннан гаять алдынгы булган Казан мохитендә яшәү аңа революцион көрәшнең эчке каршылыкларын тирәнрәк төшенергә ярдәм иткән зур сәяси мәктәп була. Искит-

кеч каршылыклы, сыйныфлар арасындагы канлы көрәш белән узган бу вакыйгалар шагыйрьгә үзенең кыйбласын билгеләргә ярдәм итә. Ул азатлык хәрәкәтенең «асыл серенә» — коры сүзнең максатка илтмәгәнлегенә, милләтнең якты киләчәге, хезмәт кешесенең бәхете өчен көрәш кирәклегенә төшенә.

Әмма вакыйгаларның кинәт тискәре борылыш ясавы М. Гафурины «аптырау», «эч пошу» халәтенә китерә.

*Баш та юк бу заманда, аяк та юк,*
*Гаделлек дигән нәрсә беркайда юк.*
*Күземезгә әллә ничек күренсә дә,*
*Асылда бу эшләрдән һич файда юк,* —

дип, күңел төшенкелегенә бирелә («Эч пошу», 1906). Баштарак бу күңел төшенкелеге беренче рус революциясенең рәхимсез рәвештә бастырылуы, ул алып килгән корбаннар, ирешелми калган максатлар белән бәйле булса, алга таба аны 1907—1910 елларда азатлык хәрәкәтен буу өчен хөкүмәт тарафыннан җәелдерелгән реакцион хәрәкәт сызландыра. 1907 елда язылган «Шөбһә», «Мәкъсуд», «Безнең хәл», «Өметсезлектә» һәм 1909 елда язылган «Кайгы», «Юк», «Таләп» кебек шигырьләрендә «хөррият кояшы бату»дан, милләтнең асыл ирләрен яклаучы юктан, җәмгыятьтәге вөҗдансызлыктан, һәрнәрсәнең акчага сатылуыннан зарлана, аны реакцион көчләр тарафыннан кешенең намусы тапталуы, рухы изелүе рәнҗетә. М. Гафуриның лирик герое самодержавиенең канлы тырнагы эчендә җан асраучы, хокуксыз меңләгән Россия халкы исеменнән нәфрәтен сөйли, ач-ялангачларны кызгана, кайвакытта тормышка ризасызлыгын белдереп, бу вәхшилек белән тулы дөньяны калдырып китәргә, җир йөзендә табылмаган хөррияткә ирешергә тели:

*Әсир кыйлдың моңа чаклы мине, җир,*
*Бу көн инде китәм мин, хөррият бир.*
*Үзем китәм, бу җисмем синдә калсын,*
*Җисемгә ихтыяҗым юк, кадалсын!*

(«Таләп», 1909) «Кайвакытта» (1910) шигырендә дә дөнья ваклыкларыннан өстен калып, илаһият биеклегенә ирешү теләге сизелеп тора.

Кара реакция елларында илдә барган вакыйгаларның киеренкелеге нәтиҗәсендә М. Гафури да каршылыклы хисләр эчендә яшәргә мәҗбүр була. Бер яктан, чын хөррият, гаделлек урнашачагына ышаныч, икенче яктан, көннән-көн авырлаша барган сәяси һәм матди хәле аны шул халәткә китерә. Шулай да аның иҗатында күңел төшенкелеге төп урын ала алмый. «Кайгырып хәсрәтләнүдә бер дә файда юклыгын» аңлап, ул үзенең бәхетен «явыз дөньяга» каршы тора алуда күрә:

*Ләкин мин ул явызга ялынмамын,*
*Теләсә нишләсә дә ихтыяры;*
*Сер бирми кырын ятып карап торсам –*
*Шул вакыт мин бу дөньяның бәхтияры.*

(«Тәэссеф», 1909)

Реакция елларында язылган әсәрләрендә ул тормышның бик төгәл күренешләре, үтемле әдәби чаралар аша социаль каршылыклар, әхлакый бозыклыкларның ачык картинасын тудыра. Үз чорының реаль сурәтен, рәхимсезлеген, җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне фаш итә һәм заманның иҗтимагый-сәяси вакыйгаларын төгәл бирә алган публицистик шагыйрь булып таныла. «Базарга чыктым» (1907), «Хәерче» (1909), «Кызганыч», «Татар хатыны», «Яшь кыз» (1910) «Ялчы бабай» (1911), «Ярлы» (1911) кебек шигырьләре шундыйлардан иде.

М. Гафуриның реакция елларындагы иҗаты турында сөйләгәндә, аның татар поэзиясен мәсәлләр белән баетуга керткән зур хезмәтенә аерым игътибар бирү тиеш.

М. Гафури дөньякүләм танылган мәсәлләрнең сюжетларын файдаланып та, үзенең оригиналь сюжетлары аша да татар поэзиясендә беренчеләрдән булып мәсәл жанрын тудыруга зур өлеш кертте, җәмгыятьтәге сәяси, әхлакый кимчелекләрне тәнкыйть утына тотып, гаделлек һәм кешелек кануннарын саклап яшәргә чакырды.

Совет чоры әдәби тәнкыйтендә М. Гафури мәсәлләренә бәя биргәндә берьяклырак якын килү сизелә: яманлык кылучылар – капиталистлар, изүчеләр сыйныфына; яхшылар, баш иеп, юк гаепне үз өстенә алучылар – эшчеләр сыйныфына тәңгәлләштерелә. Әмма М. Гафури империализм тудырган тәртипләрнең, кануннарның ялганын, шәфкатьсезлеген күрсәтә дип, аның мәсәлләренең эчтәлеген аерым тарихи фактларга гына кайтарып калдыру мәсәл жанрының да, бу жанрда иҗат иткән М. Гафуриның да иҗади мөмкинлекләрен чикләү булыр иде. Мәсәл андый кысаларга гына сыешып бетә алмый, ул кешелек яшәеше дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килгән гомумкешелек кануннарын, әдәп-әхлак кагыйдәләрен саклауга, әлеге кануннарга буйсынмаганнарны читләтеп әйтү юлы белән тәнкыйтьләүгә һәм тәрбияләүгә хезмәт итә. Алда искәртелгәнчә, М. Гафури мәсәлләренең дә тамыры еракка тоташа, анда Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыкларының акылы синтезлаша. Әйтик, «Кошларның патша сайлаулары» яки «Үгез белән Бүре» мәсәлләрен укыганда, бүгенге көн укучысы эчкә яшерелгән образда нәкъ үз чорыбызның төгәл вакыйгаларын күрә ала.

Гомумән алганда, М. Гафури мәсәлләре аерым бер чор һәм аерым бер вакыйганы гына күздә тотмыйлар, алар гомумкешелек проблемаларын үз эченә алып, киң масштабта фикерләргә урын калдыралар, нәтиҗәдә вакытлар үтү белән дә үзләренең актуальлекләрен югалтмыйлар – аларның кыйммәте дә шунда.

М. Гафуриның гасыр башы иҗаты, совет чоры әдәби тәнкыйте күләгәдәрәк калдырып килгән мөһим бер үзенчәлеге – милләт язмышы мәсьәләсен калку итеп яктыртуыннан гыйбарәт. Бер яктан, ул, патша Россиясендә генә түгел, бөтен дөньяда халыкара колониаль изүнең югары ноктасына җитүенә, анда да, мөселманнарның хәле катлаулы булуга борчыла. Төрле елларда язылган «Аурупа–Азия» (1906), «Башка җирдәге мөселманнарның хәле» (1906), «Инглизләрнең сәясәте» (1907) шигырьләрендә

турыдан-туры гомум сәясәтнең аерым милләтләргә китергән зыяны турында сөйли. «Аурупа—Азия» дә, мәсәлән, шагыйрь үзен өстен санаган Аурупага: «Мәгарифнең асыл тамырын бәхәс итсәк, Азиядәге халыклардан сезгә килгән»,— дип, тарихи яктан Шәрык дөньясында фәнни-мәдәни казанышларның иртәрәк тууын искәртеп, мөселманнарның һич тә түбәнрәк дәрәҗәдә торган халык булмауларын дәлилли.

Икенче яктан, аны Рәсәй җирлегендә яшәгән татар, башкорт, казакъ һәм башка мөселман халыкларының хәле уйландыра. Бу хакта ачыктан-ачык сөйләүгә караганда, ул, мәгълүм сәбәпләр аркасында, эчке мәгънә йөген арттыру юлын кулай күрә. «Ике кош» шигыре бу турыда ачык сөйли.

«Мал өчен», «Фидаи мәхбүс агызыннан», «Балыкчылар» (1906), «Безнең хәл», «Гафури, сән онытма милләтеңне...», «Милләткә хадим булган яхшыларга», «Икенче сада», «Мәмләкәтнең барчасы әгъдәя мөлкәт улмасын», «Сөембикә манарасы» (1907) шигырьләре «асыл ватан»-да татар халкының хокукларын даулап язылган күпсанлы әсәрләренең бер өлешен тәшкил итәләр.

М. Гафури әсәрләре идея-тематик яктан гаять киң колачлы. Ул гадәти көндәлек тормыш вакыйгаларыннан алып, шигърият өчен мәңгелек саналучы мотивларга да мөрәҗәгать итә. Шундыйлардан тормыш-яшәеш турында фәлсәфи уйланулар («Хәлең», «Күңел тарлыгы», «Кайвакытта», «Тормыш»), табигать һәм кеше («Яз башлануы», «Эңгер вакыты», «Харап бакча»), сөю-мәхәббәт («Беренче мәхәббәт», «Янган йөрәк», «Сөюдән качу») кебек темалар аның иҗатында әледән-әле чагылып тора. Әхлакый темаларны да, сәясәт, туган җир, ил, Ватан мәсьәләләрен дә яратып, теләп яктырта шагыйрь. Әмма шулар арасында гади халыкның, үз милләтенең язмышына аерым игътибар бирүе аеруча сизелеп тора. Иҗатының тәүге чорында:

*Бер адым алга басам да*
*Әйләнәмен артыма,*

*Кайда басканнар икән дип*
*Күз саламын халкыма,—*

дип язган булса, бөтен иҗаты дәвамында ул шул мәсләгенә тугрылык саклый. Нинди жанрда гына иҗат итсә дә, күңел түренә кереп утырган гади халык, милләт язмышы аның каләменә юл күрсәтә, әдипнең йөрәген халыкныкы белән бәйли.

М. Гафури иҗатында милли тойгылар гәүдәләнешендә бер нәрсә ачык чагылыш таба: бу — әдипнең үз иҗатында һәрвакыт татар милләтен, татар телен күздә тотуы, үзен шул халыкның бер вәкиле итеп күрүе. Ул моны үзе дә ачыктан-ачык яза: «Шигырь язды Габделмәҗит ибне татар» («Алмашыну», 1905), «Русияле бер татардыр — асыл затым, Габдулла ибне татар — мәшһүр затым» («Яшь гомерем», 1906).

Милләт һәм тел — шагыйрь өчен бер-берсеннән аерылгысыз. «Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь»ендә дә милләт һәм тел язмышының бердәмлеген ассызыклый, телне саклау — милләтне саклау, дигән фикер әйтә:

*Телләре югалмадисә, мәңге югалмас татар;*
*Милләт ашдыкча — ашар, милләт яшьдекчә — яшәр.*

Милләт дигәндә татар халкын күңелендә тоткан кебек, тел дигәндә дә ул татар телен күздә тота. Татар телен ул «үз ана телем» дип атый:

*Үз ана телем — минем өчен матур, иң тәмле тел;*
*Үз телем — үз әйберем булган өчен ярата күңел.*
*Шул ана теле белән мин мәкъсудымны аңлатам;*
*Шул анам теле белән «балам» диләр анам-атам.*
*Шул тел аркылы иман, уку, язуны үгрәнәм;*
*Шул тел аркылы укып-белеп булырмын чын адәм.*
*Мин бала чактук «әти-әни» дидем шул тел белән,*
*Һәм дә әнкәм дә миңа «бәбкәм» дигән шул тел белән.*
*Әле дә шул тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм,*
*Шул татар теле белән көйлим берәр көй көйләсәм.*
*Һәрвакыт шул тел белән язган матур китап укыйм,*
*Һәрвакыт шул тел белән тарих укыйм, хисап укыйм.*

1911–1915 еллар шигъриятендә милли тойгыларны гәүдәләндерү үзенчәлеклерәк төсмер белән баетыла. Шагыйрь дини мифологиягә, тарихка мөрәҗәгать итә, милләтнең һәм кешенең асылын саклауда диннең ролен югары куя. «Тәңрене искә төшерү» (1913), «Алладан сорау» «Җомга көн», «Бәйрәм көн», «Ишет, тәңрем» (1914) шигырьләренең лирик герое язмышын Аллаһ кодрәте белән бәйләгән, шуннан рухи тынычлык тапкан шәхес буларак гәүдәләнеш ала. Дини мифологиягә нигезләнеп иҗат ителгән «Адәм вә Иблис» (1910), «Рисаләт» (1916) поэмалары да шушы елларда язылა.

«Адәм вә Иблис» Коръәндәге аерым сүрәләрнең сюжетларын кулланып язылган. XX йөз башында иҗат иткән башка шагыйрьләр, аерым алганда, Г. Тукай, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Һ. Такташлар кебек, М. Гафури да җәмгыятьтәге вакыйгалар, кешеләрнең бер-берсен рәнҗетү-кимсетүләрен, мәгънәсез кан коюларын, беренчел яратылыштан тайпылып, вәхши була баруларын дини мифологиягә нигезләнеп ачкан. Ул үзенең поэмасында Адәм белән Иблис каршылыгын түгел, ә Аллаһының мәрхәмәте белән кешенең явызлыгы каршылыгын алгы планга чыгара, мәгърифәтчелек күзлегеннән карап нәтиҗә дә ясап куя: кешеләрнең табигый яшәеше, кешелекле мөнәсәбәтләре өчен уйламый табыну гына җитми, иң беренче белем һәм намус кирәк.

М. Гафури 1914 елның августында башланып киткән Беренче бөтендөнья сугышының гади халык өчен зур фаҗига алып килүен яхшы аңлый, шигырьләрендә дә империалистик сугышның сәяси асылын дөрес гәүдәләндерә. Бу әсәрләрендә дә ул халык өстенә ябырылган афәтне сурәтләүдә, искиткеч тәэсирле итеп укучыга сугышның хакыйкый асылын ачуда ислам фәлсәфәсеннән, Коръән сюжетыннан алынган образлардан оста файдалана. «Фитрәт заманы», «Кыямәт» (1914), «Юктырсың ла, Алла!..» (1915) шигырьләрендә аның дөньякүләм җәелгән вәхшилек, кан коюны туктатуда Алла кодрәтенә таянуы, Аңа мөрәҗәгате сизелә.

Үз вакытында шагыйрьне дәһрилектә гаепләп, өстенә күп ләгънәтләр яудыруга сәбәп булган «Юктырсың ла, Алла!..» шигыре дә Алланы инкяр итә дияргә һич нигез юк. Лирик геройның «Юктырсың ла, Алла!..» дип мөрәҗәгать итүе дөньядагы кан-яшь, аһ-зарга күмелгән халыкның фаҗигасе тирәнлеген аңлатуга хезмәт итә, ягъни җир йөзенә таралган гаделсезлек, тигезсезлек, гади халыкның бәхетсезлеге иң бөек хакыйкать – Алланың барлыгына шик белдерерлек дәрәҗәгә җиткән. Тик шулай да ул ахыр өметне барыбер Аллага баглый. Шигырь: «Сабыр иткән бәндәләргә вәгъдәң ахирәттә гаять зур-зурын, шул вәгъдәңнең бик аз гына кыйсьмен дөньялыкта күрсәт, ач нурың!..» – дип тәмамлана.

Кешелексез мөнәсәбәтләрнең беренче планга чыгуы, һәрнәрсә, хәтта намусның да акча, байлыкка буйсындырылуы, хәерчелекнең соң ноктасына җитүе, халыкның киләчәген күкрәк тәрбиясе белән саклаучы хатын-кызның хокуксызлык һәм наданлык тоткынлыгында булуы шагыйрьне иң тирәнтен борчыган мәсьәләләрдән булды. Коллык богауларын өзәрлек көч, хөр шәхес тәрбияләү аның шигъриятендә дә, прозасында да үзәк тема булып әверелде. «Әйдә, кызым, мәктәпкә», «Зәйнәп» (1907), «Кем бәхетсез» (1910) кебек дистәләгән шигырьләре хатын-кыз киләчәген кайгыртып, аңа мөрәҗәгать итеп, гаилә тәрбиясен, бала тәрбияләүдә ата-ананың ролен күздә тотып языла.

М. Гафуриның инкыйлабка кадәрге чор прозасында ике юнәлешне аерып күрсәтергә мөмкин. «Ачлык, яки Сатлык кыз» (1907), «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» (1907), «Үги балалар» (1908), «Онытылган җинаять, яки Үткәнне искә төшерү» (1909), «Исәпсез байлык» (1912) кебек бер төркем әсәрләре тормышны сәнгатьчә гәүдәләндерүгә мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализм синтезы аша ирешә. Ул әлеге әсәрләрендә инкыйлабка кадәрге Рәсәй мөселманнарының яшәешен сурәтләү аркылы, милли дискриминация, социаль тигезсезлек хөкем сөргән җәм-

гыятьтә кешенең асылын, шәхес һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген ачарга омтыла.

Әсәрләренең чынбарлык белән тәңгәллегенә ирешү, укучыга тәэсирлелекне көчәйтү юлында кырыс, җентекле натуралистик алым белән эшләнгән күренешләр иҗат итүдән дә читләшми. Дөрес, тормышны реалистик сурәтләүгә юнәлдерелгән әсәрләрендә дә ул әле нәтиҗәләр ясарга, хөкем итәргә ашыкмый, вакыйгалар агымын эзлекле хикәяләүче, күзәтүче буларак чыгыш ясый. Үзе тәнкыйди күзлектән карап гәүдәләндергән фаҗигаләрнең асылын да мәгърифәтчеләрчә аңлата. Әсәр тукымасында авторның субъектив карашлары, сентиментальлек, риторик мөрәҗәгатьләр урын ала. Әлеге әсәрләрендә дә беренче хикәясе «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек»нең герое Нигъмәтулла куйган: «Бу дөньяның бәла һәм казасы бетәрме икән? Һаман каза, һаман кайгы-хәсрәт, инде нишләргә?» – дигән сорауга җавап табарга тырыша.

«Ачлык, яки Сатлык кыз» әсәрендә агасының ятим кызын кавказлыларга 130 сумга сатып җибәргән Лотфулла, «Исәпсез байлык» әсәрендәге комсыз Хәбибулла, яки «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» әсәрендәге, сәдака бирер кешесе булмагач, җеназа укуны да көттереп кенә башкарган хәзрәт кебек образлар аша М. Гафури кешелексез җәмгыятьнең рухи кыйбласын югалткан типларын гәүдәләндерә.

«Ярлылар, яки Өйдәш хатын» повесте үзенең салмак агымында эзлеклелек саклап, тормышны сурәтләүдә ышандырырлык итеп, фәкыйрьлек төбенә төшкән ярлыларның һәм мал белән күңел күзләре томаланган байларның эчке дөньясын психологик төгәллек аша тасвирлый. Әсәрдә өметсезлек, фәкыйрьлек, ачлык, салкын кочагында бер-берсенә якын сыенган, үлем тырнагыннан котылып калырга теләп берләшкән көнлекче хезмәте белән генә җан саклаучы Шәриф, аның хатыны Бәдри белән балалары һәм алардан да бәхетсезрәк Җәмиләнең язмышы турында сөйләнә. Укучы күңелен тетрәндерер-

лек фаҗигаләрне хикәяләүче бу әсәрне укыганда, күңелдә авыр тойгылар белән янәшә өмет, соклану чаткысы яши. Ярлыларның өметсез, нурсыз тормышын аларның кешелеклелеге бизи. Язучы байларның күңел тупаслыгына фәкыйрьләрнең кешелеклелек сыйфатларын каршы куя. Карасаң, кешенең асылы болайрак корылган икән шул: авырлыкларны күтәрә, сабыр итә, соңгы сулышына кадәр яшәү өчен көрәшә, өметен җуймый, иманын саклый, тик үзенең башкалардан өстенрәк торуын тоюга, ул нәфес колына әверелә башлый, югарырак үрмәләү өчен намусын да, иманын да сата. Ә чынлыкта һәммәбез дә яратылышыбыз белән тигез, кайтыр урыныбыз да бер, әмма нәфес колына әверелеп шуны онытабыз. Әсәрләрендәге бер-береннән кискен аерылган байлыкта яшәүче кешелексезләр һәм тормыш төбендә җан асраучы ярлылар образлары аша автор шушы хакыйкатьне дәлилли.

Ике инкыйлаб арасында (1905—1917) хөкүмәт тарафыннан оештырылган кысу, тентү-тикшерүләр, полиция күзәтүләре, татар зыялылары арасында төрле якка тартылу, бүлгәләнеш һәм шуның нәтиҗәсендә туган кешеләргә карата ышаныч, алдагы көнгә өмет югалу, көрәш рухы сүрелү М. Гафури иҗатына да сизелерлек йогынты ясый. Җәмгыятьтәге бу халәткә карата язучы күңелендә туган эчке каршылык нигезендә әдәбиятта азатлык, шәхес иреге, милли үзаң, Ватан төшенчәсен, яшәү мәгънәсен аңлату үзенчәлекле гәүдәләнеш ала. Шигърияте ндә дини мифология, ислам фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итү, мәхәббәт, табигать культын данлау кебек үзенчәлекләр белән сыйфатланган бу күренеш, прозасында да, реалистик сурәтләүдән тайпылып, романтизмга йөз белән борылуына китерә, язучы иҗатын модернизмга хас үзенчәлекләр белән баета. Язучының рухи дөньясында барган үзгәрешләр, үзен әйләндереп алган мохит белән каршылыкка керүе, аның белән көрәшүдә яңа көч, реакцион җәмгыять вәхшилегенә каршы торырлык идеал эзләү «Болгар кызы Айсылу» (1910), «Тәэссорат» (1913), «Бу кемнең кабере?»

(1913), «Хан кызы Алтынчәч» (1914) кебек хикәя, нәсерләрен иҗат итүгә сәбәп булды. Төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Бер чәчәкнең наләсе» (1911), башкорт халык авыз иҗатына нигезләнгән ярым тезмә формада язылган «Зыятүләк берлә Сусылу» (1910) әсәрләре дә шушы исемлекне тулыландыра[1].

М. Гафури инкыйлабка кадәр шигъриятендә дә, прозасында да Рәсәй халкының, бигрәк тә, тормышы үзенә таныш булган татарларның аянычлы хәлен, хокуксызлыгын тасвирлап, аңа теләктәшлеген генә сөйләп калмады, ул «зарлы, моңлы», әмма «эч кере» булмаган, «тәкәллефсез», «ана сөтедәй хәләл» ризык белән тукланган гади кешене психологик яктан тирәнтен аңлап, аларның инсаниятен, рухи камиллеген халык хисабына яшәүчеләр әхлагына каршы куйды.

***

Февраль революциясе, патша тәхетенең җимерелүе М. Гафурины озак еллар көткән, бөтен барлыгы белән аңа ирешү максатына хезмәт иткән олы хыялы белән очраштыра. 1917 елда язылган «Хөррият иртәсе», «Татар байрагы», «Азатлык хөрмәтенә», «Курыкмагыз», «Кызыл байрак» шигырьләре шагыйрьнең инкыйлаб китерәчәк яңа тормышның күптән көтелгән хыялларны тормышка ашырачагына ихлас ышанычын күрсәтә.

Әмма Октябрь инкыйлабы һәм ул китергән авырлыклар, ил эчендә кан коюның дәвам итүе, ата – улны, ул – атаны аямаслык дәрәҗәдә дошманлык туу, хакимлек өчен барган көрәштә партияләрнең, сыйныфлар арасындагы көрәшнең соң чиккәчә кискенләшүе гомере буе кешелеклелек, шәфкатьлелек кебек сыйфатларга табынган, хакыйкать өчен көрәшүне генә максаты итеп санаган шагыйрьне артык тетрәндергән, күрәсең: 1917 елның октябреннән соң һәм 1918 елда язылган әсәрләренең сан ягыннан га-

[1] Бу турыда кара: Заһидуллина Д. Ф. XX гасыр башы татар прозасында модернизм. – Казан: Тат. кит. нәшр.,– 2003.– 255 б.

ять азлыгы һәм аларының да төшенкелек өстенлек иткән күңел лирикасы белән чикләнүе шуны раслый.

Октябрь инкыйлабы тудырган үзгәрешләргә теләктәшлек белдерүгә, аның каһарманнарын олылауга ул бераз соңрак керешә. 1919 еллардан соңгы шигърияте инде яңа туып килгән тормышны күреп канәгатьлек кичерү, социалистик төзелеш романтикасы белән тыгыз үрелеп бара, аның иҗатында электән килгән ватанпәрвәрлек, гражданлык пафосы яңа бизәкләр белән баетыла. Ул һәр нәрсәгә чагыштыру аша карый, үткән белән хәзергене кискен каршылыкта сурәтли. Искене җимереп, социаль, милли тигезлеккә нигезләнгән яңаны төзүгә, интернациональ тойгыларга зур урын бирә. Инкыйлабка кадәр үк гомуммөселман халкы язмышы өчен борчылган шагыйрь, социалистик революциянең киң җәелүен, капитализмның тулысы белән юкка чыгуын тели. «Җилфердәсен кызыл байрак» (1919) шигырендә ул Англия капиталистларына каршы бәйсезлек көрәше алып барган әфганлыларга теләктәшлек белдерә.

М. Гафури инкыйлабтан соңгы чор шигъриятендә заман белән бер сулышта, бергә атларга, яңа дәвергә хас җыр-моңнарны табарга тырыша. 1920–1930 еллар иҗатының идея-тематик юнәлешендә бу үзен бик сиздерә. Аның 1919 елда язылган «Изге юлда», «Безнең юл», «Гаһед», «Сәлам», «Татар җегетенә» кебек шигырьләре илдә яңа тормыш төзүче каһарманнарга багышланса, «Яңа бәйрәм» (1920), «Беренче май сәламе» (1921), «Нинди бәйрәм бар соң» (1922), «Таң бәйрәме» (1927) «Кызыл гаскәр җыры» (1928) кебек шигырьләрендә яңача яшәү рәвешен, совет иленең куәтен данлый. «Бир кулыңны» (1919) шигыре, «Эшче» (1920) поэмасы, «Урак һәм чүкеч» (1921), «Шахтёр» (1925), «Златоуст» (1928), «Колхоз фронтында җиңүчеләргә» (1933) әсәрләре хезмәте белән хөрмәткә лаек совет кешесенә, бөтен дөньяны таң калдырган яңа заман героена, «социализмга корыч нигез салабыз без» дигән эшчегә мәдхия булып яңгырый.

М. Гафуриның лирик герое чиркәү кагудан, азан әйтүдән туктарга, изгелеген югалткан китапларны ташларга чакыра («Яңа бәйрәм»); азан, намазга аягүрә басмаса да, «Бәйнәлмиләл»не («Интернационал»ны) җырлаганда аягүрә баса («Бәйнәлмиләл», 1925); гыйсъянчыларча «капитал дөньясын эттәй улатып, черек диннәрнең кәгъбәсен ватып» («РЛКСМ», 1923) йөри; ул шагыйрьне «күк җырлары» җырлавыннан туктап, үзенең эштән илһам алып җырлаган җир җырларын тыңларга («Күк җырлары»), дингә түгел – фәнгә ышанырга чакыра («Могҗиза» һәм радио», 1928) һәм күңел китабына язылган «гореф-гадәт, дин, тәкъдир» дигән сүзләрне ертып ташлап, «яңа иман, яңа көч, бөтен инсаннарга файда биргән изге «эш» сүзен» язып куя («Ертылган сәхифәләр», 1923).

Халык җилкәсенә төшкән авырлыктан сызлану бигрәк тә язучының Идел буен тетрәндергән зур фаҗига – ачлык афәтенә мөнәсәбәтле шигырьләрендә ачык чагылыш тапты. 1921–1922 елларда иҗат ителгән «Ач», «Сулган гөлләр», «Соңгы минутта», «Җылыйлар», «Сүнделәр», «Алтын тәре, бәрхет палас» кебек шигырьләрендә һәм «Кеше ашаучылар» поэмасында җан өшеткеч вакыйгалар, яшәүгә өметен югалткан, чарасыз, аяныч хәлдәге кешенең соңгы сулышын гәүдәләндерүдән алып, биологик зат буларак адәм баласының да кыргыйлыгын, вәхшилеген, җан саклау өчен үз баласына ук кул салуын тетрәндергеч натуралистик картиналар аша сурәтләп бирде.

Гомумән, М. Гафуриның инкыйлабтан соңгы шигъриятенең күләмле генә бер өлеше яңа тормыш төзүне хуплауга, иске белән яңаны капма-каршылыкта сурәтләп, үткәнне кире кагу, киләчәккә чиксез омтылыш һәм ышаныч баглауга юнәлдерелгән иде. Шушы идеяләр яктылыгында ул яңа чор героен тасвирлады. Ул – ирекле илнең, ирекле хезмәт кешесе, беләгендә көче, күңелендә дәрте ташып торган социализм төзүче.

Югарыда сөйләнгән чор пафосы белән бәйле әсәрләреннән тыш, М. Гафуриның бу елларда иҗат ителгән ши-

гырьләренең икенче бер өлешен күңел лирикасы, эчкерсез мәхәббәт шигырьләре, тормыш тәҗрибәсен чагылдырган фәлсәфи лирика һәм балалар өчен язылган әсәрләре тәшкил итә.

М. Гафуриның мәхәббәткә багышланган шигырьләрендә, традицион шәрык шигъриятендәгечә, сөйгәнен илаһи югарылыкка күтәреп мактау да, мәхәббәтнең татлы газапларыннан сызлану да бар. Шагыйрь гашыйк геройның хәләтен тасвирлауда гаҗәеп матур һәм гадәти чагыштырулар белән янәшә суфичыл әдәбияттан ук килә торган традицион чараларны, әдәбиятка Коръән аша кергән образ-сурәтләрне иркен куллана. «Мәхәббәт шәрабен» татыган мәгъшук зат уен-көлкедән өметен кисә, башка матурлардан ваз кичә, калебе бар пычрактан азат булып, анда сөйгәненең рәсеме генә кала, дөньяда торуы да аңа гына багышланган, гыйшкының дәлиле булып аның яшәеше зәгыйфьләнгән, йөзе саргайган, бу газаптан сөйгәненең бер елмаюы гына коткара алырга мөмкин («...гә», 1907). Икенче бер урында гыйшык хәлендәге зат үзен – мәеткә, бүлмәсен каберстанга тиңли. Аһ-зар кылып, сулган гөлдәй сулып, мәхәббәт тәхетенең әсирлегендә сөйгәне бәхетенә корбан булудан үзенә ләззәт ала. Ул суфиларча мәхәббәт шәрабен эчеп исерә, гадәти яшәеш кысаларыннан чыга, авыруга әйләнә, яшәү мәгънәсен сөйгәненә әсир, кол булуда күрә. Беркемгә баш бирмәс шагыйрь күңеле сөйгәне алдында баш июне, сөю сагышыннан үлүне бәхет саный. Шулай ук шагыйрь сөйгәненең илаһи образын тудыруда Коръәннән килгән образ, төшенчәләрне иркен файдалана. Әйтик, Г. Тукай үзенең сөйгәненең матурлыгын тасвирлау өчен: «Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңни? Ул синең васфеңдә: «Лә шәркыя, лә гарбия» ди»,– дип язган булса, М. Гафури:

*Бар матурлыклар җыелган ушбу биттә шөбһәсез,*
*«Бер вә бар, һич охшашы юктыр...» дип әйтсәң, бетте сүз,–*

дип, Коръәндә Алланың барлыгын, берлеген, охшашы юклыгын дәлилләгән аять аша сөйгәненең матурлыгын чагыштырырлык зат юклыгын раслый («Ул», 1919).

Пейзаж лирикасы, туган җир темалары М. Гафури иҗатында әлләни зур урын биләмиләр. Бу уңайдан аның ел фасылларына багышланган, аерым күзәтүләр рәвешендә язылган шигырьләр төркемен искә алып китү дә җитәр кебек. Шулай да зарын, шатлыгын уртаклашкан, күз яшьләрен үзенә сеңдергән, күңелендә шәмнәр кабызган туган җир образы М. Гафури иҗатында да газизләрдән газиз, изгедән изге.

М. Гафури иҗатында гомер юлы, яшәү мәгънәсе турында уйланулар шулай ук төрлечә гәүдәләнеш алган: «Картайдыра дөнья, картайдыра...» (1921), «Гомрем бинасына менеп барам...» (1922), «Изге күңлем кәгъбәсеннән...» (1922) кебек шигырьләрендә гомер үтү, теләгәннәрнең һәммәсенә дә ирешә алмаудан канәгатьсезлек сизелеп тора.

1921–1922 елларда язылган шигырьләрдәге күңел төшенкелегенең сәбәбе, әлбәттә, илдәге ачлык фаҗигасе белән дә бәйле булгандыр. Әмма, аларга карап, М. Гафури күңелендә яңа тормыш идеалына күләгә төшкәнен дә сиземләргә була. 1922 елның 13 маенда «Сәйфи Кудашка» дигән шигырендә ул: «Күп кешеләрне тереләй җиргә тыкты Октябрь, Октябрьне сөймәгәннәргә казылды зур кабер»,– дип язса, 1923 елда иҗат ителгән «Яңа көчләр» шигырендә: «Әйләнә-тирәм тулган монафикълар, кара көчләр белән, һәрбере мәшгуль боларның вак-төяк эшләр белән»,– дип яза. Мондый төшенкелек белән сугарылган шигырьләре алга таба да очрап тора.

1920 елда язылган «Эшче» поэмасының нигезендә, М. Гафуриның башка күп әсәрләрендәге кебек үк, капиталистик шартларда гади хезмәт кешесенең аянычлы язмышы сурәтләнә. Поэмада бирелгән эшче образында яшәешеннән канәгатьсезлек, изүче сыйныфка нәфрәт ачыктан-ачык белдерелә.

1927 елда Гыйльми үзәктә эшче темасына яңа опера иҗат итү мәсьәләсе күтәрелә. Бу эш әлеге темада тәҗрибәсе булган М. Гафурига йөкләнә. Үзәкнең җитәкчесе Г. Ибраһимов аңа үзенең «Эшче» поэмасын нигез итеп алырга киңәш бирә. «Эшче» поэмасы бик нык эшкәртелеп, либретто иҗат ителә. Аңа музыканы С. Габәши, Г. Әлмөхәммәтев һәм В. Виноградовлар яза. Либретто тексты поэманыкыннан шактый нык аерыла. Анда персонажлар конкретлаштырылган, эшче Нигъмәт образында революцион фикер үсеше, изүчеләргә карата көрәш мотивы гәүдәләнеш алган. 1904–1905 еллардагы революцион хәрәкәт һәм Рәсәй белән Япония арасындагы сугыш фонында эшченең революциягә килү юлы билгеле бер дәрәҗәдә чагылыш тапкан. Эшчеләр арасында революцион күтәрелешнең сәбәпләре реаль җирлектә, эзлекле үсештә ачылган.

М. Гафуриның инкыйлабтан соңгы чор прозасы, шигърияте белән чагыштырганда, тематик яктан әлләни зур үзгәреш кичерми: ул революциягә кадәрге чор гади халык тормышының авырлыкларын гәүдәләндергән, күбесе үз тормышы белән үк тыгыз бәйләнешле булган «Кара йөзләр», (1926), «Тормыш баскычлары» (1927), «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1931), «Тәрҗемәи хәлем» (1923), «Баштан үткәннәр» (1923), «Серле бер мәхәббәтнең тарихы» кебек әсәрләрен иҗат итә.

Бу әсәрләр өчен («Серле бер мәхәббәт тарихы»ннан кала) автор идеясе һәм тенденциясе уртак: М. Гафури аларда революциягә кадәр авыл җирендә яшәп мәдрәсә белеме генә алган типик геройның рель тормышны кабул итүдәге каршылыкларын, фикри үсешен гәүдәләндерә. Бу герой, әлбәттә, төрле әсәрләрдә төрле планда, төрле югарылыкта сурәтләнә. «Кара йөзләр»дә ул – апасының фаҗигасен кичергән, дин әһелләренең икейөзлелегеннән, шәфкатьсезлегеннән аларга ышанычын югалткан Гали; «Тормыш баскычлары»нда мәдрәсәдә «Китабелҗиһад» укып, кяферләргә каршы көрәшкә әзерләнгән җиреннән аерым

сәбәпләр аркасында социалистик революция каһарманына әверелгән Вахит; «Шагыйрьнең алтын приискасында» ат башы кадәр алтын табып бәхет елмаячагына ышанган, тик капиталистик мөнәсәбәтләрнең кырыслыгы белән йөзгә-йөз очрашып, бәхеткә илтүче юлның башкада икәнлеген аңлаучы шәкертләр; «Тәрҗемәи хәлем» һәм «Баштан үткәннәр» кебек автобиографик әсәрләрендә дә тормышны күзаллавы мәдрәсә белеме алудан башланган егетнең иҗтимагый-сәяси каршылыкларны аңлау, революцион фикерне кабул итү дәрәҗәсенә ирешүе сурәтләнгән. Болар һәр әсәрдә үзәк мотив булып торалар дип әйтеп булмас, әмма аларның һәр сюжет сызыгында үз урыннары бар.

«Кара йөзләр» повестеның тәмамлану вакытын автор 1926 ел дип күрсәтә. 1927 елда ул Казанда басылып чыга. Әмма беренче варианты аның 1923 елда Башкортстанда «Яңа юл» журналының 2, 3 (апрель, май) саннарында ук дөнья күргән була.

«Кара йөзләр» әсәре – татар һәм башкорт телләрендә пьеса һәм опера өчен либреттолар язылып, ярты гасырга якын вакыт эчендә күп тапкырлар татар һәм башкорт сәхнәләрендә уйналган, төрле тәрҗемәчеләр тарафыннан тәрҗемә ителеп биш тапкыр рус телендә басылган иң уңышлы язмышлы әсәрләреннән берсе.

М. Гафури үзе әсәр башында «иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе» дигән аңлатма бирә. Шул аңлатма ук авторның хикәяләнәчәк вакыйгаларга шәхси мөнәсәбәтен, иске тормышның кешеләргә китергән фаҗигасен ачарга теләвен күрсәтеп тора. Шул уңайдан совет чоры әдәби тәнкыйтендә әсәрнең тиешле урыннарына игътибарны җәлеп итеп, ислам дине канунарының кешелек өчен зарары, дин әһелләренең кара йөзләр, шәфкатьсез затлар икәнлеге турында язылды да. Бу, үз чиратында, М. Гафурины атеизмны пропагандалаучы язучы буларак күрсәтергә сәбәп булды. Әмма тарихи дәлилләр М. Гафуриның бу сюжетка 1914 елда ук тотынуын – «Кара йөзләр» исемле пьеса эшләргә теләп, соңрак аны хикәя итеп язар-

га ниятләвен[1], бу әсәрнең реаль җирлеге булып, Җилем-Каран авылындагы Гайния һәм Садриларның фаҗигасенә нигезләнүен сөйлиләр[2]. Болар, үз чиратында, автор социаль заказ үтәгән дигән фикер белән генә чикләнмәскә кирәклеген искәртәләр.

Шундый нәтиҗәгә килергә була: әсәр чор идеологиясенә тирәнтен керешкән, ул инкыйлабка кадәрге татар хатын-кызының хокуксызлыгын, дин әһелләренең ислам динен халыкны куркыту коралына әйләндерүен ачуга корылганлыгын исбатласа да, аның мәгънәви йөге моның белән генә чикләнмәгән. Ул кешеләр арасындагы көнчеллек, хөсетлек кебек сыйфатларның фаҗигагә китерүен, һәммәбез бердәй кабул иткән һәм инанган кануннарның да аерым кешеләр тарафыннан бозылып, явызлыкка хезмәт итүләре турында сөйли. Кешеләрнең хөсетлеге, кара күңеле, башкалар өстеннән хакимлек итәргә омтылуы, туып кына килгән бәхетне бөресендә килеш үк карага батыра, кешеләрне кайгыга сала, гариплəндерә һәм кабергә кертә. Бу әсәрдә сурәтләгән Галимә һәм Закирлар язмышы гына түгел, ә кешелек җәмгыятендәге яхшылык һәм явызлык көрәшенең бер чагылышы буларак та яңгыраш ала.

М. Гафуриның Октябрь инкыйлабыннан соң иҗат ителгән проза әсәрләре арасында гына да түгел, гомумән бөтен иҗатында, тематикасы, әдәби эшләнеше – сюжет үстерелеше, образлар системасы, идея-проблематикасы ягыннан «Тормыш баскычлары» повесте аерым игътибарга лаек. Аның бу әсәре – милли характер, милли көнкүреш аша гомумкешелек проблемалары югарылыгына күтәрелгән, мохит тәэсире, тормыш тәҗрибәсе ярдәмендә шәхес формалашуын аерым вакыйгалар яктылыгында, ышандырырлык итеп ачып бирә. «Тормыш баскычлары»

---

[1] Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.– 267 б.

[2] Мәҗит Гафури турында замандашлары (Истәлекләр).– Уфа. 1961.– 32 б.

әсәренең төп герое Вахит, үзенең яшьтәшләре кебек үк гадәти гаиләдә тәрбияләнеп, хәлфәләрдән күп тапкырлар газават – дин өчен изге сугыш – турында тыңлап, егерме яше тулганда хәзрәтнең үзеннән «Китабелҗиһад»ны өйрәнеп, динпәрвәрлеге шул дәрәҗәдә югары – һич икеләнүсез бу сугышта шәһит китәргә әзер егеткә әверелсә дә, солдатка китүе аның язмышында кискен борылышка сәбәп була. Күпмилләтле патша армиясендә хезмәт итеп, алдынгы фикерле иптәшләр тапкан, революцион эчтәлекле листовкалар белән танышкан, солдатның төп вазифасы халык җилкәсендә яшәүче патша һәм аның якыннарының иминлеген, ваемсыз тормышын саклау икәнен аңлаган Вахитның фикер сөреше тамырдан үзгәрә. Ул иске тәртипле мәдрәсәләрдә укуның тормыш өчен кирәкле белем бирмәвен, авыл кешеләренең артык тыйнак, күп нәрсәләрдән мәгълүматсыз, шуңа күрә баш иеп, авырлык белән көн итүләрен аңлый. Солдат хезмәтен тәмамлап кайткан Вахит мәдрәсә шәкерте Вахиттан бик күпкә аерыла. Ул мәдрәсәдә укуын дәвам итәргә, мулла булырга теләми.

«Шагыйрьнең алтын приискасында» әсәренең сюжеты биографик башлангычка корылган. Троицкида мәдрәсәдә укыганда М. Гафурига бертуган Рәмиевләрнең «Восьмой» исемле алтын приискасында эшләргә туры килә. Автор шунда күргәннәрен, алардан алган тәэсирләрен әсәрнең нигезенә салган. Ул эшчеләр тормышының авырлыгын һәм аларның хуҗалар белән мөнәсәбәтендәге каршылыкларны шактый төгәллек белән сурәтли.

М. Гафури прозасының бер өлешен балалар өчен язылган хикәяләр тәшкил итә. Аларның язылу вакытлары билгеле булганнары инкыйлабтан соң иҗат ителгән. «Ялчы» (1921), «Безнең әйберләрне сатканда» (1927) кебек хикәяләре М. Гафури иҗатына хас гомуми тематиканы – байлар һәм ярлылар арысындагы кискен каршылыкны, хезмәт кешесенең рәнҗетелү-кимсетелүен, байларның кешелексезлеген сөйләүне дәвам итә. «Хәзер ансат ул – элек

кыен иде» (1927), «Югалган Актырнак» (1930) хикәяләрендә инкыйлабка кадәрге тормыш белән яңа заманда гади кешенең яшәү рәвеше чагыштырып бирелә. Дөрес, алда әйтелгән һәм язылу вакыты күрсәтелмәгән «Кыр казы» хикәясе гомумән кеше күңелендәге шәфкатьсезлек һәм кешелеклелекне каршы куя, укучыны уйланырга мәҗбүр итә.

М. Гафури талантлы шагыйрь, прозаик буларак кына түгел, туры сүзле, үткен күзле, җәмгыятьтәге һәр үзгәрешкә үзенең мөнәсәбәтен белдереп барырлык гаять киң фикри даирәсе булган публицист буларак та танылa. Беренче рус революциясе йогынтысында туган милли азатлык хәрәкәтенә теләктәшлек белдерү, гади халык белән хисләрен эчкерсез бүлешергә теләү аның шигъриятенә дә беркадәр агитацион-публицистик төсмер өсти. Бу аның революциягә кадәр һәм Октябрь инкыйлабыннан соң язылган шигырьләрендә дә шактый нык сизелә.

Әдипнең иҗади эшчәнлеге матбугат органнарында хезмәт итү белән үрелеп бара. Халыкның мәгълүматлылыгын баету, иҗтимагый аңны үстерүдә вакытлы матбугатның ролен тирәнтен аңлап эш итә. Аның мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылып, халыкны аң-белемгә, прогресска чакырган беренче мәкаләләренең күбесе шәкертләргә мөрәҗәгать итеп язылган иде. Алга таба ул халык арасында агарту эшен пропагандалауны дәвам итә һәм үтә җитди рәвештә үз чорының бик әһәмиятле социаль-икътисади мәсьәләләрен күтәреп чыга.

Октябрь инкыйлабыннан соң, бигрәк тә «Шәрык ярлылары» «Башкортстан» һәм «Яңавыл» газеталарында эшләгән елларда, аңа халык арасында еш булырга туры килә. Шунлыктан ул үз чорының көндәлек проблемаларын ачык тоеп, халыкның рухи халәтен, яңа тормыш төзү юлына баскан кешенең психологиясен тирәнтен аңлап һәм аңа чын күңелдән теләктәшлек белдереп мәкаләләр, хәбәрләр, очерклар яза, искелек калдыкларыннан ачы көлеп, кимчелекләрне фаш итеп фельетоннар бастыра.

Җәмгыятьтәге һәр иҗтимагый-сәяси, социаль-мәдәни үзгәреш, халыкны борчыган һәр мәсьәлә, һәрбер алдынгы тәҗрибә М. Гафуриның үткен каләме аша халыкка җиткерелеп килә.

Әдип иҗаты Рәсәй җирлегендә генә түгел, кешелек дөньясында тамырдан борылыш барган чорга туры килүе һәм шул вакыйгаларны милли мәнфәгатьләр яссылыгында гәүдәләндерүе белән үзенчәлекле. Аның каләме милли һәм социаль тигезсезлек тудырган каршылыклар соң дәрәҗәдә кискенләшеп, җәмгыятьнең әхлакый кануннардан йөз чөергән, кыргыйлык хөкем сөргән елларны да, тормыш авырлыгыннан гаҗиз булган халыкның инкыйлаб дулкыннарыннан гарык булып, кыйбласын югалткан, ярым саташулы хәлдә канлы юл белән тигез тормыш төзергә омтылуын да иҗат көзгесендә гәүдәләндерде.

Милләт язмышы, гади кеше хокукларын яклаучы буларак иҗат мәйданына атлаган язучы М. Гафури, давыллы еллар сынавын үтеп, чын мәгънәсендә халык шагыйре булып җитеште һәм татар әдәбияты күгендәге иң якты йолдызларның берсенә әверелде.

# МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ
# ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРЕ

# *ШИГЫРЬЛӘР*

## Өндәү

Йә татар! Вакыт йитте кузгалырга,
Мәгариф шәмгыданын[1] кулга алырга;
Тәфәккерсез, гафил булып[2] карап ятмый,
Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!

Бу заман кузгалганга килде форсат,
Бер эздән барча милләт кузгалыр чак.
Һич кеше китереп бирмәс «алыңыз» дип,
Үзебез авыз ачып карап торсак.

Әфәнделәр! Бу гафләтне[3] куймак яхшы,
Дөнья – ахирәт булсын, дисәк, йөзебез ак.
Һәр кеше «мәрхаба»[4] дип кабул итәр,
Әгәр булса файдасы – күп, сүзебез – хак.

Арамыздан китәрелсен яман эшләр,
Шулай булса, алга китәр тәмам эшләр.
Ата-баба торган, диеп, без дә торсак,
Мотлакан[5], һәлак итәр бу китешләр.

Һәрбер эшләр көннән-көнгә китсен алга,
Муафикъ тарыз[6] илә бу заманга.
Файдалы эш вөҗүдкә чыксын[7], дисәк,
Карап яту тиеш түгел мөселманга.

*«Казан мөхбире». 1905 ел, 10 декабрь*

[1] Шәмгыданын – шәмдәлен.
[2] Тәфәккерсез, гафил булып – уйсыз–фикерсез.
[3] Гафләтне – гамьсезлекне.
[4] Мәрхәбә – хуш килдегез!
[5] Мотлакан – һичшиксез.
[6] Муафикъ тарыз – тиң килгән рәвешендә.
[7] Вөҗүдкә чыксын – барлыкка килсен.

***

Ничә йөз ел изелгәнгә татар юаш,
Без татарың[1] юашлыгы дөньяга фаш.
Зур эшләргә батырчылык итә алмас
Әүвәледән курка-курка өйрәнгән баш.

Эш күрсәтеп өйрәнмәгәч буңа чаклы,
Һичбер эшкә керешалмый чын ихласлы,
Бундай эшне күреп гадәт алмаганга,
Бу тугърыда сүзләшергә сүз дә тапмас.

Кояш чыкты, эш башланды ушбу көндә,
Инша алла, инде татар карап ятмас.
Гафләттән уяндылар, күз ачтылар,
Җәһаләтнең[2] чокырына инде батмас.

Бу көндә дә гафләт илә карап калсак,
Моннан соң безнең өчен таңнар атмас.
Биргәненә шөкер кыйлып, алмай торсак,
Соңра безне ходаем һич яратмас.

*«Казан мөхбире». 1906 ел, 4 гыйнвар*

---

[1] Татарың – татарның.
[2] Җәһаләт – наданлык, белемсезлек.

## Ике кош

Ике кошны ябып куйсаң бер кафәскә[1],
Әгәр булса бу кошларның җенсе башка,
Ничаклы тату кеби күренсә дә,
Мөмкин түгел бервакытта талашмаска.

Ашымыз ашалмады безнең тигез,
Шул сәбәпле дошманымыз булды симез;
Биналар бер вакытта һәлак булыр,
Дустлык илә корылмаса асыл нигез.

Һәрбер җан үз җенесенә тартып туар,
Һәрберсе үзе күргән горефен куар;
Эт илә кода булсаң, әфәнделәр,
Нәҗес[2] белән туй кыйлырсың, дигән сүз бар...

Тыштан – дус, дошман иде алар эчтән,
Белгертте дошманлыгын бик аз эштән;
Дус булса да, төрле җавап хәзер торсын,
Хосусән[3], гафил[4] булма бу китештән!

Дус булып гомер иттек күп заманнар,
Аларны саклар өчен түгеп каннар;
Яхшылык эшемезне дустларымыз,
Наданлыктан эшли, дип уйлаганнар.

---

[1] Кафәс – читлек.
[2] Нәҗес – пычрак.
[3] Хосусән – бигрәк тә, аеруча.
[4] Гафил – гамьсез, ваемсыз.

Аларның уйлаганы булса дөрес,
Ачуланып җан бирерлек начар бер эш.
Хурлык күрмәй эшем алга китсен, дисәң,
Тик ятма! Алар кеби эшкә кереш.

Һәрбер эштә алар илә булдык уртак,
Бирелмәде файдасыннан безләргә хак,
Үзара асыл кеби күренсә дә,
Хакымызны сорарга булдык куркак.

Булмаса әгәр бездә гакыл кыска,
Ышанма аслы нәҗес залим дустка!
Җан-тән илә күрсәтелгән яхшылыклар
Бер тиенсез һич файдасыз китәр бушка.

*«Йолдыз». 1906 ел, 4 февраль*

## Мәкъсуд[1]

Бик җиңел юл белән мин мәкъсудым тапмак булам,
Бу юлымда булса манигъ[2] – бер тараф атмак булам.

Мәкъсуда[3] җитмәк җиңел түгел, имеш, бу дөньяда,
Инде мәкъсудым өчен агулары татмак булам.

Мин халыкны «гаклы юк» дип шелтә кыйлмак эстәсәм,
Мин алар кашында[4] алардан да күп ахмак булам.

Тәртибе юк бу китешнең – инкяр итмәс һич кеше,
Дөньяның бу хәлләрен күргәч, үзем асмак булам.

Жаныма тәэсир итеп күп төрле хәлләр килмәге[5],
Баш алып, бу җирдә тормый, бер тараф качмак булам.

Шунда да куймас качуга милләтем берлән ватан,
Бервакыт яхшы булыр дип, күңлеме ачмак булам.

Бер кеше наз-нигъмәт эчрә[6], бер кеше тапмый тәгам[7]!
Һәрбере булсын тигез дип, ачуларым басмак булам.

Бер көндә бер сәгать шатлык күрү насыйп түгел,
Кальбемең[8] янган утына күз яшем чәчмәк булам.

*«Милләт мәхәббәте»*. 1907 ел

---

[1] Мәкъсуд – омтылыш, теләк.
[2] Манигъ – тоткарлык, киртә.
[3] Мәкъсудә – мәкъсудка.
[4] Кашында – каршында.
[5] Килмәге – килә.
[6] Наз-нигъмәт эчрә – мул-рәхәт тормыш эчендә.
[7] Тәгам – ризык.
[8] Кальбемең – күңелемнең.

## Татар милләтенең лисане хәле[1] илә шикаяте

Эчем кайгы, идәр аһ-ваһ лисаным –
Бу хәсрәтне каләмдер тәрҗеманым[2];
«Кеше хәлен кеше белми» дигәннәр,
Ничөн хәсрәт чигә минем бу җаным?

Гафил[3] ятмый урыннан кузгалырга
Мине мәҗбүр идәр инде заманым;
Бу көннәрдә кулымда калмагандыр
Нә Әстерхан, нә Болгар, нә Казаным.

Җиһанда миннән әхкарь[4] һич кеше юк,
Мине кызган!.. Мине кызган, туганым!
Зәвал[5] юк, дип фикер иттем мин ахмак,
Кая китте гүзәл хан илә ханым?

Озын чәчкә мөсәххәр булды[6] бунлар –
Моны күреп тәгайер итте[7] каным.
Гаҗиз булдым аякка баса алмый,
Ята-ята агырган ике саным.

---

[1] Лисане хәле – ап-ачык күренеп торган хәле.
[2] Тәрҗеманым – аңлатучым, күчерүчем.
[3] Гафил – ваемсыз, гамьсез.
[4] Әхкарь – түбәннәр; хур ителгәннәр (кешеләр).
[5] Зәвал – бетү, юкка чыгу.
[6] Мөсәххәр булды – буйсындырылды.
[7] Тәгайер итте – үзгәрде, алмашынды (монда: каным катты?)

Динем – дөнья пәракәндә улыптыр[1],
Кулымда калды ялгыз бу иманым;
У[2] мөлкәт берлә китмеш бергә гайрәт,
Кулымда калмаган гайрәт нишаным[3].

Бу көннәрдә миңа махсус ватан юк,
Мәкам[4] улмыш шу дошманга мәканым;
Качан бетәр татарның аһ-зары?!
Кулымда файда юк, күптер зыяным.

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

---

[1] Пәракәндә улыптыр – таркалыптыр.
[2] У – ул.
[3] Нишаным – эзем, галәмәтем.
[4] Мәкам – тору урыны.

***

Үзенең гаклына татбикъ итеп[1] диннәрне һәр милләт,
Буңа чаклы бу дөньяда ничә диннәр бозылгандыр.

Җидаль[2] һәм ихтиляль[3] берлән бетерделәр китапларны,
Явыз куллар кереннән сакланып калганы — Корьәндер.

Һабил кател итеп[4], Кабил кабул итмәде тәүбәне,
Шу[5] көннән бу көнгә чаклы бу дөнья кып-кызыл кандыр.

Бәни адәмдә һәр заман гөнаһ кыйлмак — гадәт бер эш,
«Кулың сузма!» дигән йиргә адәм кулы сузылгандыр.

Һаваи[6] нәфсенә алданды инсан һәм хатыннарга,
Хатыннарның сүзи берлән аталары хур булгандыр.

Безем тәгъбирчә бу көндә тәмәдденле[7] дигән йирләр
Бөтен инсаннари мөһлик[8] зарарлар берлә тулгандыр.

*«Милләт мәхәббәте». 1907*

---

[1] Татбикъ итеп — яраклаштырып.
[2] Җидаль — гауга, низаг.
[3] Ихтиляль — фетнә.
[4] Кател итеп — үтереп.
[5] Шу — шул.
[6] Һаваи — буш.
[7] Тәмәдденле — культуралашкан, мәдәниятле.
[8] Инсаннари мөһлик — инсаннарны һәлак итә торган.

***

Алар бездән оялганнан
Тәрек кыйлмадылар горфен[1];
Алардан бән оялганнан
Тәрек итмәм татарлыкны.

Әгәр белсә иде милләт:
Хәвефледер киләчәк көн;
Ганимәт дип белер иде
Татарлык бездә барлыкны.

Аларга улма, дус, хәйран,
Һәр эшләре гаҗәеп дип;
Алар алмадылар күктән
Бу без күргән кибарлыкны[2].

Әгәр син иҗтиһад итсәң,
Алардан артта булмазсән;
Шигем юк, бер вакытларда
Алырсән игътибарлыкны.

Кешенең фазлына[3] кызма!
Фәзаилне[4] үзең эстә!
Алырга иҗтиһад иткел
Алар безгә кызарлыкны.

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

---

[1] Тәрек кыйлмадылар горфен – гадәтләрен ташламадылар.
[2] Кибарлыкны – горурлыкны, тәкәбберлекне.
[3] Фазлына – өстенлегенә, яхшы ягына (дәрәҗәсенә).
[4] Фәзаил – өстенлек, дәрәҗә.

## Бер татар шәкертенең Казанда мәшһүр Хан мәсҗеденең манарасыны күргәндә иншад итдеге шигыредер

Һәр бинадан биек улып күкләргә чыкмыш башың,
Бән беләм, белдермәсәң дә, агадыр канлы яшең.
Бу хәлеңдән шикаять кыйлды сәнең һәрбер ташың –
Калбеме мең парә кыйлды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Бер заманнар синдә намаз укыганнар хан иде,
Кауме татар һәм төрекнең мәскәне[1] Казан иде.
Ул вакытны тасвир итсәң, нә гүзәл заман иде –
Калбеме мең парә кыйлды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Һәб кәлисә[2] уртасында ялгызың калдың нәчөн,
Илтифатың без татардан син бина алдың нәчөн,
Әһле ислам кальбенә сән хәсрәт салдың нәчөн –
Калбеме мең парә кыйлды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Бер вакытта сәндә торды әһле ислам гаскәре,
Шәүкәтең бетте бу көндә, калмады меңнән бере.
Башкаларның йире улды ошбу көн ислам йире –
Калбеме мең парә кыйлды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Сән өмид өзсәң дә бездән, без өмидне өзмәдек,
Заһирем гәр түзсә дә дус[3], кальбемездән түзмәдек.
Җаһил улган бер заманда кыйммәтеңне белмәдек –
Калбеме мең парә кыйлды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

---

[1] Мәскәне – яши торган урыны, йорты.

[2] Һәб кәлисә – барлык чиркәү.

[3] Заһирем гәр түзсә дә дус – тышкы яктан бер-беребезгә дус күренсәк тә.

***

Сәгадәткә ирешмәк әс-
бабын күрмәк йөгермәкләр,
Тәрәкъкый токасын токкан
Безем әрбаб һимматтә.

Татар намен ишеткәндә
Җаһәләт исләрә төште,
Татардан таҗ төшәр искә,
Косур[1] улмазса хезмәттә.

Бөтен милләт хәлен баксак,
Бер инсан хәленә охшар.
Бер инсанның җәмигъ[2] гомере
Үтәрме наз-нигъмәттә?

Гасырларча хөкем сөргән
Җиһангир без татарлардыр –
Булып гайриләрә[3] гыйбрәт
Газимәт илә гайрәттә[4].

Бу әхвалъ алмашынды, гак-
се[5] килде, эш начарланды;
У гайрәт китте, нур бетте,
Татарлар калды зилләттә[6].

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

---

[1] Косур – кимчелек, җитешсезлек.
[2] Җәмигъ – бөтен.
[3] Гайриләрә – башкаларга.
[4] Газимәт илә гайрәттә – уйлап эш итүдә, кыюлыкта (тырышлыкта).
[5] Гаксе – киресе.
[6] Зилләттә – түбәнлектә, хурлыкта.

***

Бәңа[1] бу көн мәхәббәт булды михнәт,
Күңелдән һичвакыт китмәй, ни хикмәт?

Бүтәннәргә буның һич кыйммәте юк,
Вәләкин бу күренде бәңа кыйммәт.

Харап итте заһирны[2] бу фикерләр,
Буны уйлау калебкә бирде зиннәт.

Кеше хәлен кеше тәкъдир итәрме[3]?
Итәр тәкъдир буны әсхабе һиммәт[4].

Ничә төрле фикерлә[5] мөбталя[6] мин,
Җәһәннәм чыкты истән, дәхи җәннәт.

Мәхәббәтсез җиһанда тормак улмас[7],
Бу дөньяны тотып торган — мәхәббәт.

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

---

[1] Бәңа – миңа.
[2] Заһир – тышкы күренеш, кыяфәт.
[3] Тәкъдир итәр – бәя бирер, таныр (аңлар).
[4] Әсхабе һиммәт – идеаллы кешеләр.
[5] Фикерлә – фикер белән.
[6] Мөбталя – бәхетсезлеккә дучар.
[7] Тормак улмас – торып булмый.

***

Милләтем улганга татар, бән дә улдым бер татар;
Бергә булгач асыл җенсем, бергә булсын аһы-зар.

Алга китсә, бергә киттем, ташламам бән бунларый,
Милләтем алга китәр дип, хөсне зан[1] бунлара бар.

Асты-өскә кыйлды анлар дөньяның үткән заман,
Шунларә мәнсүб[2] татармын дип кыйлырмын ифтихар[3].

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

[1] Хөсне зан – яхшы уй.

[2] Шунларә мәнсүб – шулар арасындагы (шуларга караган).

[3] Кыйлырмын ифтихар – мактанырмын, горурланырмын.

***

Гафури, сән[1] онытма милләтеңне,
Сарыф ит ушбу юлда һимматеңне[2].

Дәвам ит, ушбу юлда күп чалышкыл[3],
Белер әрбабе һиммәт[4] кыйммәтеңне.

Татарның зилләтен[5] күр һәм намусын әйт,
Димә зилләт үзеңнең зилләтеңне.

Тәләф улсаң[6] тәләф ул ушбу юлда,
Фида ит милләтә һәп риннәтеңне[7].

*«Милләт мәхәббәте». 1907 ел*

---

[1] Сән – син.

[2] Һиммәт – тырышлык, дәрт.

[3] Чалышкыл – тырыш.

[4] Әрбабе һиммәт – тырышлык ияләре.

[5] Зилләт – түбәнлек.

[6] Тәләф улсаң – һәлак булсаң.

[7] Фида ит милләтә һәп риннәтеңне – корбан ит милләткә барлык тавышыңны.

## Әтәч белән Сандугач

Әтәч йөри җим эзләп, аяк белән типкәләп,
Янында тавыклар бар – барысы җиде-сигезләп.

Әтәч мохтаҗ азыкка һәм ихласы зәвыкка[1],
Сирәк-сирәк кычкырып, гайрәт кыйла тавыкка.

Сандугач күзен салып, урыныннан кузгалып,
Тәрәзәнең төбеннән диде Әтәчкә мактанып:

«Әй Әтәч, син, бичара, болай таба бер кара:
Кечкенә бу Сандугач ничек көнен узгара?

Тәмле орлыклар ашап, рәхәтлек белән яшәп,
Синең кебек җир казып, күрмимен һичбер азап.

Чүплек башына барып, йөрмимен чүп актарып».
Әтәч, моны ишеткәч, җавап бирде кайтарып:

«Ни файда аш күплектән? Чыгалмыйсың читлектән,
Хөр көенчә азык эзләү күп артыктыр чүплектән.

Күрәмсен: мин ничек хөр, кайда барсам – анда бер;
Ушбу йөргән җиде тавык – барысы минем хатындыр.

Уйнап-көләм теләсәм, теләгәнчә сөйләшәм;
Кай җирем синнән ким, орлык ашап үсмәсәм?

Торган урының бик тар, тарлыкта ни рәхәт бар?
Кайгы-хәсрәтең күплектән кыйласың син аһ-зар.

Адәмнәргә син әсир, торган җирең – бик тар җир;
Ничек чыдап торасыз? Сандугачым, җавап бир!..»
Әтәчкә жавап тапмый гаҗиз калды Сандугач,
Башыны түбән салды, башка хәйлә тапмагач.

Гыйбрәт илә монда бак, Әтәчнең һәр сүзе хак:
Әсир булып торудан хөр булу артыгырак.

*«Милли шигырьләр».* 1907 ел

---

[1] Ихласы зәвыкка – күнеле ләззәтләнүгә.

## Алмас[1] ташы

Гелән вәхши көн иткән бер заманда
Бер Алмас ташы яткан шул яланда.

Чын алмас ташы кадрен белми алар,
Бу Алмасны алар һич алмаганнар.

Кадерсез ятканын Алмас та белгән,
Бу эшкә кайгырып чиксез үкенгән.

Үкенгән берлә ни файда аңарга?
Түгел мөмкин моңа хәйлә табарга.

Менә бер көн моны бер вәхши алган,
«Нигә соң бу?» – дигән дә суга салган.

Наданнар һич синең кадрең беләлмас,
Кара ташлар янында син бер Алмас.

Кара таштай чаклы булмастыр базарың,
Ишетмәсләр синең һич аһ-зарың.

*«Тәэссоратым» (китап). 1910 ел*

[1] Алмас – алмаз.

## ...гә

*(Бер хатирә)*

Башкаларга бирелсә бу мәхәббәтем,
Чыдамас күтәрергә моны һичкем.
Хур сыйфатлы матурлыгың касәсеннән
Мәхәббәт шәрабыны мин дә эчтем.

Мәхәббәтем сезгә төшкән көннән бирле
Гыйш-гыйшрәт[1] кыйлуымнан өмид кистем,
Дөньяда булган башка матурлардан
Күз йомып, барчасыннан инде кичтем.

Калеб ул – үзе нәкъ бер фотограф,
Башка тап вә пычрактан булды бу саф,
Калебемдә ялгыз синең сурәтең бар,
Шуны уйлап мине кызган, кыйлгыл инсаф.

Күңелемдә ялгыз бер шул сурәт калды,
Дөньяда торуым сезгә багланды,
Гыйшкыма бер дәлил сорасаңыз:
Вөҗүдем[2] зәгыйфь, йөзем сарыланды.

Уемда сез генәсез – төш вә өндә,
Синең белән саташамын көн дә, төн дә,
Мәхәббәт җәфасыннан коткарсаңыз,
Сөеклем, ялгыз синең кодрәтеңдә.

Бер генә рәт шатландыр син мине көл дә,
Елмаюың шифа була бу күңелгә,
Бу көндә нәкъ сандугач төсле булдым –
Сайраган гашыйк булып кызыл гөлгә...

*«Моң вә зар» (китап). 1911*

---

[1] Гыйш-гыйшрәт – уен-көлке.
[2] Вөҗүдем – яшәешем.

## Инкыйлаб

Дөньяда торсаң – күрерсең һәр көне бер инкыйлаб,
Бер көне юаш торыр, икенче көн китәр дулап.

Дустларыңнан аерып, фирак[1] утына яндырыр;
Эшләрең чуалдырыр да су кебек болгандырыр.

Йөрмәс ул син уйлаганча – бәдбәхеттә юк сәбат[2]:
«Бу фәкыйрьне рәнҗетермен ич», – димәс, юк анда ят[3].

Яәҗүҗ ул: сиңа һөҗүм кыйлыр өчен ачмакта юл;
Син аның юлына сәд чик[4], син аңа Искәндәр ул[5].

Ул сине эскәнҗәгә[6] кыскан кебек кысар, ватар,
Бервакыт тартыр үзенә, бервакыт читкә атар.

*«Мәҗит Гафури шигырьләре». 1909 ел*

---

[1] Фирак – аерылышу.
[2] Сәбат – ныклык, даимилек.
[3] Ят – оят.
[4] Сәд чик – киртә кор.
[5] Ул – бул.
[6] Эскәнҗә – тиски, кыса торган җайланма.

## Бакчада...

Бүген әллә нигә мәхзүн[1] күңелләр,
Минем күңлемне ачмыйлар бу гөлләр.
Матур хур кызлары, алдымда торса,
Мине мәсгуд итәр төсле түгелләр.

Нигә күп сайрашасыз, сандугачлар?
Сези[2] шатландырамы бу агачлар?
Сези дә, юкса, мәфтүн итәләрме[3]
Зифа буйлы матурлар, кара чәчләр?

Алай түгел, мәхәббәт – башка-башка,
Алар гашыйк чәчәк берлән агачка;
Мине мәфтүн итеп торган матурның
Чәчәк тик кадре юктыр сандугачка.

Яратмак бер, вәләкин юллары күп,
Берәүнең дошманы башкага мәхбүб[4];
Кеше шелтәсе кяр[5] итмәс кешегә,
Әгәр булса гашыйк чын гыйшка мәнсүб[6].

Кешенең үзенә – үз хәсрәте зур,
Димә аны хәкыйрь[7], бичара һәм хур;
Мәхәббәт – мәҗбүри булган бер эш ул,
Мәхәббәт әһле[8] мәхзүн һәм дә мәгъзүр[9].

*«Мәҗит Гафури шигырьләре». 1909 ел*

---

[1] Мәхзүн – кайгылы, моңлы.
[2] Сези – сезне.
[3] Мәфтун итәләрме – үзенә буйсындыралармы, сокландыраларммы.
[4] Мәхбүб – сөекле.
[5] Кяр – тәэсир, йогынты.
[6] Гыйшка мәнсүб – гыйшыкка бирелгән.
[7] Хәкыйрь – кимсетелгән.
[8] Мәхәббәт әһле – мәхәббәт тотучы.
[9] Мәгъзүр – гозерле.

## Үз мөселманым

Мөселманлыкны миннән кызганып бер үз мөселманым,
«Кәфер» диде, моның сүзен кабул итмәде вөжданым.

Дидем: «Син бит минем газиз иманыма түгел уртак,
Бүтән нәрсә, мине алсаң ал, үземдә калсын иманым.

Иман алып, иман бирмәк синең кулыңдамы юкса?
Әгәр фикерең шулай булса, хата фикерең, хата, җаным.

Әгәр дә син чапан, чалма мөселманлыкка шарт дисәң,
Өемдә, сандыгымда бар миндә чалма-чапаным.

Безем кулда, диеп дәгъва итәр булсаң шәригатьне,
Бу эштә алдансаң, минем өйдә бар Коръәнем.

*1909*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 2 эш, 61 бит*

## Балалар теләге

Илаhи йир вә күкләрне яраттың, барлыгың чиксез,
Бөтен дөньяны асраучы Хода Син, рәхмәтең чиксез.
Илаhи, берлегең икърар[1] итәбез барчабыз телдән,
Сине тәсдикъ итәбез[2] барчабыз телдән.
Илаhи, үстерәсең кап-кара йирдән кызыл, ак гөл,
Сәгадәтең сәбәп булган гыйлемлекләр насыйп иткел.

*1909*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраhимов исем. Тел, әдәбият hәм сәнгать институты, Музыкаль hәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 16 эш*

---

[1] Икърар – карар.
[2] Тәсдикъ итәбез – таныйбыз.

## Үрдәк — Лачын

Бик матур һәм ташлы күлдә, сулары торган тонып,
Ялгыз Үрдәк шатланып йөзә иде чумып-чумып.

Анасын күргән бала тик: бер чума, бер талпына,
Әйләнә дә тулгана бер алдына, бер артына.

Бәгъзе вакыт болгата башын тыгып күлнең ташын —
Шул вакыт Үрдәкне күзләй күктә торган бер Лачын.

Ул Лачынның мәкъсуды: бу Үрдәге[1] типмәк була,
Ташлы күлдә йөзгән Үрдәкне алып китмәк була.

Инглиз кеби Лачын бу: бик ерактан күз сала,
Килде, типте жу итеп, Үрдәк аны белмәй кала.

Ул — Лачынның тырнагында ихтыярсыз кычкыра,
Ычкынам дип талпынып, ул төрлечә башын бора.

Ычкынырлык итмәгән ул: тырнагы баткан аның,
Шәфкать итмәй ул сиңа, аксын каның, чыксын җаның.

Җан бирү агырлыгын[2] тат[3], инде башка юк чара,
Баштарак качу кирәк иде сиңа, и бичара!

Ул сине итәр тәләф[4], ашар итең, эчәр каның —
Тәэсир итмәс ул залимга күз яшь илә бакканың.

*«Мәҗит Гафури шигырьләре». 1909 ел*

---

[1] Үрдәге — үрдәкне.

[2] Агырлыгын — авырлыгын.

[3] Тат — таты.

[4] Тәләф итәр — һәлак итәр, бетерер.

## Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь

Җанга бик тәэсир итәдер моңлы җыр һәм тәмле тел,
Милли җырларны ишеткәч, дәртләнә төшкен күңел.

Телләрен тәмләндерергә инде кузгалсын халык,
Тәмле тел – халык җаны бит, инде җанлансын халык.

Үз көен, үз җырларын белсен вә ишетсен халык,
Үз телендә инде тәмнәр барлыгын күрсен халык.

Милли көй, милли музыка тәэсирендә башка ул:
Тиз вакыт чәчкә атып, йимеш бирүче бакча ул.

Җырладык үз халкымызның монда моңлы җырларын,
Соң заманда иншад иткән[1] бик матур шигырьләрен.

Ушбу кичтә милли телнең иң беренче атламы,
Иҗтиһад итсә[2] халык, алга китәр озакламый.

Уртача булса да булсын, бу – беренче баскычы,
Чөнки бу башлангычы, бирсен Хода тел ачкычы.

Вакты берлән чәчкәгә су сипмәсәң, бетәр кибеп,
Тел дә шулай үстерүгә мохтаҗ ул сулар сибеп.

Тел үсүгә иң беренче җыр, шигырь ярдәм итә;
Яхшылап язган әсәрләр берлә тел алга китә.

Телләре югалмадисә, мәңге югалмас татар;
Милләт ашдыкча[3] – ашар, милләт яшьдекчә[4] – яшәр,

Монда килгәннәргә мин чын-чын тәшәккерләр итәм[5],
«Яшәсен милләт вә тел!» – дип, сүзләремне хәтем итәм[6].

*«Вакыт». 1909 ел, 19 декабрь*

---

[1] Иншад иткән – иҗат иткән.
[2] Иҗтиһад итсә – тырышса.
[3] Ашдыкча – ашкан саен.
[4] Яшьдекчә – яшәгәндә.
[5] Тәшәккерләр итәм – рәхмәтләр белдерәм.
[6] Хәтем итәм – тәмамлыйм.

## Күңел тарлыгы

Күңелләр тарлыгыннан нинди эшләр итмәде нәшьәт?[1]
Гадавәт[2] тамрыны җәйде, арада калмады шәфкать.

Күңелләр тарлыгыннан чыкты дөньяга ничә диннәр,
Ничә мәзһәбкә[3] айрылган кяферләр берлә мөэминнәр...

Шуның тәэсире берлән чыктылар байлар белән коллар,
Карендәшлек бетеп, безгә ачылды берничә юллар...

Күңелләр тарлыгыннан тартыша картлар белән яшьләр,
Күңелләр тарлыгыннан акты каннар һәм дә күз яшьләр.

*«Тәэссоратым». 1910 ел*

---

[1] Нәшьәт итмәде – барлыкка килмәде.

[2] Гадавәт – дошманлык.

[3] Мәзһәб – фәлсәфәдә, дөньяга караштa тоткан юл.

## Дин вә ислам

Дин вә ислам – чи тиредер, тарт аны үз файдаңа,
Үз көенчә калдыру, икрам[1] вә хөрмәт кайда аңа?

Чың күңел белән будыйсың, инкыяд[2] юк әмеренә,
Гали динне тәкъдис иткән[3], гали өммәт кайда аңа?

*1910*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 2 эш, 146 бит*

[1] Икрам – хөрмәт, олылау.

[2] Инкыяд – тәнкыйть.

[3] Тәкъдис иткән – изге иткән.

## Сөембикәнең соңгы сүзләре

Тып-тыныч торган вакытта купты монда шау да шу,
Килмешәкләр берлә үз тәхетем өчен зур даулашу,
Туган-үскән, суыны эчкән[1] йирләремнән киттеләр,
Белмимен бу ниндәй эш? Йә Рабби, бу мәхшәрме[2] бу?

Юк, бүген мәхшәр түгел, бәхетең бетүнең билгесе,
Үз ватаныңнан китәр вакытың җитүнең билгесе,
Чын күңел берлән үзең дошман күреп йөргән кешеләр
Кулына ошбу көн тәхетең китүнең билгесе.

Чит җенескә[3] ошбу көн дәүләт китүнең билгесе,
Ихтыярың булмавы, куәт китүнең билгесе,
Кан түгәрлек бер урында яшь түгеп буилар суны,
Бу – Казан халкындагы шәүкәт китүнең билгесе.

Аһ, бүген һәр килде башка, соң минем тәхетем кая?!
Хан илә ханым булып торгандагы бәхетем кая?!
Дөньяда безгә галиб[4] дошман булыр дип уйламый,
Бездә кувәт, бездә шәүкәтләр дигән вакытым кая?

Мин халык өчен көям, шулар өчен дә яшь түгәм,
Бу Казаннан башка йирдә мин табалмам бер дә ямь...

*1910*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 2 эш, 9 бит*

[1] Текстта *үскән* сүзе тора.

[2] Мәхшәр – дини мәгънәдә: Кыямәт көнендә яңадан терелгән кешеләрнең җыелу урыны яки вакыты.

[3] Җенес – нәсел, раса, кабилә, кавем.

[4] Галиб – җиңүче.

## Телеңне киссәләр...

Әй татар, нишләрсең инде, бар телеңне киссәләр?..
Зар җылап сорауларыңны юкка хисап итсәләр?..

Агызыңны көчләп ачып, бер башка телне тыксалар;
Нишләгән булырсың инде, чын аяктан ексалар?

Барлыгыңны искәрерләрме Дума мәбгусләре[1]?
Кайчы тотканнар кисәргә, бар микән соң үчләре?..

Әй бичара! Тел барында үтте гомрең тик йөреп,
Инде телсезләр кебек ымлап йөрерсең тилмереп...

Кулда форсат бар вакытта барлыгын белдермәдең,
Тик талаштың үз араңда, ни кирәкне белмәдең!..

Телеңә ябышкач кына, бар, тел сорап бир телеграм,
Ничә еллар әйтә килдең: «Юк! Мин искечә торам...»

Инде бик белдең белүгә: файда бирми искелек,
Эш үтәр чакта гына калды башыңа ис кереп.

Инде селке өстеңдәге чүп-чарны, бу хәлне күреп,
Искелек берлән торып беткән идең бит искереп.

Соң да булса инде тор! Селкен, тазар, тизрәк яңар!..
Мәкъсудыңча шул вакыт мәктәп тә бардыр, тел дә бар...

*«Вакыт». 1910 ел, 4 ноябрь*

---

[1] Дума мәбгусләре – Дума депутатлары.

## Кайвакытта

Кайвакытта әллә нишләп әйләнәм ямьсезләнә,
Бер югалткан нәрсәсе бар төсле күңлем эзләнә.

Бер урында тормый күңлем, тибрәнә, тапмый карар,
Җир йөзе нурсызлана, бал-майлары тәмсезләнә.

Шул вакытта: «Йир йөзендә чын сәгадәт[1] юк!» – димен,
Әй күңел! Җирнең йөзеннән чын сәгадәт эзләмә.

Әйләнәмдәге матурлыкларны тиң күрми күңел,
Иң ахырда мәгънәви бер көчкә күңлем тезләнә.

Ушбу куәт каршысында баш иям, хәйран калам,
Шул минутта шатланам, шуннан гына ләззәт табам.

*«Шура». 1911 ел, № 2*

[1] Сәгадәт – бәхет.

## Итагать

Ходa әмеренә буйсынды, итагать итте йолдызлар,
Кояш, ай, йир вә андагы агар сулар вә диңгезләр,
Агачлар, тагълар, ташлар, болытлар һәм исәр җилләр,
Йир өстендә үсеп торган үләннәр, чәчәкләр, гөлләр.

Шулай ук башка мәхлуклар тәхәллеф[1] итми һич берсе,
Ходa әмере ничек булса, шулайдыр вагы вә эресе,
Боларның һәммәсе шиксез Ходa кушканны тыңлыйлар,
Ходаның катгый әмренә болар һич каршы тормыйлар.

Ничә әйтсәң дә, Ходa әмренә буйсынган алар барсы,
Фәкать усал кешеләр торалар Хак әмренә каршы.

*(Елы билгесез)*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 2 эш, 59 б.*

[1] Тәхәллеф – артка чигенү; регрессия.

## Ана теле

Үз ана телем – минем өчен матур, иң тәмле тел;
Үз телем – үз әйберем булган өчен ярата күңел.

Шул ана теле белән мин мәкъсудымны аңлатам;
Шул анам теле белән «балам» диләр анам-атам.

Шул тел аркылы иман, уку, язуны үгрәнәм[1];
Шул тел аркылы укып-белеп булырмын чын адәм.

Мин бала чактук «әти-әни» дидем шул тел белән,
Һәм дә әнкәм дә миңа «бәбкәм» дигән шул тел белән.

Әле дә шул тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм,
Шул татар теле белән көйлим берәр көй көйләсәм.

Һәрвакыт шул тел белән язган матур китап укыйм,
Һәрвакыт шул тел белән тарих укыйм, хисап укыйм.

*«Милли шигырьләр». 1911 ел*

[1] Үгрәнәм – өйрәнәм.

## Хәкыйкать

Хәкыйкать юк түгел, бар нәрсә, ул булган элек солтан;
Борын ул өстә булган, дөньяда бик зур урын тоткан.

Заманалар үтеп, дөньяга инсаннар таралгачтан,
Озак тормый җир астыннан килеп алтын-көмеш чыккан.

Халыклар, акчаны күргәч тә, хаклыкны онытканнар,
Хакыйкатьтән сары алтынны бик күп алда тотканнар...

Менә нәкъ шул вакыттан бирле хаклык, акча шәрреннән[1]
Качып, иң саф калебләргә[2] кереп бик ныклы яшьренгән.

Адәмнәрдән бизеп инде, җәсарәт[3] итми күрнергә,
Аны сөйгән кеше аһ-зар белән йөреп керә гүргә...

Җыелмас бер урынга һич вакыт хаклык белән алтын.
Алар бер-берсенә дошман, аларның арасы салкын...

Җир өстендә качан алтын бетәр, шунда чыгар хаклык,
Түгел мөмкин боларның икесен бер җиргә җыймаклык...

*«Шура». 1911 ел, № 13*

---

[1] Шәрреннән – усаллыгыннан, явызлыгыннан.

[2] Калеб – күңел.

[3] Җәсарәт– батырчылык, кыюлык.

## Алладан сорау

Әй, мәгъсум[1] яшь бала, каршы торып кыйблага,
Ихлас белән дога кыл мәрхәмәтле Аллага.
Синең керсез күңелең, йомшак сөйләүче телең,
Ихлас белән сорасаң, бирер Алла һәр берен.
Бирер Алла теләкне, безгә һәрбер кирәкне,
Бер Алладан башкадан теләк сорау кирәкми.
Ялгыз Ходай бирүче, һәр нәрсәне белүче,
Синең һәр эшеңне тикшерүче, күрүче.

*1914*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 16 эш*

[1] Мәгъсум – гөнаһсыз; саф.

## Йолдыз

Еракта, бик еракта... күк читендә күренә бер йолдыз –
Югары, күккә күтәрелми, офыкта калган ул ялгыз.

Итә җем-җем, югарыга менәргә талпына, ашыга,
Көлә дә җылмая – барган саен бер моңлы сер ачыла.

Мин уйлыйм: әллә күптәннән югалган йолдызым шулмы?
«Бәхет йолдызысыңдыр...» дим, өмид берлән сузам кулны.

«Җә булмаса, халыкларның югалткан бәхтесеңдер,– дим.–
Гомерлек, мәңгелек рәхәт, сәгадәтләре синдер»,– дим.

«Караңгы төндә монда булмыйча, шул җирдә булсам,– дим,–
Япа-ялгыз балыккан нурлы йолдызга кушылсам»,– дим.

Шушы йолдыз кебек мәңгегә сүнми, ялгызым шунда –
Гомер итсәм, теге бик якты йолдыз торса каршымда,

Хисап итәр идем шунда үземне чын бәхетле дип,
Хәятым мәгънәле булды, бу инде мәңге бетми дип...

*«Янган йөрәк». 1918 ел*

## Үгез белән бүре

Симез, таза, зур бер Үгез ялгыз үзе
Урманга якын җирдә ашап йөри.
Ачыгып ау эзләгән ялгыз Бүре
Урман буйлап барган чакта моны күрде.

«Эзләгәнем табылды»,– дип килеп җитте,
Үгез искәрмәгән чакта һөҗүм итте.
Хәлсез Бүре – симез Үгез арасында
Җан-фәрман белән канлы сугыш китте.

Бүре килә, Үгез кыйла мөдафәга[1]:
Бүрене сөзә, һаман читкә кага.
Үгез, Бүре һәр икесе яраланып,
Тәннәреннән шыпыр-шыпыр каннар ага.

Күп сугышып, һәр икесе яралангач,
Бүре урманга кереп китте, гаҗиз калгач.
«Тик йөргәндә Үгез мине кыйнады!» – дип,
Аюга гарыз кыйлды[2], аптырагач.

Кыйсас[3] таләп кыйла Бүре теге Үгездән,
Мәзлумсынып[4], яшь агызып ике күздән.
Шул сәгать Аю Төлкене җибәрде:
«Үгез монда килеп җитсен,– диеп,– тиздән!..»

---

[1] Мөдафәга кыйла – саклана, каршылык күрсәтә.
[2] Гарыз кыйлды – зарланды, сөйләп бирде.
[3] Кыйсас – канга каршы кан белән җәза бирү.
[4] Мәзлумсынып – мескенләнеп.

Буйсынып, суд җиренә килде Үгез,
Мөддагый[1] берлән бергә торды тигез.
Хакимлек көрсисенә[2] менеп алып,
Ачуланган төсле Аю башлады сүз:

«Бар идеме бу Бүредә берәр үчең?
Шулай золым кыйлалармы, бар, дип, көчем?
Сөзгәнсең – тәмам эштән чыгаргансың,
Зур җәзага сәбәптер бу кыйлган эшең.

Әйтәсе сүзең булса – әйт шушында,
Гадел хөкем урныдыр безнең монда».
Аюның карашыннан Үгез куркып,
Җавап бирде үз ягыннан бу да шунда:

«Йөри идем кырда ашап ялгыз үзем,
Тик торганда Бүре килеп итте һөҗүм,
Мөдафәга кыйлдым – башка гөнаһым юк,
Әй, хаким, кыйл гаделлек белән хөкем».

Бүре әйтә: «Бирим эшнең аслын ачып,
Файда юк тугърылыктан читкә качып.
Бу Үгезне бик дус күреп, якын барып,
Уйнамак булган идем кочаклашып.

Кан басты шунда аның ике күзен.
Сабырлыкта тота алмады Үгез үзен.
«Уеннан уймак чыгар» дигән кебек,
Җенле кеше рәвешендә итте һөҗүм».

Һәрберсенең сүзен Аю бетте тыңлап,
Хөкемгә кереште инде Аю чынлап:
«Тик йөргән бер мәзлумга тигәнсең син,
Әй, залим, усаллыкның җәзасын тап!

[1] Мөддагый – дәгъва итүче.
[2] Көрсисенә – тәхетенә, урынына.

Беләсеңме, касдан[1] һөҗүм шәригатьтә
Йөридер үтерү белән бер рәттә.
Әлбәттә, син явызга кыйсас лазем[2],
Калсын бу эш башкаларга гыйбрәткә!»

Булдымы – булмадымы хөкем тигез,
Үлемгә мәхкүм булды мәзлум Үгез:
Аю, Бүре бергәләшеп ашадылар,
Үгез – мәзлум, диеп һичкем әйтмәде сүз.

Бу низаг тәмам булды менә шулай:
Хөкем булды Үгезгә авыр, Бүрегә – уңай.
Гаепсезне гаепле итеп чыгаручы
Хакимнәрдән безне сакла үзең, Ходай!

*«Әмсаль». 1913 ел*

[1] Касдан – явыз ният белән.
[2] Кыйсас лазем – җәза бирү тиеш.

## Г. Тукай вафатыннан соң

Көтмәгәндә кайгы салды безгә бу көндә фәләк[1]:
Әй сөекле яшь шагыйрькәй! Син югалдың иртәрәк.

Тар күреп бу чикле тормышны үзенең башына,
Кайтты «нәфсе мөтмәиннәң[2]» инде үз Алласына.

Гали рухың бу түбән дөньяны һич тиңсенмәде,
Тик бүтән дөньяга китте, ул бөтенләй үлмәде.

Үлмәдең син: чөнки бу көн һәр татар күңлендә син,
Бетмәдең син: һәр кеше сүзендә син, телендә син...

Һичвакытта чыкмас истән монда кыйлган эшләрең,
Һәрвакыт сөелеп укылыр бар «Күңел җимешләрең».

Син сөеклесең, сине шулай сөя һәрбер татар,
Сиңа каршы ихтирам һәрбер татар күңлендә бар.

Югалуың – бик зур авырлык, һәммәбезгә син әрәм,
Бар кешеләрдән дә артык мин җылыйм, хәсрәтләнәм.

*«Кояш». 1913 ел*

---

[1] Фәләк – язмыш.

[2] Нәфсе мөтмәиннә – тискәре кичерешләрдән соң килгән тынычлану тойгысы, тыныч күңел.

## Саф күңел

Мәхәббәт берлә тулган саф күңелләр дәрьядан да киң,
Бөтен күзгә күренгән нәрсәләрдән – дөньядан да киң.

Күңел киң булса, анда сыймаган һичнәрсә юк – ул зур,
Күңел – һәр нәрсәне күрүче гали, мәгънәви бер нур.

Сөя ул тип-тигез мескин вә мәзлум[1] һәм фәкыйрьләрне,
«Мин инсанмын[2]» дигәннәрне – хатыннарны вә ирләрне...

Карый ул дөньяга һич хәйләсез-нисез вә күзлексез,
Шулай ул кайгыра һәммә халык өчен һич өзлексез...

Вәләкин ул күңелнең сахибе[3] күрми – сукырланса,
Күңелне кысса, юк-бар шәй[4] өчен сызланса, тарланса.

Күңелдән тар бер әйберне табып булмыйдыр ул чакта,
Кая дөнья сыю!.. Андай күңелгә сыймый борчак та.

Күңел тар булса, мин андай күңелләрне «бозылган» дим,
«Илаһым, мондый пычрак тар күңелләрдән үзең сакла!..»

*«Аң». 1914 ел, № 1*

[1] Мәзлум – изелгән, кыерсытылган.
[2] Инсан – кеше.
[3] Сахибе – иясе.
[4] Шәй – нәрсә, әйбер.

## Исле гөл

Күп үләннәр уртасында үсте бер хуш исле гөл,
Ушбу гөл читтән карауга бик матур һәм бик зур түгел.

Җилләр иссә, селкенә бу гөл, чәчә хуш исләрен,
Аңкый хушбуй исләре көндезләрен һәм кичләрен.

Ушбу гөлнең бу эшеннән башка гөлләр көнләшә,
Бу аларның шул эшен күргән саен хуш ис чәчә.

Бу үсә, үскән саен, хуш исләре арта гына,
Төрле күбәләк кунып иски аның яфрагына.

Ушбу исле гөл кебектер яхшылык кыйлган кеше,
Исле гөл төслүк кешеләрнең була ул изгесе.

*«Кызларга махсус милли шигырьләрем». 1914 ел*

## Ул

Ай кебек йөз, кап-кара күз, ал-кызыл йомшак яңак,
Энҗедәй теш, ул матур түш, ул муеннар – сөттән ак.

Гөл кебек бигрәк килешле кып-кызыл йомшак ирен,
Җан керер җансыз кешегә бер тигезсә төкреген.

Кап-кара һәм сап-сары түгел чәче, тик уртача,
Мәгънәви бер җанлы төсле, күрдисәң күңлең ача.

Бар матурлыклар җыелган ушбу биттә, шөбһәсез,
«Бер вә бар, һич охшашы юктыр...» дип әйтсәң – бетте сүз.

*«М. Гафури шигырьләре». 1914*

## **Бәйрәм көн**

Атты мөэминнәр көтеп алган матур бәйрәм таңы,
Нурланып чыкты кояш та, басты нур бар дөньяны.

Яңгырый тәкбир тавышы, һәр күңелләр нечкәрә,
Һәр кешегә, барча әйбергә матур бер төс керә.

Бар кешеләр иртә торгач та, матур киемен киеп,
Бер-бересен каршылыйлар, чын күңел белән сөеп.

Зур кешеләр һәммәсе мәсҗедкә киткәннәр торып,
Тәңрегә коллык итәләр, анда алар саф-саф булып.

Балкый нур һәрбер урында, аңкый хушбуй исләре,
Бар кешенең дә матурланган бу көндә төсләре.

Ул балалар да яңа түбәтәй, яңа күлмәк киеп,
Шатланалар, сикерешәләр «ух, бүген бәйрәм!» диеп.

Тулган өстәл өстләре һәртөрле күп нигъмәт белән,
Каршы алалар кунакларны тәмам хөрмәт белән.

*1914*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 16 эш*

## Язмыш

Йөзәбез шаулаган, тау-тау кебек тулкынлы диңгездә,
Барабыз зур корабларның арасыннан шулай без дә!

Үтә һәрбер минут курку белән өмид арасында,
Җил иссә кайсы яктан, бу кораблар да бара шунда...

Түгел мәгълүм: бара торгач та, бәрелерме болар ташка?
Калырмы бәгъзесе[1] өстә, китәрме бәгъзесе аска?!

Хәвеф зур!.. Куркыныч арта!.. Үлем алга килеп баскан,
Халыкның язмышы чишелер вакыт гаять якынлашкан...

Ирек юк, нәкъ уенчак төсле, язмыш уйната безне,
Якабыздан тотып, бер тарта, бер читкә ата безне!

Мокатдәс яшь, мокатдәс кан!.. Китәрләрме болар юкка?!
Җә булмаса, ирештерерме безне мәңге шатлыкка?

*«Тормыш». 1915 ел, 19 ноябрь*

---

[1] Бәгъзесе – кайберсе.

## Ул кем?

«Дошманым» дип син хәзер чәнчеп үтергән бәндә кем?
Күкрәгеннән кан агып, алдында яткан гәүдә кем?
Нәрсәгез уртак иде соң һәм беләмсең кемлеген?
Юк, аны син белмисең, очраштыгыз сез тик бүген.
Бик шәп иттең! Ныклы чәнчедең! Ташлады ул дөньяны,
Уйла инде: мондан әүвәл кайда күрдең син аны?
Ул Гаребдән[1], син Шәрыкдан,– ошбу йиргә килдегез,
«Кем элек өлгерсә, шул үтерү тиеш» дип белдегез.
Эшнең асылын уйлый алмыйсыз, димисез, «Ник болай?»
Иркегезне тартып алганнар да кушканнар шулай.
Инде син алдыңдагы җансыз кешегә бер кара:
Кызганыч! Тәгәрәп ята, тик күкрәгеннән кан ага.
Мин сорыйм синнән хәзер: «Үтереп аны үч кандымы[2]?
Син аны чәнчеп үтергәч, дөнья бик киң калдымы?»
Син шулай коллыкта йөрсәң, дөнья киң булмас сиңа,
Барча эшләрдән элек баш бул, туган, үз иркеңә.
Үз кулыңда саклый алсаң син әгәр хөрриятең,
Бер дә чәнчеми дә сөярсең, дөнья киң бик, дөнья киң.

*1915*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 7 эш*

[1] Гареб – Көнбатыш.
[2] Үч кандымы – үч алдыңмы.

## Юктырсың ла, Алла!..

*(Зарыйлык[1])*

Юктырсын ла, Алла!.. Әгәр булсаң,
Сабыр итмәс идең бу эшкә,
Бөтен кодрәтеңне баглап куймас
Идең җирдә алтын-көмешкә.

Күрер идең көчсез бәндәләрне,
Ярдәм итәр идең аларга,
Ирек бирмәс идең көчлеләргә
Көчсезләрне болай таларга...

Яшь түктертмәс идең кан аралаш,
Ишетер идең аһ-зарларны.
Күп кешеләр эчтән сызлап йөри,
Бер кызганыр идең аларны...

Яраткансың халыкларны, фәкать
Тигез итеп яраталмадың,
Чын мәхәббәт һәм дә шәфкать нурын
Тигез итеп тарата алмадың!

Бәндәләрең булды чын бәхетсез,
Диннәрең дә бәхет бирмәде;
Тәгълиматың ушбу көнгә чаклы
Сәгадәткә ирештермәде...

---

[1] Зарыйлык – зарлану.

Хаким иттең, Раббым, җир йөзенә
Кара көчне, алтын-көмешне;
Синең голувиятең[1], кодрәтеңә
Ушбу эшләр бер дә килешми...

Ярый ла син үзең бик рәхәттә,
Бәндәләрең кан-яшь түгәләр,
Гомер буйларына михнәт чигеп,
Газап эчләрендә үләләр...

Кодрәтең там[2] булса, бер фәрманың
Җитмәс идеме соң тыярга,
Чын-чын татулыкны, мәхәббәтне
Мәңге урынлаштырып куярга?

Сабыр иткән бәндәләргә вәгъдәң
Ахирәттә гаять зур-зурын,
Шу[3] вәгъдәңнең бик аз гына кыйсьмен[4]
Дөньялыкта күрсәт, ач нурың!

*«Аң». 1915 ел, № 20*

---

[1] Голувият – бөеклек.
[2] Там – төгәл, бөтен.
[3] Шу – шул.
[4] Кыйсьмен – өлешен.

## Беренче мәхәббәт

Исеңдәме?.. Утырдык айлы кичтә бакчада бергә –
Теләдем шунда мин «сине сөям, җаным...» дип әйтергә.

Телим, тик әйталмыйм, нәрсәдәндер шунда мин курыктым,
Көчем җыйдым да алдыңда башым идем, кулың тоттым.

Сүз әйтмичә генә, ак маңлай чәчеңнән бер сыйпап алдым,
«Фирештә син» дидем, хәлсезләнеп, алдыңа баш салдым.

Кызардың шунда син никтер, битең алланды, нурланды;
Күзең, кашың, йөзең, иреннәрең тагы да матурланды.

Сизеп рухымны, шунда җылмаеп, син бер көлеп куйдың;
«Рәхәт бу төн!..» диеп уфлап, сөюне белдереп куйдың.

Беләмсең? Котлады ай: безнең өсткә нурларын чәчте;
Чутылдап сайрады былбыл, гүя ул безгә эндәште.

Агачлар, чәчкәләр көлде, алар да күрделәр безне;
Алар, шаһит булып, ишеттеләр «сөям» дигән сүзне.

Онытмыйм, оныталмыйм шул матур төндәге шатлыкны,
Вөҗүдем[1] һәм җаным бу дөньядан тәмам азатлыкны...

Менә шул серле чаклар әле дә балкыйлар күз алдымда,
Башын игән кебек торган кебекмен мин әле дә алдыңда.

*«Янган йөрәк». 1918 ел*

[1] Вөҗүдем – гәүдәм.

## Азатлык хөрмәтенә

Нинди бер шатлыклы якты!.. Өнме бу я төшме бу?
Тәңренең кодрәт кулы берлән кыйлынган эшме бу?

Яп-яңа, чиксез караңгы, куркынычлы төн иде;
Бар халык мәзлум иде, мескен иде, мәхкүм[1] иде.

Шул караңгылык эчендә кычкыру мәмнугъ[2] иде,
Кузгалырга, эзләнергә һич тә рөхсәт юк иде.

Йоклатып, ил өстене баскан иде албастылар;
Нур белән безнең арада бар иде таштан дивар.

Яктылык эзләп күзеңне ачдисәң[3] — мәгъюб[4] идең,
Әллә кем булсаң да сан юк, син һаман бер чүп идең.

Эшчеләрнең хәмләсе[5] берлән ватылды таш дивар,
Хөррият шундук бөтен дөньяга күрсәтте дидар[6].

Төште куллардан, аяклардан әсарәт[7] чылбыры;
Бар кешегә тип-тигез төште гадаләтнең[8] нуры.

Нишләрен белми халык: анда — матурлык, монда — ямь,
Ул кара көчләр җәһәннәмгә егылды йөз түбән.

Әй ирек, син ит тәҗәссем[9], гөл йөзеңнән бер үбим;
Күп кешеләрдән сине көткән гашыйкның берсе — мин...

*«Тормыш». 1917 ел, 12 март*

---

[1] Мәхкүм – хөкем ителгән.
[2] Мәмнугъ – тыелган.
[3] Ачдисәң – ачтың исә.
[4] Мәгъюб – гаепле.
[5] Хәмләсе – һөҗүме.
[6] Дидар – йөз, бит.
[7] Әсарәт – әсирлек, коллык.
[8] Гадаләт – гаделлек, хаклык.
[9] Тәҗәссем ит – гәүдәлән, алга бас.

## Татар байрагы

Дүрт йөз ел буе
Тәхкыйрь ителгән[1]
Татарның туы[2]
Бу көн эленгән.

Дүрт йөз ел буе
Хәбестә[3] торган
Татарның уе
Бу көн котылган.

Дүрт йөз ел буе
Ниләр күрмәдек?
Түздек, чыдадык,
Һаман үлмәдек!

Канлы бәгърebез
Янды, сызлады.
Өмид байрагы
Һаман сынмады.

Сакланып эчтә
Сынмый килде ул.
Бу көн эленгән
Байрак әнә шул.

Тәкрар[4] эленгән
Байрак инде аумас.
Татарның исме
Мәңге югалмас.

Башка байраклар
Белән бер сафтан
Барсын бу байрак,
Алсын бетмәс дан.

*«Кызыл байрак».*
*1917 ел*

---

[1] Тәхкыйрь ителгән – мыскыл ителгән.

[2] Ту – байрак.

[3] Хәбестә – ябылуда, биктә.

[4] Тәкрар – кабат.

## Курыкмагыз!..

*(Икеләнеп торучыларга багышланган иде)*

Курыкмагыз!.. Шайтан таңы түгел: бу – чын, хак таң ату;
Шөбһә юк, мотлак[1] харамдыр бер минут йоклап яту.

Хаклык алдында халык сәҗдә кыйлып, иткәч ямин[2],
Инде шайтаннар тозагыннан хәвеф юк, син әмин[3]...

Шөбһәгә, куркырга юл юк – һәммә нәрсә ап-ачык;
Инде хаккың бар чыгарга, курыкма, тор, мәйданга чык!

Китте өстән ул караңгы пәрдәләрнең һәммәсе,
Бетте коллыклар: бүген сез – тик ходайның бәндәсе.

Инде хөррият кулында, тот та ычкындырма тик,
Ул Кызыл гөл өстенә тузан вә кер кундырма тик...

Ул Кызыл гөл – назлы гөлгә тимәсен дошман кулы,
Суздисә[4] пычрак кулын – шундук аңар кил аркылы.

«Чит кеше син, кит!..» – диергә һич кешенең хаккы юк:
Ушбу инде Хөррият һәм ушбу инде киң хокук.

*«Тормыш». 1917 ел, 19 март*

[1] Мотлак– һичшиксез.
[2] Иткәч ямин – ант иткәч.
[3] Әмин – тыныч.
[4] Суздисә – сузды исә.

## Бер төндә

Шундай дәһшәтле, караңгы бер кичә,
Куркынычлы фаҗига баштан кичә.

Бар халык тынган, фәкать ялгыз йөрим,
Балкыймын, янам – янып шәмдәй эрим.

Гүяки дөньяда ялгыз мин генә,
Тик миңа иптәш караңгы төн генә.

Тик үзем аңлыйм бу төннең дәһшәтен,
Бик күп эчкәнмен мәхәббәт ширбәтен.

Эзлимен шунда олуг җанлы кеше –
Бар кешеләрдән дә вөҗданлы кеше.

Эзлимен, тик очратып булмый аны,
Әйләнеп чыксам да барча дөньяны.

Көн болыт, һич булмаса юк йолдызы,
Җиргә бакмый җылмаеп ак ай кызы.

Шул бәхетне эзләп-эзләп тапмагач,
Моңлы күңлем талпынудан туктагач,

Аһ орып, кул селтәдем бу дөньяга,
Илтиҗа[1] иттем олуг бер Аллага.

Шул вакытта булды күңлем тып-тыныч,
Бетте хәсрәт, бетте һәммә куркыныч.

Шатлыгымнан моңлы көйләр җырладым,
Нәкъ сабыйдай тәмле-тәмле егъладым.

*«Тормыш». 1918 ел, 12 апрель*

---

[1] Илтиҗа – барып сыену.

## Сәлам

Әй, каһарман җегет – татар җегете!
Куа-куа дошман яуларын,
Нәкъ арыслан кебек нәгъръә[1] орып,
Ярып чыктың Урал тауларын.

Җилле көндә янган үртләр[2] кебек,
Тирә-якны каплап янасың,
Көзге көнге тоташ болыт кебек,
Себер илен каплап барасың.

Син Газраил булдың дошманнарга,
Берәм-берәм алып җаннарын,
Егылдылар җансыз күмкә[3] кебек,
Таптап үтдең мордар каннарын.

Сарык кебек өреккән дошман качар
Синнән куркып, аны куарсың.
Җәрәхәттән аккан каннарыңны
Байкал күлләрендә юарсың.

Бәрәкаллаһ, җегет, гайрәтеңә!
Тар-мар килә дошман яулары;
Алда көтә мине күкрәк киереп
Күккә чыккан Алтай таулары.

---

[1] Нәгъръә орып – ачы, каты кычкырып.
[2] Үрт – дала янгыны.
[3] Күмкә – балчык, түмәр.

Арттан сәлам укый камәр[1] кебек,
Назлы, матур, сылу ил кызы,
Гайрәтле күреп, ул елмая,
Нәкъ шәрекъның нурлы йолдызы.

Батыр җегет белән ай, матур кыз,
Болар – туган илнең бизәге,
Сәлам укый сиңа, батыр җегет,
Туган илнең назлы йөрәге.

*(Елы билгесез)*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 74 эш, 7 нче бит*

[1] Камәр – ай.

## Мин – «исерек»

«Кичә без очрадык юлда Мәҗиткә, ул иде исерек,
Тәмам дөньясы онтылган, аны без күз белән күрдек!..»

Дип әйтерләр минем хакта, бу сүздә бер дә юк ялган,
Фәкать монда тагын бер сүз генә арттырасы калган.

Кирәк иде: «Мәҗит ул даимән исерек...» – дип әйтергә,
Чыгар иде мине тәгъриф итә[1] торган тулы җөмлә!

Минем айнык көнем бармы соң ул, көндә түгел, елда?
Күңел исерә мәхәббәттән, шәраб тик ул минем кулда.

Хәмерсез дә мин исерекмен: эчәм мин шуннан айнырга –
Нитәк[2] гөлләр була мохтаҗ эссе көннәрдә яңгырга.

Исертә без шагыйрьләрне нәфис-назлы, кызыл гөлләр,
Исертә тулган айдан да матур булган матур йөзләр...

*1918*

*Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2010. – 151 б.*

---

[1] Тәгъриф итә – таныта.

[2] Нитәк – ничек.

## Җилфердәсен Кызыл байрак

Шәрекъта кып-кызыл утлар яна, ялт-йолт итеп балкый,
Уянды мәллә күп еллар гафил[1] яткан Шәрекъ халкы?

Уян инде, вакыт җитте, арыслан төсле тор ыргып;
Авыр зынҗыр-богауларны Гаребнең[2] өстенә ыргыт!

Аларның коллыгыннан чык та кит изге юл эзләргә,
Кыямәт куптар анда башлык иткән инглизләргә!

Ул алтын колларын күм бик тирән һәм кап-кара гүргә,
Җәһәннәмгә җибәр алтын санәмнәре[3] берлән бергә!

Күренде инкыйляб ялкыннары Һинд таулары аша,
Капитал золмы белән анда кемнәрдер бик ыңгыраша.

Тянь-Шань тауларыннан шаулап аккан шарлама төсле,
Арысландай каһәрләнгән тавышлар бар гаҗәп көчле!

Башы күккә чыгып торган биек таулар башы аппак,
Әнә шул җирдә җилфердәп күренсен кып-кызыл байрак!

*1918*

*«Совет әдәбияты». 1937 ел, № 3*

---

[1] Гафил – ваемсыз, гамьсез.

[2] Гареб – Көнбатыш.

[3] Санәм – табыну әйбере.

## Миң

Синең аппак йөзең өстендәге шул кечкенә миңне
Күрәм дә тулган айның бер эшен уйлап көләм инде.

Менә ул ничек булган: сиңа айның күзе төшкән,
Синең матурлыгың күргәч, эче янган вә көнләшкән.

Күрә ул шунда: син айның үзеннән күп өлеш нурлы,
Битеңдәге шушы миңгә сәгатьләрчә карап торды.

Бераз торгач та мәгърур[1] ай: «Бу йөздән киммени мин...– ди,–
Фәкать үз йөземә сөртим шуның төсле матур миңне»,–

Диде дә ак нуры өстенә аз-азлап кара сөртте,
Гүяки, ул синең төсле булам дип, битенә миң төртте.

Менә нәкъ шул вакыттан бирле калды ай йөзендә тап,
Аның йөзендәге таплар минем сүзне кыла исбат.

Хәзер ул ай, сине күрсә, оялып битенә болыт каплый,
Болытлар булмаса, төннәр буе йир өстенә калыкмый...

*1918*

*«М. Гафури әсәрләре». 1941*

[1] Мәгърур – горур.

## Барчасыннан син матур

Күккә бактым: ай, кояш һәм төнге йолдызлар матур,
Җиргә бактым: монда йөргән хур кебек кызлар матур.

Ул болыннарда чәчәкләр берсеннән-берсе матур,
Бу саналган нәрсәләрнең һәммәсеннән син матур.

Син зоһур итсәң[1] әгәр дә бервакытта каршыма,
Ай, кояш, йолдыз вә кызлар онытылалар барсы да!..

*1918*

*«Коммуна». 1940 ел, 27 октябрь*

[1] Зоһур итсәң – килеп чыксаң.

## Гаҗәп эш

Бик гаҗәп эш!.. Мин кичә кичкә таба кайтып киләм,
Шунда – алдымда янып, балкып торучы нур күрәм.

Ушбу нур – кояш нуры, дисәм, кояш баткан вакыт,
Ай, дип әйтсәң, бу түгелдер тулган ай калыккан вакыт.

Сонра белдем ушбу нурның ник вә кайдан килгәнен:
Нәкъ шушы чакта урамга чыккан икән сөйгәнем.

*«М. Гафури әсәрләре». 1941 ел*

## Шәүләсе

Биш көн инде күргәнем юк сөйгәнемнең гәүдәсен,
Тик хыял берлән күрәм нурдан гыйбарәт шәүләсен.

Шәүләсе алдымда баскан – нәкъ илаһи бер санәм[1],
Шул сурәт алдында табынып шатланам, ләззәт алам.

Мин шулай тәгъзыйм итәм[2] бит сөйгәнемнең шәүләсен,
Нәрсә эшләрмен әгәр күрсәм аның чын гәүдәсен?!

*1919*

*«М. Гафури әсәрләре». 1941 ел*

---

[1] Санәм– сурәт.

[2] Тәгъзыйм итү – олылау, хөрмәт итү.

## Аяклары...

Аның аппак битен күргән саен,
Хәйран кала идем нурына;
Мин охшата идем аның йөзен
Фәрештәгә – оҗмах хурына.

Караган саен аның нуры артып
Чагылдыра иде күземне;
Матурлыгын күреп, биһуш булып,
Әйтә алмый идем сүземне.

Утыра идем аның битенә карап,
Бер сүз әйтә алмый күп вакыт;
Тик шул вакыт аның бит нурыннан
Кабызып ала идем нурлы ут.

Бүген күрдем аның ике аягын,
Сөт карарак булыр алардан;
Нәфис, матур шушы ике аяк,
Һич шөбһәсез, нурдан яралган.

Исем китте, сөбханалла, дидем,
Күргәч аның ике аягын;
Берилледән артык нур чолгаган
Ике аягының һәр ягын.

Болар баскан йирдән тузан алып
Күзенә сөрмә иткән кеше дә:
«Чын бәхетле кеше – мин»,– дип әйтер,
Шатлык белән йөрер мәңгегә.

Шул аяклар белән бер генә рәт
Басса шушы шигърем өстенә,
Һәрвакытта мактанып йөрермен:
«Иң бәхетле кеше – мин генә».

*1919 ел*

*Сайланма әсәрләр.– Казан: Татар. кит. нәшр, 2010.– 162 б.*

## Чәче

Җансыз ул чәч, ул бирелгән шул матурның иркенә.
Ул матур селкенсә, гөлдәй ушбу чәч тә селкенә.

Кайвакытта ул матурлый шул матурның аркасын,
Беразы яшьреп тора бәрхет колак һәм алкасын.

Кайвакыт сүтелеп төшә дә ал яңаклар өстенә,
Ул кызыл гөлдәй яңакларның бераз урынын күмә.

*«М. Гафури әсәрләре». 1941 ел*

## Бүләк

Ни була соң, әй Ходаем, син миңа зур көч биреп,
Мин очып китсәм матур төндә матур күккә менеп?

Анда менгәч тә янып торсам, һаман да сүнмәсәм,
Күк йөзеннән нурлы йолдызларны бер-бер чүпләсәм,

Мин аларны бик кадерләп, энҗедәй рәттән тезеп,
Сөйгәнемнең муйнына куйсам матурлап кигезеп.

Шул вакыт әйтер идем мин: «Әй сөеклем, әй мәләк[1]!
Бу сиңа бер Алладан килгән кадерле зур бүләк!..»

Шул вакытта ул сине миндәй күреп яратыр иде,
Йир йөзендә хөрмәтең, кодсиятең[2] артыр иде.

Искитәрлек ушбу эшне бар халык күрсен иде,
Күктәге хурлар бу эшкә көнләшеп йөрсен иде.

*1919 ел*

*Сайланма әсәрләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.–164 б.*

---

[1] Мәләк – фәрештә.
[2] Кодсиять – изгелек.

## Көтмәгәндә

Көтмәгән чакта килеп кергәч җаным,
Аптырап киттем, ниһаять[1] каушадым.

Шатлыгымнан әллә нишләп калтырыйм,
Сүз табалмыйм, гел генә юк-бар сорыйм:

«Кайда бардың, тышта бик салкынмы?» – дим,
«Балдагың бигрәк матур, алтынмы?» – дим.

«Син йөрергә аш ашап чыктыңмы?» – дим,
«Беркөн алган алтын алкаң шулмы?» – дим.

Нәрсә әйтсәм дә ябышмый сүзләрем,
Чөнки анда уй-фикер һәм күзләрем.

Сокланып кат-кат карыйм аппак битен,
Каушавымнан онытамын сүз тәртибен.

Сөйгәнемне аңлатам тик күз белән,
Ул шуны аңлый, матур кызарып көлә.

Күзләреннән серле нурлар сирпелә,
Ул нәфис битеннән хуш исләр бөркелә.

Шул ике нәрсә белән исерек булам,
Зур гаепле бәндә төсле тотлыгам.

Ул чыгып киткәч, алам иркен сулу,
Эчтән уйлыйм: «Их, матур соң, их, сылу!..»

Күргәнемне уйлыймын да шатланам,
Киткәнен уйлап кызу утта янам.

Күңлемә ул нурлы шәм кабызып китә,
Төн буе балкып янарга шул йитә.

*«М. Гафури әсәрләре». 1941 ел*

---

[1] Ниһаять – бик нык, соң дәрәҗәдә.

## Балалар һәм китап

Дүрт-биш бала җыелганнар бер урынга,
Нәкъ уртада берсе китап тоткан кулга;
Һәммәсе дә колакларын торгызганнар,
Берсе укый, башкалары тыңлый шунда.

Утыралар китап укып, күңел ачып,
Шатлыкларын бергә-бергә уртаклашып;
Кайвакытта тыңлый болар тып-тын гына,
Кайчагында көлешәләр шыркылдашып.

Кайчагында әллә кемне кызганалар,
Уфылдашып, әкрен генә кузгалалар;
Ахырысы бу китап бик күңелледер –
Күз дә алмый укый аны бу балалар.

*«Азат мәктәп». 1920 ел*

## Ач

Икмәк сорап кулын сузар иде,
Кулларында көче калмаган;
Күзләреннән яшен түгәр иде,
Күзләрендә яше калмаган.

Күз яшьләре белән бит нурлары
Юылып төшкән инде барсы да;
Ике кулы белән эчен тотып,
Калтыранып тора каршыда.

Ул сөйләми хәзер, ул сорамый,
Беткән инде аның сүзләре;
Тик аңлата аның авыр хәлен
Эчкә баткан нурсыз күзләре.

Аның битләренә кара белән
Ачлык сызыклары сызылган;
Аның авыр хәлен, моң вә зарын
Алып яздым монда мин шуннан...

*«Урал». 1921 ел, 1 сентябрь*

## Беренче май сәламе

Сизәсеңме, эшче, бүген нигә
Леп-леп кага синең йөрәгең?
Нигә бүген өмет белән тулган
Синең керсез, изге күкрәгең?

Нигә бүген болай шатлык нуры
Балкып чыга синең битеңнән?
Чөнки сәлам укый бер иптәшең
Бу дөньяның теге читеннән.

Ачлыкларга түзеп, каннар түгеп,
Салган идең, туган, изге юл;
Беренче Май көнне шул эш белән
Ерак җирдән сине котлый ул.

Ул да килгән шулай синең кебек
Бүген кызыл байрак астына;
Аның йөрәге дә леп-леп кагып,
Чын иреккә таба ашкына.

Чит илләрдә сиңа кулын сузган
Үзең кебек эшче туганың.
Шуны сизеп бүген леп-леп кага
Күкрәгеңдә янган йөрәгең.

*«Урал». 1921 ел, 1 май*

## Шатлык белән хәсрәт

Шатлык белән хәсрәт — болар икәү игезләр,
Төскә-биткә башкалар, буйга-сынга тигезләр.

Кайда гына барсаң да, берсе йөрер янында,
Хәсрәт китәр читкәрәк, шатлык килгән чагында.

Хәсрәт читкә китсә дә, озак тормас, тиз килер,
Хәсрәт килеп җитүгә, шатлык артка чигенер.

Шушы ике нәрсәнең арасында гомергә
Йөри торгач сыкранып, керерсең син кабергә.

*1921*

*«М. Гафури әсәрләре». 1941 ел*

## Ир җегеткә

Туры юлны сөйгән ир күкрәге
Агыйделләрдән дә киң булыр,
Тапсыз, керсез шулай пакь йөрәге
Бриллиантлар белән тиң булыр.

Уңнан искән җилгә бөгелмәс ул,
Алдан искән җилгә какшамас;
Этләр таушын түгел, арысланнар
Таушын ишетсә дә каушамас.

Муенын кылыч белән чапсалар да,
Каршы килмәс изге антына;
Дөнья җимерелсә дә кире алмас
Биргән кулын эшче халкына.

Олы таулар күреп, юлын бормас,
Алда диңгез күреп, чигенмәс;
Судан алып, утка салсалар да,
Күңлендә курку сизенмәс.

*«Башкортстан хәбәрләре». 1922 ел*

## Ул кем иде?

Язгы көндә киң болында уйнаган бер тай иде,
Шат иде, гамьсез иде, төрле хыялга бай иде.

Уңга чапты, сулга чапты, артка да һәм алга да –
Бу җәһәттән охшады ул борылып аккан елгага.

Кыска булды гомре, әмма алга бик шәп атлады,
Балкыган шәм булды, әмма тугъры бер юл тапмады.

Эшчеләрнең ак күгендә бер болыт та, нур да ул,
Инкыйлабчы[1] бер кеше, милләтче дә... ул.

Күкрәгендә нокталар бар, сүзләрендә нөктә[2] бар,
Бу кешенең кем икәнен кем зирәк – тик шул табар.

*«Бабич». 1922 ел, № 2*

[1] Инкыйлабчы – революцион рухлы.
[2] Нөктә – яшерен сер, үткен мәгънә.

***

Изге күңлем кәгъбәсеннән[1] көн дә бер таш җимрелә,
Ахры бик күп калмагандыр инде актык гомремә.

Яндырып күңлем шәмен эзләп маташтым изге юл,
Каршыдан искән каты җилдән вакытсыз сүнде ул.

*1922 ел*

*Сайланма әсәрләр.– Казан: Татар. кит. нәшр, 2010.–180 б.*

[1] Кәгъбә – монда: «алга куелган максат» мәгънәсендә.

## Сәйфи Кудашка

Күп кешеләрне тереләй җиргә тыкты Октябрь,
Октярбьне сөймәгәннәргә казылды зур кабер,
Ул шулай...
Ләкин, туганкай, Октябрьнең мәгънәсен
Алдагы шигырьләреңдә Октябрьсез әйтә бир.

Октябрьнең мәгънәсен җырлар вакыт җитте бугай,
Сүздән үттек, эшкә килдек, батты йолдыз, туды ай.
Ай да батты; батса батсын, ә хәзер чыкты кояш...
Җырла шул кояшларга карап, Сәйфи Кудаш.

Синдә бар изге теләк, изге күңел, яхшы талант.
Син шуларны эшкә кушсаң... чын шагыйрьсең, иттем ант.

*Уфа. 1922 ел, 13 май*

*(С. Кудаш архивыннан)*

*Мәҗит Гафури. Адәм вә Иблис // Туплау – Ф. Ш. Сибәгәтов, Л. М. Камаева.– Уфа: Информреклама, 2006.– 142 б.*

## **Инкыйлаб**[1]

Инкыйлаб ул – вак кына бер кыл иләк:
Энҗеләрне комнан аерадыр иләп...

Вак халыклар[2] күптән аска төштеләр,
Берсе анда, берсе монда киттеләр.

Калды өстә тик матур зур энҗеләр –
Чын иманлыклар, каһарман көчлеләр.

*«Яңа юл». 1923 ел, № 5/6*

---

[1] Инкыйлаб – алмашыну, үзгәрү, революция.
[2] Халыклар – «кешеләр» мәгънәсендә.

## Яңа көчләр

Әйләнәм тулган монафикълар[1], кара эчләр белән,
Һәрбере мәшгуль боларның вак-төяк эшләр белән;
Кайда ул зур идеалга бирелеп, канат җилпеп очу –
Һәрбере мәшгуль хатын-кыз һәм дус-ишләр белән.

Кайда ул эштән генә кодсиять[2] эзләүче кеше?
Һәрберенең күңле тулган вак-төяк хисләр белән;
Мин боларның эшләрен бер-бер күңелдән үткәрәм,
Үткәрәм дә эшкә тотынам өр-яңа көчләр белән.

*«Яңа юл». 1923 ел, № 5/6*

[1] Монафикъ – икейөзле, эчкерле (кеше).
[2] Кодсиять – изгелек, сафлык.

## Гөлләр бакчасында

Беркөн шулай гөлләр бакчасында
Чәчкәләрне кылдым тамаша,
Хуш исләре белән җан шатлана,
Нурларыннан күзләр камаша.

Нәфис төсләренә, буйларына
Хәйран калып, кызыгып карадым.
— Әй чәчкәләр, сезгә кемнәр дуслар?
Кемнәр дошманнар? — дип сорадым.

Гүя алар шунда җанландылар,
Нурлар чәчеп, җем-җем көлделәр...
Әкрен генә искән җил аркылы
Миңа болай җавап бирделәр:

— Кемнәр эшли, кемнәр җирләр казый,
Кемнәр безгә сулар сибәләр,
Кемнәр чәчкә кебек саф күңелле —
Шулар безгә дуслар...— диделәр.

Кемнәр кара эчле, тар күңелле,
Кемнәр чын эшкә кул бирмиләр;
Кемнәр килеп безне хаксыз өзә —
Шулар безгә дошман!..— диделәр.

Чәчкәләрнең шушы җавапларын
Алгач — «Дөрес!..» — дидем аларга,
Эшсез кешеләрнең хаклары юк
Сезне түшләренә кадарга...

Күңелле эш, матур тормыш белән
Ел артыннан еллар агарлар...
Эшчән егет белән эшчән кызлар
Сезне түшләренә кадарлар...

*«Төнге смена». 1927 ел*

## Җырларым

Күк күгәрченнәр гөрли – үзе кайда, күренми,
Салкын сулар сибү белән янган йөрәк сүрелми.

Күк күгәрчен күктә уйный, күләгәсе йирдә уйный,
Тыштан кеше уйный-көлә, эчтән сөйгәнен уйлый.

Су өстендә төнбоек, зәңгәр чәчәклесе юк,
Шул җанымнан аерылганнан бирле күңлем боек.

Нигә кердем бакчага, нигә өздем алманы,
Бигрәк зирәк кеше икән, күз караудан аңлады.

Ал таң ата, ак таң ата, таң артыннан чәчәк ата.
Чәчкә төсле яшь гомерләр шулай итеп алдата.

Безнең кала урамының утлары утсыз яна,
Ут якканнан артыграк янган йөрәк сызлана.

*(Язылу елы билгесез)*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 2 эш, 167 бит*

## Көндәлек

Бер-бер артлы шырт[1] кебек үскән күңелнең талларын
Сындырып салдым да үттем мин бу тормыш сазларын.

Саз гына булса тагын бер хәл – тирә-як күк томан;
Алда һичбер җай күреп булмый, көнем нәкъ төн сыман.

Шунда ачтым күкрәгемне, чыкты аннан чаткылар,
Ул томаннан һәм дә сазлардан алып чыкты шулар.

*1926 ел*

*Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2010. – 187 б.*

---

[1] Шырт – (диал.) «тарак» мәгънәсендә.

## Ленинизм минем маягым

**С**овет властена гомеремдә
Итмәдем мин һичбер каршылык.
Сыйнфый дошманга йөрәгемдә
Саклаганга бетмәс тарчылык.

Совет яклы булдым, аңа каршы
Торган чакларда да күп халык,
Батырларча Советны якларга
Кулыма каләм атлы ук алып.

Дөрес, кайчак тормыш баткагында
Тайгалады минем аягым.
Ләкин бик тиз табып алдым
Сүнмәс ленинизм маягын...

*«Коммуна». 1934 ел, 18 ноябрь*

## Бер истәлек

Айлы кичләрдә әгәр чыксаң – йөзеңне нык яшер,
Юкса, бу матур йөзеңне ай күрер дә көнләшер.

Ул чыдый алмас: сине күргәч, ачудан чайкалыр,
Ул китәр бу җир яныннан, җир йөзе айсыз калыр.

*(Язылу елы билгесез)*

*«Совет әдәбияты». 1937 ел, № 3*

***

Әй вөжданым, йөрдем сине сатмас өчен,
Пычраклыкка кермәс һәм дә батмас өчен;
Күп тырыштым һәм күп көчләр сарыф кылдым,
Үлгәндә дә тугъры юлдан чыкмас өчен.

Ушбу юлда йөри-йөри арып беттем,
Күпме михнәт, күпме газап, хәсрәт чиктем;
Авырлыкта йөри торгач начарландым –
Арыкландым, каным бетте, үзем киптем.

Тугъры юлдан һичбер чыкмам шунда да мин,
«Тугъры юлдан чыкмамын» дип иттем ямин[1],
Гомрем буе газап күрим, хәсрәт чигим,
Янар, көяр өчен туган кеше бит мин.

Рәхәт күрсеннәр дөньяда башка затлар,
Мин күрим шунда төрле-төрле газаплар,
Гомрем буе авырлыкка сабыр итим,
Үлгәч бетәр әле ушбу авыр чаклар.

*1917*

*«Совет әдәбияты». 1937 ел, № 3*

[1] Ямин – ант.

# *ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР*

## Болгар кызы Айсылу

Айсылу, күзләремнең алдында чәчкәләрдән укмашкан бер уч чәчкә кеби күренеп, күз каравы белән мине үзенә баглый, кулымнан көчне ала иде. Болгар кызларында гына була торган ак, түгәрәк йөзе өстендәге ал катыш кызгылт бите, карасы кара, агы ак булган зур күзе, озын кара чәче, тал чыбыктай сыгылып торган буе, көлә биреп, керфек кагып әйткән сүзе ничек тә үзене яраттыра иде.

Аны күптән бирле сөйсәм дә, үземнең сөйгәнемне аңа белдерми идем. Аның мине күрүе белән күз каравының башкалануы, сүзләрене калтыранкырап әйтүе мине яратуыны сиздерә иде.

Беркөн агачлар арасында идек. Аның матурлыгы янында үземне юк кеби күрсәм дә, кулымда көчем калмый, үземне үзем белми, җилгә бөгелгән агач кеби Айсылуга таба бөгелеп, куркынкырап:

– Мин сине сөям бит,– дидем.

Яратканыны белдерә торган төрдә күземә бакты да тынины җыеп: «Мин дә!» – диде. Шул мизгелдә күзендә, кояшка каршы ялтырап, ике бөртек яшь күренде. Агач күләгәсендә утырдык. Чәчкәдән чәчкәгә кунып йөргән чебеннәр Айсылуга кунарга итәләр дә, аның селкенгәнене күргәч, чәчкә түгел икәнене белеп, кире китәләр иде. Мин дә, аның күккә очуыннан куркып, кулымны тигезми идем. Күз карашымыздан җанымыз берләшкән кеби була, тел белән түгел, күңел белән күзләремез аркылы сөешү, яратышуымызны аңлаша идек. Матур йөзене үзенә белдерми генә карый идем. Икенче бер дә кавыша алмавы-

мызны белгән өчен, күзләремез яшь белән капланган иде. Ул, күземә туп-туры карап, көрсенеп сулап алды да алдыма кулыны салды. Бу йомшак кулны иренемә китереп үбәм дигәндә, бер кешенең тавышына сискәнеп киттек. Айсылу, болыт астына кергән ай кебек, агач арасына кереп югалды.

Бераздан соң беркөн Айсылу түшәктә иде. Терек булып торуы аз гына калганыны сизә, терек чакта күргән авырлыклардан үзене коткара торган үлемне көтә иде.

Тирә-ягындагы нәрсәләрдән ямьсезлек таба да тизрәк алардан котыласы килә иде.

Башыны чак әйләндереп, күзене тутырып, янында утырган анасына карады да: «Уф!» – диде. Күзендә яшьләр бетте. Башы ястык үзәренә төште. Тәрәзә аркылы төшкән вә кайгылы төстә торган кояш яктысына җаны кушылып, күккә очты. Төссез, саргайган иреннәре бу тормышны мыскыл иткән төсле ачылып калды.

Ак йөзле, кара күзле, зифа буйлы, озын чәчле болгар кызы Айсылу кайда? – Шул көннән бирле кара җир астында...

*Беренче тапкыр «Тел ярышы» исемле китапта 1910 елда (Оренбург, «Вакыт» мәтбагасе) басылган.*

## Мәхәббәт хатлары

Мөхтәрәмә туташ!

Сез минем бу мәктүбемне[1] алгач та гаҗәпләнеп бер көләрсез. Минем хакымда нәрсә әйтергә дә белми калырсыз. Хәтта «бу бер җүләр микән әллә?» дип тәрәддедтә[2] торырсыз. Вакыйган, һичбер мөнәсәбәт вә танышлыгы юк бер кешенең мәктүб язуы – тәгаҗҗеб кыйлырлык[3] эш. Сезнең шулай тәгаҗҗеб итеп, мине җүләргә хәмел кыйла[4] торган урыныңыз да бар. Ләкин ни өчен бу чаклы җәсарәт кыйлып[5] мәктүб язганымны вә моның сәбәбене үзем дә артык белмимен. Бу эш үземә дә бик оят вә чит бер эш булып күренә. Ләкин әллә нинди бер көч шулай хат язарга көчләп мәҗбүр итә. Ихтыярымны кулымнан ала.

Минем бу мәктүбемне алгач, көлсәңез дә, ни дип хөкем кыйлсаңыз да, ихтыяр үзеңездә, мин сезнең шулай көлүеңезне… белгәнем хәлдә, сезгә мәктүб язуны ихтыяр иттем. Бу мәктүбне иң ахыр чиктә, үземдә үземне туктата торган куәт калмагач кына яздым. Сезгә мәктүб язуымны гафу итүеңезне үтенүем өстенә, дәхи бер нәрсә риҗа итәм[6]: ул да бу мәктүбемне җавапсыз калдырмавыңыздыр. Ничек булса да бер җавап язсаңыз, мине шатландырырсыз. Сез мине шатландырырга, минем риҗамны җиренә җиткерергә бурычлы түгелсез. Ләкин, урынсыз булса да, мин шулай өмид итәм. Бик сирәк кенә очраган вакытларымда сезгә танышырга теләсәм дә, муаффәкъ була[7] алмадым, тугърысы, буңа җә-

[1] Мәктүб – хат.
[2] Тәрәддедтә – икеләнеп.
[3] Тәгаҗҗеб кыйлырлык – гаҗәпләнерлек.
[4] Хәмел кыйла – юрый.
[5] Җәсарәт кыйлып – кыюланып.
[6] Риҗа итәм – өмет итәм.
[7] Муаффәкъ була – булдыра, ирешә.

сарәт кыйла алмадым. Ниһаять, бу мәктүбемне яздым. Бу эш, ихтимал, сезнең карамакыңызда көлке бер эш булыр, ачуланырсыз да, ләкин ышанам вә тәкърар итәм ки: гафу итәрсез, шаять, мәктүбемне җавапсыз калдырмассыз әле.

*Гафуыңызга мәгъзур*[1] *Нажи*

Нажи бу мәктүбне язып тәмам иткәч тә тәрәддед эчендә калды. Мәктүбнең үзеннән аңлашылдыгына күрә дә, Нажи бу мәктүбне үзе дә белмәгән бер куәт тәэсире астында язды. Мәктүбне җибәрмәскә кирәк дигән фикеренең бер кыйсемене[2] ничек тә бер якка калдырып, ниһаять, мәктүбне җибәрергә карар бирде. Шунда ук җибәрде дә.

Берничә көннән соң Нажи үзенең бүлмәсендә түбәндәге мәктүбне уку белән мәшгуль иде.

Хөрмәтле әфәнде!

Күңелем тәмам башка бернәрсә белән мәшгуль булган вакытта, кулыма бер мәктүб китереп бирделәр. Бу мәктүб мине тәмам хәйрәттә[3] калдырды. Мәктүбеңезне укыгач, ниһаять дәрәҗәдә ачуым килсә дә, тәкърар укый торгач, бераз гына басылды. Өч көн буенча тирән уйда йөредем. Мин сезне читтән торып һәм ишетеп кенә беләм. Тик торганда, бер дә мөнәсәбәтсез хат язарга сезне нәрсә мәҗбүр иткәндер, төшенә алмадым. Мәктүбеңезне җавапсыз калдырмакчы булган идем. Ләкин «ничек булса да бер җавап яза күреңез» дип әйтүеңез, икенче, игътизар кыйлып[4] сызлануыңыз җавап язарга сәбәп була алдылар. Шуның өчен генә җавап мәкамендә[5] бу хатны яздым. Ихтимал, сез бу эшеңездә мәгъзуреңездер[6]. Ләкин миңа бу җәһәт караңгы. Башка нәрсә язарга каләмемә кулым бармый, тәкърар әй-

---

[1] Мәгъзур – гозерле (китапта ялгыш *мәгърур* дип басылган).

[2] Кыйсем – кисәк.

[3] Хәйрәттә – аптыраашта.

[4] Игътизар кыйлып – гафу үтенеп, гозерле булып.

[5] Мәкамендә – урынында.

[6] Мәгъзур – гозер иясе.

тәм: ни мәкъсуд белән мәктүб язуыңызның серенә төшенә алмадым.

*Санихә*

***

Нажи өмид вә яэс[1] эчендә торган вакытта, бу мәктүбне алып укыгач, төсе үзгәрде. Үзендә бер кызулык хис итте. Тәкърар укыды. Әллә нинди мәгънәләр чыгарырга тырышты. Тагы мәктүб язарга юл бармы-юкмы – шуны уйларга тотынды. Мәктүбендә артык ук илтифатсызлык күренми, шуның өчен тагы бер мәктүб язып, үземнең хәлемне гарыз кыйлу[2] шаять урынсыз булмас, дигән фикергә килеп, күп уйлаганнан соң, икенче мәктүбене язарга кереште. Ул үзенең сөйгәнен, гыйффәт даирәсендә чын яратканын нечкә вә кыска гыйбарәләр белән язып белдерәсе килә, бер гыйбарә, бер җөмлә яза да тагы боза. Бу утыруыннан үзенә башка бер ләззәт таба иде. Үзенең төп мәкъсудын, чын яратканын, яратуында хәйлә-фәләннең булмаганын кисеп әйтергә батырчылык кыйла алмый иде. Әллә ничаклы уйлап, бер язып, бер сызып, түбәндәге мәктүбне язды.

Мөхтәрәмә Санихә!

Бу мәктүбемне алгач, сезнең тагын бер рәт ачуыңыз килүене үзем дә бик ачык беләм. Бу хакта үз-үземне шелтә кыйлырга, үземдә бер кимчелек эзләргә керештем. Мәктүб язуым урынсыз булып, көлке бер эш кенә булмасын дип уйлыймын. Ләкин үземдәге җитди вә чын бер куәт сезгә хат язарга куша, моның әдәп даирәсендә булган мөддәттә[3] урынсыз түгел икәненә көчле дәлилләр китергән була. Бу дәлилләр, үземнең карамагымда бик көчле булса да, сезгә караганда дәлилләр булырга ярамасыны да беләм. Менә сезгә мәктүб язуымның сәбәбе шул гына. Тагы әллә нин-

---

[1] Яэс – өметсезлек.

[2] Гарыз кыйлу – сөйләп аңлату.

[3] Мөддәттә – вакытта.

ди сәбәпләр булса да, аларны тәгъриф кыйлырга[1] сүзләр таба алмыймын. Сезнең ачу катыш язылган мәктүбеңезне алгач, бу куәт артты гына. Шул куәтнең нәрсә икәнен үзем дә тәгаен кыйла алмаймын. Сез мине читтән генә күреп белгән кеби, мин дә сезне читтән генә күреп беләм. Очраган вакытларымда тик бер чит кеше рәвешле итеп карап күреп кенә үткәнем бар. Шул күрү, синең гүзәл әхлакыңны ишетү күңелемдә бер эз калдырган. Менә мин шул эз вә шул әсәрне[2] күңелемнән чыгарып ташлый алмыймын. Шул эз, бара торгач, бер куәткә әйләнде. Мине үзенең ихтыяры буенча йөртә башлады. Үзем дә бик күп, чынлап бик күп уйлаганнан соң гына сезгә мәктүб язарга уйладым. Татар егетләренең күргән бер кызга урынсыз хат язуларын уйлап, мин дә шулар кебек булмасам ярар иде дип ояламын. Ләкин минем мәкъсудым аларныкы төсле өстәге бер фараз, юкбар өчен генә көн үткәрү түгел. Бәлки, югарыда әйткәнчә, үзем дә тәгаен кыйлып бирә алмаган бер куәт тәэсирендә, гыйффәт[3] даирәсендә языла. Мин шуларны сәбәп күрсәтеп, алдыңызда тез чүгеп, игътизар кыйлам[4]. Бу эш тә кабахәт вә начарлыктан хисапланса, гафу итеңез… Инде сезгә: «Бу мәктүбемә дә җавап языңыз»,– дип риҗа кыйлырга телем бармый, каләмем йөрми. Теләсәңез ни эшләрсез. Ләкин мин мәгъзур бер бәндәңез булдым.

*Игътизар илә Наҗи*

***

Наҗи бу мәктүбенә каршы җавап алыр өмидендә түгел иде. Ләкин үзе дүрт күз белән бер җавап көтә иде. Һич көтмәгәндә, түбәндәге мәктүбне алды.

---

[1] Тәгъриф кыйлырга – аңлатырга, сөйләп бирергә.

[2] Әсәр – эз.

[3] Гыйффәт – намус.

[4] Игътизар кыйлам – гафу үтенәм.

Нажи әфәнде!

Бер кешедән мәктүб алып, каршы җавап язу күңелемә дә килгәне юк иде. Сезнең мәктүбеңезне алгач, үземдә зур бер ачу сизәм. Күңелемдә сезгә әллә нинди бер нәфрәт пәйда була. Ачулансам да, мәктүбеңезне укыгач, күңелемнең бер тарафында кызгану сизәм, нәрсәдер сезне кызганырга, сезгә җавап язарга куша. Читтән күрү белән генә күңелеңездә нинди эз калды икән? Шуны беләсем килә. Моңарчы күңелемә кереп тә чыкмаган уйларга калдыра. Шул сәбәпле мәктүбеңез булмаса иде дип тели башладым. Чөнки әүвәлге рәвештә тыныч, рәхәт көн үткәрәсем килә.

*Рижа кыйлуыңызга бинаэн*[1] *гына җавап язучы С.*

Нажи, Санихәнең бу җавабыны алгач, мәктүб язу-язмау арасында тәрәддед калды[2]. Аның вөжданы бер кызны көчләгән рәвешле итеп үзене сөйдерергә теләми иде. Үзенең мәктүб язып Санихәне борчуын тиешсез бер эш итеп уйлай башлады. Үзенең Санихәне яратуын, күңеленнән фәкать аның сәгадәтене генә теләвен, мәкъсуды гыйффәт даирәсендә генә үзенең сөюен чынлап Санихәгә белдерү булса да, ул аны аңлатырга батырчылык кыйлмый яки аңлатырга гыйбарәләр таба алмый иде. Санихәнең икенче җавабын укыгач, тагы бер мәктүб язудан үзене тыя алмады. Ихтыярсыз, фәкать чын күңеле белән мөтәрәддид[3] булганы хәлдә, өченче мәктүбене яза башлады.

Ханым!..

Минем мәктүбләрем, сезгә авыр йөк төсле булып, сезне борчый вә рәхәтсезләндерә икән. Шулай да мин өченче мәктүб язамын. Сүз аңламый торган нәрсә икән дип әйтүеңезне дә беләм. Ләкин мин үземне үзем тыя алмавымны игътизар юллы[4] белдерәм. Үземдә ихтыярым булса, яки эш

[1] Рижа кыйлуыңызга бинаэн – үтенечегезне канәгатьләндереп.

[2] Тәрәддед калды – икеләнеп калды.

[3] Мөтәрәддид – кыюсыз.

[4] Игътизар юллы – гафу үтенү рәвешендә.

юктан бер эш булсын дип мәктүб яза торган булсам иде, инде бу мәктүбемне язып тормас идем. Болай хат язып сезне борчуны намуссызлык дип белер идем. Күрү белән генә нинди эз булырга кирәк дисәңез, моның җавабы минем кашымда бик җиңел һәм бик мөмкин булган эш. Бер күрү белән түгел, бәлки күп мәртәбә күрү белән калган эз… беләсеңез килсә… аһ, авыр булса да әйтәем: ул сезгә булган мәхәббәтем… Минем күңелемдә сезгә мәгълүм булмаган бер мәхәббәт бар ки, мин аны эз дип тәгъбир итәм. Сезнең белән күреп танымый, чит бер кеше көенчә мәктүб язуымда бөтен тормышымыз гаепле. Менә шул мәхәббәт, яңа башлаган булса да, мине үзе теләгәнчә йөртә аладыр. Мин бу мәктүбем белән ихтыярсыз гына игълане мәхәббәт иткән булып чыктым. Инде сез ниһаять дәрәҗәдә ачуланырсыз. Ләкин сезнең гафуыңызга мәгъзур булып, буйлә итәргә җәсарәт итәм. Затән[1], бу урынсыз бер җәсарәт тә түгел. Чөнки үз ихтыярымда булмаган нәрсә икәнене тәкърар язган идем. Мин үземнең сәгадәтемне сезне яратуда гына, тугърысы, сездә генә дип чын күңелемдәй игътикад кыйлганга[2] күрә, бу рәвешчә мәктүб язып, үземнең сезне яратуымны сезгә белдерүемне урынсыз дип тә белмимен. Икенче берәүнең бәхетсезлегенә сәбәп булмау шарты илә һәр кеше үзенең сәгадәте юлында иҗтиһад кыйлуда ихтыярлы дип беләм. Инде мин мәкъсудымны үземчә ачык белдердем дип уйлыймын. Сезнең тарафта һичбер әсәр булмаса, ул вакытта мин үземне бәхетсез бер кеше дип беләм дә, моннан соң сезгә мәктүб язып борчымаска вәгъдә кыйлам. Фәкать миндә һаман мәхәббәтеңез үлгәнчә калачак. Ихтирам илә сездән дә актык мәртәбә җавап язуыңызны өмид итәм.

*Әсиреңез Нәҗи*

[1] Затән – асылда.

[2] Игътикад кыйлган – ышанган.

***

Әфәнде!

Беренче мәктүбеңезгә җавап язганыма үкенә башладым. Шул беренче мәктүбеңезне җавапсыз калдырган булсам, ихтимал, мәктүбләреңез берсе артыннан берсе дәвам итмәс иде. Сез бу мәктүбеңез белән миңа игълане мәхәббәт кыйлгансыз… Бер яктан гына булган мәхәббәттән, белмәм, зарар гына күрмәссез микән? Күңелеңездәге эзнең ни икәнен белдем. Ләкин ул эз минем тарафта бар микән? Шуны да уйлаңыз. Минем әхлак вә тәрбиямне белмәенчә, бу дәрәҗә мәфтүният изһар кыйлуыңызның[1] мәгънәсенә төшенә алмадым. Мәхәббәт тәклиф белән[2] була торган нәрсә түгел икәнен шаять миннән артык белә торгансыздыр. Мәхәббәт авыр диләр, һәм сез дә шуны язасыз. Ләкин үз башыма төшкәч, бу хакта бер сүз дә әйтә алмыймын. Бераз уйлыймын әле. Форсат биреңез, әсир булмый торыңыз.

*Санихә*

Санихәнең бу мәктүбе Наҗига, бер яктан, өмид бирде. Икенче яктан, өмидсезлек тудырды. Санихә үзене мыскыл иткән төсле күренде. Ул Санихәнең тиз генә исе китми торган кыз икәнен белгәч, бигрәк тә мәфтүн була, аның тирән гакыллы булуы белән хөкем итә иде. Инде мәктүб язаргамы, юкмы? Бераз уйлыймын әле, дигән сүзләренә карап, өмиде өзелмәде. Тагы мәктүб язса, бердән, үзенең актык мәктүбем дигән сүзенә хилафлык иткәнен, икенчедән, Санихәнең «бер яктан гына булган мәхәббәттән, белмәм, зарар гына күрмәссезме?» дигән сүзенә каршы булганын уйларга кереште. Наҗи ихтыярсыз гына түбәндәге мәктүбне яза башлады.

[1] Мәфтүният изһар кыйлу – яратканлыкны белдерү.

[2] Тәклиф белән – көчләп.

Санихә ханым!

Мөстәһзиянә[1] язган мәктүбеңезне, тугъры әйткәндә, җавабыңызны алдым. Теләсә ничек язылган булса да, җавабыңыз минем каршымда иң гали урынны тота. Истихфаф нәзаре[2] белән булган бер тәбәссемеңез[3] дә мине шатландырыр төсле була. Игълане мәхәббәт кыйлуым сезгә карaганда бик гарип күренсә дә, үзем бер дә гаҗәпсенмимен. Сезгә «миңа мәхәббәт итегез» дия тәклиф итәргә хакым юк. Һәм итмәм дә. Күңелемә кергән мәхәббәтеңезне үзеңезгә игадә кыйлыр[4] идем. Ихтыярымда түгел. Беренче мәктүбемә каршы җавап язуыңызга үкенәсез икән… Минемчә, монда үкенерлек бернәрсә дә юк. Мин бары үземнең мәхәббәтем барлыгыны сезгә белдердем. Инде сез миңа мәктүб язарга бурычлы түгелсеңез. Мәктүбеңезнең ахырында «әсир булмый торыңыз» дип куясыз. Әсир бирелү кешенең үз ихтыярында булса, һичкем әсир бирелмәс иде. «Мине алдар өчен әсир булдым дип әйтәсез» дигән булсаңыз, ул вакытта бераз яңлышасыз. Мәхәббәт дигән сүзгә бик кырын күз белән караган рәвешле күренәсез… Күңелемдә яшереп калдыру дәрәҗәсеннән узганга күрә генә яздым. Соңгы җавабыңызны алгач, каршыңыздан үтәргә тугъры килде. Нәрсәдер укып утыра идеңез, мине күргәч тәбәссем иткән төсле күрендеңез. Бу тәбәссемеңез мине мыскыллаган кеби булды. Моның тәэсирене тәгъриф итә[5] алмавыма ышанамын. Бу елмаюыңызның мәгънәсен ике көн буенча уйлап, төшенә алмадым. Кәефеңез китсә дә, тагы бер рәт әйтеп узам: сезгә булган мәхәббәтем мине тәмам изде. Сезгә күңелле, уенчак булган нәрсә минем иң мөкаддәс булган бер әйберем булды. Тәбәссем вакытыңыздагы кыяфәтеңезне күз алдыма китереп, сәгатьләр буенча тамаша итәм. Дөньяда бәндәләр өмид аркасында гына көн күреп яшәүләренә ышанам.

[1] Мөстәһзиянә – көлеп.

[2] Истихфаф нәзаре – җиңелчә мыскыллау.

[3] Тәбәссем – елмаю.

[4] Игадә кыйлыр – кире кайтарыр.

[5] Тәгъриф итә – аңлатып бирә.

Менә шул өмид җәсарәт бирде дә, бу мәктүбемне яздым. Уф!.. Мине дә кызганыңыз. Рәт белмәгән, тәрбия күрмәгән, җүнсез кешеләр рәтенә тезмәгез. Гыйффәт белән булган мәхәббәтнең мөкаддәс икәнен хәтереңезгә китереңез.

*Мәхәббәт белән мөбтәля[1] Наҗи*

***

Наҗинең бу мәктүбенә каршы Санихәдән түбәндәге кыска гына җавап килде:

Наҗи әфәнде!

Мәктүбеңезне җавапсыз калдырырга ни өчендер вөҗданым кабул итмәде. Белмимен, бу дәрәҗәдә мәхәббәт булыр микән? Мәхәббәтнең авырлыгыннан бәхәс итәсез. Бу мәхәббәт миндә булса, миңа да шулай авыр булуыннан куркып, чын көчем белән мәхәббәткә мөбтәля булудан саклanaмын. Тәбәссем итүемнең мәгънәсенә төшенә алмагансыз. Башка ни язаем? Мине мәгъзур күреңез! Миндә һәнүз[2] мәхәббәтнең ни икәнен чынлап белү юк. Үзем шулай да җавап язарга тиешле төсле күрәм. Моның нәрсәдән килгәнен үзем дә белмимен.

*Санихә*

***

Санихә ханым!

Кыска гына җавабыңыз да мине чиксез шатландыра. Гафу ит, мин тагы мәктүб язып сезне борчыймын. Нечкә табигатең, хәссас[3] күңелең, ихтимал, әсәрләнеп борчыла торгандыр. Моны бик ачык белсәм дә, мәктүб язарга юл калган төсле була да, мәктүб язамын. Мәхәббәтнең ялган булуына ышана алмыймын. Ялган булдыйсә, мәхәббәт дип әйтеп булмыйдыр. Бу эш хатын-кызны уенчык рәвешле итеп караган тәрбиясез кешеләрдә генә булса булыр. Уйлә кешеләр-

[1] Мөбтәля – кайгыга төшкән.

[2] Һәнүз – әле дә, һаман.

[3] Хәссас – сизгер.

гә чын кальбем белән нәфрәт итәм. Гыйффәт, сәдакать[1] даирәсендә булмаган мәхәббәт сәфаһәт[2], начарлык буладыр. Җәнабе хак[3] андай бер фикердән, яман уйдан үзе ерак кыйлсын. Ялган мәхәббәт белән йөргән, алдашкан кешеләр тәрбиясезлек илә мәгъруф[4] бер сыйныф халыклар арасында була. Минем вөҗданым алай булуны күтәрә алмый. Андай кешеләрне иң түбән кешеләр рәтенә тезәмен. Вөҗданым мондый түбәнлектән ерак икәнен сезгә белдерәсем килә. Бер гафифә[5] кызны алдаштырып начар хәлләргә төшергән, аларның күз яшьләре агуына сәбәп булган адәм сурәтендәге хайваннарга мең җаным белән ләгънәт укыймын. Гадел Алла аларның җәзаларын бирсен. Минем мәктүбләремне бу рәвешле начар ният белән язылганга хәмел итүеңезне[6] белсәм, үлсәм дә, баштук мәктүб язмаган булыр идем. Ләкин сезнең бу дәрәҗәдә тирән фикер белән үзеңезне тота белүеңезгә тәхсин итәм[7]. Кешенең бер күлеп караву, бер-ике юл мәктүбенә алданып ни эшләргә белми йөргән фикерсез, киләчәгенә уйламаган кызлар җөмләсеннән булмавыңызга «афәрин!»нән[8] башка сүзем юк. Фәкать минем хәтерем өчен генә юк мәхәббәтеңезне бар кыйлсаңыз, яки бер мәктүбемне алу белән, «мин дә сезне шулай яратам» дип язсаңыз, ихтимал, минем мәхәббәтем бу дәрәҗәгә ирешмәйүк сүнәр иде. Бәгъзе татар кызларының егетләрнең бер хатыны булу белән, яисә бер мәртәбә күрешеп сөйләшеп утыру белән, тәҗрибәсез-нисез, бер-берсен үләр дәрәҗәсендә яратышкан булып алданышуларыны үзем дә яратмыймын. Бу эшләрнең һәммәсе тәҗрибәсезлек, хәтта тәрбиясезлек, ниһаять, киләчәкне уйламаучылыктыр. Аларның шул

[1] Сәдакать – дуслык, турылык.
[2] Сәфаһәт – бозыклык.
[3] Җәнабе хак – Алла.
[4] Мәгъруф – танылган.
[5] Гафифә – намуслы.
[6] Хәмел итүеңез – юравыгыз.
[7] Тәхсин итәм – яхшы дип әйтәм.
[8] Афәрин! – шәп! (мактау сүзе).

тәҗрибәсезлек һәм тәрбиясезлекләренең зарарлары, үзләреннән артып, башкаларга да тиядер. Әле мин әхлак китабы язмыймын. Сезгә әхлак үгрәтүне дә дәгъва кыйлмыймын. Бу җөмләләр сезнең сүзеңез мөнәсәбәте белән язылды. Кыскасы, эш юктан эш булсын дип кенә мәктүб язмаганлыгымны белдерә. Моны исбат кыйласым килә. Мәктүбләремнең һәрберсе мәхәббәт, чын мәхәббәтнең сәүкы[1] белән язылалар. Дөрест, мәхәббәт бер генә тарафтан булса, ике калебнең бергә кушылуы, күңел берләшүе мөмкин түгелдер. Мин бу хактагы фикереңезне соңгы мәктүбеңездән генә белдем. Инде гафу итеңез. Моннан соң сезне борчымаска чын күңелем белән иҗтиһад кыйлып карармын. Сезгә төшкән мәхәббәтемне эчемдә саклап үләрмен. Артык хәлем калмады. Хушыңыз!

*Нажи*

Нажи әфәнде!

Соңгы мәктүбеңдә татар кызларының тормыш вә гадәтләренең бер чите кергәнгә күрә, бу исә минем эчемне иң пошыра торган эш булганга, бу мәктүбеңә дә җавап язмый калдыруны тиешсез күрдем.供 Сездә мәхәббәтнең бу дәрәҗәдә, ягъни үзеңез тәгъриф кыйлган шикелле үк булуына күңелем һаман ышанмый. Үзең пакь күңелле, вөҗданлы икәнеңә бу мәктүбең шаһид булырга ярарлык. Моны игътираф кыйлмый[2] чарам юк. Бу мәктүбемдә мин дә бераз әхлак сатсам, гафу итәрсезме? Менә минем дөньяда чын мәхәббәт барлыгына ышанмавыма беренче сәбәп – күз алдында булып торган вакыйгалардыр. Шулар мине мәктүб белән генә гарыз кыйлган[3] мәхәббәткә ышанмаска кушалар. Татар егетләренең гадәтләрен белгән кешеләргә бу бер дә генә яшерен эш түгел. Бер кызны корган тозакларына төшерергә теләде исәләр, бик килештергән булып, тугъры, «мин сине яратам, аһ, чыдар хәлем юк» дип хат язган булалар. Мондый хатларга

[1] Сәүкы – этәрүе.

[2] Игътираф кыйлмый – әйтми, танымый.

[3] Гарыз кыйлган – аңлаткан.

алданган кызларны мин, бер яктан, кызганамын. Бер яктан, аларның шул дәрәҗәдә тиз алдануларына ачуым да килә. Күрү, сөйләшү, мәктүб алышуларның һичберсе гаеп түгел. Фәкать кызларның бу кешеләрне тикшерми-нитми, тәрбияләренә карамый, киләчәкләрен уйламый, бары кызык өчен алданышып, гашыйк булдым дип алданулары гаептер. Нигә бер дә генә яшь вакытларының кыйммәтенә тәкъдир итә алмыйлар. Мәктүб язган бер егеткә «ә, бу мине ярата икән, каршы язмый калу кызганыч, бичара, мине күргәч, чыдар хәле калмаган икән» дип каршы җавап яза башласаң, харап булганыңны белми дә калырсың. Бу сүзләрем – гомуми сүзләр. Ә хосусый караганда, мәхәббәт булыр, ләкин бу хакта иркенләп фикер йөртәсем килә. Эш үткәч үкенүдә файда булмаганга күрә, миңа уйларга ирек биреңез. Сабыр итеп, мәхәббәтеңезне бераз басып торыңыз. Мәхәббәт соңында тормышлар да килә, боларны уйларга кирәк. Мәңгелек сәгадәтнең ничек иткәндә булачагыны онытырга ярамый. Бу сезгә гакыл өйрәтү түгел, үземә тәгаллекъ иткәнгә[1] күрә язам. Артык килешсез сүзләрем булса, гафу итәсез!

*Санихә*

Санихә ханым!

Үткән мәктүбеңезгә каршы хат язуны мәктүбеңезне укыганнан соң тиешсез булыр дип белмимен. Үткән хатыңыз мине хәкыйкатән[2] төшендерде. Язган мәктүбеңне уку белән канәгать хасил итәм. Мәктүбләремне җавапсыз калдырмавыңыз мине ни дәрәҗәдә шатландырганын белсәңез!.. Һәрбер мәктүбеңне, белмимен, ничә рәт укый торганмындыр. Сез фикер йөртүдә, минем әхлак вә табигатемне тикшерүдә тәмам-тәмам ихтыярлысыңыз. Ялгыз минем мәхәббәтем сезнең сәгадәтеңез өчен кяфи[3] булмаячагыны үзем дә беләм. Кяшки[4] һәрбер татар кызлары сезнең кебек булса иде… Уй-

[1] Тәгаллекъ иткәнгә – бәйле булганга.

[2] Хәкыйкатән – чыннан да, дөрестән дә.

[3] Кяфи – җитәрлек.

[4] Кяшки – әгәр дә.

ларга ихтыяр бирдем дип әйтергә, сез минем ихтыярымда түгелсез.

Дөньяда мәсгуд яшәр өчен ике тарафның бер-берсенә көфу[1] булуы тиешледер. Артык язарга хәзер лөзүме[2] юк дип беләм. Затән сезгә мәктүб яза башласам, телем тотлыга, сезнең хыялыңызга мәгълүб[3] була. Артык хуш!

*Нәҗи*

Нәҗи әфәнде!

Мәктүбләреңездә мәхәббәт хакында аз яза башладыңыз. Әллә фикереңез үзгәрә башладымы? Һәрвакыт шулай җитдилек кирәк… Мәхәббәттән соңгы мәкъсудыңызның нәрсә икәнен аңлай алмыймын… Гомерләр үлчәүле, коры «мәхәббәт, мәхәббәт» дип йөрүдән бернәрсә булмый. Дөнья булгач, һәркемнең бер эше булырга тиешле. Ике тарафның көфу булырга тиешле икәнен ни өчен яздыңыз? Аңламадым.

*Санихә*

Санихә ханым!

Мәктүбемне җавапсыз калдырмавыңыз өчен никадәр шатланамын. Белсәңез: «мәхәббәт» кәлимәсене күп язып, сезне борчуны вөҗданым күтәрми, чөнки моның әле ялгыз бер тарафта гына булуы ихтимал. Бу хакта язудан үземне көчләп булса да туктатамын. Мәхәббәттән соңгы мәкъсудымны фикереңезне белгәннән соң гына әйтер идем. Ике тарафның бер-берсенә көфу булырга тиешлеге мәсгуд яшәр өчен… Төп мәкъсудыма ирешер өчен сезнең тарафта да мәхәббәт булырга кирәк… Бу хакларда артык тәфсыйлә́т бирергә куркам. Сезне ялкытудан курыкмасам, әллә ничәшәр сәхифә язар идем. Мәктүб яза башласам, артык булмасын дип куркам. Мәктүбләреңездән әллә нинди әсрар[4] вә мәгънәләр чыга. Тәкърар уку белән мәшгульмен. Аңлашылмаган

[1] Көфу – тиң.

[2] Лөзүме – кирәге.

[3] Мәгълүб – җиңелү.

[4] Әсрар – серләр.

бәгъзе эшләр мәктүбне ачык язуга манигъ буладыр. Мәктүбеңездән мине мәхрүм итмәвеңезне өмид вә риҗа итәм[1]. Гафуыңызны өмид итүче.

*Наҗи*

Наҗи!

Мәкъсудыңны тәмам белә алсам, фикеремне язар идем. Юкса яза алмыймын. Дөньяда бер мәкъсудсыз бер эшнең ахырын белми, коры хыял белән йөргән вакытта алдану вә үкенү генә булыр… Ике тарафның бер-берсенә көфу булырга тиеш булуы мәсгуд яшәү өчен, дигән сүзеңездән берникадәре нәрсәләр аңларга мөмкин. Мәкъсудыңны тәмам аңлап җитә алмыймын. Үз тарафымда әллә нинди сызлану… вә мәхәббәт барлыгыны белмимен. Бу урында хәзерге көннән бигрәк киләчәгемне уйлыймын. Башым киләчәктәге сәгадәтем белән мәшгуль. Гыйффәт сәясендә[2] сәгадәткә ирешү – беренче мәкъсудым. Моннан башка яшерен серләр юк.

*Санихә*

Наҗи, бу мәктүбне алгач, үзенең мәкъсудын язмакчы булды. Ул үзенең чын мәкъсудын язарга җәсарәт итә алмый иде. Ул көчен җыйды, бар куәте белән түбәндәге мәктүбне язды.

Санихә ханым!

Соңгы мәктүбеңез минем күптән бирле язарга җәсарәт итә алмый торган фикеремне ачык сурәттә язарга юл ачты. Мин бу фикеремне язар өчен бар куәтемне җыйдым. Коры мәхәббәттән, әлбәт, бер эш тә юк. Мәхәббәттән мәкъсудым – сезнең белән гомер буенча бергә торырга теләү. Үземнең рәхәт вә сәгадәтемне шунда гына дип белүдер. Мәшругъ сурәттә[3], гыйффәт даирәсендә бу мәкъсудым

[1] Риҗа итәм – үтенәм.

[2] Гыйффәт сәясендә – намус белән.

[3] Мәшругъ сурәттә – законлы рәвештә.

хасил була калса, мин үземне иң бәхетле кешеләр җөмләсеннән дип беләмен. Менә шулай мәңге мәсгуд торыр өчен ике тарафның бер-берсенә көфу булуы тиешледер. Шул мәкъсуд белән сезне күрдем, яраттым, чын күңелем белән яраттым. Мәхәббәтеңез күңелемдә тәмам урынлашканнан соң гына мәхәббәтемне гарыз итәргә җәсарәт иттем. Башта ук бер дә мөнәсәбәтсез бу фикеремне язарга, гарыз итәргә[1] мәгъкуль булмады. Мәктүб язып, сезне борчуымда вә башкаларда мәхәббәт гаепле. Сезне яраттым һәм шуны гарыз кыйлдым. Бу мәктүбем белән чын мәкъсудымны яздым. Минем тәрҗемәи хәлем вә башка җәһәтләрем сезгә артык мәҗһүл[2] түгел. Уйларга, фикер йөртергә ихтыярлысыз, фәкать минем яратуым, минем мәслихәт күрүем белән генә эш булмый. Бөтен куәт, бар ихтыяр, минем сәгадәтем бары сезнең кулда. Мәхәббәт өчен башка шаһидем юк. Йөземнең сарылыгын, аз вакытта шул дәрәҗә үзгәрүемне күрсәңез, шаять кызганыр, мәхәббәтем камил идекенә ышаныр идеңез. Кичәләремне сезне уйлау белән үткәрәм. Хыялыңыз алдымда улдыгы хәлдә, сәгатьләр буенча төшенәм. Инде җавабыңызны көтәм. Бу хакта мине мәгъзур күр! Мине кызган, минем мәсгуд булуым үзеңә багланган икәнен бел!

*Гафу итеңез. Әсиреңез Нәҗи*

Нәҗи әфәнде!

Соңгы мәктүбеңездән мәкъсудыңыз ни икәнен тәмам аңладым. Гомердә бер генә килә торган эш булганга күрә, бу хакта күбрәк уйларга тугъры килә. Хәзергә ни язарга да белмимен. Тагы бер җавап язармын.

*Санихә*

Санихәнең кыска гына булган ушбу җавабы Нәҗига зур өмид биргән кебек булды. Нәҗи инде Санихәдән озын бер җавап көтә иде.

---

[1] Гарыз итәргә – аңлатырга, белдерергә.

[2] Мәҗһүл – билгесез.

Санихәнең тәрбияле һәм үзене гүзәл тота белгән кыз икәненә тәмам ышанды. Шуның өчен барган гына саен Санихәгә мәфтүн була[1], бөтен кальбе Санихәнең хыялы белән тулы иде. Санихәдән тиз генә җавап килмәгәч, Нәҗи тагын мәэюс була башлады. Ниһаять, Нәҗи тагы бер мәктүб язды.

Санихә ханым!

Үткән мәктүбемә каршы язган кыска, фәкать мәгънәле җавабыңны алган идем. Аһ, бу җавабыңыз ничаклы өмид биргәнен белсәңез… Андагы вәгъдәңезгә бинаән[2], мин бу көнгә чаклы тагы бер мәктүбеңезне көткән идем. Ләкин өмидем бушка китте. Бу вакытларда үткән көннәрем табигый көннәрдән мең кат озын булып күренде. Минутларны үткәрү дә авыр була башлады. Ниһаять, ушбу мәктүбемне язарга карар бирдем. Монда язарлык бер яңа эш юк. Бер куәт тәэсире белән генә язам. Сезнең ни фикердә икәнеңезне белсәм дә… үзеңезне күреп, тәмам фикеремне белдерсәм… Ләкин бу эш мөмкинме?.. Аһ! бездәге гадәт! Кысынкы тормыш… бөтен мәкъсудларымны җимерә, теләгән теләкләрне әда кыйлырга[3] манигъ була. Ниһаять, тагы мәктүб язарга мәҗбүр буласың. Менә тагы җавабыңызны көтәм. Башка юк.

*Нәҗи*

Нәҗи әфәнде!

Соңгы мәктүбеңне дә алдым. Мәхәббәт чын күңелдән булса, көннәрне үткәрүнең авыр булуында шөбһә юк. Мин әле бер нәрсә дә уйлап җиткерә алганым юк. Моның күп уйлый торган эш икәне үзеңезгә мәгълүм. Күңелне генә ригая кыйлмаганда, монда күп уйларга, күп сынашырга тугъры килә. Болар берсе дә гаеп түгел. Рәхәт вә сәгадәт шул вакытта гына мәңгелек булырга мөмкиндер. Күреп сөйләшергә

[1] Мәфтүн була – соклана, сөя.

[2] Бинаән – нигезләнеп.

[3] Әда кыйлырга – үтәргә.

манигълар бар, дип әйтәсез. Минемчә, монда артык бер манигъ да юк. Бу бик табигый һәм мөмкин булган эш. Чын-чын танышу, әхлак вә табигатьне белү өчен моннан башка мөмкин түгел. Моны һичкем инкяр итмәс. Күрү, сөйләшү гади бер эш булырга тиешле. Ягъни моны, мөмкин түгел, фәлән дип, зурга җибәрергә кирәк түгел. Тормыш, бер кешенең гомере… истикъбале[1], боларга багланган сәгадәт дигән нәрсә – һәммәсе чын уйлауга, холык вә табигатьне тәҗрибә кыйлуга баглыдыр. Мондый эштә һичкемнең хәтере ригая кыйлынырга тиеш түгел. Гыйффәт, сәдакать[2] юл башы булган мөддәттә монда куркып торырлык һичнәрсә юк. Һәркем үзенең сәгадәте өчен тырышырга һәм дә моңа ирешергә теләгән мөддәттә һәммә манигъларны бер якка куеп торырга кирәк. Чын тормышка керергә хәзерләнгән кешеләргә боларны төшенү тиешледер. Коры мәктүб-фәлән белән генә тормышның нигезен кору, тышкы вак нәрсәләргә генә алдануның ахыры хәерле булмас. Җавап язарга вәгъдә кыйлган фикерем дә ушбуларны язу иде. Нигезле мәхәббәт өчен бу эшләр, ушбунда язылган фикерләр зарурдыр. Капылга минем фикерем ушбу.

*Санихә*

Санихә ханым!

Соңгы мәктүбеңез ни дәрәҗә тирән фикер, тормышка тугъры карау белән язылганын күреп, фикереңезнең тугърылыгына хәйран калдым, мәктүбеңезне тәкърар укып бөтен кайгыларымны оныттым. Инде мин шатлык белән минутларымны үткәрә башладым. Күрү, сөйләшүнең тиешлеге хакында артык язып торырга да лөзүм тапмыймын. Затән, күреп, әхлак вә табигатьләрене сынашмаган ике кешенең берләшүләре мөмкин түгелдер. Минем мәктүбләрем күрешү, сөйләшүгә мөкаддимә[3] генә иде. Шул мәктүбләрем-

[1] Истикъбале – киләчәге.
[2] Сәдакать – турылык.
[3] Мөкаддимә – кереш.

не васита итеп[1], сезнең фикерeңезне белдем, беркадәре улсын әхлакыңызны төшендем. Бу эшләр минем матлубым[2] өчен иң зарури эшләрдән хисап кыйлынадыр. Монда язып торырга, чын хиссиятемне аңлатырга сүз таба алмыймын. Минем уй вә фикерем тәмамән[3] шул мәхәббәт тирәсендә әйләнә. Башка сүзләр күрешкәндә.

*Нәҗи*

Нәҗи белән Санихә арасындагы соңгы көннәрдә язылган мәктүбләр.

Сөекле Нәҗи!

Соңгы көннәрдәге үземдә булган үзгәрешләргә үзем дә тәгаҗҗеб итәм[4]. Моннан элек синнән мәктүб килсә-килмәсә дә бер була торган иде. Инде мәктүбләрне көтеп алам. Үземдә булган хиссиятнең алмашуына тәгаҗҗеб итәм. Үткән вакытта сәгатьләрне түгел, көннәрне хисап итми, тизлек белән үткәрә идем. Инде көннәр түгел, минутлар да агырлык белән үтәләр. Күңелемдәге хиссиятемне белдерә алмавым ачык мәгълүм. Күреп сөйләшкәнне көтми, бу мәктүбемне язам. Син безгә килгән вакытта әйтә торган сүзләремнең күбесен оныткянмын. Белмәм, ни сәбәптәндер, хәтеремнән чыкканнар. Сез минем әти, әни хакында язгансыз. Мөхтәрәм әти-әниләрем мине тәрбия иткәннәр. Минем тәрбия вә гыйффәтемә ышаналар. Алар миңа әдәп даирәсендә хөррият биргәннәр. Күрешү-сөйләшүгә алар тарафыннан һичбер манигъ юк. Ата-ана җәһәтеннән никадәре мәсгуд икәнемне тәгъриф итә алмыймын. Мин ул яктан чын бәхетлемен. Табигый, алар минем бәхет-сәгадәтем өчен чын күңелләре белән иҗтиһад итәләр. Аларга итәгать итү белән, аларны шатландырырга бурычлымын. Сезнең

---

[1] Васита итеп – йөртеп.

[2] Матлуб – теләнгән (нәрсә), максат.

[3] Тәмамән – тулысынча.

[4] Тәгаҗҗеб итәм – гаҗәпләнәм.

монда килүеңезгә алар һичбер борчылмый, шатланалар гына. Башкасы күрешкәндә.

*Санихә*

Гүзәлем Санихә!

Дөньяда төрле рәхәтләрнең булуына артык ышанмый идем. Инде ышанамын. Истикъбалемнең кояш төсле якты булуына иман китердем. Мәхәббәтем көннән-көн тәзаид итә[1]. Пәдәреңезнең[2] холыкыны ни дәрәҗәдә ятратканымны белсәңез… Моннан соңгы мөмкин була торган эшләр әмереңезгә табигъдыр[3]. Сәгадәт вә рәхәтемнең сезгә баглануына канәгать хасил иттем. Сине күреп кайтканнан соң булган гомерем минутларына чаклы саналып үтәләр. Көн вә төн уйлаган уйларымны уйлап карасам, һаман шулай сине уйлаган булып чыгам. Очсыз вә чиксез булган бу уй һаман шулай бара. Гомеремнең ахырына чаклы уйларым дәвам итәр төсле күренә. Ниһаять, истикъбальдәге сәгадәтләрне уйлап, үземә җиддият бирәм[4]. Киләчәкне уйлау белән генә күңелем тынычлык таба. Чиксез шатланамын. Шул рәвешле гомерләр үтә, бары бу көннәрнең тизрәк узуын телимен.

*Нажи*

Газизем Нажи!

Мин инде үз-үземнән көләм. Мәхәббәтнең адәмнәргә бу дәрәҗә тәэсир итүенә ышанмый идем. Хәтта чын мәхәббәтнең барлыгыны инкяр итә идем. Буңа исә мокаддәмдәге мәктүбләрем шаһидтер. Инде мәхәббәт, гыйшык дигән нәрсәләрнең барлыгына канәгать хасил иттем. Үзенә мәңгелек иптәш сайлауда, аның әхлакыны тикшерүдә һәрбер кеше чын вә җитди иҗтиһад итәргә тиешледер. Мин моны һәрвакытта иң алда тоттым, үземнең уйлаган фикеремә тугъры килгән, сәгадәтемне көткән бары син генә.

[1] Тәзаид итә – арта.

[2] Пәдәр – ата.

[3] Табигъдыр – иярүдер.

[4] Җиддият – җитдилек.

Инде мин үземнең иҗтиһадымда алданмавыма, мәкъсудыма ирешүемә ышанамын. Мин теләгән эшкә ата-анамның риза булуында шөбһә юк. Менә мин ул яктан чын мәсгудмен. Хәзер күп язып торырга, хиссиятемне тәгъриф кыйлып маташырга лөзүм[1] күрмимен. Фәкать киләчәктәге якын һәм якты көннәрнең тизрәк җитүен, мәсгуд сәгатьләремнең тизрәк килүен көтәм.

*Бакый мәхәббәт илә Санихә*

Гүзәлем Санихә!

Көткән мәсгуд сәгатьләр җитә. Хәзерге көннәрем шатлык белән узалар. Мин шатлыгымнан нәрсә язарга белмимен. Алдымдагы балкып торган көннәрнең булуын сабырсызлык белән көтәм. Синең кебек галиҗәнаб, үз-үзен тота белгән тәрбияле бер кызның үземә мәңгелек иптәш булуын уйлап, үземнең чын бәхетле булуым белән хөкем итәм. Санихә! Чынлап та, мин бәхетлемен. Саф калеб, гыйффәт вә тугърылык сыйфатлары юлбашчысы булган мөддәттә, инсаннарның рәхәт вә сәгадәткә ирешүләрендә шөбһә юк икәненә ышандым. Фәкать шул сыйфатларны сәгадәткә ирешү юлында иң зур корал итеп истигъмаль кыйлырга гына кирәк. Чын мәкъсудка ирешү көннәремез якынлашты. Ихтимал, бу мәктүбем соңгы мәктүбем булыр. Моннан соң бәхет-сәгадәт белән бергә, гомер буе бергә яшәргә насыйп булсын!

Хәзергә сау бул, гыйффәтле, гүзәл Санихәм. Озакламый күрешермез.

*Нажи*

*Беренче тапкыр 1912 елда Уфадагы «Шәрекъ» мәтбагасендә аерым китап булып басылган.*

---

[1] Лөзүм – кирәк, тиеш.

## Хәзрәте Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһи вәссәлләм вә дүрт хәлифә[1]

Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим.

### *Ислам диненең зоһур[2] иткән җире Гарәбстан*

*I*

Азия кыйтгасының[3] гарәб җәнүбәсендә[4], төн ягыннан җәнүбкә таба сузылып яткан, өч тарафы диңгез, бер тарафы корыга тоташкан озын бер җир бар. Бу җирдә борынгы заманнардан бирле гарәб дигән халыклар торганга күрә, бу җирне Гарәбстан яки Җәзирәтел[5] Гарәб дип әйтәләр. Гарәбстан шималь[6] ягыннан Сүрия, шәрык ягыннан Басра көрфезе[7], җәнүб ягыннан Гоман диңгезе, кояш батышы тарафыннан Шаб[8] диңгезе белән чикләнмештер. Хәритадан[9] караган вакытта бу җирнең бер генә ягы коры җиргә кушылып, калган өч ягы су булып күренәдер. Ошбу Гарәб җәзирәсе мәшһүр биш бүлемгә бүленәдер: Хиҗаз, Хадрамәүт, Нәҗат, Йәмән, Гоман. Гарәбстан, комлык булу сәбәпле, иген игәргә яхшы түгел. Анда үзенә махсус төр-

---

[1] Хәлифә – пәйгамбәр урынына калган рухани башлык; берәүнең эшен дәвам иттерүче.

[2] Зоһур – барлыкка килү, килеп чыгу, беленү, күренү, мәйданга чыгу.

[3] Кыйтга – Җир шары коры җиренең аерым кисәкләре, континент; кисәк, өлеш; бүлек, парча: кыска шигырь.

[4] Җәнүб – көньяк.

[5] Җәзирә – атау, утрау.

[6] Шималь – төньяк; сул як, сул кул.

[7] Көрфез – култык.

[8] Шаб диңгезе – Кызыл диңгез.

[9] Хәрита – географик карта.

ле җимешләр, ислемай чыга торган төрле үләннәр генә җитешәдер. Гарәбстанның һавасы гаять эссе, күл-фәлән, агар суы юктыр, һичбер вакытта анда кар яумый, яңгыр да бик сирәк буладыр. Гарәбстанда һәртөрле хайваннар була – иң мәшһүрләре гарәб аты белән дөяләрдер.

### *II*

Хиҗазның шималь ягы белән шәрык тарафы Бәдиятел гарәб дигән җир белән чолганып, җәнүб тарафы Йәмән, кояш батышы тарафы Шаб диңгезедер. Хиҗазның күп җирләре иген игәргә яраксыз булып, күп җирләре тау-таштан гыйбарәттер. Ошбу Хиҗаз кыйтгасында Мәккә, Мәдинә исемендәге мәшһүр ике шәһәр бардыр. Мәккә шәһәре – Шаб диңгезеннән ерак түгел, Гарәфәт, Аби, Кабит, Хира исемендәге таулар арасында салынган бик иске шәһәрдер. Мәккә шәһәренең тирә-ягында Сафа, Мәрвә, Мина, Гарәфәт, Мөздәлифә дигән шәриф[1] вә хөрмәтле урыннар бардыр. Шәһәрнең эчендә Мәсҗид әл-хәрәм[2] дигән урын булып, Кәгъбәтулла хәрәмнең уртасындадыр. Мәккә шәһәренең һавасы гаять эссе булып, җәй көннәрендә тору өчен уңайсыздыр. Мәккә шәһәрендәге бу вакытта алтмыш мең кадәре халык бардыр. Хәзрәте Рәсүл ошбу Мәккә шәһәрендә дөньяга килмештер.

Мәдинә шәһәре Мәккәгә дүрт йөз чакрым чамасы шималь тарафындадыр. Мәдинәдә хәзрәте Рәсүлнең мәсҗид шәрифе, мәсҗид шәриф эчендә Рәсүлебезнең кабер шәрифе – Рәүзаи мотаһһәрә[3] бар. Хәзрәте Рәсүл ошбу Мәдинә шәһәрендә вафат булмыштыр.

---

[1] Шәриф – кадерле, игътибарлы, кадерләүгә лаек; пәйгамбәр нәселе.

[2] Мәсҗид әл-хәрәм – Мәккә һәм Мәдинә шәһәрендә чикләре билгеләнгән изге урын.

[3] Рәүзаи мотаһһәрә – изге бакча.

## *Хәзрәте Рәсүлнең сабый чаклары*

### *I*

### Сөт анасы

Ул вакытта Мәккә гарәбләре яшь балаларны шәһәрдә асрамый, авылларга җибәреп, сөт аналарына биреп имезderәләр иде. Шул рәвешчә хәзрәте Рәсүлне дә Мәккә тирәсендә торучы Бәнү Сәгыйть кабиләсеннән булган Хәлимә исемле бер хатынга имезергә бирмәкче булганнар. Бу хатын башта хәзрәте Рәсүлне алмаска теләсә дә, күргәннән соң, бик яратканга күрә алып кайткан. Хәзрәте Рәсүл боларга килгәч, йортларына бәрәкәт кергән. Малларының сөтләре арта башлаган. Шуннан соң, «бу баланың аягы җиңел булды» дип, яхшы тәрбия итә башлаганнар. Хәзрәте Рәсүл, бик тиз үсеп, алты айда тәпи йөргән, тугыз ай тулганда бик ачык иттереп сөйләшә башлаган. Дүрт яшенә чаклы шул авылда торган. Бишенче яшенә чыккач, сөт анасы хәзрәти Хәлимә Рәсүлебезне Мәккәгә алып килеп, анасы хәзрәти Әминәгә тапшырган. Хәзрәте Рәсүл моннан соң Мәккә шәһәрендә тора башлаган.

### *II*

### Хәзрәте Рәсүлнең анасы һәм бабасының вафат булулары

Хәзрәте Рәсүл алты яшенә җиткән вакытта, анасы Мәдинә шәһәренә атасына зиярәт кылырга бармак булды. Анасы белән хәзрәте Рәсүл дә бергә барды. Мәдинәдән кайтып килгән вакытта анасы авырый башлап, юлда вафат булды. Хәзрәте Рәсүл Мәккәгә Өмәймин кочагында кайтты. Хәзрәте Рәсүлнең анасы да вафат булгач, моннан соң картбабасы Габделмотталиб тәрбия кыла башлады.

Габделмотталиб хәзрәте Рәсүлне ярата иде. «Бу угълым бөек бер кеше булса кирәк»,– дип әйтә торган иде. Хәзрәте Рәсүл сигез яшенә җиткән вакытта, бабасы Габделмотталиб та вафат булды. Үзенең тәрбия кылучысы вә ярат-

кан бабасы вафат булгач, хәзрәте Рәсүл бик кайгырып, җәназасы артыннан елап барды. Моннан соң Рәсүлебезне атасы белән бертуган Әбү Талиб тәрбия кыла башлады. Әбү Талиб бик рәхимле, йомшак күңелле, бик яхшы кеше иде. Бу да хәзрәте Рәсүлне бик яратты. Үз балаларыннан артыграк күреп тәрбия кыла иде. Башта Әбү Талиб уртача тормышлы булса да, хәзрәте Рәсүлне тәрбия кыла башлагач, бәхете ачылды, байлыгы артты. Хәзрәте Рәсүл бала вакытыннан бирле бик матур, гакыллы, гаять әдәпле, искитәрлек канәгатьле иде. Шуның өчен аны күргән бер кеше ярата, аның гакылына хәйран кала торган иде.

## *III*

### Хәзрәте Рәсүл унике яшенә җиткәндә

Хәзрәте Рәсүлнең яше уникегә җиткән чакта, Әбү Талиб Шам шәһәренә сәүдә кылырга китәргә уйлады. Хәзрәте Рәсүлнең Әбү Талибтан каласы килмәгәч, бергә Шамга барырга теләде. Әбү Талиб хәзрәте Рәсүлне гаять яратканга күрә, үзеннән калдырасы килми, үзе белән бергә Шамга[1] алып китте. Кәрван Шамга якын Басра шәһәренә җиткәч, Бәхира дигән бер галимгә очрады. Бәхира: «Әүвәлге китапларда гарәбләрдән бер пәйгамбәр киләчәге хәбәр бирелгән, әле ул пәйгамбәр килгәне юкмы?» – дип сорашты. Болар: «Әле бер дә ишетелгәне юк»,– дип җавап бирделәр. Шул вакытта Бәхира хәзрәте Рәсүлне күреп бик яратты. Гакылы белән моның ахырзаман пәйгамбәре булуын белде. Хәзрәте Рәсүлне янына чакырып, нәселнәсәбен, фикерен сорашты. Рәсүлуллаһның сыйфатлары борынгы китапларда хәбәр бирелгән сыйфатларга туры килгәч: «Гарәбләрдән киләчәк пәйгамбәр ошбу буладыр»,– дип шәһадәт бирде. Әбү Талибка, Шамга бармыйча, малларын шушы җирдә сатып кайтырга киңәш бирде. Әбү Талиб, бу раһибнең[2] сүзе буенча малларын сатып, кире Мәккә шәһәренә кайтып китте.

[1] Шам – Дәмәшкъ, Сүрия.

[2] Раһиб – рухани.

## *Хәзрәте Рәсүлнең өйләнүе вә Шамга икенче рәт сәфәре*

Хәзрәте Рәсүл егерме биш яшенә җиткәч, аның гакылы һәм тугъры булуы бөтен халыкка таралган, һәркем аны яхшы белә иде. Мәккә шәһәренең иң мәшһүр хатыннарыннан Хәдичә исемле хатын хәзрәте Рәсүлгә үзенең малы белән Шамга баруын үтенде. Хәзрәте Рәсүл, кабул итеп, кәрван белән Шамга сәфәр кылды. Монда иптәше Хәдичәнең Мисрә исемле колы иде. Бу елдагы сәфәрдә бик табыш күреп кайттылар. Мәккәгә кайткач, Мисрә хәзрәте Рәсүлне Хәдичәгә бик мактады. Хәдичә хәзрәте Рәсүлнең гакыллы һәм тугъры икәнен белгәнгә күрә, Мисрәдән бу рәвешле ишеткәч, үзен хәзрәте Рәсүлгә гарыз кылды[1], кабул кылса, бармак булды. Хәзрәте Рәсүл кардәшләренә һәм агаларына киңәш кылгач, алар да мәслихәт күрделәр. Чөнки хәзрәти Хәдичә, тол булса да, гаять гакыллы, халык арасында игътибары бик зур, шуның өстенә бик бай иде. Әбү Талиб никах укыды. Бу вакытта хәзрәте Рәсүл егерме биштә, хәзрәти Хәдичә разый Аллаһ ганһә[2] кырык яшендә иде.

## *Хәзрәте Рәсүлнең пәйгамбәр булганчыга кадәре булган хәлләре*

Хәзрәте Рәсүл күркәм холыклы, тугъры сүзле, фәкыйрьләрне кызганучан, гаять мәрхәмәтле иде. Халык арасында тугърылык исеме таралганга күрә Мөхәммәд әл-Әмин дип йөртәләр иде. Бөтен кешеләр хәзрәте Рәсүлне яратып, гаять тугъры сүзле булганга, араларында ызгыш-фәлән булса, хөкем кылдырырга хәзрәте Рәсүлгә киләләр иде. Хәзрәте Рәсүл утыз биш яшенә җиткән вакытта гарәбләр Кәгъбәне яңартырга керешеп, эшләре тә-

---

[1] Гарыз – җиткерү; аңлату, тәкъдим итү.

[2] Ганһә (хатын җенесендәге алмашлык); ганһү (ир җенесендәге алмашлык) – аннан, аның турында.

мам булгач, Хәҗәре әсвәдне[1] урнына кую тугърысында кабилә башлыклары арасында низаг чыкты. Һәрбер кабилә үзе куярга теләде. Иң соңында: «Мәсҗид әл-хәрәм капкасыннан кем керсә, шуның хөкеменә разыйбыз»,– дигән карарга килделәр. Шул вакытта иң элек хәзрәте Рәсүл килеп керде. Бөтен халык шатланып, эшнең ничек икәнен хәзрәте Рәсүлгә сөйләделәр. Хәзрәте Рәсүл бер кием алып, Хәҗәре әсвәдне шуның өстенә салды. Соңра, киемнең һәрбер почмагыннан бер кабиләнең башлыгы тотып, Хәҗәре әсвәдне куя торган урынга китерделәр. Хәзрәте Рәсүл мөбарәк кулы белән Хәҗәре әсвәдне урнына алып куйды. Бу эшкә бөтен халык шатланды.

Хәзрәте Рәсүл яшь вакытыннан бирле кеше белән низаг итмәде. Сүз көрәштерми торган иде. Хәзрәте Рәсүл кырык яшенә чаклы шул гарәбләр арасында торды. Уку-язу өйрәнмәде, һичбер вакытта потларга гыйбадәт кылмады. Ул эшне яратмый торган иде. Ялгыз йөрүне ярата, һәрвакыт фикердә була торган иде. Хира дигән тауга барып гыйбадәт кыла, бәгъзән[2] өчәр көн кайтмый, шунда тора иде.

### *Хәзрәте Рәсүлгә пәйгамбәрлек килүе*

Хәзрәте Рәсүл кырык яшендә вакытта, Хира тавында торган заманында, Җәбраил фәрештә килеп: «Әй Мөхәммәд! Син хак пәйгамбәрсең, мин сиңа Аллаһтан вәхи[3] китердем»,– диде. Шул вакыт «Икъраэ» сүрәсе иңде. Хәзрәте Рәсүл бу вакыйганы хәзрәти Хәдичәгә сөйләгәч тә, хәзрәти Хәдичә: «Аллаһ белән ант итеп әйтәм: син бу халыкның пәйгамбәресең»,– диде.

Хәзрәте Рәсүл башта халыкны ислам диненә яшерен генә өнди башлады. Иң элек үзе якын күргән ышанычлы кешеләрне иманга өндәде. Иң әүвәл иман китереп, мөсел-

[1] Хәҗәре әсвәд – изге Кара таш.

[2] Бәгъзән – кайвакыт, кайчак.

[3] Вәхи – Аллаһ тарафыннан пәйгамбәр күңеленә нинди дә булса фикер ирештерү.

ман булучылар – ирләрдән: хәзрәте Әбү Бәкер; хатыннардан – хәзрәти Хәдичә; сабыйлардан хәзрәте Гали, коллардан – Зәйд бине Харисәдер. Моннан соң күп тә тормый хәзрәте Госман, Габдрахман бине Гәүф, Әз-Зөбәйр бине Әлгәвәм кеби мәшһүр адәмнәр иманга килделәр. Хәзрәте Рәсүл өч ел буенча яшерен генә иманга өндәде. Шул өч ел эчендә утыз кеше иманга килделәр, дин исламның хак вә тугры дин икәнен белеп, җан вә тәннәре белән мөселман булдылар. Бу вакытта мөселманнар яшерен гыйбадәт кылып, Коръәнне аулак җирдә генә укый торганнар иде.

### *II*

Хәзрәте Рәсүл пәйгамбәрлекнең дүртенче елында Аллаһның әмере белән кешеләрне әшкярә[1] сурәттә иманга өнди башлады. Моннан соң бер дә курыкмый, яшерми, һәрбер урында халыкны иманга һәм дә ислам диненә керергә өндәргә кереште. Кяфирләр[2] башта хәзрәте Рәсүлгә ачуланмасалар да, соңыннан ачулары кабара башлады. Төрлечә усаллыклар күрсәтә башладылар. Ләкин хәзрәте Рәсүл аларга һаман йомшаклык белән каршы тора һәм ислам диненең хаклыгын аңлатырга тырыша иде. Кяфирләр һаман ышанмадылар. Хәзрәте Рәсүл аларга: «Әгәр дә минем пәйгамбәр икәнемә, Коръәннең Аллаһ сүзе булуына ышанмасагыз, Коръән кеби бер генә сүрә сөйләп күрсәтегез»,– диде. Бу сүзгә барчасы гаҗиз калдылар. Бер сүрә түгел, бер генә дә аять китерә алмадылар. Аптырагач, хәзрәте Рәсүлгә килеп: «Әй Мөхәммәд! Яңа дин чыгарудан максудың – мал өчен булса, мал бирәбез, әгәр дә кешеләргә башлык итү булса, үзебезгә сине баш итәбез – син бу эшеңнән кайт!» – диделәр. Хәзрәте Рәсүл аларга каршы: «Миңа боларның һичберсе кирәк түгел, Аллаһы тәгалә мине сезгә пәйгамбәр итеп җибәрде. Кабул кылсагыз бәхетле булырсыз, кабул итмәсәгез – Аллаһка тапшырам»,– диде. Шуннан соң мөшрикләр мөселманнар-

---

[1] Әшкярә – яшермәстән, ачыктан-ачык.

[2] Кяфир – Аллаһның берлеген танымаучы.

га төрле-төрле иза вә җәфа кыла башладылар. Ниһаять, хәзрәте Рәсүл әйтүе буенча, бәгъзе мөселманнар Хәбәш дигән җиргә күчеп киттеләр. Бу күчүдә Хәбәш җиренә мөселманнар унике ир, дүрт хатын күчте. Болар өч ай Хәбәштә торып, соңында Мәккәгә кире кайттылар.

## *III*

Хәзрәте Рәсүл һаман иманга өндәүдән туктамагач, Мәккә мөшрикләре[1] ачуларын, иза вә җәфаларын арттырдылар. Хәзрәте Рәсүл һәм мөселманнарны Әбү Талиб һәм Бәнү Һашим яклыйлар вә химая[2] кылалар иде. Шуның өчен мөшрикләр мөселманнарга һәм аларны яклаучы Бәнү Һашим ыругына катышмаска, нәрсә сатмаска, кыз биреп – кыз алмаска гаһед[3] кылып, язып, бу язуны Кәгъбәгә асып куйдылар. Шулай итеп, Шөгәб Әбү Талиб дигән җирдә Бәнү Һашимның мөселман һәм кяфирләре көрәешләргә катыша алмый өч ел тордылар. Ошбу чорда (вакытта) мөселманнардан сиксән ике ир, унсигез хатын икенче мәртәбә Хәбәш җиренә күчтеләр. Бу вакытта мөселманнар һәртөрле иза-җәфаларны күрсәләр дә, хак булган дин исламда булулары өчен сабыр итеп түзделәр, өч ел кадәре вакыт шулай торгач, гарәбләр бәгъзе зурларының киңәше белән, теге гаһеднамәне боздылар. Әбүҗәһил боздырмаска теләсә дә, аның сүзе кабул кылынмады.

## *IV*

## *Кайгы елы (гамь әл-хазан)*

Пәйгамбәрлекнең унынчы елында, һиҗрәттән өч ел элек, Әбү Талиб вафат булды. Хәзрәте Рәсүл, Әбү Талиб вафат булгач, бик кайгырды. Чөнки Әбү Талиб хәзрәте Рәсүлне яклый, кулыннан килгән кадәре ярдәм итә иде. Әбү Талиб вафат булганнан өч көн соңра өммелмөэми-

---

[1] Мөшрик – Аллаһка тиңдәш тотучы.

[2] Химая – саклау, яклау.

[3] Гаһед – килешү, ант итү.

нин[1] хәзрәти Хәдичә разый Аллаһ гәнһә вафат булды. Бу ике затның үлүе хәзрәте Рәсүлгә гаять тәэсир итте. Хәзрәте Рәсүл ниһаятьсез кайгырды. Шуның өчен бу елга кайгы елы дип исем бирде. Болар вафат булгач, мөшрикләр иза вә җәфаларын тагы арттырдылар. Мәккә кяфирләре юл өсләрендә торып, читтән килгән кешеләргә хәзрәте Рәсүлне начар күрсәтергә тырышалар, иманга килмәскә кушалар иде. Бу вакытта бигрәк тә хәзрәте Рәсүлнең якын кардәше Әбү Ләһәб һәм хатыны хәзрәте Рәсүлгә һич тынычлык бирмиләр, намаз укый башласа, өстенә пычрак нәрсәләр ыргыталар, йөри торган юлына чәнечкеле чыбыклар китереп салалар иде. Ләкин хәзрәте Рәсүл моңа карап гайрәт һәм ислам диненә өндәвен киметмәде, һәммәсенә сабыр итеп түзде. Ошбу вакытта хәзрәте Рәсүл Мәккәгә якын Таиф шәһәренә барды. Ләкин алар да хәзрәте Рәсүлнең сүзенә колак салмадылар. Хәзрәте Рәсүл кире Мәккә шәһәренә кайтты.

## *V*

Мәккә кяфирләре хәзрәте Рәсүлгә каршы килеп, һәртөрле иза вә җәфалар кылгач, хәзрәте Рәсүл аларның иманга килүләреннән өмид өзә башлады. Шул сәбәпле чит кабиләләрнең гарәбләрен иманга өндәргә кереште. Шуның өчен Хаҗ вакытында һәм мәшһүр ярминкәләрдә йөреп ислам динен сөйли, халыкны иманга өнди иде. Ислам дипенең гакылга муафыйк булуын күреп иманга килүчеләр күбәя башлады. Пәйгамбәрлекнең уникенче елында Мәдинә шәһәреннән бераз халык Мәккәгә килеп, ислам динен кабул итеп кайтып киттеләр. Икенче елда тагы күбрәк килеп, хәзрәте Рәсүлгә бәйгать[2] биреп, мөселман булып кайттылар. Моннан соң Мәдинә шәһәрендә ислам дине тарала башлады. Моны күргәч, сәхабәләр Мәдинәгә күчә башладылар. Чөнки монда дин тоту өчен иркенчелек иде. Мөселманнар берәм-берәм Мәдинәгә күчә торгач,

---

[1] Өммелмөэминин – пәйгамбәребез җәмәгатьләрен хөрмәтләү сүзе.

[2] Бәйгать – тугрылык хакында ихластан ант итү.

Мәккәдә мөселманнар бик аз калды. Мәккә халкы, Мәдинә шәһәрендә ислам диненең көчәюен күргәч, аптыраша башладылар. Хәзрәте Рәсүлгә, ниһаять, ачулары килде. Бу тугърыда киңәш итәр өчен, Киңәш йортына җыелдылар. Караңгы төндә хәзрәте Рәсүлне үтерергә карар кылып, моның өчен баһадир егетләр сайладылар.

### *Хәзрәте Рәсүлнең Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәте (күчүе)*

Югарыда язылган кяфирләрнең киңәшләрен һәм Аллаһы тәгаләдән Мәдинәгә күчәргә изен[1] булганын, Җәбраил фәрештә килеп, хәзрәте Рәсүлгә хәбәр бирде. Шул көн кич хәзрәте Рәсүл Әбү Бәкер разый Аллаһ гәнһү белән бергә Мәккә шәһәреннән чыгып киттеләр, һичбер кеше сизми калды. Шәһәрдән бик ерак түгел Сәүер дигән таудагы бер чокырга кереп яшеренделәр. Кяфирләр эзләп чыксалар да – таба алмадылар. Хәзрәте Рәсүл белән Әбү Бәкер шул гарда[2] өч көн кадәре торып, кяфирләр арасында шау-шу басылгач, чокырдан чыгып, Мәдинәгә киттеләр. Хәзрәте Рәсүл, пәйгамбәрлек килгәч, Мәккә шәһәрендә унөч ел торды. Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта илле өч яшендә иде. Миляди илә 622 елда 17 сентябрьгә тугъры киләдер. Хәзрәте Рәсүл Мәккәдәге өеннән чыгып киткәндә, урнына хәзрәте Галине калдырып киткән иде. Кяфирләр, төн буенча Гали разый Аллаһ гәнһүне хәзрәте Рәсүл дип саклап, төн үткәрделәр.

### *Хәзрәте Рәсүлнең Мәдинәгә ирешүе*

Хәзрәте Рәсүл һәм Әбү Бәкер миляди белән 622 елда Рабигүләүвәл аеның 8 нче көнендә Мәдинәгә якын Күба дигән җиргә килеп җиттеләр. Күбада өч-дүрт көн торганнан соң Мәдинә шәһәренә керделәр. Мәдинә халкы хәзрәте Рәсүлне каршы алырга һәммәсе коралланып, ма-

---

[1] Изен – рөхсәт, ирек.

[2] Гар – тау тишеге, мәгарә, тау куышлыгы.

тур киемнәр киенеп чыктылар. Гаять зурлап, олугълап каршы алдылар. Хатын вә бала-чагаларына чаклы каршы чыкканнар иде. Бөтен Мәдинә шәһәре зур бер бәйрәмгә әйләнде. Балалар шатланалар. Хатыннар: «Я Рәсүл, хуш килдегез!» – дип матур шигырьләр әйтәләр иде. Мәдинә шәһәренә кергәч, һәркем хәзрәте Рәсүлне үзенең өенә төшерергә теләп, дөясенең тезгененә ябышып: «Безгә рәхим итегез!» – дип әйтәләр иде. Хәзрәте Рәсүл дөясенең ихтыярына куеп, дөя кайда чүксә, шунда төшмәк булды. Ниһаять, дөя Әюб дигән әнсарның[1] йорт алдына килеп туктады. Хәзрәте Рәсүл Әюб әнсарның өендә кунак булды.

### *Хәзрәте Рәсүл Мәдинәгә килгәч ни эшләде?*

Хәзрәте Рәсүлнең Мәдинә шәһәренә күчеп килүенә һиҗрәт дип әйтәләр. Мөселманнарның ел хисабы ошбу һиҗрәттән исәпләнәдер. Хәзрәте Рәсүл Күбада мәсҗид өчен нигез салды. Иң элек салынган мәсҗид ошбу Күба мәсҗидедер. Мәдинәгә кергәч, Мәсҗид әл-хәрәмне салды. Бу мәсҗиднең бер ягына кушып, хәзрәте Рәсүлгә торырга урын-хөҗрә ясадылар. Хәзрәте Рәсүл Мәдинәгә урнашкач, Мәккәдә калган гаиләсен китертте. Хәзрәте Рәсүл килгәч, бөтен Мәдинә халкы мөселман булдылар. Мәдинә халкы хәзрәте Рәсүлгә хөрмәт иткән кеби, Мәккәдән күчеп килгән мөһаҗирләргә[2] дә хөрмәт кылдылар. Мәккәдән күчеп килгән сәхабәләргә мөһаҗир, Мәдинә халкына әнсар дип әйтәләр. Хәзрәте Рәсүл болар арасында, боларны дуслаштыру өчен, бер-берсенә карындаш ясады. Хәзрәте Рәсүл Мәдинәгә килгәч тә дин исламны өйрәтү, аны тарату белән мәшгуль булды. Моннан соң мөселманнар күбәя башладылар. Көчләнделәр. Хәбәш җиренә күчеп киткән мөселманнар да Мәдинә шәһәренә кайттылар.

---

[1] Әнсар – сәхабәләр; пәйгамбәрнең ярдәмчеләре.

[2] Мөһаҗир – чит җиргә күчүче, эмигрант.

## *Хәзрәте Рәсүлнең моннан соңгы хәлләре*

### *I*

### Һиҗрәттән беренче вә икенче ел

Һиҗрәтнең беренче елында, фарыз намазларының вакытларын белдерер өчен, азан укыла башлады. Дошманнар белән сугыш фарыз кылынды. Мәдинәдә дин ислам куәт табып, Мәдинәгә якын җирләрдәге гарәбләр арасына ислам динен тарата башладылар. Мәккә халкы ислам diненең куәт табуыннан курка башладылар. Ничек булса да ислам динен бетерергә тырыштылар. Хәзрәте Рәсүлне үтерергә дип кешеләр җибәреп карадылар. Ниһаять, кяфирләр белән мөселманнар арасында һиҗрәтнең икенче елында Бәдер сугышы дигән сугыш булды. Бу сугышта мөселманнар булганы өч йөз генә иде. Кяфирләр меңгә якын булса да – җиңелделәр. Бу сугышта мөселманнарга иң зур дошман булган Әбү Җаһил һәм җитмеш кадәре кяфир үтерелде. Калганнары качтылар. Бәгъзеләре мөселманнар кулына әсир булып төштеләр. Мөселманнардан ундүрт кеше шәһид булды. Ошбу елда кыйбла алмашынды. Моннан элек намазны Бәйтелмөкаддәскә[1] карап укыйлар иде. Моннан соң Мәккә шәһәрендәге Кәгъбәтуллага карап укый башладылар. Рамазан аенда рүзә тоту, фитыр сәдакасы бирү, гайд намазы уку, зәкят бирү һиҗрәтнең икенче елында фарыз булдылар.

### *II*

### Һиҗрәттән өченче ел
### Өхед сугышы

Бәдер сугышында җиңелеп кайткан Мәккә мөшрикләре, мөселманнардан үч алыр өчен, һиҗрәтнең өченче елында өч мең гаскәр белән Мәдинәгә карап чыктылар. Мөселманнар бу хәбәрне ишеткәч, төрлечә киңәш кылышып, ахырда кяфирләргә каршы чыкмак булдылар. Монда да мөселман

[1] Бәйтелмөкаддәс – Иерусалим (Кудс) шәһәрендә изге гыйбадәт йорты.

гаскәре бары җиде йөз генә иде. Хәзрәте Рәсүлуллаһ сәхабәләргә: «Мин кушкан рәвешле йөрсәгез, сабыр итсәгез, җиңәрбез»,— диде. Мәдинәгә якын Өхед дигән тауда ике гаскәр очрашып, сугыша башладылар. Башта мөселманнар үзләреннән әллә ничә өлеш артык булган дошманнарны җиңә башлаганнар иде, ләкин бәгъзе мөселманнар, Рәсүлуллаһ әйткәнчә, урыннарында тормаганлыкларыннан, ахырда үзләре җиңелә башладылар. Мөселманнар кача башладылар. Хәзрәте Рәсүл берничә сәхабә белән урыныннан кузгалмады. Бу сугышта мөселманнардан җитмеш кеше шәһид булды. Хәзрәте Хәмзә дә шулар арасында иде. Хәзрәте Рәсүлнең мөбарәк яңагы яраланды. Соңыннан кяфирләр: «Без җиңдек инде»,— диделәр дә, мөселманнарга башка зарар китерә алмый, кайтып киттеләр. Үзләре дә артык файда күрә алмадылар. Бу ел мөселманнарга хәмер эчү хәрам булды.

### *III*

### Һиҗрәттән бишенче ел
### Хәндак сугышы

Һиҗрәтнең бишенче елында Мәккә кяфирләре тирә-яктан ун мең кадәре гаскәр җыеп, Мәдинәне алырга, мөселманнарны тәмам кырырга ният кылып, Мәдинә шәһәренә килергә чыктылар. Хәзрәте Рәсүл, кяфирләрнең бу эшләрен ишеткәч тә, сәхабәләргә киңәш итте. Сәлмән әл-Фарси дигән сәхабәнең фикере буенча, Мәдинәнең тирә-ягына тирән канау казып, әйләндереп алдылар. Шуның өчен бу сугышка Хәндак[1] сугышы дип әйтәләр. Кяфирләр, бу хәндакны күргәч, хәйран калдылар. Шәһәргә керә алмыйча, канауның тышкы ягына, Мәдинәне чолгап, ике атна кадәре тик яттылар. Беркөнне, төнлә бик каты җил-давыл чыгып, кяфирләрнең куышларын егып бетерде. Кяфирләрнең күңелләренә курку төште. Мөселманнар капыл гына басып, кырып бетерерләр дип, ашыгып кире кайтып киттеләр. Мөселманнарга һичбер зарар китерә алмадылар.

[1] Хәндак – озын итеп казылган чокыр, траншея, окоп.

## *IV*

## Һиҗрәттән алтынчы ел
## Хөдәйбиия мөгаһәдәсе

Һиҗрәтнең алтынчы елында хәзрәте Рәсүл Мәккә шәһәренә Кәгъбәтулланы зиярәт кылып, гөмрә[1] кылмак булды. Бер мең дә йөз сәхабә белән юлга чыкты. Хөдәйбиия исемле бер җиргә җиткәч, хәзрәте Госманны Мәккәгә җибәреп, сугыш өчен түгел, Кәгъбәне зиярәт кылыр өчен килгәнен белдерергә кушты. Мәккә халкы бу эшкә дә разый булмыйча – хәзрәте Госманны җибәрми, ябып куйдылар. Хәзрәте Рәсүл: «Алай булса, безгә сугыш тиешле булды»,– дип, дин өчен сугышырга сәхабәләрдән вәгъдә алды. Бу хәбәрне көрәешләр ишетеп курыктылар. Хәзрәте Госманны җибәрделәр. Шуннан соң көрәешләр белән мөселманнар арасына бер мөгаһәдә[2] төзелде. Менә ошбу мөгаһәдәгә Хөдәйбиия мөгаһәдәсе дип әйтәләр. Ошбу мөгаһәдә буенча хәзрәте Рәсүл, киләсе елга килмәк булып, Мәдинәгә кайтып киттеләр. Хәзрәте Рәсүл, Мәдинәгә кайткач, чит падишаһларга хатлар язып, илчеләр җибәрде. Аларны да ислам диненә өндәде. Бу патшаларның кайсылары мөселман булдылар. Бәгъзеләре буйсынып, бүләкләр җибәрделәр.

## *V*

## Һиҗрәттән җиденче һәм сигезенче еллар

Һиҗрәтнең җиденче елында хәзрәте Рәсүл бер мең дә алты йөз сәхабә белән Мәдинәдән өч көнлек җирдәге Хәйбәргә барып сугышты. Бу җирләр дә мөселманнар кулына керде. Шул елда Хөдәйбиия мөгаһәдәсе буенча Мәккәгә барып, ике мең сәхабә белән, Кәгъбәне тәваф[3] кылып кайтты.

Һиҗрәттән сигезенче елда мәккәлеләр Хөдәйбиия мөгаһәдәсен боздылар. Моны ишеткәч, хәзрәте Рәсүл ун мең

[1] Гомрә – фарыз булмаган вакытта Хаж, нәфел Хаж, фарыз түгел Хаж.

[2] Мөгаһадә – килешү, вәгъдәләшү, сүз бирешү.

[3] Тәваф – карау; бер нәрсәнең тирә-ягын әйләнү.

сәхабә белән Мәккә шәһәренә китте. Мәккәгә җитәр чакта, бәгъзе зур кешеләр үзләре каршы килеп, мөселман булдылар. Бу чаклы мөселманнарның килгәнен күргәч, Мәккә халкы бик курыктылар. Каршы сугыша алмадылар. Хәзрәте Рәсүл сәхабәләр белән бергә Мәккә шәһәренә керделәр. Хәзрәте Рәсүл Мәккәгә кергән вакытта, кайгылы кеше кеби, башын түбән салып керде. Кәгъбәтуллага барып, потларны чыгартып ташлатты. Кәгъбәне тәваф кылганнан соң, ике рәкәгать намаз укыды. Соңыннан кяфирләргә һичбер зарар ишеттермәде. Соңра бик әсәрле хөтбә[1] сөйләп, дин исламның хөкемнәрен бәян кылды. Көрәешләр хәзрәте Рәсүлнең бу чаклы яхшы, күркәм мөгамәләләрен күргәч, хәзрәте Рәсүлнең Хак пәйгамбәр икәненә ышанып, мөселман булдылар. Шул көн хәзрәте Билал азан укыды. Мәккә халыклары Рәсулуллага бәйгать бирделәр. Хәзрәте Рәсүл моннан соң Мәдинәгә кайтып китте.

### *VI*

### Хәзрәте Рәсүл Мәдинәгә кайткач һиҗрәтнең тугызынчы елы

Мөселманнар Мәккә шәһәрен алып кайткач, тирә-яктагы кяфирләр бик кайгырып, егерме мең гаскәр җыйдылар. Сугышка хәзерләнделәр. Моны ишетеп, хәзрәте Рәсүл, унике мең гаскәр белән, боларга каршы чыкты. Бу сугышта да, ниһаять, мөселманнар җиңеп, кяфирләр качтылар. Бәгъзеләре, кире килеп, мөселман булдылар. Бәгъзеләре Таиф шәһәренә барып җыелдылар. Мөселманнар, артларыннан барып, Таиф шәһәрендә сугышмакчы булсалар да, аларның мөселман булырга теләгәннәрен ишетеп, кире кайтып киттеләр. Соңында болар, үзләре килеп, мөселман булдылар. Хәзрәте Рәсүл әсирләрне кире кайтарып җибәрде.

Һиҗрәтнең тугызынчы елында хәзрәте Рәсүл Әбү Бәкер разый Аллаһ гәнһүне баш кылып, Мәккәгә хаҗ кылырга җибәрде. Иң элек кылынган хаҗ – ошбу хаҗдыр.

---

[1] Хөтбә – нотык, сөйләнгән сүз; вәгазь.

Ошбу вакытта хәзрәте Гали Мәккәгә барып, «Бәраәт» сүрәсен укып, ислам хөкемнәрен бәян кылды.

## *VII*

## Дин исламның куәт табып таралуы

Хак булган ислам динендәге мөселманнар, кайда барсалар да, дошманнарын җиңгәч, Мәккә шәһәре алынып, Хөнәйөн сугышында да кяфирләр җиңелгәч, күп кешеләр дин исламның хаклыгын белделәр. Тирә-яктагы гарәбләр нәсел-ыру, бала-чагалары белән килеп ислам диненә керә башладылар. Бөтен Гарәбстанда ислам нуры балкыды. Егерме өч ел эчендә бөтен гарәп халкы мөселман булып беттеләр. Моннан соң мөселманнарга һичкемнән курку калмады. Кайда гына булса да, һич курыкмый, ислам хөкемнәрен җиренә җиткерделәр. Ислам дине чит җирләргә чаклы ишетелде. Борынгы надан, эшлексез гарәбләр, ислам динен кабул кылу белән, яхшы һәм эшлекле була башладылар. Борынгы начар гадәтләрен ташладылар, моннан соң хәзрәте Рәсүл, бик тырышып, ислам диненең хөкемнәрен өйрәтә башлады. Гыйбадәт, әхлак, тормыш хакындагы мәсьәләләрне бәян кылды, һәрбер эшне тәртипкә салды. Кешеләргә дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булу юлын күрсәтте.

## *VIII*

## Һиҗрәттән унынчы ел
## Хәҗҗәт әл-видагъ[1] (хәзрәте Рәсүлнең соңгы хаҗы)

Һиҗрәтнең унынчы елында хәзрәте Рәсүл хаҗ кылырга бармак булды. Бу хәбәрне ишеткәч, тирә-ягындагы мөселманнар Мәдинәгә килделәр. Хәзрәте Рәсүл туксан мең кадәре кеше белән Мәккәгә барырга юлга чыкты. Бу хаҗда йөз меңнән артык мөселманнар җыелган иде. Хәзрәте Рәсүл тугызынчы Зөлхиҗҗәдә Гарәфәттә хөтбә укып, дин исламның хөкемнәрен бәян кылды. «Әлйәүмә әкмәләтү» аятен укып, гомеренең аз калганына ишарә кылды. Бөтен

---

[1] Видагъ – озату, саубуллашу.

өммәтенә сөйли торган васыятьне сөйләде. «Аллаһы тәгалә тарафыннан җибәрелгән дин исламның хөкемнәрен һәм Коръәнне сезгә ирештердемме?» – дип сорады. Хәзрәте Рәсүлнең гомере аз калганын сизеп, бәгъзе сәхабәләр егъладылар. Мәккәдә ун көн кадәре торгач, хаҗилар белән күрешеп, Мәдинәгә кайтып китте. Бу хаҗ хәзрәте Рәсүлнең соңгы хаҗы булганга күрә хәҗҗәт әл-видагъ дип әйтәләр.

## *IX*

## Хәзрәте Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһи вәсәлләмнең вафаты

Һиҗрәтнең унберенче елында, Сәфәр аеның ахырларында, хәзрәте Рәсүл авырый башлады. Авыруы көннән-көн артып, Рабигүләүвәл аенда авыруы гаять куәтләнде. Вафатына өч көн калгач, мәсҗидкә чыга алмады. Хәзрәте Әбү Бәкергә, имам булып, намаз укырга кушты. Сәхабәләр[1], хәзрәте Рәсүлнең намазга чыга алмаганын күргәч, гаять кайгырыштылар. Шулай да хәзрәте Рәсүл, башына бәйләп, намазга чыкты. Сәхабәләргә актык нәсыйхәтләрен сөйләде. Шуннан өч көн соңра – Рабигүләүвәлнең уникенче көнендә, дүшәмбе көн, төштән элек – алтмыш өч яшендә вафат булды (хәзрәте Рәсүлнең вафаты миляди илә 632 елга тугъры киләдер). Хәзрәте Рәсүлнең вафат булганын ишеткәч, сәхабәләр гаять кайгырдылар. Мәсҗидләрдә вә башка урыннарда егълаган тавышлар ишетелде. Бәгъзе сәхабәләр һушсыз булдылар. Вафат булганының икенче көнендә, вафат булган урынын казып, дәфен[2] кылдылар. Бу көндә Мәдинә шәһәрендә Рәүзаи мотаһһәрә дигән урын хәзрәте Рәсүлнең кабер Шәрифедер. Хәзрәте Рәсүл үзе вафат булды. Ләкин мәңге бетми торган, адәмнәрнең бәхет вә сәгадәтенә сәбәп булган дин ислам һәм Коръән Шәрифне калдырды.

---

[1] Сәхабә – пәйгамбәрнең замандашлары, иярченнәре.

[2] Дәфен – җирләү; мәетне күмү; яшерү.

## *Коръән Шәриф*

Коръән Шәриф Аллаһы тәгалә тарафыннан хәзрәте Рәсүлгә егерме өч ел эчендә тәмам итеп бетте. Шәригать хөкемнәре һичбер калмыйча тәмам бәян кылынды. Коръән – бөтен кешеләрнең дөнья вә ахирәттә бәхетле булулары өчен җитәрлек бер китаптыр. Коръән – Аллаһы тәгаләдән Рәсүлебезгә бирелгән бер китаптыр. Коръән – Аллаһы тәгаләдән Рәсүлебезгә бирелгән иң зур могҗизадыр. Коръәннең бер генә аяте[1] кеби аять яза алу һичкемнең кулыннан килерлек түгелдер. Шуның өчен күп кешеләр, Коръәнне укыгач хәйран калып, Аллаһы тәгалә сүзе икәненә ышанып, иман китерделәр.

Коръәндә Аллаһының барлыгы һәм берлеге, гыйбадәт һәм мөгамәләт[2] эшләре, Шәригать хөкемнәре, халыкка яхшылык кылу, ярлыларны ярату, гыйлемгә рәгъбәт[3] итү, һәрвакытта фикердә булып, бу дөньядагы нәрсәләрне уйлау вә башка шундый бәндәләргә иң кирәкле эшләр бәян кылынмыштыр. Коръәндә иң әүвәл иңгән сүрә «Икъраэ» сүрәсе булып, иң ахырда иңгән аять «Әлйәүмә әкмәлтү ләкүм динәкүм»[4].

Коръәндә 114 сүрә булып, 6616 аять бардыр[5].

---

[1] Аять – галәмәт, әсәр, билге (әмма шигырь түгел).

[2] Мөгамәләт – «мөгамәлә» сүзенең күплек саны.

[3] Рәгъбәт – теләү, омтылыш, кызыксыну.

[4] Мөхтәрәм зат М. Гафуриның бу фикере хата. Хак ки, бу өлкәдә заманында зур бәхәсләр булып, соңыннан Ислам фәлсәфәсе галимнәре уртак фикергә килгәннәр: Коръәни Кәримдә иң азагы иңгән аять – бу 2 нче сүрә «Бәкарә»нең 280 нче аять-кәримәседер: «Ваттаку йаоман туржагунә фиһи илаллаһ, сумма туваффа көлле нәфсинма касабат вә һум лә йузламун». Димәк, автор күрсәткән 5 нче сүрә «Маидә»нең 3 нче аятькәримәсе гыйльми хаклыкка хилаф икән. Кара: Ризаэддин бине Фәхреддин. Коръән вә Мосхәф // Ислам мәҗәлләсе.– 1924.– № 2.– 45 б.

[5] Бу фикер дә гыйльми хакыйкатькә туры килми. Коръәни Кәримдә, асылда, аятьләр саны 6236–6238 дип исәпләнелә. Кара: Зыяэтдин әл-Камали. Фәлсәфәи исламиядән икенче җөзә. Уфа – 1911.– 31 б. *Равил Үтәбай-Кәрими искәрмәләре*.

## *I*

## Хәзрәте Рәсүлнең сыйфат вә холыклары

Хәзрәте Рәсүл урта буйлы, тулы гәүдәле, бик сәламәт тәнле, киң күкрәкле, сирәгрәк сакаллы иде. Йөзе түгәрәк булып, бик матур вә нурлы, зур кара күзле, нечкә озын кашлы, уртасы калкурак борынлы, тешләре саф вә энҗе кеби ак вә сирәк иде. Чәч вә сакалы чем кара булып, чәче бөдрәләнеп тора иде. Йөргән вакытта эре атлап йөри, һичбер вакытта анда-монда каранмый иде. Хәзрәте Рәсүл гаять мәһабәт булдыкыннан, тәү күргән кеше куркып китә, ягъни хәзрәте Рәсүлнең мәһабәте баса иде. Хәзрәте Рәсүл белән утырдаш булган кеше, мәҗлесенә гашыйк булып, шатлана, кайгылы адәм булса, бөтен кайгысын оныта иде.

Хәзрәте Рәсүлнең тавышы күркәм, сөйләшүе мөлаем вә йомшак, сүзе гаять фәсыйх[1] вә ачык булып, сүзне кирәк вакытта гына сөйли торган иде. Уйнап сөйләшми, начар вә ярамас сүзләр әйтми, һичкемне гайбәт кылмый, сүз сөйләгәндә, сүзләрен санап торырга мөмкин иде. Сүз сөйләргә керешсә – бөтен мәҗлес тып-тын булып, бик ихлас белән тыңлыйлар иде.

Хәзрәте Рәсүл һәркемгә – хәтта дошманнарына да – ачык йөзле, татлы сүзле булып, һичкемгә чытык йөз белән тормый иде. Кешеләргә әүвәл үзе сәлам биреп, күрешкәндә башлап кулын суза, сөйләшә башласа, теге кеше сүзен бетергәнче тыңлап тора, ягъни аны ташлап китми иде. Кешегә барганда, рөхсәт сорап керә, «кем бар?» дип сораганда, «мин» дип кенә әйтми, «Мөхәммәд» дип җавап бирә иде.

Мәҗлестә кайда урын булса, шунда утыра, сүз сөйләгәндә бер генә кешегә карап сөйләми иде. Нинди гаҗәп нәрсә күрсә дә, кычкырып көлми, елмаеп кына көлә, берәр кеше начар сүз ычкындырса, илтифат кылмый

---

[1] Фәсыйх – матур һәм килешле итеп сөйләнгән фәсахәтле сүз; әдәби; әдәби тел кагыйдәләре нигезендә сөйли белүче.

яки иплəп кенə алай ярамаганлыкны аңлата иде. Хəзрəте Рəсүл һəркемгə түбəнчелекле булып, үзен һичкемнəн артык күрми иде. Фəкыйрь һəм мескеннəрне, ятим һəм хатыннарны ригая[1] кыла, аларны ярата, аларның хəллəрен сораша, аларга ярдəм итə иде. Үзенең эшлəрен эшлəтергə кеше тапса да – күп вакытта үзе эшли. «Мин пəйгамбəр» дип эрелəнеп тормый, базарга барса, нəрсəлəрне үзе күтəреп алып кайта, вак-төяк йорт эшлəрен дə үзе эшлəргə авырсынмый иде. Хəтта үзенең киеменең ертыкларын үзе тегə, киемнəрен тазарта, кул тегермəне белəн он тарта, хайваннарны эчерə вə ашата иде. Кунак килсə, ачык йөз белəн каршы алып, ахырда үзе озата торган иде.

## *III*

Хəзрəте Рəсүл гаять киң холыклы, сабырлы булып, һичкемгə ачуланмый, берəүдəн дə үч алырга телəми, үзенə усаллык кылган, зарар китергəн кешелəрне дə гафу итə иде. Рəсүлебез бик юмарт булып, кулында булганда һичкемне буш җибəрми, малын кызганмый биреп җибəрүчəн иде. Кулына ничаклы мал керсə дə, һəммəсен таратып бетерə иде. Ниһаять дəрəҗəдə юмарт булганлыктан, вафат булган вакытта бик аз гына малы калды. Хəтта бер киеме закладта иде.

Хəзрəте Рəсүлнең тормышы да уртача булып, һичбер тəкəллефне[2] яратмый иде. Туйганнан артык ашамый, ашаганнан соң Аллаһка шөкер кыла, соңыннан кулын юа иде. Гомерен һичбер вакытта буш үткəрми. Аллаһка гыйбадəт кыла, мөселманнарга мəслихəт һəм кирəк булган эшлəрне карый, эшлəгəн эшлəре белəн мактанмый иде. Кулында ничаклы малы булган вакытта да артык тотынмый, артык малын фəкыйрь һəм мескеннəргə өлəшеп бетерə иде. Хəзрəте Рəсүл пакьлек вə тазалыкны гаять ригая кыла, киемнəрен таза тота, тырнакларын кисə, чəчлəрен майлап йөри, янында һəрвакыт хуш ис аңкып тора иде. Хəзрəте

---

[1] Ригая – кайгырту, карау, игътибар итү, олылау, хөрмəтлəү.

[2] Тəкəллеф – ясалмалык, кылану, табигыйлектəн ашу.

Рәсүл гаять йөрәкле баһадир булып, куркуның ни икәнен белми, һичвакытта дошманнан куркып качмый иде.

Хәзрәте Рәсүлнең моннан башка гүзәл холыклары, матур сыйфатлары гаять күп булып, бөтен мөселманнарга рәһбәр[1] итеп алырга тиешле булган әүсафы[2] чиксездер. Хәзрәте Рәсүлнең искиткеч гүзәл сыйфатларын күреп – ислам динен кабул итүчеләр булды.

## *Хәзрәте Рәсүлнең балалары*

Хәзрәте Рәсүлнең барлыгы җиде баласы булып, исемнәре болардыр: Касыйм, Габдулла, Зәйнәп, Рокыя, Өммегөлсем, Фатыйма, Ибраһим. Бу балаларның һәммәсенең аналары хәзрәти Хәдичә булып, ялгыз Ибраһим гына Мария исемле кыптый җариянекедер[3].

Касыйм. Мәккә шәһәрендә дөньяга килеп, ике яшеннән соң вафат булды.

Габдулла. Бу һәм Мәккә шәһәрендә сабый вакытында вафат булды.

Зәйнәп. Хәзрәте Рәсүлнең иң зур баласы булып, Мәдинәгә килгәч, һиҗрәтнең сигезенче елында вафат булды. Һалт дигән кемсә (кеше) никахында иде.

Рокыя. Башта Әбү Ләһәбнең Готбә исемле угълында иде. Әбү Ләһәб, туй булмастан элек, көчләп аертты. Соңында хәзрәте Госман никахланды. Бәдер сугышы вакытында вафат булды.

Өммегөлсем. Хәзрәте Рәсүлнең өченче кызы булып, Рокыя вафат булгач, хәзрәте Госман үзләренә никах улынды. Һиҗрәтнең тугызынчы елында вафат булды.

Фатыйма. Хәзрәте Рәсүлнең иң кече кызы булып, уналтынчы яшендә хәзрәте Гали үзләренә никах улынды.

---

[1] Рәһбәр – үрнәк.

[2] Әүсаф – «васыф» сүзенең күплек саны; сыйфатлар, билгеләр, үзлекләр.

[3] Җария – яшь кол хатын, кәнизәк.

Ибраһим, һиҗрәтнең сигезенче елында дөньяга килеп, ике яшь тулмас борын вафат булды.

## *Хәлифәләр*

### *I*

### Беренче хәлифә Әбү Бәкер әс-Сиддыйк (разый Аллаһ ганһү)

Хәзрәте Рәсүл вафат булгач, әһле исламның эшләрен башкару, дин исламның хөкемнәрен йөртү өчен, хәзрәте Рәсүл урынына тизрәк бер хәлифә сайларга сәхабәләр карар бирделәр. Кемне сайларга тиешле икәне хакында киңәш кылыр өчен җыелдылар. Кемне сайлау – һәм дә мөһаҗирләрдәнме, әнсарларданмы булсын,– тугърысында бераз ихтиляф[1] чыкты. Һәр ике як хәлифәне үзләренең арасыннан сайламакчы булдылар. Бара торгач бу ихтиляф басылды. Хәзрәте Әбү Бәкерне хәлифә итеп сайладылар. Иштә[2] хәзрәте Рәсүл урнына хәлифә булып сайланган беренче кеше хәзрәте Әбү Бәкердер. Хәзрәте Әбү Бәкер, иң әүвәл иман китереп, мөселман булучы – гаять гакыллы, үткен, нечкә күңелле, бик мәрхәмәтле бер кеше иде. Бөтен байлыгын дин ислам юлында тотты. Хәзрәте Рәсүл һиҗрәт иткән вакытта бергә һиҗрәт кылып, Рәсүлуллага юлдаш булды. Хәзрәте Рәсүлнең хатыннарыннан хәзрәти Гайшә ошбу хәзрәте Әбү Бәкернең кызы иде. Хәзрәте Әбү Бәкер ике ел да өч ай да тугыз көн хәлифә булып торды, һиҗрәтнең унөченче елында, алтмыш өч яшендә, вафат булды.

### Хәзрәте Әбү Бәкер хәлифәлек кылган вакытта булган эшләр

Хәзрәте Рәсүлнең вафатыннан элек, Гарәбстанның бәгъзе җирләрендә ялган пәйгамбәрләр чыгып, халыкны аздыра башлаганнар иде. Хәзрәте Әбү Бәкер, хәлифә

---

[1] Ихтиляф – каршылык, үзара килешмәүчәнлек; дау, ызгыш.

[2] Иштә – менә.

булгач та, боларга каршы гаскәр җибәрде. Мөселман гаскәрләре бару белән Әсвәд әл-Гонсый дигәнен тотып үтерделәр. Мөсәйилимәт әл-Кәззаб исемле булганы бераз каршы сугышса да – соңыннан җиңелде. Үзе дә ошбу сугышта үтерелде. Хәзрәте Әбү Бәкер заманында исламнан баш тартучылар да була башлаган иде. Болар да итәгатькә китерелделәр. Хәзрәте Рәсүл вафат булмас борын, Коръәнне һәркем күңелдән бикли, яттан укый иде. Болай булганда Коръәннең бәгъзе аятьләре онытылу яки ялгыш булып китүе ихтимал иде. Хәзрәте Әбү Бәкер, сәхабәләрнең киңәше белән, Коръәннең аятьләрен бер җиргә җыйдырып яздыртты. Бу Коръән хәзрәте Хәфсаның өендә сакланды. Хәзрәте Әбү Бәкернең хәлифәлеге вакытында Гыйрак дигән җирләр мөселманнар кулына керде. Шам шәһәре фәтех кылынды[1].

## *II*

## Икенче хәлифә хәзрәте Гомәр (разый Аллаһ ганһү)

Хәзрәте Әбү Бәкер вафат булгач, аның урынына хәзрәте Гомәр хәлифә булды. Хәзрәте Гомәр разый Аллаһ гәнһү хәлифә булган вакытта ислам гаскәрләре Гыйрак гаҗәмнәре[2] белән, Сүрия дигән җирдә рум[3] халыклары белән сугышалар иде. Сүриядә румлыларның йөз мең гаскәренә каршы мөселманнарның бары утыз мең гаскәре булып, бу гаскәргә Халид бине Вәлид башлык итә иде. Румлылар белән мөселманнар арасында Ярмук дигән җирдә сугыш башланды. Бу сугышта мөселман гаскәре өч-дүрт рәт җиңелсә дә, соңында румлыларны җиңеп, башлыкларын кулга алдылар. Ошбу Ярмук сугышыннан соң Сүриянең күп шәһәрләре мөселманнар кулына керде. Кудс[4] шәһәре фәтех кылынды. Иран тарафына җибәрелгән мөселман гаскәренә Әбү Габидә бине Мәсгуд

[1] Фәтех кылынды – яулап алынды, ачылды.

[2] Гаҗәм – иранлылар, фарсылар; гарәптән башка халык.

[3] Рум – грек, византияле.

[4] Кудс – Иерусалим.

башлык итә иде. Иран гаскәре белән ике арадагы сугыш Кадисия дигән җирдә булганга күрә, бу сугышка Кадисия сугышы дип әйтәләр. Ислам гаскәре бик аз булсалар да, күп гайрәт күрсәтеп, Иран гаскәрләрен тәмам җиңделәр. Иранлыларның гаскәр башлыгы Рөстәм ошбу сугышта үтерелде. Иранның пайтәхете Мәдаин шәһәрен дә алдылар. Ошбу вакыттан соңра Күфә һәм Басра дигән шәһәрләр салынды. Моннан соңра мөселманнар-гарәбләр белән Иран гаскәре арасында Ниһаунд шәһәре янында зур сугыш булып, монда да гарәбләр җиңделәр. Шулай итеп, Иранның бик күп җире мөселманнар кулына керде.

Хәзрәте Гомәр разый Аллаһ гәнһү бик гайрәтле, гаделл, кеше күңеленә карамый, тугърылыкны итә торган бер кеше иде. Хәзрәте Гомәр разый Аллаһ гәнһү, гаять гадел һәм тугъры булганга күрә, Әл-Фарук[1] дип исемләнмештер. Хәзрәте Гомәр хәлифә булып торган вакытта бик күп җирләр мөселманнар кулына керде. Бу вакытта Ислам мәмләкәтенең чикләре Йәмәннән Кавказга, Тунистан Кытайга чаклы сузылды. Шуның өчен хәзрәте Гомәр разый Аллаһ гәнһү һиҗрәтнең 32 нче елында, 63 яшендә вакытта, Әбү Лүълүъ исемле бер кол тарафыннан шәһид ителде. Хәзрәте Гомәрнең хәлифәлек мөддәте ун ел ярым кадәредер.

## *III*

## Хәзрәте Госман (разый Аллаһ ганһү)

Хәзрәте Гомәр разый Аллаһ гәнһү шәһид булгач, сәхабәләр дүрт көн киңәш иткәннән соң, аның урынына хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһүне хәлифә итеп сайладылар. Бу вакытларда мөселман гаскәре Туниска чаклы барып җиткәннәр иде. Румлылар гаскәр җыеп, мөселманнарга каршы килә башлагач, мөселман гаскәре дә аларга каршы барып, ике арада бик зур сугыш булды. Бу сугышта да мөселманнар румлыларны җиңеп, башлыкларын үтер-

[1] Фарук – дөрес белән ялганны бик нечкәләп аера белүче.

деләр. Башлыклары үтерелгәч, румлылар төрле якка качып беттеләр. Һиҗрәтнең 28 нче елында Ак диңгездәге Кыбрыс[1] атавы мөселманнар тарафыннан алынды. Хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү хәлифә вакытта Иран бөтенләй мөселманнар кулына кереп, андагы патшалыклар тәмам бетте.

Хәзрәте Госман хәлифә булган вакытта Ислам мәмләкәте тәмам зураеп, бик күп шәһәрләр мөселманнар кулына керде. Әһле ислам гаять күбәйде. Шуның өчен төрле тарафка Коръәнне бер рәвешле яздырып таратырга тиешле иде. Чөнки һәр җирдә Коръән Шәриф бертөрле укылырга, төрле җирдә төрлечә булып китмәскә тиеш иде. Шуны уйлап, хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү Әбү Бәкер әс-Сиддыйк заманында язылган Коръән Шәрифтән күчертеп, берничә нөсхә яздырып, төрле тарафларга таратты.

Хәзрәте Әбү Бәкер разый Аллаһ гәнһү – Кәлями Шәрифне җыючы, хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү – яздырып таратучыдыр.

### Хәзрәте Госман (разый Аллаһ гәнһү)нең шәһид ителүе

Хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү бик шәфкатьле, йомшак табигатьле, кеше сүзен екмый торган бер зат иде. Бу эш төбендә бик зарарлы чыкты. Үзенең якын нәселләре сүзен тыңламый башладылар. Бу эшне күреп, эчләреннән разый булмаган сәхабәләр дә күренә башлады. Бервакытта хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү Мөхәммәд бине Әбү Бәкерне Мисырга вәли[2] итеп җибәрде. Аның артыннан икенче бер илче аркылы Мисыр халкына хат язып җибәрде. Бу хатны язучы Мәрвән исемле кеше иде. Бу хатны ике төрле уку мөмкин булганга күрә – бу хат бик зур низаглар чыгуына сәбәп булды. Бу хатны укыгач, Мөхәммәд бине Әбү Бәкер Мисырга бармый, Мәдинә шәһәренә кайтып

[1] Кыбрыс – Кипр.

[2] Вәли – вәкил; ия, хуҗа; яклаучы; изге, илче.

китте. Мөхәммәд бине Әбү Бәкергә башка кешеләр дә кушылып, теге хат язучы Мәрвәнне кулга алырга сорадылар. Хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү разый булмады. Хәзрәте Госман Мәрвәнне яклый дип, ике арадагы дошманлык тагы да артты. Хәтта хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһүнең үзен үтермәкче булып, йортын камап алдылар. Җитмеш көн кадәр камап торганнан соң, өенә кереп, хәзрәте Госманны шәһид кылдылар. Хәзрәте Госман шәһид булган вакытта 75 яшендә булып, һиҗрәтнең 35 нче елы иде. Хәзрәте Госман разый Аллаһ гәнһү унике ел хәлифә булып торды.

## *IV*

## Хәзрәте Гали (разый Аллаһ ганһү)

Хәзрәте Госман шәһид ителгәннән соң, сәхабәләр хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһүне хәлифә итеп куярга теләделәр. Башта хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһү хәлифәлекне кабул кылмаса да, сәхабәләр бик үтенгәч, соңында кабул итте. Хәзрәте Гали хәлифә булган вакытта мөселманнар арасында зур чуалулар башланып тора иде. Бик күп кешеләр хәзрәте Госманны үтергән кешеләргә тизрәк хөкем кылуны телиләр иде. Бара торгач, ошбу эш зурга китеп, мөселманнар икегә аерылдылар. Ошбу сәбәптән мөселманнар арасында зур сугышлар булды.

Бу сугышларның берсе Җәмәл вакыйгасы дип мәшһүрдер. Бу сугышны хәзрәте Гали ничаклы булдырмаска теләсә дә – файдасы булмады. Ахырда, үзе гаскәр җыеп, алар өстенә барды. Бу сугышта ике яктан ун меңләп кеше үлде. Хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһү гаскәре тегеләрне җиңеп, күбесен әсир алдылар. Хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһү боларга бик зур гадәләт[1] вә шәфкать күрсәтте.

Бу сугышларның икенчесе Сәффәин вакыйгасы дип мәшһүрдер. Хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһү Җәмәл сугышыннан соң Гыйракта калган иде. Ошбу вакытта Шамда

[1] Гадәләт – турылык, гаделлек.

вәли булып торган Могавия бине Әбү Суфиян күп гаскәрләр белән хәзрәте Галигә каршы чыкты. Ике гаскәр арасында, Сәффәин дигән җирдә, бик зур сугыш булып, җитмеш меңләп кеше кырылды. Соңында сугышны туктатып, хәзрәте Гали берлә Могавия арасында солых ясалмак булды. Моннан соң хәлифәлек Могавиягә калды. Аз гына бер эштән мондый зур низаглар чыгып китүе – мөселманнар өстенә килгән бәлаләрнең иң зурыдыр

**Хәзрәте Гали разый Аллаһ ганһүнең шәһид ителүе**

Сәффәин вакыйгасыннан соң Хауариж таифәсе[1] хәзрәте Галине, Могавияне, Гәмр бине әл-Гас дигән кешене беркөнне үтерергә карар бирделәр. Шамда торган Могавияне үтерергә барган кеше Могавиягә корал белән ташланса да – үтерә алмады. Мисырда торган Гәмр бине әл-Гасны үтерергә барган кеше ялгыш икенче бер кешене үтерде. Ибне Мәлхәм дигән кеше хәзрәте Галине мәсҗидкә барган вакытында шәһид итте. Бу эш һиҗрәтнең кырыгынчы елында булып, хәзрәте Гали хәлифә булуының дүртенче елында иде. Хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһү вафат булганда алтмыш өч яшендә иде. Хәзрәте Гали разый Аллаһ гәнһү бик гади, галим, юмарт, баһадир кеше иде. Хәзрәти Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһи вәсәлләмгә сабыйлардан иң әүвәл иман китерүче ошбу хәзрәте Гали иде. Хәзрәте Галидән соң Куфә халкы хәзрәте Галинең углы хәзрәте Хәсәнне хәлифә итсәләр дә,– хәзрәте Хәсән алты айдан соң, үз теләве белән, хәлифәлекне Могавия бине Суфиянга тапшырды. Моннан соң Хүләфәи Рәшидин дәвере бетеп, хәлифәлек Өммәвиләргә калмыштыр.

*1912*

*Гафури М. Хәзрәте Рәсүлуллаһ галәйһи вәссәлләм вә дүрт хәлифә.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.– 47 б.*

---

[1] Таифә – бер диндә булган бер төркем халык, кабилә; төркем, җәмәгать.

## Бу кемнең кабере?

### *(Тарихи бер мәкъбәрә[1] янында)*

Авылдан ерак кара урманның янында калкып торган бу туфрак җыентыгы кемнедер эченә алган... Вакыты илә кемнәр тарафыннандыр бу ялгыз кабергә күмелгән кешегә бер ядкяр вә галәмәт уларак куелган зур вә мәһабәт таш гасырлар үтүе белән җиргә батып кергән. Бу урында бер бәндәнең мәдфүн[2] икәнен белдереп, килгән кешеләргә хәл тел илә дәлиллек итеп торган ушбу зур таштан башка, кабер өстендә һичбер галәмәт юк. Ихтимал, башка галәмәтләр заманнар үтүе белән берәм-берәм югалганнардыр.

Ихтимал, менә бу зур ташка кабер иясенең вафат тарихы, исеме язылгандыр да. Ләкин ул язулар, еллар үтүе белән, үзенә каршы искән җилләргә, сибәләп яуган ниһаятьсез ягъмур тамчыларына каршы тора алмый кителеп төшкәннәрдер...

Бу кемнең кабере? Бу кабернең кем кабере икәнлеге мазыйның[3] караңгы тарихлары астына кереп югалган. Язмыш белән бунда күмелгән ялгыз бу бәндәнең кем икәнен белер хәл юк. Шулай да мәгънәви бер көч бу өем туфрак янында булган кешенең бөтен вөҗүденә тәэсир итә, бунда бер газамәт[4] бар кебек тоела, бу кабергә күмелгән бәндәгә хөрмәт итәсе килә. Үткән вакытларга, тарихка әйләнеп карарга, бу кабер сахибенең[5] бер заманда якты дөньяда йөргән заманнарын уйларга мәҗбүрият хис ителә...

---

[1] Мәкъбәрә – кабер, каберлек.

[2] Мәдфүн – күмелгән.

[3] Мазый – үткән заман.

[4] Газамәт – олылык, бөеклек.

[5] Сахиб – ия.

Газамәт катыш мәхзүният[1] чолгаган бу кабер кемнеке? И таш! Син бунда күмелгән бәндәнең тарихыны, аның кем икәнене, әлбәттә, беләсең! Сине бунда шаһидлек вазифасыны үтәп торыр өчен нинди куллар китереп куйдылар? Сине монда китереп куюларына күпме гасырлар үтте?

И таш, сөйлә! Бу кабернең иясе кем иде? Аның башыннан нинди вакыйгалар үтте?

И таш! Син бу кешегә әллә ничә гасыр иткән иптәшлек хөрмәте өчен, буның рухи хакы өчен сөйлә! Һичбер сөйләмәскә, бу кешенең әсрарене кәшеф итмәскә[2] синнән гаһед[3] алдылармы? Шул иткән гаһедеңне, кыйлган яминеңне[4] бозмаска карар бирдеңме?.. Алай булса, гаһедеңне бозма, өстеңә йөкләтелгән әсрареңне кыяматкә кадәре сакла...

И шаулап торган агачлар! Бу кабернең кем кабере икәнен сездән сораугa да ихтыяҗ юк. Чөнки сезнең бу дөньяга килү, бу җирдә үсә башлау тарихыңыз бу адәмнең бу җиргә күмелүеннән, әлбәттә, бик күп соң. Сезнең бу кабер хакында бер төрле дә шәһадәт бирә алмавыңыз бик табигый.

Онытылган, ташланган бу кабер кемнең?

Ихтимал, бу кабер татар ханнарыннан берәр хан кызының кабередер. Бер вакытта алтын-көмешләр белән зиннәтләнеп ясалган тирмә эчендә атласлардан гыйбарәт юрганнар өстендә, ефәкләргә чолганып, асыл ташларга күмелеп, иркәләнеп, үзенең сакчы кызлары арасында ай кебек балкып торган бер кыз булгандыр. Буның энҗе тешләре арасыннан чыккан һәрбер сүз Тәңренең әмере кебек, һичбер тәхәллефсез иҗра кыйлынып[5], җиренә җиткерелеп торгандыр.

---

[1] Мәхзүният – моңлылык.

[2] Әсрарене кәшеф итмәскә – серләрен ачмаска.

[3] Гаһед – вәгъдә.

[4] Ямин – ант.

[5] Тәхәллефсез иҗра кыйлынып – каршылыксыз үтәлеп.

Бунын һәркемне мөсәххәр итә[1] торган күзләренең гадиләнә[2] бер карашы үзенең теләгене артыгы белән җиренә җиткерергә кяфи[3] булгандыр. Бу кызның ай йөзене күргән кешеләр икенче бер мәртәбә күрү өчен җаннарын фида итү дәрәҗәсенә килүләре бик мәгълүм.

Ихтимал, вакыты илә бу кызның агызыннан бер сүз ишетергә, бунын бер әмерене йиренә җиткерергә муаффәкъ булган бәндәләр үзләрене мәсгуд, бәхетле кешеләрдән хисаплаганнардыр.

Яңа аткан бу чәчәкнең сабагыннан өзелеп төшүе, явыз тәкъдирнең язмышы белән бу айның менә бу йиргә күмелүе бөтен тирә-як өчен хәсрәт булып, бунын тәэсиреннән әллә кемнәр, әллә кемнәр күз яшьләрене түккәннәрдер.

Бу кызның гашыйкы, актык сулышларын бу кабер өстендә алып, үзенең иң ачы хәсрәтле күз яшьләрен ушбу туфрак өстенә агызгандыр.

Бу кыз өчен хәсрәт чиккән, бу җиргә күз яшьләрене түккән бәндәләр үзләре дә инде әллә кайчан югалып онытылганнар... Алар бу дөньядан китү белән бу кызның кабере дә мәнса вә мәтрүк булган...[4] Менә бу таш, менә әллә кемнәрнең куллары белән өелгән бу туфраклар — шул борынгы кешеләрнең хәсрәт белән хәрәкәт итүләренең бәкъиәсе...[5]

И таш, сөйлә, бу кемнең кабере? Бу әле һаман миңа караңгы, син шул караңгылыкны ач, таки үткән заман тарихының бер генә юлыннан булса да хәбәрдар булыйм[6].

Читтә, тыныч бер җирнең уртасында булган ялгыз кабер!.. Бунын ялгыз булуыннан, бу кабернең татарларның борынгы бабаларыннан беренең, бер каһарманының кабере булуы бигрәк якын ихтимал...

---

[1] Мөсәххәр итә – сихерле.

[2] Гадиләнә – тугърылыклы.

[3] Кяфи – җитәрлек.

[4] Мәнса вә мәтрүк булган – онытылган һәм ташланган.

[5] Бәкъиәсе – калдыгы.

[6] Таки... булыйм – ... булыр өчен.

И кабердәге зат!.. Үзең торып, кем икәнлегеңне, башыңнан үткән вакыйгаларны тәфсил кыйлып, тарихи караңгылыкларны кәшеф ит...

Син Җучи гаскәрләреннән булган бер затмы? Татарларның бу дөньяны тетрәткән вакытларында кайда идең?.. Гарби Азияне, Шәркый Аурупаны истиля итеп, аның вә башкаларның йөрәген алган татар гаскәрләре бу муаффәкыятьләренә ничек ирештеләр?.. Шул дәвердә булган төрле вакыйгалар хакында, безнең башымызга килгән төрле шөбһәләр тугърысында изахәт[1] биреп, чуалчык тарихларның ачык вә якты булуына сәбәпче бул. Тарихның мөгаммәләрен[2] хәл кыйлып, бабаларымызның әхвале, хәрәкәтләре хакында безгә мөфассал[3] мәгълүмат бир.

Ихтимал, син гади бер гаскәри булмый, вакытында меңнәрчә гаскәргә башчылык итеп, дөньяның иң зур каидләреннән[4] саналгансыңдыр.

Синең йөрәгеңдә булган ватан һәм милләт хисе сине арслан кебек хәрәкәт иттереп, дошманнарыңа каршы күтәргән кылычыңны теләгәнчә хәрәкәт иттергәнсеңдер, синең гайрәтең каршысында дошманнарың гаҗиз калып, синең һәрбер әмереңә буйсынырга, синең һәрбер теләгеңне җиренә җиткерергә мәҗбүр булганнардыр. Үзеңнән соң киләчәк балаларыңның бәхете <...> өчен сахраларны, тау-ташларны, чиксез кара урманнарны үтеп, көне-төне ат өстендә йөреп, дошманнарыңның көчләрен бетереп, үзеңнең мәкъсудыңа ирешкәнсеңдер.

Синең гаяи[5] хыялың соңыннан киләчәк балаларың өчен җимерелмәслек бер дәүләт төзү, аларны кыяматкә кадәр мәхкүмияттән[6] коткарып, дөньяның һәр җәһәтендә рәхәтлектә яшәтү булгандыр. Синең гомереңнең

---

[1] Изахәт – аңлатмалар.

[2] Мөгаммә – табышмак.

[3] Мөфассал – тулы, җентекле.

[4] Каид – (гаскәри) җитәкче.

[5] Гаяи – төп, соңгы.

[6] Мәхкүмият – хөкем астында тору.

һәрбер минутлары ушбу теләгеңне җиренә җиткерергә сарыф кыйлынып, һәрбер сәгатьләреңдә ушбу мәкъсудыңа җитәргә яңа бер адым атлагансыңдыр.

Ниһаять, явыз үлем тырнагы сине ушбу җирдә очраткан, син һәммә нәрсәгә каршы тора алсаң да, менә ушбу үлемгә каршы тора алмый тәкъдиргә буйсынгансың. Сине үзеңнең меңнәрчә булган сөекле гаскәрең, күз яшьләрен түгеп, ошбу йиргә күмгәннәр. Менә бу ташны баш очыңа утыртып, үзләре тәкърар дошманга каршы киткәннәр. Синең ниһаятьсез гайрәтеңне, үлемгә каршы торып туктаткан арыслан кебек, бу дөньяны тар күреп йөргән вөҗүдеңне менә бу туфрак җыентыгы гына эченә сыйдыра алган. Син үзеңнең теләгән мәкъсудларыңны тәмам итүне балаларыңа калдырып, рухыңны тәслим иткәнсең. Балаларың, синең соңыңнан килгән башкалар синең тәмам итәргә теләгән теләкләреңне тәмам иттеләрме? Һәйһат![1] Аларның рухлары синең вафатыңнан соң күпкә сузылмады, сүнде... Алар синең гали мәкъсудларыңны тәмам оныттылар.

Синең ватанга кыйлган хезмәтләреңә мөкяфәт[2] уларак балаларың берни дә эшли алмадылар. Менә үзең сугышып алган җирләреңнән алынган бу кисәк таш белән менә бу туфрак җыентыгы – бу ике нәрсә синең җир өстендә торып киткәнлегеңне белдереп торырга гаһед иткәннәр. Бу ике нәрсә үзләренең гаһедләрендә сабитлар[3]. Синең зиратың әхфадың[4] кашында мәҗһүл[5], бездә сиңа мәңгелек ядкяр кыйлып бер һәйкәл куярлык көч вә икътидар[6] юк.

Бу минутта синең бу ташландык, мәҗһүл кабереңдә утырган мине бу җиргә тәсадеф[7] китергән. Менә бу ачы

---

[1] Һәйһат – «нинди үкенечле!» мәгънәсендә.

[2] Мөкяфәт – бүләк.

[3] Сабит – нык торучы.

[4] Әхфад – оныклар.

[5] Мәҗһүл – билгесез.

[6] Икътидар – куәт.

[7] Тәсадеф – очраклылык.

күз яше синең хезмәтеңә каршы җөзьи[1] генә булса да бер мөкяфәт. Бу сине бер мәртәбә булса да искә төшерү.

Менә бу калтыраган кулларым белән өзеп алынган чәчкә – үзеңнән әллә ничә гасыр соң килгән бер гаҗиз баланың сиңа ихтирам йөзеннән кабереңә куйган чәчкәсе.

И мәтрүк[2] кабер иясе! Гаҗиз булган бүз ирне гафу ит. Рухың шат булсын.

*Беренче тапкыр «Аң» журналының 1913 ел, 20 октябрь санында чыккан.*

[1] Җөзьи – кечкенә.

[2] Мәтрүк – ташландык.

## Тәэссорат[1]. Җәй көненең төнге ай яктысында

Без Агыйделнең буенда, агачлыклар арасында кичке ай яктысында, җәйге көннең йотып туя алмаслык саф һавасында тамаша кыйлып йөреп, табигатьнең матурлыгыннан мәфтүн булып[2], ниндидер бер матурлык астында арбалган-сихерләнгән кеби булып утыра идек. Читтәрәк торган биек тау айның тонык яктысы белән аз-маз гына күренә, тирә-ягындагы агачлар аз гына акка маил булып[3] торалар иде.

Буны шатлык катыш моңлылык, әллә нинди бер шигърият тәмам изрәткән, мәгънәви бер куәтнең тәэсире безне тик торырга мәҗбүр иткән иде.

Чынлап та, бу вакытта бөтен җир өстене бик тирән сөкүнәт[4] каплаган... Һәммә нәрсә бик көчле тәэсир астында... Бөтен мәхлукат[5] мәгънәви бер куәтнең тәэсиреннән гайре ихтыяри сөкүтне илтизам кыйлганнар[6]. Боларның һәрберсе фәүкыльгадә[7] бер эш көткән сымак бер куәткә тәвазыйглык итәләр[8]... Барча әшья[9] кайдандыр... бер илһам, сирри[10] бер тәблигъның[11] булуын көтә, яки тиздән

---

[1] Тәэссорат – сиземләүләр.

[2] Мәфтүн булып – сокланып.

[3] Маил булып – өретелеп.

[4] Сөкүнәт – тынлык.

[5] Мәхлукат – җан ияләре.

[6] Гайре ихтыяри сөкүтне илтизам кыйлганнар – ирексез тик торуны өсләренә алганнар.

[7] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[8] Тәвазыйглык итә – баш ия.

[9] Әшья – әйберләр, нәрсәләр.

[10] Сирри – яшерен.

[11] Тәблигъ – хәбәр итү.

булачак бер нәрсәнең ләззәтеннән мәхрүм калмас өчен, бөтен калебләре, вөҗүдләре белән бер куәтнең алдында чүккәннәр.

Боларның һәммәсе дә бер хатыйбның әсәрле хотбәсене[1], бөтен инсаннарны[2] азатлыкка чыгара торган сүзләрене тыңларга хәзерләнгән кешеләр кеби мөсәххәр булып[3], селкенми-нитми нәрсәдер... көтәләр...

Бу вакытта йолдызлар гадәтләренчә күп җылтылдамый, җилбердәми, шөбһәсез бер нәрсәгә мәфтүн булып шаккатып урыннарында торалар.

Тулган ай да, бер газамәт[4] алдында сәҗдә иткән кеби җиргә карап, урынында кузгалмый тора, нурлары үзенең ихтыярыннан башка гына җиргә сирпелә... Агачларның яфраклары, бу сөкүнәтне бозмас өчен, бер-берсенә бәрелешүдән, ботаклары бер-берсенә сәлам бирешүдән туктап, һәммәсе тик торырга мәҗбүр булганнар.

Мәңгедән бирле акрын, фәкать мәһабәт, мөнтәзам[5] ага торган Агыйделнең суы, тавыш чыгарудан куркып, үзенең агуын тәртипле рәвештә акрынайтып, нәрсәгәдер... итәгать иткән[6].

Бу сөкүнәтне бозарга, бу газамәт алдында сәҗдәдән баш күтәрергә, боларның тик торуларыннан килгән матурлыкка хәләл[7] китерердәй эшне эшләргә – башлап селкенергә һичбер мәхлук вә башка җансыз нәрсәләр җәсарәт кыйла[8] алмыйлар.

Бу минутта дөньяны бер мәгънәви газамәт чолгаган... Бөтен җир өсте: кырлар, урманнар, таулар, су буйлары,

---

[1] Хатыйбның әсәрле хотбәсене – сөйләүченең (ораторның) тәэсирле сүзен (нотыгын, чыгышын).

[2] Инсан – кеше.

[3] Мөсәххәр булып – сихерләнеп.

[4] Газамәт – олылык.

[5] Мөнтәзам – тәртипле.

[6] Итәгать иткән – буйсынган.

[7] Хәләл – зарар.

[8] Җәсарәт кыйла – батырчылык итә.

болардагы мәхлуклар чын ихлас белән тик торырга мәхкүмнәр[1].

Боларның һәммәсе үзләренең өстләрендә бу куәтнең галиб[2] булуын сизәләр... Һәммә нәрсә күңелләрен илһам кылә торган тарафка юнәлдергәннәр. Бу ләззәтле минутларның, бу илһам вакытының озакка сузылуыны телиләр.

Сөкүнәт тагы да катырак хөкем сөрде... Тынлык ниһаясенә[3] иреште. Илһам көтәргә тагы ныграк хәзерләнделәр.

Шул вакытта Идел буенда бөгелеп-сыгылып үскән агачларның арасында, кайдадыр... кеше күзе күрә алмый торган мөнбәр өстендә бер сандугач шыңгырдатып, яңгыратып, бер күтәреп, бер төшереп, сыздырып, сызгырып, чутылдатып, кәмал мәртәбә голүвият белән[4] сайрап җибәрде. Сандугачның күңелендә сакланып торган мәхәббәт, гыйшык, сер моңлы тавыш белән тирә-якка тарала башлады.

Бунын сайравы бөтен мәхлүкат тарафыннан вәкәләт белән табигатьнең илһамына каршы бер нотык яки мәгънәви куәтнең илһамыны боларга тәблигъ иде.

Сандугач үзенең сайравын барган саен арттыра бара, тавыш аның саен матурлана, җир өстендә сөкүнәт арта бара иде.

Сандугачның сайравы бераз вакытка сузылды. Ниһаять, үзенә илһам кыйлынган әсрарны[5], мәхәббәт вә гыйшыкны кәмал муаффәкыять белән[6] тәблигъ итеп беткән рәвешле, үзенең сайравыннан туктады. Бу минутта җир өсте һичбер җинаять вә усаллык эшләнмәгән арзы мөкаддәс[7] сурәтене алды. Сөкүнәт тагы бер-ике минутка сузылды.

---

[1] Мәхкүм – хөкем ителгән.

[2] Галиб – өстен.

[3] Ниһаясенә – чигенә.

[4] Кәмал мәртәбә голүвият белән – иң югары дәрәҗәдәге рухи күтәренкелек белән.

[5] Әсрар – серләр.

[6] Кәмал муаффәкыять белән – тулы уңыш белән, тулысынча.

[7] Арзы мөкаддәс – изге җир (Палестина).

Соңра сандугачның сайраганын тыңлаган мәхлук вә башка нәрсәләр, үзләренең шатлыкларын белдерү өчен, ихтият[1] белән генә хәрәкәткә килделәр. Агачларның яфраклары әкрен генә хәрәкәткә килеп, кул чапкан рәвешен китерделәр. Ай җылмаеп, көлеп, яктылыгын арттырып, урыныннан кузгалган сымак булды, йолдызлар, ялтырауларын арттырып, тамарга торган тамчылар кеби селкенеп, җир өстенә сәлам юллаган, башларын игән кеби булдылар. Агыйделнең суы мөнтәзам сурәттә матур гына тавышланып ага башлады.

Ләкин бу хәрәкәтләр, бу кузгалышлар күпкә тартылмады. Тирә-якны баягыдан да тирән сөкүнәт каплады. Газамәт, әллә нинди мәгънәви бер куәт тагы да арта төште.

Әшьяләрнең бер-берсе арасында галәка[2] сизелде. Болар бер-берсенә мәгънәви, фәкать ныклы бер көч белән бәйләнгән кеби булдылар, һәр нәрсә бер-берсен кочакларга, бер-берсенең муенына сарылырга омтыла башлады. Айның нуры тагы артты. Андагы Зөһрә кыз ап-ачык, хиҗабсыз[3] күренә башлады. Күктәге йолдызларның саннары күбәйде. Агач яфраклары бер-берсенә сәлам бирештеләр. Айдагы Зөһрә кыз җиргә карап башын иде. Һәммә нәрсә бер низам[4] белән хәрәкәт башлады. Һәммә әшья шатланган сымак булып җылмайдылар. Сандугач баягыдан да әсәрле, серле, моңлы тавыш белән сайрап җибәрде...

Бу минутта һәрбер нәрсә тәэссернең[5] иң ниһаятенә җиткән иде. Чөнки бу минутта җир өстендә чын мәхәббәт белән чын гыйшык хөкем сөрә иде... Аһ, чын мәхәббәт белән чын гыйшык...

*«Аң» журналының 1913 ел 17 (20 август) санында чыккан.*

---

[1] Ихтият – саклык.

[2] Галәка – бәйләнеш.

[3] Хиҗабсыз – пәрдәсез.

[4] Низам – тәртип.

[5] Тәэссер – сиземләү.

## Беренче табгы

«Мөхтәрәм әфәнде!

«Карлыгачлар» намендәге[1] әсәрләреңезнең беренче табгысыннан[2] һичбер нөсхә калмый сатылып беткәнгә күрә, мәзкүр[3] әсәрнең яңадан табгы кыйлынырга лязим[4] икәнене хәбәр бирү илә кәсбе шәрәф әйләр[5] вә моның хакында сөйләшер өчен күрешергә көтепханәмезгә килү зәхмәтене ихтыяр итүеңезне риҗа итәргә җөрьәт итәрем[6], әфәндем.

Нашир Массул».

Үткән көн мәшаһире мөхәрриреннән[7] Һанри, югарыдагы мәктүбне безгә күрсәтеп, ушбу рәвешчә сүз башлады:

– Бу мәктүбне алган вакытымда шатлык вә аптыравымнан үлү дәрәҗәсенә килгән идем. Ләкин һәр хәлдә аптыравым шатлыгыма талиб иде.

«Карлыгачлар» исемендәге беренче әсәрем булган мәҗмугаи әшгаремнең[8] беренче мәртәбә табгы кыйлынган нөсхәләре сатылып беткән, имеш!.. Аһ, никадәр сәгадәт!

Мин бу вакытта фәкать егерме ике яшемдә идем. Парижда танышларым аз иде. Гәзитәләрдән һичберсе мәзкүр беренче әсәрем хакында сүз кузгатып, тәнкыйть яки тәкъриз кыйлып[9] бер сүз булсын язмаганнар иде. Бәгъзе

[1] Нам – исем.

[2] Табгы – басма.

[3] Мәзкүр – әйтелеп үтелгән.

[4] Лязим – тиеш, зарур.

[5] Кәсбе шәрәф әйләр – үзе өчен бәхет санар.

[6] Зәхмәтене ихтыяр итүеңезне риҗа итәргә җөрьәт итәрем – эшен үз өстегезгә алырга риза булуыгызны үтенергә батырчылык итәм.

[7] Мәшаһире мөхәрриреннән – мәшһүр язучыларыннан.

[8] Мәҗмугаи әшгарем – шигырьләр җыентыгым.

[9] Тәкъриз кыйлып – мактап.

гәзитәләрнең дүртенче битендә «Карлыгачлар» хакында басылган игъланнан башка һичбер сүз кузгатылмады. Шулай була торып та, бу дәрәҗәдә өмид ителмәгән, гакылга сыймаслык булган нәтиҗә күпме вакытта булды, беләсезме? Ялгыз бер ай эчендә... Димәк ки, бу бер муаффәкыять[1] һәм дә, бик хәкыйкый, гаҗәп булган бер муаффәкыять түгелме?.. Димәк, миндә бер талант, фәүкыльгадә бер истигъдад[2] бар икән!.. Шуның аркасында бөтен укучыларның илтифатларын үземә караткканмын...

Инде бу беренче әсәремнең муаффәкыять табуыннан соң язудан тукталачак түгел идем. Тагы башка әсәрләрне мәйданга китерәчәк идем. Инде бөтен уем, фикерем язу-сызу тирәсендә әйләнә иде. Бара торгач, театру китаплары, пьесалар язмакчы идем. Ул бабта[3] бик тизлек белән исем вә шөһрәт табачак идем. Шуның өчен төрле мәүзугъта[4] хикәяләр тасвир итеп, һичбер буш тормый, тырыша идем.

Китапчының мәктүбене тәкърар укыдым, бүлмәдә бер аркылы, бер буйга йөреп, бер минут та туктап тора алмый идем.

— Балам! Ни, ни бар? Сиңа [ни] булды? — дип, ишектән сөйкемле чәһрәсе[5], көләч йөзе белән карт әти килеп керде. Башыны яңа гына тараган, киемнәрен матурлап кигән, миңа җылмаеп кына карый иде.

— Менә нәрсә бар! Карт әти, ал, шул мәктүбне бер мәртәбә укы,— дип, наширдән килгән мәктүбне бирдем. Мәктүбне укып:

— Шулай булуы табигый түгелме иде?.. Минем фикеремчә, шигырьләрең гаять мөәссир[6] вә гүзәл иде...

---

[1] Муаффәкыять – уңыш.

[2] Фәүкыльгадә бер истигъдад – гадәттән тыш бер сәләтлелек.

[3] Бабта – мәсьәләдә, өлкәдә.

[4] Мәүзугъта – темада.

[5] Чәһрә – кыяфәт, төс.

[6] Мөәссир – тәэсирле.

— Ләкин, карт әти, уйлап кара, бу — өмид ителгәннән артык бер муаффәкыять. Бу көндә Париж халкы шигырь белән артык мәшгуль түгел, чын мәнзумнарны[1] артык укымыйлар.

— Син язганны укыганнар бит, бу сиңа җитмиме? Әлбәт, алай булгач, син бәхетлесең, шулаймы?

— Бу да сүзме, карт әти?

— Затән,[2] лязим булганы да бу иде.

Карт әтием, әнфия[3] савытыны акрын-акрын ачып, бераз әнфия алды. Күзләрендә миңа каршы шатлык әсәре ялтыраганы хәлдә, әнфиясене тартты.

Бер чирек сәгать соңра китап нашире Массулның дөкянендә[4] идем. Бөтен Париждагы мәшһүр каләм әһелләре булган мөхәррирләр бу китапчыны беләләр. Магазинның дүрт ягына тезелгән, кәмаль[5] әһәмият белән тәртипкә куелган, аклы, сарылы, кызыллы, мави[6] тышлы китаплар вә магазинга матурлык биреп торалар. Магазин эче матурлар, алучылар вә башка йомыш кешеләре белән тулы. Һәр вакытта килеп-китүчеләр белән магазин тулы була.

Бик ашыгып югары катка чыктым. Массулның мәхсус эш күрә торган бүлмәсе ушбу катта иде. Мин кергәндә, бүлмә ябулы тора, эчендә сөйләшкән тавышлар ишетелә иде. Димәк, Массул әфәнде берәресе белән утырыша икән. Үземнең нәүбәтемне көтәр өчен, бер утыргычка утырдым. Бу вакытта бу урынга беренче мәртәбә килгән көндә үземдә хис иткән каушау, калтыравымны хәтергә китердем. Язган шигырьләрем култыгымда көенчә, баскычны ни рәвешле йөрәк тетрәве белән менгәнемне белермен. Ул вакытта Массулның бүлмәсенә кергәндә, нинди калтырый идем. Массул мине нәзакәт белән, фәкать

---

[1] Мәнзум – шигырь.

[2] Затән – асылда.

[3] Әнфия – борын тәмәкесе.

[4] Дөкян – кибет.

[5] Кәмаль – тулы.

[6] Мави – зәңгәр.

бераз суыграк кабул иткән иде. Ничек тә әсәремне бәгъзе шартлар белән табгы кыйлмак булып алган иде. Шул вакыттан бирле ничаклы тәшвишләргә төштем. Кәгазьләргә яңа басылган мөсәүвәдәләрне төзәтергә китергән вакытларында бик сөенә идем. Меңнәрчә хаталар белән тулган бу мөсәүвәдәләрне[1] гаять дикъкать белән укып, ялгышларын тасхих итә[2] идем. Соңра бәгъзе сарыф[3] кагыйдәләре хакында шөбһәгә төшеп, тәрәддедтә[4] кала идем. Бигрәк тә нокта вә ишарәтләр[5] куюю мине гаҗиз калдыра иде. Иң соңра фиһрист[6] белән хата-сәваб җәдвәлене[7] ясадым. Ниһаять, беренче әсәрем көтепханәләрнең тәрәзә төпләрендә, бульварларда, пассажларда күренде.

Ниһаять, Массулның бүлмә ишеге ачылды. Бүлмәдән академия әгъзасыннан берәү чыкты. Нашир җиргә кадәр иелеп, аны озатып калды. Бу кеше китапчы өчен бик файдалы кеше, күрәсең... Гаҗәба![8] Мин дә шул дәрәҗәгә ирешә алырмынмы?

Массул, мине ачык йөз белән каршы алып, бүлмәсенә керергә ишарәт итте. Үзенә мәхсус урынына утырып, миңа да бер урын күрсәтте. Утырдым.

– Мәктүбемне алдыңыз түгелме?

– Алдым, мосье Массул.

– Бер ай эчендә бер мәҗмуганең сатылып бетүе бик гаҗәп, китабыңызның сатылып бетүе бик кызык... Сатыла, ләкин аннан һичкем бәхәс итми. Бик кызык! Бик!.. Инде сатылуына хәләл[9] килмәсен өчен, яңадан биш йөз нөсхә табгы итәргә карар бирдек.

Риза булып чыгып киттем.

[1] Мөсәүвәдә – корректура.

[2] Тасхих итә – төзәтә, дөресли.

[3] Сарыф – грамматика, морфология.

[4] Тәрәддедтә – икеләнеп.

[5] Ишарәт – тыныш билгесе.

[6] Фиһрист – эчтәлек.

[7] Хата-сәваб җәдвәле – төзәтмәләр таблицасы.

[8] Гаҗәба! – ни гаҗәп!

[9] Хәләл – зарар, кимчелек.

Чын да, бераз көннән соң көтепханәләрнең тәрәзә төпләрендә, әсәремнең тышында эре хәрефләр белән «икенче табгы» дип язылган сүзләрнең ялтырап торганын күрдем.

Инде шөбһә юк, мин исем һәм шөһрәт тапкан идем. Шулай булса да Массулның: «Китабыңызның сатылуы бик кызык, сатыла, ләкин һичкем аннан бәхәс кыйлмый», – дигән сүзләре хакында бераз уйда йөри идем. Чынлап та, һичкем минем әсәремнән бәхәс кыйлмый, китабымнан берәр нөсхәсен һәдия[1] итеп биргән кешеләрдән башка һичкем аны укыган кебек күренми. Хәтта алар да минем әсәремнән артык бәхәс итмиләр, китабымның муаффәкыятьле чыгуы хакында һичбер сүз сөйләмиләр, фәкать үз-үземә болай уйларга тиеш түгел икәнен, юк кына урында, тиешсезгә үземне бетерүемне уйлый идем.

Вакыйган, мин бушка кайгырам. Мадам ки[2] «Карлыгачлар» сатыла, шулай булгач, аны сатып алучылар булырга кирәк, мин моннан артык нәрсә өмид итәм?

Һәм дә минем китабымны мотлакан хатыннар ала торган булырга кирәк. Чөнки минем мәҗмугамдәге шигырьләрнең күбрәге хиссияте кальбиягә гаид[3] иде. Бу фикергә төшкәч, шатландым. Матур тышлы китапларымның бай хатыннары кулыннан бер минут та төшмәвен, аларның кичкырын ятакларына ятканда минем шигырьләремне моталәга кыйлуларын[4] уйлый идем.

Бу беренче муаффәкыятьтән җәсарәт алып[5], бик дәрт белән иҗтиһад кыйлырга керештем. «Бөек валидә»[6] исемендәге бер театру китабы яздым. Беләсезме? Бу уен «Удәур» театрында уйналды. Соңра «Җимнас» театрында баш-

---

[1] Һәдия – бүләк.

[2] Мадам ки – чынлыкта, чөнки.

[3] Хиссияте кальбиягә гаид – күңел хисләрен эченә алган, чагылдырган.

[4] Моталәга кыйлу – уку.

[5] Җәсарәт алып – кыюланып.

[6] Валидә – ана.

ка бер әсәрем куелды. Тагы соңрак «Комеди франсуз»да муаффәкъ булдым[1]. Әлхасил, арадан еллар үтте. Инде беренче әсәрем «Карлыгачлар»ны һичбер уйламый идем. Бу беренче әсәремне тәмам оныткан идем.

Ушбу арада карт әтием вафат булды. Бичара, кулларым арасында улдыгы хәлдә дөньяны куйды.

Вафатыннан бер ай соңра бүлмәсенә кергән вакытымда хис иттекем нәрсәләрне, газаплануымны һичбер онытмыймын. Бүлмәдәге һәрбер нәрсә ул мөхтәрәм картны искә төшерә иде.

Аның мәхсус бүлмәсенә кергән вакытта, үзе булмаса да, аякларымызның очы белән генә басып йөреп, акрын гына сөйләшә идек. Безгә ул мохтәрәм карт әти һаман шул бүлмәдә, үзенең пәрдәләре каплаулы булган караватында яисә үзенең утыргычында гәзитә укыган хәлдә, яки дикъкать белән исәп-хисабы белән мәшгуль булган кебек тоела иде.

Безгә яңарак кергән бер хезмәткәр, безнең кыйланмышларымыздан бернәрсә дә аңламый, дәрхаль[2] тәрәзәнең пәрдәләрен күтәрде. Шунда ук тыштан кергән яктылык бөтен бүлмәгә керде, искән җил урам тавышларын үзе белән бергә китереп эчкә һөҗүм итте.

Мәрхүмнең бүлмәсене иҗарәгә[3] бирмәкче идек. Шуның өчен шунда булган әйберләрне алып, җыештырып тазартырга кирәк иде. Бүлмәдәге нәрсәләрне күчерә башладык. Мин бу эштән бик әсәрләнгән идем. Миңа карт әтиемнән калган һәрбер нәрсә акрын-акрын бөтенләй бетәр кебек сизелә иде. Һәрбер нәрсәне кузгатканда күңелемдә иске бер хәтирә кузгалып, мәрхүмне искә төшерә иде. Ушбу вакытта арамыздан берәү:

— Һанри! Кил әле монда, кара! — диде.

Дәрхаль шул җиргә бардым, ни күрсәм яхшы булыр?

---

[1] Муаффәкъ булдым – ирешә алдым.

[2] Дәрхаль – шунда ук.

[3] Иҗарәгә – вакытлы файдалану өчен.

Аһ, мөхтәрәм карт әти! Шкафның иң асткы катында, һәммәсе дә бер-берсенә тәмамилә охшаган, сәхифәләре һичбер киселмәгән гаять күп китап күрдем, мави тышларыннан таныдым ки, болар «Карлыгачлар», минем «Карлыгачлар» иде. Дөресте, беренче әсәремнең беренче табгысының һәммәсе ушбу җирдә иде. Массулның әйткәне кебек, сатылып алынган, фәкать һичкем тарафыннан бәхәс ителмәгән бу китапларның һәммәсе шкафның ушбу бүлмәсендә сакланган икән. Бу китаптан һичбер вакытта бәхәс кыйлынмауның сәбәбене инде аңладым. Чөнки бу китапларның һәммәсен дә карт әтием сатып алган икән, минем китабымны укучы фәкать ул гына икән. Ятакларында, дантәләле[1] ястыклар арасында «Карлыгачлар»ны укуларын фараз кыйлган хатыннарның һәммәсе карт әтиемнән гыйбарәт, имеш.

Шул вакытта ук тез чүктем. Куелган көенчә торган бу китапларны кулларым тетрәгәне хәлдә мөгаянә иттем[2]. Бәгъзеләренең өстендә бик ерактагы китапчыларның мөһерләре бар. Боларны караганда, мөхтәрәм пәдәремнең[3], зәгыйфь аякларын сөйрәп, минем китабымны алыр өчен Парижның төрле тарафында йөрүе күзем алдына килде. Аның бер магазинга кереп, кәмаль вәкарь[4] белән: «Һанриның «Карлыгачлар» исемендәге әсәрене биреңез»,– дип соравы, китапчы шөбһәләнмәсен өчен, һәрберсеннән фәкать өчәр, дүртәр данә генә алуы, соңра аларны култыгына кыстырып, үзенең хәйләсеннән мәмнүн[5] булып өенә кайтуы исемә төште. Өенә кайту белән шкафы янына барып, анда үзенең ганимәтләрен[6] саклавы күземә күренгән кебек булды. Ул унбиш ел буенча бу серне саклаган, миңа һичбер белдермәгән иде. Моннан соң Массулның мәктү-

---

[1] Дантәләле – челтәрле.

[2] Мөгаянә иттем – күздән кичердем, карадым.

[3] Пәдәр – ата.

[4] Кәмаль вәкарь – тирән горурлык, камил горурлык.

[5] Мәмнүн – шат, разый.

[6] Ганимәт – байлык, трофей.

бене алган көндә, күзлекләренең артыннан көлеп, миңа сөйләгән сүзләрен хәтерләдем. Ул миңа:

— Син мәсгуд түгелмесең, балам? — дигән иде. Дөрест, мин мәсгуд идем. Ул заманнан бирле ирешкән муаффәкыятьләремнең һичбересе беренче әсәремнең беренче табгысының сатылып беткәнен ишеткән вакыттагы кадәр шатландыра алмадылар. Шул вакытта бу муаффәкыятьләрнең ни сәбәптән килеп чыкканлыгын белдем. Карт әтиемнең хәйләсенә вакыйф булдым[1]. Инде үткән сәгадәт вә шатлыкларны, бу бәхтиярлыкны[2] бирергә сәбәпче булган карт әтиемә миннәтдармын[3]. Саф булган ушбу мәхәббәт галәмдә иң мөкәммәл нәрсәнең яхшылык булуыны тагы бер кат исбат итте.

Һанри, бу җиргә җиткәч, сүзеннән туктады. Яңагында бер тамчы күз яше бар иде. Без һәммәбез дә, ушбу хикәядән мөтәәссир булып[4], Һанриның янында сөкүт иткән[5] идек...

*1914*

*«Әдәбият кисәкләре»*

---

[1] Вакыйф булдым – төшендем.

[2] Бәхтиярлык – бәхетлелек.

[3] Миннәтдар – (яхшылыгы өчен) бурычлы.

[4] Мөтәәссир булып – тәэсирләнеп, әсәрләнеп.

[5] Сөкүт иткән – тын калган.

## Хан кызы Алтынчәч

### *I*

Без, җәйгә чыгу белән, иптәшләремез белән бергә җыелып, Агыйдел буена балык тотарга – кармак салырга бара торган идек. Көн аяз, матур булса, бу эш безнең һәр көнге гадәтемез иде. Иртән тору белән, чәй-шикәр, күмәчләремезне култыгымызга кыстырып, кармак чыбыкларын кулымызга тотып, Агыйдел буена йөгерә торган идек.

Без, анда барып, кармак салып арыганнан соң, балыкчы бабай янына барып, балык пешереп, чәй эчеп көнне үткәреп, кояш баер алдыннан гына кайта торган идек.

Балыкчы бабай – бу бабай безне бер урынга җыярга, безнең күңелемезне ачарга иң зур сәбәпче иде. Бу карт, кыш булса, мәдрәсәдә ятып мәсҗед карый, безгә иптәшлек итә, җәйгә чыгу белән, Агыйдел буена күчеп, көне-төне Идел буенда тора торган иде. Ул үзенең бөтен гомерен ушбу матур Агыйдел буенда үткәргән. Аның сакалы ушбу җирдә, бу матур, моңлы тугайда йөреп агарган, ул менә бу астында утырдыкымыз карт карама белән бергә картайган. Бу җирләр – аның шатланган, моңланган, җылаган җирләре... Бу бабай бу тирәдәге әсрарны[1], бу тирәдә булган нәрсәләрне җөзьиятенә[2] кадәрле белә. Бу сахра, бу урман, бу тугай, бу Агыйдел буеның һәммә нәрсәләре бабайга таныш. Ул матур җәйге кичне шул урман арасында сайраган сандугач тавышын тыңлап үткәрә. Кош-кортларга иптәш булып шулар белән бергә моңлана, бабай тирәягындагы нәрсәләрнең һәммәсене үзенеке итеп карый, бу – алар өчен, алар моның өчен торган кеби дип уйлый. Бу бәхетле карт ушбу матур урыннарда иртәле-кичле су өс-

[1] Әсрар – серләр.

[2] Җөзьият – ваклыклар, кисәкләр.

тендә йөреп тапкан аз-маз акчасы белән мәсгуд көн күрә. Ул һәммә нәрсәгә, барча кешеләргә мәхәббәт белән карый. Ул без белән без булып – балалар булып сөйләшә.

## *II*

Гадәтемез буенча бүген дә идел[1] буена барып, бераз кармак салып утырганнан соң, кояш кызуына чыдый алмый, балыкчы карт янына – әлеге карт караманың астына җыелдык. Без барган вакытта безнең сөекле бабай нәрәтәләрен[2] элеп киптерә, өзелгән урыннарын рәтләп, бәйләштереп тора иде.

Без баргач та, бабай:

– Ягез, балалар, су алып килеп чәй кайнатып җибәрегез әле. Син, Габдерахман, Нафикъ белән менә балыкларны әрчеп пешерә башла,– дип, әрекмән яфраклары астында яткан балыкларны күрсәтте. Үзе һаман нәрәтәләрене рәтләү белән мәшгуль булып китте.

Без үземезне астына алган карт караманың ботакларына әйберләремезне элеп, кайсымыз балык әрчергә, бәгъземез су алып менеп чәй кайнатырга, кайсыларымыз утын җыеп ут ягарга керештек.

Без эшләрне рәтләп йөргәндә, балыкчы бабай үзенең эшләрен бетереп, чыланган киемнәрен салып, яланаяк көенчә безнең янга килеп утырган иде.

Безнең эшләр беркадәр рәтләнде. Балыклар әрчелеп казанга салынды. Корымланып беткән зур тимер чәйнекне карама ботагына тагылган җепкә бәйләп ут уртасына куйдык. Эшләр юлга куелгач, балыкларның пешкәнен, чәйнең кайнаганын көтеп, карама астына теләсә ничек урнашып, тирә-ягымызны карый башладык.

Безне астына алган карт карама Агыйделнең яр башына үскән, зур, калын ботаклары иделнең өстенә таба авышып торалар иде. Безгә каршы иделнең икенче ягында Акташ

---

[1] Идел – монда «елга» мәгънәсендә.

[2] Нәрәтә – талчыбыктан кәрзиндәй үреп эшләнгән балык тоту җайланмасы.

тавы идел буйлап сузылып ята, кояшның нурларын гакес итеп[1] күзне камаштырып тора иде.

Саф һава, матур табигать, Агыйделнең тавышсыз гына агуы безне җиңеләйтә, ашкындыра, моңландыра иде.

Тип-тигез, мөнтәзам[2] аккан идел өстеннән сал белән барган салчы башкортлар, үзләренең салларын су агымының ихтыярына куеп, акрын гына кузгалып, ишкәкләренең башларында утырганнары хәлдә, бик моңландырып озын көйләрен җырлап баралар иде.

Боларның җырлаган тавышлары Акташ тавына бәрелеп, безгә икәү булып ишетелә, тирә-якка тарала, Агыйдел буе буйдан-буйга яңгырап китә иде.

Без аларның җырларын бүлмәс, моңлы тавышларын өзмәс өчен, аларга сүз кушмадык. Аларны рухани ләззәтләреннән аерырга теләмәдек. Алар, шулай акрын гына агып, иделнең борылган җиренә, тау буеннан урман арасына кереп югалдылар. Бу вакытта безнең чәйнек актарылып кайнап, суы утка түгелеп, көлләрен күккә очырды. Бу безне хәрәкәткә китерде. Шуннан соң без, яшь үләннәрне кул белән тигезләп, балыкчы бабайның чобар буйлы чүпрәк паласын, аның өстенә ашъяулыгын җәйдек. Суга тыгып куйган шешә белән сөтемезне алып килдек.

Без чәй эчеп бетүгә, балык та пешеп өлгерде. Без, үземезнең өлешемезгә төшкән балыкларны агач яфраклары өстенә куеп, ашарга керештек. Шулай да безнең күзләремез һаман тирә-якны тамаша итүдә иде.

Безнең арамыздан берәү:

– Иделнең аргы ягына, каршыдагы Акташ тавының өстенә, әнә теге өелеп-өелеп, киртләчләнеп, салынып төшәргә торган зур ташларның арасына менеп йөрергә кирәк иде...– диде.

Безнең балыкчы бабай, мөхаль[3] бернәрсәне ишеткән сыман, бик кызык иттереп көлде дә:

[1] Гакес итеп – чагылдырып.

[2] Мөнтәзам – тәртипле (тигез генә).

[3] Мөхаль – мөмкин булмаган, булмый торган.

– Чыгарсың анда, атаң башы! Бар әле, чыгып кара, үзеңне ботарлап ташласыннар,– диде.

Без балыкчы картның бу сүзенә гаҗәпсендек һәм бабайдан: «Ничек алай соң?» – дип, сөйләвен үтендек. Бабай, бер дә киреләнеп тормый сүз башлап:

– Менә бу Акташ тавының аръяк өсте тип-тигез; анда киң яланнар һәм борынгы мөселман ханнарыннан калган шәһәр урыннары бар. Алар борынгы заманнарда шул җирләрдә хан булып бик шәп гомер иткәннәр. Алар шунда бик көчле булып гомер иткән вакытта, аларның өстләренә икенче җирдән бик зур яу килгән.

Бу шәһәрнең шул замандагы ханы, бу яуның башлыгына илче җибәреп, ни өчен килгәнлекләрен белергә кушкан...

### *III*

Менә бу Акташ тавы өстендә торган ханның Алтынчәч исемендә бик матур, бер бите ай, бер бите көн кеби бик сылу кызы булган икән. Теге яуның башлыгы ханның җибәргән илчесенә Алтынчәчне алырга килгәнлеген, яхшылык белән бирмәсә, сугышып булса да алырга теләгәнлеген әйтеп җибәргән.

Хан, яу башының бу сүзен ишеткәч, кызы Алтынчәчкә хәбәр җибәреп, барырмы икән, дип сораткан: «Урал тавы аръягындагы Җаек буендагы фәлән хан сине сугышып алырга дип килгән, барасыңмы, юкмы?», – дигән.

Алтынчәч:

– Мин җәенке битле Җаек буе яубасарына бара алмыймын. Акташ тавы өстеннән Урал тавы аръягына барыр хәлем юк. Әткәм, дошманга каршы сугыш ачып булса да, мине бирмәсен, әгәр дә мине көчләп бирәләр икән, икенче көн мине якты дөньяда күрмәсләр,– дип җавап кайтарган.

Хан, кызының бу сүзләрен ишеткәч, Алтынчәчне бирмәс өчен дошманга каршы сугышырга карар биргән һәм дә яу башына:

— Кызым сиңа үлсә дә барырга риза түгел, инде килгән юлыңыздан кире кайтып китәрсең, булмаса, миндә көч юк түгел, башкасын үзең бел, сугышырга хәзер тора безнең ил,— дип хәбәр җибәргән.

Яу башы, ханның җавабын ишеткәч, бик ачуланып:

— Сугышып булса да Алтынчәчне алырмын, буш кул белән илемә кайтмамын,— дип, шунда ук гаскәренә атка менәргә кушкан.

Алтынчәчнең атасы да, үзенең гаскәрен җыеп, яуга каршы чыккан. Хан гаскәре (бабай кулы белән ишарә кыйлып) әнә теге тауның өстеннән торып, әнә теге аркадан килгән яуга каршы ук белән атканнар. Ул замандагы бабайларның сугыша торган кораллары ук, сөңге кеби нәрсәләр генә булса да, аларның уклары өч-дүрт чакрымга җитеп, каты агачларга барып кадала торган булган.

Хан гаскәре яу белән бик озак вакытлар сугышсалар да, яу бик күп булганга күрә, хан гаскәре җиңелеп, шәһәргә качып керә башлаганнар. Шәһәр эчендәге халыклар да кайда барырга белми аптырауда калганнар.

Хан кызы Алтынчәч, әтисенең гаскәре җиңелгәнен күргәч, бик шәп кара юргага менеп, кулына ук һәм сөңге алып, үзенең янына Каракүз дигән иптәш кызын ияртеп, яуга каршы чыккан. Алтынчәч, бик нык сугышса да, уң кулы җәрәхәтләнү сәбәпле кире кайткан.

Хан, эшнең ахыры бик начар булачагын белеп, үзенең хәзинәсендә булган алтын-көмешләрен, җәүһәр-якутларын яшермәкче булып,— әнә, әнә күренә бит әле иң текә җирдә, мич кеби эчкә кереп, эңрәеп торган бер тишек сыман урын,— әнә шуның эченә җыйдырган, аның эче бик киң ялан, ди, анда күл дә бар, ди.

Хан үзе тагы да гаскәре белән яуга каршы чыгып сугыша башлаган. Шулай да һаман җиңелгән.

Алтынчәч, дошман кулына төшмәс өчен, төнге ай яктысында, үзенең иптәше Каракүз дигән бер кызы белән, качып, әнә шул ханның хәзинәсе яшерелгән тау тишегенә килеп кергән.

Яу, ханның гаскәрен җиңеп, ханның үзен тоткынга алып, үзләренең илләренә кайтып китkәннәр. Алтынчәч шунда кереп югалган.

## *IV*

Бабай вакыйганың иң кирәкле җирләренә җитеп туктагач, һәммәмез беравыздан:

– Шуннан соң Алтынчәч ни эшләгән соң? – дип кычкырып җибәрдек.

Бабай:

– Шуннан соңмы?.. Шуннан соң Алтынчәчнең ничек булганы мәгълүм түгел. Тик җәй көнге матур төннәрдә Алтынчәчнең тау тишегеннән чыгып, тауның киртләчләнеп торган урынына утырып, Агыйделгә таба карап торганын, хәтта бәгъзе кешеләр аның бик моңланып җырлаганын күргәннәр. Ул бичара шунда ай яктысы булган төннәрдә чыгып, үзенең аякларына төшеп торган озын чәчләренә күмелеп, учына таянып, тугайга таба карап бик моңаеп таң атканчы утыра, ди. Шуннан соң тагы да артына карап, шунда кереп югала, ди.

Ул борын заманда бик еш күренгән, бу көннәрдә аны күргән кеше ишетелми. Тик безнең карт әти кич белән монда ялгыз кунган вакытта Алтынчәчне күргәнен, матурлыгына исе китеп карап торганын сөйли торган иде.

Без:

– Хәзинәләр шунда микән соң? – дидек.

Бабай:

– Менә минем әйтә торган сүзем дә шул. Менә инде озак вакытлар үткәч, шул хәзинәләргә җеннәр ияләшкәннәр. Аларны алырга барып, әллә никадәре кешеләр шунда һәлак булганнар. Анда кулына мылтык тоткан солдатлар каравыллап торалар икән. Алырга теләгән кешеләрне якын да җибәрмиләр икән.

Бабай, сүзене бетергәч, тагы да тауга таба бик куркынычлы, серле итеп, хәзин[1] бер сурәттә карап куйды. Нигәдер бик тирән күрсенде.

Без чын ихлас белән бабайның сүзләрен тыңлап беттек. Бу вакытта кояш баерга якынлашкан иде. Хан кызы Алтынчәчнең ак ташлар арасыннан абына-сөртенә качып килүе, тирә-ягына моңлы итеп каравы, куркуыннан агарган матур йөзләре, яшь белән чыланган озын керфекләре астындагы зур кара күзләре белән күз алдымызга килеп баскан кеби булды. Гүя бу минутта, шушы кичтә Алтынчәч үзенең иптәше Каракүз белән тау тишегеннән кереп баралар иде. Балыкчы бабай сүзене бетергәндә, һәммәмезнең дә күзләре каршымыздагы ак тауның салынып төшәргә торган ташларында иде.

*Беренче тапкыр «Аң» журналының 1914 ел*
*16–17 (30 сентябрь) санында басылган.*

[1] Хәзин – кайгылы, хәсрәтле.

# *ПУБЛИЦИСТИК ҺӘМ ФӘННИ МӘКАЛӘЛӘР*

## Үрмәкүчтән гыйбрәт алмалы

Үрмәкүч, һәр кешегә мәгълүм, хосусән, хатыннарның дошманы булган, өй эчләрендә ватан тоткан кечкенә бер мәхлуктыр. Бер хатын һәркөн өйне җыештырыр вә тазартыр. Өйнең түбә тактасының почмакларында булган үрмәкүч авыны себерке илә себереп төшерер. Үрмәкүч, бичара, бу вакытта бер читкә китеп, дөньясының харап булганыны бик хәсрәтле сурәттә карап торыр. Себеркене мөдафәга иттерергә[1], хатынга каршы торырга хәле җитмәгәнене ачык белгәнгә күрә, тавыш-фәлән чыгармас. Үрмәкүчнең иң дошман күргән нәрсәсе шул себерке булса кирәк. Хатын шулай һәр сәгать бунын авыны ватып-себереп төшерсә дә, үрмәкүчнең касды[2] вә һиммәте[3] зәррә кадәрле булсын кимемәс, бәлки һаман мәкъсудына җитәргә иҗтиһад итәр. Себерке китү илә, баягы урынына барыр. Әүвәлгедән дәһа[4] матур итеп ау корыр. Үрмәкүч авының бөтен әтрафы һәндәсә[5] гыйлеме илә эшләнәдер. Бунын дөрестлегеннән адәм балалары гаҗиз калалар. Тәҗрибә илә караганда, һәндәсә кагыйдәләрен тәмам ригая итмеш[6], аз гына булсын – фәлән хилаф итмәмештер[7].

---

[1] Мөдафәга иттерергә – кире кайтарырга.

[2] Касды – теләге, максаты.

[3] Һиммәте – тырышлыгы.

[4] Дәһа – тагын да.

[5] Һәндәсә – геометрия, инженерлык эше.

[6] Ригая итмеш – саклый.

[7] Хилаф итмәмеш – каршы килми.

Күп тә үтмәй, баягы хатын себерке илә үрмәкүч авыны себермәк өчен дәһа килә, ачулана-ачулана себереп ташлай. Фәкать себеркенең һөҗүме үрмәкүчнең гайрәтене вә сәбатыны[1] бер дә бетерә алмай.

Үрмәкүч, карап торган урыныннан кузгалып, шул сәгать ау корып та бетерер, чебеннәрне тота башлар. Хатын, никадәре иҗтиһад итсә дә, үрмәкүчкә галиб[2] килә алмас. Бара-бара гайрәте кайтып, үрмәкүчнең авыны себермәй башлар.

Үрмәкүч тынычлык илә гомер итәргә вә чебеннәрне теләгәнчә тотарга керешер.

Хатын илә себерке бәласеннән дә бераз заман котылып торыр.

Безем милләтемездә шул үрмәкүчтә булган кадәре гайрәт, газимәт[3] вә һиммәт булса иде, тиз көндә мәкъсудларыны алырлар, себерке кеби манигъларны мәгълүб итеп[4], галиб килерләр иде. Бу үрмәкүч никадәр кечек вә никадәр зарар күрсә дә, мәэюс улып башлаган эшне эшләмәй, теләгән мәкъсудына җитмәй туктамас. Тагъ кеби себеркеләр, гыйфрит кеби хатыннар буның юлына сәд чигә[5] алмаслар. Буның гайрәтенә фөтур[6], кимчелек китермәсләр. Бу үрмәкүч, бер кәррә эшем булмады инде дип, безем милләт кеби күңелне суытып эштән туктамас. Бер булмаса, бер булыр. Себеркегә галиб килермен дия, сабырлык илә эшендә дәвам итәр.

Безем милләтемез менә шул үрмәкүчтән булса да гыйбрәт алсалар, зарар булмас иде.

*Беренче тапкыр «Бәянелхак» газетасында*
*1907 елның 25 декабрь санында басылган.*

---

[1] Сәбат – чыдамлык, ныклык.

[2] Галиб – җиңүче.

[3] Газимәт – теләк.

[4] Мәгълүб итеп – җиңеп.

[5] Сәд чигә – киртә була.

[6] Фөтур – сүлпәнлек.

## Гаҗәпләнмәгән идем, гаҗәпләндем

### *I*

Ул саф күңелле, үткен зиһенле булу өстенә, тәрбия вә тәхсилем[1] дә аның белән бергә, бер вакытта булганлыктан, мин аны ярата идем. Кеше һәрвакыт та фәлсәфи, хөкми[2] мәсьәлә белән генә мәшгуль булып тора алмый, бәгъзән вак-төяк мәсьәләләргә, уен-көлке кеби күңел ача торган шәйләргә дә вакытыннан өлеш чыгарадыр. Менә ул да шулай иде. Уен бабына керсә бик көлдерә, эчне катырмый туктый алмый иде. Ул миңа якын бер иптәш, чын бер дуст булып киткән иде.

Ике арамызда мәсләк җәһәтеннән[3] бераз гына аерма булса да, ул аерма безем дустлыкны мәхү итәчәк[4] дәрәҗәсендә түгел иде. Аның мәсләге «җир йөзе – ватаным, бөтен инсаннар – кардәшләрем» димәктән гыйбарәт булып, шул заманча әйткәндә, сул иде. Мин алай ук киң күңелле була алмый, үземне «урта» тотып, тугърысыны әйткәндә, «милләтче» дигән була идем.

Без күп вакытта тату торсак та, шушы ноктага килгәч кычкырышмый чыдай алмый идек. Ул миннән милләтче дип көлә, мин дә «тик торсана!» диеп сүзене бүлә торган идем. Без шул «милләт», «сул» кәлимәләре тирәсендә сәгатьләрчә талашсак-тартышсак та, арамыздагы мәхәббәткә зарар килми, бәлки арта гына иде. Бәгъзән ул аз гына уңгарак, мин сулгарак килеп, мәсләкемез берләшә яза иде. Ләкин берләшүемез күпкә бармый, бер сәбәп чыгу белән

[1] Тәхсилем – гыйлем алуым.

[2] Хөкми – фикер йөртүле.

[3] Мәсләк җәһәтеннән – дөньяга карашлар ягыннан.

[4] Мәхү итәчәк – юкка чыгарырлык.

әлеге «миллилек», «суллык» мәүзугы бәхәсемез[1] булып китә иде. Ул бәгъзе вакытта ифрат китеп, «милли» дигән сүзне үзеңнән башкаларны вату, изү, кан эчү урыннарында истигъмаль кыйлып[2] мине чын да ачуландыра, ихтыярсыз мөкабәлә кыйлырга[3] мәҗбүр итә иде. Ул гүя бу көннән сәгадәтне, тигезлекне, рәхәтлекне кулына алган да, моннан соң иҗтиһад кыйлу, тырышу, эшләү буш бер нәрсә, дигән төсле була иде.

Мәгълүмат җәһәтенә килсәк, икебез дә гади, ягъни урта мәгълүматлы идек. Ул, аз гына белгән русчасыны төрлечә әйләндереп, үзене русча бик оста итеп күрсәтергә маһир иде.

Ул күп вакытта, берәр җирдән ишетеп кайткан чит сүзләрне тәкрар итә торгач, мине ялыктырып ташлый иде.

Аның сүзенә караганда, тиздән бөтен кешеләр тигез була, милли дигән сүзләр лөгать китапларында гына очрый, байлыкның игътибары калмый, һәммә кеше эшли, бер мохтаригъ[4], бер мәүҗид[5] белән бер кара эшче икесе дә бер хокукта була. Кыскача әйткәндә, куй белән бүре бергә йөри, җылан белән бала бергә уйный иде.

Ул бу дәгъваларыны исбат итәр өчен дәлилләр, мисаллар китерә, дәлиле бетә башласа, кара гакыл, коры тел белән мине җиңәргә тырыша иде.

Мин: «Туган! Бу нәрсәләрнең кирәклегене белеп дәгъва кыйлсаң, бер сүзем дә булмас иде, ләкин гыйлемсез көенчә, башкаларга тәкълид белән генә дәгъва кыйлуың килешеп бетми, үзебез кеше булып алаек әле. Коры сүз белән гомер үткәрмәек»,– ди идем.

Муллаларны сүгүгә, аларның килешмәгән җирләрен тикшерүгә килсәк, бу тугърыда икәү тәмам берләшә идек. Бу мәсьәләдә һичвакытта ике арада ихтилаф вакыйгъ бул-

[1] Мәүзугы бәхәсемез – бәхәсебез темасы, проблемасы.

[2] Истигъмаль кыйлып – кулланып.

[3] Мөкабәлә кыйлырга – каршы торырга, каршы җавап кайтарырга.

[4] Мохтаригъ – уйлап табучы.

[5] Мәүҗид – иҗат итүче, иҗатчы.

мады[1]. Бигрәк тә «сул», «милли» кәлимәләре тирәсендә чобала идек. Бу кәлимәләр сәгатенә йөзәр мәртәбә тәкрар кыйлына торган иде. Күп сүздән соң: «Фикер һәм мәсләк төрлечә булырга мөмкин, монда гаҗәпләнерлек эш юк. Бу мәсьәләнең нәтиҗәсене истикъбаль[2] күрсәтер әле»,— дип, икемез дә китап моталәга кыйлырга[3] керешә идек.

Бәй! Күп тә тормый, әлеге иптәшем баягы мәсьәләне дәхи китереп чыгара да китабыны ябып куеп, әрле-бирле йөрергә башлый, минем белән талашырга керешә иде.

Мин: «Әллә, туган, сине берәр кеше яллап куйдымы? Бер эш тә кыйлмый, һаман шул мәсьәләне китерәсең дә чыгарасың! Әйтерсең бу дөньяның ачкычы, халыкларның сәгадәте минем кулымда да мин аны бирми торам, мин үзем дә бер ярлы кеше, кулымда бер тиенлек нәрсәм юк»,— ди идем.

Бәгъзе вакытларда хатын-кыз, гаилә мәсьәләләренә күчә идек. Татар хатыннарының әсарәттә[4] калуларына, бөркәнчек астыннан чыга алмауларына, мәктәп йөзе, гаилә тәрбиясенә гаид[5] бернәрсә дә өйрәнмәүләренә даир[6] мәсьәләләрне мәүкыйгы мөзакәрәгә[7] куя торган идек. Бу тугърыда да ул артык, ифрат китә иде, ягъни: «Хатын алсам, иң әүвәл чапаныны алып ыргытырмын, тәмам русча йөртермен. Һичбер кешедән качырмам. Үзем тәрбия итәрмен. Татар гадәтләренең һичбересене кыйлдырмам»,— дия тезеп алып китә иде.

Мин: «Хатын-кызларны тәрбия вә тәгълим[8] — иң кирәкле эш, бу көенчә пәрдә артында торсалар, татар милләтенең югалуына шөбһә юк. Алар тәрбия кыйлынма-

---

[1] Ихтилаф вакыйгъ булмады — каршылык барлыкка килмәде.

[2] Истикъбаль — киләчәк.

[3] Моталәгә кыйлырга — укырга.

[4] Әсарәт — тоткынлык, коллык.

[5] Гаид — караган (кергән).

[6] Даир — бәйләнешле.

[7] Мәүкыйгы мөзакәрәгә — фикер алышуның үзәгенә.

[8] Тәгълим — укыту.

ганда истикъбалемез начар. Аларга хиҗабның[1] лөзүме[2] юк. Фәкать ислам тәрбиясе һәм милли рухта тәрбия кыйлынулары матлүб[3]»,– ди идем. Ул минем сүземә шундук бәхәс кыйла, хатыннарга киң хокук бирми, тар рамка эчендә генә тотмакчы буласың, ди иде.

Кыска гына әйткәндә, дустымның фикеренең хөласасы[4] дөньяда һәммә халыклар бертигез хокукка малик[5] булу, байлыкка «буржуаз» дип истихфаф илә[6] карау, хатыннарга рус хатыннарыннан да артыграк хөррият бирүдән гыйбарәт иде.

## *II*

Безнең болай кызыктырган, бергә көн иткән гомеремез озак дәвам итмәде. Бер елдан соң үз эшләремез сәбәпле аерылып торырга тугъры килде.

Менә шул көннән соң мин аны бик сирәк очрата башладым. Безнең аерым тора башлавымызга бер ел тулып та китте. Инде ул бераз басылган иде, сәгатенә йөзәр мәртәбә тәкрар кыйлган «сул» кәлимәсене бер генә рәт тә әйтми башлаган иде. Бу көндә ул да, мин дә сәясилек сатмый, үз эшемезне карый торган бер кеше булган идек. Шулай да мин, сүзне борып, үткән заманда бөтен көннәремезне мәшгуль иткән мәсьәләләргә алып бардым: «Бу көндә тормыш, инсаннар һәм дә милләт тугърысында фикереңез ничек?» – диеп сорадым.

– Юк шул, безнең халыкның башына ул фикерләрне кертергә иртәрәк, үз файдасыны белми торган халыкка сүз аңлатуы бик мөшкел,– диде.

– Нигә теге вакытта шуларны уйлый алмаган идек? – дигәч:

---

[1] Хиҗаб – пәрдә, чаршау.

[2] Лөзүме – кирәге.

[3] Матлүб – таләп ителгән нәрсә.

[4] Хөласасы – нәтиҗәсе, йомгагы.

[5] Малик – ия.

[6] Истихфаф илә – кимсетеп, мыскыллап.

– Ул вакыт бит Русиянең кайнаган вакыты, инде һәр милләт үз файдасыны карарга, дөньяда шул як белән тигез торуны уйларга кирәк,– диде.

– Әллә сез фикер җәһәтеннән бераз үзгәрдеңезме? Милләт дигән сүзне әйтә башлагансың,– дидем.

– Мин дә милләтче, синең кеби тар милләтче түгел,– дип куйды.

– Инде милләтче булгач, кирәк тар милләтче бул, кирәк киң милләтче бул, анда күп хикмәт юк, әмма хикмәт сезнең милләтче була башлавыңызда,– дидем.

### *III*

Ике ел була инде, мин аны бер дә очрата алмадым. Менә беркөн бергә очраштык. Инде ул уң да түгел, сул да түгел, бу мәсьәләләр белән баш та ватмый, бәлки үз эше белән мәшгуль иде. Бу көндә яхшы гына баеган, ике тиенлек нәрсә килә торган урын күрсә, ничек тә үзенә алырга тели, дүрт почмаклы өй – аның ватаны булган, ике баласы да туган иде.

Мин моның үзе яратмый торган байлык юлына керүенә бер дә гаҗәпсенмәдем. «Чөнки бөтен тормышның нигезе акчага корылгач, дөнья шулай итәргә мәҗбүр иткәч, бу гына инде бушка карап ятмас, иҗтиһад кыйлыр, бай булыр, үз эше белән мәшгуль булгач, уңлык, суллык, миллилек белән чобалып йөрергә вакыты булмас, фикер – бер вакыт үзгәрә торган нәрсә, биш ел буенча фикере үзгәргәндер. Бик яхшы бай булсын, бервакытта инсаннарга, милләткә файдасы тиеп куяр»,– дидем.

Ләкин ул: «Хатын алсам тар бүлмәдә ябып асрамам, тәмам хөрлек бирермен, һичбер кешедән качырмам, алар да бит адәм баласы, кешеләр белән утырсыннар, сүзгә, мөгамәләгә өйрәнсеннәр»,– ди торган иде.

Ни өчендер ул бу вәгъдәсендә дә тора алмаган. Чөнки аның зәүҗәсе[1] һаман тар бүлмәдә мәхбүс[2], залга

[1] Зәүҗәсе – хатыны.

[2] Мәхбүс – тоткын.

чәй-фәлән бирергә теләсә — кулыны сузып кына бирә, бүлмә эчендә пеш-пеш дигән тавыш чак ишетелә, бакча-фәләнгә чыгарып йөртми, үзе алып чыкканда башына капчык ябып чыгара иде.

Дустымның бу эше күңелемә ошамады. Хатыннарны бу дәрәҗә адәм күзенә күрсәтми, аерым тотарга нәрсә мәҗбүр итә, алар да кеше бит, хөр, рәхәт-рәхәт йөрсеннәр, ачык дөньяны күрсеннәр. Аларны нигә адәм саныннан чыгарырга кирәк?

Бу дустымның фикере үзгәргәндә дә яман үзгәргән икән дип, менә бу эшкә гаҗәпләндем.

*Беренче тапкыр «Вакыт» газетасының*
*1910 елгы 22 сентябрь санында басылган.*

## Татар җырчысы

Аңлы вә алга киткән милләтләрдә җырчы вә уенчылар иң беренче шөһрәтле мәүкыйгны[1] тоталар. Мәнсүб[2] булган милләтләре аларга үзләренең зур кешеләре итеп карыйлар, аларга тиешле ихтирамны кыйлалар, аларның һөнәрләрене тәкъдир итәләр. Милләтләренең тәкъдир итүләрене күргәч, боларның рухлары күтәренке була, үзләренең һөнәрләрене арттырырга иҗтиһад итәләр. Концертлар бирәләр. Бу эшләре белән үзләре дә файда күрәләр. Халыкның музыка вә көйләренең тәрәккыйсенә дә сәбәп булалар.

Бездә әле алай мәшһүр җырчы вә уенчылар җитешкәне дә юк. Халык та андый кешеләрне тәкъдир итәрлек дәрәҗәгә ирешмәгән. Бездә музыканың тәрәккый итмәвенә, җырчыларның чыкмавына бик күп сәбәпләр бар. Ул тугърыда язуны икенче вакытка калдырып, мин монда татар җырчысы Мөхәммәтҗан әфәнде Габидуллин хакында аз гына язмакчы булам.

Мин Мөхәммәтҗан әфәнде белән моннан ике ел мокаддәм Уфада иттифакый[3] гына танышкан идем. Танышып бераз утыргач, ул, янында торган гармуныны алып уйнап, кычкырып җырлап җибәрде. Җыр дигәч тә күңелемезгә, акырып-бакырып, әүвәленең ахырына мөнәсәбәте булмаган җөмләләрне тезү искә төшәдер. Ләкин Мөхәммәтҗан әфәнде алай түгел иде. Ул яңа татар шагыйрьләренең тәмле җырларыны яңа көйләргә салып җырлый, җырлавы илә шигырьнең мәфһүмене[4] күз ал-

[1] Мәүкыйг – урын.

[2] Мәнсүб – үз.

[3] Иттифакый – очраклы.

[4] Мәфһүм – эчтәлек.

дына тәҗәссем[1] иттерә, ихтыярсыз хәйран калдырадыр. Аның өстенә, бик шәп иттереп гармун уйный иде. Мин Мөхәммәтҗан әфәнденең тавышыны, һәркемнән тәкъдир иттерерлек итеп җырлавыны чын күңелем белән яраттым. Затән[2] тәмле вә рухлы шигырь, матур тавышлы агыздан чыкса, аңа музыка да кушылса, кемгә булса да тәэсир итәдер. Мин дә Мөхәммәтҗан әфәнденең үз милли шигырьләремезне матур вә ачык тавыш белән җырлавына мөфтүн улдым[3]. Яңа шигырьләрне көйгә салып җырлаучыны беренче мәртәбә генә күргәнгә күрә, бу эше өчен Мөхәммәтҗан әфәндегә рәхмәт укыдым. Мөхәммәтҗан әфәнде минем күңелемә тирән бер хис, бетмәс бер эз калдырып киткән иде.

Менә якын арада Мөхәммәтҗан әфәнде, Мәскәүгә «Общество граммофон»га барып җырлап кайтып килгәндә, Уфага дәхи төште. Мин аны тәмам сагынып көтеп торган идем. Бер генә көн булса да, милли җырчымыз белән утырып калдым. Аның моңлы вә дәртле тавышыны тәкърар ишеттем. Мөхәммәтҗан әфәнде үзенең матур тавышы белән мөхтәрәм шагыйремез Габдулла Тукаевның «Теләнче», «Алтынга каршы», «Тотса мәскәүләр якаң!» вә гайре шигырьләренә һәм дә башка бер-ике кешенең шигырьләрене тәэсир иттерерлек дәрәҗәдә килештереп җырлый, гармуныны уйный иде. Мин, борыннан Габдулла Тукаев шигырьләренең мөфтүне булуым өстенә, аның матур шигырьләрене матур тавышлы бер агыздан ишеткәч, бигрәк тә мөфтүн булдым, күңелемдә онытылмаслык бер хиссият калды.

Югарыда мәзкүр сәрләүхәле[4] шигырьләрне Мөхәммәтҗан әфәнде граммофонга җырлаган. Тиз көннән матур тавыш белән җырланган матур шигырьләрне, яңа көйләрне һәркем ишетә алачактыр. Музыкамыз юк, бу эштә халкы-

---

[1] Тәҗәссем иттерә – гәүдәләндерә.

[2] Затән – үзе.

[3] Мөфтүн улдым – сокландым.

[4] Мәзкүр сәрләүхәле – исемнәре аталган.

мызның аңы аз, бу тугърыда мәгълүматым накыйс булганга[1] күрә, шул кадәре язу белән генә туктыймын.

Мөхәммәтҗан әфәнде сәбат[2] белән бу эшендә дәвам итсә, киләчәктә милләт балалары тәкъдир итәр, хезмәте җирдә калмас дип әйтәм. Мәүһибәти илаһияти[3] булган тавышны ишетүне арттыруны үтенәм.

*Беренче тапкыр «Вакыт» газетасының 1910 елгы 14 октябрь санында басылган.*

---

[1] Накыйс булганга – тулы булмаган, аз.

[2] Сәбат – ныклык, чыдамлылык.

[3] Мәүһибәти илаһияти – алла бүләге.

## Чуар тел

Бер милләтнең теле югалса, бер милләт икътисади[1] җәһәттән җиңелсә, ул милләт үзе дә югала, бинаән галәйһи[2] тел мәсьәләсе – гаять әһәмиятле мәсьәлә дип, телнең әһәмияте хакында озын мөкаддәмәләр[3] язып тормый, туп-тугъры телемезнең нинди җәһәттән үзгәргәнен, бетсә – ничек бетәчәген язып китәсем килә.

Төрек-татар кавеменең иске лөгатьләренең әксәре[4] онытылып беткән. Аларның күбесе истигъмальдән[5] чыгып, алар урынына гарәби, фарси кәлимәләр кереп урыннашканнар. Шуларның мокабиле[6] үземезнең асыл төрек телендә булса да, алар югалганнар яисә истигъмаль кыйлынмыйлар. Чит кәлимәләр бездә шул кадәре күп, шул кадәре мәгълүм булып беткән, аларны чыгарып ташлап, алар урынына үземезнең иске төрек сүзләрен истигъмаль итү мөмкинлек дәрәҗәсеннән узган. Мәсәлән, дөнья, гакыл, гыйлем, илтифат, игътибар, тәгам илх...[7] вә башка кәлимәләрне һәркем кирәк кайда гына булса да истигъмаль итә, боларның нинди мәгънәдә икәнене дә һәркем үз теле кеби беләдер. Мондый сүзләрне татар теле арасыннан чыгарып ташлау гаять читен. Бу сүзләр үз сүземез кеби булган, әдәби телемездә урын алган. Халык, мәкъсудыны ифа иткәндә[8], боларны теләсә генә ничек истигъмаль итә һәм аңлый. Хәтта боларның бәгъзеләрене истигъмаль ит-

---

[1] Икътисади – экономик.

[2] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[3] Мөкаддәмә – кереш сүз.

[4] Лөгатьләренең әксәре – сүзләренең күбесе.

[5] Истигъмаль – файдалану.

[6] Мокабиле – алмашы, эквивалентлары.

[7] Илх (ила ахириһи) – һ.б. (һәм башкалар).

[8] Мәкъсудыны ифа иткәндә – максатын белдергәндә.

ми калу мөмкин түгел. Аларны катыштырмый язарга уйласак, көчләнеп кенә яза аламыз. Вә илля[1] юк. Бу лөгатьләр асыл төрек телене вә шивәсене бозарга сәбәп булсалар да, бу көндә төрек-татар теле шулар катышкан көенчә төрек-татар теле булып киткәнгә, моннан соң тагы андай лөгатьләр кермәсә, безнең телемез, моннан да артык бозылмый, бер әдәби тел тәшкил итә алыр.

Үз фикеремчә, моннан соң телемезгә гарәби, фарси кәлимәләр катышып, ул яктан безнең тел бозылмас, фәкать асыл телемездә булмаган, бәгъзе фәнгә гаид[2] гарәби исемнәрең дә телемезгә артык зарар итә алмас. Ниһаять, әдәби тел дигәнемез татарчалашып беткән гарәби сүзләр белән катыш булыр, һәрбер телдә азмы-күпме әҗнәби[3] лөгатьләр була. Моннан һичбер кавемнең теле мөстәсна түгел[4]. Бу әҗнәби лөгатьләр бигрәк тә фәнни, гыйльми һәм дә яңа ихтираг кыйлынган[5] берәр нәрсәнең исемнәре булалар. Бер нәрсә читтән керсә, аның исеме дә бергә килеп, тел арасында кысылып кала. Мондый нәрсәләрнең исемнәре үземездә әүвәлдән булмаганга күрә, болар, үз сүзләрене югалтып, аның урынына кереп калмыйлар. Мондый чит бер сүз керү белән үземезнең бер сүз югалып китми. Бәлки болар белән телемезнең байлыгы арта, лөгатьләре күбәя. Бер чит сүз кереп тә, үземезнең телдә шул ук мәгънәне аңлата торган сүзне югалтмаса, артык зарар юк, чөнки бу асыл татар сүзенең кимүенә сәбәп булмый, мәгәр чит сүз кереп урынлашып үземезнең бер сүзне югалтуга сәбәп булса, менә монда бик зур зарар булачагында шөбһә юк. Чөнки болар, барган гына саен күбәеп, меңнәрчә лөгатьләремезнең онытылуына, югалуына сәбәп була алалар. Мисал, бер вакытта кайдандыр «дөнья» кәлимәсе кергәндә, татарча «аҗун» сүзенең урынын алып,

[1] Вә илля – башкача булса, югыйсә.

[2] Бәгъзе фәнгә гаид – кайбер фәнгә караган.

[3] Әҗнәби – чит.

[4] Мөстәсна түгел – читтә кала алмый.

[5] Ихтираг кыйлынган – уйлап табылган.

аны югалткан. «Игътибар», «илтифат» сүзләре кереп, шул ук мәгънәдә булган татар сүзләренең югалуына сәбәп булганнар. Шундый гарәпчә кәлимә керү сәбәпле онытылып киткән меңнәрчә татар сүзләрен табарга мөмкин. Шулай бара торгач, гарәпчә-татарча катыш ушбу күрдекемез тел мәйданга чыккан.

Бу шулай инде. Бу чит сүзләрне чыгарып ташлап, кире югалган татар сүзләрен урынына кую, халык арасына таратып истигъмаль кыйлдыра алу бик кыен. Бу хакта үкенеп, моннан соң сакланып барудан артыгы юк. Госманлы төрекләре дәрәҗәсендә калмаганымыз өчен шатланырга да урын бар. Чөнки аларның бу көндә әдәби лисан дип йөрткән телләренең яртысыннан артыгы гарәпчә белән фарсыча.

Әлхасил, безнең халкымыз әдәбият белән мәшгуль булмас борын, әллә ни вакытта телемезгә чит сүзләр кереп калган, алар күбесе үз лөгатемез кеби булып киткән, җыеп алып чыгарып ташлау дәрәҗәсеннән үткән. Дөрест язу, дөрест уку өчен боларның авырлыгы тия. Шулай булса да, безнең татар теле моннан соң моннан артык бозылмас. Госманлы төрекләре кеби безнең үз лөгатемез югалып бетә язмаган әле. Тугърысы, гарәпчә кәлимәләр ягыннан артык зур куркыныч юк. Татар теленә аз-маз гарәп кәлимәләре катышу белән әллә ни булмас. Булган эш булган, солы арасында үскән борай кеби булып торырлар. Язучыларымыз ихтыят[1] белән язсалар, шул күргәнемездән артык телемез гарәп кәлимәләре белән чобарланмас.

Телемез гарәп кәлимәләренең һөҗүменнән котылды инде, дип торган вакытта, телемезгә икенче бер һөҗүм башланды. Монысы борынгыга караганда да куркынычлырак. Бунысы, бик тизлек белән таралып, үземезнең асыл лөгатьләремезне халык арасыннан югалта башлады. Бу хәзергә беленмичә торса да, бара торгач, искиткеч дәрәҗәдә телемезнең тамырыннан какшавына сәбәп булыр. Моның сәбәбеннән ниһаятьсез күп сүзләремез юга-

[1] Ихтыят – саклык.

лыр. Югалмый калсалар да, шул лөгать китапларында гына калып, халык арасында истигъмаль ителмәс. Менә ике сатучының сөйләшкәнен тыңлап караек:

« – Ну, тавариш, ярминкәгә барасыңмы?

– Юк, нигә? Дахуты расхутка җитми торган нәрсә артыннан вримә тирәйт итеп йөрүе не стоит. Үткән ел ул ярминкәгә барып, тәк сибә бушка йөреп, расхутланып кайттым. Бармасаң, дватсат раз лутчы икән».

Менә дүрт-биш юл сүздә унбиш чит сүз бар. Хәлбуки, бу ике татар үз телләре белән сөйләшәләр. Рус кәлимәләренең сүзләре арасына кергәнен алар үзләре дә белми калалар. Чөнки табигый хәлгә әйләнгән. Бу сүзләрнең һәрберсе үз телемездә дә бар. Аларны хәтерләренә китерә алмый калганга күрә, чит сүзләрне ихтыярсыз китерәләр. Бу инде шәһәр җирендә, инде авылга кайтып караек. Ике агай сөйләшә:

« – Ул дуракка сереңне напрасна сөйләгәнсең, никагда сер тотмый ул.

– Чурт беләмени аның алай икәнен, муж бит, берни булмас.

– Фсудки, сөйләмәгән яхшы булыр иде.

– Ну, туган, эш үтте, ничава не падилаеш, терсәкне тешләп булмый».

Менә бу ике агай ни чаклы чит сүзне үз сүзләре кеби иттереп, сүзләре арасына катыштырып җибәрәләр. Бу чаклы рус кәлимәләренең татар теле арасына кысылуы өчен нәрсә әйтергә?.. Бу сүзләр бер вакытта күбәеп, гомуми булып китеп, ничаклы үз лөгатьләремезне югалтуларына кем шөбһә итәр? Рус теле үз алдына торганда бик әдәби, безнең өчен белүе гаять матлуб[1] булса да, телемезгә катышып китеп, телемезнең чуарлануы, шивә вә өслүб[2] җәһәтеннән үзгәрүе, лөгатемезнең югалуы игътибарга алынса, телемезгә катышуы матлуб түгелдер. Бу китеш

[1] Матлуб – кирәкле.

[2] Өслүб – стиль.

белән барса, татарча, русча, гарәпчәдән мөрәккәб[1] яңа бер тел дөнья йөзенә чыгар. Асыл төрки теле вә лөгатьләре лөгать китапларында гына калыр. Китапларымызда гына булса, бу билийятне[2] чыгарыр да ташлар идек. Ә бу алай түгел. Бәлки халык арасына тарала, андагы татарча сүзләрнең урыннарын аладыр.

Әле югарыда мисал итеп күрсәтелгән агайлар русча укымаганнар. Инде русча укыган татарларның ана лисаннары белән сөйләшкәннәрен тыңлап торсаң – ис китәр! Алар, шөбһәсез, яртысыны русча, яртысыны гына татарча сөйлиләр. Эшләр шулай барса, үз телемез белән укуның базары да төшә башласа, егерме-утыз елдан соң саф татар теле белән язылган китапны аңлаучы да булмый башлар. Татар сүзенең нинди мәгънәдә икәнен лөгатьләрдән генә карап белә башлармыз. Без бу хәлгә төшмәсәк тә, болай барганда, балаларымыз шул хәлдә калыр. Ушбу киләчәкне уйлап, телемезгә чит сүзләр катыштырып сөйләшүдән, кызык яисә русча белгәнемезне кешегә белдерү өчен, телемезне чит сүзләр белән чобарлаудан ниһаять дәрәҗәдә сакланырга кирәк иде. Ике телне бергә катыштырып сөйләүдән, бара торгач, бер бозык, эшкә яраксыз тел генә туар. Моннан безгә башка файда килмәс. Фән аркылы яисә берәр нәрсә белән бергә кергән кәлимәләрдә сүз дә юк. Алар ихтыярсыз керәләр. Чөнки аларның исемнәре бездә борыннан булмый. Алар безнең сүзләремезне югалтмыйлар. Кирәк вакытта аларны истигъмаль итми дә мөмкин түгел. Югарыда сөйләшкән агайлар истигъмаль иткән чит сүзләр берсе дә болай зарурәт сәбәпле кермәгән. Аларның мокабиле телемездә артыгы белән бар, шуларны истигъмаль[3] итәргә, онытмаска, югалтмаска кирәк.

*Беренче тапкыр «Шура» журналының*
*1911 ел 13 (1 июль) санында басылган.*

---

[1] Мөрәккәб – оешкан.

[2] Билийят – бәлаләр.

[3] Истигъмаль – файдалану.

## Уфада кызларга мәхсус мәдрәсә салыну мөнәсәбәте белән

Уфа шәһәре кызлар укытуга әһәмият бирүдә иң алда булган шәһәрләр җөмләсеннәндер. Бунда җиде-сигез урында кызлар укыталар. Бөтен халык үзенең кызын укытырга, дөньядан хәбәрдар итәргә һич низагсыз иҗтиһад итә. Ничек тә тәртипле мәдрәсәгә баласын бирергә, укытырга һәркем чын күңеле белән тели.

Бу көнгә чаклы кызларга мәхсус ике мәдрәсә булып, башкалары фатирда укыта торганнар иде. Моннан өч сәнә мокаддәм шәһәр идарәсе тарафыннан кызларга мәктәп салу өчен буш бер урын бирелгән иде. Русларның икенче женский гимназияләренә янәшә булган бу урында бүгенгә чаклы кечкенә генә бер агач мәдрәсә булып, башка урын салыначак мәдрәсәгә корылган нигез белән тик ята иде. Зур мәдрәсәне тәмам итәргә акча күп кирәк булдыгыннан, мәхәллә[1] әһалисенең[2] генә көче җитми иде. Бу көннәрдә бу урынга мәдрәсә салу, укыту эшләрен карау Уфа «Мөслимәләр җәмгыяте»нә тапшырылды. Шуннан соң «Мөслимәләр җәмгыяте»нең рәисәсе вә башкаларның ярдәм вә иҗтиһады белән хәкыйкатән мәдрәсә дип әйтерлек, кызларга мәхсус бик зур итеп таштан бер мәдрәсә салырга керештеләр. Мәдрәсә, өч табакале[3] булып, пар белән җылытылачак. Мәдрәсәнең зур вә матур булып тәмам булуында шөбһә юк. Эчке Русиядә кызларга мәхсус мәдрәсә бу көнгә чаклы юк иде. Кызларны укытуга әһәмият биреп бу чаклы мәдрәсәләр салырга иҗтиһад итүче ханымнарга рәхмәттән башка сүз юк.

[1] Мәхәллә – шәһәр яки авылның бер мәчеткә караган өлеше.

[2] Әһали – кешеләр.

[3] Табакале – катлы.

Менә ушбу мәдрәсә салыну мөнәсәбәте белән мин укыту һәм мөгаллимәләр хакында бераз язып үтмәкче булам. Югарыда әйткәнчә, Уфада укытучы мөгаллимәләр, укучы кызлар ниһаять дәрәҗәдә күп. Болар һаман эшләрендә дәвам итәләр. Бу мәктәпләрнең өч-дүрте «Мөслимәләр җәмгыяте»нең каравы һәм аларның иганәләре белән бара. Өч данәсе хосусый байларның тәрбиясендә.

Ләкин бу мәктәпләрнең һичберсендә кызлар өчен иң кирәкле булган төпле мәгълүмат бирелми иде. Дөньяга чыгу белән кирәк була торган нәрсәләрдән юньләп бер нәрсә дә укытылмый, аз-маз татарча яза, укый башлагач та гарәпчәгә төшереп, рөшди сыйныфлары[1] дигән булып, кызларның башларын гына ваталар иде. Бу хакта мөгаллимәләргә төшендерә алмавы хакында җәмгыять рәисәсе[2] Мәрьям ханым үзе дә зарлана иде. Шул чаклы мәктәпләр булып та, юньле тәрбия бирә алмаулары хәкыйкатән зарланырлык иде. Монда инде мөгаллимәләрнең мәгълүматларын тикшереп торыр хәл дә юк. Чөнки аларның укыганы, тәрбия күргән җирләре шул ук карт абыстайлар булган. Күбесе кияүгә баргач кына мөгаллименнән бераз укыган. Башка юк.

Алар шул иске тәрбияләре буенча кызларны да гарәпчә укытырга кызыгып торалар. Байлар тәрбиясе белән барган мәктәпләрдә һичкемнең тикшерергә хакы булмаганга, аларда бигрәк түбән. Алар кыш буена кызларны имтиханга хәзерләп чыгаралар. Ягъни китапның билгеле урыннарын ятлату белән мәшгуль булалар. Икенче рөшди дигән сыйныфларында Кодури кеби кыен китапларны укытып мәшәкатьләнәләр. Фән исемнәре, программда булса да, укуда һич юк.

Өченче ел бер мөгаллимә өченче рөшдидәге бер кызга тәфсир укыта башлаган иде. Табигый, мондый эшләр кешегә күренү, надан халыкларны алдау өчен генә эшләнәдер. Тикшереп караганда, шундый җитешсезлекләр

[1] Рөшди сыйныф – башлангычтан югарырак класс.

[2] Рәисә –хатын-кыз башлык (җитәкче).

ниһаять күп. Милләт анасы булачак кызларның үзләренең киләчәктәге тормышларына тәгаллекы[1] булмаган нәрсәләрне укып гомерләрен үткәрүләре хәкыйкатән эч пошыра иде.

Мәктәпләр булып, иганә кыйлучылар табыла торып та, кызларның укулары өмид иткәнчә булмавы күп кешенең, хосусән, ханымнар җәмгыяте рәисәсенең, дикъкатен җәлеп итте. Мөгаллимәләрнең төрле программда, үзләре теләгәнчә укытулары, кызларга тиешле кадәре мәгълүмат бирә алмаулары соңгы елларда бигрәк ачык күренә башлады. Шуның өчен мөгаллимәләргә бер программ буенча укытырга кушу, аларны ныграк тәфтиш итеп торырга лөзүм күрелә иде. Бу эш бигрәк тә мәзкүр[2] зур мәдрәсәне салгач мөһим булачагыннан, шундый җитешсезлекләрне игътибарга алып, ушбу көннәрдә кызларга – мөгаллимәләргә гомуми һәм файдалы бер программ төзү өчен имамнар һәм мөгаллимнәрдән гыйбарәт бер һәйәт[3] тарафыннан эшкә башланды. Болар ибтидаи[4] һәм рөшди дәрәҗәсендә программ ясау белән мәшгуль. Бундан соң, югарыда зикер кыйлынганча[5], тәртипсезлек һәм теләсә нәрсә укытып кызларның гомерләрен исраф итүләр бетеп, укыту юлы бераз тәртипкә салынса кирәк. Кызларымызны укыту, аларны адәм рәтенә кертергә тырышу ниһаfive дәрәҗәдә мөһим булганга күрә, бу хакта башлап йөрүче «Ханымнар җәмгыятенә», хосусән, рәисәсе Мәрьям ханым белән Фатыйма Алкина җәнабләренә тәшәккер итәрлектер[6]. Русиядә башлап кызларга бу кадәре зур мәдрәсә сала башлау һәм аларның укуларын тәртипкә салу өчен программ тәртип кыйлу мөнәсәбәте белән бу мәкаләмне

[1] Тәгаллекы – бәйләнеше.

[2] Мәзкүр – әйтеп үтелгән.

[3] Һәйәт – комиссия, комитет.

[4] Ибтидаи – башлангыч.

[5] Зикер кыйлынганча – әйтеп үтелгәнчә.

[6] Тәшәккер итәрлек – рәхмәт белдерерлек.

шатлык белән язып, «Йолдыз» укучыларына гарыз итүне[1] тиешле күрдем. Бу эшләрне башка җирдәге мөселман һәм мөслимәләр дә үрнәк итсәләр, яхшы булыр иде.

*Беренче тапкыр «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 6 октябрь санында басылган.*

---

[1] Гарыз итү – җиткерү.

## Авыл халыклары өчен файдалы китаплар вә земстволар

Авыл халкы арасына гыйлем вә мәгариф тарату өчен иң беренче васита[1] мәктәп-мәдрәсәләр булып, моннан соңра да аларның тормышларыны яхшылатыр вә рәтләр өчен таратылган гәзитә-журналлар һәм дә файдалы китаплардыр.

Ушбу мәзкүр[2] нәрсәләр авыл халыклары арасында ничаклы тәгълим ителсә, файдалы рисаләләр[3] ничаклы таралса, аларның шул нисбәттә күзләре ачылып, үзләренең тормышларыны яхшылатырлар, уң вә сулны аерып, дөньяда рәхәт вә иркенлектә көн күрерләр.

Мәктәп мәсьәләсене бер якка куеп торып, авыл халыклары арасында таралыр вә укылыр өчен аларга нинди китаплар файдалырак булуы хакында бераз язып китүне тиешле күрдем.

Рисалә исемене алган һәрбер китап авыл халыклары өчен бер дәрәҗәдә файда китерә алмаслар. Бәгъзе бер нәрсә хакында язылган рисаләләрдән, тирән нәрсәләрдән бәхәс кыйлган китаплардан мәхсус бер генә сыйныф файдалана алыр.

Гомумән, авыл халыклары өчен файдалы булган рисалә вә китаплар – аларның тормыш вә хәрәкәтләренә якыннан тәгаллекъ иткән, тугърысы, аларның үзләренең тормышлары хакында, кәсепләре тугърысында язылганнарыдыр. Игенчелек, умартачылык, бакчачылык, мал асрау, аларны үрчетү, нәселләрен яхшылату, үзләренең сәламәтлекләрен саклау, малларыны төрле авырулардан саклау хакында язылган рисалә вә китаплар авыл кешеләре өчен иң файдалы рисаләләрдән булырга тиешле дип беләм. Ләкин безнең авыл халыклары арасында бу хакта

[1] Васита – чара.

[2] Мәзкүр – күрсәтелгән.

[3] Рисалә – кечкенә китап, брошюра.

рисаләләр кирәк кадәр тарала алмый. Мондый җитди тормышымызны үгрәтә торган рисаләләр урынына хыялый әкиятләр, вак-төяк нәрсәләр тулып беткән. Әле һаман халык шундый үзләренең тормышларына бер тинлек тә файдасы булмаган хыялый нәрсәләрдән, Хәзрәте Гали, Салсал сугышларыннан котыла алмый. Китап вә рисалә шулар рәвешле булырга тиешле дип игътикад кыйладыр.

Шуның өчен безнең татарларның берәрсенең кулына сельский хозяйство хакында язылган берәр рисалә тугъры килә калса, ул аны юньләп игътибарга да алмый, дөнья хакындагы нәрсәләрне без укымасак та беләмез, безгә теге дөнья хакындагы китап булсын, дип, рисаләне бер якка ыргытып кына ташлый. Дикъкать белән уку, үзенең кәсеп вә тормышыны шул хакта язылган фикер вә тәгълиматка татбикъ кыйлырга[1] иҗтиһад кыйлу, шулай итеп, тормыш юлларыны яхшылатырга тырышу хәтерләренә дә кереп чыкмый. Ул үзенең әллә кайчаннан калган, череп эштән чыгып беткән юлы белән баруны ирлек вә егетлек саный. Шул кирелеге аркасында дөньяда рәхәт яши дә алмыйдыр.

Авыл тормышы хакында язылган китапларның файдалы икәнендә шөбһә дә юк. Шуның өчен бөтен земстволар үзләренең губерналарындагы халык арасына бу хакта язылган рисаләләрне әллә никадәре буш тараталар. Моның өчен ничаклы зур сумалар тәгаен итеп, ушбу юл белән халыкның тормышыны яхшылатырга иҗтиһад кыйлалар. Земстволарның мондый файдалы иҗтиһадларыннан, мәгаттәәссеф[2], безнең халык һичбер файда күрә алмый. Безнең халыкка бары күңел юата торган вак-төяк нәрсә булсын.

Безнең халыкның мондый китапларга ни күз белән караганын, бу китапларның безнең халык арасына тарала алмаганын белдерү өчен түбәндәге хисапны язам.

Уфа губернский земствосы, мөселманнар арасына сельский хозяйство хакында язылган китапларны тарату

[1] Татбикъ кыйлырга – яраштырырга.

[2] Мәгаттәәссеф – үкенечкә каршы.

өчен, башлап 1897 елда 150 сум акча тәгаен кыйлган. Башлап умартачылык хакында бер рисалә бастырып тараткан-нар. Шул елдан соң һәр елда татарча китаплар бастырып тарату өчен акча бирә барганнар. Мондый китапларны тарату өчен ундүрт ел эчендә 5450 сум акча бирелгән. Ләкин, бердән, бастырып таратырга рәтле файдалы китап килмәгәнлектән, икенчедән, нәшер ителгән китапларны укучылар гаять аз булганлыктан, бу акчаларның күбесе, матбугат юлына кереп бетми, шул көенчә калган.

Шул ундүрт ел эчендә бары 1663 сум гына китап тарату юлына сарыф кыйлынып, 3879 сум 68 тине тотылмый калган.

Земство «татарлар мондый китапларны кирәксенәләрме, бастырып тараткан китапларны укыйлармы, башка шундый китаплар кирәкме?» икәнен беләсе килеп, шул ният белән 1904 елда 3 ноябрьдә түбәндә мәзкүр биш сөальне язып, Уфа өязендәге муллаларга таратып җавап язуларыны үтенгән:

1) татарлар земство тарафыннан буш таратылган китапларны укыйлармы?

2) сезнең авылда күпме кеше укыды?

3) укыган вакытта аңлай алалармы?

4) башка нәрсә хакында язылган файдалы китаплар кирәк түгелме?

5) нәрсә хакында язылган китапларны укырга яратасыз?

Ушбу биш сөальгә булганы унбиш кенә имам җавап язып, үзләренең фикерләренә бәян кыйлганнар.

Бу җавапларны дикъкать белән карасаң, бу китапларның ни өчен нәшер кыйлынганлыкларыннан да хәбәрләре юк икәне бик ачык күренеп тора.

Имамнарның әксәре буш таратылган китаплардан гаять куркып, моны дини мәсьәләгә тәгаллекъ иткән рәвешле фарыз кыйлып: «Безгә моннан соң мондый ки-

таплар җибәрелмәсә иде»,– дип, дини бер вазифаны әда кыйлган[1] төсле җавап биргәннәр.

Унбиш хәзрәттән бары ике генә хәзрәт, мондый китапларны кирәксенеп, күбрәк бастыруны үтенгәннәр. Бу ике хәзрәт үзләренең мәхәлләсендә земство тараткан китапларны илле кеше укыганлыктан хәбәр биргәннәр. Калган унөч хәзрәтнең биргән җаваплары һәммәсе дә бертөсле дип әйтерлек.

Мисал өчен бер генә хәзрәтнең җавабыны язып үтәем. Бу хәзрәт болай дип җавап бирә:

1) Бездә бу китапларны укучы юк.

2) Укыган кешене күрмәдем.

3) ...

4) Безгә мондый китаплар кирәк түгел.

5) Дини китапларны укырга яратамыз. Вәссәлам.

Бу әфәнде үз күңеленнән, шаять, буш таратылган китапта берәр хикмәт булыр, ахыры начар нәрсәләргә сәбәп булыр дип уйлагандыр.

Хосусән, борынгы вакытларда, «Ахрызаман» белән «Бәдәвам»нарны җыялар икән, дигән хәбәрләр чыгып, халык шау-шу килгән иде. Шул хәбәрләр өстенә, мондый дөньяви сурәтле китаплар да буш таратыла башлагач, бигрәк курыкканнар булса кирәк, һәр нә исә, бу эшләр моннан ун еллар чамасы мокаддәм, халкымызның бигрәк тә аңсыз вакытында булган эшләр.

Бу көндә татар халкы ул көндәге төсле бик үк аңсыз түгел. Укырга, белергә әһәмият бирә башлаган. Шулай да сельский хозяйство хакындагы китаплар халкымыз арасында кирәк кадәр укылмый. Авыл халыклары өчен иң мөһим булган бу рисаләләрнең әһәмияте тәкъдир кыйлынмавы бик яхшы эш түгел. Мәгыйшәтемезгә һәм дә ул хакта язылган әсәрләргә җитди вә чын күз белән карарга вакыт дип беләм.

Аннан соң мондый рисаләләр күбрәк земстволар тарафыннан буш таратылалар. Земстволарның ни өчен тәэсис

[1] Әда кыйлган – үтәгән.

кыйлынганын[1] белгән кешегә буш таратылган китаплардан куркып, «монда берәр хәйлә булмасын» дип торырга да урын юк. Шатлана-шатлана укырга гына кирәк.

Халык рәгъбәт белән[2] укып файдалана башласа, мондый китапларны, шөбһәсез, земство күбрәк бастырып таратачак. Бу юлга тәгаен кыйлынган сума да елдан-ел артачактыр. Сатып алып укыган сурәттә дә, мондый рисаләләр авыл халыклары өчен башка нинди генә китаптан булса да файдалырак дип беләм. Мәгыйшәтемезне яңа тормышка татбикъ кыйлырга вакыт җиткән икәнен белергә тиешле һәм лязем дип уйлыймын.

*«Йолдыз» газетасының*
*1912 елгы 24 январь санында басылган.*

---

[1] Тәэсис кыйлынган – төзелгән.

[2] Рәгъбәт белән – кызыксынып.

## Госманлы төрекләрнең әдәбиятларында кафияләр

Гомумән, безнең төрек әкъвамының[1] шигырь һәм җырларында кафия[2] бик зур урын тота. Ләкин монда махсус кагыйдәләргә ригая кылуда башкалыклар булып, болар соңыннан зекер ителерләр. Хәтта болардагы шигырьләр һәм җырларның кафияләре мәгълүм шартларга туры килмәс, ул шигырь һәм назымнар мәгънә җәһәтеннән бик гали булсалар да, шигырьдән саналмаган кебек булып хисапланалар.

Кафия мисрагъларының соңгы сүзләре, сирәк истисна белән, соңгы сүзләреннән әүвәлге сүзләр бер вәзендәге сүзләрдән гыйбарәт булып, сүз һәм мәгънә ягыннан, яки мәгънә ягыннан, яки ялгыз сүз ягыннан башка булып киләләр:

Мисаллар:

| | |
|---|---|
| 1 – Әя дәүләт сараеның сөрирендә улан мәсрүр,<br>Сәгадәт таҗы башыңнан һәмишә улмасын мәһҗур.<br><br>Нәсыйхәт дыңламас дил сәхте мәхбүб.<br>Күгәрмәс ташка ягмур ягса һәм күп. | Сүз һәм мәгънә ягыннан башкалар.<br><br><br><br>Бу да шулай. |
| 2 – Сүзеңле даима рәтбеллисанем<br>Сүзеңнән калмасын хали зебанем. | Сүз җәһәтеннән башка булып, мәгънә җәһәтеннән бер. |
| 3 – Вармы бер җариядә буйлә бәһа,<br>Мөмкин улмаз боңа тәкъдир бәһа. | Сүз җәһәтеннән бер булып, мәгънә җәһәтеннән башкалар. |

Кафия кайвакытта иң (...) сүздән алдынгы сүздә яки иң ахырдан караганда өченче сүздә дә була, мисал:

[1] Төрек әкъвамы – төрки кавем.

[2] Кафия – рифма.

*1 — Ул пәринең санки гакыс итмеш хияли дагларе,*
*Агладым, аһ әйләдем, бакдым шу хади дагларә.*
*2 — Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер, белмәдем,*
*Үтте гомрем, барчасы хосран икәндер, белмәдем.*

Шәрык төрекләрендә шигырь һәм назымнар кафия игътибары белән мәснәви, мөрәббәгъ, мөхәммәс, мөсәддәсләргә вә аннан артык кафияләргә бина кылынып киләләр. Мәснәви – һәр ике мисрагь бер төрле кафиядә була, мисалы:

*Сәна ли-Халик[1], габед вә әмляк[2],*
* Яратты котрыдан[3] гәүһәр[4] пакь.*

*Имкян[5] мөсәгыйд[6] улмады тәгъдил[7] хәсрәтә,*
*Һәб күзләрең[8] күренмәдәдер хәшәм[9] хәятка[10].*
*Шәҗәгать[11]гарыз[12] идәркен мәрд[13]кобти сирхатен[14] сөйләр,*
*Табибың улса да, кәзебе маризың[15] сыйххатен[16] сөйләр.*

«Сөбател гаҗизин» вә башка кайбер әсәрләр бөтенләй шушы юл белән язылганнар.

Мөрәббәгъ өчен мисал:

---

[1] Сәна ли-Халик – Аллаһыга мактаулар.
[2] Габед вә әмляк – кол (бәндә) һәм фәрештәләр.
[3] Котрыдан – тамчыдан.
[4] Гәүһәр – монда: «кеше» мәгънәсендә.
[5] Имкян – мөмкинлек; мөмкин булу.
[6] Мөсәгыйд – ярдәм итүче.
[7] Тәгъдил – гадел хәл итү; гаделлекне кайтару; йомшарту.
[8] Һәб күзләрең – бөтен күзләрең.
[9] Хәшәм – олылык; бөеклек.
[10] Хәятка – тормышка.
[11] Шәҗәгать – кыюлык.
[12] Гарыз – тәкъдим итү; алга китереп кую.
[13] Мәрд – кеше; ир; егет.
[14] Сирхатен – авыруын.
[15] Мариз – авыру кеше.
[16] Сыйххатен – исәнлеген; саулыгын.

*Адемдә нә пирая нә (...) истәр*
*Махлук идеке суратә истәр,*
*Би файдадыр зиннәт вара ишләр,*
*Бак айя я софут җәүһәр эстәр.*

Икенче мисал:

*Алыр ләззәт у безләрдән зиядә*[1] *аб җаридән*[2]*,*
*Нәсим гяһ*[3] *пәймандан*[4] *мөсәхабәдән*[5] *сыхар идән,*
*Ләтәифдән*[6] *нә күрдисә белеп алтаф*[7] *идән,*
*Рөхт өстендә бер дик кош тәгдад итәр*[8] *бер кош.*

Мөхәммәскә мисал:

*Табки гареш*[9] *чыка аһ дил*[10] *нашадым,*
*Көннәре агъләдән*[11] *хәсрәтлә кыйдвә фәрьядым*[12]*.*
*Ничә бер җанны якка налә*[13] *атәш*[14] *задәм*[15]*,*
*Мөстәгыд кыл*[16]*, югыйсә лотфыңлә истигдадым*[17]*,*
*Сиңа... вар, и шаһ кәрәм мөстадам*[18]*.*

---

[1] Зиядә – бик тә.

[2] Аб җаридән – агым судан.

[3] Гяһ – кайчак.

[4] Пәйман – вәгъдә.

[5] Мөсахәбәдән – сәхәбәдән.

[6] Ләтәифдән – гүзәллекләрдән; мәрхәмәтләрдән; киң күңеллелекләрдән.

[7] Алтаф – иң гүзәл; иң мәрхәмәтле; иң киң күңелле.

[8] Тәгдад итәр – күп мәртәбә санар.

[9] Гареш – тәхет.

[10] Дил – күңел; йөрәк; акыл.

[11] Агъләдән – югарыдан.

[12] Кыйдвә фәрьядым – алдымдагы ярдәм сорап кычкыруым.

[13] Налә – ыңгырашу; елау; үксү; үксеп елау.

[14] Атәш – ут; ялкын.

[15] Задәм – ир балам; патша улым.

[16] Мөстәгыйд кыл – әзер бул.

[17] Истигъдадым – сәләтлелегем, булдыклылыгым; зирәклегем; үткенлегем.

[18] Мөстәдам – дәвамлы; мәңгелек.

Мөсәддәс һәм башкаларның мисаллары китерелмәде. Төрек әдәбиятында, бигрәк тә борынгырак әдәбиятларда кафияләр хәреф аслига[1] бина кылыналар. Болар хәрфе аслиның да кафиядә бер төрле булуын шарт иткән кеби йөртәләр: мәсәлән, боларча беренче мисрагда «җуя» сүзе, икенче мисрагда «зиба» сүзе килсә, бу шигырь кафиясез язылган шигырьдән саналып йөртелә.

Боларның бу кагыйдәләренә караганда Тукайның:

*Фәкыйрь калдым хәзер, тормыш үзенең биргәнен алды,*
*Күңел буш, анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы.*
*Гомер итмәк – тырышмактыр ялыкмый һич тә ял итми,*
*Гаталәт хурлыгын асла үзенә ихтыяр итми,* –

шигыре кафиясез санала.

Әйтелүләре бер төрле булып та, хәреф руй[2]лары башка-башка булган сүзләр белән тәмам ителгән кафияле шигырьләр бездә һәм кыргыз-казакъ назымнарында бик күп һәм еш очрыйлар.

Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| 1 – Бакырганнан сәфәр итсәм таваф кылгали кәгъбәне,<br>Барып рәкене йөз сөрсәәм өя хәннани меннани. | Иске Чыгтай әдәбиятыннан |
| 2 – Үзенең ходай биргән дәүләте күп,<br>Кырык угыл, кырык кызы бар – күңле тук.<br>Алытты ялгыз үзе тукыз хатын,<br>Ил сездә җата дигән ваем жук. | Казакъ |
| 3 – Кодыгына карай гына каугамыз бар,<br>Мәҗлесенә карай гына гаугабыз бар.<br>Эрбет менән Мәкәрҗәгә чама кайда,<br>Базарына карай гына сәүдәбез бар. | |

Шуның белән төрек һәм гарәп шигырьләрендә:

---

[1] Асли – асыл.

[2] Ру – кыяфәте, сурәте, рәвеше.

| | | |
|---|---|---|
| | Маил<br>Кабил | Тәэсис |
| Һәм рагыйб важиб | Кафиян мөәссә, | |

кебек сүзләргә тәмам булган шигырьләр, кафияле шигырьләрдән саналып йөртеләләр:

Төрекчә моңа мисал:

*Бәни зекер итмәз ил инсанә мәҗнүне маилдер,*
*Нә биузәр ул бәңа дәрди, аның дәрмани кабилдер.*

Гарәпчә: Мөтәнәббинең Сәйфеддәүлине мактаган гаять озын касыйдәсендәге шигырьләреннән:

خَليلَيّ إنّي لا أرَى غيرَ شاعِرٍ
فَلِمْ منهُمُ الدّعوَى ومني القَصائِدُ
فَلا تَعْجَبَا إنّ السّيُوفَ كَثيرَةٌ
وَلكِنّ سَيفَ الدّوْلَةِ اليَوْمَ واحِد[1]
بذا قضَتِ الأيّامُ ما بَينَ أهْلِهَا،
مَصائِبُ قَوْمٍ عِندَ قَوْمٍ فَوَائِدُ

Гарәп шигырьләренең кафияләренә килсәк, боларда кафиягә соң дәрәҗәдә әһәмият бирелгәнен һәм кафияләр хакында аерым-аерым кагыйдәләр куелганын күрәбез.

Аларның шигырьләрендә: дөнья; хәбибән[2]; кадимән[3] яки кәгъби[4]; әләфи[5]; сәхаб[6]; кәсад[7] кеби әйтелү һәм ишетелүләре бер төрле була торып та, икенче төрле хәрефләргә беткән кафияләргә һичбер очрап булмый. Мәсәлән, дүртбиш йөз юлдан гыйбарәт булып, бер кафиягә тәәсис ителгән шигырьләр һаман бер төсле хәрефкә тәмам булалар, (Касыйдәи Бердә, Мөгаллкат Сәгбә һәм ибн Тәлмамларның озын касыйдәләре кебек).

[1] Сүзгә-сүз тәрҗемә: «И дустым, Мин «шагыйрьләр» дип кыланучыларга охшамаган, мин – чын шагыйрь, касыйдәләр тезүче шагыйрь».

[2] Хәбибән – сөеклем (төшем килешендә).

[3] Кадимән – иске (төшем килешендә).

[4] Кәгъби – куб; кубик.

[5] Әләфи – мең.

[6] Сәхаб – болыт.

[7] Кәсад – торгынлык; тоткарлык; сүлпәнлек.

Шуның белән бергә, әүвәлге мисрагның кафиясе «Шиһап», икенчедә «җавап», өченчедә «гарәп» кебек булулар мәкъбул саналалар.

كَمْ أبْرَأَتْ وَصِبا باللَّمْسِ راحَتهُ
وأَطْلَقَتْ أرِباً مِنْ رِبْقَةِ اللَّمَمِ[1]

Мөтәнәбби шигырьләреннән мисал:

وما التأنيثُ لاسمِ الشّمسِ. عَيبٌ ولا التّذكيرُ فَخْرٌ للهِلالِ[2]

Фарсы шигырьләренә килсәк:

می خردن و شاد بودن آیین منست؛
فارغ بودن ز کفر و دین؛ دین منست؛
گفتم به عروس دهر: کابین چیست؟
گفتا: – دل خرم تو کابین منست

Болар да кафия кагыйдәләрендә гарәп кагыйдәләренә ияргән, я булмаса үзләреннән моңа гаять әһәмият биреп, шигырьләрдә кафияләрнең ригая ителүен шарт иткән кебек күренәләр. Мисал өчен Гомәр әл-Хәйямнең робагыйсын алыйк:

چون هشیارم طرب ز من پنهان است
و مست شوم در خردم نقصان است
حالیست میان مستی و هشیاری
من بنده ی آن که زندگانی آن است

حمد بی حد آن خدای پاک را
آنکه ایمان داد مشتی خاک را

Шушы Шәех Гаттар тарафыннан язылган озын вәгазь китабы башыннан ахырына чаклы шул кагыйдәне ригая итеп килгән.

---

[1] Әлеге юлларның авторы атаклы гарәп шагыйре Имам Бусайри (1212–1296), «Бурда» касыйдәсе авторы, бу икеюллыкта Мөхәммәд пәйгамбәрнең сыйфатларын мактап яза: «Әгәр дә ул (Мөхәммәд пәйгамбәр) үз кулы белән кемгә дә булса кагылса, аны [кайгы һәм начар фикерләрдән] дәвалаган, аның белән аралашу кешеләрне гөнаһлардан азат иткән».

[2] «Ай» сүзенең ир җенесендә булуның горурлыгы, «кояш» сүзенең хатын-кыз җенесендә булуның ояты юк». Ягъни ир-ат малай булып туганы өчен генә үз-үзе белән горурланырга тиеш түгел.

Бу сөйләгән сүзләрдән нәтиҗә шул ки, гарәп, фарсы һәм алар әдәбияты уртасында туган госманлы төрекләрендә кафиягә ригая итү һәм моңа махсус кагыйдәләр төзеп, шигырьләрнең ахырларын аһәңле һәм ишетелгәндә матур ишетелү юлларын тоту бик зур урын тоткан кебек күренә.

Безнең чыгътай, казакъ-кыргыз һәм татар-башкортларда шигырь һәм назымнарның ахырларын кафиягә тәэсис итеп, бер төрле ишетелгән сүзләргә бетерү шарт кебек ителеп йөртелсә дә, моның өчен махсус кагыйдәләр юк. Шуңа күрә бу телләрдә язылган назымнарда кафияләр бер кагыйдә астына алынмый, иркен рәвештә истигъмал ителә бирәләр.

Мәсәлән, бездә әүвәлге мисрагъның кафиясе «дөньяга» дип бетә икән, икенче мисрагъны – «аллага», өченчесен «алдама» дип бетерү бер дә мәкруһ һәм ят, кагыйдәсезлектән хисап ителми.

Кыргызча мисал:

*Сайрайды былбыл кус кунып тал-га,*
*Мактаулы былбыл кус барча җан-га.Урмандың эчендә сылу былбыл*
*Сайраганда, барча кус калыр таң-га.*

Татарча:

*Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,*
*Боты озын-га күрә.*
*Шул матурны бик сөямен*
*Бите кызыл-га күрә.*

Тукай шигыре:

*Валлаһи, җандай күрәм мин искеләрнең җырларын,*
*Күкрәгемдә саклыйм, әйтерсең, рәсүлнең тырнагын.*

Гарәп, фарсы телләрендә мондай нечкәлекләргә игътибар итү аларның телләре байлыгыннан булса кирәк. Шул ике бай телдән бик күп бурыч алган госманлылар да шигырьләрендәге кафияләрдә аларга ияргәннәр, моның өчен кагыйдәләр төзегәннәрдер, дип уйлыйм.

Сүз ахырында бездәге шигырь һәм манзумнарның ничә мисрагълы булып, шул мисрагъларның кайсыларында кафиягә әһәмият бирелүен әйтеп узарга ярый.

Бездә халык җырлары дип аталып йөргән җыр һәм бәетләр галибан кыска яки озынрак дүртәр мисрагътан гыйбарәт булып, боларның әүвәлге ике юлы белән соңгы юлында кафия була:

*1 – Алып бирим ак таббас илә ахри*
*2 – Су буенда сусар күп илә ахри.*

Озын көйгә:

*Агыйделкәйләрне ай кичкәндә –*
*Бер җырладым ишкәк ишкәндә.*
*Бер җырламак түгел, ун җырларсың –*
*Үткән гомерең искә төшкәндә.*

Борынгы язылган манзум әсәрләрнең кайберәүләре («Йосыф», «Ахырзаман вә бәдавам», «Кызыл алма» кебекләр) дүрт мисрагълы булып та, әүвәлге өч мисрагъларында кафиягә игътибар ителә:

*Белегез алла берлеген, ислам дине хаклыгын,*
*Әхмәт пигамбәрлеген, алла дигел бәдавам.*
*Замана ахри булса нәләр булгай,*
*Дөньяга төрле-төрле фитнә тулгай,*
*Галимнәр чагыр эчеп, зина кылгай,*
*Аннан артык тәкыйгаҗәп тыңлары вар.*

Мондагы назымнарның соңгы мисрагы галиба булып, бер төрле мисрагъларны тәкрарлаудан гыйбарәт була.

Кыргыз-казакъларда назымнар галибән дүрт мисрагълы булып, кафияләре беренче, икенче һәм дүртенче юлларда булалар.

Шуларга тәкълид итеп язган Акмулланың да бик күп шигырьләре дүрт мисрагъ белән язылганнар:

*Казаннан бер фазил[1] чыкты алмас булып, хасидләре[2] күбәйде гам[3] хас[4] булып,*

---

[1] Фазил – өстен, намуслы, галим кешегә карата кулланыла торган эпитет.

[2] Хасид – көнче, көнләшүче.

[3] Гам – кайгы, хәсрәт, борчу.

[4] Хас – сизүче, тоючы.

*Мәгани*[1] *җәваһирен*[2] *кулга алган хәкаикъ*[3]
*диңгезендә гаувас*[4] *булып,* –
шикелле.

Башкортларда да шулай дүрт мисрагълы назымнар мәкъбул булып йөртелә.

Соңгы сүз уларак шуны әйтергә кирәк була:

Бездә, бигрәк тә соңгы вакытларда, кафия белән язабыз дип, шигырьнең вәзененә һәм мәгънәгә зарар китерерлек рәвештә булган назымнар язалар. Хәтта кафиясез нәрсә бөтенләй шигырь булмый дигән уйга кереп, кафия китерергә көчләнәләр, мәгънәнең матур булуын уйлаудан бигрәк тә, кафия эзләп баш ваталар. Шуның белән бергә, кафия хакында һичбер мәгълүм кагыйдәләр куелмаганлыктан, бик күп ямьсезлекләр чыгаралар, кафиягә килерлек сүзләр бездә бик санлы булганлыктан, мисрагъларны төзегәндә һәм мәгънә бирергә теләгәндә, кафиягә туры килгән бер сүзгә карап, бөтен мисрагъның, хәтта берничә юллы назымның мәгънәләрен бозып, кафиядә килгән сүзгә туры китерергә тырышалар.

Шуның өчен дә кафияләрне тикшереп, бу хакта кайбер фикерләр йөртелсә, бик урынлы булыр иде.

*1915–1920 еллар булырга тиеш*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 12 эш*

[1] Мәгани – мәгънәнең.
[2] Җәваһир – җәүһәрнең.
[3] Хәкаикъ – хәкыйкатьнең.
[4] Гаувас – су төбеннән әйберләр чыгаручы, водолаз.

## Бер-ике сүз

Киләчәктә ни буласы һичкемгә мәгълүм түгел. Алдагы гомернең якты яки караңгы булуы да – бик томанлы нәрсә... Шуларны уйлаганнан соң күп вакытта үткән хәяткә күз әйләндереп карарга тугры килә. Һәркемнең үткән хәяте, шушы хәятендә кылган гамәлләре бар. Шушы кыска хәяттә эшләнгән эшләр, салынган сукмаклар кызыл җеп кебек булып күз алдында сызылып яталар. Шул сызыктагы төенләрнең кайберләрен уйлап ләззәт алган вакытлар булган кебек, кайберләрен уйлаганда хәсрәтләнгән вакытлар да була. Бу эш һәркемдә шулай була торганмыдыр – бу эшен тикшерү минем эшем түгел.

Мин монда үземнең шул үткән хәятемдә эшләгән эшләрем – шулар җөмләсеннән язган язуларым хакында бер-ике сүз әйтеп китмәкче булам. Минем шактый яшь вакытымда, моннан егерме еллар элек, бер заманнан бирле язып килгән нәрсәләрем бар иде. Үткән хәятемә әйләнеп караган вакытта, боларның һәммәсе дип әйтерлек рәвешдә күз алдыма киләләр. Боларның һәрберсе шул хәятнең шатлыклы яки зәһәрле бер тәэсире белән язылганнар. Шигырь һәм нәсердән гыйбарәт булган шул нәрсәләрнең бәгъзе бер вакытлар сәбәпле тәләф[1] булганнары булган кебек, төрле манигълар[2] сәбәпле бу көнгә чаклы матбугат дөньясына чыкмаганнары да байтак җыелган икән. Мәҗмуга яки хикәя рәвешендә төрле вакытта төрле кулда нәшер ителгәннәренең дә басылганнары бөтенләй беткән икән. Болардан кайберәүләренең нөсхәләрен бер данәсен табуы да кыен.

Яхшымы-начармы булган шул әсәрләремне үзем исән чакта, тәләф булып, югалып (бу ике сүзне бу көнгә кадәре

[1] Тәләф – әрәм-шәрәм итү, бетерү, бозу.

[2] Манигълар – киртәләр.

басылмаган нәрсәләрем хакында әйтәм) бетмәс борын, язылган тарихлары белән бер рәттә тезеп, бер җиргә җыеп кую күптән уйлаган уемның берсе иде. Ләкин бу эш һаман исәптә генә йөреп, бу көнгә чаклы гамәлгә куелмый торды.

Менә шул исәбемне чынлап та гамәлгә куярга бер-ике гамил[1] сәбәп булды. Боларның берсе – алдагы гомернең тагы күп кенә сузыла алуына шөбһә белән карау булып, икенчесе дә – бәгъзе бер[2] таныш вә иптәшләрнең, хосусан әдәбият белән мәшгуль кешеләрнең, шулар җөмләсеннән милли мәктәпләребездә әдәбият дәресе, татар телен укытучы мөгаллимнәрнең, мәҗмуга-и әсәремне бер җиргә җыеп бастыру мәтлуб[3] икәне үземә берничә кат әйтүләре булды. Шушы ике сәбәп өстенә, халкыбызның да укуга бирелгән кыйсменең[4] бер өлешенең шуны кирәксенгән сымак хәрәкәт итүләре кушылды.

Югарыда әйтелгән сәбәпләрне игътибарга алып, үземнең язган нәрсәләремне шигырь вә нәсердән гыйбарәт ике кыйсемгә бүлеп җыйдым. Шигырь кыйсеме (беренче җилд[5]): 1) «Җитди шигырьләр»; 2) «Мәхәббәт»; 3) «Мәсәлләр»; 4) «Балалар өчен язылган шигырьләр»; 5) «Поэмалар» исемендә биш бүлемгә бүленде.

Бу бүлемгә кергән шигырь вә нәзыймләрнең[6] төзелү тәртибендә язылу тарихлары мөмкин кадәре ригая ителде[7]. Ягъни кайсы шигырьнең язылу тарихы элек булган булса, шул башка языла килде. «Нәсер» кыйсемендә иң элек вак мәкаләләрне яздым, соңыннан озынрак хикәяләр куелды. Боларда да язылу тарихлары ригая кылынды. Шигырьләрне җыйган вакытта үземне җимеш җыйган кешегә

[1] Гамил – биредә: этәргеч, фактор.

[2] Бәгъзе бер – кайбер.

[3] Мәтлуб – таләп ителгән.

[4] Кыйсменең – бүлекнең, өлешнең.

[5] Җилд – том.

[6] Нәзыйм – шигырь, поэзия.

[7] Ригая ителде – каралды.

охшаттым. Җимеш җыйганда җимешнең пешкәннәре кулга эләккән кебек, чи һәм пешмәгәннәре дә кулга эләгеп савытка төшә. Монда да шулайрак булды. Яшь вакытларымда язылган бәгъзе бер нәзыймләрне, үзем артык ярап бетмәгәннәрен дә калдырмадым. Тугърысын әйткәндә, хәзинәмдә барын – шул көенчә халык алдына чыгарып салуны тиешле таптым. Нинди генә нәрсә булса да, үткән хәятнең бер тәэсире астында язылуында шөбһә юк, шулай булгач, аның бөтенләй югалмавы мәтлүб табылды.

Яхшы нәрсәләрне генә күрсәтергә тырышу – бу минем сөймәгән эшем. Башка әйтергә теләгән сүзем калмады бугай. Калганын бөтен мәҗмугам үзе күрсәтер. Калган сүзләрем булса, китапның ахырында әйтермен әле.

*1920 ел, 10 гыйнвар, Уфа*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 7 эш*

## «Себер тимер юлы» дигән әсәрем хакында берничә сүз

Татарстан Мәркәзе Гыйльми оешмасы карамагында «Татар әдәбияты тарихы» исеме астында мәҗмугалар басылырга карар бирелеп, шунда минем тарафтан язылган әйберләргә дә берничә табаклык урын бирелгән һәм шунда шушы беренче әсәрем булган «Себер тимер юлы»н кертергә булганнар икән.

«Себер тимер юлы»н язганнан соң күп сулар акты, фикерләр үзгәрде, күп алмашынулар булды: Россиядә яшәүче башка халыклар белән бергә, татарлар арасында да иҗтимагый, сәяси яктан зур үзгәрешләр ясалды. Шулай ук татарлар да, борынгы хорафатлардан бизеп, фән-белемгә омтылу арзусы[1] туып, халык – күпчелеге эшче, крестьян гаммәсе – йөзләрен гыйльми, мәдәни тормышка, техникага юнәлдерделәр. Хәзер, борынгы вакытта (моннан 25–30 еллар гына элек) күңелләрдә хыял урынында гына йөргән нәрсәләр гамәлгә чыга башлап, якты тормышка таба зур адымнар белән атлау дәвере килде. Хәзер инде моннан 25 еллар элек шул заманның хосусый тәэсире белән язылган «Себер тимер юлы» кебек күп әйберләр үзләренең кыйммәтләрен югалтып, тик тарихи һәм әдәби тикшеренүләргә материал булып кына калдылар. «Татар әдәбияты көтепханәсе»ндә, миңа бирелгән берничә табаклык мәҗмугага «Себер тимер юлы» кебек иң беренче язылган әсәремне кертүдә Гыйльми үзәк шул яктан карагандыр дип уйлап:

«Алай булса, ярый шул, татарның башлангыч әдәбият тарихын, аның үткәнен тикшерергә аз гына ярдәме яки файдасы тия торган булса, мәҗмуганың башына бу әйбер дә керсен инде...» – дим. Шуның белән бергә бу нәрсә-

[1] Арзу – теләк, омтылыш.

нең язылу тарихы һәм нинди тәэсир астында чыгарылуы хакында берничә генә сүз әйтеп китәсем килә.

Мин яшь чакта (16 яшьләрдә вакытта) Троицки шәһәрендәге мәдрәсәләрнең бик шәп икәнлекләрен ишетеп, шунда китәргә булдым. Кесәдә барлыгы 65 тиен генә акча булганлыктан, тимер юлы белән китәргә көч җитмәгәч, Урал таулары аша 500 чакрымлык юлны җәяү үтәргә туры килде. Юлда «Зигәзе – Шамов» һәм «Белорецкий» заводларын күреп үттем, боларның биек таулар уртасында, кара урманнар арасында һаваларга төтен чыгарып, кычкырып утырулары миңа бик нык тәэсир иттеләр. Бу минем заводларның трубаларыннан чыккан мәһабәт төтеннәрне беренче күрүем һәм аларның урманнарны, тауларны яңгыратып кычкыртуларын беренче рәт ишетүем иде.

Троицки шәһәре, андагы хәят, русларның уку йортлары, аларның татар һәм башкорт, кыргызларга караганда бөтенләй икенче тормыш белән торулары да аз тәэсир итмәде. Бу тәэсирләр миндә болар арасында, шул заманга күрә генә булса да, чагыштыру хисен тудырды:

Бер якта – ишан мәдрәсәсе (мин үзем шунда укый идем), андагы алты-җиде йөз укучылар җыелышы, мөритләр, зикер, тәсбихлар... Мондагы әйтеп, санап бетергесез ваклыклар...

Икенче якта – мәдәни хәят, гимназия, реальный училищелар, аларда укучыларның бөтенләй икенче төстә булулары...

Бу ике тормыш күңелгә ике төрле тәэсир итә һәм «бу ник болай?» дигәнсөальне бирдерә иде.

Троицкидә дүрт ел торганнан соң, туган илне, үскән авылны күрү арзусы туды. Миндә хәзер тимер юл белән кайтып килерлек акча бар иде. Мин Чиләбе аркылы, тимер юлының бер кисәге булган Самар-Золотоуст юлы белән кайтырга уйлап, Троицкидан Чиләбегә ат белән килдем.

Бу көнгә чаклы тимер юлын да, вагон һәм паровозларны да күргәнем юк иде. Шуңа күрә вагоннарны тизрәк

күрү өчен йөрәк ләп-ләп кага иде. Стансага килеп җиткәч, көлтер-көлтер төтеннәрне артка калдырып, пух-пух итеп кычкыруы белән дөньяны яңгыратып алга барган һәм артына безнең авылдагы өй зурлыгындагы кырык-илле вагон таккан паровозны күр! Әлбәттә, мине хәйран калдырды, йөрәгем калтырап китте. Аның дәһшәт һәм мәһабәт рәвештә баруын күреп, безнең атлар артка чигенделәр. Минем күземә бу атлар бик зәгыйфь һәм бик мескен булып күренәләр иде. Мин бу тимер юлларны, андагы кайнап торган тормышны, шул көчле машиналарны йөрткән һәм үзләре майланып беткән эшчеләрне күреп, гаҗәпләнү өстенә, үземне бик бәхетле санадым.

Без, күп юлчылар, ерак Себердән килеп, безне Урал таулары аша Уфа–Самара ягына алып китә торган поездны көтә идек.

– Килә! – диделәр. Чынлап та, поезд үзенең тимер юл буйлап мохит диңгезенә барып терәлгән җиреннән килгәнлеген белдерергә теләгән кебек кычкырып, салмак кына тын алып, безнең алга килеп туктады.

Шунда минем каушавымны, икенче төрле әйткәндә, шатлыгымны белсәгез! Халык дулкынланды. Поезд тиз генә китеп барыр да, без торып калырбыз төсле тоела иде. Кузгалып киттек. Тирә-яктагы нәрсәләр, агачлар артка авып калалар иде.

– Миңа да тимер юлын күрү, вагонга утыру насыйп булды бит,– дип шатланам.

Вагоннарның шәп барулары, тимер юлының Урал тавын ярып үтүе, тирә-якта күренеп калган мәһабәт заводлар, шуларга якын гына җимерелеп бетәргә торган кебек утырган мескен татар-башкорт авыллары,– һәммәсе-һәммәсе мәдәни хәят белән мәдәниятебез тормышыны, эш дөньясы белән эшсезлек дөньясын чагыштырырга сәбәп булдылар. Мин хәзер, бер яктан, мәдәният арбасына утырып баруыма шатланам, икенче яктан, һөнәрле халыклар белән һөнәрсез халыкларны чагыштырып кайгырып барам. Һәм ун мең чакрымларга сузылган бу тимер

юлны салуга киткән көчләрне, монда куелган гыйлемне уйлап хәйран калам. Шулай итеп, миңа беренче рәт тимер юлга утыру, аның да дөньядагы юлларның иң озыны булган Себер тимер юлы булуы бик нык тәэсир калдырды һәм шул тәэсир аркасында «Себер тимер юлы» мәнзумәсен[1] язып ташладым.

Хәзер инде тимер юлларга карап ис китүләр дә, хәйран калулар да һәм аның тәэсире белән генә халыкны мәдәни эш тормышына өндәп вәгазь әйтү дәверләре дә узган. Хәзер бөтенләй башка хәят, башка юл. Татарларның тормышлары да, тоткан юллары да, әдәбият ысуллары да үзгәрде. Борын язган бу нәрсәләр, югарыда әйткәнчә, иске тормыш, иске әдәбиятны (әйтергә яраса) өйрәнүгә материал булып кына калдылар. Менә шул яктан карап:

– Басылса да, зарар юк, чагыштыру өчен болар да кирәк булыр шул,– дидем. Һәм бер генә сүзен дә үзгәртми, тик имлясен үзгәртү белән канәгатьләнеп калдым.

*1926 ел, Уфа*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 1 эш, 111–113 б.*

[1] Мәнзумәсен – шигырен.

## Гармун тавышы

### *I*

Көзге төн булса да, көн аяз һәм, әле яктысы булганлыктан, караңгы түгел. Авыл киң басулар уртасында тын гына йоклап ята. Җиткән кызлар, аулак өйгә җыелып, кич утыралар. Мин кечкенә булгач, авырсынмадылар. Һәм артык яшереп сөләргә дә кирәк тапмадылар. Куллары эштә булса да, күңелләреннән әллә ниләр уйлап, телләре белән авыл җегетләренең исемнәрен тезәләр: «Салих – абау, шуның күзләре! Тычкан күзе кебек кечкенә... Әбтрәй малае бишмәтенең төймәләрен дә каптырып йөри белми!... Гыйззәт – бүреген кырын салып йөргән була!.. Вәлинең борыны озын, шуның борыныннан тартасы иде... Ә, соң Габдрәхим! Авызыннан сүзен алыр хәл юк...» Һәрбер җегетнең бер сыйфатын сөйләп көләләр, мыскыл итәләр. Ләкин эчләреннән аларны яратканлыклары күренеп тора. Мин көнләшеп куям. Шуның өстенә каюларын миннән яшерер өчен, сүзләрне бозып, мин белмәгән телдә сөйлиләр: «Вәснәле кечничә безнең өснурамдан өснетеб баснара. Ә өснүзе беснезгә таснаба каснари. Миснин көснөләм өснүл кыснызара...».

Мин дә зирәк малай бит – аларның яшерен сүзләрен аңлап алдым, ул кыз: «Вәли кичә безнең урамнан үтеп бара, әй үзе безгә таба карый! Мин көләм, ул кызара...» – димәкче була. Шундый сүзләрдән соң шаркылдашып көләләр. Берсе минем аңлаганымны белде, күрәсең: «Бөсне масналайның төснүбәсе тиснек мәллә?» – ди. Беләм мин, беләм: алар җегетләрне яраталар, ләкин миннән яшермәкче булалар. Ул кыз миннән шикләнеп: «Бу малайның түбәсе тишек мәллә?» – ди. Әйтерсең, аңласам, әтиләргә кайтып әйтәм.

## *II*

Ерактан гармун тавышы ишетелде. Кызларның төсләре үзгәреп китте. Шундук кулларындагы эшләрен ташлап, лампаны баса төшеп, тәрәзәгә ябырылдылар.

Кайда кызлар кич утырганны җегетләр сизәләр бит: алар бу турыга җиткәч йөрешләрен әкренәйтеп, гармунны киерә төшеп, тагын да дәртлерәк уйный башладылар. Берсе гармунга кушылып җырлап җибәрде:

*Таң әтәчләре кычкыра,*
*Әллә таң ата микән?*
*Тәрәзәдән карап кала,*
*Әллә ярата микән?*

Кызлар шатланып киттеләр. Берсе-берсен төртешеп, тәрәзәдән чыгардай булып карыйлар. Үзләре пәрәх-пәрәх көлешәләр.

– Салих гармун уйный, Сәлим җырлый,– диделәр.

Үзләре белеп торалар тагын...

## *III*

Гармун белән җыр тавышы ераклашкач кына, кызыл лампаны күтәреп, эшләрен кулларына алдылар. Ләкин алар тирән уйга чумганнар, моңга батканнар, хәзер җегетләрне мыскыл итеп көлмиләр иде. Аларның моңлары эчләренә сыеп тора алмады: Нәгыймә апа кубызын алды да кып-кызыл иреннәре арасына куеп, матур бармагы белән кубызның телен чиртә башлады. Фатыйма апа: «Урамнардан үткән ай үзе икән, кулларында яшел музыкан... Урамнардан үткән чакларында күрми үтеп ничек түзә икән?» – дип әкрен, ләкин бик моңлы иттереп җырлый башлады. Сәлимә авызына капкан оек энәсен дә онытып тыңларга кереште. Бу күренеш матур да, моңлы да, кызганыч та иде.

Яшь кызларның янып торган күңелләре тар читлектән чыгып ирек теләгәндер. Матур җыр һәм матур көйне якыннан тыңлап, иркен һавага чыгасылары килгәндер шул. (Хәзер шулай уйлыйм.)

## *IV*

Иртәгесен чәй эчкәндә, әти: «Бүген төнлә рәтләп йоклый да алмадым. Инде йокыга киттем дигәндә гармун белән җырлап үтеп, йокымны качырдылар. Үткән гомерләрем искә төшеп китте. Кем уйный соң анда?» – диде. Мин балалык сафлыгы белән: «Салих гармун уйнады. Сәлим җырлады» – дип әйткәнемне сизми дә калдым. Бу сүздән соң апа кызарып китте. Миңа күз кысып куйды. Әти шундук: «Син, малай, кайдан белдең? Әллә кызлар янына керделәрме?» – дип кыска гына сөаль[1] биреп, минем күзгә карады. Мин тәрәзәдән карап белгәнлегемне әйтеп, чак котылып калдым. «Кара син аларны, музыканны кайдан тапканнар да кайдан үрәнеп өлгергәннәрдер. Бу чактагы яшьләр таш астыннан табарлар агай!» – ди.

Музыка картларның да йокыларын качырган икән. Ә үзләре яшьләргә ачуланмакчы булалар, дип уйладым.

Шулай, матур, моңлы, дәртле тавышларны ишеткәндә яшьләр дә, картлар да әсәрләнми кала алмыйлар.

Кәккүк айларын, сандугач сайрый торган язны һәркем көтеп ала. Боларның тавышларын ишеткәндә арыган кешегә көч, күңелсез кешегә дәрт кереп китә. Ләкин сандугач сайраулары, кәккүк кычкырулары бик вакытлы. Адәм баласы музыканны кирәксенеп:

– Скрипка кылларының сызлануы белән йөрәк бергә сызлана.

– Мандолинаның кыллары селкенгәндә йөрәк бергә селкенә.

– Гармун белән йөрәк бергә тибә.

– Духовой оркестр уйнаганда аякларның басулары үзгәреп китә, – ди.

Музыканның тәэсире элек тә шулай иде, хәзер дә шулай. Мәңге шулай китәчәк.

---

[1] Сөаль – сорау.

## *V*

Шушы арада матбугатта «Ул яшьләр арасында гармун» дигән бер мәсьәлә кузгалды. «Яшь юксыл» гәзитендә бу хакта байтак язучыларның фикерләре басылды. Шуларны укыгач, мондан бик күп еллар элек, бәләкәй чакларда, гармун ишеткәндә яшьләрнең һәм картларның ни рәвешле әсәрләнүен күрүем искә төште.

– Бу мәсьәләне кузгату нигә кирәк икән? – дип әйтүчеләр булыр.

Җан азыгы булган музыкан хакында сүз кузгату – бик кирәк эш. Гармун – авылларга бик күптәннән кергән уен коралы. Ул, үзенең простойлыгы, уйнарга өйрәнергә җиңеллеге һәм башка уен коралларыннан арзанлыгы аркасында, авылларга таралып өлгергән. Тик ул – борынгы яшьләрнең картлардан, муллалардан куркып мунчаларда, печән асларында яшереп асралуы, караңгы төннәрдә урамнарда гына уйналуы аркасында, түргә менү хокукын ала алмый калган «батрак» булып килгән бер нәрсә. Карт байлар, муллалар сандыклы уен белән граммофонны өстәлләренә куеп уйнатсалар да, гармунга «шайтан коралы» исеме биреп, аны күргән бер җирдә ватып ташлаганнар.

Хәзер авылларда музыка кирәк. Мөмкин була икән, гармуны, скрипкасы, мандолины бергә булса да. Яшьләр буш вакытларында авыл халкына концерт бирерлек бер хәлгә килсеннәр.

Комсомоллар, аңлы яшьләр гармунда уйнау эшләрен башка эшләргә зарар итмәслек рәвештә тәртипкә кую, гармун һәм башка музыка коралларыннан файдалану юлларын билгеләү эшләрен үзләре карарга тиешлеләр.

Эш үз вакытында эшләнеп, музыка үз вакытында уйналса гына күңелле була ул. Шәһәрләрдә шулай куелган.

*«Яңа авыл» газетасының 1926 ел,*
*1 сентябрь санында басылган.*

## Казандагы «Яңалиф» нәшрият идарәсенә

«Яңалиф» нәшрияты, татар пролетариат язучылары турында бер альбом нәшер итмәкче булып, бу хакта пролетариат язучыларына, шулар рәтеннән миңа да мөрәҗәгать итеп, хат язган иде.

Сезнең шушы мөрәҗәгатегезне җавапсыз калдыруны уңайсыз табып, үземнең тәрҗемәи хәлем турында, кыскача гына булса да язып җибәрүне тиешле таптым.

Ярты гасырлык бер гомердә, тормышның төрле баскычларын атларга, бик күп эшләрне, төрле вакыйгаларны баштан үткәрергә туры килә. Өч-дүрт битлек тәрҗемәи хәлдә боларның һәммәсен дә баштан үткәнчә күрсәтеп үтү яки бөртекләп тасвир итү, әлбәттә, авыр. Аларны вакыт иркен, урын мул булган вакытта гына тиешенчә күрсәтеп була ала. Шуның өчен бу тәрҗемәи хәлне озын гына бер гомердәге вакыйгаләрнең кыскача бер фиһерсе урынында гына бирергә тиешле күрдем. Укучыларның да шулай итеп каршы алуларын көтәм.

*Мәҗит Гафури*

*1930 нчы ел, 10 нчы март. Уфа*

## Тәрҗемәи хәлемнән өземтәләр

### *I*

Сүзне туган елдан башламый туры килмәс, ахыры.

Митрикә дәфтәре минем 1880 елда туганымны күрсәтә. Мин кечкенә чакта әнием: «Син тары утавы вакытында тудың»,– ди торган иде. Шуңа караганда, мин 80 нче елны июнь числосында туган булсам кирәк.

Хәзерге көндә һәркем үзенең фәкыйрь гаиләнең кызганыч бер баласы булганын әйтергә ярата. Мин инде аны байлык белән мактана торган бер чорда да шулай язган булыр идем. Чынлап та, минем белгәнемнән безнең бер-ике атыбыз (сыерыбыз барлыгын хәтерләмим) бар иде, ләкин,

аларның берсен ат караклары алып киткәч, зур гына гаилә ялгыз атка карап калды. Ул вакытларда безнең гаилә тормышы бик авыр һәм өс-башларыбыз сәләмә булуын әле дә исемдә саклыйм.

Безнең өйдә арыш икмәге бик кадерле санала, чәй урынына күп вакыт юкә чәчкәсе яки мәтрүшкә эчелә, җәй көннәре итле аш урынына арыш чумары салган балтырган үрәсе ашала, аның да катыгы иркен тормышлы күршеләрдән алынган була иде. Шуларны искә алсам, хәзерге көндә анкета язганда «мин – ярлы крестьян баласы...» дип язсам, хаклыдырмын төсле булам.

Минем әни мәрхүм язу-сызу белми торган булса да, бик йомшак күңелле, матур табигатьле бер хатын иде.

Әти, яхшы гына төрки таныган кеше булып, кайбер елны авылның указлы мулласының рөхсәте яки кушуы буенча, авыл мәктәбендә вак балалар укыта иде.

Әти үзе «укыган» кеше булгач, мине надан калдырасы килмәгән, күрәсең: ул мине дүрт-биш яшькә җитү белән укытырга кереште. Аның миңа иҗек, «Һәфтияк» сүрәсе, «Бәдәвам», «Ахырзаман»... китапларын бик ихлас белән укытуын, кай вакыт «чикәгә утыртуларын» әле дә оныта алмыйм.

Җиде яшемдә авыл мәктәбенә сабакка йөри башладым. Мин инде 8–9 яшьләремдә төрки танып[1], гарәпчәгә дә төшкән идем. Шунлыктан әтинең миңа бирә торган «гыйльме» төкәнде. Мин бер-ике ел авыл мулласыннан укып йөрдем. Минем әти мине нигәдер үзебезнең авылда гына укытасы килми, тирә-якка дан тоткан Үтәш авылы мәдрәсәсенә җибәрде. Бу вакытта 12 яшемдә идем. Чит авылга китү, бигрәк тә әнидән аерылу миңа бик нык тәэ-

---

[1] Ул вакытта татарча укый-яза белүне «төрки тану» дип тәгъбир итәләр иде. Бу инде, ул вакыт саф татар телендә язылган китаплар булмаганлыктан, дәрес урынына укытылган китапларның иске төрек шивәләре белән язылганлыкларыннан шулай «төрки тану» дип йөртелгән булса кирәк. *(Гафури искәрмәсе)*

сир калдырды, авылдан киткән айларда елаган вакытларым да була иде.

Мин Үтәш мәдрәсәсенә барган кышны әти белән әни икәвесе дә вафат булдылар. Мин ятим калдым. Минем хәятымдагы чын авырлыклар шуннан башланып китте. Үтәш мәдрәсәсендә өч кыш тордым. Хәзер миңа өйдән килә торган азык киселгәнлектән, төрле шәкертләргә хезмәт итеп тамак туйдыра идем.

Үтәш мәдрәсәсе мине туйдырды, авылда тору да авырлашты. Шунлыктан, тоттым да Уфага киттем. Ләкин ярлы шәкертләр өчен анда да тормыш авыр икән, шуңа күрә «Кыешкы» авылына Мирсаф хәзрәт мәдрәсәсенә кайттым. Анда ярты кыш чамасы торгач, тагы да авылыбызга кайтып, бер яктан укып, икенче яктан балалар укытып, «хәлфә» булып тора башладым.

Шушы елның җәендә үзебезнең авылдашлар белән Урал тауларының эчендә яңа салына башлаган «Лапашты» дигән заводка эшкә киттем. Анда мин ат белән балчык ташу, соңга таба кирпеч сугу эшләрендә булдым.

1898 елга чаклы җәй көннәрен «Лапашты», «Зигәзе» һәм «Француз» заводларында эшләп, кыш көннәрен үзебезнең авыл мәдрәсәсендә укып-укытып тордым да, авыл мулласы белән килешә алмый, Троицкига киттем һәм шул заманда эчке Россиядә иң мәшһүр мәдрәсәләрнең берсеннән саналган, Зәйнулла ишан карамагында булуы белән дан тоткан «Мәдрәсәи Рәсүлия»гә кердем. Анда өч елга чаклы, кышын мәдрәсәдә иркен тормышлы шәкертләргә хезмәт итеп укып, җәен тирә-якка эшкә чыгып үткәрдем. Бу эшкә барган җирләремнең күңелдә иң нык тәэсир калдырганнары: Рәмиевләрнең «Восьмой» исемендәге алтын приискаларында эшләү, аларга алтын чыга торган җирләрне эзләп разведкә йөрү (әлбәттә, иптәшләр белән), Троицки байларыннан Учаровларның имениеләрендә хезмәт итү, Троицки тирәсендәге казакъ һәм рус кулакларына урак уру кебек эшләр булып, мин ул урыннарда үземнең һәм башка эшчеләрнең күргән авырлыкларын

әле дә йөрәгемнән чыгарып ташлый алмыйм... Бу эшләргә Троицки меховнында тире киптерергә чөй очлап, тире киптереп йөрүләрне дә кушарга ярый...

### *II*

Троицкидәге «Мәдрәсәи Рәсүлия»гә баруымның беренче елларында миңа «дөнья-ахирәт бәхетен» кулга тоттырып бирә торган бер урын кебек булып күренде. Пот ярым авырлыгында булган кабак зурлыгындагы ак чалма кигән берничә дистә хәлфәләр, җиргә карап кына йөргән, китаптан күзләрен алмаган сакаллы шәкертләр мине сокландырдылар. Ләкин ике-өч ел үтү белән ул бәндәләрнең коры кабык икәнлекләрен, бу мәдрәсәдә бирелгән «тәрбия» һәм укытыла торган нәрсәләрнең яшь шәкертләрнең миләрен агулап, рухларын үтереп чыгаруын сизенә башладым. Минем алдымда ниндидер бер кара пәрдә торган кебек була иде. Шул вакытта шәкертләргә бер дә кирәкмәгән нәрсәләр укытылуын һәм андагы укучыларның соң дәрәҗәдә ялкаулыкларын, ишанга мөрит булудан башка хасыятләре булмаганын тасвир итеп, «Ишан шәкертләре» исемендә ике-өч битле бер манзума (көйле нәрсә) яздым. Бу манзуманың мөндәриҗәсе хәлфәләргә дә, шәкертләргә дә бер дә ошамады. Алар миңа каршы аякландылар һәм бер форсат табып:

– Син әле безнең ишан хәзрәттән, аның мәдрәсәсеннән көләсеңме? Аны тәхкыйр итәсеңме?! – дип, мине буып алдылар һәм төрле яктан бәргәләп, аяк астына салып таптарга керештеләр. Инде беттем дигәндә генә, кайбер шәкертләр мине яклап, аларның кулларыннан коткарып алдылар.

Бу манзума минем иң беренче язган шигырьләремнең берсе булып, теге шәкертләрнең мине кыйнаулары шуның бүләге иде. Шушы вакыйгалардан соң мәдрәсәне ташлап фатирга чыктым (1902 ел).

Казакъ-кыргыз арасына башлап укытучы, икенче төрле әйткәндә «мулдакә» булып, 1901 елның март аенда, Тро-

ицкидән 130 чакрым җирдәге бер кыргыз[1] авылына бардым. Беренче елда казакъларның тормышларын бер дә яратмадым. Андагы беренче җәем, читлеккә ябылган кош кебек, күңелсезлектә үтте. 2–3 нче елларда, аларның гореф-гадәтләренә үрәнеп алгач, анда тору күңелле күренә башлады. Шул елларны «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» исемендәге хикәямне һәм «Себер тимер юлы» исемендәге шигырь мәҗмугасен яздым. Соңыннан бу мәҗмугаләрнең басылып таратылулары миндә язучылыкка булган һәвәсне тагы да арттырдылар һәм язучылык юлына кереп китүемә бик зур сәбәпче булдылар.

Казакъларның сүзгә осталыклары, алардагы җыр һәм шигырьгә булган табигый кабилият, аларның шагыйранә булган күчмә тормышлары, хатын-кызларының ачык йөрүләре миңа бик матур тәэсирләр калдырдылар.

Аларның үз кавемнәре, акыннары (шагыйрьләре) белән мактанулары һәм татар, башкортларны түбәнсетүләре дә миңа бик авыр тәэсир итә торган иде. Аларның татар, башкортларга, хәтта үзләрендә укытучы булып торган кешеләргә дә өстән карашлары, аларны түбәнсетүләре аркасында, алар белән сүзгә килешеп, үләң әйтеп җаваплашкан вакытлар күп булды. Бер вакыт шулай мин үземнең хуҗам булган Муса һәм күрше авылның старостасы Җилдер бай дигән кешеләр белән Троицкигә кайтырга чыктым. Юлда, кунар өчен бик бай бер казакъка төштек. Бай казакъның үзенең дә мулласы бар иде.

Теге мәгърур байның безгә түбәнсетеп каравы минем йөрәккә үтте. Төн булып, ятар вакыт җиткәч, кунакларга ятак урыннары хәзерли башладылар. Иң элек икешәр кат юрган җәеп, аның өстенә ап-ак мендәрләр куеп ике урын әзерләп, Муса белән Җилдер байга карап:

[1] Инкыйлабка кадәр казакъ һәм кыргыз халыкларының бер өлешен «кыргыз-кайсаклар» дип, бер этноним белән атап йөрткәннәр. Күп вакыт «кайсак» сүзе төшеп калып, ике халыкка карата да «кыргыз» сүзе кулланылган.

– Рәхим итәсез!– диделәр. Ә инде без ике укытучыга катып беткән бер юрган белән караеп беткән кечкенә бер мендәр ыргытып, шуларны җәеп ятарга куштылар. Мондый түбәнсетеп карауга чыдый алмадым, тоттым да кулым белән байларга хәзерләнгән урыннарны күрсәтеп:

Ике кат көрпә (юрган), ике мендәр Җилдер байга,
Түшәлгән шундый урын Муса байга.
Кара мендәр, бер кат көрпә муллаларга,
Җатаек дау чыгармый инде җайга...–

дидем.

Минем бу сүзләремне ишеткәч, теге кызарды. Муса белән Җилдер бай уңайсызланып, бер-берсенә карашып:

– Уй-бай, монау мулда, монда да айтасы сүзен әйтте гуй! – дип, сүзне уенга бордылар. Теге бай, безгә урынны кайтадан җәйдерде һәм ахырда:

– Бу мулдагыздан сак булыгыз. Троицкигә баргач, үзегезне бәлагә очратып куймасын...– дигән сүзне әйтте...

Казакъта йөргәндә, алар белән минем арада шундый вакыйгалар бик еш булып, алар мине шул ачыклыгым өчен яраталар һәм барган саен үзләренә якын күрәләр иде.

Шуның өчен алар белән ике арадагы алмаш тәэсирләр, сигез җәй рәттән алар белән кайнашып үткән яшь гомерләр минем хәятемдә бик матур эз калдырганнар. Әле дә мин ул вакытларны искә алам һәм аларның хөрмәтләрен һичбер вакыт күңелдән чыгарып ташлый алмыйм...

### *III*

Троицкинең суфилык белән сугарылган, искелек учагы булган мәдрәсәсе мине туйдырды.

1905 не елның август аенда Буби мәдрәсәсенә киттем. Ләкин аның даялы[1] исеме коры төтен икәнен күреп, анда өч кенә көн тордым да Казанга карап юлга чыктым. Ул шул замандагы мөтәрәккый[2] байларның назлы балаларын

[1] Даялы – даһи, югары сыйфатлы.

[2] Мөтәрәккый – алга киткән, прогрессив.

бераз «фән» белән буяп чыгаруны үзенә төп вазыйфа итеп алган бер мәдрәсә икән.

Кайнап торган Казан күңелгә дәрт бирде. Мин байтак мәдрәсәләрне күреп, аларның хәлләре белән танышканнан соң, «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә кердем. Бу мәдрәсә ару гына булса да, барыбер Троицкиның икенче бер үрнәге кебек булып, күп шәкертләр Галимҗан хәзрәткә мөрит булуны алда тоталар иде. Шуның белән бергә шәкертләр арасында мәдрәсәнең барышыннан ризасызлык көчәеп, икенче бер тормышка омтылу теләкләре бик ачык күренә иде. Аларның шул омтылулары 1905 ел революциясе чорында бик ачык күренде һәм шул вакыт мәдрәсәгә каршы бик көчле кузгалышлар булып, мәдрәсә идарәсен байтак үзгәрешләр ясарга мәҗбүр иттеләр. Байтак шәкертләр мәдрәсәне ташлап чыктылар. Ләкин Октябрь революциясе каһәрле кул белән бастырылганнан соң, мәдрәсә тагын иске юлына кайтты.

Казанда мин шул елны чыга башлаган «Казан мөхбире» һәм «Йолдыз» газеталарына байтак нәрсәләр яздым һәм «Яшь гомерем» дигән шигырь мәҗмугасын тәртипкә салып басарга бирдем.

Күңел эзләнә. Шул эзләнү нәтиҗәсендә 1906 елның көзендә генә ачылган Уфаның мәдрәсәи «Галия»сенә барып кереп бер ел укыганнан соң, рәсми шәкерт булып укуны ташлап, калган ике елны самигъ булып үткәрдем. Чөнки аның тоткан юлы һәм андагы күңелне ялкыта торган фәлсәфә тиз туйдырды. 1907—1908 һәм 1909 елларны язу эшләренә бирелеп, байтак нәрсәләр язып тәмам иттем. Җәй көннәрен казакъ арасына барып йөрдем.

1909 елны кышын да, җәен дә Уфада торып, тик язусызу эшләре белән шөгыльләндем. 1909 елның көзендә мин дә, башкалар гакде «гаилә»[1] берәү булып, бөтенләй Уфада торып калдым.

---

[1] Гакде «гаилә» – гаилә корган кеше.

1912 елны, кемнәрнеңдер доносы буенча, жандарм тарафыннан мине тәгъкыйп[1] итү башланды. Берничә айлар полиция назаратында тордым. Алар минем байтак нәрсәләремне тәрҗемә итеп, хөкүмәткә һәм патшага каршы булуда гаеплиләр иде.

Шул ук елны «Шәрык» матбагасына мөсәххих (корректор) булып кердем. Бу эш минем өчен бик күңелле булды. Типогрфия эшчеләре белән минем мөнәсәбәт бик самими һәм яхшы иде. Бу эш Октябрь революциясенә кадәре дәвам итте. Аннан соң, типография хөкүмәт кулына күчкәч, без дә шунда күчтек. Империализм сугышы күңелгә авыр тәэсир калдырды. Февраль һәм аннан соң булган Октябрь революцияләре... андагы шатлыклар миңа үлчәп бетергесез дәрт бирделәр. Минем яза башлаган вакытымнан бирле килгән һәм империализм сугышы чорында җимерелә башлаган милләтчелегем Октябрь революциясеннән соң авып төште. Бу урында, ул вакытларда сәяси мәсьәләләрне аңлауда артталыгымны, Октябрь революциясенең бөтен эшчәннәргә һәм изелгән милләтләргә азатлык байрагы алып килүен сәукый табигый (инстинкт) беләнрәк сизүемне, шуның аркасында кайбер мәсьәләләрне төшенеп җитмәвем аркасында, хәзерге көндәге күз белән карaганда хаталануларым булуын игътираф итеп үтүне үземнең бурычым саныйм. Югарыдан бирле язылып килгән бер мохит эчендә яшәп, мең елларча үзгәрешсез килгән бер төрле тормыш эчендә тәрбияләнеп килгән бер кешедә нинди хаталар булмаска, ул сазлыклар аркылы үткәндә ничек итеп өстеңә бер тап та төшерми үтәргә мөмкин соң?.. Октябрь революциясен пәрдәсез-нисез, ачык йөз белән каршы ала алуым мине шатландыра, озын сәфәрдә адашып калмый, кызыл байракка карап шигырьләр әйтүем өчен үземне бәхетле саныйм...

1917, 1918, 1919, 1920 елларда байтак нәрсәләр яздым. Һәм «Ирек», «Безнең юл» газеталарында язышып килдем. 1921 елда корректор булып торудан чыгып, «Шәрык ярлы-

[1] Тәгъкыйп – эзәрлекләү, күзәтү.

лары» һәм «Башкортстан» газеталарында язышучы булып эшли башладым.

1921 ел ачлыгы күңелгә авыр җәрәхәт салды. «Ачлык тырнагында» мәҗмугасы шул дәһшәтле ачлык тәэсире астында язылды.

1922 елда, Кырым совнаркомы исеменнән Гәрәй иптәш Сәедгалиевнең чакыруы буенча Кырымга барып, бер ай чамасы торып кайттым. Үз гомеремдәге иң озын сәфәрләрнең берсе булган бу сәяхәтнең истәлекләре хатирә дәфтәремдә сакланалар...

1923 елда, минем аз гына хезмәтемә каршы зур хөрмәт күрсәтелеп, 20 еллык юбилей үткәрелде. Юбилей вакытында мин үземдә бик зур бер авырлык сизеп, аны соң дәрәҗәдә уңайсызлык белән үткәрдем.

— Кяшки[1], әдәби эшләр белән эшчәннәргә зуррак хезмәт күрсәткән булсам иде!— дигән уй йөрәгемне тырнады.

1922 елдан башлап «Башкортстан» газетында, соңра «Яңа авыл»да язышучы булып хезмәт итеп килдем, шуның белән бергә язу эшләремне дә дәвам иттердем. 1928 елда, сәламәтлегем азая төшкәнлектән, газетта эшләүне ташлап, язучылык эшләремне дәвам иттердем. Гомер мосагадә итсә, яза башлаган берничә әсәремне язып тәмам итү — иң зур теләкләремнең берсе...

Җәй көннәрендә, Дим буендагы авылларның берсенә барып берәр ай торып кайту — гадәтем. Авылда торганда, иң яраткан нәрсәм аулак бер урында утырып кармак салудыр. Шуның өчен җәйне бик зарыгып көтәм.

Әхваль мөсагадә иткәндә сәфәр йөрүне бик яратам. Шул теләк белән үткән 1929 елда тагын да Кырымга барып бер ай чамасы йөреп кайттым. Кырым миңа матур кыз кебек булып күренә, ләкин ул артык назлы булганлыктан, аның белән үзләшеп китә алмыйм. Моннан соң Уфадан чыгып йөрергә туры килсә, завод һәм фабриклар кайнап тора торган районнарга барып йөрер идем.

[1] Кяшки – ичмаса (кереш сүз).

Минем иң күп барган шәһәрем — Казан. Анда ел аралаш дип әйтерлек барып кайтам.

Быел «Эшче» операсының сәхнәгә беренче тапкыр куелуы мөнәсәбәте белән тагын да Казанга барып, унике көн тордым. «Эшче» операсы бер-ике рәт тамашага куелганга кадәре аның уңышлы булып чыгуына курку катыш өмит белән торганлыгымнан, башта күңелсез йөрдем. Сәхнәгә куелуын күргәннән соң, «Эшче»не бераз гына төзәтү белән, аның зур уңышларга ирешәчәгенә күңелем утыргач, бу сәфәр күңеллегә әйләнде.

Мин Казанда, Татар дәүләт академия театрында берничә әсәрнең тамашага куелуын карап, андагы уйнауларны бик яраттым. Мин элек татар эшчәннәре сәхнәсенең тиз арада болай үсә алачагын күз алдыма китерә алмый идем. Эшчәннәр театрының алдагы көндә тагын да зур уңышларга ирешеп, иске театрны пәрдә артында калдырачагында шөбһәм калмады.

Уйнаучыларның уйнауларын, аларның сәхнә сәнгатенә чын күңелләреннән бирелүләрен чиксез яратуымны үзләренә әйтә алмый, үзләре белән утырыш ясый алмый китүемә үкенәм. Казанда башка мәдәни эшләр белән театр эшләренең мөтанасип рәвештә үсә баруы читтән барган кешенең күзенә бик ачык күренә.

Озын гына бер гомердәге башымнан үткән вакыйга һәм эшләрнең кыскача бер фиһресе урынында язылган тәрҗемәи хәлем шунда бетте.

Хөрмәт белән Мәҗит Гафури

*1930 ел, 25 март. Уфа*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12ф., 1 тасв., эш, 49 б.*

# М. Гафуриның иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлегенә галимнәрнең бәя-карашы

*Мөхәммәт Мәһдиев*

# Мәҗит Гафури

«Җыеп караганда алай бик зур
Төсле түгел гомрем йомгагы;
Сүтеп караганда чак күренә
Аның бер ягыннан бер ягы».

*М. Гафури*

Татар һәм башкорт халыкларының уртак язучысы, күренекле прозаик һәм шагыйрь Мәҗит Гафури үзенең тормыш юлы турында әнә шулай язды.

Галимнәр арасында, М. Гафури татар язучысымы әллә башкорт язучысымы, дип бәхәсләшергә яратучылар бар. Мондый бәхәснең урынсыз һәм кирәксез икәнен исбат итеп торуга ихтыяҗ юк шикелле. Әмма бу бәхәснең төбендә бик зур һәм әһәмиятле бер мәгънә ята: «безнеке» дип, гадәттә, кыйммәтле, яхшы кеше турында сүз көрәштерәләр. Антик заманнан ук моңа мисал бар: сукыр Гомер бездә туган дип, җиде шәһәр дәгъва кылган. Бу бәхәс әле дә хәл ителмәгән. Талантсыз булса, Гомер өчен бәхәсләшеп тормаслар иде...

Шагыйрьнең гомер йомгагы. Бу йомгак нинди җепләрдән җыйналды икән соң? Моны сүтеп, тикшереп карау кызыксыз булмас кебек.

Нәшриятларда М. Гафуриның әсәрләре ел саен басылып тормый, филология галимнәре дә аның иҗатын күптән инде төрле яклап өйрәнеп бетерделәр кебек. Хәлбуки, М. Гафури узган тормыш юлын һәм аның иҗатын бүгенге яшь буын укучыларының хәтеренә төшергәләп тору комачау итмәс иде. Ул бит үз заманында Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов кебек язучылар белән бер сафта барган кеше. Ул шагыйрь дә, прозаик та, ялкынлы журналист та һәм җәмәгать эшлеклесе дә

иде. Кулына каләм алганда коеп куйган үгет-нәсыйхәтче, мәгърифәтче язучы беренче рус революциясеннән соңгы реакция елларында әдәбиятта мөстәкыйль тавышлы, абруйлы бер әдипкә әйләнде.

Дөрес, язучының иҗаты каршылыксыз булмады, бу иҗат шома юлдан гына бармады. Шагыйрь һәрвакытта да, үзе әйткәнчә, иҗатында «изге юл» эзләде. (...)

Ул 1880 елның 1 августында (иске стиль белән 20 июльдә) Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Җилем-Каран авылында хәлфә гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Нургани хәлфәнең тормышы шактый авыр була. «Тәрҗемәи хәлемнән өземтәләр» дигән язмасында Гафури үзе бу турыда болай яза: «Ул вакытларда безнең гаилә тормышы бик авыр һәм өс-башларыбыз сәләмә булуын әле дә исемдә саклыйм. Безнең өйдә арыш икмәге бик кадерле санала, чәй урынына күп вакыт юкә чәчәге яки мәтрүшкә эчелә, җәй көннәре итле аш урынына арыш чумары салган балтырган үрәсе ашала, аның да катыгы иркен тормышлы күршеләрдән алынган була иде. Шуларны искә алсам, хәзерге көндә анкета язганда: «Мин ярлы крестьян баласы...» дип язсам, хаклыдырмын төсле булам...»

Нургани хәлфә улына бик кечкенәдән төрки сабагы өйрәтә. 8–9 яшьләрендә инде кечкенә Мәҗит, төрки сабагын үзләштереп, гарәп телен өйрәнүгә күчә. Бераздан әтисе аны шул яктагы Үтәш мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Туган йортыннан аерылып чит авылда укып ятуын малай бик авыр кичерә. Ул арада Җилем-Каранда аның әтисе һәм әнисе үлеп китәләр. Малайның өеннән ярдәм туктагач, ул баерак шәкертләргә хезмәт күрсәтеп тамагын туйдыра башлый. Үтәш мәдрәсәсеннән кайткач ул үз авылларында яшәп карый, бераздан Уфага китә, әмма, йорттан ярдәм килерлек булмагач, аннан кайта. Уфадан ул Кыйшкый дигән авылга кайтып, мәдрәсәгә урнаша һәм, ярты ел чамасы укыгач, үз авылына кайта.

Язучының иҗат биографиясенә аның туган ягы, туган туфрагының йогынтысы – бәхәссез. Кырлай урманы Ту-

кайга, Рязань каеннары, Ока буендагы печән кибәннәре Сергей Есенинга нинди илһам биргән булса, М. Гафурига да Агыйдел һәм Җилем елгалары тирәсендәге сихри табигать балачактан ук поэтик азык биргәннәр. Уралның еракдан күренгән чал кыялары, кыя өсләреннән күккә мәһабәт күтәрелгән бөркетләр, бөдрә куаклар белән чигелгән иксез-чиксез болыннар, әкияттәге серлелеккә ия булган тау куышлары Җилем-Каран авылында туган малайның рухи дөньясына зур тәэсир ясаганнар, сизгер күңелле уйчан малайда акрынлап җиргә һәм хезмәт кешесенә гашыйк булган шагыйрь өлгереп килгән. Ярлы авыл хәлфәсе улы Мәҗитнең хыялында үз якларының гаҗәеп иркен болыннары, сулары, галибанә табигать матурлыгы белән берлектә халыкның тирән, чал тарихына таба юл сузыла — шундый гүзәл табигать шартларында яшьтән ата-бабаларының борынгы тарихын күз алдына китерү теләге туа.

М. Гафури эшчеләр дөньясы белән бик яшьли таныша. Мәдрәсәләрдә белем күтәрү белән беррәттән, ул сезонлы эшләрдә катнаша. Унсигез яшенә җиткәндә ул инде, «Лабашты», «Зигәзи», «Француз» кебек Урал заводларында эшләп, зур мәктәп узган егет була.

1898 елда М. Гафури шул чор өчен мәшһүр Троицк мәдрәсәсенә (Зәйнулла ишан карамагындагы «Мәдрәсәи Рәсүлия») укырга килә. Анда кышын хәллерәк шәкертләргә хезмәт күрсәтеп, җәен алтын приискаларында, разведкада, казакъ һәм рус байларының хуҗалыкларында, тире фабрикаларында эшләп «белемен күтәрә». «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыганда ул андагы тәртипләрдән риза булмый һәм ишанчылык, мөритчелектән көлеп көйле бер әсәр дә яза. Шулай да Троицкидагы тормышы бушка узмый: Троицк — күпмилләтле, күп вак кибетле, күп һөнәрчеле (тиречеләр, тегүчеләр, йон-ябага җыючылар, вак тартмачылар), мәдрәсәле һәм, ниһаять, ишанлы шәһәр. Троицк — мәчетләр һәм казылык кибетләре, спекулянтлар, алдаучы һәм алданучылар тулы базарлар шәһәре. Әмма күпчелеге хезмәт ияләреннән, фәкыйрь шәкертләрдән

торган шәһәр. Троицк – Азия белән эчке Россия сәүдә юлындагы капка. Мәҗит шәкертнең дөньяга карашлары әнә шул «капка»да формалаша башлый. Яшь, укуга сәләтле егет берничә елдан үзенең «Ишми ишан капкасы» аркылы узачагын әлегә белми...

Троицк мәдрәсәсендә укыганда Гафури тагын бер тормыш мәктәбен уза: җәйләрен ул казакъ-кыргыз даласына чыгып, бай балаларын укытып йөри. Шул ук елларда язучылык эшенә дә ныклап керешә. «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясе һәм «Себер тимер юлы» дигән шигыре әнә шул чорда языла. (...)

Дөньяны инде байтак гизгән Гафуриның суфичылык белән сугарылган Троицк мәдрәсәсеннән күңеле кайта. 1905 елның август аенда ул Иж-Буби мәдрәсәсенә килә, әмма, андагы гомуми атмосфераны ошатмыйча (бай балалары күп була), Казанга юл тота. Казанга ул 1905 елның августында килеп, кышны шунда уздыра. Гафуриның «Мөхәммәдия»дә укыган чоры революциянең күтәрелгән көннәренә туры килә. Шәкертләр күтәрелү дулкыны, уяну хәрәкәте шагыйрьгә көчле тәэсир ясый, һәм ул «Яшь гомерем» исемле шигырь мәҗмугасын тәмамлап басарга бирә. Моннан тыш яңа ачылган матбугатта – «Йолдыз», «Казан мөхбире» кебек газеталарда шигырьләр, мәкаләләр бастыра. Иҗтимагый-политик тормыштагы һәрбер яңалык бу көннәрдә аңа зур тәэсир ясый. (...)

Җиденче, сигезенче, тугызынчы еллар – Гафуриның Уфада торып актив иҗат иткән еллары. 1909 елның августында Гафури – инде танылган шагыйрь – Зөһрә исемле кызга өйләнеп, гаилә тормышы корып җибәрә. Әмма унынчы елларның башында Гафурига патша администрациясеннән бик күп җәфа күрергә туры килә.

Шул ук елны Россиянең Эчке эшләр министрлыгы янында Дин эшләре департаменты директоры җитәкчелегендә махсус киңәшмә оештырыла. Бу киңәшмәдә эчке эшләр министрлыгы, халык мәгарифе һәм православие диненең үзәктәге һәм урындагы вәкилләре

катнаша. Махсус киңәшмә Россия мөселманнары арасындагы прогрессив хәрәкәткә каршы көрәшүне үзенең программасына нигез итеп ала. Моның мәгънәсе, әлбәттә, тирәндәрәк: патша властьлары яңа революцион күтәрелештән куркып калалар һәм, ничек кенә булмасын, Россия халыклары арасындагы интернационализмга омтылышны бастырырга, сүндерергә тырышалар. 1911 елның башында патша властьлары Казан, Оренбург, Вятка, Саратов, Астрахань губерналарында «профилактика» уздыралар. Татар интеллигенциясе булган төбәкләрдә, китапханә, нәшрият, китап кибете, мәктәп, мәдрәсәләрдә язучы, журналист, алдынгы карашлы мулла, мөгаллимнәрнең өйләрендә бер төн эчендә кинәт тентү ясыйлар. Бик күп татарлар – алдынгы карашлы мөгаллимнәр, муллалар, шәкертләр, студентлар кулга алына, уку йортлары тар-мар ителә. С. Рәмиев, Җ. Вәлиди, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинов кебек язучыларның өйләрендә тентү уздыралар. Жандарм идарәләренә тау-тау дәфтәрләр, китаплар, хатлар, альбомнар, кулъязмалар озатыла, һәм бу материалны өйрәнү, сөзү, сыгу башлана. Сөзеп чыкканнан соң нәрсәләр аерылып алына соң? Беренче чиратта – М. Гафуриның «Милләткә мәхәббәт» исемле шигырьләр җыентыгы. Әйтергә кирәк, Гафуриның бу китабы тентү нәтиҗәсендә генә килеп кергән әйбер түгел. Китап жандармериягә башка юл белән дә килеп керә. Вятка губернасы Малмыж өясе Түнтәр авылы ишаны Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев тә бу китап белән таныш булган. Казан арты авылларының бөтен мәхәлләсе, мәктәбе, мәдрәсәсе Ишми ишанның йогынтысын, көчен сизеп, тоеп яшәгән. 1911 елда, тентүләр куерган бер чорда, Ишми ишан, Казан арты авылларындагы яңа карашлы муллалар, мөгаллимнәрнең исемлеген төзеп, жандармериягә җибәрә, һәм боларның барысын да кулга алалар. Уфада яшәгән Гафури, Түнтәр ишаны белән язмыш очраштырыр, дип башына да китермәгәндер. Әмма Гафуриның китабы Түнтәргә барып җитә. Ишми

ишан Түнтәрдән Казанга йөргән егетләр аркылы үзенең шәһәрдәге танышына үтенечен белдереп тора, нинди яңа китаплар бар, алып җибәр, ди. «Милләткә мәхәббәт» китабы әнә шулай Ишми кулына килеп керә. Гафуриның китабын Ишми ишан кулына карандаш тотып укый. Укый һәм хәйран кала... Бу ни эш? Яңа ысулчылар кая баралар? Цензура нәрсә карый? Һәм карандаш белән чуарланган бу китапны Ишми Вятка губерна жандарм идарәсе начальнигының Сарапул өязе буенча ярдәмчесе ротмистр Будагоскийга озата. Будагоский исә, үз чиратында, китапны Казанга җибәрә: бездә чыккан түгел, үзегез хәл итегез, янәсе. М. Гафуриның Ишми ишан кулы белән «төзәтелгән» китабының экземпляры тарих өчен әнә шулай сакланып кала.

Ишми бигрәк тә Гафуриның ике шигыренә тукталган: «1906 елдан 1907 елга васыять», «Җиденче елның җавабы». Китапның титул битенә үк Ишми язып куйган: «Гафури — яңа юнәлеш тарафдары». Текст эченә кергән саен эмоцияләр куера бара. «Язган китабына караганда, бу кеше һич тә мөселман түгел, ә дәһри». Жандарм чиновниклары китапның юлга-юл тәрҗемәсен өйрәнәләр (тәрҗемәне профессор Н. Ф. Катанов эшли).

1911 елның 11 февралендә жандармерия Уфада «Шәрык матбагасы»нда кинәт кереп тентү уздыра. Тентүне алып барган жандарм офицеры, протокол төзегәндә, «Чын азатлык кайчан булыр?», «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!», «Халык акчалары кая җыела һәм нәрсәгә тотыла?» дигән брошюраларны, Г. Тукай шигырьләренең 4 нче дәфтәрен һәм М. Гафуриның «Яшь гомерем» дигән әсәрләрен «аеруча хәтәр китаплар» дип билгели.

Әнә шулай итеп жандармерия чиновниклары каршында «аеруча хәтәр» бер шәхес Мәҗит Гафури барлыкка килә (...).

Уфадагы «Шәрык матбагасы» патша хөкүмәте алдында шактый кыен хәлгә эләгә. 1911 елда «Шәрык матба-

гасы» М. Гафуриның «Милли шигырьләр» дигән җыентыгының дүртенче басмасын чыгара. Ул вакыттагы тәртип нигезендә, китапны сатуга озатканчы, Казандагы матбугат эшләре буенча Вакытлы комитетка җибәрергә тиеш булалар. Заказлар бик күп булудан файдаланып, барыбер рөхсәт килер әле, дип уйлыйлар да, рөхсәт язуы килгәнче үк, китапның тиражын Казан, Оренбург, Орск, Троицк кибетләренә озата торалар. Әмма китапка рөхсәт килмәгән, һәм властьлар аны конфискацияләргә карар биргәннәр. Китапның тиражын кире җыеп алалар, һәм матбага штрафка тартыла[1]. Гафури үзе исә полиция участогына чакыртыла һәм Уфадан чыгып китмәскә имза бирә. Шулай полиция күзәтүе астында тормыш башлана (...)

Әмма бу тентүләр, судлар, күзәтүләр Гафурины каушатмый. Аның халык язмышы, ил язмышы турында уйланулары бу чорда тагы да тирәнәя. Балачактан ук хәтергә уелып калган тәэсирләр аны халыкның, илнең тарихына эчкәрәк керергә чакыралар. Бу өлкәдә аның эзләнүләренең иң матур нәтиҗәсе буларак «Агыйдел буенда» («Хан кызы Алтынчәч») дигән искиткеч легенда туа. «Бер бите ай, бер бите көн кебек» сылу кыз Алтынчәч үзен алырга килгән «җәенке битле Җаек буе яубасарына» барырга риза булмый гына түгел, ә туган җирен саклау ниятендә, кулына корал тотып, дошманга каршы чыга. Җаек аръягыннан килгән дошман гаскәре Алтынчәчнең туган җирен таптый, Алтынчәч, кулы яраланып, тау куышына чигенә һәм шунда кача. «Шуннан соң Алтынчәчнең ничек булганы мәгълүм түгел. Тик менә аның, җәйге матур көннәрдә шул тау тишегеннән чыгып, теге тау киртләченә утырганын күргән кешеләр бар. Ул шунда чыгып, үзенең аякларына төшеп торган озын чәчләренә күмелеп, учына таянып, бик моңаеп тугайга таба карап таң атканчы утыра, ди. Ул борын заманда бик еш кү-

[1] Бу турыда: Мәҗит Гафури тураһында замандаштары.– Өфө, 1961.– 45 б.

ренгән, инде бу көннәрдә аны күргән кеше ишетелми. Тик безнең карт әти кич белән монда кунган вакытта үзенең Алтынчәчне күргәнен, матурлыгына исе китеп карап торганын сөйли торган иде».

Мәҗит Гафуриның «гомер йомгагы» — ул «иҗат йомгагы». Әйе, гомер буе, бер көн калмыйча, ару-талуны белмичә тудырган иҗат йомгагы. Ул иҗат йомгагына үз Ватанын, үз халкын сөйгән, кулына корал алып дошманга каршы чыккан гүзәл кыз Алтынчәч очраклы рәвештә килеп кермәгән. Алтынчәч образы — ул тормышның үзеннән, тарихтан. Тарих ул, легенда туганнан бирле, Жанна д'Арк, Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина кебек кызларын күп тудырды...

Халык образы, ил язмышы мәсьәләсе М. Гафуриның бөтен иҗат нигезен тәшкил итте. Гомер йомгагының төп җепләреннән берсе дә әнә шул — Гафуриның үзен ил, халык язмышыннан аерылгысыз каравы.

Гомер йомгагы тагын ниләрдән тора соң?

1912 елның җәендә казакъ даласына дәваланырга барышлый Тукай Уфага туктала. Ике шагыйрьнең очрашуы шунда була. Авырлык, авыру, патша Россиясендәге намуслы интеллигенция кичергән хәлләр белән кыйналган ике шагыйрь. Бу очрашу турында тарих безгә бик аз мәгълүмат саклап калдырган. Тукай үзе бу очрашу турында болай искә ала:

«Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мөсахәбәмез күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек — әле күздән яшемез дә кипкән.

Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән»[1].

Әйе, «хөкүмәт тынычлыгын бозучы» шагыйрьләрне әле генә «язмыш ханым кыйнаган» чор иде бу...

***

М. Гафуриның Октябрьгә кадәрге прозасы турында сүз алып барганда, беренче чиратта аның «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» әсәрләренә күз салырга кирәк.

Татар әдәбиятында Октябрьгә кадәрге крестьян, һөнәрчеләр тормышының бәхетсез караңгы чынбарлыгын чагылдырган хикәя-повесть, шигырьләр байтак. Әмма бу темага язылган әсәрләр арасында М. Гафуриның хикәя һәм повестьлары аерым урын алып тора.

...Дөнья әдәбиятында катлаулы язмышлы Кнут Гамсун дигән бер язучы булган. Гамсунның чит илдән салкын якка килеп урнашкан бер рәссам турында язган «Кояш улы» исемле хикәясе бар. Кырыс климатлы бу илдә рәссам – кояшлы ил улы – берөзлексез туңа, урамда салкын, бүлмәдә салкын – аның җаны өши, рухы туңа. Гамсунның бу хикәясен укыганда урамдагы эссе кояшлы көнне дә, бүлмә җылысын да онытасың, кояш та, йомшак җылы җил дә – барысы да чын түгелдер кебек тоела, кыскасы, үзең дә туңа башлыйсың. Кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтне тасвирлауда хикәянең көче әнә шулай сизелә. М. Гафуриның «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» исемле әсәре нәкъ шундый психологик корылмага ия. Бер дә икеләнмичә әйтергә мөмкин: «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» әсәре фәкыйрьләрне тасвирлау ягыннан Европа һәм

[1] Г. Тукай. Әсәрләр: 4 том.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1977.– 199 б. Тукайның бу сүзләре хакында әдәбиятта төрле фикер яши. Соңгы басманы төзүчеләр «яшебез дә кипкән» сүзен, «елап яшебез калмаган» мәгънәсендә аңларга тәкъдим итәләр. Безгә калса бу – типография хатасы. Ихтимал, сәламәтлеге бик нык какшаган Тукай бу әсәрнең корректурасын үзе укый алмагандыр. Дөресе – «әле күздән яшемез дә кипмәгән» булырга тиеш.– *М. М.*

бөтендөнья әдәбияты югарылыгында язылган. Әсәр вакыт һәм пространствода гаҗәп эзлекле, төгәл һәм ышандыргыч. Монда без Виктор Гюгога хас сабырлык һәм эзлеклелекне, тормыш шыксызлыгын тасвирлауда хәзерге заман япон язучысы Кобо Абэга хас чыдамлылыкны, фәкыйрьлекнең төбенә төшкән кеше рухын сурәтләүдә О'Генрига хас осталыкны күрәбез.

Менә көнлекче Шәриф һәм аның хатыны Бәдри, алардан да бәхетсезрәк Җәмилә... Боларны кешелек сыйфатлары гына түгел, ә актык читенә җиткән фәкыйрьлек тә берләштерә. Беренче карашка болар – хәерчелекнең иң төбенә төшеп җиткән бәхетсезләр – бөтен төрле кешелек сыйфатларын югалтырга тиешләр иде. В. Гюго әнә шулай ди бит: «Фәкыйрьлекнең мәгълүм бер баскычында хәерче кеше шулкадәр томаналана, ул инде үзенең газапларыннан зарланмый һәм яхшылык эшләгәннәргә рәхмәт әйтми башлый».

Әмма М. Гафуриның ярлылары өметсез фәкыйрьлек, ачлык, салкын тырнагы астында бер-берсенә тагын да якынрак килеп сыеныргa, тормыш итәргә үзләрендә көч табалар. Әнә шул өметсез, нурсыз хәяттa да аларның тукларда, хафасыз гомер итүчеләрдә булмаган матур сыйфатлары калкып чыга: ярлылар шатлана беләләр! Очраклы рәвештә килеп кергән 15 тиен акчага ризык алып, алар бәйрәмчә табын хәзерли, куана, шөкер итә, өметләнә беләләр. Америка язучысы О'Генриның бер җөмләсе бу уңайдан искә төшә. Ул болай ди: «Ярлы кеше үзенең ертык жилетының чабуына әллә кайчан төшеп югалган чирек долларын тапканда яшәү шатлыгына шундый тирән итеп чума – мондый тирәнлеккә бер миллионер да ирешә алмый».

Фәкыйрьләрдәге иң гади кешелек сыйфатларына контраст итеп, Гафури байлардагы күңел тупаслыгын, кешелексезлекне бирә. Киемсез, ризыксыз, ирсез калган ярлы хатын Җәмиләне бай хатыны өеннән куып чыгара: үзенең

тышкы кыяфәте белән үк Җәмилә аның кәефен бозып тора.

Өй тулы кунак чакырган тәкәббер күңелле бай хатыны, Җәмиләне күргәч:

– Бу нинди хәерче хатыны тагы!.. Галош яисә башка нәрсәләрне урлап алып китмәсен! – дип кычкыра.

Бай хатыны әнә шулай, эт кугандай, аны өеннән куып чыгара. Менә озак та үтми, Җәмиләнең мәетен зиратка алып баралар. Җеназа әлеге бай капкасы турысыннан уза.

Җәмилә, ди автор, теле булса, болай дип әйтер иде, – ди:

– Җаным! Син мине өең алдыннан эт кебек итеп куып җибәргән идең! Инде мин шул дәрәҗәдә мәсгут бер хәлдәмен, синең мал вә милкең минем күземә чүп кадәрле булсын күренми, әгәр дә син үзеңнең бу хәлгә төшәчәгеңне белсә идең, бу малларның бернәрсәгә дә яраксыз икәнен белер идең! Инде минем күземә синең ефәк күлмәкләрең өстемдәге кәфен кадәре дә күренмидер. Мин инде тигезлек дөньясына чыктым. Монда икебезнең арада зәррә кадәре аерма юктыр».

Үлгән Җәмилә әнә шулай тере Җәмиләгә караганда теллерәк, кыюрак. Ни өчен шулай? Чөнки тере Җәмилә фәкыйрьлек, ачлык белән кыйналган иде, ул тереклек итәр өчен, ачтан үлмәс өчен һәр минут көрәш алып бара иде, аның максаты – исән калу иде. Үле Җәмилә исә бу максаттан инде азат, монда ул автор исеменнән дә сөйли, хәзер инде ул социаль гаделсезлеккә гаеп ташлаучы буларак күренә.

Ярлылар зәмһәрир салкында аның гәүдәсен мәчет ишегалдына алып киләләр, салкында өшеп, хәзрәтне көтәләр. Монда да үле Җәмилә сөйли. Теле белән ул хәзрәткә болай дигән сыман:

– И хәзрәт, бәнем сезнең җеназа-фәләнегезгә ихтыяҗым юк, тере вакытымда инде күргән хурлыкларым җитәр иде, инде үлгәч, бәнем сөягемне тизрәк кара кабергә җибәрегез! Дүрт мәртәбә тәкбир әйтүгә авырсынмагыз.

Бәннән сезгә тиячәк бер тиенем булмаса да, җеназа укып кына бирегез, бу торган киемсез ярлыларны кызганыгыз...

«Ярлылар, яки Өйдәш хатын» повесте үзенең мәгънәсе белән әле дә заманча. Повесть Җир шарының почмакларында әле дә яшәп килгән фәкыйрьлек, ачлык афәтенең корбаннарын яклау булып яңгырый, социаль тигезсезлекне гаепли. Бу повесть гуманлы бөек мәгънәгә ия, үзенең идея-эстетик йөге белән ул бер татар әдәбиятының гына түгел, дөнья әдәбиятының да уртак хәзинәсе.

Утызынчы еллар ахырында М. Гафури иҗатын киң тарихи планда һәм бик җентекләп тикшергән Муса Җәлил шагыйрьнең мәсәл жанрындагы эшчәнлегенә югары бәя бирде. М. Гафуриның мәсәл жанрын киң куллануы реакция елларында башлана. «Бу һич тә очраклы хәл түгел,– дип яза М. Җәлил.– М. Гафури бу дәвердә кара реакция шартлары эчендә язды. Кара реакция аңарда өметсезлек һәм эч пошу белән бергә тирә-як буржуаз мөнәсәбәтләргә, буржуа җәмгыяте әхлакларына нәфрәт уятты. Реакция һәм патша хөкүмәтенең эзәрләүләре аның әдәби стилендә төрле формаларга һәм жанрларга күчеп эзләнүне, караш һәм тойгыларын төрле гиперболик формаларда әйтергә теләү омтылышын тудырды»[1].

Әйтергә кирәк, мәсәл жанры – поэзиянең иң авыр формасы. Мәсәлче – әдәбият тарихында бик сирәк очрый торган шәхес. Мәсәлченең әдәбиятка, җәмгыятькә, тарихка китергән файдасы гадәттән тыш зур, абруйлы. Мәсәл жанрының дөнья әдәбиятында зур традицияләре бар. Борынгы Грециядә Эзоп, Римдә Федр, Көнбатышта Лафонтен, Лессинг, Геллерт, Мур мәсәл жанрында иҗат итеп бөтен дөньяга танылдылар. Унсигезенче гасырның ахыры – унтугызынчы гасырның башында мәсәл жанры Россия әдәбиятында да урын ала. В. Тредиаковский, А. Кантемир, А. Сумароков, И. Хемницер, А. Измайлов, И. Дмитриевлар иҗатында бу жанр рус әдәбияты өчен

[1] Мәҗит Гафури. Сайланма әсәрләр.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1939.– 22 б.

тулысынча үзләштерелә. Ләкин мәсәлне бөтен реальлеге, политик үткерлеге һәм психологизмы белән рус әдәбиятында тудырган кеше Иван Андреевич Крылов була. Крылов мәктәбе Россиядәге башка халыклар әдәбиятына да зур йогынты ясый. Татар мәгърифәтчеләре 19 йөз ахырында – 20 йөз башында нәкъ менә Крылов мәсәлләренә мөрәҗәгать итәләр, һәм кайсы – прозада (Таип Яхин, бераздан Тукай), кайсы поэзиядә бу жанрны татар әдәбиятында да тудыралар.

Мәҗит Гафуриның татар әдәбиятында мактаулы урынын билгеләүче шартларның берсе нәкъ менә шул – аның поэзиядә татар мәсәлен тудыруы. Мәҗит Гафуриның мәсәл жанрында эшчәнлеге турында сүз алып барганда тагын бер үзенчәлеккә игътибар итми мөмкин түгел. Үзенең мәсәлләре белән Гафури татар әдәбиятының җепләрен бик тирәнгә, ерак тарихка бәйләде һәм иҗатында жанр тына түгел, тематика, сюжет, композиция кору ысулларының тарихи-интернациональ юлларын тоташтырды. Бөтендөнья әдәбият фәне раслаганча, антик заман мәсәлчеләре Эзоп, Федр һәм башкаларның тематикасы тагы да ерак заманнарга – борынгы Һиндстан фольклорына һәм әдәбиятына барып тоташа. Борынгы Һиндстан халкының гыйбрәтле мәсәлләре халык теленнән Эзоп иҗатына, Эзоптан Үзәк Европага (Лафонтен), аннан Россиягә (Крылов) һәм Россия эчендәге башка халыклар әдәбиятына да күчкән. М. Гафури тарафыннан язылган «Ике чебен» (1911), «Чикерткә белән Кырмыска» (1913), «Бабай белән Аю» (1913) һ.б. мәсәлләр үзләренең тарихи тамырлары белән Крылов – Лафонтен – Федр – Эзоп аркылы ерак борынгылыкка – Һиндстан халкының фольклорына һәм язма әдәбиятына барып тоташалар. Бу яктан караганда Гафури татар әдәбиятын рус – Көнбатыш Европа – антик Рим – антик Греция – борынгы Һиндстан белән бәйләүче шагыйрь булды. Әмма борынгы Һиндстан халкының акылы Греция – Рим – Көнбатыш Европа аша гына түгел, рус һәм татар әдәбиятларына турыдан-туры Көнчыгыш

әдәбиятлары аркылы да килеп керә. Моның шулай икәнлеге М. Гафури иҗатында аеруча күзгә ташлана. Чөнки 19 гасыр ахырында, 20 гасыр башында татар китап нәшриятлары, төрек, фарсы, гарәп чыганакларыннан файдаланып, күп «хикәят» тәрҗемә итәләр, бу китаплар Мәҗит Гафури шагыйрь булып формалашкан дәвердә татар халкы арасында бик популяр була. М. Гафурины без, бер дә шикләнмичә, татар әдәбиятының «Крыловы» дип әйтә алабыз. Гафури бу жанрда эшләгәндә, Крыловны үзенең остазы дип санаган хәлдә, күп оригиналь әсәрләр иҗат итә. Әсәрләрендә ул еш кына конкрет халыкара хәлләрне яктырта. Бу яктан караганда аның «Кара елан белән Бакалар патшасы» дигән мәсәле – аеруча үткен, оригиналь әсәр. Гафури монда империалистик державаларның Африка һәм Көнчыгыш халыкларына карата кулланган (бу очракта Марокконы йотуларына кагылышлы) мәкерле политикасын фаш итә.

Гафуриның поэтик осталыгы, ихтимал, мәсәл жанрында аеруча күзгә ташланадыр. «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле аның иҗатында зур казаныш, поэтик осталык үрнәге булып кала. Кайбер дәреслекләрдә еллар буе бу мәсәлне вульгарлаштырып аңлатып килделәр. Бүре – капиталист, Куян – хезмәт ияләре вәкиле, дигән абсурдка барып җитүчеләр дә булды. Әмма Гафури мәсәлдә әле мәгърифәтче буларак чыгыш ясый һәм җәмгыятьне конкрет сыйныфларга бүлеп тормастан гына «яхшылар» һәм «явызлар»га бүлеп карый. Мәгърифәтче Гафури уйлавынча, явызлар – усал, яхшылар – юаш. Болай уйлау, әлбәттә, мәгърифәтчелек, бәндәчелеккә, явызлыкка баш иеп, каршы килмәү тенденциясенә кайтып кала. Әмма, әдәби-эстетик карашларында никадәр генә чикләнгән булмасын, шагыйрь бу мәсәлендә зур гомумиләштерү ясый:

*Бүре төсле ерткычларга киңдер җиһан,*
*Һәркайсында золым күрер мескен Куян.*
*Зарарлы бәндә булып күренерсең,*
*Башкаларга кыйлмасаң да һичбер зыян.*

(...) Гафуриның бөек рус мәсәлчесе И. Крыловтан алып тәрҗемә иткән («Маймун белән күзлекләр», «Карт белән Әҗәл» һ.б.) мәсәлләре революциягә кадәрге татар мәктәп-мәдрәсәләрендә һәм революциядән соңгы татар совет мәктәпләренең дәреслек, хрестоматияләрендә зур урын алып торды. Безнең уебызча, Мәҗит Гафуриның мәсәл жанры өлкәсендәге эшчәнлеге, бу жанрны поэзиядә тудыруда беренчелеге, татар мәсәленең тарихи-интернациональ тамырлары турында киләчәктә галимнәр, һичшиксез, зур тикшеренү алып барырлар, һәм бу тикшеренүдә Гафури иҗаты үзенең тагы да әһәмиятле, матур сыйфатлары белән ялтырап китәр...

***

...Безнең гасырның унынчы елларында шигырь язучылар арасыннан чын шагыйрьләрне аерып алырга омтылу модага кергән булган. Кайбер газета, журналлар, шул чорның иң күренекле өч шагыйрен, биш шагыйрен атап күрсәтегез, дип анкеталар да тараткannar. Бу исемлеккә керер өчен тырышып чаралар күрүче шагыйрьләр дә булган. Күпчелек беренче чиратта, әлбәттә, Тукай исемен атаган. Әмма икенче урынны билгеләү кыенрак булган. Тукайдан соң кемне телгә алырга? Рәмиевнеме, Думавины, Гафурины, Дәрдемәндне ме? (...)

Теге замандагы анкеталарда Гафурины беренче чиратта атаучылар да була. Бу – кызыклы күренеш, чөнки поэтик осталык ягыннан Тукайның үз замандашы Гафуридан алдарак булуы фәндә беркайчан да бәхәс астына алынмады. М. Гафури шул ук вакытта С. Рәмиев һәм Дәрдемәнд шикелле «идеаль поэзия» вәкиле дә түгел. Гафури – халыктан, шәкертләрдән, фәкыйрь крестьяннардан, һөнәрче, эшчеләрдән. Аның шигырьләрендә бәхетсез фәкыйрьләрнең иңрәү авазларын, ачы язмыш ноталарын башка шагыйрьләрнең әсәрләренә караганда ешрак ишетәсең. Халык аһ-зары, халык ыңгырашуы беренче рус революциясе елларында башка шагыйрьләргә караганда Гафурида тиз-

рәк революцион рух алды, «зур агачны» аударырга чакыруга кадәр үсте. Менә бу яктан – политик вакыйгаларга дөрес бәя бирү, кыйбла табу ягыннан караганда – Гафури иҗаты тарихның һәрбер борылышына дөрес юлны башкалар белән чагыштырганда тизрәк табуы белән аерылып тора. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач та нәкъ шулай була.

1913 ел – татар әдәбиятында торгынлык елы. Ф. Әмирхан моны нәкъ шулай, «уңышсызлык елы» дип атады. Тукай юклыгы сизелә. Г. Коләхмәтов, Г. Камал авыру. Г. Ибраһимов Казаннан читтә, зур әсәргә керешкән. Ф. Әмирхан үзе дә бу елда аз яза. Әдәбиятта тынлык. 1914 ел августында Россиянең көнбатыш чикләрендә ярылган герман снарядлары бу тынлыкка чик куя. Моны ничек бәяләргә? Ватанны сакларга дип халыкны чакырыргамы? Татар әдәбияты бит күпме вакытлардан бирле Россия халыклары белән туганлыкны, Ватан уртаклыгын пропагандалап килде. Әллә патша армиясенә җиңелү теләргәме, монарх кулындагы бу армия бит хезмәт ияләренең революцион хәрәкәтен бастыру өчен дә кулланыла.

Ватанны тышкы дошманнан сакларга чакыру темасы әдәбиятны, публицистиканы басып китә. Макулатур «әдәбият» барлыкка килә – барысы да патша хәзрәтләрен, анабыз Ватанны сакларга, Ватан өчен шәһит китәргә өндиләр. Әнә шундый әдәби ташкын эченнән М. Гафуриның әлегә кыюсыз гына авазы ишетелә. Шагыйрь сугыш афәтен бөтенләй көтмәгән яктан килеп тикшерә: ул Аллага мөрәҗәгать итә. Татар әдәбиятында антимилитаристик пропаганданы ул Алланың үзен шик астына алудан башлый.

*Юктырсың ла, Алла! Әгәр булсаң,*
*Сабыр итмәс идең бу эшкә,*
*Бөтен кодрәтеңне баглап куймас*
*Иденң җирдә алтын-көмешкә.*

*Бәндәләрең булды чын бәхетсез,*
*Диннәрең дә файда бирмәде,*
*Тәгълиматың ошбу көнгә чаклы*
*Сәгадәткә[1] ирештермәде.*

*Кодрәтең там[2] булса, бер фәрманың*
*Җитмәс идеме соң тыярга?*
*Чын-чын татулыкны, мәхәббәтне*
*Мәңге урнаштырып куярга?..*

(...) Канкойгыч сугыш фонында, Алланың кодрәтен какшатып, ул кайгы-хәсрәт темасына күчә: тол калган миллион хатыннар исеменнән ул «Сугышта хәбәрсез югалган туганга» мөрәҗәгать итеп шигырь яза. Бу шигырь юлларында бөтен дөньяның ятим солдат аналары, тол солдат хатыннары сөйли. М. Гафури бөтендөнья кайгысы белән кайгыра, бөтенкешелек күз яше белән җылый белә иде. Әнә шул бөтенкешелек җәмгыятенең күз яшьләрен күрү аны эзлекле, интуитив рәвештә сугышның империалистик характерын аңлауга кадәр китереп җиткерә – татар шагыйрьләре арасында беренче чиратта сугышның бу сыйфатын М. Гафури аңлый. (...)

Моннан соң инде Гафури вакыйгалар эзеннән атлый. Февраль революциясендә монархияне бәреп төшерү вакыйгасын ул шатланып каршы ала («Хөррият иртәсе»). Дөрес, шигырен әле ул «Яшәсен чын хөррият!» дигән җөмлә белән тәмамлый. Ихтимал, самодержавиене бәреп төшерүне баштарак шагыйрь «чын хөррият» дип кабул иткәндер. Шундый ук интонация аның «Азатлык хөрмәтенә» дигән шигырендә дә сизелә.

Ләкин бу очракта Гафури – 1917 ел җәенең катлаулы политик атмосферасында да – үзенең кыйбласын тиз таба. Вакытлы хөкүмәтнең сугышны дәвам итү политикасы халыкка нинди «хөррият» әзерләгәнен төшенеп алгач, Гафури поэзиядә турыдан-туры сугышка каршы пропа-

[1] Сәгадәт – бәхет.

[2] Там – тулы.

ганда башлый. «Бетсен сугыш!», «Хөрриятькә каршы торучыларга» кебек шигырендә Гафури канкойгыч сугышны туктатырга кыю рәвештә өнди, чакыра. Әмма шагыйрьне пацифист булган дип уйларга нигез юк: Корнилов фетнәсе мөнәсәбәте белән язылган «Аждаһа» шигырендә ул хезмәт халкын, кулына корал алып, үз иреге өчен сугышка чыгарга өнди.

*Канлы байракларны тәкрар кулга алыйк,—*
*Ул явыз дошманга каршы кузгалыйк,*
*Хөррият җырларыны җырлап барыйк,—*
*Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!*
*Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...*

М. Гафуриның «Кызыл байрак» шигыре татар поэзиясе фондына асылташлардан берсе булып кереп калды. Бу шигырь беренче тапкыр патшасыз уздырылган Май демонстрациясе тәэсире белән язылган. Гафури монда эшчеләр сыйныфының кара көчләргә каршы көрәше символы булган Кызыл байракка гимн җырлый. Бары тик шул Кызыл байракта гына чын хакыйкать, чын ышаныч. Әнә шуңа күрә ул башка һәммә байрактан югары күтәрелгән.

*Әй, Кызыл байрак,*
*Нур бир җиһанга!*
*Әйдә, эшчеләр,*
*Алга вә алга!..*

М. Гафури әнә шулай империалистик сугышны кире кагудан эшчеләрнең революцион көрәшләрен яклау позициясенә килеп чыкты. Октябрь революциясен ул әнә шуңа күрә тарихи барышның табигый бер финалы буларак шатланып кабул итте.

Ил эчендә һәм планетада барган вакыйгаларга мөнәсәбәттә политик сизгерлек Гафуриның Октябрьдән соңгы иҗаты өчен дә характерлы булды. Совет властеның эчке һәм тышкы дошманнарына каршы юнәлтелгән үткен шигырьләре Гафури мирасында бүген дә иң актуаль яңгырашлы әсәрләр булып саналалар.

***

Октябрь социалистик революциясе Мәҗит Гафуриның иҗат чишмәләре өчен искиткеч зур мөмкинлекләр тудыра. Ул киң колач алып проза, поэзия, публицистика жанрларына кереп чума, бераздан үзен драматургиядә сынап карый.

Аның Октябрьдән соң язган күренекле әсәрләреннән берсе – «Тормыш баскычлары» дигән повесте.

Гафури – прозаик, гомумән, үз әсәрләренә, башкалардан аермалы буларак, бик гади исемнәр куя: «Ярлылар, яки Өйдәш хатын», «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» һ.б. «Тормыш баскычлары» да шулай – туры мәгънәгә ия. Бу системадан, ихтимал, «Кара йөзләр» исеме генә бераз аерылып торадыр. (...)

XX йөз башы татар әдәбиятында күзгә ташланып торган бер үзенчәлек бар: язучылар, солдатта булмаган көе, беренче бөтендөнья сугышын узмаган көе, хәрби тормыш, сугыш турында язалар. С. Рахманколый, К. Тинчурин кебек «тыл язучылары»ның сугыш темасына язган хикәяләренә хәрби-стратегик яктан килеп бәя бирә башласаң, әлбәттә, кыен хәлгә каласың. Әмма шинель киеп карамаган бу кешеләр сугыш турында язалар, ялкынланып, пафос белән, детальләр дөреслеген сакларга тырышып язалар, канкойгыч сугышны кире кагалар, гади солдат батырлыгына сокланалар, һәлак булганнарны кызганалар. М. Гафурида да шул хәл. Үзенчә ул да солдат, казарма тормышын, яңа алынган егетләрнең, инде срок тутырган солдатларның эчке дөньясын зур төгәллек белән сурәтли. Күрәсең, художниклык таланты язучының иҗат фантазиясенә ялгыш юлдан китәргә ирек бирми. «Тормыш баскычлары» повестенең реалистик көченең нигезе әнә шундый.

М. Гафуриның Октябрьдән соңгы иҗатында «Кара йөзләр» повесте аерым бер урын алып тора. Идея-эстетик йөге ягыннан чыгып караганда, ихтимал, бу әсәр иң тирән фәлсәфи уйлануларны таләп итә торган әсәрдер. «Кара йөзләр» повесте милли үзенчәлеккә корылган. Хәер, бу

әсәрдә дә без Н. Лесков, А. Н. Островский, Г. Успенский, В. Г. Короленко, М. Горький әсәрләрендә чагылыш тапкан патша Россиясендәге башбаштаклык, кыргыйлыкны күрәбез. Бу яктан килгәндә «Кара йөзләр» повесте шулай ук гомуми әдәбиятның бер кисәге. Сюжетның милли үзенчәлеге исә шуннан гыйбарәт: татарлар яшәгән төбәкләрнең бик караңгы почмакларында «уйнаш»та тотылган егет белән кызны, яки ир белән хатынны, битләрен корымга буяп урам йөртү гадәте булган. Моның бөтенесе шәригатькә нигезләнеп эшләнгән. Чөнки шәригать уйнашта тотылган хатын-кызны, муеныннан җиргә күмеп, таш ыргытып үтерергә рөхсәт иткән. Шәригатьнең мондый кыргый законы белән файдаланучылар булгандырмы, юктырмы, тарихта андый истәлекләр калмаган. Әмма йөзләренә кара ягып урам йөртүләр булган. Башта ук кисәтеп куйыйк: М. Гафуриның бу повестена биргән искәрмәсеннән чыгып («Иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе»), һәр очрашкан егет-кызны йөзләренә кара ягып урам йөртү татарлар арасында массовый күренеш булган икән, дип аңланмасын. Юк, үз хезмәте белән көн күрүче крестьян яшьләре бергә кырда, ындырда эшләгәннәр, өмәләрдә, аулак өйләрдә очрашканнар, сөешкәннәр, хәреф белгәннәре мәхәббәт хатлары язган, кавышканнар, тормыш иткәннәр. Әгәр инде Гафури үзенең Галимәсен «иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе» дип атый икән, моны киңрәк аңларга кирәк: патша Россиясендә татар хатыны шундый хурлыклы, газаплы язмышка дучар ителгән иде ки, корбаннар, чыннан да, миллионнар белән исәпләнерлек иде. Татар хатынын, социаль хокуксызлыктан тыш, әле ислам дине, шәригать, дин-шәригатькә нигезләнгән патриархаль гадәтләр изә иде. Татар хатынына корбан булырга, шулай итеп, сәбәпләр байтак иде...

«Кара йөзләр» повесте үзенең сюжет төзелеше буенча «Тормыш баскычлары» повесте белән охшаш. Мондый нәтиҗә беренче карашка сәеррәк тә яңгырарга мөмкин:

«Тормыш баскычлары»нда бит солдат язмышы, солдат тормышы; «Кара йөзләр»дә исә вакыйга караңгы татар авылында бара һәм авылның бердәнбер матур кызы Галимәнең имгәтелгән тормышы тасвирлана. Ләкин бу – әсәрнең нигезенә алынган материаллар аермасы гына. Авторның идеясе, тенденциясе исә һәр ике әсәр өчен дә уртак: Гафури һәр ике повестенда да үз геройларының кадими мәдрәсәдә башларына төягән чүп-чардан эзлекле рәвештә азат булуларын сурәтли. Беренче очракта – Вахит шәкерт. Аны схоластик мәдрәсәдә кяферләргә каршы җиһад рухында тәрбияләгәннәр иде. Әмма ул шул ук хәзрәтләрнең үзен кяфер патшага турылыклы булырга ант иттерүләрен һәм солдатта вакытта кяферләрнең икенче бер кяферләрне атып үтерүләрен күргәч айнып китә һәм революцион көрәш ягына адым ясый. Икенче очракта исә Гали шәкерт – шулай ук иске мәдрәсә җимеше – үзе ихтирам иткән хәзрәтләр, хәлфәләрнең аның сөекле апасы Галимәне ничек пычратуларын, имгәтүләрен күреп айный башлый; күз алдында булып үткән трагедия аның гына түгел, Галимәнең әти-әнисенең һәм башкаларның да күзен ача.

Кара йөзләр битенә корым ягылган Закир белән Галимә түгел, кара йөзләр – бөтен мәхәлләнең рухи атасы – карт хәзрәт, Галигә сабак бирүче бозык күңелле хәлфәләр, кыргый инстинктлары уянган, шәригатькә сукырларча ышанган надан мужиклар, куштаннар. Алар, кан күргәч, ерткычлык инстинктлары уянып, яшьләргә ташланалар һәм аларның һәлакәтенә сәбәпчеләрнең берсе булалар.

Бу повестьта, алда әйтелгәнчә, Н. Лесков, В. Короленко, Г. Успенский, А. Н. Островский, С. Подъячев, М. Горький иҗатларына хас булган реализмның кыюлыгы, язучының дөреслеккә тугрылыгы күзгә ташлана. М. Гафури бу әсәрендә дә үзенең язу манерасын үзгәртми: ул үз героеның тормышын сәгатьләп, көнләп төгәл тасвирлап бара, кинәт күчешләрдән, күп нокталардан кача, төгәллеккә, пөхтәлеккә омтыла.

Тормышны аңлауга, дөньяга карашларын ачыклауда соклангыч эзлеклелек – Гафури прозасының геройларын берләштерә торган уртак сыйфат.

Вахит, Гали шәкерт, Фәхри бабайларның тормыш баскычлары әнә шундый. М. Гафуриның Октябрь революциясеннән соң иҗат иткән проза әсәрләре арасында «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1929) дигән автобиографик повесте бар. Әсәрдә XIX йөз ахырларындагы татар-башкорт эшчеләренең коточкыч эксплуатация шартларында тир түгүләре, хуҗаларын баету өчен бил бөгүләре тасвирлана. Зур социаль мәсьәләләр куелып та, художестволы гомумиләштерүнең җитеп бетмәве, әлбәттә, бу әсәрнең кимчелеге иде. Әмма бу әсәрендә дә Гафури каләменә хас булган бер күркәм сыйфат алгы планга чыга: ул – түбән катлау вәкилләрен югары әхлаклы, кешелекле сыйфатлар белән сурәтләү. Бу повестьта исә эшче Сибгат – әнә шундыйлардан берсе.

М. Гафури Совет власте елларында үзе яраткан газета-журнал эшендә актив катнаша. 1917–1920 елларда «Ирек», «Безнең юл», «Шәрекъ ярлылары», «Башкортстан» кебек матбугат органнарында Гафури бик күп публицистик мәкалә, шигырь бастыра. Гафуриның әсәрләре, мәкаләләре Татарстан газеталарында да еш басыла («Безнең юл» – «Совет әдәбияты» журналында, «Татарстан» газетасында һ.б.). Шагыйрьнең корреспондент сыйфатында ил буенча йөрүләре нәтиҗәсе буларак язылган шигырьләре дә бар («Себер истәлеге», «Златоуст» һ.б.).

1923 елда киң җәмәгатьчелек Мәҗит Гафуриның иҗат эшчәнлегенә 20 ел тулу уңае белән зур тантана үткәрде. Татар шагыйре хөрмәтенә Совет дәүләте уздырган беренче юбилей иде бу. Юбилей көннәрендә уздырылган тантаналар партия һәм хөкүмәтнең элек изелгән милләтләрнең культурасын үстерүгә никадәр зур игътибар биргәнен күрсәтте. Юбилей көннәрендә Гафурига «Башкортстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде.

Егерменче-утызынчы елларда М. Гафури үзенең бөтен поэтик талантын яңа тормышны мактап җырлауга багышлады. Бу елларда өлкән буын шагыйрьләреннән социалистик тормышка дан җырлаучы иң актив кеше М. Гафури иде. Аның егерменче-утызынчы еллар иҗатында иске тормышка яңа, азат тормышны контраст итеп алу — чагыштыру иң яраткан алымы булды. Үзенең бөтен иҗаты белән Гафури Октябрь казанышларын сакларга, моның өчен берөзлексез хезмәт итәргә чакырды. Үзе исә азат тормыш шатлыгы белән дулкынланып, җиң сызганып, әдәбиятка, культурага хезмәт итте: хикәяләр, повестьлар, поэма, драма, шигырьләр, мәкаләләр язды, ил буенча күп йөрде. Аеруча яратканы — завод-фабрикадагы эшчеләр белән очрашу, яңа эшченең эчке дөньясын өйрәнү максатында алар белән аралашу иде. М. Гафури Октябрьдән соңгы бөтен гомере буенча социалистик җәмгыять тудырган хөрлек, азатлыкка ташланып, сокланып туя алмыйча яшәде.

Әнә шуңа күрә татарлар өчен әлегә зур яңалык булган милли опера сәнгатенең беренче адымнарында композиторлар Солтан Габәши һәм Газиз Әлмөхәммәтовлар нәкъ менә М. Гафурига мөрәҗәгать итәләр. Габәши һәм Әлмөхәммәтовларның беренче хезмәте булган «Сания» операсы турында хәбәр бөтендөнья матбугатын шаулата. Бу, әлбәттә, очраклы хәл түгел. Бөек Октябрь революциясен кабул итмичә чит илгә качкан милләтче ак эмигрантлар «большевиклар милли сәнгатьне бетерәләр» дип, Харбин, Хельсинки, Париж, Истамбул газеталарында гайбәт сатып яткан арада, татарларда беренче милли опера иҗат ителә. Опера сәнгатен тудыру — теләсә кайсы халыкның культура үсеше дәрәҗәсенең күрсәткече. Беренче татар операсы турындагы хәбәрләр Берлин, Рим, Токио матбугатларында басыла. Ак эмигрантларның прогнозлары акланмый. Беренче операны тудыру композиторларны яңа иҗат эшенә дәртләндереп җибәрә. Бу юлы инде сыйнфый юнәлеше, социаль эшчәнлеге ачыграк булган әсәр тудыру турында хыялланалар. Моның өчен М. Гафури-

ның «Эшче» поэмасы кулай табыла. 1926 елның җәендә композиторлар М. Гафури белән сөйләшүләр башлыйлар. Озак та үтми алар очрашалар да. Гафури үзенең поэмасы буенча либретто язарга ризалык белдерә. Шул максатта ул Казанга килә. Бу эшкә композитор Василий Виноградов та тартыла[1]. «Эшче» операсын иҗат итү турындагы мәсьәлә партия, хөкүмәт органнары белән берлектә тикшерелә һәм рәсми төс ала. Ул арада матбугатта, яңа опера тудыру юлында эш башланды, дигән хәбәр дә басылып чыга. Либреттоның нигезенә 1905 ел революциясе чорында татар-башкорт эшчеләренең тормышын, көрәшен алырга тәкъдим ителә. Эшчеләр тормышын өйрәнү, истәлекләр сөйләтү, карт эшчеләр белән очрашу максатында, алар 1928 елда Златоуст заводларына киләләр. Златоуст заводларында, бәхеткә, 1905 ел вакыйгаларын үз башларыннан кичергән карт эшчеләр байтак була. Истәлек сөйләтүләр, йә язып алулар, әңгәмәләр кыза... Газиз Әлмөхәммәтов үзенең булачак герое эшче Нигъмәткә туры килерлек прототип таба. Шул очрашулар вакытында ук инде аерым фрагментлар туа. Моның өчең уңайлык та бар: Г. Әлмөхәммәтов баш герой Нигъмәт партиясен үзе башкарырга җыена. Авторларга бигрәк тә Нигъмәтнең саубуллашу ариясе зур канәгатьлек хисе бирә. М. Гафуриның үзенә хас булган уйчанлык, тыйнаклык, сагышлылык сыйфатлары Нигъмәт образына күчеп, Октябрь революциясенә кадәрге татар эшчесенең колоритлы бай образын тудыра.

*Кай диңгезгә барып төшә икән*
*Ашыгып-ашыгып аккан агымсу.*
*Рәхәт иде бергә торган чаклар,*
*Аерылышу бигрәк ямансу.*

[1] Операның ничек иҗат ителүе һәм сәхнәгә ничек куелуы турында Г. Әхмөхәммәтовның хатыны Мәстүрә ханым Фәйзуллина истәлекләрендә тулы мәгълүмат бар. Кара: Мәҗит Гафури тураһында замандаштары.– Өфө, 1961.– 163–171 битләр.

Дүрт кешелек «берләшмә» бик уңышлы эшли. Композиторлар һәм башкаручы теләгенә буйсынып, Гафури текстларны эшкәртә, төзәтә; Әлмөхәммәтов, татар-башкорт музыкаль фольклорын яхшы белүче буларак, әсәрне халык мелизмнары белән бизи; Виноградов һәм Габәши әсәрнең музыкаль композициясен төзүдә зур осталык күрсәтәләр.

Татарстан АССР хөкүмәте республиканың унъеллык бәйрәмен «Эшче» операсының премьерасы белән билгеләргә карар бирә.

Опера Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә 1930 елның 22 июнендә куела. Уфадан махсус премьерага килгән Гафурины һәм композиторларны һәр пәрдәдән соң көчле алкышлар белән сәхнәгә чакыралар, әсәр шулай зур триумф белән бара.

Сәнгатьнең авыр, катлаулы бер фронтында әнә шулай җиңү яулана. Сәнгатьнең бу төрендә традицияләр булмаган көе социаль эчтәлекле милли опера тудыру М. Гафуриның һәм композиторларның гражданлык батырлыгы иде.

Советлар Союзында культура, әдәбиятның гөрләп чәчәк ата баруына шатланып бетә алмаган Гафуриның гомере кыска була. Шәкерт вакытындагы ачлы-туклы тормыш, шахталарда, приискаларда башкарган газаплы хезмәт, полиция-жандармерия тарафыннан эзәрлекләнү, «язмыш ханым тарафыннан кыйналу» — барысы бергә җыелып, аның сәламәтлеген какшата. Ул 1934 елда нибары 54 яшендә үлеп китә. (...)

*1979, август.*

*Мәһдиев М. Мәҗит Гафури // Сызып ак нур белән...: Шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. — 234–256 б.*

*Фоат Галимуллин*

## Якты идеаллар җырчысы

Мәҗит Нургани улы Гафурины күп еллар буена әдәбиятыбызда иҗтимагый-сәяси мәүзугларга язучы каләм әһеле буларак бәяләп килделәр. Әлбәттә, моңа нигез дә юк түгел. Чөнки аның күпчелек әсәрләре туган халкының авыр язмышына, мәгърифәттән һәм мәдәнияттән читләштерелгән хәлдә яшәвенә борчылу, хәсрәтләнү рухында иҗат ителгәннәр. Ул, сүз дә юк, татарларның нигездә укый-яза белүче, китаплы халык икәнен белә, шуңа горурлана. Әмма халкыбызның мәдәнияткә, мәгарифкә, дөньяви белемгә якын китерелмәве аны ихлас борчый. «Ишан шәкертләренә» дигән беренче шигырендә ул шул хактагы уйларын чагылдыра да. Башлап каләм тибрәтергә ниятләгән егерме өч яшьлек Мәҗитнең караш офыклары шактый тар кебек.

*Исмем Мәҗит, шигырь әйтеп, шигырь язам,*
*Бу заманда татардан аз шигырь язган.*
*Укыган мәктәбем Троицкида,*
*Баралмадык Бохара һәм Кышкар, Казан.*

Моннан күренгәнчә, аңарда әле үзе булмаган Бохара, Кышкар, Казан мәдрәсәләре тирәнрәк белем бирәләр дигән ышану бар. Менә ни өчен ул 1905 елның көзендә Буби мәдрәсәсенә килеп чыга. Инде монда кадәр килгәч, Казанга ук китәргә ниятли. Биредә ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырга тели. Мәдрәсәнең мөдәррисе Галимҗан Баруди (1859–1921) шәхсән үзе аның белем дәрәҗәсен тикшерә һәм гали сыйныфта укырга тәкъдим итә. Мәҗит мондагы укытучылардан аеруча география һәм тарих дәресләре биргән Йосыф Акчураны хөрмәт итә. 1905 елда инкыйлабый күтәрелеш Казанда да көчәя. 17 ок-

тябрьдә патша фәрманы белән халыкка кайбер ирекләр бирелү егетне куандыра, шул уңай белән ул «Милләтемә шатлык» дигән шигырь яза.

*Бу көн кебек шатлык көннәр булыр сирәк,*
*Бу көннең кадерене белмәк кирәк.*
*Кулымыздан богау, зынҗыр алынганда,*
*Кузгалыйк, әфәнделәр, без тизрәк!..*

«Баштан үткәннәр» исемле язмасында әйтелгәнчә, әлеге әсәрне Йосыф Акчура хуплый, яшь авторга тагын да иҗат каләмен шулай тибрәтергә киңәш итә. 1908 елда Төркиягә күчеп киткән Й. Акчура галимлеге, әтрафлы фикерләре, игелекле гамәлләре белән туган илендә абруй казана. М. Гафури да аны хөрмәт белән искә ала. Россия шартларында гаять кысынкылыкта яшәгән татар халкының кулыннан богау, зынҗырны төшерү өчен кузгалырга өндәгән шигырьне хуплап чыккан Й. Акчураның эчке дөньясын аңлау кыен түгел.

Татарлар, гомумән, Россиядәге инкыйлабый хәрәкәтләргә ике максатны күздә тотып кушылдылар: патша хакимлеген юкка чыгару һәм татарларга да тиешле хокукларны яулап алу. М. Гафури иҗатында боларның икесе дә чагылыш тапты.

*Бу заман кузгалганга килде форсат,*
*Бер эздән барча милләт кузгалыр чак.*
*Һич кеше китереп бирмәс, алыңыз дип,*
*Үзебез авыз ачып карап торсак.*

(«Өндәү»)

Шушы шартларда шагыйрь читтән карап күзәтүче хәлендә генә кала алмый.

*Монда шигырь язмаенча булмый чыдап,*
*Ачылды язар өчен безләргә баб.*
*Моңа чаклы күреп торган хәкарәттән*
*Йөзләр сулып, йөрәгебез булды кәбаб.*

(«Бай кеше»)

Шагыйрь күрә: татарлар гына түгел, дөньяның кайсы тарафына күз салсаң да, дин буенча кардәшләребезнең хә-

ле авыр, кимсетүле. «Башка җирләрдәге мөселманнарның хәле» дигән шигырь әнә шул уйлануларга нигезләнгән. Моның асыл сәбәбен ул әле аңлап бетерми, наданлыктан күрә.

*Күп халык хурлык күрә аз халыктан,*
*Тәкъдир, димә, мондый эшләр — наданлыктан.*
*Мөселманның һәр урында кол булуы*
*Кулларында мәгърифәт һәм гыйлем юктан.*
*Буйсынып мөселманнар тик торалар,*
*Ауропалар шуны күреп котыралар,*
*Инкыйяд шул дәрәҗә кямил булды:*
*«Тор!» дисә — тор, «утыр!» дисә — утыралар.*
*Ауропалар һәр тарафка күзне сала,*
*Үз милләте золым күрсә — тиз кузгала.*
*Үзләреннән башка милләт тугрысында*
*Инсаният бер тарафта торып кала.*

Бу шигырь язылганда (1906), татарларның гына түгел, күпчелек мөселман илләренең Англия, Франция, Алмания һәм башка Европа илләре тарафыннан колония хәлендә тотылуы хак иде. Сәяси ирекләре, дәүләтчелекләре булмау фәнни-техник мәсьәләләрне хәл итүгә, гомуми тәрәккыяткә юлны яба.

«Сандугачлар» (1906) шигырендә ул Европа метрополияләрен карчыгага тиңли, бу соңгылары сандугачларны (мөселманнарны дип аңларга кирәк) тоткын хәленә төшергән.

*Һичберсе котылмады Карчыгадан,*
*Үз хәленнән бичаралар үзе надан;*
*Котылмады Сандугачлар һәрбересе,*
*Котылмаган мөселмандай Аурупадан.*

Сүз дә юк, М. Гафурига Россиядәге мөселманнарның хәле якынрак, ул алар турында тагы да ачыныбрак кайгырта. «Беренче Дума ачылды» (1906, 27 апрельдән соң язылган) шигырендә патша хакимиятенең бу демократия уенына ул әле ышана, халыкка җиңеллекләр китерер, дип өметләнә.

*Көтәбез без һәрбер эшне бер Ходадан,*
*Икенче зур өмидләр бу Думадан;*
*Әүвәлге идарәләр начар булгач,*
*Халык булды үзе фәкыйрь, үзе надан.*

Бу шигырь хакимиятләр (цензура) тарафыннан «җинаятьчел» дип бәяләнгән. 26 юллык әсәрнең 1913 елда кабат басылганда беренче 14 юлы гына калдырылуы шул хакта сөйли. Нәкъ менә шуннан соң «әүвәлге идарәләрнең начар булуы», искеләрнең «адәм канын эчү»ләре, «золым белән мәшгуль булу»лары әйтелә. Мондый юнәлешле шигырь авторы, әлбәттә, эзәрлекләнергә тиеш иде һәм ул шулай булды да. Шуның өстенә, ул үзе әйткәнчә, «татар дөньясында хәят юк»лыгы, «тормышның мәгънәсе юк»лыгы хәлне тагын да авырлаштыра иде. Бу һәм башка шигырьләре басылган «Милләт мәхәббәте», «Яшь гомерем» җыентыкларының тарату өчен тыелуы аның хәлен тагын да кыенлаштырды. Бигрәк тә аның «1906 елдан 1907 елга васыять» (1907, 1 гыйнвар), «1907 елның җавабы» (1907, 3 гыйнвар) шигырьләре хакимиятләрнең ачуын кабарта. Аның беренчесендә, күпме тырышып та, «зур агачны тиз аудару» (патша хакимиятен юкка чыгару) бурычының үтәлмәгәне әйтелә. Яңа елга исә шагыйрь болай дип мөрәҗәгать итә:

*Тырыштым бер булсын, дип, ярлы һәм бай,*
*Эш хакын яхшы алсын фәкыйрь малай,*
*Бер мең дә тугыз йөз дә йиденче ел!*
*Иҗтиһад кыйл минем кебек син дә шулай.*

Җиденче ел исә үзенең элгәресенең эшен дәвам иттерергә сүз бирә:

*Сарыф кыйлдың яхшы юлда бик күп көчне,*
*Моннан соң тапшырыңыз безгә эшне.*
*Үзеңезгә бик мәгълүм зур «кеше»гә,*
*Хәл кадәре, батырырбыз үткен тешне.*

«Зур кешегә» дигәндә, сүз дә юк, «патшага» дигән мәгънә аңлашыла. Ләкин болай дип ачыктан-ачык әйтү ул вакытта куркыныч иде. Шуңа күрә М. Гафури аны «күп

кешегә» дип бастыра. 1932 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»дә инде «зур кешегә» диелгән. Әле шул көенчә дә бу әсәр авторга карата җинаять эше кузгатырга нигез була. Матбугат эшләре буенча комитет Казан полиция башлыгына җибәргән хатында Габделмәҗит Гаффуровның (шулай ике «ф» белән язылган) җинаять җыелмасының 1034 һәм 129 маддәләре буенча хөкемгә тартылачагы хәбәр ителә (Кудаш С. Незабываемые минуты. Уфа: Башкнигоиздат, 1962, 197 с.). Шагыйрьнең 1911 елда даими рәвештә полиция күзәтүе астына алынуы, аңа, Уфа шәһәреннән чыгып йөрмәскә, дигән шарт куелуы аның хәлен шактый катлауландыра.

М. Гафуриның барлык иҗатына эпиграф итеп аның «1907 елның җавабы» шигыреннән *«Һәр заман кайгы күрәм татар өчен»* дигән юлын алырга мөмкин. Без бу рухның аның иҗатының буеннан-буена дәвам итүен күрәбез. «Иске җырга кушып...» (ягъни «Тәфтиләү» көенә җырларга тәкъдим итеп) дип исемләнгән шигырендә (1911) ул Идел, Дим, Ак Идел буйларында хуҗа булып, рәхәт гомер кичергән вакытларын сагына.

*Үткән заман безнең, ай, бабайлар*
*Монда туып, монда үскәннәр,*
*Монда гомер итеп, монда йөреп,*
*Бу суларны алар эчкәннәр...*
*Кайда киткән татар-башкортларның*
*Монда йөргән асыл затлары?*
*Кайда киткән икән бу дөньяны*
*Дер селкетеп торган чаклары?*

Мәгълүм булганча, рус тарихчылары татарларны «Идел–Урал буйларына күчеп килгән халык» дип күрсәтә, ягъни аларның җирле кавем булуын таныргa теләми. Шушы ук юнәлешне совет хакимияте чоры тарихчылары да дәвам иттерделәр. Менә ни өчен «Иске җырга кушып...» әсәренең 1917 елдан соң беренче тапкыр М. Гафуриның туусына 100 ел тулу уңаеннан чыгарылган дүрттомлыкта,

ягъни 1980 елда гына дөнья күрүе (1 том, 272–273 бб.) аңлашыла булса кирәк.

Шундый ук язмышка дучар булган шигырьләреннән тагын берсе – «Шәех Шамил рәсемене күргәндә» (1908) әсәре. Ул 1920 елда басыла, әмма укучыларга кабат 1980 елда гына тәкъдим ителә алды. Шамил (1797–1871) – XIX гасырда чечен халкының ирек өчен көрәшенә җитәкчелек иткән шәхес, имам булган зат. Патша тарафдарлары аны бары 1859 елда гына кулга төшерә алалар. Калугага сөрелгән имам берничә елдан хаҗ сәфәренә бару өчен рөхсәт алуга ирешә һәм шул изге юлда вафат була. М. Гафури әлеге тарихи шәхескә олы ихтирам белән карый.

*Бу сирәт, гайрәтең берлә тарихта зур мәкам алдың,*
*Егерме биш сәнә мәйдан тотып, тәхсин мөдам алдың.*

Шагыйрь татарлар арасыннан да шундый фидакарь җаннар чыгуын тели. Кешеләр өчен яшәп, көрәшеп үлүне олы мәртәбә итеп санавын белдерә.

*Син асылда кеше өчен тугансың бит,*
*Кешегә ярдәмче бул һәм хезмәт ит.*
*Тугрысы: кеше чөн ту, кеше чөн тор,*
*Кеше өчен хезмәт итеп, дөньядан кит!..*

(«Нәсыйхәт»)

Күргәнебезчә, «кеше өчен хезмәт итеп, җәзалар күрү»не М. Гафури идеал итеп карый. Әлбәттә инде, үзен дә шушы көрәшчеләр сафында саный. Ягъни үзенә дә шул ук таләпләрне куя.

*Гафури, сән онытма милләтеңне,*
*Сарыф ит ушбу юлда һиммәтеңне.*
*Татарның зилләтен күр һәм намусын әйт,*
*Димә зилләт үзеңнең зилләтеңне.*

(Исемсез шигырь, 1 т., 111 б.)

Шагыйрь үз милләтен ярату аркылы гомумкешелек гуманизмына чыга.

*Ул белә – белми түгел бит: башкалар алтын сөя,*
*Монда ул юк, бу кеше бу дөньяның халкын сөя.*

(«Саф калебле дустым»)

1914 елгы дөнья сугышы башлангач, бу кырылышның гади халыкка һич тә кирәге юклыгын күреп, М. Гафури аңа каршы чыга. Төрле илләрнең идарәчеләре, күрәсең, кешелек хисләреннән мәхрүм ителгән, күңелләре бозылган. «Фитрәт заманы» (1914) шигырендә М. Гафури ул чорга шундый бәя бирә: Җиргә күп пәйгамбәрләр килеп яшәп киткән. Бер пәйгамбәр дөньядан кичеп, икенчесе җиргә килгәнче булган вакытны «фитрәт заманы» дип атау гадәткә кергән. Ягъни, җитәкчесез калу сәбәпле, халыкта бозыклык башлана, кешелеккә хисапсыз афәтләр килә. Бу сугышны да әнә шулай «фитрәт заманы» китереп чыгарган, дигән нәтиҗәгә килә. Чөнки Мөхәммәд пәйгамбәр – соңгы пәйгамбәр. Бүгенге көндә исән-сау пәйгамбәр юк. Шулай булгач, безнең чор, чыннан да, «фитрәт заманы».

*Килде бер «фитрәт заманы» – бетте дөньяның яме,*
*Бер пәйгамбәр дә халыкны тугры юлга өндәми.*

Шул ук мәүзуг «Кыямәт» (1914) шигырендә дәвам иттерелә. Инде фитрәт чоры да үткән, әлеге сугышның дәһшәте кыямәт көненә бәрабәр.

*Чик бирер өчен явызлыкларга килде бу газап,*
*«Калдымы миннән бүтән?!» – ди Тәңре. Шунда юк җавап.*

Сугыш кешегә үлем китерә. Әмма шунысы гаҗәп, берберсен үтерүчеләр моңа кадәр бер-берсен бөтенләй белмәгәннәр. Биредә «кем элек өлгерсә, шул үтерү тиеш» дигән кыргый канун хөкем сөрә. Ник дигәндә, сугыш үзе – шул ук кыргыйлык. Бу инде кеше өчен табигый нәрсә түгел. Сугыш башлануга бер ел тулу көннәрендә язылган «Сугышта хәбәрсез югалган туганга» (1915), соңрак «Ул кем?» (1917) шигырьләре белән М. Гафури шул фикерләрне үткәрә.

*Мин сорыйм синнән хәзер: «Үтереп аны үч кандымы?*
*Син аны чәнчеп үтергәч, дөнья бик киң калдымы?..»*

(«Ул кем?»)

Әмма 1917 елның февраль инкыйлабыннан соң да Россиянең вакытлы хөкүмәте бу сугышны дәвам иттерергә ниятләвен белдерә. Халык исә солых булдыруны таләп

итә. Илдә «хөррият авазы» яңгырый, ә сугышта мылтык, сөңге, туп ядрәсе хакимлек итә. Җаннар кырыла, җир кан белән сугарыла. Моңа чик кую өчен «Бетсен сугыш!..», «Бетсен җиһад!..» дип аваз салырга өнди М. Гафури.

Күрәбез, М. Гафури сугышның буеннан-буена идарәче даирәләр тарафыннан кешелеккә каршы алып барылган сәясәтләрне фаш иткән әсәрләр яза. Шул ризасызлыктан үсеп чыккан «хөррият авазын» хуплый. Шул ук көннәрдә язган «Кызыл байрак» шигырендә ул инде үзенең кемнәр ягында торуын тәмам ачыклаган. Әле генә сугышта кан коелуны «фитрәт заманы» белән тиңләгән шагыйрь өстен катлауларга каршы көрәштә үлүне «хак эш өчен сугышта корбан булу» дип аңлый һәм аны аклый. Ул дөньяны кара һәм кызыл көчләргә бүлә. Кызыл байрак астында көрәшүчеләрнең җиңәчәгенә ышана, халыкны шушы тарафдарлар янына җыелырга чакыра. «Изге юлда» (1919), «Бир кулыңны» (1919), «Гаһед» (1919) һәм башка бик күп әсәрләрендә М. Гафури «Кызыл байрак»та үткәрелгән карашларын тагын да җентекли, үстерә бара. «Сәлам» (1919) һәм «Татар егетенә!» (1919) шигырьләрендә, гаять зур илдә шуралар җөмһүрияте урнаштыру өчен көрәшүче татар егетләренә эндәшеп, аларны тагын да кыюрак, батыррак һәм аяусызрак булырга чакыра.

Шул ук вакытта «Хисап көне» (1917), «Бай абзый» (1919) кебек әсәрләрендә инкыйлабка кадәрге өстен катлау кешеләренең хәзерге көндәге көлкеле хәлләрен сурәтли. «Эшче» (1920) поэмасында хезмәт кешесенең инкыйлабка кадәрге авыр хәлен күрсәтеп бирә. Бу әсәрен ул берничә елдан соң либретто итеп эшләде. Аңа С. Габәши, Г. Әлмөхәммәтов һәм В. Виноградов опера музыкасы яздылар (1930), ул татар сәнгате тарихында икенче опера булып тора. 1921 елгы ачлык уңае белән дә М. Гафури укучыларны тетрәндерерлек шигъри әсәрләр бирде. «Җәннәт көткәндә» (1931) исемле язылып бетмәгән поэмасында исә Сафа байның дөньядагы рәхәт яшәвен ахирәттә дә дәвам иттерергә теләвеннән килеп чыккан көлкеле хәлләрне

сурәтләде. Күрәбез ки, инкыйлабтан соңгы тормышны ихласлылык белән хуплап җырлауны М. Гафури төп максаты итте. Бу аның «Себер истәлеге» (1930) дигән озын шигырендә аеруча ачык чагылды. Элек «Себер» дигәч, сөрген урыны аңлана иде. Хәзер биредә матурлык, иркенлек, хозурлык, ди ул. Андагы төзелешләрнең күплеге шагыйрьне хәйран калдырган.

*Матур Кырымнан да, Кавказдан да*
*Якын күренден син күңелгә...*
*Исән булсам, тагын бер килермен,*
*Хуш бул әле, Себер, хәзергә!..* –

дип тәмамлана ул.

Утызынчы еллар башында илдә корткычлар эзләү, булмаса, аларны «ясау» һәм хөкемгә тартулар көндәлек вакыйгаларга әйләнә башлады. 1930 елда, мәсәлән, бер төркем инженерларны (Промпартия) хөкем итү булды. Алар завод-фабрикаларны элеккеге хуҗаларына кайтарып бирергә омтылуда гаепләнделәр. М. Гафури аларны өнәмичә «Агулы миләрне тикшергәндә» дигән күләмле генә шигырь язды. Аларның баш миендә бары тик безнең илгә дошманлык, ди автор. Шунысы гыйбрәтле, әдәбияттан бөтенләй читтә торган күренешләр турында язганда да М. Гафури Гаяз Исхакый, Фоат Туктаров кебек әдипләргә һәм журналистларга да шактый усал-усал кагылып үтә.

*Пилсудский коралланган көе*
*Баскан ул миләрнең түренә,*
*Шуның янында ук аның лакейлары –*
*Гаяз, Фоатлар да күренә.*

Алай гына да түгел, 1934 елда ул чит илгә китәргә мәҗбүр булган әлеге шәхесләргә шактый усал бәя биргән махсус әсәр яза. Ул «Берегез анда, берегез монда» дип атала. Шигырь камил эшләнмәгән, каралама хәлендә генә. Шулай да аның өч строфасы матбугатта да чыкты (Коммуна, 1934 ел, 18 ноябрь). Кулъязма хәлендә сакланганында мондый строфа да бар:

*Күптән ишеттек без Төркиянең*
*Сезнең күбегезне сөргәнен.*
*«Монда күп лыгырдап йөрмәенчә,*
*Үкчә күтәрегез»,— дигәнен.*

Сүз дә юк, М. Гафури монда хакыйкатькә хилафлык итә. Г. Исхакый, Ф. Туктаров, Й. Акчура һәм башка күренекле шәхесләребез тугандаш Төркия илендә сыену урыны таптылар, бу илнең игелеген тоеп яшәделәр. М. Гафуриның, Г. Исхакыйны тәнкыйть итеп, тагын «Мөселман каргасы», «Гаяз Исхакыйның папа алдында сәҗдәсе» кебек шигырьләр язарга ниятләнгәне дә мәгълүм. «Пролетариат язучысы Афзал иптәш Таһировка» (1934) дигән котлау шигырендә ул бу мәүзугка гомуми рәвештә тагын бер әйләнеп кайта:

*Бик күп язучылар безнең яктан*
*Дошманнарга карап качтылар,*
*Капитал белән тәре яклы булып,*
*Эшчәннәргә сугыш ачтылар.*

Мәҗит Гафури үзенең шагыйрь һәм шәхес буларак ачык карашын «Мин – Ватанчы» (1932) шигырендә туптуры әйтеп бирде:

*Чиксез Ватанчы мин,*
*Совет иле*
*Булу шарты белән ул Ватан,—*

дигән юллар аның Уфадагы кабер ташына да язып куелган.

Беренче нәүбәттә сәяси шагыйрь булса да, М. Гафури кешенең нечкә хисләре, мәхәббәт, табигать турында да язды. Мәсәлән, ул хатын-кызларны чәчәкле гөлләргә, йолдызларга тиңләде. Бигрәк тә бу аның иҗатының башлангыч чорында үзен шактый сиздерә иде. «Сөюдән качу» (1915), «Беренче мәхәббәт» (1915) шигырьләре мәхәббәт хисләрен кичерүчеләрнең оялчан, матур күңелле итеп сурәтләнүләре белән укучыны җәлеп итә.

*Телим, тик әйталмыйм, нәрсәдер шунда мин курыктым,*
*Көчем җыйдым да алдыңда башым идем, кулың тоттым.*

«Вафасыз гашыйк» (ягъни «Вәгъдәсез гашыйк») (1909) шигырендә исә сөешү кебек гаять нечкә мөнәсәбәтләрдә кешенең вәгъдәсезлеге нәтиҗәсендә туган күңел газаплары тасвирлана.

*Ул һаман сөя аны, ләкин ачу катыш сөя,*
*Шул мәхәббәт алдына барып, һаман да баш ия.*

«Янган йөрәк» (1914) шигырендә ул мәхәббәтне бик югары, тәхет дәрәҗәсенә күтәреп куя:

*Чын мәхәббәтнең җиһан тәхтендә булуын мин телим,*
*Сәҗдә итсен шул мәхәббәткә генә янган йөрәк.*

Шул ук вакытта ул татар кызларын, аң-белемнәрен үстерү аша, киңрәк мәйданнарга чыгарырга теләде.

*Йорт эче матурлана һәм нурлана сезнең белән,*
*И татар кызы, бүгеннән соң укы, бел, яз, өйрән.*
*Ушбу көнгә чаклы күрми үстегез укуны да;*
*Тырышыңыз, без тыршабыз: сезнең өчен җаннар фида.*

Мәҗит Гафури – иң әүвәл шагыйрьме, әллә язучымы? Бу сорауга өздереп кенә җавап бирү җиңел түгел. Чөнки ул шигырьләрне һәм проза әсәрләрен бер үк вакытта яза башлый. «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» хикәясе 1902 елда, «Ачлык ел, яки Сатлык кыз» 1906 да, «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» 1907 елда языла. Шул ук елларда аның шигъри әсәрләре һәм публицистикасы да укучыларга шактый еш тәкъдим ителә. Әдип язу өчен мәүзугны түбән катлау кешеләре арасыннан эзли, аларның аһ-зарларын, авыр хәлләрен һәм язмышларын сурәтли.

«Хәмитнең хәяте, яхуд Ләйлә вә хәятем» (1910), «Болгар кызы Айсылу» (1910), «Серле бер мәхәббәтнең тарихы» (егерменче елларда), «Мәхәббәт хатлары» (1912) кебек әсәрләрендә исә шигырьләрендә тасвирланган мәхәббәт хисләре тагын да дәлиллерәк, эпик киңлек белән бирелә. Аларга үз заманында ук битараф калмыйлар. 1909 елда «Шура» журналы чит тел сүзләре кушылмаган саф төрки телдә язылган әсәрләргә ярыш ача. «Болгар кызы Айсылу» нәсере беренчелекне алган өч әсәр арасында була. «Хәмитнең хәяте, яхуд Ләйлә вә хәятем» повесте исә Г. Тукай

һәм Г. Ибраһимовларны бәяләмә язарлык дәрәҗәдә кызыксындыра. Бертөрле тук тормыштан ялыгып, гыйлемле булырга омтылучы яшь егетнең сурәтләнеше ягыннан әсәр Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?» повесте белән дә аваздаш. Г. Тукай болай ди: «Ул язган әсәрләрнең иң яхшысы вә иң тормыштан алып язылганыдыр» («Идел», 1911 ел, 10 май). Г. Ибраһимов та аңа карата «матур гына бер хикәя» дигән фикер әйтә («Йолдыз», 1912 ел, 22 гыйнвар).

«Мәхәббәт хатлары»ның исеме татар әдәбияты өчен ят булмаса да (Харәзминең «Мәхәббәт хатлары» әсәрен искә төшерик) егерменче йөз башы татар егет-кызларының күңел дөньяларын, яшәү рәвешләрен күрсәтеп бирү, хатлар өслүбенең хасиятләрен ачу ягыннан бүгенге һәм киләчәк буын укучылар өчен әһәмиятен беркайчан да җуймас дип уйларга кирәк.

Болардан тыш М. Гафуриның төрле-төрле мәүзугларга язылган «Кара йөзләр» (1923–1926), «Тормыш баскычлары» (1927), «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1930) повестьлары бар. Бу әсәрләр егерменче гасырның туксанынчы елларына кадәр мәктәп һәм башка уку йортларында өйрәнелеп килделәр, аларга игътибар зур булды. Моның сәбәбе, әлеге повестьларда коммунистлар идеологиясенә яраклы яклар булуда гына түгел, бәлки сәнгатьчә эшләнешләренең шактый камил булуларында да. Автор аларны әдип һәм шәхес буларак өлгергәч иҗат итә. Шул сәбәпле повестьлар сюжет оештырылышы, теле, кеше образларын тудырудагы осталыгы белән дә уңай якка аерылып торалар.

«Кара йөзләр» повестенда бер-берсен өзелеп яратучы Галимә исемле кыз белән Закир атлы егет үзәккә куеп сурәтләнә. Ул вакытлар гадәтен сакламыйча, алар мәхәббәтләрен яшереп тормыйлар. Егет белән кызның яратышулары авыл яшьләренә дә мәгълүм. Әмма гашыйкларның бу бәхетен күпсенүчеләр дә бар. Болары әлеге мәхәббәт каһарманнарын әхлаксызлыкта гаеплиләр. Алай гына да түгел, Галимә белән Закирны, бозыклык эшләгәндә тоттык, дип, Сафи хәзрәт хозурына китерәләр.

Дүрт егет ялган шаһитлек бирәләр. Шуның нәтиҗәсендә мәхәббәт каһарманнарын, йөзләрен карага буяп, урам буйлап йөртәләр, мәсхәрә итәләр. Әсәрнең бу ягы аны дингә каршы көрәштә куллану мөмкинлеген бирә иде. Әмма авторның әсәрне язу максаты һич тә бу түгел.

М. Гафури Галимә белән Закирны мәхәббәттә аңлашканнары өчен хөкем итү юлыннан бармый. Аның өчен бу хәлгә бәя бирүдә кешеләрнең икегә бүленүләрен күрсәтү мөһим. Гайнулла, Сәлим, аларга кушылган Сәйфулла белән Гәрәй – әлеге егет белән кызны гаепләүчеләр. Күгәрчен Сәлим, бер җегет дип бирелгән персонаж, Бәдри абзый моңа ышанмаучылар арасында, алар моны «дошманлык белән ягылган бәла» дип карыйлар.

Сафи хәзрәт бу бәхәсләрдә урталыкта тора. Ул икеләнә. Шаһитләрнең күрсәтмәләреннән шәригать хөкемен йөртерлек нигез юк сыман тоела аңа. Чөнки алар капма-каршы гуаһлык бирәләр. Шул ук вакытта хәзрәт – авылда тәртип өчен җавап бирүче кеше. Шуңа күрә, ул: *«...бозыклыкка каршы тору өчен, мондый эшләрне җәзасыз калдырып та булмый, шәригать хөкемен йөртү – безнең бурычыбыз»*,– дип уйлый. Авылдагы җәмәгатьчелек фикере дә (гәрчә ул капма-каршы ике якка аерылган булса да) аңардан тиешле карар көтә. Ягъни хәзрәтнең хәле җиңелдән түгел. Ул, хөкемдә ялгышмас өчен, хәлне мөмкин кадәр дөрес итеп ачыкларга тели. Димәк, хәзрәт хилаф нәтиҗәгә килә икән, моңа иң әүвәл ялган гуаһлык кылучылар гаепле. Галимәнең этисе Фәхри абзыйның кызына карата аеруча каты торуы да хәлне катлауландырып җибәрә.

Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның киеренкелеген бирредә зур төркем кешеләрнең сәламәт булмаган, ягъни бу хәл белән мавыгып китеп, берсеннән-берсе уздырып егет белән кызны гаепләргә омтылышыннан туган психологик мохитнең аерым бер зат – Галимәнең эчке дөньясы белән каршылыгы тәэмин итә. Сүз дә юк, мондый басымга каршы тору җиңел түгел. Закир, егет кеше буларак, мондый

хәлдән җисмән ватылып-кыйналып чыкса да, рухи нык-лыгы сәбәпле, әллә ни бирешми. Галимәнең исә акылына зәгыйфьлек килә, ахырдан һәлак тә була.

Әсәрнең исемен тәшкил иткән «кара йөзләр» дигән бәя кемгә карый? Коммунистлар идеологиясенә нигезләнгән әдәбият белеменең моңа җавабы әзер иде — Сафи хәзрәтләргә. Ләкин автор андый каты хөкем чыгарырга ашыкмый. Егет белән кызның сөйләшеп торуы да гаеп саналган яшәү рәвешен тәнкыйтьләү әсәрдә өстенлек ала. Мондый күренеш гаепләү өчен нигез буларак кабул кылынмаган булса, теге ялган шаһитлек итүчеләр дә хакыйкатькә хилафлык кылмаслар иде. Кешеләрдәге күңел тарлыгы, бер-беренең нинди дә булса өстенлеген өнәмәү дә шуңа килеп кушылгач, Галимә белән Закир кебекләрне эзәрлекләүгә теләсә нинди ялган җитәргә мөмкин икән. Кара максатларына ирешүдә җәмәгатьчелек фикерен ялгыш юлга борып файдалану кебек мәкерлелек бу әсәрдә аеруча калку күренә.

Һәрхәлдә укучы Галимә белән Закирне дә, Сафи хәзрәтне дә «кара йөзләр» итеп санамый. Кара йөзләр — шушы коллизияне оештырган ялганчылар, хөсетле бәндәләр, җәмәгатьчелек фикерен үз максатларында усал ният белән кулланучылар.

Күрәбез, әсәрнең кызыксындыру көче — анда сурәтләнгән хәл-әхвәлләрнең гаять киеренке булуында. Чишелешнең бер якның һәлакәте белән хәл ителүе бу очракта укучыны гаҗәпләндерми. Чөнки әсәрнең нигезендә драма вакыйгасы ята. Шуның өчен Н. Исәнбәт кебек драматургның әлеге хәлне сәхнә әсәре итеп язуы аңлашыла да. Казан, Уфа театрлары аңа берничә тапкыр мөрәҗәгать иттеләр.

«Шагыйрьнең алтын приискасында» дигәндә Дәрдемәнднең (Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең) алтын приискасында дип аңларга кирәк. Әлеге бертуганнарның Урал якларында егермеләп алтын приискалары була. Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыганда, бер ел-

ның җәйге ялында М. Гафури шуларның сигезенчесендә гади эшче булып хезмәт итеп ала. Димәк, монда сурәтләнгәннәр, нигездә, аның үз башыннан кичкән хәлләр. Авыр хезмәт белән көн күрүчеләрнең хәлен бик яхшы белеп язуы шуннан килә. Дөрес, аның (бигрәк тә әсәрнең ахырында) Дәрдемәндкә карата әйткән фикерләре белән бәхәсләшергә дә мөмкинлек бар. Сыйнфыйлык бизмәнен бердәнбер дөрес үлчәү итеп карау аңа Дәрдемәнднең (гомумән Рәмиевләрнең) халкыбызга күрсәткән игелекле хезмәтләрен тәкъдир итәргә мөмкинлек бирмәгән. Сүз дә юк, М. Гафури иҗатына ул яшәгән һәм иҗат иткән елларның үзенчәлегеннән чыгып бәя бирергә кирәк. Кыскача әйткәндә, ул прозада да, аеруча публицистикасында барыбер сәясәтче булып калды.

Моңа һич тә гаҗәпләнергә ярамый. Ул үз чорының бер типик шәхесе иде. Менә шуның өчен аның шәхси идеаллары җәмгыять мәнфәгатьләре белән тыгыз үрелде. Ул шул инануларына, киләчәкне күзаллауларына тугрылыклы булды. Дөрес, бүгенге караш белән бәяләгәндә, аңарда гомумкешелек идеаларыннан беркадәр тайпылуны, эстетик кыйммәтләргә караганда сыйнфыйлыкка өстенлек бирүне дә күрәбез. Әмма ул бу тигезлекнең бер якка авышып китүендә дә ихлас иде.

Ул болай дип язды: *«Һәр эшне эшләдем вөҗдан буенча»*. Бу, чыннан да, шулай иде. Мәҗит Гафуриның шәхесен һәм иҗатын гадел бәяләгәндә вә өйрәнгәндә, моны күрмәү мөмкин түгел. Аның әсәрләренең әһәмияте яңа гасырда да кимеми. Татар халкының үткән олы юлын өйрәнүдә алар яңадан-яңа буыннарга мөһим чыганак булып хезмәт итәрләр.

*2010*

*Галимуллин Ф. Якты идеаллар җырчысы // Мәҗит Гафури: әдип һәм халык язмышы: Мәҗит Гафуриның тууына 130 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары.– Казан, 2010.– 15–27 б.*

*Хатыйп Миңнегулов*

## Татарның олы бер моңчысы

Октябрь инкыйлабыннан соң төзелгән «Башкортстан Җөмһүрияте», гәрчә ул бу исем белән йөртелсә дә, чынлыкта аны Татар-башкорт Республикасы дип атарлык. Чөнки андагы халыкның өчтән берен, ягъни миллионнан артыгын татарлар тәшкил итә. Шунысы мөһим: алар биредә диаспора түгел, ә шушы туфракта, биредәге башкортлар кебек, элек-электән гомер кичергән җирле халык. Мондагы кавемдәшләребез күп гасырлар буе үзләрен милләтебезнең мөһим бер кыйсеме итеп тойган: бер үк телдә сөйләгән, бер үк телдә язган, бер үк моңнарны көйләгән. Башкортстан җирләрендә туып үскән, биредә яшәгән меңәрләгән талантлар гомумтатар рухи мирасына гаять зур өлеш керткәннәр һәм кертәләр. Безнең әдипләребезнең, мөгаен, өчтән бере бу җөмһүрият туфрагы белән бәйләнешледер. Алар арасында Шәмседдин Зәки, Акмулла кебек элегрәк чор шагыйрьләре дә, Г. Ибраһимов, Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Ф. Кәрим, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Ә. Еники, Н. Фәттах, И. Юзеев, Ә. Баян кебек XX йөз әдипләре дә, Р. Гаташ, Р. Миңнуллин шикелле бүгенге каләм ияләре дә бар. Болардан башка татар сүз сәнгатен күз алдына да китереп булмый.

Башкортстан җирлеге, Урал татарлары биргән иң зур әдипләрнең берсе – әлбәттә, Мәҗит Гафури (1.08.1880–28.10.1934). Күңелендә аз гына татарлык чаткысы булган һәр кешегә бу исем яхшы таныш. Аның уй-кичерешләргә бай иҗаты, милли рухлы, инсани эчтәлекле язмалары инде менә гасырдан артык халкыбыз белән бергә яши, аның күңелен нурландыра; берничә буын мәктәп балалары әдип-

неӊ шигырьләрен ятлый, әсәрләрен өйрәнә. Телебезне, милли рухыбызны саклауда, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүдә бу шагыйрьнең роле искиткеч зур. М. Гафуриның әсәрләре инде йөз ел буена басылып тора, аның тормышы, иҗаты хакында да күпләгән мәкалә-хезмәтләр язылган. Болар арасында Г. Тукай, Г. Ибраһимов, С. Кудаш, А. Таһиров, Г. Рамазанов, Ә. Нигъмәтуллин, Г. Халит, Н. Юзиев, М. Мәһдиев һәм башка бик күпләгән зыялыларның язмалары бар. Бу үзе генә дә әдип эшчәнлегенең зур әһәмияткә ия икәнлеген сөйләп тора.

Г. Ибраһимовның мәшһүр «Кызыл чәчәкләр» бәяны «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек» дип башлана. Бу сүзләр М. Гафуриның тәрҗемәи хәленә дә туры килеп тора. Чыннан да, ул гадәти татар авылыннан чыгып, яшәеш-мәгыйшәтнең бөтен мәшәкатьләрен, кыенлыкларын күреп, үз көче, үзенең тырышлыгы белән әдәбият сәхнәсенең түренә күтәрелә.

М. Гафури – ихласи шәхес. Аның тормыш юлы, рухи халәте әдәби әсәрләрендә, геройларының эш-гамәлләрендә шактый дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Өстәвенә, аның «Тәрҗемәи хәлем», «Баштан үткәннәр» кебек автобиографик язмаларында әдипнең гомер юлы шактый тулы һәм үтемле яктыртыла. Шуңа күрә биредә шагыйрьнең тәрҗемәи хәлендәге аерым факт-күренешләрне генә атап китү максат ителде.

Габделмәҗид Нургали углы Гафуров үзенең бер язмасында болай ди: *«Метрика дәфтәре минем 1880 елда туганны күрсәтә. Мин кечкенә чакта әни минем: «Син тары утау вакытында тудың»,– ди торган иде. Шуңа караганда мин 80 нче елның июнь числосында туган булсам кирәк»*. Әмма хәзерге фәндә әдипнең туган вакыты 1880 елның 1 августына нисбәт ителә.

Табигать, тирә-юнь кешенең формалашуына, аеруча иҗат әһелләренең үсешенә зур йогынты ясый. Әгәр дә кечкенә Габделмәҗид олуг Гафури булып өлгергән икән, монда аның кече Ватаны да мөһим роль уйнаган. Әдипнең

туган авылы Җилем-Каран Уфадан көньяк-көнчыгышка таба «җитмеш-сиксән чакрымнар» ераклыкта урнашкан. Гаҗәеп матур Агыйдел, Җилем сулары, Урал таулары, болынлыклар. Күп еллар үткәч тә әдип: *«Табигатьнең иң матур бер урынына ташланган шушы Җилем-Каран авылы минем туган бишегем була инде»*,– дип сокланып яза (IV т., 354 б.).

М. Гафури, Дәрдемәнд, Г. Ибраһимов, М. Әмир һәм татарның кайбер башка мәшһүр затлары да шушындый ямьле төбәктән – элеккеге Эстәрлетамак өязеннән, андагы татар авылларыннан. М. Гафури иҗатында пейзаж, табигать күренешләре, ел фасыллары хакында сәнгати камиллеккә ия булган шактый гына юллар бар. Аларда әдипнең туган төбәге тәэсирен абайлау кыен түгел.

Булачак шагыйрьнең төп йорттагы тәүге еллары, балалык вакыты да чагыштырмача тулы канлы, табигый, бөтен уза. Үзенең «Тәрҗемәи хәлем» әсәрендә ул болай яза: *«Әти Нургани исемендә, әни Марзия исемендә булып, мин ун яшьләргәчә шуларның җылы кочакларында тәрбияләндем. Үз-үземне белә башлаган вакытта әни дә, әти дә исән булу өстенә, Нурислам, Мәһди исемендә ике абзам, Әхсән исемендә бер энем, Фатыйма һәм Сафия исемендә ике апам бар иде»* (IV т., 356 б.). Күрәсез: алты бала. Бу исә, үз чиратында, холыкны тәрбияләүдә, үзара аралашу, ярдәмләшү күнекмәләре булдыруда мөһим роль уйный. М. Гафури әнисенең «бик йомшак күңелле» булуын, әтисенең «сүзгә оста» икәнлеген искәртә. Нургани хәлфә өендә чын мәгънәсендә китап культы яши. «Әбугалисина», «Хатәме Тай», «Сәйфелмөлек», «Тутыйнамә» һәм Шәрыкның, төрки-татарның башка бик күп әсәрләрен тыңларга кичләрен авылның башка кешеләре дә җыела. Мондый «әдәби салоннар»ның үзәгендә, әлбәттә, Нургани хәлфә үзе. Ул күпвакыт «китапны кулына да алмыйча», «яттан гына сөйли». Шулай итеп, уку, китап белән мавыгу Габделмәҗиднең күңеленә бала вакыттан ук сеңеп кала. Шунысын да әйтик: әсәрләре аша, истәлекләрдән әдипнең укымышлы

булуы, аеруча гарәп, фарсы һәм төрки телләрен, әдәбиятларын белүе, казакъ, башкорт фольклорыннан яхшы хәбәрдарлыгы, төрки-татар рухи мирасында балык кебек йөзүе ачык сизелеп тора. Аның үз иҗатында китапны, белем-мәгърифәтне зурлавы, мәктәп балаларын, сабак укучыларны сөеп тасвирлавы да юкка гына түгел. 1909 елда язылган бер шигырендә ул китапны үзенең сердәше, юлдашы, бәхет чыганагы, «атам, анам, балам һәм остазым» дип атый (I т., 151 б.).

М. Гафури шәхесе – укуга, белем эстәүгә омтылышның күркәм бер гәүдәләнеше. Ул, әүвәл, туган авылында – әтисендә, аннан үзләреннән ерак булмаган Үтәш мәдрәсәсендә белем ала. Әмма булачак әдипне болар гына канәгатьләндерми: ул Уфага «Госмания» мәдрәсәсенә килә. Әмма язмыш аны бу шәһәрдән «20 чакрым ераклыктагы» Кыешкыга илтеп ташлый. Биредә шагыйрь 3–4 ай гына укый. 1897–1898 елларда инде Габделмәҗид – туган авылында хәлфә. Үтәштәге остазы Хатыйп хәзрәт киңәше белән ул 1898 елның көзендә Троицкидагы Зәйнулла ишан мәдрәсәсенә («Рәсүлия»гә) юнәлә. Бу уку йортында шагыйрь 7 еллап белем ала. 1905 елгы инкыйлаб җилләре аны яңа мәдрәсәләр, остазлар эзләргә канатландыра: Иж-Бубига килә, әмма андагы мәдрәсәне ошатмыйча, Казанга юнәлә. Биредә ул бер елга якын «Мөхәммәдия»дә укый, Йосыф Акчура кебек атаклы гыйлем ияләреннән дәресләр ала.

Мәгълүм ки, 1906 елда күренекле татар мәгърифәтчесе Зыя Камали (1873–1942) »Галия» мәдрәсәсен нигезли. Бу татар уку йортының даны тиз арада төрки-татар дөньясында киң тарала. Шуның бер нәтиҗәсе буларак, 26 яшьлек М. Гафури да 1906 елның көзендә бу мәдрәсәгә күчеп килә һәм биредә өч еллап укый.

Күрәсез: әдип 30 яшенә кадәр диярлек төрле мәктәп-мәдрәсәләрдә белем ала. Мондый төрлелек, урын алыштыру матди як белән генә түгел, ә шагыйрь табигатенең эзләнүе, рухи канәгатьсезлек белән дә аңлатыла.

М. Гафури иҗатында мәктәп-мәдрәсә тормышының, шәкерт-мөгаллим образларының зур урын алуы да язучының тәрҗемәи хәле белән аңлатыла.

Әдипнең белем алуын, хәзерге кебек, уку йортыннан аерылмыйча уку рәвешендә генә күзалларга ярамый. Уку елы еш кына көз урталарында башланып, апрель айларында ук төгәлләнә. Елның яртысын диярлек шәкертләр үзләре теләгәнчә уздыра. Габделмәҗид тә моннан чыгарма түгел.

Үтәш мәдрәсәсендә уку елларында, ягъни аңа 13—14 яшьләр вакытында, бер-бер артлы әти-әнисе үлеп китә. Моңа кадәр чагыштырмача көйле аккан тормыш тамырдан үзгәрә. Әле буыннары да ныгымаган үсмер Габделмәҗидкә ятимлек шулпасын эчәргә, үз көнен үзе күрергә туры килә. Мәдрәсәдә уку елларында ул җир сөреп, иген дә игә, баерак шәкертләргә һәм мөгаллимнәргә хезмәтче булып та тора, заводларда, алтын приискаларында да эшләп ала, казакъ далаларында хәлфәлек тә кыла... Кыскасы, Идел—Урал төбәгенең төрле җирләрендә булып, төрле шөгыль-һөнәрләрне сынап карый. Болар киләчәктә әдип әсәрләрендәге тормышчанлыкны, тематик һәм географик киңлекне, психологик төрлелекне билгели.

1906 елдан башлап гомеренең ахырына кадәр, М. Гафуриның тормышы ул вакытта Казан, Оренбург кебек татарның мөһим мәдәни үзәкләренең берсе булган Уфа белән бәйле. Биредә ул 1917 елга кадәр бертуган Кәримевләрнең «Шәрык» матбагасында корректор булып эшли. 1909 елда М. Гафури гаилә корып җибәрә. Булачак хатыны Зөһрә белән танышуы хакында әдип болай яза: *«Ятим үсеп, үзенең кул көче белән тегү тегеп, үзен тәрбия иткән эшчән бу кыз шул заманның үзенә күрә ачык фикерле кешесе һәм ару гына укыган да иде. Аның эшчән һәм шулай аңлы булуы минем дикъкатемне җәлеп итте»* (IV т., 474 б.). Зөһрә ханымның татар теле мөгаллиммәсе булып эшләве дә мәгълүм. 1910 елда аларның ир баласы туа. Аңа Әнвәр исеме бирәләр. Күп кенә факт-мәгълүматлар әдипнең Зөһрә ханым белән

бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшәүләрен күрсәтә. Бу гаилә белән якыннан аралашкан язучы Зариф Бәшири (1888–1962) үзенең «Замандашларым белән очрашулар» исемле истәлекләр китабында болай яза: «Мин Мәҗит Гафуриның Зөһрәдән чиксез риза булганлыгын аның үз сүзләреннән генә түгел, Зөһрәнең Мәҗиткә булган мөнәсәбәтеннән дә аңладым... Зөһрә Мәҗит Гафури өчен чын бер иптәш, аның рухын, әдәби зәвыгын күтәрүче һәм аның иҗади хезмәтен аңлый торган ихлас ярдәмчесе иде. Ул Мәҗитне тормыш юлдашы иттереп кенә түгел, иҗат кешесе буларак та хөрмәт итә, аны тәрбияли, юк-бар сораулар белән борчымый, аның уй-фикерен әдәбияттан башка якка юнәлдермәс өчен, юкны бар итәргә, барны тота белергә тырыша иде» (Казан, 1968, 177 б.).

Октябрь инкыйлабыннан соң 1928 елга кадәр М. Гафури типографиядә, татар телендәге газета-журнал редакцияләрендә, җөмләдән, хәзерге «Кызыл Таң» башлангычы булган «Башкортстан» газетасында эшли. Уфада яшәү чорында ул күп мәртәбәләр Казанга килә. Билгеле булганча, 1927 елда композиторлар В. Виноградов, С. Габәши, җырчы Г. Әлмөхәммәтов, либретто авторы М. Гафури белән берлектә, «Эшче» операсын иҗат итүгә керешәләр. Шушы вакытта шагыйрь берничә ай буена Казанда, Татарстанда була. Шулай ук М. Гафуриның Мәскәүдә, Кырымда, Оренбургта һәм башка төбәкләрдә дә булуы мәгълүм.

Башкортстан җитәкчелеге һәм җәмәгатьчелеге татарның күренекле әдибенә һәрчак диярлек игътибарлы булды. Аның әсәрләре оригиналда, башкортчага һәм русчага тәрҗемә итеп кат-кат басылды. 1923 елда ук М. Гафурига, иҗатының 20 еллыгы уңае белән, «Башкортстанның халык шагыйре» дигән шәрәфле исем бирелә. Әдипнең туган районы, Башкорт Академия театры аның исемен йөртә. Билгеле булганча, мәшһүр татар әдибе Афзал Таһиров (1890–1937), 1927 елдан алып шәхес культы репрессиясенә эләккәнчегә кадәр, Уфада җитәкче урыннарда эшли (әүвәл – Башкортстан өлкә комитеты партколлегия-

сенең җаваплы секретаре, 1931 елдан – Башкортстан Үзәк башкарма комитеты рәисе). Бу республиканың язучыларын туплауда, аларның берлеген оештыруда да башлап йөри. А. Таһиров М. Гафурига да тирән кайгыртучанлык күрсәтә. Үз чиратында шагыйрь аңа ихтирами мөнәсәбәтен белдереп, «Пролетариат язучысы Афзал Таһировка» дигән шигырен яза (1934). Анда М. Гафури каләмдәшен һәм дәүләт эшлеклесен «егерме биш еллык» иҗат бәйрәме белән тәбрик итә, аның бай иҗатын, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген югары бәяли (II том, 322–324 б.).

Сүз сәнгатен кечкенәдән үк яраткан Габделмәҗиднең әдәби иҗат белән кайчан шөгыльләнә башлавы төгәл билгеле түгел. Мөгаен, күпләр кебек үк ул да яшьтән үк шигърияткә тартылгандыр. Әмма аның тәүге билгеле әсәрләре чагыштырмача соңрак чорга – XX йөзнең башларына гына карый. Бу вакытта инде М. Гафури – егерме яшен тутырган, шактый белем, тормыш тәҗрибәсе туплаган, кеше буларак өлгергән шәхес. Аның укучыларга билгеле беренче әсәре «Ишан шәкертләренә» дип атала. Автор бу шигырен «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыганда, 1902 елда язып тарата. Әлеге уку йортындагы искелекне, андагы тәртипләрне тәнкыйть уты астына алган бу тезмә шактый ыгы-зыгы, каршылыклар тудыра. Шушы ук елда М. Гафури «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» дигән тәүге чәчмә әсәрен яза. 1902–1903 елларда аның мәгърифәти, дидактик рухлы, тәрәккыятьне зурлаган «Вә иннә мин әш-шигъри ли хикмәтин» («Чыннан да, шигырьдә хикмәт бар»), «Гыйлем», «Себер тимер юлы» кебек шактый күләмле шигъри әсәрләре иҗат ителә. Авторның бу һәм кайбер башка язмалары 1904–1906 елларда Казан һәм Оренбург нәшриятларында аерым китаплар рәвешендә дөнья күрә башлый. Алга таба аның әсәрләре аерым җыентык булып та, көндәлек матбугатта да бер-бер артлы басылып тора. Һәм тиз арада ул күренекле шагыйрь, прозаик буларак таныла. Г. Ибраһимов 1910 елда язылган «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә аны «Тукаевтан кала иң беренче

урынны алган» шагыйрь дип атый (Г. Ибраһимов. Әсәрләр. 5 т.– Казан, 1978.– 6 б.). «Морад» (Ризаэддин Фәхреддин) «Вакыт» гәҗитендә (1906) «Габделмәҗид әфәнде милли шагыйрьләремездәндер» дигән сүзләрне яза (I т., 446–447 б.).

М. Гафури, гәрчә әдәби иҗат эшенә соңрак керешсә дә, бик күп яза, гомеренең ахырына кадәр каләмен кулыннан төшерми. Шагыйрьнең үләренә бер ел кала язган «Гомерем йомгагы» дигән мондый шигыре бар:

*Җыеп караганда, алай бик зур*
*Төсле түгел гомрем йомгагы.*
*Сүтеп караганда, чак күренә*
*Аның бер ягыннан бер ягы* (II т., 311 б.).

Әдипнең мирасы белән танышкач, чыннан да, аның биниһая зурлыгы, «бер ягыннан икенче ягы» «чак күренүе» күзәтелә.

1932 елда Казанда «Мәҗит Гафуриның сайланма әсәрләре» дигән җыентык дөнья күрә. Шушы уңай белән Г. Ибраһимов «Яңалиф» журналында (1933 ел, 2–3 нче саннар) «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» дигән рецензиясен бастыра. Биредәге әсәрләр, ди ул, М. Гафуриның бөтен гомер юлын, иҗатын «чагылдыра». Рецензент китапка уңай бәя бирә. Г. Ибраһимов язмасында «карт шагыйрь» дигән төшенчә мәгънәле. Югыйсә, бу вакытта әле М. Гафурига 53 нче генә яшь. Күрәсең, рецензент, әдипнең яшеннән бигрәк, аның бай һәм күләмле иҗат мирасын, әдәбияттагы дәрәҗәле урынын күздә тоткандыр.

Шунысы әһәмиятле: М. Гафури һәм шигърияттә, һәм прозада бердәй осталык белән иҗат итә. Аның сәхнә әсәрләре дә бар. Мәсәлән, әдипнең Октябрьдән соңгы еллардагы тормышны сыйнфый көрәш, шул чор рухы белән гәүдәләндергән «Кызыл йолдыз» драмасы (1926) Башкортстан Мәгариф комиссариаты оештырган конкурста беренче урынны ала, бераздан театр сәхнәләрендә дә уйнала. Аның хакында Г. Кутуйның 1926 елда язылган махсус рецензиясе дә бар. «Бу 4 пәрдәлек пьеса,– диелә

анда,– киң авыл катлавы, аның революция вакытындагы үзгәреш, көрәшләрен һәм хәзерге еллардагы төзелешен, яңаруын укучы күзенә яхшы, чибәр тел белән сәхнәләштерә...» (II т., 585 б.). М. Гафуриның «Эшче» исемле либреттосы да жанр таләпләрен тирәнтеп тоеп, шигъри-драматик яктан камил тел-стиль белән язылган. Әдипнең «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Үги балалар», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» һәм кайбер башка чәчмә әсәрләрендә дә драмага хас элементлар (персонажларның турыдан-туры үзара сөйләшүләре, репликалар һ.б.) урын алган. М. Гафури, чордашы Г. Тукай кебек, фольклор, мифологик материаллардан да файдаланып әсәрләр яза. Болар арасында аеруча 1910 елда дөнья күргән «Заятүләк берлә Сусылу», «Болгар кызы Айсылу» язмалары кызыклы. Шулай ук әдипнең Йосыф–Зөләйха темасына да мөрәҗәгать итүе мәгълүм. Язучы мирасында публицистиканың, әдәби тәнкыйтьнең дә матур үзенчәлекләре бар.

Әйткәнебезчә, М. Гафури төрле мәдрәсәләрдә укып, төрле остаз-мөдәррисләрдән озак еллар буе белем-мәгълүмат алган, мөстәкыйль рәвештә дә күп гыйлем туплаган. Ул үзенә кадәрге татар әдәбиятыннан яхшы хәбәрдар, Шәрык рухи мирасын да, татар, казакъ, башкорт фольклорын да тирәнтен үзләштергән. Шуның нәтиҗәсендә шагыйрь әдәби иҗатта, аеруча тел-стильдә, шигырь техникасында судагы балык кебек эш итә. Аның әсәрләрендә элеккеге сәнгати традицияләрнең иҗади дәвам ителешенә мисаллар гаять күп. М. Гафури интертекстуаль ысул белән үз әсәрләренә рухи мирастагы күп кенә элементларны, образ-детальләрне кертеп җибәрә, назыйрәләр дә яза, башка чыганакларга, авторларга ишарә-кинаяләр дә ясый. Мәсәлән, ул «Бер татар шәкертенең үз хәленнән зарлануы» (1906) шигыренең һәр строфасын нәкъ «Бакырган китабы»ндагы кебек, «Мин егъламый, кем егъласын?» сүзләре белән төгәлли, билгеле шигъри шәкелгә яңа, заманча эчтәлек сала, шәкертләрне хәрәкәткә өнди:

*Вакыт үтә, вакыт үтә, төрле хәлләр инде йитә,*
*Милләт сездән хезмәт көтә. Мин егъламый, кем егъласын?*
(I т., 68–69 б.).

«Мәмләкәтнең барчасы...» дип башланган парчасын (1907) шагыйрь, нәкъ Акмулланың «Хатимә» әсәрендәге кебек, шигъри үлчәм, строфа төзелеше, рәдиф белән төгәлли. Аның соңгы юллар түбәндәгечә яңгырый:

*Үз эшен баксын үзе татарның милләте,*
*Аһ-зарга алданып йөргән бу милләт булмасын!* (I т., 108 б.)

Шагыйрьнең 1909 елда дөнья күргән «Замана шигырьләре» җыентыгы – Суфый Аллаһиярның (1616–1713) атаклы «Собател гаҗизин» китабын иҗади файдалануның күркәм бер үрнәге. М. Гафури элеккеге әдипләргә генә түгел, үз чордашларының әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә, алардан алынган аерым детальләрне шигырь тукымасына иҗади рәвештә кертеп җибәрә. Г. Тукай үзенең «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» дигән мәрсиясен (1908) мондый юллар белән тәмамлый:

*Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,*
*Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар.*

М. Гафури бу строфаны, бераз үзгәртеп, «Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь»гә (1909) бу рәвешле кертеп җибәрә:

*Телләре югалмадисә, мәңге югалмас татар;*
*Милләт ашдыкча – ашар, милләт яшьдекчә – яшәр.* (I т., 195 б.)

М. Гафуриның элеккеге сәнгати казанышларны яхшы белүе аеруча шигырь системасында, жанрлар куллануда ачык күренә. Аның күпчелек шигырьләре гаруз белән язылган. Шагыйрь бигрәк тә һәзәҗ, рәмәл төрләрен ярата. Шуның белән бергә аның иҗатында, аеруча Октябрьдән соңгы мирасында силлабикага, сөйләм интонациясенә корылган шигырьләр дә шактый. М. Гафури газәл, робагый, мәдхия, мәрсия, мөрәҗәгать, багышлама, хикәя, повесть (бәян), нәсер, истәлек һәм башка бик күп классик жанрлар белән эш итә.

Ул аеруча татар шигъриятендә мәсәл жанрының ныклап үсешенә зур өлеш кертте. Аның «Кәлилә вә Димнә»дән, башка чыганаклардан, тормыштан алынып язылган мәсәлләре элек тә, хәзер дә яратып укыла, зиһенне кузгата, гыйбрәт алдырта. Шагыйрь иҗатында, гомумән, сәнгати табышлар, бүгенге әдипләребезне дә кызыктырырлык шигъри чаралар һәм сурәтләр гаять күп. Мәсәлән, аның «Бер гашыйкның сүзләре» әсәре үзенең шигъри техникасы, образ-детальләре, эмоциональ яңгырашы белән мәхәббәт лирикасының классик бер үрнәге булырлык.

М. Гафуриның әсәрләре идея-тематик яктан киң һәм бай. Аларның исемнәре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Шагыйрь көндәлек тормыш, табигать, яшәү һәм үлем, белем-мәгърифәт, тарих, мәхәббәт, әхлак, бала тәрбияләү, туган җир, Ватан, ил, сәясәт һәм мәгыйшәткә хас булган гаҗәеп күп төрле мәсьәләләр хакында яза. Әмма аларның һәммәсен диярлек үзара ялгый, берләштерә торган бер проблема бар – ул да булса милләт язмышы. Бу мәсьәлә әдипнең бөтен җанын, рухын биләгән, аның барлык яшәеш күзәнәкләренә сеңгән. Татар әдәбиятында, аеруча XX йөз башы сүз сәнгатендә «милләт», «татар» дип язучылар күп. Татарлыкта, миллилектә М. Гафури, мөгаен, күпләрне узып китәдер. Татар атамасы аның кечкенә генә парчаларында да, хәтта аерым строфаларында да берничәшәр мәртәбә телгә алына:

*Ничә йөз ел изелгәнгә татар юаш,*
*Без татарның юашлыгы дөньяга фаш*... (I т., 42 б.).
*Черделәр шунда бик нәфис хәссас*[1] *татарның кызлары,*
*Черделәр шунда татар җегетләре михнәт күреп*. (I т., 371 б.).
*Русияле бер татардыр асыл затым,*
*Габдулла ибне татар – мәшһүр атым*. (I т., 426 б.)

М. Гафури «милләт», «халкым», «туган телем» дип язганда да казакъ, башкорт, чуваш, урысны түгел, ә һәрчак татарны күздә тота, үзен шуның бер вәкиле саный: *«Безнең татар, үгәй бала булганы өчен»* (I т., 65 б.); *«Әле дә шул*

[1] Хәссас – сизгер, хисле.

*тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм, Шул татар теле белән көйлим бирәр көй көйләсәм» (*«Ана теле», I т., 254 б.); *«Милләтләр арасыннан безем татар»* (I т., 404 б.); *«Шигырь язды Габделмәҗид – ибне татар»* (I т., 34 б.) һ.б.

Чын татар авылында һәм гаиләсендә туып үскән, татар мәдрәсәләрендә белем алган, татарча сөйләшкән, фикерләгән, татарча язган Мәҗит Гафури үз иҗатында, иң беренче чиратта, үз халкының мәнфәгатьләрен күздә тотты, аны укымышлы, хөр, алдынгы, әхлаклы, бәхетле итәргә омтылды:

*Йа татар! Вакыт йитте кузгалырга,*
*Мәгариф шәмгыданын[1] кулга алырга,*
*Тәфәккерсез[2], гафил булып[3] карап ятмый,*
*Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!* («Өндәү», I т., 38 б.).

*И татар кызы, бүгеннән соң укы, бел, яз, өрән. Торма бушка! Үгрән инде тәрбия, гыйлем, әдәп.* («Укучы кызга», I т., 79 б.)

Татарларны ярату хисен автор аларны тәнкыйтьләү аша да бирә: *«Бу дөньяда безем төсле фәкыйрь һич җирдә милләт юк»* (I т., 96 б.):

*Татарда «милләт, милләт!» диюче бар,*
*Вәләкин күбебездә юк икътидар[4].*
*Бака кебек коры телдән «бак-бак» итеп,*
*Хур кыйлмаек үзебезне, кыл, зинһар!..* («Инсаф», I т., 53 б.)

*Әй татар, нишләрсең инде, бар телеңне киссәләр?..*
*...Агызыңны көчләп ачып, бер башка телне тыксалар?* (I т., 242 б.)

М. Гафури милләткә, халыкка хезмәт итүне, әдип буларак, үзенең төп вазыйфасы дип саный. Бу мотив аның күп кенә әсәрләрендә гәүдәләнеш тапкан.

---

[1] Шәмгыданын – шәмдәлен.
[2] Тәфәккерсез – уйланмыйча.
[3] Гафил булып – пошмыйча.
[4] Икътидар – көч, ныклык.

*Гафури, син онытма милләтеңне,*

*Сарыф ит ушбу юлда һимmәтеңне*[1]. (I т., 111 б.)

*Безләр, и туган, анадан туган*

*Булырга корбан милләт юлында.* (I т., 113 б.)

Әдип фикеренчә, һәр кеше, иң беренче чиратта шагыйрьләр, үз милләтенең көтүчеләре кебек булырга тиеш. (I т., 98 б.)

М. Гафури – нечкә, йомшак, сизгер күңелле, вөҗданлы, гаделлекне яратучы бер шәхес. Аның бу сыйфатлары иҗатында төп тенденция рәвешендә гәүдәләнеш таба. Әдип фәкыйрьләрне, ятимнәрне, ялангачларны, авыруларны, мөшкел хәлдә калучыларны чын күңеле белән кызгана, үз укучыларын аларга теләктәшлек кылырга, ярдәм итәргә чакыра:

*Дөньяда азмы газапланды минем бу гаҗиз җаным?*

*Азмы сызланды халык хәлен күреп бу вөҗданым?* (I т., 314 б.)

*Кайда ярлы, кайда зарлы, кайда моңлы күп була –*

*Мин шулар янында булам, алар белән килшеп була.* («Мин кайда», I т., 288 б.)

М. Гафури үз халкы өчен генә түгел, авыр хәлдә калган башка кавемнәр өчен дә борчыла. Юкка гына ул: *«Дөньяда тулган мәзлумнарга күзе төшеп, Габделмәҗид шигырь яза аптырагач»*,– дип әйтми (I т., 65 б.). Аурупадагы аерым илләрнең колониаль сәясәте дә, мөселман дөньясының коллыкка төшүе дә аның күңелен әрнетә.

М. Гафури үз халкының да коллыкта, ирексезлектә яшәвен яхшы аңлый, моңа чын күңелдән борчыла, хөрлеккә омтыла.

*Хөр улмай йөргәнемнән үлгән артык,*

*Үземне кара йиргә күмгән артык...*

*...Бу милләтне сәгадәткә чыкармак*

*Минем чөн гарешкә ашканнан артык.* (I т., 65–66 б.)

*Мохитне уйлаган чакта, дисең шунда: «Бәхетсез без,*

*Күңелсез без, эрәтсез без, тавышсыз без, тәхетсез без».* («Күңелсез минутлар», I т., 291 б.)

[1] Һиммәтеңне – тырышлыгыңны.

Милләтнең хокуксызлыгы, халыкның авыр хәле, империалистик сугыш, канкоешлар мантыйкый рәвештә илдә үзгәрешләр булуны таләп итә. Моны, башка бик күп адәм балалары кебек, тормышның үзәгендә кайнаган, яшәешнең бөтен ачысын-төчесен татыган М. Гафури да көтә. Менә илне тетрәткән инкыйлаб-революцияләр башлана. Шагыйрь, бу вакыйгалар милләткә ирек, бәхет китерер, дип ышана. Шуның нәтиҗәсе буларак «Кызыл байрак», «Татар җегетенә», «Мин – ватанчы» һәм башка әсәрләр туа. Яңа чынбарлык, совет идеологиясе, сыйнфый көрәш тәгълиматы М. Гафурины да үз дулкыннары кочагына ала, билгеле бер эчке эволюциягә этәрә. Диндар табигатьле шагыйрь күңелендә атеистик очкыннар да күренә башлый. Кайчандыр үзе олылаган, хөрмәт иткән Гаяз Исхакыйларны да, вазгыятьнең асылын аңламыйча, «фаш» итеп ташлый. Әмма совет чорында да М. Гафуриның матур тел-стиль белән язылган, чынбарлыкны сәнгати югарылыкта гәүдәләндергән, инсани рухлы әсәрләре шактый. Болар арасында «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Тәрҗемәи хәлем», «Эшче» кебек әдәбиятыбызның классик ядкярләре бар. Аларда тормышның төрле яклары, катлаулы язмышлар, инсаннарның холык-табигате, рухи халәте үтемле, тәэсирле итеп күрсәтелгән. М. Гафури яңа җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә дә күз йоммый. 1921–1922 еллардагы ачлыкка мөнәсәбәтле язмалары чор фаҗигасен югары кимәлдә гәүдәләндерәләр.

Мәгълүм ки, яшәеш-мәгыйшәтнең нигезен тәшкил итүче хезмәт, эш кешеләре элек-электән безнең әдәбиятта макталган. Йосыф Баласагунлы шөгыль ияләрен төрлечә зурлый. Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендәге (1342) Фәрһад таш эшен дә сәнгати дәрәҗәгә күтәреп башкара. XVII йөз шагыйре Мәүлә Колый иген игүне иң «гали» (бөек), изге эш, дип саный, игенчеләр тәмуг газабыннан «азад булып, ахирәткә керә», ди.

М. Гафури иҗатында да хезмәт мөһим урынны били. Әгәр дә инкыйлабка кадәрге әсәрләрендә хезмәтнең

михнәти ягына күбрәк басым ясалса, совет чоры язмаларында, яңа җәмгыятькә нисбәтән, эшнең иҗади, куанычлы ягы ассызыклана, хәтта хезмәтнең романтик асылы да күрсәтелә («Төнге смена», «Туры ат белән соры ат», «Нигә эшлиләр?» һ.б.).

*...Уйлап торам-торам, әмма һичбер*
*Җеп-җиңел эш юк ул дөньяда.*
*Эш – мактаулы, авыр булган өчен,*
*Аның матурлыгы шунда да.* (II т., 378 б.)

Яшәеш никадәр генә авыр, катлаулы булмасын, аны нурлый, ямьләндерә, мәгънәләндерә торган бер сыйфат бар. Ул да булса – сөю-мәхәббәт. Бу мотив М. Гафури иҗатында якты бер нур, балкыш рәвешендә килә. Әдип чын мәхәббәт ияләрен, сөю хисләрен төрлечә зурлый, яклый. «Кара йөзләр»дәге Закир белән Галимәнең фаҗигаи мәхәббәте күңелләрне тетрәндерә, аларның карага буялган йөзләре укучы күз алдында акдин ак, пакьдин пакькә әйләнә. М. Гафури бу изге хисне тасвирлаганда элеккеге шигъри казанышларны мул һәм уңышлы файдалана. *«Дөнья сезсез һич төзәлмәс, иң кадерле бәндә сез»*,– ди ул кыз баланы тасвирлап (I т., 79 б.). 1907 елда иҗат ителгән бер газәлен шагыйрь *«Мәхәббәтсез җиһанда тормак улмас, Бу дөньяны тотып торган – мәхәббәт»* дигән юллар белән тәгәлли (I т., 110 б.). Шушыңа охшаш мотив түбәндәге строфада да гәүдәләнеш тапкан:

*Мәхәббәт булмагач, тормышта нинди бер кызык бар соң?*
*Болай булгач, кешенең вәхшидән аермасы нәрсә?* (I т., 287 б.). Алтын Урда чоры шагыйрьләре Котб һәм Харәзми яшәешне мәхәббәт кануннары нигезендә корырга омтылалар. Шул вакытта гына җәмгыятьтә гаделлек, сәгадәт урнашачак. М. Гафури да мәхәббәтне чын мәгънәсендә абсолютлаштыра, хәтта аны җиһан тәхетенә утырта:

*Чын мәхәббәтнең җиһан тәхтендә булуны мин телим,*
*Сәҗдә итсен шул мәхәббәткә генә янган йөрәк (I т., 321 б.).*

Урыны белән татар шагыйре мәхәббәткә, аны егет белән кыз мөнәсәбәтләре белән генә чикләмичә, го-

мумән, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре рәвешендә дә карый.

Үз чорындагы иҗтимагый, сәяси, мәдәни вакыйга-хәлләргә гаять сизгер булган М. Гафури иҗатында конкрет вазгыять, вакыт белән бәйләнмәгән фәлсәфи, әхлакый рухлы язмалар да күзгә ташлана. Алар, ничектер, шагыйрьнең эчке дөньясын, андагы тетрәнү-газапларны, куану-сызлануларны шартлы, йомык хронотопик яссылыкта гәүдәләндерә. Бу төр парчаларда («Мәкъсуд», «Кызык заман», «Яман юлдаш», «Йолдыз», «...гә» («Бетте ул!..»), «Эш», «Бу да калмасын» һ.б.) автор шагыйрь-философ, хикмәт иясе рәвешендә күзаллана. Мәсәлән, «Язмыш...» шигыреннән бер өзек:

*Йөзәбез шаулаган, тау-тау кебек тулкынлы диңгездә,*
*Барабыз зур корабларның арасыннан шулай без дә!..* (I. т., 351 б.).

Аерым затларга багышлап мәдхия яисә мәрсия рәвешендә шигырьләр язу татар сүз сәнгатендә күптәннән килә. М. Гафури да бу традициягә тугры кала. Аның иҗат мирасында дистәдән артык багышлаулар бар. Алар – дәүләт эшлеклеләре (М. Вахитов, В. Ленин, А. Таһиров, Ш. Ходайбирдин...), әдипләр (З. Бәшири, С. Кулибай...), укытучылар (Ф. Сатиев, Һ. Сәгъди...) һ.б. Болар арасында аеруча Г. Тукайга багышланган мәрсия (I т., 310 б.) игътибарга лаек. Ул бөек шагыйрь вафат булганның тәүге көннәрендә үк иҗат ителә. Биредә автор Тукайның бөекләгеен («гали» рухын), һәр татар өчен «сөекле» булуын, аның үлеме зур «кайгы» икәнлеген искәртә, шагыйрьнең күңелләрдә сакланачагын ассызыклый:

*Үлмәдең син: чөнки бу көн һәр татар күңлендә син,*
*Бетмәдең син: һәр кеше сүзендә син, телендә син...*

Мәрсия бик тә мәгънәле, эмоциональ юллар белән төгәлләнә:

*Югалдың – бик зур авырлык, һәммәбезгә син әрәм,*
*Бар кешеләрдән дә артык мин җылыйм, хәсрәтләнәм.*

Бөек Тукай вафатының М. Гафури өчен олы шәхси кайгы да булуы аңлашыла. Чөнки алар – мәсләктәшләр, фикердәшләр, дуслар. Татар язмышы һәр ике шагыйрьнең дә бәгырь түрендә. Билгеле булганча, 1912 елда Тукай Уфага килә. Бер үк халыкның, бер үк татар әдәбиятының ике шагыйре очрашалар, озаклап гәпләшәләр. Бу хакта М. Гафуриның 1914 елда «Габдулла Тукай Уфада» исемле хатирәсе басылып чыга. Язмада никадәр самимилек, үзара хөрмәт бөркелеп тора! (Ә бит заманында Тукай үзенең каләмдәшен берничә мәртәбә тәнкыйть тә иткән.) Үз чиратында Казан кунагы да «Мәкаләи махсуса» исемле язмасында (1912) Уфада М. Гафури белән очрашуларын бик җылы, күңеленә якын итеп яза. (...)

М. Гафури иҗаты – XIX гасыр ахыры – XX йөзнең беренче яртысындагы татар яшәешенең тулы бер энциклопедиясе. Анда илнең, кайбер башка халыкларның тормышы да теге яки бу дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Үзенең биш дистә елдан артык гомерендә әдип инкыйлабларны, төрле сугышларны, иҗтимагый формацияләр алышуны күрә, кичерә, әмма, нинди генә кыенлыклар булса да, үзенең вөҗданына, халкына, иҗатына тугры кала, киләчәккә өмет-ышанычны югалтмый.

*Күпме гамьнәр күрмәдем мин,*
*Күпме яшьләр түкмәдем,*
*Күпме таулар кичмәдем мин,*
*Күпме сулар үтмәдем.*
*Юл авыр булды, шулай да*
*Тик ятып җан түзмәде,*
*Йолдызын, бәхтен табудан*
*Зур өмидне өзмәде* (I т., 295 б.).

М. Гафури – иҗат әһеленә йөкләнгән бөек вазыйфаларны намус белән үтәүнең классик бер үрнәге.

Язучы мирасында аерым җитешсезлекләр, чор белән чикләнгән яклар да бар. Әмма, гомумән, аның иҗаты – һәм идея-тематик, һәм сәнгати яктан бәһаләп бетергесез бер хәзинә. Аның әсәрләре бүгенге укучыны да

дулкынландыра. Әдипнең күңелен телгәләгән күп кенә мәсьәләләр, бигрәк тә милләт язмышы, шәхес тәрбияләү, милли мәгариф һәм мәдәният, сыйнфый тигезсезлек, эчүчелек проблемалары хәзерге көн өчен дә актуаль. (...)

Халкыбыз асылының, татар менталитетының иң төп сыйфатларыннан берсе – моң. Мин бу сүзне көй, музыка кысаларында гына түгел, ә киң мәгънәдә, яшәешкә хас билге рәвешендә алам. Күрәсең, татарның күпгасырлык авыр, газаплы язмышы, ирексезлектә гомер кичерүе аны моңлы-сагышлы иткәндер. М. Гафури – шундый рухи халәтне, моң-зарны сүзләр ярдәмендә гәүдәләндергән татарның бөек бер моңчысы.

*2010*

*Миңнегулов Х. Татарның олы бер моңчысы // Мәҗит Гафури: әдип һәм халык язмышы: Мәҗит Гафуриның тууына 130 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары. – Казан, 2010. – 35–50 б.*

*Равил Рахмани*

## Мәҗит Гафури – балалар шагыйре

Әдәбият мәйданына яңа гасыр башында аяк баскан, ятимлек һәм фәкыйрьлекнең бөтен кимсетүле авырлыгын үз җилкәсендә татып, беренче иҗат адымнарыннан гади хезмәт кешесенең аһ-зарларын «йөрәк бәгъре каны белән» җырларга керешкән, «кайда ярлы, кайда зарлы... шулар янында булам...» дип халык язмышына якын торуны төп иҗат кредосы итеп билгеләгән,

*Бер адым алга басам да,*
*Әйләнәм мин артыма,–*
*Кайда басканнар икән дип*
*Күз саламын халкыма,–*

*(«Үзем һәм халкым», 1912)* дип, бары тик халкы бәхете өчен көрәшеп яшәүне генә иманы һәм кыйбласы итеп таный алган шагыйрь Мәҗит Гафури шаулы Октябрь көннәрен «Кызыл байрак» (1917) исемле революцион рухлы шигырьләр җыентыгы белән каршылый. Татар совет поэзиясенең иң тәүге китапларыннан булган әлеге җыентыктагы «Кызыл байрак» шигырен, олыларга кушылып, ул көннәрдә балалар да кабатлый, алар да «шәһидләр каны буялган», «көчле эшчеләр күтәргән», яңа заманның ымсындыргыч көрәш символын күңелләренә мөмкин кадәр тирәнрәк сеңдереп калырга омтылалар:

*Егылды инде*
*Башка әләмнәр,*
*Җиңелде инде*
*Залим адәмнәр.*
*Әй, Кызыл байрак,*
*Нур бир җиһанга!*

*Әйдә, эшчеләр,*
*Алга вә алга!..*

«Марсельеза», «Варшавянка» җырлары ирекле рәвештә урамга чыккан көннәрдә язылган әлеге шигырь үзе дә тиз арада көйгә салына һәм, революцион гимн булып, фронтларда, урам-мәйданнарда, тантаналы кичәләрдә җырлана башлый[1].

Нәни совет гражданнарының да яраткан декламациясенә әверелгән, аларның күңелен халык бәхете өчен изге көрәшкә рухландырган бу әсәр алтмыш елдан артык татар совет балалар поэзиясенең алгы сафында әйдәүче көч булып торды.

Дөрес, М. Гафуриның нәни укучылары йөрәгенә юл салган беренче шигыре түгел ул. 1905 елгы революция елларында ук инде шагыйрь күп кенә әсәрләрен балаларның турыдан-туры үзләренә атап иҗат итә. Аның табигатьне һәм социаль тормыш күренешләрен тасвирлаган, әхлак һәм тәрбия мәсьәләләренә багышланган шигырьмәсәлләре, хикәяләре «Кызыл байрак» барлыкка килгәнче үк инде татар балалар әдәбияты үсешендә ныклы урын ала.

Шагыйрьнең Беренче рус революциясеннән соң, «һәр җәһәттән хөрриятләр ачылганга» сөенеп, милләтнең күзне йомып йөрү вакыты үткәнлеген, аның, ниһаять, кузгалып, аң-белемгә омтылырга тиешлеген, мәктәпләрнең «һәр бәхеткә ачкыч», «югары мөнәр өчен иң беренче баскыч» булуын аңлатып язган шактый гына шигырьләре мәдрәсә шәкертләре һәм абыстайда сабак тыңлаган кыз балалар арасында зур популярлык казана, аларның күмәкләшеп күңелдән әйтә торган көйле әсәрләре рәтендә йөри:

*Бу нурлы мәктәп! Укыйк күмәкләп,*
*Булаек без шәп, укыйк, шәкертләр!*
*Укыйк, туганнар, укыр заманнар,*
*Бетсен наданнар, укыйк, шәкертләр!*

---

[1] Гафури М. Әсәрләр: Дүрт томда. I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 519 б.

(«Уку», 1907) М. Гафури бу елларда язган шигырьләрендә бигрәк тә хатын-кызларны тигез хокуклы итү, аларга белем бирү кирәклеген күтәреп чыга. Ул гына да түгел, хатын-кызларда шагыйрь, гомумән, милләтебез үсешенең башлангычын һәм алшартын күрә:

*Сезне наданлыкта тоттык, кыйлдык инде тәҗрибә;*
*Без кеше булу өчен сездән кирәктер тәрбия.*

(«Укучы кызга», 1906) М. Гафуриның балалар өчен язган күп кенә шигырьләре туган як табигатенең матурлыгын күрсәтүгә багышланган. Шунысы игътибарга лаек: бу әсәрләрдәге шигърилек еш кына баланың үз фикерләү үзенчәлеге ярдәмендә ачылып китә. Мондый төр тасвирлар, һичшиксез, авторның балалар күңеленә үтеп керү осталыгы хакында сөйли:

*Безнең илләр бик матур һәм бик күңеллегә күрә,*
*Көз киткән бу кошлар яз көне тагын да килә.*

(«Кошлар кайттылар», 1914) Шагыйрь иҗатында үзәк урынны иске тормышның фәкыйрьлеген, ач-ялангачлыгын һәм аның социаль каршылыкларын тасвирлау алып тора. Бу иҗтимагый проблемаларның чагылышы тематикада гына түгел,– алар М. Гафури әсәрләрендәге образдетальләрнең дә төп асылын тәшкил итә:

*Өстендәге киемнәре тузган кебек,*
*Кар белән кара-ала буладыр җир.*

(«Яз фасылы», 1906) Шушы ук эчке сәбәпләр, ягъни тормышның социаль контрастлардан торуын күрсәтү омтылышы шагыйрьне иҗатында яңа жанрга – мәсәлгә алып килә. М. Гафури татар поэзиясендә мәсәл жанрын тернәкләндереп, аңа мөстәкыйль яшәү көче биргән, аны шигъриятебезнең олы үсеш юлына алып чыккан әдип. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, иҗади эзләнүләрендә ул, Тукай кебек үк, башка милләтләр тудырган рухи хәзинәгә, бигрәк тә бөек рус мәсәлчесе И.А. Крылов иҗатына мөрәҗәгать итә. Аның күп кенә әсәрләренә татарча яшәеш бирә, һәм алар, үз чиратында, шагыйрьгә зур поэтик өйрәнү мәктәбе була.

«Гафуриның иҗади тырышлыгы аркасында татар әдәбиятында шигъри мәсәл тулы хокуклы жанр дәрәҗәсенә күтәрелде,– дип яза әдәбият галиме Г. Халит әдип әсәрләренең дүрт томлыгына язган сүз башында.– Аңа иҗтимагый һәм әхлакый әһәмиятле, актуаль эчтәлек салынды. Көнчыгыштан һәм Көнбатыштан килгән традицион мәсәл сюжетлары, геройлары заман рухында, әдипнең төп идея-эстетик карашлары ноктасыннан яңартылды, татар әдәбиятының үз казанышы булып китте»[1].

М. Гафуриның тәрҗемә һәм оригинал мәсәлләреннән «Мәймүн белән күзлекләр» (1911), «Ике чебен» (1911), «Тавык белән Үрдәк» (1912), «Сарыкны кем ашаган?» (1912) һ.б. балалар күңеленә аеруча хуш килә:

*Диде Мәймүн: «Файда юктыр бу күзлектән,*
*Мәҗнүндер – пыяладан файда көткән.*
*Начар күзгә күзлек яхшы,– диләр иде,–*
*Бигрәк тә ялганчы икән моны әйткән...»*

Әлеге мәсәлләрдә шигъри тел дә, бала күңелен яулап алырлык җанлылык һәм драматизм да бар:

*Мәҗлестә Төлке – кятиб, Бүре – рәис,*
*Рәис сүз башлап әйтте: «Бу нинди эш?*
*Аучының Сарыгыны кем ашады? –*
*Танмаенча ушбу җирдә әйтү тиеш».*
*Куян, мескен, куркуыннан калтырады,*
*«Ашаучы мин түгел»,– дип чак әйтә алды.*
*Шөбһәле кеше төсле җавап биргәч,–*
*Барча ерткыч: «Ашаучы шул!..» – дип аваз салды.*

М. Гафуриның күпчелек мәсәлләре, шул рәвешчә, изүчеләр һәм изелүчеләр сыйныфы арасындагы мөнәсәбәтне сурәтләүгә корылган. Автор тәэсирле контраст буяулар ярдәмендә хаклык-хаксызлык, гаделлек-гаделсезлек, шәфкать һәм рәхимсезлекнең асыл сыйфатларын ачып сала. Баланы үзен чолгап алган мохит һәм җәмгыятькә социаль призма аша карап фикер йөртергә өйрәтә.

[1] Гафури М. Әсәрләр: Дүрт томда, I том.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.– 14 б.

Балалар күңеленә революцион көрәш оеткысы сала белгән М. Гафури үзе дә, өч революцияне кичеп, һәм гражданин, һәм шагыйрь буларак зур чыныгу мәктәбе уза. «Чын хөррият иртәсе»н сөенеп каршылаган, татар поэзиясендә беренчеләрдән Кызыл байрак күтәреп чыккан пролетарь шагыйрь булып җитешә. Совет власте елларында ул иҗади эзләнүләрен уңышлы дәвам итеп, балалар яратып укырлык күп кенә яңа әсәрләр бирде. Аның 1921 елда язылган «Урак белән Чүкеч» шигыре шуларның берсе. Биредә автор эшче һәм крестьян союзының какшамас бердәмлеген – реаль чынбарлыкны, аллегорик-шартлы образ ярдәмендә сынландырып, әсәрнең төбендә яткан иҗтимагый-сәяси мәгънәне бер үк вакытта эш кораллары кебек гадәти, сиземле-конкрет һәм Кызыл Байрак сыман гомумиләшкән зур символик тәэсир итү көченә әверелдерә. Әйе, бу берләшү очраклы түгел, аның нигезендә яшәүнең чыганагы – Хезмәт ята. «Йортына барсаң, фәкыйрьлектән бүтән бер нәрсәсе булмаган ярлы халык», шул рәвешчә берләшеп, үзенең чын бәхетен яулап ала.

М. Гафуриның совет чорында язылган шигырьләрендәге нәни геройлар да элеккечә ятим, фәкыйрь, мескен түгел,– алар хөр күңелле, шат авазлы, алар күмәклек көчен, күмәклек бәхетен тоеп, үз ватаннарына җаннары белән бирелгән, аның белән горурлана белгән, киләчәккә тирән ышаныч һәм зур өмет белән караган нык ихтыярлы совет иле балалары.

*Кояш нурын болыт капласа да,*
*Яз язлыгын итә, эретә...*
*Карлар бетеп, кара җир яшәреп,*
*Сандугачлар сайрар көн җитә.*
*Җирнең йөзен, кара чатыр кебек,*
*Кара болыт каплап ятса да,–*
*Яз язлыгын итте, үлән чыкты*
*Көнгә каршы булган бакчада.*

(«Яз!..», 1925) Салкын кара болыт пәрдәсен «нурдан булган кояш җәдрәләренең ертыклавы» һәм, гомумән,

«һәммә караңгылыкның кояш нурларына юл бирүе» әнә шулай балаларның үзләре дә күреп-сизеп торырлык итеп – зур ышандыру көче белән сурәтләнә.

М. Гафуриның балалар шагыйре буларак үзенчәлеген тулырак күзаллау өчен, һичшиксез, аның уңышлары белән беррәттән, иҗатындагы кайбер кимчелекле якларга да тукталып китми булмый. Авторның, әйтик, шактый гына шигырьләрендә әле алынган теманы коры сөйләп чыгу, чынбарлыкны натуралистик формада тасвирлау өстенлек итә. Табигый ки, сәнгать әсәрләренең үзәгендә ятарга тиешле Кеше күңеле исә мондый шигырьләрдә, гадәттә, гомуми фон, коры бер схемадан узмый:

*Инде өлгерде игеннәр – һәр кеше, һәр нәрсә тук;*
*Симерәләр иген ашап каз белән үрдәк, тавык.*

(«Басу», 1914)

*Кырда йөргән көтүдәге сарыгыбыз*
*Безгә оек бәйләр өчен җон җиткерә.*
*Ак сакаллы, озын мөгезле кәҗәбез*
*Көн буенча кырда йөреп сөт китерә.*

(«Безнең терлекләр»)

Бу гомумилек, гади информация бирү белән чикләнү, һичшиксез, турыдан-туры балалар тормышын тасвирлаган юлларга да килеп керә. Әйтик, «Яңгыр» (1914) шигырендә балалар *«зур урам буйлап йөгерешеп йөри»*, «Язгы кояш»та (1908) алар *«иркен-иркен уйныйлар»*, «Көз» (1910) шигырендә *«китапларын тотып мәктәпкә китәләр»*, «Балалар һәм китап»та (1920) исә *«утыралар китап укып, күңел ачып, шатлыкларын бергә-бергә уртаклашып...»* Балаларның әсәрләрдә нәрсә белән мәшгуль булуы да әйтелә, хәтта соңгы шигырьдә «күңел ачу», «көлешү», «кызгану», «уфылдашу» кебек рухи халәткә караган информация дә күпмедер дәрәҗәдә бирелә – әмма без балаларның күңел дөньяларын барыбер тиешенчә конкрет күрә алмыйбыз. Шагыйрь балаларны тышкы бер күзәтүдән чыгып кына бәян итә, алар күңеленә, башлыча, тематик яктан чыгып, гомуми төстә генә якын килә.

М. Гафури үз әсәрләрендә бигрәк тә яшь буынны тәрбияләүгә зур игътибар итә. Аның күпчелек шигырьләре эш яратырга, тырыш һәм түземле булырга, белемгә омтылырга, ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга өндәп язылган. Шагыйрь ялкаулыкны, наданлыкны, кош ояларын туздыруны, урынсыз шаяру һәм балалар арасында очраган башка күп төрле кимчелекләрне тәнкыйть итә. Әмма шигырьдә фикер-идея еш кына гомуми сүзләр аша белдерелә, әсәрдә коры дидактизм, үгет-нәсыйхәт өстенлек ала:

*Бер минут та бушка ятма, алга атларга тырыш,*
*Син шулай итсәң, булыр күңелең рәхәт, җаның тыныч.*

(«Эш», 1914) Кайчак шигырьләрдә педагогик яктан бик үк дөрес булмаган фикерләр дә күренеп куя:

*Зәйнәп эшли кара эш, уку-язу белмәгәч,*
*Инде аңа шулай кирәк, чигү-туку белмәгәч...*

(«Зәйнәп», 1907) Дөрес, бу әсәрләрнең моннан йөз ел элек һәм бөтенләй башка яшәү шартларында язылуын да онытмаска кирәктер...

Ә, гомумән алганда, Тукай тудырган профессиональ татар балалар поэзиясен яңа чорда, яңа социаль үсеш баскычында, яңа шигъри ачкычтагы ноталарга салып – татар совет балалар поэзиясе итеп үстереп алып китүдә М. Гафури иҗаты гаять зур әһәмияткә ия. Балалар шагыйренә нинди зур таләпләр куелганын, киләчәк яшь буынга нинди казанышларны алып барырга кирәклеген М. Гафури Тукай иҗатына карап, мөгаен, бик ачык төшенгәндер. Аның Тукай традицияләренә соң дәрәҗәдә игътибарлы булуын, иҗатында бөек шагыйрь каләме кагылган һәр нәрсәгә артык зур саклык белән якын килүен һәм бу шигъри рухны дәвам итәргә омтылуын бары тик шулай гына аңларга мөмкиндер...

Тукайның М. Гафури иҗатына ясаган тәэсирен без иң элек әсәрләрдәге тематикадан күрәбез. Чыннан да, берберсен хәтерләткән охшаш шигъри парларны бу ике әдип иҗатында табып алуы кыен түгел. Хәер, бу уртаклык, бу

аваздашлык шигырьләрнең тематикасына гына карамый, ә бәлки тасвир детальләре, сурәтләү рәвеше һәм әсәркүләм образлар системасына да үтеп керә. Фикеребезне раслап, әлеге «парлы» шигырьләрдән өзекләр китереп үтик:

*Син шулай итсәң, булыр күңлең рәхәт, җаның тыныч.*
*Якты көннәр, зур бәхетләр эшләгәнлектән килә.*
(М. Гафури, «Эш», 1914)
*Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.*
*Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә.*
(Тукай, «Эшкә өндәү», 1911) Менә М. Гафуриның «Җәй» (1914) һәм Тукайның «Елның дүрт фасылы» (1910) шигырьләреннән өзекләр:

*Төннәр кыскара, көннәр озая,*
*Кояш бик иртә чыгып соң бая.*
*Кешеләр белән басулар тула...*

(М. Гафури)

*Көннәр озая, төннәр кыскара.*
*Бу кайсы вакыт? Йә, әйтеп кара.*
*Халык ашыга, китә басуга.*

(Г. Тукай)

Әлеге аваздашлыкны без «Яңгыр» (1914) – «Яңгыр» (1912), «Ана теле» (1911) – «Туган тел» (1909) шигырьләрендә дә күрәбез. Бу охшашлык М. Гафуриның олылар өчен язган шигырьләрендә дә очрый: «Җыла» (1915) – «Көзге җилләр» (1911), «Сатлыклар» (1911) – «Алтынга каршы» (1907) һ.б., әмма балалар шигъриятендә ул аеруча ачык төсмерләнә һәм, әйтергә кирәк, мондый әсәрләр М. Гафури поэтик иҗатының үзенчәлеген тагын да ачыграк билгеләргә мөмкинлек бирә.

Бу уңайдан, М. Гафуриның «Кошларга» (1920) шигыре белән Тукайның 1909 елда язылган шул ук исемдәге шигырен чагыштырып карыйк:

*Ник качасыз, әй матур кошлар?..*
*Алай сез качмагыз!*

*Сезне без куркытмабыз һәм*
*Таш, агач та атмабыз.*
*Уйнагыз шул бакчаларда,*
*Кич вә иртән сайрагыз;*
*Тик кенә тыңлап торырбыз,*
*Сезгә бер сүз катмабыз.*

(М. Гафури)

*Куркъмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;*
*Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.*
*Куркъмагыз – яхшы беләм, мин һич тә сезне ауламам;*
*Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.*

(Г. Тукай)

Бу ике шигырьдәге охшашлыкка гына түгел, алардагы аерымлыкка да игътибар итегез: Тукайдагы «мин» М. Гафури шигырендә «без»гә әверелә, ягъни индивидуаль герой күмәклек белән алыштырыла. Шулай ук Тукайдагы бала күңеленең психологик кичерешләрен чагылдырган «әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин?!» кебек юллар урынына М. Гафурида дуслыкта яшәүнең матурлыгы турында гомуми информация бирелә һ.б.

Тукай иҗатының М. Гафурига тәэсирен, аларга хас уртаклыкны мондый аваздашлыкларга гына кайтарып калдыру, һичшиксез, мәсьәләне бик тарайтып аңлау булыр иде. Тукай һәм Гафури арасындагы бәйләнешләр күпкә тирәндәрәк ята. Әлеге охшашлыкны гади бер кабатлану итеп кенә карарга ярамый. Моны, барыннан да бигрәк, Тукай иҗатының, Тукай традицияләренең онытылырга тиеш булмаган һәр детален, югалтмыйча үстереп, киләчәк буыннарга тулырак илтеп җиткерү теләге, дип уйларга кирәк. Әлеге омтылышның беренче адымнары Тукай үзе исән чакта ук ясалу бер дә гаҗәп түгел. Тукай талантының тәэсир итү көче чын-чынлап зур була. Әмма шунысын да әйтеп үтәргә кирәк – Тукай талантының бөтен киңлеген һәм тирәнлеген колачлап алу мөмкин түгел һәм, гомумән, Тукайдан соң иҗат итүче шагыйрьләргә (бигрәк тә аның чордашларына) бик үк

җиңел булмагандыр... М. Гафурига килсәк, ул, бөек шагыйрьнең эстетик казанышларын, психологик тирәнлеген иҗатында тулысынча үзләштереп бетерә алмаса да, Тукайның һәм классик әдәбиятыбызның башка бик күп гүзәл сыйфатларын үстереп, аларның лаеклы дәвамчысы булып кала алган.

Нинди сыйфатлар соң алар?

Иң элек – М. Гафуриның Тукай кебек үк халык җырчысы икәнлеген билгеләп үтәргә кирәк. Бу дәрәҗәне ул гомере буена бөтен иҗаты белән раслаган әдип. Аның һәрбер адымын халкы белән бергә атларга омтылып яшәве («Халык һәм мин» шигырен искә төшерик) очраклы түгел – ул, беренче иҗат тәҗрибәләреннән башлап, демократик әдәбият сафына басты, гомеренең соңгы көннәренәчә бөек гуманизм идеяләренә дан җырлады.

М. Гафуриның гаять милли һәм шул ук вакытта зур интернационалист шагыйрь булуын да ассызыклап үтәсе килә. Җаны белән ул милләтнең киләчәген кайгыртып яши. Гомер буена Көнчыгыш, рус һәм Көнбатыш әдәбияты казанышларын өйрәнә, классик һәм халык әдәбияты үрнәкләреннән хикмәтле сүз сәнгате серләрен үзләштерә. Аның татар, башкорт һәм казакъ халык иҗаты аһәңнәренә бай үз шигърияте дә лаеклы төстә күпмилләтле совет халкының уртак хәзинәсенә әверелде.

М. Гафури әсәрләренең гаять тормышчанлыгы һәм реаль җирлеккә таянуы да игътибарны җәлеп итә. Шагыйрь романтик рухта язылган әсәрләрендә дә тормыш чынлыгына һәм реальлеккә тугры булып кала. Халык язмышына якын тору, аның әрнүен үз әрнүе итеп тою (Тукайның «Көзге җилләр»е белән аваздаш «Җыла» шигырен искә төшерик) шагыйрь иҗатының саекмас илһам чыганагы була һәм әлеге аһ-зарлы «җир җырларын» ул «күк җырларын»нан һәрвакыт өстен күрә. Шуңа да аның әсәрләреннән җир һәм тормыш сулышы бөркелеп тора. Русның бөек пролетарь язучысы Горькийның «Гафурида зур әдә-

биятның сулышы сизелә»[1] дип әйтүе дә, беренче чиратта, аның шул сыйфатына бәйледер.

Ниһаять, М. Гафури, Тукай кебек үк, көрәшче-трибун шагыйрь. Ул, беренче иҗат адымнарыннан – 1902 елда «Ишан шәкертләре»н язып, мәдрәсәне ташлап китәргә мәҗбүр булган көннәреннән алып соңгы иҗат сулышынача, туктаусыз «хакыйкатькә таба барган» «туры Тукай» булып кала. Аның өчен халкы алдында гражданин һәм шагыйрь вөҗданын югалтмый көрәшеп яши алу – зур мәртәбәле бер эш булып тоела. Ә белгәнебезчә, М. Гафури яшәгән заманда Тормыш Кеше алдына каршылыкларын да, сынауларын да аз куймаган.

Шагыйрь 1932 елда язган «Утыз ел» шигырендә:

*Утыз ел саклап вөҗдан,*
*Утыз ел сатмадым вөҗдан.*
*Шуны саклар өчен бик күп*
*Авырлыклар күтәрде җан,* –

дип, юкка гына әйтмидер...

М. Гафури утыз елдан артыкка сузылган иҗат гомерендә «берничә стиль ситуациясе кичерә»[2], берничә иҗат методын алыштыра, әмма ул көрәшче шагыйрь буларак үзенә һәрвакыт тугрылыклы кала. Мәгърифәтчелек белән сугарылган беренче шигырьләреннән алып, совет әдәбияты таләп иткән социалистик реализм үрнәкләре әсәрләренәчә бөтен иҗат этаплары аның поэзиядә халыкчанлык, тормышчанлык, гражданлык өчен көрәшеп яшәвенең төрле форма, төрле төсмерләре генә иде. Шагыйрь әсәрләренең публицистик кайнарлыгы, фикер әйтелешенең хикмәтлелеге, образ-сурәтләрнең контрастлыкка һәм антитезаларга тартымлыгы да нәкъ әнә шул көрәшнең конкрет чагылышы түгелмени?! Зур социаль проблемалардан алып, интим характердагы гаилә-әхлак, тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә кадәр булган тематик диапазон-

[1] Юзиев Н. Г. Шигърият дөньясы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 41 б.

[2] Шунда ук.

да М. Гафури үзенең көрәшчелек сыйфатларын җуймый, халыкка дошман көчләр белән генә түгел, үз-үзе белән дә чынлап торып көрәшә белә; башкаларга куелырга тиеш булган таләпләрнең иң кырысын үзенә куя. *«Йөрәк майларыңның бер тамчысы калганчы син янарга тиеш!..»* («Әй, Мәҗит...», 1926) – ди ул, үз-үзенә мөрәҗәгать итеп.

Тукайлардан килгән көрәш рухы иде бу! Һәм, әлбәттә, бу рух турыдан-туры балалар шигъриятенә дә үтеп керде. Әле 1915 елда ук, шактый шау-шу куптарган «Юктырсың ла, Алла!..» шигырен яза. Тукай вафатыннан соң ике ел үткәч, М. Гафуриның Империалистик сугыш фаҗигаләре белән тәэсирләнеп иҗат ителгән бу әсәре, С. Кудаш истәлекләрендә әйтелгәнчә, матбугатта чыкканчы ук, «Галия» кебек дини бер мәдрәсәдә укылып, тиз арада яшьләрнең фикерләрен биләп ала, тойгыларын сискәндерә. Әсәр «үзенең кыюлыгы белән бу көнгә чаклы мондый сүзләрне ишетергә гадәтләнмәгән башларны зыңкытырлык иде... шәкертләр арасында бөтенләй көтелмәгән яңа уйлар, бәхәсләр тудырды»,– дип яза истәлек авторы. Казан, Уфа, Оренбург мәчетләрендә М. Гафурины каргап бәддогалар яудырыла, аны ләгънәтләп, журнал битләрендә мәкаләләр бастырыла[1].

Авторның бу шигырен, Алла барлыгын инкарь итү яисә шикләнү кичерешләрен күрсәтүдән бигрәк (чөнки аның дини карашлары болай дип әйтергә һич җирлек бирми, дин-иманга багышлап язган башка шигырьләре шул хакта сөйли), шагыйрьнең кан-яшь коюны күреп, укучыга фикерен әнә шулай гасабиланып әйтү чарасы дип аңларга кирәк. Шигъри остазы Тукайда да бит ислам әһеленең дини тойгыларына саксызрак килеп бәрелгән, мондый чама чикләрен узгалаган ирекле фикерләү үрнәкләре юк түгел. М. Гафури иҗатында да кайчакта социаль көрәш мотивлары яшь буынны тәрбияләү эшенә әнә шулай, нәкъ үз

[1] Гафури М. Әсәрләр: Дүрт томда. I т.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.– 513 б.

заманы кебек, традицион карашларны шактый ук ватып-җимереп килеп керә.

Һәрхәлдә, татар совет поэзиясе алга таба, М. Гафури иҗаты аша, көрәшче поэзия буларак, үзенең тоткан юлын тагын да конкретлаштыра төшә һәм Октябрь социалистик революциясенә Кызыл Байрак астында килеп керә. Татар совет язучыларының М. Гафурины көрәштәш үз өлкән буын каләмдәше итеп санаулары да бит бер дә тикмәгә түгел.

Татар совет балалар поэзиясенең, беренче көннәреннән үк, ныклы социаль җирлеккә басуында, Тукайлардан килгән халыкчанлык, тормышчанлык, гражданлык традицияләрен саклап, социализм өчен барган көрәш мәйданына чыгуында һәм, гомумән, үзенең социалистик эчтәлекле яңа үсеш этабын башлап җибәрүендә – күргәнебезчә, М. Гафури иҗатының лаеклы үз урыны бар.

*Рахмани Р. Мәҗит Гафури – балалар шагыйре // Мәҗит Гафури: әдип һәм халык язмышы: Мәҗит Гафуриның тууына 130 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары.– Казан, 2010.– 65–75 б.*

*Гульназ Азаматова*

# Общественная деятельность Мажита Гафури в 1907–1916 гг.

В период между революциями 1905–1907 и 1917 гг. творчество и общественная деятельность Мажита Гафури отражали подъём национально-освободительного движения. В 1907 г. в Казани вышел в свет сборник поэта «Милли шигырьләр» (Национальные стихи). Толчком к его созданию стали сообщения от учителей о том, что шакирдам – учащимся мусульманских школ – для чтения во внеурочное время почти нет литературы, которая могла бы пробудить любовь к нации: «Мы нуждаемся в таких стихах и, если возможно, напишите и выпустите их как можно скорее, для детей это было бы полезно»,– писали они.

Мажит Гафури сформировал книгу как пособие внеклассного чтения. В ней были стихи на разные темы: посвященные мектебу (школе), родному народу, воспитательного, нравоучительного характера, о временах года – об осени и зиме, басня «Петух и Соловей».

Многие из них сопровождались предисловием: о чём этот стих, как следует его читать – «в перемену», «по четвергам», «хором». Многие стихи рекомендовалось читать или петь вместе, на определённый мотив, некоторые двустишия выделялись как припев, надписью: «должно произноситься дважды». Предисловия написаны с чувством искренней любви к детям, имеют характер живых обращений к подрастающему поколению. Позволим себе передать перевод некоторых из них близко к оригиналу:

– «Какими бывают воспитанные шакирды? Вы наверно читали об этом в книгах. Я вам о воспитанном ребенке напишу стихами. Попробуйте прочесть!»

– «О том, какими бывают воспитанные дети, я вам написал. А теперь, какими бывают плохие дети, написал на примере ленивого ребенка по имени Гали, вы почитайте и старайтесь не быть такими плохими как он!»

– «Молодые шакирды! Посмотрите, как вас отцы, матери стараются хорошо воспитывать, ради вас готовы перенести все тяжести. Чтобы показать степень их сострадания и милосердия я вам написал о том, как одна благовоспитанная мать будит со сна своего ребёнка».

Сборник Мажита Гафури «Милли шигырьләр» встретили в мектебах как долгожданную книгу, он попал как зерно в благодатную почву. Также большую популярность получила и последующая книга «Шигырьләр» (Стихи), изданная в Казани в 1909 г. Наряду с лирическими произведениями, в ней содержались и революционные, проникнутые любовью к своему народу, его историческому прошлому, призывом к свободе.

В этот период центральные и местные власти развернули борьбу против национально-культурного движения среди российских мусульман – репрессиям подверглись видные мусульманские деятели, закрывались передовые учебные заведения, благотворительные общества. В Уфимской губернии жандармское управление завело «Дело о панисламизме», в поле зрения полиции попали и книги Мажита Гафури. Начальник Уфимского губернского жандармского управления писал 20 апреля 1911 г.: «Во многих мектебах и медресе, особенно где введён «Эсул Джадид» всех учеников обучают петь хором национальные песни, содержащие в себе панисламистические идеи; таких песен насчитывается немного; автором этих песен является Маджид Гафуров, проживающий в Уфе. Представляю при сем две брошюры Гафурова на татарском языке и краткий перевод их, имею честь донести Департаменту

полиции, что мною предположено сделать осмотр всех татарских магазинов на предмет изъятия этих брошюр, а Гафурова подвергнуть обыску, возбудив о нём переписку об охране»[1]. В этом же деле сообщалось о том, что Мажит Гафуров командирован Уфимской губернской земской управой для организации национальных библиотек в уездах.

В этот период Мажит Гафури принял активное участие в работе Уфимского земства в области просвещения мусульманского населения. Весной 1911 г. он вошёл в состав библиотечной комиссии при отделе народного образования губернской земской управы, участниками которой были также известные современники: юрист Ибрагим Ахтямов, депутат I Государственной думы Салимгарей Джантюрин, он же автор словаря «Люгат», кадий Оренбургского Духовного собрания Хасан-Гата Мухамедов, автор «Истории тюрков», имам I-й Соборной мечети Джихангир Абызгильдин. Кроме отбора книг комиссия определяла места открытия библиотек, для которых выбирались населённые пункты с более или менее многочисленным мусульманским населением и с «сознательными муллами».

Основная масса мусульманского населения не имела о земстве никакого представления, поэтому Мажит Гафури стремился просветить население, чтобы оно получало практическую пользу от земских мероприятий. В газете «Йолдыз» в декабре 1911 г. писатель поместил статью «Уфимское земство», а в двух номерах 1912 г. обширную работу «Что такое земство?»[2]. Последнюю в виде отдельной работы губернское земство отпечатало в типографии товарищества «Каримов, Хусаинов и К°». В книге на доступном татарском языке подробно разъяснялась деятельность земства, порядок выборов гласных в земские собрания и управы, формирования земской казны и т.п. Отдельное внимание М. Гафури уделил описанию земских

[1] ЦГИА РБ. – Ф.181. – Оп.1. – Д.412. – Л. 213.

[2] Гафури М. Что такое земство? – Уфа,1912.

мероприятий в области медицины, агрономии, ветеринарии, организации дорожного строительства, почты и противопожарных мер. В заключении писатель подчеркивал, что мусульмане до сих пор не получали должной пользы от земств и на то могли быть разные причины (прежде всего, ограниченное представительство нерусских гласных в земских собраниях и управах, что вытекало в свою очередь из дворянского характера земств.– Г.А.). Вместе с тем, многое зависело и от самих мусульман,– говорил автор,– привычка относиться к посторонним начинаниям с опаской, недостаточная информированность, равнодушие и неумение различать происходящие вокруг дела служили главными причинами того, что они оставались в стороне от общественных дел, в том числе земских. Действительно мусульманское население долгое время было привержено традициям культурного изоляционизма, что позволяло сохранять религию, культуру и обычаи, ограждало от ассимиляции и христианизации. К началу XX века джадидским движением была создана почва для приспособления общества к происходящим социально-экономическим и культурным изменениям. Мажит Гафури писал, что время страха прошло, и призывал народ идти в ногу со временем, не отставать от происходящих вокруг перемен. В отзыве, помещенном в оренбургской газете «Вакыт» (июнь, 1912 г.), говорилось, что книга Мажита Гафури эфенди «очень полезна для населения», освещалось её содержание и высказывалось пожелание распространения подобных изданий в Оренбургской губернии в связи с ожидаемым введением земства. О выходе книги М. Гафури сообщала также газета «Пермская земская неделя» в заметке «Книга о земстве на татарском языке». Уфимская губернская управа разослала книгу «Что такое земство» в качестве подарка в мусульманские приходы во время земского обследования мусульманских школ в 1912 г. В ответ управа получила многочисленные отзывы имамов и мугаллимов (учителей), которые благо-

дарили за нужную книгу и просили земство продолжать подобные издания.

Мажит Гафури поднимал и проблему распространения в народе популярных земских изданий. Уфимское губернское земство с 1897 г. выделяло некоторую сумму на издание брошюр на татарском языке. Как отмечал служащий губернской земской управы П. Н. Григорьев в 1910 г., дело двигалось «в высшей степени слабо». Причинами были как отсутствие специалистов и целенаправленной работы, так и огромная дистанция между мусульманским населением и земскими начинаниями. В статье «Полезные книги для народа и земство», опубликованной на страницах «Йолдыз» в 1912 г. писатель убеждал читателей, что для сельского населения самыми полезными книгами являются практические книги о земледелии, садоводстве, животноводстве и других отраслях сельского хозяйства. Мажит Гафури критиковал приверженность деревенского народа лубочной литературе для «успокоения души», позицию мулл, отказывающихся от земских изданий. «Сегодня в народе чувствуется внимание к чтению. Настало время посмотреть на нашу жизнь и написанные о ней книги с практической точки зрения. Тогда подобные издания будут больше распространяться земством бесплатно»,– писал автор. К 1915 г. губернская земская управа выпускала 32 наименования брошюр на татарском языке по санитарии, сельскому хозяйству и народному просвещению. Они посвящались насущным и злободневным темам: «Как вести дела кредитного товарищества», «Кредит и общество потребителей», «Пчеловодство», «Как передаются заразные болезни», «Глазные болезни и как от них предохраняться», «О чахотке», «Холера» и др.

В ходе развернувшейся работы по внешкольному образованию, изданию народной литературы и учебных пособий чувствовалась необходимость в компетентном знании языка, поэтому губернская земская управа 1 апреля 1914 г. объявила конкурс по составлению особого словаря. Ав-

торам лучшего Словаря непонятных слов по всем отраслям знания, вошедших в литературный татарский язык из арабского, персидского, русского и др. языков выделялась премия размером 450 рублей. Однако по ходу рассмотрения проблемы земство решило вести работу не на конкурсных условиях, а поручить её определённым авторам. Ими стали Мажит Гафури, Сагит Рамеев и Джамалетдин Валидов, словарь увидел свет в 1916 г.

Мажит Гафури принял участие в организованном Губернской земской управой в июле 1915 г. областном совещании для просмотра учебников начальных русско-инородческих школ. В списке участников значилось 25 человек из Уфимской, Оренбургской, Казанской губерний, среди них: Мухутдин Курбангалиев – учитель русско-татарской школы в Казани, член редакционной коллегии журнала «Магариф», Нургали Надеев – учитель русско-татарской школы в Оренбурге, Фатих Сайфуллин (Сайфи-Казанлы) – учитель-мугаллим в Казанской губернии, Халим Искандеров – мугаллим в Троицке, Ахтямов Хабибулла – вероучитель мужской гимназии и реального училища в Уфе, Бадигов Ходжа – фольклорист, мугаллим в Казани, Мирсаид Султангалиев – учитель Стерлитамакского уезда, Сагит Сунчалеев – учитель Осинского уезда Пермской губернии, а также другие. В качестве «сведущих лиц» пригласили Мажита Гафури и Галимжана Ибрагимова, представителями от земства были заведующие инородческим образованием губернских земских управ Гумер Терегулов (Уфа), и Ибрагим Бикчентаев (Оренбург, он же мугаллим медресе Хусаиния). Члены совещания являлись высокообразованными специалистами, знатоками в области языкознания и педагогики, многие из них – авторы известных учебников. Комиссия рассмотрела книги на русском и татарском языках 63 авторов, заслушала 112 докладов. Совещание явилось первым опытом критического разбора национальных учебников. Назовем лишь некоторые из обсуждавшихся работ: «Татар алифбасы» (Та-

тарская азбука) Гибадуллы Алпарова, «Тел ачкычы» (Ключ языка) Хасана Гали, «Татар алифбасы» (Татарская азбука), «Татарча уку» (Чтение по-татарски), «Дөнья» (Мир) Мухутдина Курбангалиева, «Яңа кыйраэт» (Новое чтение) Габдуллы Тукая, «Белек йорты» (Дом знания) Халима Искандерова, «Татар теле дәресләре» (Уроки татарского языка) Сайфи Фатиха-Казанлы, «Яңа әдәбият» (Новая литература), «Татар сарыфы вә татар нәхүе» (Татарская морфология и синтаксис) Галимжана Ибрагимова и др.

Проблема обучения мусульманского населения в рассматриваемый период была одной из наиболее злободневных для общественности. В печати активно обсуждались вопросы реформирования национальных учебных заведений, приспособления русско-инородческих школ к культурным запросам населения, подготовки учителей. Многие выступления Мажита Гафури на страницах периодической печати были посвящены этим вопросам.

Статья «Дарелмөгаллимин мәсьәләсе» (Проблема учительской школы) была опубликована в «Йолдыз» (1913). Автор отмечал, что от подготовки учителей зависит будущее народа, только хорошо подготовленные мугаллимы смогут вести его по пути прогресса. Поэтому самым нужным учебным заведением, занимающим достойное положение должна стать учительская школа. Статья «Авылларда мәктәп вә школа» (Мектебы и школы в деревнях), опубликованная в газете «Вакыт» в 1915 г., сравнивала роль мектебов и школ в формировании подрастающего поколения. В ней автор писал о том, что, несмотря на распространение государственных школ, их хорошую материальную базу, население остается приверженным национальным мектебам, которые содержит своими силами. По словам Гафури, школа не смогла дать нужной пользы народу, поскольку обучение в ней было основано не на родном языке и выпускники по окончании теряли приобретённые знания, не имея возможности повышать свой уровень. Те, кто понимал необходимость русского языка,

считали, что изучать его нужно с помощью материнского языка, на котором должно строиться обучение в начальной школе, писал автор[1].

Творческая и общественная деятельность Мажита Гафури отражала животрепещущие проблемы современности, вносила свой вклад в развитие общественной мысли и национально-культурного строительства башкирского и татарского народов.

*Азаматова Г. Общественная деятельность Мажита Гафури в 1907–1916 гг. // Мәҗит Гафури: әдип һәм халык язмышы: Мәҗит Гафуриның тууына 130 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары.– Казан, 2010.– 85–91 б.*

[1] Статья опубликована с сокращениями: Авылларда мәктәп вә школа // Гафури М. Сочинения. Башкирское книжное издательство.Т.6.– Уфа, 1957.– С. 95–98.

*Радик Хөснетдинов*

## «Шура» журналы һәм Мәҗит Гафури

Танылган татар әдибе, шагыйрь Мәҗит Гафуриның XX гасыр башы «Шура» журналында уздырылган «Кәлям мөсабәкасы – Тел ярышы»нда җиңүче булуы мәгълүм. «Шура» журналында әдипнең ике хезмәте: «Болгар кызы Айсылу» хикәясе һәм бүгенге көн вазгыятендә дә актуаль булган «Чуар тел» мәкаләсе басыла.

XX гасыр башында беренче татар газетасы булган «Нур»да (1905. 2.09.– 1914) басманың мөхәррире Гатаулла Баязитов тарафыннан «Газета мәкаләсен ничек языйк?» дигән сорау күтәрелә. Бу сорауга дин галимнәре, мөхәррир, әдип, мөгаллим, шәкертләр һ.б. кешеләр газета идарәсенә җавапларын язып җибәрәләр. Г. Баязитов ассызыклаганча, укучыларның күпчелеге, беравыздан, «газетага дигән мәкаләне үзебез сөйләшә торган, үзебез аңлый торган тел белән генә язарга кирәк» дигән төп бер нәтиҗәгә киләләр. Димәк, газетага дип язылган мәкаләнең телен төрлечә яза торган әдипләрнең язма теле белән чагыштырып кына түгел, бәлки тулаем җанлы сөйләмә телнең үзенчәлеге мөнәсәбәтендә дә билгеләргә кирәк була. Менә шушы катлаулы мәсьәлә хакында фикер алышу, «милләтне гыйлемле вә мәгърифәтле итмәк» максатын күз уңында тотып, мәшвәрәт – киңәш мәҗлесе буларак басыла башлаган «Шура» журналы битләренә дә күчерелә һәм тагын да көчәебрәк дәвам итерелә. «Нур» газетасында «Әдәби телемез нә делдер?» дип башланган фикер алышу уңаенда, күпчелек укучылардан, газетага дигән мәкаләләрне фәкать үзебез сөйләшә торган тел белән генә язарга кирәк, дип җавап алынгач, бу хәлнең тормышка ашмаячагын яхшы аңлаган Р. Фәхретдиннең (1859–1936)

»Игълан»ы белән «Шура» журналында 1909 елның август аенда «Кәлям мөсабәкасы – Тел ярышы» башланып китә. Игъланның асылында: «...40 йулдан аз вә 60 йулдан күб улмаз шарты илә, нә тугърыда улса да улсын, һичбер чит сүз катыштырмай, халис вә саф төркичә бер мәкалә йазмакдан гыйбарәтдер»[1], ягъни язганнардан «...Теләсә нәрсә турысында, бернинди дә чит сүз катыштырмыйча, чиста-саф төркидә бер мәкалә язып, Идарәгә җибәрергә» кирәклеге аңлашыла.

Шушы эксперимент ярдәмендә мөхәррир Риза Фәхретдин «нә тугърыда улса да улсын, халис вә саф төркидә» язып булмасын башкаларга да исбат итәргә тырыша.

«Кәлям мөсабәкасы» барган дәвердә (1909–1911) «Шура» идарәсенә 72 мәкалә килә. Тик шушы мәкаләләрнең күбесе, мөхәррир куйган шартка туры килмәве, ягъни күпчелек мәкаләләрдә күп сүзләрнең саф татар телендә булмавы ачыклана. Килгән мәкаләләрне тикшерергә педагог, телче-фольклорчы галим, Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте Хәсән Гали (1878–1940)[2] алына. Аның тарафыннан тикшерелгән һәр мәкалә диярлек тәнкыйтькә алына, һәрберсендә диярлек бер үк хата – авторларның үз мәкаләләрендә чит сүзләр кулланган булуы ассызыклана. Тик шагыйрь Мәҗит Гафури тарафыннан язылган «Болгар кызы Айсылу» хикәясенең генә, тәнкыйтьче Хәсән Гали белдергәнчә: «...Бу мәкалә 72 мәкаләнең эчендә иң ләззәтлесе, иң рухлысы вә иң шигъри язылганыдыр; шуның өчен барчасыннан галидер»[3], булуы ачыклана.

**«Болгар кызы Айсылу**

*Айсылу, күзләремнең алдында чәчәкләрдән укмашкан бер уч чәчкә кеби күренеп, күз каравы белән мине үзенә баглый, кулымнан көчне ала иде. Болгар кызларында гына була торган*

---

[1] Шура.– 1909.– № 15.– 467 б.

[2] Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек).– Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.– 278 б.

[3] Шура.– 1911.– № 17.– 528 б.

*ак, түгәрәк йөзе өстендәге ал катыш кызгылт бите, карасы кара, агы ак булган зур күзе, озын кара чәче, тал чыбыктай сыгылып торган буе, көлә биреп, керфек кагып әйткән сүзе ничек тә үзене яраттыра иде...*

***

*...Бераздан соң беркөн Айсылу түшәктә иде. Терек булып торуы аз гына калганыны сизә, терек чакта күргән авырлыклардан үзене коткара торган үлемне көтә иде. Тирә-ягындагы нәрсәләрдән ямьсезлек таба да тизрәк алардан котыласы килә иде.*

*Башыны чак әйләндереп, күзене тутырып, янында утырган анасына карады да: «Уф!» — диде. Күзендә яшьләр бетте. Башы ястык үзәренә төште. Тәрәзә аркылы төшкән вә кайгылы төстә торган кояш актысына җаны кушылып, күккә очты. Төссез, саргайган иреннәре бу тормышны мыскыл иткән төсле ачылып калды.*

*Ак йөзле, кара күзле, зифа буйлы, озын чәчле болгар кызы Айсылу кайда? — Шул көннән бирле кара җир астында...»*[1].

Шушы язмасы белән шагыйрь Мәҗит Гафури «Шура» журналында ике ел дәвамында барган «Тел ярышы»ның җиңүчесе булып таныла.

Беренче карашка Риза Фәхретдиннең барлык язмаларны да саф татар телендә язып булмавы хакында фикере, уздырган эксперименты тормышка ашмаган кебек күренә. Кайбер кешеләр, Мәҗит Гафуриның ярышта үз хикәясе белән җиңү яулавын, чит сүзләр катыштырмыйча теләсә нәрсә турында язып булудан күрәләр. Тик «Шура» идарәсенә килгән 72 мәкаләнең калган 71 ендә чит сүз катыштырмый язылганы табылмый. Ә Риза Фәхретдин үз «Игълан»ында: «...Нә тугърыда улса да улсын, һичбер чит сүз катыштырмай, халис вә саф төркичә бер мәкалә йазмакдан гыйбарәтдер» шартын куйган иде. (...)

[1] «Шура»ның «Тел ярышы».– Оренбург, тип.газ. «Вактъ», 1910.– 195 б.

«Болгар кызы Айсылу» хикәясенә килгәндә, әсәрнең көче, гүзәллеге, сюжетны кискен бора белүе авторның чын профессионал булуын күрсәтә. Мәҗит Гафури әлеге хикәясенең әдәбилеге, ягъни тасвир-сурәтләре өчен «Шура» журналының 1908 елгы саны һәм «Тәрҗеман» газетасының еллык төпләнмәсе белән бүләкләнә.

«Шура» журналында Мәҗит Гафуриның тагын бер мәкаләсе дөнья күрә. «Чобар тел» мәкаләсендә автор чит телләрдән кергән сүзләрнең телебезгә булган тәэсире турында бәян итә.

**«Чобар тел**

*Бер милләтнең теле югалса, бер милләт икътисади җәһәттән җиңелсә, ул милләт үзе дә югала, бинаән галәйһи тел мәсьәләсе гаять әһәмиятле мәсьәлә, дип, телнең әһәмияте хакында озын мөкаддәмәләр язып тормый, туп-туры телемезнең нинди җәһәттән үзгәргәнен, бетсә ничек бетәчәген язып китәсем килә.*

*Төрек-татар кавеменең иске лөгатьләренең әксәре онытылып беткән. Аларның күбесе истигъмальдән чыгып, алар урынына гарәби, фарси кәлимәләр кереп урыннашканнар. Шуларның мөкабиле үземезнең асыл төрек телендә булса да, алар югалганнар, яисә истигъмаль кыйлынмыйлар.*

*Үз фикеремчә, моннан соң телемезгә гарәби, фарси кәлимәләр катышып, ул яктан безнең тел бозылмас, фәкать асыл телемездә булмаган, бәгъзе фәнгә гарәби исемнәрең дә телемезгә артык зарар итә алмас. Ниһаять, әдәби тел дигәнемез татарчалашып беткән гарәби сүзләр белән катыш булыр. Мондый чит бер сүз керү белән үземезнең бер сүз югалып китми, бәлки болар белән телемезнең байлыгы арта, лөгатьләре күбәя».*

Мәкаләнең беренче өлешендә автор гарәп, фарсы сүзләренең үз телебезгә ни дәрәҗәдә тәэсир итүе хакында, мондый сүзләрнең безнең телгә артык зыян булмавы, бары телебезне баетуы турында билгеләп үткән, ә мәкалә-

нең икенче өлешендә безнең телгә рус сүзләренең тәэсире турында хәбәр иткән:

*«...Телемез гарәп кәлимәләреннән котылды инде, дип торган вакытта, телемезгә икенче бер һөҗүм башланды. Бунысы борыныга караганда да куркынычрак. Бунысы, бик тизлек белән таралып, үземезнең асыл лөгатьләремезне халык арасыннан югалта башлады. Моның сәбәбеннән ниһаятьсез күп сүзләремез югалыр».*

Мисал итеп автор ике сатучының сөйләшүен китерә. Аларның сөйләшендәге: «тавариищ», «дахуд», «расхуд», «тирәйт», «не стоит» кебек сүзләргә игътибарын юнәлтә. Мәкаләнең дәвамында:

*«Рус кәлимәләренең сүзләре арасына кергәнен алар үзләре дә белми калалар. Чөнки табигый хәлгә әйләнгән. Бу сүзләрнең һәрберсе үз телемездә дә бар... Бу китеш белән барган, татарча, русча, гарәпчәдән мөрәккәб яңа бер бозык, эшкә яраксыз тел дөнья йөзенә чыгар. Асыл төрки теле вә лөгатьләре лөгать китапларында гына калыр. Моннан безгә башка файда килмәс.*

*Фән аркылы яисә берәр нәрсә белән бергә кергән кәлимәләрдә сүз дә юк. Алар ихтыярсыз керәләр. Чөнки аларның исемнәре бездә борыннан булмый. Алар безнең сүзләремезне югалтмыйлар. Югарыда сөйләшкән агайлар истигъмаль иткән чит сүзләр берсе дә болай зарурәт сәбәпле кермәгән. Аларның мөкабиле телемездә артыгы белән бар, шуларны истигъмаль итәргә, онытмаска, югалтмаска кирәк»*[1]. (...)

Нәтиҗә итеп шуны әйтик: Мәҗит Гафури безнең күңелләргә танылган әдәбият белгече, шагыйрь, прозаик, «Фәкыйрлек берлә үткән тереклек», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» кебек проза; «Милләт мәхәббәте» кебек шигырьләр циклы, «Яшь гомерем» шигырьләр җыентыгы, «Шөбһә», «Васыять» кебек шигырьләрнең авторы булarak та, Риза Фәхретдин тарафыннан язылган махсус игълан белән «Шура» журналында уздырылган «Тел ярышы»

[1] Гафури Мәҗит. Әсәрләр: 4 томда, III т. – Казань: Татар.кит.нәшр., 1983. – 357–361 б.

җиңүчесе буларак та кереп калган әдип. «Болгар кызы Айсылу» хикәясе – «Шура» идарәсе хезмәткәрләренең, тәнкыйтьче Хәсән Галинең генә түгел, күпләрнең күңелен кузгата торган әсәр буларак кабул ителә. «Чобар тел» мәкаләсе исә, бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган тема булып кала бирә.

*Хөснетдинов Р. «Шура» журналы һәм Мәҗит Гафури // Мәҗит Гафури: әдип һәм халык язмышы: Мәҗит Гафуриның тууына 130 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары.– Казан, 2010.– 277–282 б.*

*Миркасыйм Госманов*

# Мәҗит Гафури мирасыннан

Соңгы вакытларда революциягә кадәр чыккан татар журналларын караштыргалап утырган чакта шагыйребез Мәҗит Гафуриның иҗат үзенчәлеген, кайбер мәсьәләләр буенча дөньяга карашын төгәлрәк чагылдыра торган яңа фактларга очрарга туры килде. Шагыйрь мирасын, аның иҗтимагый позициясен өйрәнү, тагын да ачыклый төшү өчен алар кызыклы мәгълүмат булып тора. Мәсәлән, аның милли хәрәкәткә караган кайбер фикерләрен чагылдыра торган бер мәкаләсе игътибарга лаек.

Мәкалә «Сәбәп нәрсә» дип аталып, «Сөембикә» журналының 1918 елгы беренче, төгәлрәге, аның иң соңгы санында басылган (моннан соң, мәгълүм булганча, журнал чыгудан туктый). Мәкалә ахырында күренгәнчә, ул 1917 елның 16 декабрендә язылган. Бит итәгендә публикациягә карата «Бу мәкалә Башкорт федерациясе игълан ителеп, башкорт халкы зур вакыйга алдында тору мөнәсәбәте белән дәреҗ ителде. Идарә» дип искәрмә бирелә. Моннан татар журналының тугандаш халыкның азатлык өчен көрәш мәсьәләсенә карата теләктәшлек белдерүе сизелеп тора.

Мәҗит Гафури исә Урал артында киң таралган башкорт милли азатлык хәрәкәтенең – аны күзәтеп торучы буларак – табигатен аңларга, үзе аңлаганнары хакында укучыларга да төшендерергә омтыла. Аны иң гаҗәпләндергән беренче күренеш – Башкортстанда яшәүче мишәрләрнең, типтәрләрнең әлеге хәрәкәткә мөнәсәбәте була. Башкортларның соңгы вакытларда бик активлашуын, максатларына ирешер өчен үз җирләреннән башка халыкларга өлеш бирергә риза икәнлекләрен искәртеп, ул болай дәвам итә: «Мишәр вә типтәрләр исә, йә асыл федерациянең үзенә

бик салкын карыйлар вә яхуд шул башкорт федерациясенең койрыгына тагылырга әзер торалар. Башкортны тәртипсезлек вә эшсезлекнең мәҗәссәм мисдакы (мәгънәви гәүдәләнеше – *М. Г.*) итеп тоткан, башкортның бөтен нәрсәсеннән көлгән, ул халыкта гыйбрәткә вә үрнәккә тотарлык бер генә нәрсә дә тапмаган бу «горур» кавем хәзерге көндә килә дә шул башкорт хәрәкәте алдында ихтирам күрсәтә, мөселманчылык вә иманы өчен нинди фидаилекләр итәргә торган вә иткән «мөселман» бүген килә дә гомум мөселман күпчелегендә аерылып, «Башкорт эспискә»сенә тавыш бирә, мөселман күпчелеген бер дә хаксыз «буржуазия фиркасе вә кадетлар» дип атый!» [9 б.] Шулай итеп, М. Гафури Башкортстанда яшәүче татарларның кайберләренең, тар матди мәнфәгатьтән чыгып, әлеге хәрәкәткә карата икеле-микеле позициядә торуларын, җае килсә, иманнарыннан тиз тайпылуларын ярыйсы ук оста тотып алган икән.

Башкортларның үзләренә килсәк, М. Гафури аларның һәр адымы, һәр гамәле максатчан, алдан исәпләнгән булуын махсус билгеләп уза, шул фикерен төрле яклап дәлилләргә омтыла. Аның фикеренчә, башкортларның садәлеге ул тышкы күренеш кенә. Кирәге чыкса, башкорт кешесе бик оста итеп мәсьәләне аңламаган үтә беркатлы адәмгә дә салыша ала. Һәрвакыт аның хуҗалык эшләре эшләнгән, ягъни печәне вакытында чабылып, балыгы кирәгенчә тотылган булыр; ауга да үз вакытында чыгып, кунагын да чакырырга, әйбәтләп сыйларга өлгерер ул. Аның ваемсызлыгы, садәлеге тышкы күренеш кенә. Мәсәлән, ди автор, белеме чамалы, зур гаиләле бер агайга башкортларның Учредительный собраниеләренә ярдәм итү, акча җыю кирәклеге хакында әйтсәң, аның бер дә исе китмәс: «Эшләрбез, ул эшләрне Алла эшләп йибәрми, йирдә бәндәләр эшли бит!» – дип кенә җавап бирер.

Шул ук вакытта башкортларга хас бу искитмәслек сыйфаты гадәти ваемсызлык та түгел икән. Фикерен дәлилләр

өчен, М. Гафури башкортлар тормышыннан берничә мисал китерә. Шулардан берсе: «Бер башкорт кунаклар чакыра. Кунаклар киләсе көндә генә 14 яшьлек бер кызы суга батып үлә. Аны бик тиз генә җыештырып куялар. Кунаклар килә, өч-дүрт көн кунак булып китәләр. Ләкин суга батып үлгән кыз вакыйгасын һич тә белмиләр. Фәкать күп вакытлар үткәч шул хәл зоһур итә» (ачыла – *М. Г.*).

Башкорт халкының шушындый сыйфатына игътибар иткән автор түбәндәгечә йомгак ясый: «Менә шул табигатьләргә малик (ия – *М. Г.*) булган мәзкүр рәвештәге башкортлар хәзер дә Зәки типтәр (Әхмәтзәки Вәлиди – *М. Г.*) белән Манатов дигән бер «дәликалы»ның «башкорт федерацияләренә» муафәкат (ризалык – *М. Г.*) итәләр. Ләкин муафәкат итеп ни эшлиләр? Җан башына утыз-кырык тиен акча җыешалар да Оренбург вә башка йирләргә кешеләр йибәрәләр вә үзләре, һич нәрсә юк кебек итеп, казылык ашый вә кунакка йөрешәләр» [12 б.].

Башкортларның холкын болай бик үзенчәлекле итеп сурәтли алган Мәҗит Гафури, тарихтан күренгәнчә, азатлык өчен барган хәрәкәтнең перспективасын тасвирлаганда шактый нык ялгышкан икән. Моның шулай икәнлеген шагыйрьнең үз язмышы да – гомеренең соңгы дәверендә «паспорт» алыштырып, титуллар үзгәртеп йөрүе дә расласа кирәк. Ихтимал, моңа Башкортстандагы мишәр-типтәрләрнең автор үзе күрсәткән гамәли омтылышлары да сәбәп булгандыр...

Шагыйрь мирасына караган икенче бер мөһим факт «Дин вә әдәп» («Әд-дин вә-л-әдәб») журналының иң беренче санында сакланып калган.

Мәгълүм булганча, бу журналны 1906–1917 елларда Казанда күренекле дин галиме, җәмәгать эшлеклесе һәм мөдәррис Галимҗан хәзрәт Баруди (1857–1921) чыгарган. Исеменнән үк күренеп торганча, ул журнал гел дини, фәлсәфи мәсьәләләрне яктыртуга багышланган. Дөрес, анда, игътибар белән укый белсәң, иҗтимагый, мәдәни тормышны чагылдырган материаллар да шактый.

Түбәндә тексты төгәл күчерелә торган шигырьне автор әлеге журнал чыга башлау мөнәсәбәте белән махсус язган. Текст алдыннан «Мәдрәсәи Мөхәммәдия таләбәсендин (укучыларыннан – *М. Г.*) шагыйре милли Габделмәҗит әфәнде әсәре» дип күрсәтелгән. Моннан күренгәнчә, журналның беренче санын әзерләү эшенә үк М. Гафуриның җәлеп ителүе ап-ачык. Аның шәкерт килеш (26 яшьлек пишкадәм!) нашир һәм мөхәррир тарафыннан «милли шагыйрь» дип олылануы да шуны раслый.

Унөч строфадан, ягъни 52 юлдан торган әсәр шагыйрьнең җыентыкларына кермәгән. 1980–1983 елларда Казанда М. Гафуриның туган телендә чыккан иң тулы дүрттомлыкта да аңар урын бирелмәгән. Һәм бу аңлашыла. Чөнки моңарчы безнең әдәбият белемендә (дәреслекләрдән алып махсус монографияләргә кадәр) Мәҗит Гафуриның дингә мөнәсәбәте бары «Юктырсың ла, Алла» шигыре мисалында тасвирланып килде. Яңа ачылган факттан күренгәнчә, шагыйрьнең дингә, димәк, Аллага мөнәсәбәте ул кадәре үк берьяклы булмаган икән.

Дөрес, әлеге популяр шигырьне дә, игътибар белән укысаң, авторның диннән тәмам йөз чөерүен түгел, бәлки җирдә хөкем сөргән гаделсезлектән рәнҗүен күрәсең.

Түбәндә кабат басыла торган әсәрдән М. Гафуриның дингә шактый тирән мөнәсәбәттә булуы ачыла. Аныңча, кеше өчен «дин, әдәп һәм мәдәният» бертигез дәрәҗәдә кирәк һәм бергә булган хәлдә генә чын-чынлап файдалы икән. Шагыйрь ышануынча, бозылган әхлакны төзәтү, надannарның, бигрәк тә рухан хәерчеләрнең белемсезлеген бетерү өчен дә динлелек зарур икән. Әлбәттә, бу мәсьәлә буенча төрле яклап фикер алышырга мөмкин. Тик шунысы хак, киләчәктә шагыйрь иҗатын яктырткан чакта, мәсьәләнең шушы ягына да тиешле дәрәҗәдә игътибар ителсә, позиция күпкә гадел һәм нәтиҗә чагыштырмача объективрак булыр иде. Ниһаять, мондый алым шагыйрь кичергән фикъри эзләнү процессын да, эволюция һәм үсү үзенчәлеген дә төгәлрәк аңларга ярдәм итәр иде.

## Әд-дин вә-л-әдәб

*(1) Эчтә булган шатлыгымны кылып изһар[1],*
*Бәгъзы вакыт шигырь язу гадәтем бар;*
*Яхшы эшкә һәр вакытта дәрт кузгала,–*
*Былбыллар аваз салыр, күрсә гөлзар.*
*(2) Милләткә хезмәт өчен ошбу көндән,*
*Казанда бер журнал чыгу сәбәбендин,*
*Бу мөҗәллә[2] берәм-берәм тәфсыйль итәр*
*Дин-исламдан, дәхи аның әдәбендән.*
*(3) Безләрне ошбу журнал әйләде шад,*
*Бу фәкыйрьнең шатлыгына кыл игътимад[3],*
*Дин вә әдәп мөҗәлләсен тәбрик идеп,*
*Ихтыярсыз бу шигырьне кылдым иншад[4].*
*(4) Дөнья-ахирәт сәгадәткә ирешкән зат,*
*Кыладыр һәрберсенә зур иҗтиһад,*
*Бергә булса дин, әдәп һәм мәдәният,*
*Шул вакытта хасил булыр асыл морад.*
*(5) Дин-исламның фәлсәфәсен бәян итсен,*
*Хакыйкатьне һәр кешегә гайан итсен[5],*
*Хак аңлану тәрәккъыйгә сәбәп булып,*
*Көннән-көн милләтемез алга китсен.*
*(6) Дин-ислам күктә торган якты кояш,*
*Мәстүр түгел[6], хакыйкате дөньяга фаш,*
*Дин-исламга зәррә кадәр зарар килмәс,*
*Мөганидлар һәр тарафтан атса да таш.*
*(7) Дин-ислам – бакый булган якты бер нур,*
*Бу нурдан бушка калган буладыр хур,*
*Дин-исламның фәлсәфәсен тәфтиш итсә,*
*Әһле инсаф һич вакытта тапмас косур[7].*

---

1 Изһар кылу – белдерү, игълан итү.
2 Мөҗәллә – журнал.
3 Игътимал кылу – ышану.
4 Иншад кылу – инша итү, иҗат итү.
5 Гайан кылу – ачык итү (аңлату).
6 Мәстүр түгел – ябык түгел.
7 Косур – кимчелек, җитешсезлек.

*(8) Күп йирдә әдәп-хәя күтәрелгән,*
*Кирәкмәс гәдаутләр[1] эчкә кергән,*
*Хосусән бу заманда дөнья тулды*
*Беләмез дип дәгъва кылып белеп йөргән.*
*(9) Саф нәрсәгә пычраклар аралашкан,*
*Күңелне күптән бирле кара баскан;*
*Мин-минлек дәгъвасендә йөргәнләрнең*
*Әксәре[2] кырын юлга карап ашкан.*
*(10) Милләт өчен тырышудан ләззәт алып,*
*Дөньяңыздин динеңезне алга алып,*
*Һичбер кеше онытмастай эш кылдыңыз,*
*Артта калган мөселманга күзне салып.*
*(11) Дин-карендәш мөселманга кылып шәфкать,*
*Күтәрдеңез өстеңезгә зур мәшәкъкать.*
*Һәп[3] рәхәтне милләт өчен фида итеп,*
*Үзеңезгә рәхәтсезлек калды фәкать.*
*(12) Әүвәлдән Русиядә мәшһүр остад[4],*
*Дин юлында алгы сафтан кылды җиһад[5]:*
*Борынгы хезмәтләрен тәкъдир итсәк,*
*Өмидемез дәхи арта ничә мең кат.*
*(13) Мотлакан заманабыз башка заман,*
*Сезләргә күп сәвенеч, әһле Казан!*
*Өч гәзитә дә бер журнал чыгып тора,–*
*Кадрен белеп укыңыз сез инде һаман!*

Бәндәләре Габделмәҗит ГАФУРИ

*Госманов М. Мәҗит Гафури мирасыннан // Казан утлары.– 1991.– № 6.– 179–181 б.*

[1] Гадауәт – дошманлык.
[2] Әксәре – күпчелеге.
[3] Һәп – барлык, һәммә.
[4] Остад – остаз.
[5] Җиһад кылу – тырышу.

# Замандашларының бәясе, тәнкыйть мәкаләләре

*Габдулла Тукай*

# Мәкаләи махсуса[1]

## *III*

Уфага җиттем. Тау башында тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым. Ләкин бу инде Самарныкы түгел. Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем, такта арбага буш салган дилбегә кеби, үрле-кырлы сикерә иде. Таудан акрынлап менәсең. Җулның әтрафында җәһәннәм кеби тирән чокырлар – хисабы юк. Җәһәннәмнәрнең тирәсенә саклык өчен тезгән баганаларның арасы бик сирәк булып, арба янтайса, мөкиббән галә вәҗһи[2] җәһәннәмгә төшү бик мөмкин иде.

Уфага кергәндә бер дә шәһәргә кергән кебек булмый. Әллә нинди ачык-тишек вә рәтсез һәм пустынный урамнар белән барасың. Эч поша. «Кая соң моның шәһәрлеге?» – дип сукранганда, көчкә беркадәр яхшырак урамнарга кердек. Шулай барганда, «Сабах» көтепханәсенең ак вывескасы күренде. Тугъры анда туктадым.

«Сабах»ка килүдән максудым, Самардагы кеби, бер «Бристоль»гә барып эләкмәскә, ягъни нинди номерлар ничек булачагын сорашу иде. Ләкин күрдем ки, магазинга тоташ шундый киң вә яхшы бер квартир бар, монда мин түгел, миңа тагы 19 кеше кушсаң да сыярлык иде. Җитмәсә, аның асты кухня булып, һәрвакыт астан җылы бәргәнлеге беленде. Менә рәхәт! Менә икенче ләүкә! Монда китап төялеп килгән гайре мөтәнаһи[3] ящиклардан караваты ясау вафли пешерү шикелле тиз. Аста ящик булса да, өстенә йомшак вә матур нәрсәләр каплагач,

---

[1] Кыскартып бирелде.

[2] Мөкиббән галә вәҗһи – йөзтүбән.

[3] Гайре мөтәнаһи – чиксез күп.

ярый ул: өстеңдә әйбәт кием булгач, синең бәрәңге генә ашаганыңны кем белә? Урамга чыксаң, мыекны кашыктагы май белән майлап була. Дөнья яратылганнан бирле ялганнар күбесенчә тотылмый калган. Бичара Рәшит казый гына, микадо мөселман була дигән булып, һәммә татар галәмен алдый язган иде. Ләкин «Тәрҗеман» мөхәррире чыгып, Рәшиткә: «Баба, кашыктагы мыек майлый торган маеңны песи ашады»,— дип оятлы итте. Мин фәкыйрь дә, татар вә исламга гаид[1] эшләрдә «чебен тимәс чер итәр» бер кеше булганымнан, «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» сәрләүхәле[2] бер шигырь язган идем.

Квартир гомумән күңелле. Кеше күп килә. Эч пошарлык түгел. Монда һәр көн мөхәтдисе кәбир[3] Әхмәтфаиз Даутов[4] белән күрешәбез. Ул скрипкәдә маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый җыруны бөтен гомеремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голүвиятен[5] изһар итә[6]. Мин Латыйповны ишеткәнем юк, ләкин Камил бушбугаз кебиләрне бу җирдә телгә алырга да хурланам. Петербург профессорлары хәзер башкорт халкының бик тиздән монкариз[7] булачагына иман иткәннәр. Башкортларның гадәт вә әхлакларын язып һәм кием вә зиннәтләрен музей өчен тикшереп ятмакталар икән. Әгәр Фаиз әфәнде кеби чын башкорт рухы вә башкорт моңы белән җырланган җырлар да граммофоннарга алынып калса, моның башкорт инкыйразыннан соң азмы әһәмияте булыр иде?! Ләкин

---

[1] Гаид – бәйләнешле.

[2] Сәрләүхәле – исемле.

[3] Мөхәтдисе кәбир – хәдисне (пәйгамбәр сүзен) күп белүче.

[4] Әхмәтфаиз Даутов – һәвәскәр җырчы, «Буби» мәдрәсәсе җырчысы булган.

[5] Голүвият – бөеклек

[6] Изһар итү – ачып бирү.

[7] Монкариз булу – бетү.

милләтемез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өсткә кала шул.

Дикъкать итәсезме? Хәзер граммофонга җырлау фахишәләр вә әнвагъ[1] эшсез, ашсызлар кәсебе булды. Казанның «Кәҗә Маһи», «Подвал Фатыйма», «Этле Хөсни», «Җиңгәчи кызлары»на кадәр төрле шәһәрләрдә граммофонга җырлап, милләтнең сәмгын[2] мәсхәрә итеп бетерделәр. Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй! Фахиш мәгънә! Менә шулар безнең фәхшиятсез, пакь мөселман түрләренә кереп утыралар. Түрдә утырып, граммофоннан сүгенәләр. Мин Казанда, Әстерханда әллә ничә граммофоннан шуны уйнатучы гаилә әфрады[3] өчен кызарып утырдым. Алар минем кәефемне ачарга граммофон боралар иде. Мин исә чыраемны сытып утыра идем. Чөнки алар миңа, шикәр дип, үзләре белмичә, ачуташ каптыралар иде.

## *IV*

Уфаның мәгъмурият[4] ягы Казаннан күп начар булса да, табигать ягы күп шәһәрләрдән өстен. Әүвәл үк ул тау башында. Димәк, җәй көне дә, кыш көне дә һава яхшы. Җырларымызда шулкадәр күп җырланган Агыйдел буенда. Шәһәр эчендә йортларга караганда агачлар күп диярлек. Моның җәй көнеге әһәмияте! Өстән караштa Уфаның халкы да айнык вә саф күренә. Чөнки бу шәһәрдә чат саен халык саулыгын химая итә[5] торган сөт кибетләре, һәммәсендә халык. Пивнойлар сирәк. Бу шәһәр – «ай-һай, Казанның каласы, аза ишан баласы» түгел. Сөт сатучылар, мендәргә утырган мулла кеби, үзләре хезмәт итмиләр. Сөт эчүчеләр үзләре буфеттан сөт алып килә. Чөнки мулла сиңа Коръән укыта, дин өйрәтә, сөтче дә сәламәтлек бирә, алар нишләп хезмәт

[1] Әнвагъ – төрле-төрле.

[2] Сәмгын – тыңлау тойгысын.

[3] Гаилә әфрады – гаилә әгъзалары.

[4] Мәгъмурият – төзеклек.

[5] Химая итү – саклау.

итсеннәр! Мөселман буласың килсә – дин өйрән, сау буласың килсә – әнә сөтне үзең барып ал! Монда трактир официантлары кеби рия, нифакъ[1] вә посетительгә ярарга тырышып кыйлану күренми.

Фәлсәфәгә кердем... язам, язам – кая көлкесе; урман, урман – кая төлкесе?!

### *V*

Әйе, урманның да бөтен җирендә төлке булмый, мәкаләнең дә һәр сәтырында көлке булмый. Актар агач араларын – бардыр төлкесе; укып чык бөтен караларым – бардыр көлкесе.

Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мосахәбәмез[2] күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек – әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек – әле күздән яшемез дә кипкән[3].

Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә[4] китергән...

Әйе, әле күздән яшемез дә кипкән. Киләчәктәге шатлык – яки ерак, яки юк.

Уфада шактый заман торсам да, аның эчен вә әтрафын карап йөри алмадым. Мәҗит белән йөрергә чыксам да, ярты юлда хәл беткәч, өйгә борыла идек. Монда трамвай юк. Извозчикта эч кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде.

Шәһәр бакчасында борадәран Кәримевләрнең «Йолдыз» исемендә кинематографлары бар. Көннәрдә бер көн

---

[1] Рия, нифакъ – ялагайлык, икейөзлелек.

[2] Мосахәбә – әңгәмә.

[3] «Елый-елый яшебез дә калмаган, кипкән» мәгънәсендә.

[4] Халәте рухия – рухи хәл.

Кәримевләр, әлбәттә, үзләре сизмичә булырга кирәк, кинематографларында «Мөхәммәт оҗмахы» дигән нәрсәне күрсәтмәкче булып игълан тараткannap. Бу хәлне сизгәч, Уфага яңарак килгән бер «зыялы» мәсҗедтәге картларга Кәримевләрнең шундый начар эш эшләячәген сөйләгән. Картлардан хәбәр халыкка да таралган. Халык кызып, витринадагы афишаларны җыртып, Кәримев кешеләрен кыйнарга да уйлаганнар. Ләкин Кәримевләр ни дип җавап биргәннәр?

*Наданлык сәбәпле көфергә төшү җиңел инде:*
*Алар, без белмәдек дип, зари кыйлды*[1]*,*
*Гөһәрләр*[2] *күзләреннән җари кыйлды*[3]*...*

Әлкыйсса[4], мәзкүр нәрсәне күрсәтмәгәннәр. Хәзергә җитәр әле.

## *VI*

Өстән генә ләктереп китү тарызын[5] алган мондый сәяхәтнамә өчен Уфада артык нәрсә күрмәдем бугай.

Хәер, шәһәр бакчасында, өстенә җөббә[6], башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка «батинкә», авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкертне туктатып, җүри, «вәкар[7] вә мәһабәтен» бозар өчен: «Син курай уйный беләсеңме?» – дип сорыйсым килде. Мин үзем гомумән шундый «кәмитле» мәһабәтлекне бозудан ләззәт табам. Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек, аның «вәкар»ен бозарга кирәк.

---

[1] Зари кыйлу – кычкырып елау.

[2] Гөһәр (гәүһәр, җәүһәр) – алмаз, асылташ: монда «алмаздай күз яшьләре» мәгънәсендә.

[3] Җари кыйлу – агызу.

[4] Әлкыйсса – кыскасы.

[5] Тарыз – рәвеш.

[6] Җөббә – җиләннең бер төре.

[7] Вәкар – һавалылык, корыкуыклык.

Бу – өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кеби кагыйдә инде.

Андый «вәкар» яшьлектә җимерелмәсә, бәгъзан[1], мөхәррир булып гомер итеп, неграмотный үләчәк «зате галиләрдә»[2] дә кала. Мисал эзләсәңез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез.

Әле апрельнең әүвәлге яртысы гына җитә. Минем өчен көннәр әкрен кичәләр. Апрельнең әүвәл ягыннан, «әүвәле Коръән»[3]нән чыгалмый җөдәгән малай кеби, мин дә үтә алмыйм. Малай, хәлфәсе сизмәгәндә, сабагын «сикерткән» кеби, мин дә күп йоклап карыйм. Ләкин максады аслый[4] булган кымыз сезоны җитми. Уфада кымыз юк.

Дөрест, мин кымызны Уфада да, әтрафында да эчәчәк түгел. Мин аның өчен Троицкигә барырга Казаннан ук карар биреп чыккан вә йөзләп баш бия саудыра торган бер Троицки кешесенә барасы, кымызны савылган урынында чатыр торып эчәсе кеше. Чөнки Уфа әтрафын европалылар басып, биттабгы[5], андагы кымыз искусственный (җәгъли) ланганыннан хәбәрем бар иде. Ләкин Уфада кымыз да булмаганлыгыннан, Троицки «кусагасылары»ның[6] да «бия байламаганлыгын» истидлял итә идем.

Шулай ни ары, ни бире булып торганда, кесәмдәге Петербургка мине чакырып язган бер хат исемә төште. Бу хат инде беренче түгел, берничәнче иде. Буш та түгел, җитди иде. Ләкин җитди булса да, мин Петербургка баруны көзгә, кымыз эчеп хәлләнгән чакка кичектермәкче идем. Юк инде, Петербургка хәзер барам. Кымыз да булмагач, Уфада нәрсәгә ятыйм. Җитмәсә аның «авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем әле хасил булмактагы европалылы-

---

[1] Бәгъзан – кайчакта.

[2] Зате гали – бөек зат.

[3] Әүвәле Коръән – Коръәннең беренче кисәге.

[4] Максады аслый – төп максат.

[5] Биттабгы – табигый.

[6] Кусагасы – кымызчы.

гымны, культурный шәһәр кешеселегемне, шау-шу яратучылыгымны, галәбәлек, көрәш сөючелегемне үчекләгән кеби булды. Китәм Петербургка! Кымызга кадәр торам. Телеграм, ответ. Киттем.

*1912*

*Тукай Г. Мәкаләи махсуса // Әсәрләр: 6 томда: 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913).– Казан: Татар. кит. нәшр., 2016.– 167–183 б.*

*Гаяз Исхакый*

# «Үги балалар»

Шагыйрь Габделмәҗит Гафуриның бу китабы иң әүвәл «Әхбар» гәзитәсендә фельетон булып басылып, соңыннан китап булып чыкмыштыр. Шуның өчен китапның мәале[1] шактый күп кешегә мәгълүм булса да, мин дә, укучыларны тагы таныштырыр өчен, иң әүвәл китапның мәален сөйләп, соңыннан гына тәнкыйтькә керешмәкче булам.

Галә исемле бер шәкерт, мәдрәсәдә череп, сасып беткәннең соңында, мәдрәсәдә озак ятып, «давность» правосы буенча мулла булу хакына малик булганның соңында, солдатка китә. Солдаттагы тормышы аңарга аз гына да тәэсир итми. Аның дөньяга күз карашы һаман үзгәрми. Ул анда да, үзенең мәдрәсәдәге «Шәмсия»ләрен моталәга кылып[2], солдат мулласы булып гомерен кичерә.

Соңыннан авылына кайтып, үзенең солдатта күргән михнәтләрен бик тиз онытып, тагы мулла булу уена төшә. Һәм дә мулла да була. Авылдагы бер байның Зөһрә исемле кызын алып, ирле-хатынлы булып гомер сөрә башлый. Мәдрәсәдә табигате бозылу сәбәпле, әхлакы бик начар булса да, хатыны Зөһрә бик гакыллы, тәрбияле була. Шуның саясендә[3] боларның тормышлары бик матур ук үтмәсә дә, арада әллә нинди зур тавышлар, низаглар булмый. Алты елдан соң боларның Фатыйма, Зәйнәп исемле ике кызлары, Галиәхмәт исемле угыллары да була. Шуннан соң Зөһрә авырырга тотына. Тагы бер-ике елдан өч яшәрлек Галиәхмәтне, биш яшьлек Зәйнәпне, җиде яшьлек Фатыйманы иренә яхшы тәр-

---

[1] Мәале – кыскача эчтәлек.

[2] Моталәга кылып – укып, өйрәнеп.

[3] Саясендә – күләгә, ышык.

бияләргә васыять итеп вафат була. Бераз кайгырганнан соң, табигый, безнең Галә мулла тагы өйләнә. Яшь хатын Зөһрәне һәм дә Галә мулланың Зөһрәгә биргән балаларны «яхшы тәрбия кылырмын» [дигән] вәгъдәләрен дә оныттыра, ул, яшь хатынның башмакчысы кебек, аның сүзеннән чыга алмый. Балалар аталары, яшь аналары ягыннан аш өенә чыгарылалар. Аларның ашау-эчүләре үзгәртелә. Алар өйдә әрәмтамак правосына тора башлыйлар. Яшь хатын Латыйфа балаларны бик кыйный, бер ачуы килгәндә, уклау берлә Зәйнәпнең башын сугып ярып, Зәйнәпне үтерә. Тавышсыз-тынсыз гына Зәйнәпне күмәләр. Латыйфа шул куркудан кулын бераз тыйса да, теленә тагы ирекне киңрәк бирә. Шулай итеп, балаларны нечкә юл берлә җәзалый башлый. Менә сугыш башлана. Галә мулла, мулла булса да, сугышка алына һәм дә простой солдат итеп Маньчжуриягә җибәрелә. Латыйфага бу эш бик авыр була. Ул, үзенең бу кайгысына да сәбәп шул үги балалар кебек итеп уйлап, аларны тагы артыграк көчли башлый. Беркөнне коега суга, үзе чыгарга иренеп, Галиәхмәтне чыгара. Галиәхмәт бик тырышып коедан суны тартса да, аны чиләк җиңеп, ул су берлә коега төшеп китә һәм шунда үлә. Галә мулла сугышта җәрәхәтләнә, сугыш бетмәс борын ук кулы зәгыйфь көенчә авылына кайта. Кайтып кергәнче Галиәхмәтнең үлүен белми. Кайтудан бераз элгәре күрше шәһәр аша больницага озатканда, Латыйфа берлә бабасын күргән булса да, балалар хакында сорарга оныта. Олуг кызы Фатыйманың «Галиәхмәт үлде» диюе аның күзенә яшьләр агыза. Ләкин озак үтми, тагы ул аны да онытып, тагы яшь хатын берлә чәй эчеп, кәеф итә башлый. Хикәя менә шунда беткән кебек була.

Ләкин мөхәррир, китапның шул төшенә җиткәч, бер шәһәрнең номерасында торганда, күрше номерадан бер зәгыйфь кенә тавышлы кыз баланың сөйләвен ишетә. Ул тавыш иясе безнең сәламәт калган актыккы үги баламыз Фатыйма булып чыга. Ул да авырганга күрә, атасы доктор-

га күрсәтер өчен алып килгән, имеш. Шуннан хикәя тагы номерадан Галә мулланың өенә сикерә, Галә мулланың аш өе беркемсез, Галә мулла ашка йөргәндә, Фатыйманың үлеп ятуыны күрсәтә, шуның берлә хикәя тәмам була.

Шуның өстенә «Үги балалар»да урыны чыккан бер йирдә безнең татар халкын Русия тормышында үги балалар берлә охшатуын кушсак, китапның бөтен мәале кыскача гына бәян ителгән була. Китапның мәале халкымыз арасында бик шаигъ булган үги балаларга илтифат итмәү мәсьәләсе мөляхәзә[1] кылынганга, табигый, бу китапта үги балаларның хәлләре бик начарлыгын мөхәррир әфәнде бик ачык тасвирлар берлә күрсәтергә тиеш иде. Аларның үги аналарының вә тупас аталарының җәбере аркасында, әллә никадәр җисмән генә түгел, рухан да җәза кылынуларын укучының күзеннән яшьләр агызырлык иттереп тасвир итәргә тиеш иде. Мөхәррир әфәнде балаларның кыйналуларын, катыкка буялып, былчыранып гомер кичерүләрен бәян итсә дә, аларның күңел сыныкларын, аларның эчке тормышларын тасвир итмәгәнгә, китап эче куыш агач кебек, тыштан китап булса да, эчтән буш кебек күренә. Шуның өчен укучының китаптан алган тәэсире зәгыйфь кенә булып, аның күңелендә тәмам түгеллек хисе калдыра. Өстән караганда гына китапның бу җитешмәве кечкенә кебек күренсә дә, әдәбиятның мәгънәсен аңлаган кешегә, әдәбиятның хезмәтен ни вә ни юл берлә идекен белгән кешегә бу хата китапның базарын бик төшерәдер. Әдәби тарызда бер вакыйганы тасвирдан язучының максуды — шул вакыйганың иң ямьсез яки иң матур тарафларын чишеп, укучының күңеленә тәэсир итәрлек матур вакыйга булса, аның матурлыгына аны гашыйк итәрлек, ямьсез булса, аның ямьсезлегеннән чырайларын сытып, шул ямьсезлеккә әллә никадәр дошманлык хисе уятырлык иттереп язудыр. Бер-бер язылган китап никадәр ямьсез йә матур вакыйганы бәян итсә дә, аның язылуы вакыйганың өстке катыннан гына йөресә, вакыйганың рухка

[1] Мөляхәзә – игътибар белән уйлау, фикер йөртү.

тәэсире, күңелнең шул вакыттагы уйлары, кайгылары, хәсрәтләре тасвир ителмәсә, китап, әдәби китап исемен югалтып, простой гына бер хикәя була да каладыр. Шуның өчен мондый әһәмиятле мәсьәләләр хакында китаплар язылганда, шул вакыйганың рухани тарафын тасвир итү вә шул тасвирны матур иттереп укучының күңеленең иң яшерен йирләрен ачарлык иттерү, аның йөрәгендәге иң авырта торган йиренә барып бәрелеп, аның бөтен рухын селкетү, аның йоклаган вөжданын уяту, аның миен хәрәкәткә китереп, аңарда әллә нинди яңгы сөальләр кузгату – әдәби китап берлә простой хикәянең аерыла торган йирләредер. Бу хата, китапның «эч тарафына» әһәмият бирмәенчә, механически гына китап оештырып чыгару – безнең хәзерге әдәбиятымызның иң зур кимчелеге, безнең әдәбиятымызның әлегә әле әдәбият түгел, «хикәяләр» генә идекен күрсәтә торган барометрыдыр. Бу хаталар, бу кимчелекләр үзеннән-үзе генә бетмәгәнгә, боларны бетерер өчен, беренче, боларның хаталыкларыны мөхәррирләр үзләре икърар кылырга тиеш булганга, шундый вакытларда тәнкыйтьнең файдасы бик күп булганга, китапларның бәгъзе тулмаган йирләрен ачкан өчен мөхәррирләр, әлбәттә, миңа ачуланып, урам эте кебек миңа бәйләнмәенчә, минем көзгемә ачуланып, көзгене ватарга тырышмасалар уе берлә тәнкыйтемдә дәвам итәм. Моңарга башка, китапның тышкы тарафыннан карагандa да, хаталар юк түгел. Китапның бик күп йирендә бик урынсыз иттереп шигырьләр язылуы, ул шигырьләр кайсыларының (мәсәлән, әүвәлге башның ахырындагы шигырь) мөляхәзә кылына торган мәсьәләгә һич тәгаллекы[1] булмавы китапның төсен ямьсезләтәдер. Китаптан иске «Бүз егет», «Таһир–Зөһрә» исен чыгарадыр.

Мөхәррир әфәнденең шагыйрь икәнен белсәм дә, аның шигырьләренең шактый матур булуына ышансам да, үзенең куәи шигърыясе берлә урынлы-урынсыз уйнавына, кирәкмәгән йирдә шигырьләр кыстыруына кимчелек дип

[1] Тәгаллекы – бәйләнеше.

караудан башка исем таба алмыйм. Бу шигырьләр бәгъзе вакытта моназарәнең дә төсен бозалар; аңардан алына торган тәэсирнең дә азаюына сәбәп булалар. Тормышның да мантыйкына каршы килеп, эчне пошыралар (мәсәлән, Зөһрә үлгәндә әйтелгән шигырь). Тагы ун-унбер яшьлек Фатыйманың авызыннан шигырь сөйләтү һәм дә әдәби бер телдә сөйләтү, табигый, мөхәрриреның шагыйрьлегенә бик зур дәлил булса да, мөхәррирнең тормышны белмәвенә дә шулкадәр зур дәлилдер. Анасыз үскән, катык ашап, уклау берлә кыйналып тәрбия кылынган Фатыйманың – Латыйфаның үги баласының моңлануы, ерлавы гаҗәп булмаса да, аның ерларының әдәби мәгънәле булуы гаҗәптер. Шәкертчә әйткәндә, мөхальдер[1]. Безнең халыкның мондый балалары, аталарыннан, аналарыннан тәрбия күрмәгәнгә, матур китаплар, матур шигырьләр укып, шигырьнең нәрсә икәнен аз гына да белә алмаганга, үзләренең моңнарын асрауларыннан ишеткән «Ай бәгърем» элекке ерлары берлә яисә әбиләреннән ишеткән солдат бәетләре берлә генә үтиләр, шуларны гына ерлый алалар. Бик күпкә китсә, «Мөхәммәдия», «Әхмәдия» китапларыннан берәр мисрагъ[2] ятлап, шуны авызларында әвәләндерәләр. Шуларга үзләренең кайгыларын кертеп бетермәкче булалар. Бәгъзе шигырьләр үзләренең мәгънәләре берлән дә дөрест түгел.

Мәсәлән:

*Сезне киттеләр алып,*
*Агач табутка салып.*
*Ничек сабыр итәрмез,*
*Безләр бу йирдә калып.*

Шигырьнең әүвәлге бүлеге мәгънә җәһәтеннән дөрест түгел. Шигырьлеге дә бик шөбһәледер, чөнки бездә җеназаны табутка салып алып китмиләр, җеназаны кабыкка салып кына алып китәләр. Бундай шигырьләр кысылмаган булса иде, шөбһәсез, китапның кыйммәте

[1] Мөхальдер – мөмкин булмаган эштер.

[2] Мисрагъ – шигырь юлы.

азаймаячак, бәлки китапның моназарәләре ким булмаячак иде. Шуның өчен бу шигырьләр гәзитәләрдә басарга яисә шигырь мәҗмугаларында язарга яраса да, «Үги балалар»га кертелүе, минемчә, бик урынсыздыр, китапның бәһасен киметәдер. Моңарга башка өч яшьлек Галиәхмәтнең үлем, тормыш хакында «фәлсәфә сатуы» да бер дә табигый түгел, бер дә күңел ышанырлык түгелдер. Тормышта өч яшьлек балалар фәлсәфәдән битәр уен берлә мәшгуль булганга, тормышның көзгесе булган әдәбиятта да өч яшьлек балаларны философ иттереп тасвир кылынмаска тиештер.

Иң соңыннан мөхәррирнең Фатыйма берлән очрашуы китапның төсен бөтенләй боза. Китапны 1908 елдагы татар әдәбиятыннан битәр, аны иске замана хикәяләренә охшатып, китапның тәмен җибәрә. Укучының күңелендә әллә нинди мөхәррирдән наразыйлык[1] хисе уяндыра, вакыйган, ни өчен бу очрашу кирәк булды икән? Ни өчен мөхәррир мондый тормышта бик аз тугры килә торган хыялларга мөрәҗәгатькә мәҗбүр булды икән?

Минемчә, бу очрашу, мотлакан, мөхәррирнең әсәрен чынлап уйлап бетермәвеннән генә килгән бер хатадыр.

Шул әйтелгән хаталар булмаса иде, мөхәррир әфәнде юл арасында милләт кайгысын бик күп кайгыртмаса иде, бу китап бик матур әдәби бер әсәр булыр иде. Шулай да китапның яхшы тарафлары да юк түгел. Теле бик үк матур булмаса да, бик тупас та түгелгә күрә, укылуы өчен бик зур гайрәт сарыф кылырга мәҗбүр булынмый. Укып чыккач та, күңелдә мөкәммәл хиссият уянмаса да, үги балалар хакында кешенең димагсы[2] азрак хәрәкәткә килә. Тормышның шул золымына азрак ачуны китерә. Әгәр мөхәррир әфәнде гомум әдәбият берлә таныша төшсә, рус, ятрак мөхәррирләреннән бер-берсен үзенә остаз итеп, шуның юлы берлә бара башласа, вә әсәрләренең теленә әһәмият биреп, фикеренең мантыйкый ачуына тырышса, шөбһә-

[1] Наразыйлык – риза булмаулык.

[2] Димагсы – мие.

сез, моннан соңгы китаплары әдәбият ноктаи нәзарыннан китап булачаклардыр. Шуның өчен, әгәр мөхәррир әфәнде шигырьгә башка китаплар язып хезмәт итәргә уйласа, үзенең шул кимчелекләрен тутырыр өчен, рус әдәбияты берлә чынлабрак танышуын тәүсыя итеп[1], мәкаләмне кыскартамын.

*1908*

*Исхакый Г. «Үги балалар» // Әсәрләр: 15 т.: 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.– 141–145 б.*

---

[1] Тәүсыя – киңәш итеп.

*Фатих Әмирхан*

# Татар шагыйрьләре

## Идарәгә хат

Бүген Казан пристанендә «Волжский листок»[1] газетасының № 696 сында «Татар шагыйрьләре» гонванлы[2] бер мәкалә укып, имзасының да татар имзасы булганын күргәч, тәгаҗҗеб[3] иттем. Тәгаҗҗеб кенә дә түгел, тәәссеф[4] иттем. Бәлки, башка газеталарда күренсә, бер тар милләтче вә татар әдәбиятыннан бөтенләй хәбәрсез татар тарафыннан язылган бу мәкалә миңа ул кадәр гаҗәп тә тоелмас иде. Ләкин демократлык флагы астында чыга торган газетада бу мәкалә бөтенләй урынсыз күренеп, ул хакта үз фикеремне язарга мәҗбүр булам. Ләкин мин «В. К. Р.»[5] газетасында «А. П-ч.»[6] тарафыннан язылган мәкаләне күрми уздырган идем. Шунлыктан, рәхим итеп миңа шул I номерны табып җибәрсәгез, тизлектә «Әльислах»та уз мөляхәзэмне[7] язар идем. [...][8]

[1] «Волжский листок» – Казанда 1904–1909 елларда чыккан рус газетасы.

[2] Гонванлы – исемле.

[3] Тәгаҗҗеб иттем – гаҗәпләндем.

[4] Тәәссеф иттем – борчылдым.

[5] «В. К. Р.» – Казанда 1905–1908 елларда чыккан «Волжско-Камская речь» газетасы.

[6] «А. П.– ч.» – А. Пинкевич – цензор, педагог, мәктәпләр инспекторы һәм Татарская учительская школа укытучысы Альберт Петрович Пинкевич (1884–1939).

[7] Мөляхәзэмне – фикеремне.

[8] Бу урында редакциядән түбәндәге искәрмә бар: «Идарә: бу хат идарәгә хосусый җибәрелгән булса да, бу урында дәреҗ кирәк табылды».

## Татар шагыйрьләре

Шушы гонван белән «Волжский листок» газетасында Касыйм Уралец исемле бер ходай бәндәсе мәкалә язып, «Волжско-Камская речь»тә шул ук хакта фельетон язган Пинкевич җәнапларының фикерен «тәнкыйть» иткән иде. Пинкевич үзенең мәкаләсендә «Тукаев шигырьләрендә нәфасәт һәм шагыйрьлек очкыннары күренә, ләкин ул, күп вакытта, өстенә урынсыз мөгаллимлек ролен ала. Мәҗит Гафури шигырьләре тар милләтчелек белән язылганнар»,– ди. Безнең ходай бәндәсе дә, Пинкевичның болай «тарафдар»лык итүенә бик ачуланып, «Тукаевның шигырь мәҗмугалары кечкенәләр, бары унбиш-егерме генә нәүиҗат[1] шигырьләре бар, калганнары муаффәкыятьсез[2] тәрҗемәләр. Әмма Гафури? Бу – бөтен Русия һәм Себердә (бөтен Гарби[3] Европада түгелме?) мәшһүр. Гафури татарларга укырга куша, аларның наданлыклары өчен бик кайгыра. Тукаев шигырьләрендә бик күп русча сүгенү сүзләре истигъмаль итә[4], хәтта «фахишә» диясе урынга «Охшату»да «б...» дигән. Гафури Америка шагыйрьләренә дә якын, аның «Электрик фонарена хитаб»ын күрсәң, исең китәр. Аның өстенә ул бик күп тарафтан яза: менә сезгә аның: «Инглизләрнең сәясәте» исемле шигыре... Аның теле матур, җиңел, нәфис. Әмма Тукаевныкы бөтенләй мөмкин түгел...» – ди. Ходай бәндәсенең бу мәкаләсен язгач, татар әдәбияты белән, хосусән, ул ике шагыйрь белән белеш кешеләр алдында бер дә рәд[5] итеп азапланырга кирәк булмаса да, бу сүзләр үзләреннән үзләре мәрдүд[6] вә ияләренең татар шагыйрьләреннән камил хәбәрсез икәнчелеген күрсәтеп торсалар да, мин бу тәнкыйтьче татар шикелле тагы татарлар булмавыннан имин

[1] Нәүиҗат – оригиналь.

[2] Муаффәкыятьсез – килешсез.

[3] Гарби – көнбатыш.

[4] Истигъмаль итә – куллана.

[5] Рәд итеп – кире кагып.

[6] Мәрдүд – кире кагылып.

булмаганга күрә, мәзкүр[1] ике шагыйрьләрнең әсәрләре арасындагы мөнәсәбәтне карамакчы булам.

Шунысы кызык, «тәнкыйтьче әфәнде», Пинкевичнең Гафурины «тар милләтче» дип гаепләвенә каршы бер генә җавап бирергә дә кирәк тапмыйчан: «А, куркыныч, аны тар милләтче ди бит!» — дип кенә узып китүне муафыйграк күргән.

Мин тәнкыйтьче әфәндегә, Пинкевичнең Гафурины тар милләтче диюеннән куркып китмәс өчен, аның әсәреннән менә шуларны укып чыгарга гарыз итәм[2].

(«Яшь гомер», 48 сәхифәдә):

*Мәзһәбе башка кешене*
*Мин үзем дошман беләм,*
*Заһире[3] дус булса булсын,*
*Эче — кара кан, беләм.*

(57 сәхифәдә):

*Ике кошны ябып куйсаң бер кафәскә[4],*
*Әгәр булса бу кошларның җенесе башка,*
*Ничаклы тату кеби күренсә дә,*
*Мөмкин түгел бер вакытта талашмаска.*
.................................................................
*Тышыннан дус, дошман иде алар эчтән,*
*Белгертте дошманлыгын бик аз эштән.*

(«Милләт мәхәббәте», 12 сәхифә).

*Аталары каһарман намыны алган татарларның...*

Нинди шәп каһарманлык! Хәтта шагыйрь әфәнде бу касыйдәдә европалыларны тәнзире биннар[5] да итә. Пинкевичнең Гафурины «тар милләтче» диюе нәкъ хәзергә кадәр чыккан әсәрләреннән карап истихраж[6] ителгән хөкемдер. Хәзер мин, «тәнкыйтьче әфәнде»нең, Гафуриның

[1] Мәзкүр — күрсәтелгән.
[2] Гарыз итәм — тәкъдим итәм.
[3] Заһире — тышкы ягы.
[4] Кафәс — читлек.
[5] Тәнзире биннар — тәмуг белән куркыта.
[6] Истихраж ителгән — нәтиҗә чыгарылган.

теле җиңел, нәфис, ә Тукаевныкы бөтенләй мөмкин түгел, дигән сүзенә килеп, ике шагыйрь әсәреннән дә бер мәфһүмдәге[1] шигырьләрне алып гарыз итәм.

Гафури яза:

*Егермедә фәрекъ кылдык[2] дусны дустан,*
*Дустымның күбе чыкты булып дошман;*
*Мотлака[3] бер вакытта дошман булыр*
*Заһирән[4] йөзен ачып, сүзен кушкан.*
*Дус кайда; бер як булып яклагандай,*
*Җандай күреп дошманнардан саклагандай,*
*Үлсә дә аерылмый бергә йөреп,*
*Сыйраттан[5] тотынышып атлагандай.*

Тукаев яза:

*Кеше сатмас кеше тапмак асатмы?*
*Сине соң кайсы дус дошманга сатмый?*
*Синең якты көнең кемнәргә тансык?*
*Кирәксә яшь җиренә кара кан сык!*

Әйтегез зинһар, кайсында нәфасәт, кайсында җиңеллек? «Тәнкыйтьче әфәнде», Гафури укырга, әхлакка өнди, дип, шигырьне коры моральлек җәһәтеннән тәкъдир итә.

Бу җәһәттән караганда, мәшһүр «Бәдәвам» китабына Гафури әфәнде барып җитә алганы юк әле: анда гыйлем – фарыз, хәмер эчү, исереккә сәлам бирү – хәрам, ди.

Һәм Гафуриның сәхифәләр белән язган мәгънәсе урынына, ул бер-ике генә сәтыр[6] шигырь истигъмаль итә.

«Тәнкыйтьче әфәнде», Гафури Америка шагыйре Уитмэнга да якын, ди. Мин сорыйм, үзенең фәлсәфәи

---

[1] Мәфһүмдәге – фикердәге.

[2] Фәрекъ кылдык – аера белдек.

[3] Мотлака – шиксез.

[4] Заһирән – тышкы йөзен.

[5] Сыйраттан – ислам өйрәтүләре буенча, кешеләрнең гөнаһлымы икәнен сыный торган мифик күпер турында сүз бара. Ул күпер кылдан нечкә, кылычтан үткен, имеш.

[6] Сәтыр – юл.

тәнкыйдиясе белән Гарби Европа шагыйре Гётегә дә якын түгелме?

Булыр, булыр, татардан бар да булыр!

Уралец, Тукаевның шигырьләре муаффәкыятьсез тәрҗемәләрдән гыйбарәт, ди. Ул әфәнде, рәхим итеп, менә шушылар арасыннан муаффәкыятьсезлекләр күрсәтсен иде: «Шагыйрьгә», «Бишектәге бала», «Вәгазь», «Шиллердән», «Мәхбүс» һәм «Әльислах» сәхифәләрендә чыккан икътибаслары[1].

Бу язганнардан Касыйм Уралецның татар әдәбиятыннан камил хәбәрсезлеге һәм шигырь дигән нәрсәне вәгазь китабы дип аңлаучылыгы дигән нәтиҗәләрдән башка нәрсә истихраҗ итәлә[2] алмыйдыр.

«Алай булгач, ни өчен соң ул рус матбугатында, хосусән, демократический бер газета сәхифәләрендә, бу мәкалаи галиясен[3] язарга да мәҗбүр булган?» – диярсез.

Мин дә: «Ла лихобби Галиин, бәл либогзый Могавиятин», – дим[4].

*Әмирхан Ф. Татар шагыйрьләре // Әсәрләр: 4 томда: 4 т: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– 60–63 б.*

---

[1] Икътибаслары – файдаланганнары.

[2] Истихраҗ итәлә – нәтиҗә чыгарыла.

[3] Мәкалаи галия – бөек мәкалә.

[4] Гарәпләр мәкале: «Галине яратканлыктан түгел, бәлки Могавиягә дошманлыктан». Бу урында «Гафурины яратканлыктан түгел, Тукайга дошманлыктан» мәгънәсендә.

*Габдрахман Сәгъди*

## Мәҗит Гафури

Милләт, тәрәкъкый кайгысы белән кабынып китүче татар шагыйренең берсе һәм иң карты М. Гафури булды. Октябрьдән соң язган «Эшче» поэмасы белән үзенең иң соңгы әдәби үсү дәрәҗәсен ачык күрсәткән бу шагыйрьнең башта төп йөрәк орлыгы ике тармаклы булып кыяк җибәргән иде. Берсе – аның фикерчелеге, рационалистлыгы һәм шуның белән бергә үгетчелеге, икенчесе дә сентименталистлыгы иде. Башта анда менә шушы ике хосусият катышып барды. «Себер тимер юлы», «Яшь гомерем», «Милләт мәхәббәте» кебек шигырьләре һәм «Аң»дагы шигырьләре шуның ачык мисаллары булды. Озакламыйча ук, шушы ике тармак, ике кыяк уртасыннан ул реализм ботагы үстерә башлады. Хикәяләре шуңар мисал булдылар.

Бу шагыйрьнең беренче шигыре 1902 елда «Тәрҗеман»-да басылып чыкса да, татар әдәбият дөньясында аерым китап рәвешендә, аның беренче адымы 1904 елда «Себер тимер юлы» яки «Әхвале милләт» белән башланган иде.

Ул үзенең шушы беренче әсәрендә Аурупаның мәдәниятен, һөнәрен, сәнгатен, фәнен, машинасын, телеграф, телефон иҗат итүен, гимназия, дарелфөнүн (университет), академия ачуларын мактап җырлады. Татарларны шулардан гыйбрәт алырга өндәп, татарның наданлыгы, тәгассебе, тәрәккыйдән качулары өчен кайгырды. Анналары тәрәккыйгә чакырды. Ахырда «Русия» патшалыгының көчен мактап сүзен тәмам итте.

Ләкин бу шагыйрь бу адымнарында, түбәндә казакъ шагыйре Акмулла шәкерте булып мәйданга чыккан һәм әле, шагыйрь булудан да бигрәк, Акмулла өслүбендәге бер

тезмәче (нәзыйм) генә иде. Вәзен, өслүбтә Акмулла тәэсире анда соңыннан да байтакка сузылды.

1905 ел революциясеннән соң Гафури «Казан мөхбире» һәм «Әхбар»да үзенең шул ук милли-дини рухтагы һәм рационализм юлындагы, ләкин үзендә ярлыларны, мәзлумнарны кызгану, шуларга якынлык тойгыларын аңкыта торган тезмәләр дә язды. Ләкин ул һаман Акмулла тәэсирендә булса да, аның шагыйрьлеге әкренләп ачыла барды. 1906 елда инде Гафуриның «Яшь гомерем» дигән шигырь мәҗмугасы басылып чыкты. Үзен шагыйрь дип таныта башлаган бу әсәрендә дә әле ул өслүб, вәзен ягыннан Акмулла шәкерте иде. Әдәби агым ягыннан исә, монда инде рационалистлык белән сентименталистлык бер тамырның ике тармагы, яисә бер үзәкнең ике кыягы булып үсә башлаган иде.

«Яшь гомерем»е чыккач, Мәҗит Гафури татар дөньясында «милли шагыйребез» дигән исемне алды. Монда:

*Һәр мәкъсудны Хак Тәгалә үзе бирер,*
*Тәвәккәл кыл, иҗтиһад ит, эшкә кереш! –*

дип, татарны дини рухта эшкә өндәүче бу шагыйрь үзенең шушы мәҗмугасы аркылы әле иске «дини, милли» тәрбиясе тәэсирендә, рационализм сызыгында илһамланучы һәм революция дулкыны эчендә фикере ачыла башлаган бер тезмәче, шулай ук шагыйрьлек сызыгына аяк басучы икәнен күрсәтә иде. Бу шигырьләрендә шагыйрьнең яшь чагында башыннан кичкәннәре хикәя кылына. Болардагы бәгъзе шигырьләре аркылы үзендә лиризм чаткысының бара-бара көчәю өмете дә күренде. Бу шигырь мәҗмугасында, заманынча, чыныннан шигырь диярлек матур урыннары юк түгел иде.

*Яз булса, дуслар илә уйнап-көлеп*
*Сәер кылып йөрер идек Идел буен.*
*Ул заман үтеп китте судай аккан,*
*Матур кыздай ишек ачып, кире япкан.*
*Аһ орсаң да ул заманнар кире килмәс,*
*Бәйләвеннән ычкынган эттәй чапкан.*

мисрагълары һәм:

*Бөйлә матур төрле чәчәк үскән ничек?*
*Төрле тараф башын бора җилләр исеп;*
*Күз салсаң, ул кызыллы манзарасы*
*Хыянәтсез саф күңелне китә кичеп,—*

дип башланып, шуннан соңгы 36 мисрагъ матур шигырьләреннән булып, үзләре җиңел, садә татарча белән язылганнар иде. Шуның белән бергә, бу шагыйрь беренче чыгышларыннан ук ач, ялангачларны, ярлыларны кайгыртучы бер шагыйрь булып чыкты. Аның шушы ук мәҗмугасындагы:

*Инсаннарның бәгъзесе тук, бәгъзесе ач;*
*Ачларга мәрхәмәтле күзеңне ач.*
*Дөнья тулган мәзлумнарга күзе төшеп,*
*Габделмәҗит шигырь яза, аптырагач,—*

дигән мисрагълары шуны ачык күрсәтә иде.

Аның бу әсәре чыккач, Риза казый тарафыннан аның турында түбәндәге фикерләр язылып үткән иде: «Габделмәҗит әфәнде милли шагыйрьләремездәндер. Шигырьләрне Акмуллага тәкълид яхуд нәзыйрә юллау сөйләдекене дәгъва иделер вар. Ихтимал ки, бусы бер кадәр дөрест улыр, фәкать буның шигырьләре мәгънә вә асыл җәһәтенчә, Акмулла шигырьләрендән гали идеке мәйдандадыр.

Истибдад гасыры илә хөррият фәрык нә кадәр улыр исә, бунларның адымлары арасында улан фәрык шул дәрәҗәдә бөектер. Хөррият гасырының вә хөррият мәмләкәтенең иң бөек асыры заһири хәлләрдә дәгел, бәлкә батыйндадыр. Һәр мәмләкәтдә зиһен саф, хәят гали, әфкар (шамуллы) улыр. Шул җәһәттән, 17 нче Октябрьгә ирешмәгән Акмулла, бәним кашымда, мәгъзурдыр.

Мәдмуны милләт, гыйлем, җәһаләт, иттифак кеби хакыйки вә файдалы шәйләрдән гыйбарәт улдыгы җиһаты илә Габделмәҗит әфәнденең шигырьләре, әлбәттә, биһалидер, ләззәтледер.

Әгәр дә ошбу өслүбендә дәвам идер улса, халыкларының бөек саналырына мәзһүр улыначагында шөбһә юк. Шуйлә исә дә җөзьи бер нәсыйхәт вирер улсак, шагыйрь әфәнде хәсәнәтемезгә хөрмәт идәрәк сүземезне тәхмил итсә кирәк. Бу да: сөйләячәк шигырьләре ата, ана, угыл, кыздан гыйбарәт улан гаилә җәмгыяте арасында йөз кызартмас рәвештә укылачак сурәтдә улса иде. Буңа күрә 4 нче бәет вә 14 нче мисрагъ йиренә башка шәйләр куелса, гүзәл улмыш улыр ди.

Бән гарәп шигырьләрендә, гадәттә, гашыйк улдыгым хәлдә, күб шигырьләр гаилә җәмгыятендә укылырлык улмадыгы җәһәте илә асыф иләдем. «Яшь гомерем»не укыдыгымда мәктәб вакытлары кичдекне шагыйрь илә берлектә тәәссыф идермәк дәвам әйләдем исә дә, 9 нчы бәеттә улан «Уфа сахраларыны» сөйләдеке җирдә, үзүземне дәват идә алмый, шагыйрьдән аерылып калдым. Бу вакытлар бән һәм шул җирләрнең суларыны эчмеш вә һаваларыны да юламыш идем.

Тәшбиһ дөрестме, дәгелме, бән «Әлгасрелҗәдит» мәҗәлләсендә шигырьләре күрелмеш Г. Тукай әфәндене Мәгарригә вә Габделмәҗит әфәндене Зуфраигә охшатмакдаем. Бу көн илә улмаслар исә дә, бер көн шуйлә улачакларына өмидем камилдер». («Вакыт» гәзитәсе, «Миръат» имзасы белән язылган.)

Мәҗит Гафури шигырьләре аркылы халыкка ике төрле яктан әдәби, иҗтимагый тәрбия бирелә: 1) дини-әхлакый һәм милли тәрбия; 2) динсезлек һәм советчылык юлына тарту – советчылык тәрбиясе.

Шуның өчен Гафури шигырьләрен һәм, шуңа карап, аның әдәби гомерен икегә аерып тикшерә алабыз. Шул яктан карап, Мәҗитнең шигырьләрен, аның әдәби әсәрләрен тикшергәндә без ике төрле Мәҗит күрәбез! Берсе – милли-дини шагыйрь Мәҗит, икенчесе – советчы, динсез материалист Мәҗит.

«Себер тимер юлы», «Яшь гомерем», «Милләт мәхәббәте» (1907 елда басылды), «Ирләргә махсус милли ши-

гырьләр», «Кызларга махсус милли шигырьләр»не язган Мәҗит динле, милләтче идеалист Мәҗит иде. Хәтта аның Февраль революциясеннән соң басылган «Кызыл байрак»ында да андагы бу рухи салыныш көчле иде әле. Октябрь революциясен бик яратып күтәп каршы алган һәм революция ялкыны белән яңадан нык күтәрелгән Мәҗит анда да әле:

*Изге, ак, пакь юл белән барганда булсын җан фида,*
*Шул вакытта алсаң ал бу пакь җанымны, йә Хода! –*

дип, башта ук Ходага эндәшеп, аңа ялынып башлаган булса, шул ук шигыренең ахырында:

*Әй шәһид! Әле дә синең рухың янып шул гөл кебек,*
*Сайрый торгандыр һаман да моңланып, былбыл кебек, –*

(«Изге юлда» дигән шигыреннән)

дип, рух дигән бер нәрсәнең барлыгын һәм аның мәңгелеген тәлкыйн итүдән котыла алмаган иде. Монда:

*Булса күңелең киң, сыярсың,*
*Тәңренең киң дөньясы.*

(«Күңелгә» дигән шигыреннән)

*Нинде сер шатлыклы, якты? Өнме бу, я төшме бу?*
*Тәңренең кодрәт кулы белән кылынган эшме бу?*

(«Азатлык хөрмәтенә» дигән шигыреннән)

*Китте өстән ул караңгы пәрдәләрнең һәммәсе,*
*Бетте коллыклар, бүген сез тик Ходайның бәндәсе.*

(«Курыкмагыз» дигән шигыреннән)

*Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Казан: Татар.дәүләт нәшр., 1926. – 203–207 б.*

*Габдрахман Сәгъди*

## Мәҗит Гафури — символист

Монда без Мәҗит Гафуригә аз гына тукталып үтәргә телибез. Бу шагыйрьнең дә символизм мәктәбенә кайткан вакыты һәм шуның нәтиҗәсе булып туган шигырьләре бар. Ул 1911 елгы «Шура»ның 2 санында түбәндәге шигырен бастырды:

*Кай вакытта әллә нишләп әйләнәм ямьсезләнә:*
*Бер югалган нәрсәсе бар төсле күңлем эзләнә.*
*Бер урында тормый күңлем, тибрәнә, тапмый карар,*
*Җир йөзе нурсызлана, бал-майлар тәмсезләнә.*
*«Җир йөзендә чын сәгадәт юк» дип әйтеп куям:*
*Әй күңел, җирнең йөзеннән чын сәгадәт эзләмә.*
*Әйләнәмдәге матурлыкларны тиң күрми күңел,—*
*Иң ахырда мәгънәви куәткә күңлем тезләнә.*
*Ошбу куәт каршысында баш бөгәм, хәйран калам:*
*Шул сәгатьтә шатланам, шуннан гына ләззәт табам.*

Шуңа тагын бу шагыйрьнең «Тәэссорат» («Аң», 17, 1913) дигән чәчмә лирик парчасы белән «Мәхәббәт» («Аң», 8, 1914) һәм «Халәте тәәссердә» («Аң», 24, 1914) дигән тезмәләре кебек шигырьләрен кушарга кирәк. «Тәэссорат»ы тәмамән тәсауф[1] һәм символизм җимеше. Монда ул язның матурлыгын тасвир итеп болай яза: «Безне шатлык катыш бер моңлылык, әллә нинди бер шигърият исерткән. Мәгънәви бер куәтнең тәэсире безне тик торырга мәҗбүр кылган сыман иде».

«Бөтен мәхлукат мәгънәви бер куәтнең тәэсиреннән җәйге ихтыярый сөкүнәткә илтизам кылганнар. Боларның һәрберсе фәүкылгадә бер эш көткән сыман бер куәткә тәуаскылык итәләр. Барча әшья кайдандыр... бер илһам,

---

[1] Тәсауф – суфичылык тәгълиматы.

сихри бер тәбликның булуын көтә яки, тиздән булачак бер нәрсәнең ләззәтеннән мәхрүм калмас өчен, бөтен калебләре, вөҗүтләре белән бер куәтнең алдында тез чүккәннәр».

* * *

«Бу минутта дөньяны бер мәгънәви газамат чолгаган...»

* * *

«Сандугачның күңелендә сакланып торган мәхәббәт, гыйшык, сер моңлы тавыш белән тирә-якка тарала башлады».

* * *

«Ниһаять үзенә илһам кылынган әсрарны, мәхәббәт вә гыйшыкны кәмале муаффәкыять белән тәблик итеп беткән рәвешле үзенең сайравыннан туктады. Бу минутта җир өсте һич бер җинаять вә усаллык эшләнмәгән әрзе мөкатдәс сурәтен алды. Сөкүнәт тагы бер-ике минутка сузылды».

* * *

«Газамат, әллә нинди бер мәгънәви куәт тарафыннан арта төште. Әшьяларның бер-берсе арасында галәкә сизелде. Болар бер-берсенә мәгънәви, фәкать ныклы бер көч белән бәйләнгән кебек булдылар. Һәммә нәрсә бер-берсен кочакларга, бер-берсенең муенына сарылырга омтыла башлады».

* * *

«Бу минутта һәммә нәрсә тәэссернең иң ниһаятенә җиткән иде. Чөнки бу минутта җир өстендә чын мәхәббәт белән чын гыйшык хөкем сөрә иде. Аһ, чын мәхәббәт белән чын гыйшык...»

Әсәрдән гәрчә кисентеләр генә алынган булсалар да, безгә шушы мисаллар Мәҗит Гафуриның да вакыты белән татар әдәбиятындагы символизм агымына кушылып киткәнен яхшы ачалар. Бу мисаллар да янә ачык; артык аңлатуга терәлеп тормыйлар. Шулай да монда тик шуны

гына искәртеп үтәргә тиешбез. Шагыйрьдән китерелгән шул мисаллар монда сандугачның «Илаһи мәхәббәт»кә символ итеп алынганын, шуның аркылы шагыйрь үзе дә шул мәхәббәтне «Хәкъ гыйшкы»н җырлаганын ачык күрсәтәләр. Шагыйрь монда шундый минутлардагы «ләззәт»ләр аркылы гүя матди дөньяның азапларыннан юаныч эзли һәм таба... Бу юлда активлык күрсәтеп, башкаларны да шуның белән юатырга тели.

«Мәхәббәт» дигән шигырендә ул аны болай тасвирлый:

*Кайда барма, кайда йөрмә, ул мәхәббәт чаткысы,*
*Кап-караңгы төндә дә балкый аның шул яктысы.*
*Кайда барма, кайда йөрмә, ул мәхәббәт анда бар;*
*Тик аны кешеләр һаман да күрмәмешкә салыналар.*
*Ул мәхәббәт төрле җирдә, төрле төстә ялтырый,*
*Ул тәҗәлла итдисә таулар вә ташлар калтырый.*
*Юк җире юк ул мәхәббәтнең, аны белми кеше,*
*Булмавы мөмкин түгел, ул – бу галәмнең тәңресе.*

Югарыдагы мисалларда да, бу тезмәсендә дә шагыйрь карашында Көнчыгыш суфилары һәм символистлардагы шикелле үк дөньяның «Хәкъ гыйшкы» белән әйләнә дип төшенүчелек бар икәнен ачык күрәбез.

Шагыйрь үзенең «Халәте тәәссердә» дигән шигырендә:

*Һәр вакыт иссә күңелдән чын мәхәббәтнең җиле,*
*Мин буламын шул вакыт бу бапта Мәҗнүннән тиле,*–

дигәне шикелле, аның бу моменты – чынлап та шундый «мәҗнүн»ләшү моменты. Ләкин ул кай вакытта бу турыда «мәҗнүн»леккә дә төшә:

*Хәйләсез, чын саф мәхәббәтне күңел эзләп оча,*
*Әйләнеп мәҗнүн булып кайта, кунар җир тапмыйча.*

* * *

Чолгап алган дөньяның вак тормышы башка кунып,
Көч бетә, хәлдән таям, булмый һаман да чыныгып,–
дип җырларга керешә.

*Сәгъди Г. Символизм турында.– Мәскәү: Центриздат, 1932.– Б.102–105 б.*

*Кәрим Тинчурин*

## Мәҗит Гафуриның драматургиядәге урыны

Мәҗит Гафуриның Октябрьдән соңгы иҗат дәвере идея байлыгы, мәгънә тирәнлеге һәм иҗатындагы төр күплеге белән, революциягә чаклы булган иҗатыннан бик нык аерыла.

Бу дәвердә аның иҗатына драматургия жанры өстәлеп, «Эшче» поэмасын һәм «Кызыл Йолдыз» пьесасын яза. «Эшче» поэмасы татар операсы тудыру эшендә, аның үсү тарихына нигез ташы булып салынды. «Кызыл Йолдыз» пьесасы – татар совет драматургиясендә авылда сыйнфый көрәшне, яңа кешеләр туу тарихын күрсәткән, авылда коллектив хуҗалык төзелешен беренче тапкыр чагылдырган уңышлы драма әсәрләр тезмәсенә кергән әсәр. Бу пьесаның эчтәлеген әсәрдәге бер генә җөмлә дә аерымачык күрсәтә: «Иске тормыш җимерелә, яңа тормыш төзелә, бу бик күп хезмәт, күп көрәш, күп көчләрнең берләшүеннән килеп чыккан матурлык»,– ди.

Мәҗит Гафуриның драматургия өлкәсендә кыйммәте, дөреслекнең, чын күңеллелекнең, катлаусыз чынлыкның һәм сыйныфлар арасындагы көрәшнең үткен рәвештә сизелүендә. Дөрес, аның образлары катлаусызлар, ләкин шулай да аларның чын кешеләр икәнлекләренә ышанасың. Вакыйгаларның, интриганың бик гадилегенә карамастан, алар укучыларны да, карауччыларны да үзенә якынлаштыра алалар.

Драматургия иҗатында ул нигез урынны сүзгә бирә. Вакыйгаларны, хәлләрне күп урында хәрәкәткә караганда сүз аркылы бирергә ярата. Шуңар карамастан, укучылар да, карауччылар да ялыкмыйлар. Моның төп сәбәбе, югарыда әйткәнчә, дөреслек, катлаусыз чынлык аркылы

тенденцияне үткәрә белүдә. Мисал өчен, «Кызыл Йолдыз» пьесасыннан берничә юлны күрсәтергә мөмкин. Бу пьесаның интригасы болай башлана:

**Сәлимә** – Кайттыңмыни, ничек бик тиз кайттың?

**Салих** – Әйтмә дә инде. Анда күзне дә ачырмыйлар. Әлеге шул Газизнең бәласе. Тегермәнгә барып керү белән: «Әле син исәнме?» – диләр. Аптырагач, арышны кире алып кайттым.

**Сәлимә** – Анда нәрсә сөйлиләр тагын?

**Салих** – Шул бер балык башы инде. Кызыллар китеп, аклар килгәннән бирле күрә алмаган кешеләре без булдык инде.

**Сәлимә** – Кемнәр котырыналар соң?

**Салих** – Кем булсын. Шулар инде. Иң элек тегермәнче Вәли сүз башлады: «Нигә, – ди, – безнең тегермәнгә киләсез? Синең Газизең, бөтен нәрсәләрне байлар кулыннан ярлыларга алып бирәбез, дип сөйләгән иде бит. Әнә, барыгыз ярлылар салган тегермәнгә. Син үзең нигә кызыллар белән китмәдең?» – ди. Аның сүзенә тәкърлек Низам кушылып китте: «Ярлыларның тегермәннәре буламыни? Аларга әзер тегермән кирәк бит», – ди. Шуларның сүзләренә гарьләнеп кайтып киттем.

Әсәр баштанаяк шул юл белән бара. Вакыйгалар күбрәк сүзләр аркылы гына бирелсәләр дә, чынлык, дөреслек көче тамашачыны да, укучыны да ялыктырмый. Мәҗит Гафури үзенең бөтен иҗатында чынлыкны нигез итеп алганлыктан, аның кулаклары да плакат, сурәтләр булып кына түгел, аерым үткен штрихлар аркылы җанлы кешеләр булып гәүдәләнәләр. Шуның аркасында сыйныфлар көрәше үткен, ачык чагылдырыла. Яшь язучыларга драматургия өлкәсендә дә җанлы тел тудыруда чынлыкны, катлаусыз чынлыкны күрсәтү юлында Мәҗит Гафуридан өйрәнерлек урыннар бар.

*Тинчурин К. Мәҗит Гафуриның драматургиядәге урыны //Коммуна.–1934.–18 ноябрь.– № 186*

*Муса Җәлил*

## Мәҗит Гафуриның иҗаты турында[1]

### *I*

Шагыйрь Мәҗит Гафури — Бөек Октябрь социалистик революциясенә чаклы булган татар әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе. Шуның белән бергә, ул үзенең иҗат тормышының яртыдан күбрәк өлешен Советлар хөкүмәте шартлары эчендә үткәреп, совет язучысы дигән хөрмәтле исемгә ия булып үлде. Октябрь социалистик революциясенә чаклы булган иҗатында киң хезмәт иясе халыкның аянычлы тормышын, ерткычларча изелүен, күз яшен чагылдырган һәм үз чорының демократик идеяләрен гәүдәләндергән шагыйрь Мәҗит Гафури, илебездә бөек социалистик революция җиңеп чыккач, советлар платформасына басты һәм барлык иҗат көчен пролетариат диктатурасын ныгытуга, эксплуататор сыйныфларны кысрыклау һәм бетерүгә, социалистик җәмгыятьне төзүгә хезмәт иттерде.

Октябрь революциясенә чаклы булган татар әдәбиятына аның социаль нигезе һәм идея юнәлеше күзлегеннән тулаем бер караш ташлаган чакта, аңарда бер-берсенә каршы куелган ике төп сызыкны һәм ике төп төркем язучыларны аерырга була. Бер якта — реакциягә хезмәт итүче, буржуазия һәм помещиклар властен ныгытырга омтылучы, капитализм системасын яклаучы, буржуа идеологиясен алга сөрүче әдәбият һәм язучылар төркемен күрергә мөмкин булса, икенче якта исә — реакциягә каршы көрәшүче, реакцион буржуазияне, эксплуататорларны һәм, гомумән, капитализм системасын фаш итүче, демократик идеяләрне алга сөрүче әдәбият һәм язучылар төркемен очратырга була. Бер якта — күпчелек халык җилкә-

[1] Кыскартып бирелде.

сендә көн күрүче бер уч эксплуататорларның тормышы белән кызыксынган, изелүче халык авазын ишетмәскә тырышкан, сәнгатьне тормыштан аерырга омтылган һәм аны содержаниесе, теле, формасы белән халык иҗатына каршы куйган әдәбият һәм язучыларны күрсәк, икенче якта – киң халык тормышын чагылдырырга тырышкан, әдәбиятны халыкка хезмәт иттерергә омтылган һәм үз иҗатларын содержаниесе, теле, формасы ягыннан халык белән, халык иҗаты белән бәйләгән әдәбият һәм язучылар төркемен күрәбез.

Әлбәттә, бу ике төркем арасында «кытай стенасы» төсле бер чик куеп булмаган кебек, ул төркемнәргә кертелгән аерым язучыларның да һәммәсен бертигез хөкем итү мөмкин түгел. Буржуаз идеологияле язучыларның һәммәсе дә бертигез дәрәҗәдә реакцион булмаган кебек, демократик группа язучылар арасында да дөньяга карашлары ягыннан булсын, халыкка мөнәсәбәтләре ягыннан булсын, әдәби стильләре ягыннан булсын, зур аерымлыклар табарга була. Шулай ук бу ике төркем арасында икеләнүче, ике уртада торучы, күп төрле каршылыклы язучылар бар һәм, һәр язучыны аерым алган чакта да, ул бер рамка эчендә катып калган булмый, һәр язучы социаль шартлар һәм шул чорның идеология үсеше тәэсирендә һаман үзгәрә, үсә бара, һәм шуның өчен ул бер позициядән икенче позициягә күчәргә мөмкин. Менә шуларны искә алган чакта, революциягә чаклы татар әдәбиятын гомуми караштан чыгып бу ике төркемгә бүлүдә билгеле бер шартлылык бар. Ләкин, гомумән алып караганда, революциягә кадәрге татар әдәбиятының үсеш юлында бу ике омтылыш һәм бу ике сызык – реакцион һәм демократик сызыклар – бик ачык күзгә ташланалар. (...)

Демократик идеяләр белән сугарылган, помещиклар һәм буржуазия строена карата оппозициядә булган төркем язучыларның иҗат юллары бөтенләй башкача булды. Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, М. Гафури, Ш. Камал, М. Фәйзи кебек язучылар изелүче халык файдасын яклап,

аларның тормышларын яхшырту идеяләрен алга сөрделәр. Алар патша Россиясендәге коточкыч эксплуатацияне фаш иттеләр. Самодержавиегә һәм эксплуататор сыйныфларга нәфрәт белдерделәр. Төрлесе төрле дәрәҗәдә демократик идеяләр өчен көрәштеләр. Бу төркем язучылар стильдә һәм формада да реакцион группа язучылардан нык аерылдылар. Болар өчен реализм, халыкчанлык һәм фольклорны үзләштерү характерлы булып калды. Инде бу төркем әдәбиятның үсү юлы һәм язмышына карасак, аның, логик рәвештә революциягә табан үсә барып, пролетариат революциясе платформасына килеп кушылганын күрәчәкбез. (...)

Революциягә чаклы татар әдәбиятының демократик катлавын тәшкил иткән язучылар барысы да бертигез караштa булмадылар, әлбәттә. Мәсәлән, Гафур Коләхмәтов пролетариатның помещикларга һәм буржуазиягә каршы сыйнфый көрәше һәм пролетариат революциясе идеяләрен куйганы хәлдә, Галиәсгар Камал әле бу чорда бары консерватив рухани һәм буржуалар средасын һәм әхлагын тәнкыйть итү белән генә чикләнде; пролетариат сыйнфый көрәше карашларын чагылдырмады. Демократик поэзия вәкилләре булган Г. Тукай һәм М. Гафуриның да мәсьәләләрне куюларында аермалар бар. Шунлыктан гомумән татар әдәбиятында тоткан урыннары, идея юнәлешләре, тулаем дөньяга карашлары ягыннан бер сафка куйган хәлдә, бу язучыларның конкрет урыннарын билгеләү өчен, аларның һәркайсын аерым-аерым тикшерергә кирәк.

Болар арасында М. Гафури баштагы чорларда үз иҗатының шактый каршылыклы булуы, иҗатының катлаулы юл үтүе белән күзгә бәрелә.

М. Гафури авылда ярлы хәлфә семьясында туып, яшьлеген иске мәдрәсәләрдә, зур шәкертләрнең вак-төяк йомышларын үтәп, тамак туйдырып үткәрә. Шәкертлек дәверендә җәйләрен читкә китеп, байларга ялланып, ялчылык белән көн күрә. Итчеләрдә хезмәтче булып эшләүдән башлап, Рәмиевләрнең алтын приискаларында кара эшче булып эшләүләрне дә башыннан кичерә. Ка-

зах сахраларында һәм татар авылларында хәлфәлек итү дә анық кәсебенә керә. Ахыр килеп, ул Уфадагы «Шәрык» типографиясендә корректор булып эшли. Бу дәвердә ул типография эшчеләре белән бик якынлашып, аларның тормышын яхшы өйрәнә.

М. Гафури үзе хезмәт иясе халык арасында, үз кул көче белән көн күреп, изелеп яшәгәне хәлдә, аларның кайгы-хәсрәтләрен, зар һәм нәфрәтләрен үз йөрәгеннән кичереп үсте. Бу хәл шулай ук аның иҗатының демократик карашлар белән сугарылуында роль уйнамый калмады. (...)

Әлбәттә, аның социализмга таба булган бу иҗат юлы тигез генә, шома гына үтмәде. М. Гафури үз башыннан төрле йогынтылар, икеләнүләр кичерде. Аның иҗат юлы борылмалы һәм катлаулы булды.

Без бу мәкаләдә, аның ижат тормышындагы бөтен моментларга тулы рәвештә тукталмастан, аның тулай иҗат юлына кыскача гына анализ ясауны бурыч итеп куябыз.

### *II*

М. Гафуриның әдәби иҗат эше 1902–1903 еллардан башлана. Шушы елларда аның «Себер тимер юлы» һәм «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» исемле әсәрләре басылып чыгалар. «Себер тимер юлы» җыентыгына шушы исемдәге озын шигырьдән башка «Вә иннә мин әш-шигъри лә-хикмә», «Гыйлем» кебек шигырьләре дә кертелгән иде. Моннан соңгы 1904–1905 елларда язылган шигырьләре соңрак «Яшь гомерем», «Милләт мәхәббәте» җыентыкларында чыктылар.

Бу еллар Россиядә помещиклар һәм фабрикантларның эшчеләр һәм крестьяннарны рәхимсез изүләре, илдә кара монархия хөкем сөрүе һәм илне каплап алган промышленность кризисы нигезендә илдә эшчеләр хәрәкәтенең күтәрелүе белән характерлы. (...)

Мәҗит Гафури яшьтән хуҗаларга кул көчен сатып, ярлы авыр тормышта яшәгәнгә, хезмәт ияләренең ул вакыттагы тормыш шартлары аның башыннан да кичтеләр. Бу

хәл аны хезмәт иясе халыкка якын итте һәм аның дөньяга карашына зур йогынты ясады.

М. Гафуриның беренче әсәрләреннән булган «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» шәһәрдәге сезонлы эшченең авыр тормышын чагылдыра. Бу әсәрдә капитализм системасында үз кул көче белән көн күрүче ярлының нинди авыр шартларда яшәве, аның киләчәгенең никадәр өметсез булуы, аның аяусыз изелүе гәүдәләндерелгән. Икенче яктан, эшче һәм крестьяннарның бу кызганыч авыр тормышы һәм илдә эшчеләр хәрәкәтенең күтәрелүе, революциянең якынлашуы М. Гафурида азатлык өчен көрәш фикерләрен уяттылар. Азатлык өчен көрәш фикерләре М. Гафурида башлыча милләтне азат итү, милли иркенлекне алу төсендә чагылдылар.

«Милли өлкәләрдә барлык яки барлык диярлек дәүләт хезмәте урыннарында рус чиновниклары утырдылар. Учреждениеләрдә, судларда барлык эшләр рус телендә алып барылды. Милли телләрдә газеталар һәм китаплар чыгару тыелды; мәктәпләрдә ана телендә уку-укыту тыелды. Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды, рус булмаган милләтләрне көчләп «руслаштыру» политикасы үткәрде. Царизм рус булмаган халыкларның палачы һәм аларны газаплаучы иде». («ВКП(б) тарихының кыскача курсы»)

Патша Россиясендә бу милли кысынкылыкларга каршы изелүче милләтләрнең укымышлылары арасында протест һәм оппозицион хәрәкәт күтәрелде. Бигрәк тә 1905 елгы революция алдыннан булган елларда бөтен илдә эшчеләр хәрәкәтенең көчәюе, крестьяннарның помещиклар һәм урындагы властьларга каршы чыгышлары ешаю, студентлар арасында оппозицион хәрәкәт башлану һәм самодержавиенең нигезе какшау – милли кысынкылыкларга каршы булган бу хәрәкәткә зур этәреш бирделәр. (...)

Әгәр без Мәҗит Гафуриның бу чордагы әсәрләренә күз төшерсәк, аның милли азатлык өчен көрәшне чынлап та

самодержавиегә һәм империализмга каршы куелган хәлдә аңлавын күрәбез.

Ул «Чит җирләрдәге мөселманнарның хәле» дигән шигырендә Европа империализмы тарафыннан talanучы Көнчыгыш колония халыкларының хәлләрен сурәтли. Европа империалистларының югары культурага һәм техникага, кораллы көчкә таянып, үз байлыкларын арттыру өчен колонияләрдәге халыкларны талаулары бу шигырьдә ачык әйтелгән, һәм бу шигырь, һичшиксез, империализмның йөзен фаш итә:

*Французның күзе төшеп тора Фаска,*
*Германия кырын төшә алдырмаска.*
*Фас аларга әзер пешкән аш булганга,*
*Аурупалар мөмкин түгел талашмаска.*

Бу юллар изелгән милләтләрнең дошманы империализм булганын ачык аңлаталар.

Шушы юллардан соң М. Гафури шигырьдәге фикерне Россиягә күчерә дә түбәндәге юлларны өстәп куя:

*Моннан соң күзеңне сал син бирегә:*
*Халкымыз ниләр эшли, ниләр күрә!*

Бу шигырьдә М. Гафуриның милли азатлык мәсьәләсен ничек куйганы ачык күренә. Ул, бер яктан, милли азатлыкны халык азатлыгы төсендә куйса, икенче яктан, изелүче милләтләрнең дошманы итеп империализм һәм самодержавиене таный. Аның «милләтне азат итү» турында язган бөтен юллары изелүче милләтнең бер уч эксплуататорлары интересын күзәтүгә кайтып калмый, ә һәрвакыт изелүче милләтнең киң халык массасын азат итүгә карата әйтелә.

М. Гафуриның бу дәвердәге иҗатында өченче бер характерлы мотив – наданлыкка, искелеккә, дини хорафатларга һәм консерватизмга каршы көрәш мотивы булды. Бу еллар татар интеллигенциясе арасында җәдитчелек хәрәкәте көчәюе белән характерлы. Татар либераль буржуазиясе дә бу җәдитчелек хәрәкәтенә тотынып карады. Россиядә сакланып килгән иске патриархаль мөнәсәбәт-

ләр, феодализм калдыклары, дин һәм руханиларның артык хакимлеге капитализм үсүенә комачаулаучы киртә булып тордылар. Татар буржуазиясе үзенең завод-фабрикаларын үстерү өчен, производство һәм сәүдә эшләрен юлга кую өчен яңа фән һәм техниканы үзләштергән кадрларга сусый башлады. Ул вакыткача яшәп килгән дини схоластик мәдрәсәләр буржуазияне канәгатьләндермәделәр. Шунлыктан мәктәпләргә реформа кертү, балаларга яңа фәннәр укыту, аларны европалаштыру буржуазия өчен дә файдалы булды. Шунлыктан башлыча иске дини мәктәпләргә каршы яңача фәннәр укыта торган мәктәпләрне алга сөргән җәдитчелек хәрәкәтендә буржуазия дә берникадәр роль уйнады. Ләкин буржуазиянең искелеккә, наданлыкка каршы көрәше эзлекле булмады. Ул бу көрәштә халыкны агарту һәм алга җибәрү интересын түгел, бәлки үзенең тар капиталистик интересларын гына күзәтте һәм, уңай килгән саен, үзенә файдалы булган урында, татар карагруһ руханилары һәм феодаллары белән килешү ягын карады.

Мәктәпләрне реформалаудан башланган җәдитчелек хәрәкәте демократик карашлы вак буржуазия интеллигенциясе арасында, бигрәк тә укучы яшьләр арасында, киң җәелде. Ул, фән өчен генә көрәшүдән үтеп, гомумән, консерватив руханиларга каршы, иске патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләргә каршы, бөтен яңалыкны тыеп, кысрыклап торуларга каршы гомуми көрәш төсен алды, һәм ул еш кына самодержавиегә каршы демократик таләпләргә дә илтеп җиткергәләде. Халыкны надан, культурасыз хәлдә яшәтүне күзәткән, халыкка каршы реакция көчләрен яклаган самодержавие, әлбәттә, бу хәрәкәткә аяк чалырга тырышты; аның массовый төс алып тирәнгә китүенә мөмкинлек бирмәскә тырышты.

Мәҗит Гафуриның идеологиясенә бу җәдитчелек хәрәкәте зур йогынты ясады. Ул, үзе иске дини схоластик мәдрәсәләрне күреп, шәкертлек дәверен кичкән булганы хәлдә, бу хәрәкәтнең нинди уңай яклары булганын ачык

күрде. Шунлыктан М. Гафуриның беренче әсәрләрендә үк без иске дини хорафатларга, консерватизмга каршы дулкынланып язган юлларны очратабыз.

Аның «Себер тимер юлы» дигән беренче җыентыгына кергән шигырьләрендә шундый юллар бар:

*Гаҗәеп җиһанның ташулары,*
*Мәгърифәткә һәр милләтнең ашулары.*
*Бу икедән күп дәрәҗә гаҗәбрәк*
*Тәрәккъкыйдән татарларның качулары.*

(«Вә иннә мин әш-шигъри ләхикмә»)

*Гыйлемнең өстенә һөнәр кирәк,*
*Җимешнең файдасы аз яшел булса.*
*Ник кирәк бу заманда тәгассеплек*[1]*,*
*Тәгассепле милләтләр юлдан язар.*

(«Гыйлем»)

Гыйлем алу, культуралы булуны М. Гафури эре буржуазия вәкилләречә тар капиталистик интерестан чыгып түгел, ә гомумән, халыкны ярлылыктан, бәхетсезлектән коткару интересыннан чыгып куйды. Мәсәлән:

*Кил, милләтем, фәкыйрьлектән сакынаек, –*
*Һөнәр гыйльмә тырнаклар батыраек.*
*Һәр зарарның башлыгы фәкыйрьлектә,*
*Ул мәлгунь фәкыйрьлекне ни кылаек?*

Шулай итеп, М. Гафуриның беренче чор иҗатында өч төп мотивны очратабыз. Алар, бер яктан, ярлыларның, ярлы шәһәр сезонлы эшчеләренең авыр, аянычлы тормышын чагылдыру, шулар өчен ачыну («Фәкыйрьлек белән үткән тереклек»); икенчедән, милли кысынкылыкларга һәм хокуксызлыкларга каршы протест белдерү, артта калган милләтләрне изүче империалистларны фаш итү; һәм, өченчедән, иске патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләргә каршы, наданлыкка, культурасызлыкка һәм дини хорафатларга, консерватив руханиларга каршы, яңалык һәм белем өчен көрәшү мотивларыннан гыйбарәт. (...)

[1] Тәгассеплек – наданлык, фанатизм.

### III

1905 елгы революция киң катлау халык массасын самодержавиегә каршы көрәшкә күтәрде. Изелгән милләт халыклары эксплуатация һәм милли изелүдән котылу, тигез хокук өчен көрәштеләр.

Мәҗит Гафури бу революцияне башлыча үзенең изелгән милләте өчен ирек, хокук һәм тигезлек даулау мотивлары белән каршылады. Аның бу революция уңае белән язылган «Шатлык шигыре», «Алмашыну», «Хөррият дәверендә» дигән шигырьләре башлыча милләтне революция башлану белән тәбрикләүдән гыйбарәт. Мәсәлән:

*Әй, каләм! Шатлык белән караңны түк!*
*Тәбрик итеп милләтемә язам мәктүп,*
*Һәр җәһәттән хөрриятләр ачылганга,*
*Бу көндә хәсрәтемнән шатлыгым күп.*

(«Шатлык шигыре»)

М. Гафури бу шигырьдә, революция аркылы кулга төшкән ирекне файдаланып, гыйлем алырга, «милләтне тәрәккъый иттерергә» өнди:

*Тәрәккъый фикере керсен эчебезгә,*
*Бөйлә форсат безгә гаять сирәк килә,*
*Дүрт кул белән ябышаек эшебезгә.*

(«Шатлык шигыре»)

*Һәр халык та бу көннәрдә күзен ачты,*
*Иң югары дәрәҗәгә аяк басты.*
*Гареб-шәрык милләтенә караганда,*
*Безләр булып торып калдык аяк асты.*

(«Хөррият дәверендә»)

Бу юлларда без М. Гафуриның хөрриятне башлыча гыйлем алырга, алга китәргә мөмкинлек бирүе ягыннан караганын күрәбез. Шуның белән бергә ул милләтне бербөтен итеп алып, самодержавиегә каршы куйганы хәлдә, шул милләт эчендәге эксплуататор һәм изүчеләр арасындагы сыйнфый каршылыкларга, изелүчеләр сыйныфының сыйнфый көрәшенә басым ясамый. Бу хәл аның Беренче

думаны вак буржуаз иллюзия белән каршылавына сәбәп була («Беренче дума ачылды»).

Революция башындагы шигырьләрендә күрелгән бу хәл М. Гафури иҗатында беренче дәвердә урын алган йомшаклык һәм чикләнүчәнлекнең берникадәр сакланганын күрсәтәләр.

Ләкин революция җәелгән һәм күтәрелгән саен, эксплуататорлар белән хезмәт ияләре арасындагы каршылык тирәнрәк ачылды. Буржуазия белән пролетариат, помещиклар белән крестьяннар арасындагы көрәш кискенрәк төс ала барды. Бу хәл М. Гафуриның карашларына йогынты ясады. М. Гафури алдагы шигырьләрендә гомумән «милләтне азат итү» һәм мәгърифәтле булу идеяләреннән – хезмәт халкын азат итү, эксплуатацияне бетерү, эксплуататорларны фаш итү идеяләренә күчә барды. Революция аңа эксплуататорлар белән эксплуатацияләнүчеләр арасындагы сыйнфый каршылыкны тирәнрәк төшенергә ярдәм итте. Яшьтән хезмәт ияләре белән нык бәйләнгән, алар арасында тәрбияләнеп үскән М. Гафури хезмәт иясе халыкка һәрвакыт тирән мәхәббәт белән һәм байларга каршы нәфрәт белән янды. Бу хисләр аның беренче чәчмә әсәре булган «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек»тә дә чагылган иде. Ул бу әсәрендә амбары тулы арыш һәм солы булган, көн дә кунакка йөрүдән бушамаган Садрый байларга каршы, шул байлар эшен көн-төн эшләп тә, тамак та туйдыра алмый, чиктән тыш фәкыйрьлектә яшәгән Нигъмәтуллаларның аянычлы тормышын сурәтли һәм үзе шул ярлылар белән бергә алар өчен сызланып: «Ах, ни чара, фәкыйрьлек бәласе үткән шул»,– дип ачынып куя. (...)

### *IV*

1905 елгы революция җиңелеп, эшчеләр һәм крестьяннар хәрәкәтенең самодержавие тарафыннан бастырылуы М. Гафурида реакциягә каршы кискен нәфрәт уятты. М. Гафуриның 1908–1910 еллар арасындагы шигырьләре җир йөзендәге хокуксызлыкка, тигезсезлеккә, зур күпче-

лекнең бәхетсезлектә яшәп тә, бер уч байларның рәхәттә көн итүләренә ачыну тойгылары белән сугарылганнар. М. Гафури 1905 елгы революциядән бик зур сабак алып чыкты. М. Гафуриның моннан соңгы шигырьләре аның хезмәт иясе халыкка якынайганнан-якыная барганын күрсәтәләр. Ул ярлыларның изелүе темасына бөтен йөзе белән борылып, буржуаз стройдагы бөтен тигезсезлек, ирексезлек, хокуксызлыкны аяусыз фаш итәргә керешә. Аның бу чордагы шигырьләре ул вакытта яшәп килгән системага аеруча нәфрәт, дошманлык белән яңгырыйлар һәм алар үзләренең үткен очлары белән реакцион буржуазиягә каршы юнәлтелгәннәр. (...)

***V***

1905 елгы революция бастырылганнан соң башланган кара реакция кайбер катлауларда, бигрәк тә вак буржуа интеллигенциясе арасында өметсезлек тудырды. Бу нәрсә М. Гафуриның беренче революциядән соңгы кайбер шигырьләрендә дә чагылып үтте. Мәсәлән, ул 1908 елда «Тәәссеф» дигән шигырендә:

*Дөньяга килгәнемә мин үкендем,*
*Ни чара? Китеп булмый, инде күндем.*
*Төзәлүне өмет итеп торган идем,*
*Булмый икән, ул фикердән инде дүндем,* –

дип язды.

1912–1915 еллар арасында М. Гафуриның кайбер шигырьләре дөньяга нәфрәт, дөньядан бизү, эч пошу, тарсыну, күңелгә урын таба алмау, билгесез юлда маяксыз эзләнү хисләре белән сугарылганнар. Мәсәлән, «Моң вә сагыну» дигән шигырендә эч пошу, үткәнне сагыну турында җырласа, «Уйлаган чакта» дигән шигырендә билгесез бушлыкта юл таба алмый, көймә төсле чайкалуны сурәтли. Шул ук елдагы «Бер төндә», «Уйлану» шигырьләре дә билгесез язмышта юл-маяк таба алмый аптырап эзләнүне сөйлиләр.

«Яшь күңел», «Тәрәддед» шигырендә ул «яхшылыкка һәм хаклыкка» урын калмаган дөньяга нәфрәт белдерә һәм, бу дөньяга кул селтәп, шәраб эчеп юанырга чакыра:

*«Нинди максуд бар бу тормыштан? Киләчәк билгесез,*
*Нишләгән чакта нәҗат[1] бар, кем бирер катгый җавап?*
*«Яхшылык», «хаклык» дигән сүзләр алар алдау гына,*
*Һичвакыт алданма бу сүзләргә, чын сүз, дип карап.*
*Шатланырга юл таба алсаң, шатланып кайгың тарат.*
*Гыйш-гыйшрәт сөр җиһанда, алга килсә – эч шәраб». (...)*

1914 елгы Европа сугышын М. Гафури нәфрәт һәм дошманлык белән каршы алды. Ул «Ела», «Юктырсың ла, Алла», «Бер нәүхә», «Күңелсез бәйрәм» кебек шигырьләрендә империалистик сугышның халыклар өчен авыр газап һәм бәла китерүен, аның кан коюдан, ярлыларның яшен агызудан гыйбарәт булуын сөйли.

«Юктырсың ла, Алла» дигән шигырендә җирдә бөтен нәрсәне алтын-көмешкә (капиталга) буйсындыруы, көчлеләрдән көчсезләрне издерүе, халыкларның кан һәм яшьләрен түктерүе өчен «Алласына» үпкәли. «Ела» дигән шигырендә ул капиталистик сугышның аянычлы нәтиҗәсен фаш итә:

*Син ела: ярдәмчесез калган ятимнәрне күреп,*
*Син ела: каннар түгеп сынган күңелләрне күреп.*
*Син ела: күр дә кешелек дөньясы тапталганын,*
*Мәзлумә, толлар, ятимнәрнең елап ач калганын.*
*Син ела: күргән саен язмыш явыз корбаннарын.*

Шулай итеп, М. Гафури үзенең бу чордагы шигырьләрендә империалистик сугышка каршы позициягә баса. Ул гына да түгел, «Ул кем» дигән шигырендә империалистик сугыш фронтында бер-берсенә каршы мылтык тотып килгән солдатларның үзара дошман булмавын, ә бәлки бертөсле үк алданган кешеләр булуын, бары эшнең төбен белмәү, үз ирекләренә үзләре хуҗа булмау, хуҗалары сүзенә буйсынып килү аркасында гына бу фронтка басуларын аңлата:

[1] Нәҗат – котылу.

*Ул — гаребтән, син шәрыктән ошбу җиргә килдегез,*
*«Кем элек өлгерсә, шул үтерү тиеш» дип белдегез.*
*Эшнең аслын уйлый алмыйсыз, димисез: ник болай?*
*Иркегезне таптап алганнар да кушканнар шулай.*
*Юк,*
*Син шулай коллыкта йөрсәң, дөнья киң булмас сиңа,*
*Барча эшләрдән элек баш бул, туган, үз иркеңә.*

(«Ул кем»)

(...)Бу урында М. Гафуриның күп кенә санда язылган мәсәлләренә дә бераз тукталып үтәргә кирәк. М. Гафури — татар әдәбиятында мәсәлләр жанрын тудырган әдипләрнең берсе. Ул, рус әдәбиятында бу жанрда күп яхшы үрнәкләр биргән шагыйрь Крыловка ияреп һәм аның күп кенә уңышлы мәсәлләрен татарчалаштырып, шулай ук үзе иҗат итеп, байтак мәсәлләр язды. (...)

Мәсәлләр төбендә гиперболик алымнар белән тирә-як чынбарлыкны, шул вакыттагы әхлак һәм карашларны тәнкыйтьләү өчен уңайлы форма була алдылар. М. Гафури бу мәсәлләрдә җанварларга кешеләр сыйфатын биреп, алар арасындагы уйлап чыгарылган бер-бер вакыйга аркылы, кешеләр җәмгыятендәге начар эшләргә (холыкка, әхлакка, карашка) ишарә ясый. М. Гафури үзенең җанварлар турында язылган мәсәлләре белән буржуаз җәмгыятьтәге тигезсезлек, хокуксызлык һәм башкаларны тәнкыйтьләде (мәсәлән, «Җанварларга килгән үләт», «Хайваннар арасында» һ. б.).

М. Гафуриның мәсәлләре җиңел тел белән, матур итеп язылганнар. Алар безнең әдәбиятта бу төр жанрның иң уңышлы, матур үрнәкләре булып торалар.

## *VI*

М. Гафури 1917 елгы Февраль революциясен зур күтәренкелек һәм өмет белән каршылады. Ике революция арасындагы катлаулы юл аның дөньяга карашын нык кына чыныктырган һәм, аңарда капитализм системасына каршы көчле нәфрәт тудырып, аны хезмәт ияләренә нык якынайт-

кан иде. Бу хәл аның Февраль революциясе һәм Вакытлы хөкүмәт чорында дөрес позиция алуына ярдәм итә.

М. Гафури әгәр 1905 ел революциясендә тулай демократик таләпләр куеп, милли азатлыкны алга сөрсә, инде 1917 ел революциясен ул эшчеләрне азат итү, капитализм системасын җимерү фикере белән каршылады. Ул Февраль революциясе көннәрендә үзенең Кызыл байрак күтәргән эшчеләр сафында булуын кисеп әйтте. «Хөррият иртәсе» дигән шигырендә ул:

*Әй... халык шат! Һәммәсе уйный, көлә,*
*Каршыдан балкып Кызыл байрак килә.*
*Эшчеләрнең ирләре һәм кызлары*
*Җырлыйлар бердән азатлык җырлары.*
*«Канлы байраклар» югары селкенә,*
*Саф йөрәкләр сөенеченнән җилкенә.*
*Опыта алмам мәңге бу шатлык көнен:*
*– Яшәсен чын хөррият!– актык сүзем. (...)*

Хезмәт халкы ягында булган, шулар өчен янган М. Гафури өчен буржуазия белән пролетарлар арасында икеләнү мөмкин түгел иде. Ул Февральдән Октябрь революциясенә килгәндә дә, үзенең Кызыл байрак күтәргән эшчеләр белән булганын, эксплуататорларга дошманлыгын әйтеп чыкты:

*Кара син алга,*
*Күрәмсең анда –*
*Кызыл байракны,*
*Буялган канга.*
*Көчле эшчеләр*
*Күтәргән аны.*
*Кузгал, эшчеләр,*
*Дошман җиңелсен,*
*Көч кемдәлеген*
*Бар дөнья белсен.*

(«Кызыл байрак»)

### *VII*

Бөек социалистик революция җиңеп, Советлар хөкүмәте төзелгәч, М. Гафури үзенең иҗатын тагын да арттырып, зур дәрт белән җиңү җырларын җырлый башлады. (...)

М. Гафури бу елларда күп кенә Кызыл Армия фронты газеталарында язышты. Җиңүгә чакырып язган көчле, ялкынлы шигырьләре белән сугышчы кызылармеецларда дәрт уятты, аларның җиңүләренә мораль ярдәм итте. (...)

Җиңеп чыккан батырга, тәбрикләп, җылы кулын сузды:

*Бир син миңа, сугышып, шул сугышта*
*Кызыл каннар аккан кулыңны!*
*Дошманнарның биек кальгаларын*
*Тар-мар итеп ваткан кулыңны!*

(«Бир кулыңны»)

М. Гафури бу чорда, гражданнар сугышына багышланган шигырьләреннән башка, байларның эксплуататорлыгын һәм сорыкортлыгын фаш иткән, аларның революциядән соңгы хәленә сатира рәвешендә язылган («Бай абзый»), шулай ук Октябрьдән соң ярлыларга якты, шатлыклы тормыш килүен сөйләгән («Гаҗәпме», «Яңа бәйрәм») шигырьләрен язды.

### *VIII*

Кызыл Армия ак бандаларны һәм интервентларны тармар итеп җиңеп чыккач, һәм илдә төзү эше башлангач, М. Гафури совет төзелеше, андагы хаклык, иреклелек, хезмәт иясе халкының якты тормышы, матур киләчәкле булуы турында язды. «Урак белән Чүкеч», «РКСМ», «Беренче май» кебек төрле темага язылган шигырьләрендә ул коллыкка, изелүгә безнең илдә чик куелуы, иске тормыш җиңелеп, яңа тормыш килүе турында язды.

Бу шигырьләр совет яшьләрен илгә мәхәббәт хисе белән тәрбияләүдә, искелек калдыкларына каршы көрәшкә өндәүдә файдалы, иҗаби[1] әсәрләр булып тордылар.

[1] Иҗаби – уңышлы.

Шулай итеп, М. Гафури иҗатының чынлап чәчәк аткан һәм иң бай үрнәкләр биргән дәвере Октябрь социалистик революциясеннән соң Совет хөкүмәте шартларында, бигрәк тә илдә социализм төзү чорында булды.

М. Гафуриның бу чорда язган әсәрләрендә без тематиканың төрлелеген, содержаниенең байлыгын һәм форманың жанлылыгын күрәбез. М. Гафури совет төзелешенең төрле тармаклары турында язды һәм бик күп политик актуаль вакыйгаларны чагылдырып килде. Боларның барысына да тукталмастан, М. Гафуриның совет шартларындагы иҗатында төп шушы темалар урын алганын әйтеп китәргә кирәк.

Башлап М. Гафури революциядән соңгы күп кенә әсәрләрендә эшчеләр һәм хезмәт иясе крестьяннарның, хезмәт иясе хатын-кызларның Октябрь революциясенә кадәр нинди шартларда яшәүләрен һәм Октябрьдән соң тормышның ничек алышынып, хезмәт ияләренә бәхет китерүен чагылдырды. Аның «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Хәзер асат ул, элек кыен иде», «Кара йөзләр», «Тормыш баскычлары» кебек озын хикәяләре һәм «Элекке «ул» инде кеше булды» дигән поэмасы менә шул темаларга язылганнар.

«Шагыйрьнең алтын приискасында» исемле автобиографик әсәрендә М. Гафуриның үзенең иске мәдрәсәдә шәкерт булып укып йөргән вакыты, җәй көне тамак яллык эшләү өчен приискаларга барып эш эзләве һәм бер җәйне алтын приискасында эшләве чагылган. Матур, җиңел тел белән язылган бу әсәрдә иске татар мәдрәсәләренең консерватив рольләре, анда укучы шәкертләрнең булдыксыз, эшкә яраксыз булып чыгулары, алтын приискаларында эшчеләрнең эксплуатацияләнүе җанлы образлар аша яктыртылганнар.

«Элекке «ул» инде кеше булды» поэмасында татар хатын-кызларының элек хокуксыз булуы, ике кат камыт киеп изелүе, дин, шәригать законнары белән, кухня коллыгы белән кысрыклanулары гәүдәләндерелгән. М. Гафури элек

изелгән хатын-кызларның совет шартларында тулы хокук алып, социализм төзүгә актив катнашуларын әйтеп, поэманы шул сүзләр белән тәмамлый:

*Яшәмиләр хәзер тоткынлыкта,*
*Көн күрмиләр кысынкылыкта.*
*Башка илләрдәге хатын-кызлар төсле*
*Чикләнмиләр алар хокукта.*
*Колхоз-совхоз, фабрик, заводларда*
*Алар җиң сызганып эшлиләр.*
*Совет төзелеше турысында*
*Сөйләгәндә ярып сөйлиләр.*

Революциягә кадәрге татар хатын-кызларының язмышын М. Гафури аеруча «Кара йөзләр» повестенда көчле сурәтләде. Сөйгән егете белән күрешеп сөйләшкән өчен генә дә, авыл куштаннары, дин-шәригать каргалары – муллалар тарафыннан эштән чыгарылып, хурланып ташланган яшь татар кызының кызганычлы фаҗигасе бу әсәрдә эмоциональ көчле сурәтләү чаралары аркылы реалистик җанлы итеп бирелгән. Художество ягыннан тиешле югарылыкта торган, көчле язылган бу әсәрдә М. Гафури халыкның иреген, ихтыярын басып торучы әшәке диншәригать законнарын фаш итә; шәригатьче мулла һәм хәлфәләрне көчле сатира угына ала. М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте, аңарда берникадәр натурализм элементлары булуга карамастан, татар әдәбиятында кыйммәтле бер әсәр булып тора.

М. Гафури иске тормышның караңгы күренешләрен генә чагылдырып калмады, «Тормыш баскычлары» кебек әсәрләрендә шул тормышны үзгәртү өчен барган көрәшне дә чагылдырды. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы М. Гафуриның байтак кына шигырь һәм поэма, хикәяләрендә урын алды.

«Тормыш баскычлары»нда М. Гафури җанлы, реаль художество образлары аркылы иске мәдрәсәдә динчелек һәм милләтчелек карашлары белән сугарылып үскән крестьян егетендә, тормыш бусагасына чыгып баскач, тирә-як

чынбарлык тәэсире белән башланган һәм революционерлар сафына кадәр китергән үзгәрү-алмашыну процессын күрсәтә. Гомумән, Гафури иске мәдрәсә һәм андагы шәкертләр, хәлфәләр, муллалар типларын бик оста, җанлы сурәтли. Ул шушы темага язылган күп кенә әсәрләрендә реакцион руханиларны, иске феодаль көчләрне фаш итте. Бу әсәрендә инде ул иске патша солдатлары тормышын да шундый ук осталык белән бирә алган. Әсәрдә казарма тормышы һәм эшчеләр белән бәрелеш күренешләре аркылы сыйнфый аңы ачыла барган, ахыр килеп революциягә һәм гражданнар сугышына кызыл командир булып актив катнашкан Вахит образы матур, җанлы бирелгән.

«Кызыл йолдыз» пьесасы ак бандага каршы көрәшеп, аны тар-мар итү һәм ак бандадан тазартылган советлар илендә авыл хуҗалыгы артеле төзү процессын гәүдәләндерә. Әсәрнең төп образларыннан булган ярлы крестьян Салих ак бандитларның эзәрлекләүләреннән һәм ерткычларча бәйләнүләреннән аптырап, алҗып беткән. Элекке помещиклар строен кире кайтару өчен сугышучы ак бандитлар крестьяннарның җир турындагы сүзен ишетү белән дә котырып китәләр. Бу урынны М. Гафури шушы диалог белән матур биргән: ак офицерларның өйне тентергә килүләре турындагы хәбәрне ишеткәч, Салих укучы кызы Шәмсиягә шикләнерлек язмаларны, китапларны, бигрәк тә кызылармеец улы Газиздән килгән хатларны ягарга куша. Шәмсия, китапларны актарганда, география дәреслеген китереп чыгара һәм атасыннан сорый:

«**Шәмсия**. Менә монысы – үзем укыган «Бәләкәй җәгърафия»!

**Салих**. Әлеге җир йөзен сөйләгән китапмы?

**Шәмсия**. Шул. Өченче ел мәктәптә укытканнар иде бит!

**Салих**. Җир сөйләгән китап булса булыр, яндыр! Җир өчен сугыш барганны белеп торасың бит! Әллә кайда, сез һаман җир тикшерәсез икән дип, виноват итәрләр...». (...)

Пьесаның соңгы өлеше менә шул күмәк хуҗалыкка оешкан совет крестьяннарының бәхетле тормышын күрсәтә.

М. Гафуриның революциядән соңгы иҗатында киң урын алган темаларыннан берсе – намуслы эш һәм хезмәтне мактау, аның үрнәкләрен күрсәтүдән тора. Аның бу темага язган шигырьләре байтак («Төнге смена», «Эш һәм белем» һ.б.). «Гөлләр бакчасында» дигән шигырендә ул гөлләр авызыннан шул сүзләрне әйттерә:

*– Кемнәр эшли, кемнәр җирләр казый,*
*Кемнәр безгә сулар сибәләр,*
*Кемнәр чәчәк кебек саф күңелле,*
*Шулар безгә дуслар...– диделәр.*

М. Гафури совет илендәге социалистик төзелеш, бәхетле тормыш турында байтак көчле лирик шигырьләр язды. Бу шигырьләре аның күтәренке рух, чиксез шатлык һәм дәрт хисләре белән сугарылганнар.

М. Гафурида туган илгә мәхәббәт көчле иде. Ул «Чит ил кунаклары» дигән шигырендә, СССРга килүче эшче делегатларга карап, зур дәрт һәм горурлык белән, Совет иле уңышларын сөйли. Совет иле җимешләрен санаган бу юлларда аның үз ватанына булган тирән мәхәббәте һәм үз иле теләкләренә чын күңелдән бирелгәнлеге аерым бер ялкын белән әйтелгәннәр.

Совет патриотлыгы тойгысы Гафуриның «Мин ватанчы» дигән шигырендә аеруча горурлык һәм ачыклык белән әйтелгән:

*Чиксез ватанчы мин –*
*Совет иле*
*Булу шарты белән ул ватан.*
*Советларга дошман кеше миңа –*
*Дошман, әгәр булса да атам.*

Илне саклау темасы М. Гафури иҗатында шулай ук зур урын алды. Шушы ук шигырен ул:

*Шуңар карамастан безгә берәр*
*Дошман башлап һөҗүм ясаса,*

*Беребез дә тора алмабыз*
*Читтән генә кылып тамаша,—*

дип бетерә. М. Гафуриның күп кенә лирик әсәрләре Кызыл Армиягә һәм аның сафына килүче яшьләргә багышланган («Кызыл Армия», «Кызыл Армия җыры», «Дәртле яшьләр», «Чит дошманнар» һ.б.).

М. Гафури бөтендөнья эшчеләре арасындагы интернациональ бердәмлек һәм СССР халыклары арасындагы туганлык темаларына да иҗатында киң урын бирде. (...)

М. Гафури чын халык теле белән, киң массага аңлаешлы, җиңел һәм гади итеп язды. Күп халык гыйбарәләрен, мәкаль, җыр һәм әйтемнәрен файдаланды. Әсәрләрендә халыкчанлык стилен саклады. М. Гафури әсәрләренә художестволы простойлык, җанлылык һәм халыкчанлык характерлы. Ул татар әдәбиятында реализм мәктәбенең күренекле вәкилләреннән иде.

М. Гафуриның иҗаты татар совет әдәбияты фондына кыйммәтле бер җәүһәр булып кереп калды һәм ул яшь совет укучыларын хезмәт иясе халкының үткән тормышы, азатлык өчен көрәше, совет эпохасының беренче чорларындагы көрәш һәм төзү эшләре белән таныштыруда бай материал булып тора. Ул совет укучыларын хезмәт иясе халыкка чын күңелдән якын булу, коммунизм идеяләренә бирелгән булу, туган илне сөю, аны сакларга һәрвакыт әзер тору, дошманнарны таный белү тойгылары белән тәрбияләүгә хезмәт итә. Шуның белән бергә, М. Гафуриның демократик идеяләр аркылы социализмга килгән катлаулы иҗат юлы әдәбият тарихыбызны өйрәнүдә зур әһәмияткә ия булган материал урынын тота.

Шуның өчен совет җәмәгатьчелеге шагыйрь М. Гафуриga зур бәя бирә һәм аны үзенең сөекле җырчысы итеп таный.

*Җәлил М. Мәҗит Гафуриның иҗаты турында // Әсәрләр: 5 томда: 4 т.: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм биографик материаллар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 141–170 б.*

# Мәҗит Гафури турында истәлекләр

*Зөһрә Гафури*[1]

# Безнең тормыш

## *Мәҗит Гафурины беренче күрүем*

Мин йокыдан уянганда, тәрәзә капкачының ярыгыннан төшкән кояш нурлары астында тузан бөртекләренең җемелдәп уйный башлаганнары күренә иде инде. Мин сикереп тордым да, урамга чыгып, тәрәзәләрнең капкачын ачып, өйне кояш нуры белән тутырып ташладым. Яртылаш җиргә батып утырган юеш, күксегән исле өйнең һавасын иснәмәс өчен, берникадәр урамдагы бүрәнәләр өстендә утыргач, өйгә кердем. Мин ишектән кергәндә, кулына шадра тимер комганын тотып, төнлә тузгыган чәчен яулык эченә тыга-тыга, Кәримә җиңги чыгып китә. Мин тиз генә кердем дә, мич култыгынан карчыклар теше кебек булып коелып беткән чәч тарагын алып, стенага куйган, төнбөек яфраклары арасыннан аз-маз гына күренгән яшькелт күл суы төсле көзгегә карап, чәчемне өзгәли-өзгәли тарарга тотындым. Мин бит-фәлән юып килгәләгәнче, җиңгинең самавыры кайнап чыкты. Ул тупас ирләр тавышы белән:

– Йә, нишләп йөрисең инде, чәй эч тә тизрәк кит. Фатыйма тутакай, иртүк килсен, дип әйтеп җибәргән бит,– дип, кара белән кызыл мамыктан шакмаклап суккан ашъяулыкка кисеп өеп куйган икмәк телемнәреннән берсен алып, бер кисәк шикәр белән минем алдыма ыргытты. Мин ашыгыч кына бер чәй эчтем дә Фатыйма апайларга тегү тегешергә киттем.

Сентябрь аеның иртәнге кояшы җир йөзен үз нуры белән әкрен генә җылыта башлаган. Юкарак киенеп чыккан кешеләр йөрешләрен тизләтә төшәләр иде. Мин дә зур ке-

[1] Зөһрә Гафури (1891–1938) – М. Гафуриның тормыш иптәше.

шеләрдән калышмый, бик эшлекле кеше кебек, йөгерә-атлый алга киттем. Яратам да шул көз көненең шушы вакытын!

Мин Фатыйма тутакайларга барып кергәндә, алар үзләренең күптән түгел юан нарат агачыннан салынган биек, зур, якты, саф һавалы өйләренең матур бүлмәсендә, гөрләшеп, кайнар ит пирашкие белән иртәнге чәйләрен эчәргә утырганнар, тик үткән кыш Казаннан ниндидер зур уку йортыннан җәйге ялга кайткан Фәрит абый гына күренми иде. Күп тә үтмәде, башына кара түбәтәй, өстенә морзалар кия торган озын кара бишмәт, аягына үкчәле кара читек киеп, кызыл сыткы битле, кәкре танаулы, базык җилкәле, үз гомерендә кара эш эшләмәгән бай кызларының кулы кебек бәләкәй генә ап-ак куллы Фәрит агай, бер учын икенче учына суга-суга, башын бер яккарак кыйшайтып, иркәләнеп килеп керде дә чәй янына утырды. Ул утыз-утыз биш яшьләрендә булса да, әле өйләнмәгән (Уфада аңа тиң кыз юк). Ул, кирәк чәй янында булсын, кирәк аш янында булсын, һәрвакыт, Уфаның игътибарлы дигән кешеләренең кызларыннан гаеп табып көлә. Теге купец кызының аягы кәкре. Казый кызының муены ата каз муены кебек озын. Фәлән морзаның кызы үзенә күрә түгел, тәкәббер. Фәлән байның кызы чәркелдек... Менә боларның мәҗлесе шундый мәгънәсез гайбәт белән үтә. Аталары да шуңа кул куеп, рәхәтләнеп көлеп утыралар иде. Тик менә бүген генә бер күңелгә ятышлы яңа хәбәр булып алды. Фәрит агай, шундый вак-төяк сүзләрдән соң, әнисе Фатыйма тутакайга:

– Әни, мин бүген кичке сәгать алтыга Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга килгән Мәҗит Гафури дигән шагыйрьне чәй эчәргә чакырсам, син чәй янына берәр җылы нәрсә әзерләтерсең әле,– диде. Атасы Гимай агайга карап: – Әти, укысаң гаҗәп икән ул. Һәрбер нәрсәдән хәбәрдар булып беткәнмендер, дип уйласаң, синең башка да килмәгән нәрсәләрне сөйләп шаккатыралар. Әле үткән кыш безне профессорлар, шагыйрьләр, язучылар белән таныштырдылар. Аларның сөйләвенә караганда, язучыларның, шагыйрьләрнең миләре бөтенләй башка формада

эшләнгән, ди. Аларның уйлаулары, әйберләрнең сәбәбенә төшенүләре, сизенүләре дә безнең гади кеше кебек булмаенча, аерым бер формада, ди. Аннары, алар кешене үтәли күрәләр, хәтта кешенең нәрсә уйлаганын да белергә мөмкин, ди. Менә мондый халык дуслары дөньяда бик күп дияргә ярый. Мин аларның кайсыбер әсәрләрен яттан да беләм. Әле менә шундый халык безнең милләттән дә чыга башлаган. Казанда Тукай дигәне бар, монда килгәне Гафури икән. Андый халык белән таныш булу зарар итмәс. Чөнки Казандагы бик күп байлар әнә шундый халыкның әсәрләрен бастырып баеганнар,– диде.

Алар бу хакта бик озак сөйләшеп утырдылар. Без дә бит мәдрәсәдә, дәрес беткәч, шигырь әйтәбез. Әллә без әйтә торган шигырьләрне дә ул язамы икән? Без Садрый бай килгәч:

*Хуш килдегез, мәрхәба, саф килдегез, мәрхәба!*
*Мәкъсүдең бир, я Алла, кодрәтең там, йа Кәрим!* –
дип тели идек.

Аннан соң Садрый байның яшь хатынына бала тели торган шигырь дә бар иде. Чынлап та, ул шигырьләрне ничек язалар икән? Тизрәк килсә, күрер идем.

Кич булды. Өйләр җыештырылды, пәрәмәчләр пеште, столовойга керә торган ишеккә каршы ширма куелды. Менә бервакыт, шагыйрь килде, диделәр. Минемчә, гади кешеләрдән аерым хасиләте[1] булган бер кешене күрү өчен, йөрәгем аерым рәвештә дерелдәп китте. Фатыйма тутакай чәйне үз күзе белән әзерләтеп, үзенең йокы бүлмәсенә кереп китте. Шуны гына көтеп торган мин тизрәк Гафурины, халык телендә сөйләнә торган шагыйрь кешене, күрергә ашыктым. Ширманың бөкләнә торган урыныннан карарга тотындым. Гафуриның өстендә кара сукнодан костюм. Башында кара ефәк чуклы бик нәфис кызыл фәс. Аягында шыгырдап торган үкчәле кара читек. Үзе кап-кара күзле, чем-кара чәчле, кыйгач кашлы, шыңгырдап торган матур тавышлы, мөлаем йөзле, көлә биреп кенә сөйли.

[1] Хасиләт – артыклык.

Мин аны бик озак карадым, һәрбер хәрәкәтен дикъкать белән җентекләп тордым. Ул, шагыйрь булгач, чынлап та, гади кешеләр кебек кыланмый, чәйне дә үзенә бер форма белән эчәр төсле тоелды. Минем уем бушка чыкты, тик ул чынаяк астын безнең кебек читтәнрәк тотып эчми, биш бармагы өстенә утыртып эчә. Ул чикләвекне дә тап уртага ярып ашый. Алар Фәрит агай белән бик озак сөйләшеп утырдылар, сүзләрен, әлбәттә, аңларлык түгел иде. «Төркия, хөррият, ихтилал, җәдитчеләр» кебек, миңа аңлашылмый торган сүзләр катыштыралар иде.

Фәрит агай, ширманы бармагы белән чиртеп, хезмәтче хатынга:

– Бану җиңги, самавырга ут салып китер әле,– диде дә үзе, нидер алыр өчен, үз бүлмәсенә кереп китте.

Бану яулыгының бер очын уң ягына тартып, авызын каплады да самавырын алырга керде. Ул керү белән Гафури, Бану әбигә елмаеп:

– Нихәл, Бану җиңги, сәламәтмесез? – диде.

Бану әби, тавышын әкрен генә чыгарып:

– Бик әйбәт, балам, бик әйбәт,– дип, самавырны алып чыкты. Шатлыктан минем күзләрдән яшьләрем атылып чыкты. Кара әле, нинди әйбәт киенгән кеше хәерче карчыгы кебек Бану әбигә эндәшә. Мин самавыр күтәреп алып чыккан әбигә:

– Әби, ул кеше әллә сезгә танышмы? – дидем.

Әби көрсенеп куйды да:

– Юк, балам, нишләп таныш булсын. Күрәсең, дөньяда яхшы кешеләр дә бар икән. Безнең кебек ярлы кешене исәпкә алып исәнләшә бит әле. Рәхмәт инде,– диде.

Чынлап та, аңа Фәрит агай алай түгел бит. Ул бервакытта да ярлы кешеләр белән үзе башлап исәнләшми. Ул әле, син үзең исәнләшсәң дә, юньле җавап та кайтармый.

Кичә мин килгәч:

– Исәнмесез, Фәрит агай? – дигән идем дә, ул:

– Әй, кызый, беркөн теккәндә минем ыштанны тар ясагансың, төзәтеп тегеп куй,– дип ачуланды.

Иртә белән Бану әби:

– Нихәл, Фәрит балам, йокың туйдымы? – дигәч: – Әй, Бану җиңги, галошларны шулай юалармыни, яңадан ю,– дип, зур якка чыгып китте.

Мин Гафурины яңадан карарга барганда, ул, китәргә әзерләнеп:

– Бик рәхмәт, сезнең вакытыгызны алуым өчен гафу үтенәм,– дигән сүзне әйтеп кенә тора иде.

Мин Фатыйма тутакайларда тегү теккәндә дә, үзебезгә кайткач та нигәдер Гафури хакында уйлана, аны башкалардан көнләшә идем. Ләкин бу уйлар буынлы дебет[1] төсле бик тиз алмашына иде. Чөнки, бердән, бу вакытта минем бала булуым, икенчедән, зур кыз булсам да, фәкыйрь кешенең кызы булуым мине аны уйлаудан читкә тибәрәләр иде.

***

Шулай булса да мин Гафурины күрүгә өмет итә идем. Табигатьтә булган нәрсәләр үзгәрә барган кебек, мин дә үсәм, зураям. Хәзер тегүне дә кеше өйрәтеп торуы буенча түгел, бәлки үзем тегә башладым. Шулай ук дәресләремне дә бик тырышып укыйм.

Бер көндә үзебезнең Килем авылының Сәрби әби килеп:

– Балам, менә сиңа бик күп эш китердем, бу – «Галия» шәкертләренең күлмәкләре. Яхшы тегәргә тырыш. Берсеннән-берсе күреп, башкалары да җибәрерләр,– дип, өч ирләр күлмәге калдырып китте. Әле минем кебек яңа тегү тегәргә өйрәнгән кеше түгел, ничә еллар теккән кешеләр дә эшсез йөри. Шуның өчен мин, моңа чиксез шатланып, күлмәкләрне бик әйбәт тегәргә тырышам. Минем эшне яраткан булсалар кирәк шәкертләр, бертуктаусыз миңа эш яудырып кына торалар. Тегеп кенә өлгерт.

Менә бервакыт бәләкәй генә төен тотып тагы Сәрби әби килеп керде.

– Кызым,– ди,– менә шушы күлмәкне бик әйбәт итеп тегеп бир әле. Бу безнең бүлмәдә торган шәкертләр яны-

---

[1] Дебет – йомшак мамыктан эрләп эшләнгән җеп.

на килеп йөри торган Мәҗит Гафури дигән шагыйрьнең күлмәге. Иртәгә шуңа өлгерсә, яхшы булыр иде. Аны безнең шәкертләр, бик зур кеше, дип сөйлиләр. Бозмасаң гына ярар иде,– дип, бик матур сирень буйлы зефир күлмәклек калдырып китте. Мин, Гафуриның күлмәген газетага төргән көенчә, үземнең иң кадерле нәрсәләрем салынган сандыгыма салып куйдым да, әби тиклем әби шулай курыккач, бу күлмәкне ничек итеп бозмый гына тегәрмен икән дип, көне буе уйлап йөредем, төшемдә дә шуның белән саташып чыктым. Гүя шул матур ак күлмәкне мин юан кара җеп белән теккәнмен, имеш. Гүя яка урынын уйгач, изүен итәгенә тиклем ярып төшергәнмен, имеш. Гүя итәген бик нык бөреп, ике оборка салганмын, имеш. Йокыдан бик куркып уяндым. Боларның төш булуына ышанмый, сандыгымны ачып, Гафуриның күлмәклеген карап алдым.

Иртәнге чәй эчелеп, өстәл бушагач, тагы Гафуриның күлмәген кисәргә дип, өстәлгә сузып салдым да, ни рәвешле тегү хакында уйлый-уйлый, машинаның тузаннарын сөртә башладым. Калын энә урынына нечкә энә куеп, бер чүпрәкне тегеп карадым. Машинаның тегүе күңелгә ошарлык булгач, Гафуриның күлмәген тегәргә тотындым. Күлмәкне шул тиклем матур, йөзләрен нечкә ясарга бөтен көчемне сарыф иттем. Күлмәк, чынлап та, матур булды. Үзе кушмаса да, якасын кайтарма ясадым. Төймә урыннарын бик дикъкать белән, каз теше кебек, тигез итеп салдым. Тегеп бетергәч, су бөркеп, крахмалга катырган кебек итеп үтүкләдем. Күлмәк тик Гафури кушкан көнгә генә өлгермәде. Мин, үземнең кимчелекне бетерү өчен, күлмәкнең ак коленкордан куелган җиңсәсенә: «Әфәндем, күлмәгегезне вакытына өлгертмәвем өчен гафу үтенәм! Зөһрә», – дип язып куйдым.

Гафури мин теккән күлмәкне бик яраткан һәм алып кайту белән киеп йөри башлаган. Ләкин җиңсәсенә язган язуны күлмәкне юарга биргәндә генә күргән. Язуны башта күрмәгәненә бик эче пошкан. Ул аны төрлечә укырга тырышып караган. Ләкин простой каләм белән язылган бу

язуның күп хәрефе таный алмаслык хәлгә килгән булган. (Моны, әлбәттә, бергә тора башлагач сөйләде.)

Сәрби әби артыннан миңа кечкенә записка язып: «Туганым, шушы китапларны укып чык, мин сиңа тагы китаплар җибәрермен», – дип, бик җиңел телдә язылган берничә әсәр җибәрде. Мин китапларны бик шатланып укып чыктым. Шулар эчендә Гафуриның үзенең әсәрләре дә бар иде. Мин моңа тиклем китаплар бары тик пәйгәмбәрләр сүзеннән генә торадыр, дип уйлый идем. Чөнки безнең өйдә «Нәф-фәил әшһәре», «Бакыргани», «Мөхәммәдия» кебек оҗмах, тәмуг хакында гына язылган китаплар бар иде. Шулай итеп, Гафури миңа рәттән биш-алты ай китаплар җибәреп торды.

### *Гафурины икенче тапкыр күрүем*

Төннең төн буе туктамый яңгыр ява да, иртә белән кояш чыгып, дөньяны ямьләндерә. Мин дә, үземә күрә пөхтә генә киенеп, сабакка киттем. Мәдрәсәгә барып җитәргә бер квартал кала дигәндә, каршыдан Гафури килеп чыкты. Нишләргә? Ничек узып китәргә? Исәнләшми үтсәң, килешми. Чөнки ул мине белә бит. Мин бит моннан бер ел элек аны Фатыйма тутакайларның ширма ярыгыннан карап тордым. Ул бит кешене үтәли күрә. Һәм хәзер минем ни уйлап килгәнемне дә белә. Урамны аркылы чыгып китәр идем, таш җәймәгән урам төне буе яуган яңгыр белән кесәл хәленә килгән, пычрак. Берәр капкага кереп калсам, эт-фәлән тешләр. Нишләргә, хәзер килеп җитә бит. Ни булса да булыр, дидем дә, түбән карап кына:

– Исәнмесез,– дидем. Ул миңа эндәштеме, юкмы, мин аны аңлау дәрәҗәсеннән узган идем инде. Мин, бер яктан, каушавым, икенче яктан, шул тиклем оялуым сәбәпле, битләрем утта пешкән кебек булды. Тротуар минем өскә күтәрелгәндәй булды. Узып киткәч, рәхәтләнеп тын алдым. Өстемнән авыр таш төшкәндәй булды. Күзләремнән ихтыярсыз чыккан яшьләремне сөртеп, мәктәпкә кереп киттем.

## *Гафуридан беренче хат*

Беркөнне төштән соң тегү тегеп утырганда, Сәрби әби килеп:

– Мә әле, Зөһрә, Гафури сиңа хат җибәрде,– дип, конвертка салынган калын гына хат бирде. Бу хатны мин төнсез укый алмадым. Чөнки өй бәләкәй, кая гына барып укысаң да, җиңгиләр күрер кебек тоелды.

Менә төн җитеп, бөтен кеше йоклап беткәч, мин конвертны ачып, бик озын язылган хатны укый башладым. Хатның башына шулай язылган иде:

«Ханым, мәхәббәт нәрсә? Мин моңа тиклем ханымнардан бу хакта фикерләрен сораганым юк иде. Менә беренче тапкыр буларак, сездән сорарга җөрьәт иттем».

Хат, табигый, бик оста һәм миңа акыл өйрәтеп язылган иде. Ләкин мин бабайларның «Яшьлек – юләрлек, гомер буе сөйләрлек» дигән мәкальләре буенча (чөнки миңа әле бу вакытта нибары унбиш яшь кенә иде) укып бетәр-бетмәс ерткалап ташладым. Гафури миңа хәзер дошман бер кеше кебек күренә башлады. Мине алдамакчы булган төсле тоела башлады (чөнки нәкъ шул чорларда күрше кызын бер шәкерт алдап качкан иде). Менә бу да мине шулай мыскыл итмәкче була икән дип, хатны укый башлауга йөрәгем жулап китте һәм, болай хат яза башласаң, җибәргән китапларыңны да укымам дип, ачуланып куйдым. Мине бөтен куркыткан нәрсә аның җавап язарга кушуы булды, табигый, мин җавап язмадым.

## *Гафуридан икенче хат*

Җәйнең иң матур көннәренең берсе. Авылларда җыеннар башланды. Яз, шәкертләр мәктәптән таралгач, табигый, миндә дә эш бетә. Ләкин җыеннар җитү белән минем эш тагы күбәйде. Чөнки Нижегородканың ломовойлары, толчокчылар, пиво, тәмәке сатучы малайлар, извозчиклар, кызыл сатин, яшел сатин күлмәк киеп, аякларына

толчоктан алган иске ботинка белән кеше калдыгы — картуз киеп, авыл халкының исен китәрергә, мактанырга, эчәргә, сугышырга кайталар иде. Мин дә, шуларга ашыгып-ашыгып күлмәкләр тегеп, бераз акча ясап кала идем. Менә нәкъ шул чорда Сәрби әби килеп:

— Зөһрә, Гафури сиңа хат җибәрде. Үзе бездә көтеп калды. Җавап язарга кушты,— дип, үзе җиңгиләр янына кереп китте.

Гафури конвертсыз-нисез генә бер кәгазьгә шулай язган иде:

«Зөһрә ханым!

Мин сезне ятим булуыгыз өчен бик кызганам. Бәхетле булуыгызны телим. Бөре каласыннан бик бай кешенең улы Җәвит Булатов дигән бер сәүдәгәр Уфага килде. Менә мин сезне шул кешегә димләмәкче булам, сез аңа барсагыз, ефәк күлмәк, энҗеле калфаклардан, атка гына утырып йөриячәксез. Ләкин белеме русчасы да, татарчасы да түбән булыр. Әгәр югары белемле кеше кирәк дисәгез, анысы да табыла, ләкин анысы бай булмас. Җавап көтәм.

Гафури. 1909 ел».

Бу хатка җавап язмакчы булдым. Ләкин мин бит аның кебек оста яза белмим. Ничек итеп башларга соң? «Гафури абый», дип башласам, теле ачылып җитмәгән бала төсле була. «Гафури агай» дип башласам, укымаган кешегә генә «агай» диләр бит, ваксыту була. «Гафури әфәнде» дисәм, аның белән тиң кебек була. Ярый, менә шулай башлыйм.

«Сөекле әфәндем!

Сез мине сатучыга димләп язу җибәргәнсез. Мин сатучыга барырга булсам, сабак укып та йөрмәс идем. Мине колагымнан тотып алтынга мансалар да, мин сатучыга бармыйм. Нигә үзегез өйләнми торып, мине кешегә димлисез? Сез үзегез өйләнегез, аннан мине димләрсез. Ярый, алты көннән хат язырмын.

З ө һ р ә».

Нигә алты көннән? Нигәдер ике көннән түгел, анысына хәзер һич башым җитми, бәлки, ул вакытта шулай тиеш булгандыр.

### *Гафуридан өченче хат*

Гайнән[1] күчерәм.

«Сөекле ханым!

Менә сезгә беренче тапкыр буларак сөекле, дип хитап[2] итәм. Беренче тапкыр чын мәхәббәт гарыз[3] итәм. Сез минем каршымда әллә кайчаннан бирле сөекле идегез. Мин аны эчемдә генә саклап йөри торган идем, сез кичәге мәктүбегездә[4], сөекле әфәндем, дигәнсегез. Бу хитабыгыз минем өчен бик кыйммәт нәрсә булды, сезгә сөекле күренү бик зур бәхет төсле булды. Әллә кайчаннан бирле сезгә булган мәхәббәтне гарыз итәсем килә иде. Ягъни бер ханым гына туктатып тора иде.

Менә инде мин сезгә чын мәкъсүдемне бәян итмәкче булам. Мин сезгә Сәрби әби аркылы ике мәсьәлә гарыз иткән идем. بересе – бер кешегә димләү иде. Бу да үземнең башлый торган эшемә мөкаддимә булсын өчен генә иде. Икенчесе үзем идем. Турыдан-туры үземне сезгә әйтергә оялдым. Чөнки мин үземнең сезнең тарафтан сөекле булуыма ышанмый идем. Үземне чын күңелдән яратмаган кеше белән тәгаввезләнү[5] ниятендә түгел идем. Менә сезне бик күптәннән бирле ярата, йөрешегезне, әхлагыгызны тикшерә торган идем. Тикшергән саен сезне яратуым гына артты.

Ах җаным, тагы ярату тоя башладым. Чөнки инде үземнең күңел серемне, еллардан бирле саклап йөргән мәкъсүдемне язам бит.

---

[1] Гайнән – үзгәртмичә, сүзгә-сүз.

[2] Хитап – мөрәҗәгать.

[3] Гарыз итү – белдерү.

[4] Мәктүп – хат.

[5] Тәгаввезләнү – бәйләнү, сыену.

Менә инде кичәдән бирле генә безнең саклап йөргән яратулар кәгазь өстенә төшеп, «сөеклем» дия хитаб итешеп, бер-беребезне ярата икәнебезне белдерә башладык. Ханым, гаеп итмә, мин сезне яратам шул. Менә шуның өстенә сездән дәхи сорыйм, сезнең миннән башка берәр кешегә мәхәббәт баглаганыгыз юкмы? Мәхәббәт баглап вәгъдәләшкән кешегез булса, мин бер дә үпкәләми генә, хәерле булсын, дип кенә куям. Әгәр дә сез безне үзегезгә бергә тора торган мәңгелек иптәш өчен кабул итсәгез, менә мин сезне шатлык, хәсрәтемне уртаклаша торган мәңгелек иптәш итәргә разый булып, моны бик зур сәгадәтем дип беләм. Үзегез беләсез, мин төскә матур, бик мәһабәт түгел. Мин акчалы бай да түгел. Минем бары хезмәтем белән гыйлемгә мәхәббәтем бар. Мин каләм, язу аркасында гына тора торган бер язучы. Моңа шуларның барчасын уйлап, җавап язасыгыз. Минем байлык, гүзәллек, фәлсәфәләргә бер дә исем китми. Үзем ярата торган кеше белән бергә торсам, бик зур сәгадәтем дип беләм. Бик матур, бик мәһабәт егетләрдән үземнең эшем артык икәненә ышанамын. Бу сүзне мактанып әйтмим. Үземнең тәрҗемәи хәлемне сезгә белдерер өчен язам. Монда язган фикерләр сезне үземә иптәш, чын иптәш итәргә өндәвем. Сезгә караганда бик кызыклы, бик тиз генә сөйләнгән булып күренер. Ләкин мин моны бер елдан бирле уйлап, эчемдә саклап йөртеп, менә бүген генә сезгә гарыз итәм. Миңа караганда, бу уйлар бик иске, бик уйланып сөйләнгән сүзләр.

Сез, ханым, бер алты көннән үзем мәктүп язармын, дигән идегез. Анда нәрсә язуыгыз миңа бер дә мәгълүм түгел. Мин аны да көтеп тормый мәктүбемне яздым. Бу мәсьәлә бик зур мәсьәлә булганга күрә, бик уйлап эш итәргә тиеш дип беләм. Менә инде сез шул турыда уйлагыз. Шуннан соң җавап язарсыз. Күреп сөйләшәсегез килсә, анысы да мөмкин эш. Чөнки чын күңел белән һәр ике тараф тиеш табуын күрмә күреп сөйләшүдән зарар юк, дип беләм. Беләм, күреп сөйләшергә мәкъсүдегез булса, икенче мәктүбемдә вакытны әйтермен. Анда үземнең нишләячәгемне, мәкъсүдемне

берәм-берәм сөйләшер идек. Мәктүп аркылы үзебезнең тормышларны, максатны аңлап бетүе бик читен эш.

Сөекле ханым, мин сезгә бик бер зур мәсьәлә гарыз итәм. Бик ачык бел, чын күңелдәге серем бу. Үзеңнән башка һичкем белә күрмәсен, вакыты җиткәч һәркем белер. Хәзергә серне гаять нык сакларга тиеш дип беләм.

Язучы: сәгадәтемне теләүче мәгълүмең. 1909 ел, 4 май».

Гафуриның бу хатын әллә ничә тапкыр укып чыктым. Укыган саен аның белеменә, акылына хәйран калдым. Гафуриның акыл нигезенә корылып язылган хатын нишләтергә, кайда сакларга белми гаҗиз булып, ниһаять, үземнең нәрсәләремне сала торган сандык төбенә газета ябыштырып, хатны уртада калдырдым. Һәм соңгы хатларны да шунда саклый башладым.

## *Гафури янына беренче баруым*

Гафури мине төштән соң сәгать өчкә чакырган булса да, мин икедә үк әзерләнеп беткән идем инде. Бу бер сәгатьне үткәрү миңа, әлбәттә, бик авыр булды. Өстемә кигән зәңгәр күлмәгемне аз-маз үтүкләдем дә, зәңгәр газовый шарф бөркәнеп:

– Җиңгәм, мин Фатыйма тутакайларга барып кайтам,– дип чыгып киттем. Әллә күктән бардым, әллә җирдән бардым, биш-алты квартал җирне өч минутта килеп җиткәнмендер. Мин инде Гафуриның парадный ишеге төбендә идем. Батыр гына звонок бирдем. Гафури өйрәтеп куюы буенча, Гафуриның фатир хуҗасының асравы Мөслимә апай ишек ачты. Мин оялып кына:

– Гафури әфәнде өйдәме? – дидем.

– Өйдә, рәхим итегез,– дип, мине югары катка алып менеп китте. Мин баскычтан менгәндә: «Гафури белән ничек күрешермен? Ничек сөйләшермен», – дип уйлап та бетмәдем, югарыдан карап торган Гафури:

– Менә рәхмәт килүегезгә,– дип, азакккы баскычны минем уң кулымнан тотып менгезде дә үз бүлмәсенә алып керде.

Мин беренче тапкыр ирләр тарафыннан тотылган бу кулымны гөнаһлы дип хис иттем. Гафури бүлмәсенә кереп өстәл янына утыргач та уң кулыма карап алдым. Минем бу кулым зураеп, үсеп, хатыннар кулы кебек булып киткән төсле булды: «Менә, ирләр янына килеп йөрсәң, шулай була ул», – дип, үз-үземне шелтәләп тә алдым.

Гафуриның бүлмәсенә өстән генә күз ташлаганда, пөхтә генә җыештырылган. Ишектән кергәч, сул кулда гади генә карават. Өстенә челтәрсез генә ак полотно простыня җәелеп, аксыл гына ал покрывало ябылган. Бер башында ак тышлы кечкенә мендәр куелып, караватның икенче башына ак сөлге элгән. Бүлмә уртасында зур гына өстәл булып, ак ашъяулыкның өстенә «Вакыт» газетасы җәелгән. Өстәлнең бер башында дүрт данә аслы-өсле берәр еллык итеп төпләтелгән журналлар куелып, аларның өстенә урта кулда дүрт вершок калынлыкта тышы бик матур, чия кызыл материалга төрле парчаларны батырып эшләгән бер китап куелган. Түрдә һәр ике якта бәләкәй өстәл булып, аларга да шыгрым китап өелгән.

Гафури зур өстәлнең икенче башында тәртипсезрәк яткан кәгазь кисәкләрен җыеп куйды да, журналлар өстендәге әлеге кызыл тышлы китапны алып:

– Менә бу китап моннан мең еллар элек язылган «Мәкамәт[1] Хәрири» дигән әсәр булып, гаҗәп матур нәрсәләр җыелган. Моны бер кулга тотып укый башласаң, һичбер айнып булмый, шул тиклем фәсыйх[2] телдә язылган, – дип, китапның миңа укырга тиешле урынын карый башлады. Журналлар өстеннән китап алынгач, аның урыны беленеп калды. Мин түзмәдем, бу китаптан арткан урынны кояш уңдырганмы, әллә тузан кунып, аксыл хәлгә китергәнме, дип, сөртеп алдым. Чынлап та, тузан кунган булган. Жур-

[1] Мәкамәт – камилләшү юлы.

[2] Фәсыйх – матур, оста.

налның өсте бертөсле булып калды. Гафури аз гына тамак кырып алды да:

— Менә, Зөһрә ханым, бик мәшһүр гарәп әдипләреннән берсе кызларны мактаганда болай дип мактый: «Яшь кызлар — алар кыйммәтле футлярга салган сирәк табыла торган энҗе, ул көн күрмәгән тәва кошының йомыркасы шикелле ак, тәмам җитеп пешә башлаган хөрмә кебек тулы булса, муенына тезелгән кыйммәтле ташлар кебек җемелдәп балкып торса, йөзе ак, матур ай нуры кебек якты булып көлеп торса, күзләре кыр киеге күзләре кебек моңлы, килешле булсалар, сөйләгәндә ояла төшеп, керфекләрен кузгаткалап торса, теле матур, сүзе йомшак һәм хәйләсез саф булса, кыяфәте, шатраныж (шахмат) фигуралары кебек, асыл, нәфис, килешле булса, менә бу, әлбәттә, энҗе кебек кадерле, кыйммәтле булыр иде», — ди Хәрири.

Ләкин мин аның болай мактавына бөтенләй кушылып бетмәдем. Чөнки ул фәкать матурлыкны гына ала. Әмма эш, белем сүзләрен бер дә күрсәтми. Әгәр дә шул матурлык өстенә эш белән белем дә булса, бөтенләй, һәрьяклап яхшы булыр иде,— ди.

Гафури моны сөйләп бетәр-бетмәс Мөслимә апай кереп: «Әйдәгез чәй эчәргә»,— дип, тәрәзәсенә газета корылган (моны, әлбәттә, Гафури корган) террасага алып чыкты. Гафури чәй янында бик матур сүзләр сөйләп утырды. Тик мин генә сөйләргә сүз таба алмый кып-кызыл булып оялып, өстәл ашъяулыгының чукларын чәч кебек үреп утырдым.

Гафури яныннан кайткан көнне төнлә бик озын хат яздым. Җеп алырга барган кеше булып, өйдән чыгып киттем дә, Мөслимә апайга биреп киттем. Менә шуннан соң Гафуридан шушы хат килде.

«...Инде мәктүбемне нәрсә дип яза башлыйм икән? Зөһрәм, сез һаман минем исемдә торасыз. Бүген газета идарәсенә мәкалә язып куйдым. Шунда унҗиденче октябрь, дип язганмын. Ни өчен шулай яздың соң, дип сорарсыз инде.

Чөнки мин һаман шул сезгә кавышачак октябрь белән сентябрьне уйлап йөрим. Бу мәкаләне язганда да шуны уйлап утыра идем. Ахырына «унҗиденче октябрь» дип язганмын икән, төзәтеп: «унҗиденче май» дип куйдым. Менә төш вакытында өйдә аш ашадым, ашаганнан соң, бер кеше килеп, аның белән сөйләшеп утыра торгач, сәгать ике ярым булды. Бер вакыт Мөслимә:

– Гафури, чык әле монда,– диде. Чыктым, ни күзем белән күрим, сезнең мәктүбегезне бирде.

– Кем бирде? – дим.

– Үзе,– ди.

– Кайда ул? – дим.

– Китте,– диде.

Йөгереп чыктым, күзләрегезне күреп калмак булып, сез әллә кайда киткәнсез.

Күбәләк булып күккә очты микән әллә, дидем дә өйгә кердем. Керүем белән теге эшне туктатып, мәктүпне[1] яза башладым. Ах, Зөһрәм, сезгә мәктүп язу кебек ләззәтле нәрсә дөньяда бармы икән! Мин сезне бик сагындым. Сезне күргәнгә әллә ничә еллар булды инде.

«Нигә әллә ничә еллар булсын, кичә генә бергә утырдык бит», – дип әйтерсең. Ах, кояшым, алай әйтмә! Ул кичә утырганга бик күп заманнар үткән төсле булды инде. Саргаеп бетәм. Бер көн мәктүбегез килеп кенә азрак шатлык бирде. Ах, кичә бер дә йөзегезгә туйганчы карап кала алмаганмын икән. Инде сагынып беттем. Кичә чәй эчеп утырган урыныңны карап рәхәтләнәм. Чынлап та әйтәм, мин кичә сезне күзем туйганчы карап калмаганмын. Мин сез киткәч, шул шигырьләрен яздым. Инде үзегезгә җибәрәм.

Мин аның матур йөзен карап тамаша кылдисәм,
Ошбу көндә чәчкә аткан син җаным бер гөл, дисәм;
Һәр җирең килешкән инде, нәрсә дим инде бүтән,
Тугрысын әйткән вакыт, син хур, дисәм, былбыл, дисәм.

Менә шул юллар сезнең монда килүегез шәрәфенә язылган иде. Мин инде аларны сезгә дә язып җибәрәм. Шуны

[1] Мәктүп – хат.

укырмын да укырмын. Шуның кебек нәрсәләр белән күңелемне басамын. Мин сездән:

«Кайчан мине азрак ярата башлаган идегез», – дип сораган идем. Сез шуңа әллә аз гына кәефсезләндегезме? Ах, кояшым, алай итә күрмәгез. Ул бит минем гаеп сүзем. Инде беләм, бик күптәннән бирле чын яратып йөрисез икән. Рәхмәт сезгә. Менә мин сезне дә шулай яратам. Ләкин мин сезне башлап үткән көз көне күрдем. Мин дә шул күрүдән бирле ярата идем. Сезне әллә нигә үземә якын күрә торгач, сез миңа насыйп булмас төсле күренә идегез дә гыйшкымны яшерә идем. Менә шул яшерен мәхәббәтемне унбиш көн элек сезгә белдердем. Менә без шуннан бирле бер җан, бер тән булып киттек. Сез, минем Зөһрәм, сез сәгадәтем булдыгыз. Мин үземне дөньяда сездән башка тора алмам, дип игътикад[1] иттем. Мин сезне чын ярым, чын иптәшем дип карый башладым.

Ах, рухым, син бит минем рухым! Син бит минем күзем. Син бит минем иң якыным. Җанымнан да артык нәрсәм бит. Син яшәсәң, мин дә яшим. Мин бит кичә иң сәгадәтле көнемне күрдем. Сез бит кичә кич минем каршымда утырдыгыз. Минем моңлы күңелемне ачтыгыз. Әллә кайчангы дус кебек сөйләштегез. Өч сәгать гомер өч минут та булмады. Син бит минем китапларымны үз китапларың иттең. Караны, тузан кунган әйберләрне, үз әйберләрең иттереп, кулъяулыгың белән сыпырдың. Мин шуны тамаша кылып рәхәт-рәхәт сабыр итеп утырдым. Кичәдән соң һәрнәрсәм сезнең белән уртак кебек күренә башлады. Һәр әйберем Зөһрәнең әйбере булып китте. Бөтен бүлмәм сезнең белән тулган, тик үзегез генә монда юксыз. Инде кайчан дәхи[2] бергә утырырбыз. Мин кайчан сезнең йөзегезне туйганчы карармын. Юк, кайчан соң мин сезнең йөзегезне карап туярмын?! Сезнең йөзегез кешене туйдырамы соң? Сез бит минем Зөһрәм булуыгызны уйлап күңелемне басам. Һәм һаман сез, сез, сез!

[1] Игътикад – ышану.

[2] Дәхи – тагын.

Мәхәббәт баглаганмын, инде өзелмәс,
Үзем үлсәм үләрмен, гыйшкым үлмәс!
Мәгълүмегез Г.»

Шул җәйне, ягъни июль айларында Гафури Килем авылына Җантуриннарга[1] кымыз эчәргә китте. Килем авылына баруының сәбәбе боярларның крестьяннарга мөгамәләсен өйрәнү иде (миңа шулай язды). Шунда баруның сөземтәсе буларак, ул азактан шул Килем авылы янындагы Асылыкүлнең хыялый хикәясе «Заятүләк белән Сусылу» дигән әсәрен язды.

Гафури Килем авылына киткәч, миңа өч урыннан башкода йөри башлады. Икесе мөгаллимнән, берсе сәүдәгәрдән. Кәримә җиңгә, быел мотлак бирәбез, дип кенә тора. Ярый әле, минем бәхеткә каршы, зур агаем (Имаметдин) өйдә юк. Ул да авырып авылга киткән иде. Мин, табигый, Гафурига хат яздым һәм башкодаларның Имаметдин агаем кайтканчы гына көтәләр икәнен аңлаттым. Менә шуннан Гафури кайтып, миңа башкода җибәрде. Ләкин Кәримә җиңгәнең Гафурига бирү ихтималы да юк. Көне-төне бәләкәй агаем Нуретдиннең хатыны Кәримә җиңгә Шәмсинур җиңгә белән кычкырыша:

– Мин, – ди, – йортсыз-җирсез, урамда тәмәке тартып йөргән, кулындагы таягыннан башка нәрсәсе булмаган бер кешегә бирергә кыз үстермәгән, сатучыга бирәм дигәч, сатучыга бирәм, – ди. – Кыз биреп ашка, суга да йөрешерлек кешесе булмагач, аның коры күзләренә карап утырыйммы? – ди.

Ләкин мин серне Шәмсинур җиңгәмә сөйләп, Гафурига бирдерергә тырышуын үтенгән идем. Эш зурга киткәч,

---

[1] Килем авылында татар морзалары, җир биләүче Тәфкилев-Җантуриннар нәселе яши. М. Гафури Суфия һәм Сәлимгәрәй Җантуриннар утарына кымыз эчеп, үпкә чиреннән дәваланырга йөри. Җантурин Сәлимгәрәй Сәетхан улы (1864–1920) – сәясәтче, I Дәүләт Думасы депутаты, «Галия» мәдрәсәсенең иганәчесе, «Милләт» газетасына нигез салучы (1914), «Гарәп-фарсы сүзлеге» авторы (1911) буларак билгеле.

үзем дә курка башладым. Гафурига бирмәсәләр нишләрмен? Гафуриның башкодасына Кәримә җиңгә һичбер җылы сүз әйтеп кайтармый бит:

«Быелга укысын әле. Апайларын да яшьләй биреп, чиргә сабыштырып беттек»,– дип кайтара.

Ә башка башкодаларга:

«Быел бирәбез, бирмәгән кайда ул, атасыз-анасыз кыз баланы саклавы авыр, исеме-ние чыгуы бар, хәзер кеше күзенә күренә башлаган инде», – ди.

Ярый әле, минем бәхеткә, атай:

«Имаметдин, кызларны үз теләгәннәренә бир, көлгә аунасын – көн күрсен, дигәннәр», – дип васыять әйтеп үлгән икән. Менә шуны исенә төшереп, Имаметдин агай миңа үзе языпмы, яздырыпмы: «Туганым, сиңа дүрт урыннан башкода йөри. Шуның берсе Гафури, кайсысына барасың?» – дигән язу җибәрде.

Мин дә күп уйлап тормадым: «Туган итсәгез, Гафурига бирегез», – дип язып җибәрдем. Җиңгә белән агаем арасында китте ызгыш, китте җәнҗал, түзеп кенә тор! Җиңгә:

– Сатучы Садретдин дусты Хәкимгә бирсәк, бүгеннән эчке фатирына сезне буш кертәм, дип тора иде. Эчеңне тишә иде шул.

Агаебыз: Миңа фатир кирәкми, торыр җиребез бар бит, әйбәт», – ди. Шуннан соң нишләсен, Гафуриның кодасына сөенче бүләге биреп җибәрә җиңгә.

Ләкин сатучы Садретдин хатыны килеп:

– Нәрсә дип шул хәерче, бетле шәкерткә бирдерәсең? Бер иреңне җиңә алмагач, ник дип аның белән торасың? Тот та бүләкләрен кире кайтарт. Быел бирмәскә булдык, диген, – дип котыртып кайтып китте.

Менә шуннан соң җиңгә кемнәндер язу яздырып, сөенче бүләгенең кайтарылуын сорап, Гафурига язу җибәргән. Ләкин Гафури бүләкне кире кайтару урынына, Сәрби әби аркылы:

– Зөһрәне яхшылык белән бирәләр икән, бик яхшы. Әгәр дә бирмиләр икән, мин барыбер аны аларда калдыр-

мам, алырмын,– дип әйттереп җибәрә. Менә шуннан соң бирергә булалар. (1909 ел, 15 август)

## *Шагыйрьнең танышларында*

Бергәләп тора башлавыбызга унбиш көнләп үтеп китсә дә, без әле парлашып бер җиргә дә чыгып йөргәнебез юк иде. Беркөнне төшке аштан соң Гафури:

– Әйдә, Зөһрәкәй, мин сине үземнең бик якын дусларым белән таныштырып кайтыйм,– диде. Мин аның бу тәкъдименә чиксез шатланып, киенә башладым. Үзем эчемнән генә уйлыйм: берәр приказчикка алып бара микән, үзе кебек берәр язучы белән таныштырырга уйлыймы икән? Әллә берәр зур укытучыга күрсәтергә уйлыймы икән? – димем. Ләкин кемгә, нинди иң якын танышларыннан берсенә алып баруы турында, әллә кыймыйча, әллә тиеш күрмичә, сорау бирмәдем.

Без Уфа каласының Нижегородка ягына таба атладык. Ущелье тавын төшеп, тимер юлны аркылы чыгарга өлгермәдек, борынга әчкелтем бер ис бәреп керә башлады. Бу ис барган саен көчәйде. Хәтта аның әчесе белән агуланган һава күздән яшь чыгартырга иткән төсле булды.

Ул ара да булмады, без бер күл янына барып җиттек. Күл өстенә ясалган басмаларга 30–40 лап хатын-кыз зур тирән кәрзинкәләргә тутырылган йонны озын таяк белән болгата-болгата юалар иде. Боларны күргәч, мин теге сасы иснең кайдан килүен бик тиз аңладым. Ләкин күлгә якын килгәч, ул тончыктыргыч иskә чыдарга әмәл юк иде. Бу агулы истән тизрәк котылу өчен кызурак атлый башлаган идем, Гафури мине йон юуучы хатын-кызларга таба каерып алып китте. Ул читтәге басмада эшләүче бер әбигә:

– Исәнмесез, кемгә юасыз, әби? – дигән иде.

Әби бик сүзчән карчык булып чыкты:

– Әйтмә дә инде, балам,– дип, башы белән ымлап, икенче кварталга карады, сузылган кладовойлы ике катлы зур таш йортны күрсәтте.– Менә, – ди, – Гайнулла

байларга юабыз. Иртәнге җидедән кичке сигезгә тикле, баш күтәрмичә, шулай болгатабыз да болгатабыз. Шунда да сиңа,– әби күл читендә йөргән бер ир кешене күрсәтеп,– шушы этенә тиклем ыжгырып кына тора: «Нигә сөйләшәсез? Нигә карап торасыз? Байга әйтермен, көнлек хакыгызны киметтерермен», – дип ырылдый да йөри. Көнлекче булырга язмасын икән.

– Көненә күпме аласыз соң, әби?

– Күпме булсын, хатын-кызның көнлек хакы күптәннән бирле утыз тиен инде анын,– дип, әби кызылга сары парча төшкән алъяпкычының итәге белән маңгай тирен сөртеп куйды. Басманың икенче башында кырык ямаулы күлмәгенең итәген артык югары күтәреп кыстыру сәбәпле штаны күренеп торган, бер балагы тузганлыктан ертылып кыскарган, икенче балагы озын бер хатын безгә:

«Сезнең сорашуыгыздан ни файда бар? Барыбер безнең тормышны җиңеләйтәчәк башы юк» дигән сымак итеп карап алды да:

*«Агыйделкәй суы ай Дим түгел, чыгар җиркәйләре киң түгел.*
*Кешеләрдән кеше һич ким түгел, тик бәхеткәйләре*
*тиң түгел!»* –

дип сузып җырлап җибәрде. Без исәнләшеп алга киттек. Нижегородканың эреле-ваклы тартмалар кебек тезелеп торган өйләрен артта калдыра-калдыра, Иделгә якынлашып килгән чакта, Гафури кулын алга төртеп:

– Әнә без бара торган өй,– диде.

Мин, ни тиклем генә тырышып карасам да, ул кулы белән күрсәткән җирдә күз туктарлык каралты тапмадым. Аптырагач, күзләремне Иделнең аргы ягына күчердем. Анда урман арасында яңа салынган бер өй күренеп тора иде. Мин эчемнән:

«Әһә, моның таныш кешесе дачада тора торгандыр, ахырысы. Алай булгач, бик гади генә кешеләр түгелдер инде. Эре кешеләр булып, уңайсыз хәлдә калмасам ярар иде», – дип уйлап бетерергә дә өлгермәдем, Гафури тагы да уемны бүлдерде.

– Килеп тә җиттек,– диде.

Безнең алдыбызда җирдән бер аршын чамасы биеклектә, түбәсендә үскән алабуталары саргаеп беткән, тимер мич торбасы юанлыгындагы калай торбасы сөрәеп утырган бер землянка тора иде. Шул вакыт Гафури землянкадан ерак түгел бер бүрәнә өстенә утырган, уң як итәге биленә тиклем ертылган, башы кайчы белән генә кыркылган җиде-сигез яшьләр чамасындагы бер кызга:

– Нихәл, туганым, өйдә берәрсе бармы? – дигән иде, кыз ертылган итәген уң кулы белән тотып, сул кулы белән авызын каплап, бер сүз дә эндәшмичә, землянкага таба йөгерде. Мин инде хәзер үзебезнең кайда кунак булып килүебезне Гафуридан сорамыйча ук бик тиз төшендем. Без землянканың ишеген дә ачарга җитешә алмадык, өстенә ямаулы күлмәк, аягына үзе теккән чүпрәк башмак кигән, башына керләнеп беткән кара каймалы ак яулык бәйләгән 60–65 яшьләр чамасындагы зәгыйфьрәк күзле бер әби ишектән чыкты, кулларын күзләре өстенә куеп:

– Бәй, бәй! Мәҗит түгелме соң? – диде.

– Әйе, әби, мин. Менә сиңа килененңне күрсәтергә алып килдем, күреш,– диде.

– Әй, шулаймыни әле, котлы булсын инде, бәхет-тәүфыйк, мәхәббәт белән тигезлектә шатланып гомер итегез! – дип, минем аркамнан сөйде дә безне землянкага алып керде. Гафури землянкага кергәч, миңа:

– Минем фатир хуҗасының асравы Мөслимә апаеңны беләсең бит. Миңа барып йөрегән чакларда үзеңә чәй ясап эчерә торган иде. Менә бу әби шул Мөслимә апаеңның әнисе була инде,– диде.

Мин, землянкага керү белән, башта, бернәрсә дә күрмичә, әйле-шәйле булып калдым. Тик бераз торгач кына землянка эчендәге нәрсәләр бер-берсеннән аерылып күренә башладылар. Ишектән кергәч тә сул кулда әбинең үз кулы белән чыгарылган мич. Мичнең уң ягында күмер төшеп, күп җирен уйнаклап яндырган аркасыз утыргыч. Аның өстендә, карчыклар кебек алга иелгән, һава керә

торган челтәре дүрт почмаклы итеп уеп кына алынган, борынының борып агыза торган тоткасы сынганлыктан, кадак тыгып куелган бер калай самавыр утыра. Аны сүндерер өчен булса кирәк, торбасына бүрек зурлыгында иске чүпрәк тыгып куйганнар. Уң кулда бик бәләкәй бер тәрәзәсе булып, ике өлгесе булса да, рамнар табылган пыялага карап ясалганга, берсе бик тар, берсе киң булып, бик юан кеше янында үләргә җитешкән нечкә кеше басып торган төсле күренә. Пыялалары ватылган саен төшә барганга, кайсыбер урыннары өчәр катка әйләнгән. Тәрәзәгә корган пәрдә, Мөслимә апайның хозяйкасының (ул биргән) челтәр тоткан иске ак юбкасыннан тегелгән булып, аның бер як почмагы, ни өчендер, дүрт почмаклы итеп ертып алынган, тышкы яктан караган кешегә бөтен өй эче күренеп тора. Тәрәзә янындагы өстәлгә бик иске карасу яшел клеенка җәелеп, аның күп җире кубып беткәнгә, чуар хәлгә әйләнгән. Өстәлдәге чынаяклар өстенә кара ситсага ак буй төшкән, аның күп җире телем-телем булып ертылган ирләр күлмәгенең җиңен җөй турысыннан ертып ябып куйганнар, сул кулда, почмакта, яшникләрдән өелгән карават сымак җиргә, өстенә корамалары ертылып беткән юрган җәелеп, бер башында икесе ике төрле тышлы, берсе зуррак, берсе бәләкәйрәк ике мендәр тәртипсез генә ташланган. Караватның икенче башында җиңнәре ертылып беткән кыска сары тун ята. Мичнең стена янындагы бер тишеккә, ни өчендер, бер итек башы тыгып куйганнар. Менә өй эчендәге бөтен җиһаз шуннан гыйбарәт инде. Гафури, папиросын кабыза-кабыза, әби белән сүзгә кереште.

– Хәким кайда эшли, әби?

– Эшләми, балакаем. Ул бит әле һаман больницада ята. Аның бер елдан бирле аяксыз җәфалануын беләсең бит инде.

– Анысын беләм. Бит ул сәламәтләнгән иде түгелме соң?

– Сөйләмә инде. Хәерчегә җил каршы, диләр бит. Такта яру заводында эшләп йөргән чакта аягына бүрәнә башы

төшкән иде. Шуннан котырынып шеште дә китте. Без аны тиз генә докторга күрсәтә алмадык. Үзең беләсең бит, ат елларга рәт булмады. Земский больницасына чаклы аны бит күтәреп алып барып булмый инде. Алай дигәч тә бала түгел бит. Байлар кебек докторны өйгә генә китертсәң иде дә бит, безгә ул бәхет тимәс инде, балам. Шулай итеп, үзебез им-том белән маташтык. Ул бер дә килешмәде. Тозлы мүк япкач, азрак шеше кайткан кебек булган иде, әллә кагылды-нитте, яңадан җилсенеп, кып-кызыл булып ярсып шеште дә китте. Шуннан соң аптырап больницага салдык. Хәзер инде докторлар: «Аягын кисмичә туры килмәс», – дип әйтәләр икән,– дип, әби елап җибәрде.

Без уңайсыз хәлдә калып, бер-беребезгә караштык.

– Елама, әби, терелер әле,– дип, аны юатырга тырыштык. Ләкин ул тирән итеп көрсенде дә:

– Буламы соң? Булмас, бер ел буена чирли, бер җирдән дә бер тиен ярдәм алыр җиребез юк. Бәхетле кеше башта ук шулай хәерче булмый ул. Картлар, берәүнең яшь чакта бәхете булмаса, картайгач була, ди торганнар иде. Бер дә генә дөрес түгел икән шул. Дөрес булса, менә мин бәхетле булыр идем.

– Булыр әле, әби, булыр. Дөнья гел генә шулай тискәре ягы белән тормас.

– Белмим, Мәҗит балакаем, булса булыр иде инде. Менә мин биш яшемнән ятим калдым. Шул вакыттан бирле мин эшләмәгән эш калмады. Шунда да юньләп тамагым туймады. Өстем бөтәймәде. Тормышка чыккач та рәтле көн күрмәдем. Күп кайнеш өстенә төштем. Унбер кашык күтәрә торган идек. Йә инде, шул вакытта каенсеңелләрем белән күлдән нефть җыеп, бер байга көянтәсен ун тиенгә бирә торган идек бит,– ди.

Аның нефть турындагы сүзе мине бик нык гаҗәпләндерде. Чөнки Уфа каласы эчендәге бәләкәй күлләрнең берсендә дә нефть чыкмаганын бик яхшы белә идем. Шул сәбәпле әбинең бу сүзләре миңа аңлашылып бетмәгәнгә күрә, мин:

— Нигә, әби, Нижегородка күлендә нефть чыгамыни? — дигән идем, ул болытлы ямьсез көндә кабарып, күпереп аккан болыт арасыннан күренеп калган кояш нурлары кебек итеп, кайгылы битләренә бик аз гына елмаю билгесе чыгаргандай булды да тагы да сөйләп китте:

— Юк, балам, күлнең үзендә нефть чыкмый,— диде, кулы белән күрсәтеп.— Әнә, депода машиналарны кайнар су белән югач, нефтьле сулар һәм баклардан сарыккан нефтьләр канаулар буйлап күлгә агып төшә. Без аны шуннан җыеп алабыз.

— Ничек? Шулпа өстендәге майны кашык белән җыйган кебек җыясызмы?

— Түгел, балакаем. Оят булса да әйтәм инде. Күлмәкләребезне билгә тикле күтәреп бәйлибез дә, муеныбызга җеп белән чиләк тагып алабыз. Аннан соң су өстенә җәелгән нефтькә яулык зурлыгындагы чүпрәкне җәеп салабыз да чиләккә сыгабыз, җәеп салабыз да сыгабыз. Бер чиләк нефть җыяр өчен әллә никадәр газапланырга туры килә. Аның хакы күпме тагы, көянтәсе бары ун тиен генә бит. Нефть ала торган бай аны савытыннан савытка бушаттырып чиләк төбендә калган суы үткәргәч кенә акча биргәнлектән, кайсы чакта 8—9 тиеннән артык тими дә торган иде әле.

— Ул гына барыбер ашарга җитмәгәндер бит?

— Җитү кайда ул, балакаем. Безнең көч сатылмаган бай булмагандыр инде ул Уфада. Бер байга үзебез сатып алган мунчаладан чыпта суктык. Бер байның магазинына киндер суга торган көрә бәйләдек. Аршыны ярты тиен белән бер вершок киңлектә тасма суктык. Тагы бер байга биш парын бер тиен белән иске резина галошларның эчен кубарып эшләдек, ком, таш, такта ташу кебек эшләр берсе дә калмады.

— Ичмасам, балаларың да ярдәм итә алмыйлармыни?

— Сөйләмә инде, балам, кайсы бер кешенең улыннан бәхете булмаса, кызыннан була торган иде. Минем өчен ул да тимәде. Мөслимәнең беренче кияве бая сезгә очраган

кызы туган көнне машинага кысылып үлде. Мәрхүм тимер юлда эшли иде. Аннан соң такта яру заводында эшли торган кешегә биргән булдык. Анысы бик ямьсез эчә, сугыша торган кеше булып чыкты. Аптырагач, аерып алдык та, асраулыкка керде.

Шул арада әби капыл гына сикереп торды да, яшьле күзләрен сөртә-сөртә:

— Сүзгә мавыгып, самавыр куярга да онытып утырам. Бәхетсезлекне сөйли башласаң, сүзгә аптырап тормыйсың бит. Башыңнан үтелгән булгач, сөйлисең дә сөйлисең,— дип, калай самавырын кузгата башлады. Бу вакытта көн яхшы ук кичеккәнгә күрә землянканың эче шактай ук караңгыланган иде. Әби самавырга тотына башлагач та, Гафури урыныннан тиз генә кузгалды да:

— Кирәкми, әби, мәшәкатьләнмә. Без чәй эчеп тормыйбыз. Көн дә кичегеп бара. Безгә кайтырга да ерак кына. Хәким больницадан кайткач, иркенләп утырырга тагы да җайлап килербез әле. Хәзер киленегез белән таныштырып кына кайтыйм, дип килеп чыктым. Менә сиңа килен бүләге,— дип, әбигә биш сумлык кәгазь акча чыгарып бирде.

Әби, нишләргә дә белмичә, аптырап калды. Акчаны әле бер, әле икенче кулына тотып, тегеләй сугылды, болай сугылды, куяр урын тапмады.

— Рәхмәт инде, балакаем, мине шулай шатландырган өчен, сезгә көтмәгән җирдән гаеп[1] хәзинәләрнең ишеге ачылсын...— дип әле минем аркамнан, әле Гафуриның аркасыннан сөйде дә, урындыкка утырып: — Мине шатландырган өчен, сезгә Аллаһы тәгәлә бетмәс-төкәнмәс гаеп хәзинә бирсен,— дип, кул күтәреп дога кылды.

Шуннан бераз сөйләшеп утырганнан соң Гафури:

— Йә, әби, безгә кайтырга рөхсәт итегез инде,— диде һәм без чыгып киттек. Без кайтканда машина юлы аркылы чыгарга туры килде. Гафури миңа бик матур биш чуер ташы җыеп:

[1] Гаеп – көтелмәгән.

– Син таш уйнарга яратасың шикелле, җыеп бирергә чәчкә юк бит,– дип, биш таш җыеп бирде. Без кайтып җиткәндә, караңгы төшкән, өйләргә утлар алганнар иде инде.

### *Миңа тегү машинасы алдык*

Без бергә тора башлагач, кием-салымнарыбыз ару гына булса да, ашау-эчү ягы шәп түгел иде. Гафури көне-төне язып утырса да, язучыларның әсәрләре белән кесәләрен калынайткан татар буржуазиясе әсәр өчен бик аз түли. Безнең ике-өч көн, хәтта бер атна ит ашамаган көннәребез күп була. Ләкин моны мин кешеләргә түгел, хәтта агайларга да белгертмим. Чөнки мин Гафурига үзем теләп бардым. Стена аша торган (безне «ач торалар» дип гайбәт сатучы) хатыннар сизмәсеннәр дип, иртә белән кухнядәге көрчәкләрне, аш пешереп йөргән кеше сымак, әвеш-тәвеш китереп, тавыш чыгарам. Төш вакытында аш пешмәсә дә, тәрилкәләрне шылтыратам. Бер алам, бер куям. Аш-су пешергән кеше сымак, еш кына помой чиләге түгәм.

Капка төбенә Гафурины карарга чыксам, моннан ун көн элек ашаган ашның итләрен теш арасыннан казып торган булам. Ә үзем, кич булгач, Гафурига:

– Әйдә, җиңгәләргә барабыз. Хәзер агаем да кайткандыр инде (агаем – приказчик), – дим.

Гафури, әлбәттә, минем анда ни өчен барасы килгәнемне белә. Чөнки агаем кайтуга җиңгәм, арык кына иттән булса да, турап аш пешерә. Чәй янында да аз булса да вак-төяк нәрсәләре була. Анда баргач, табигый, алар:

– Әйдәгез, бик вакытлы килдегез, рәхим итеп, аш ашарга утырыгыз,– диләр.

Гафури:

– Юк, минем бер кабар җирем дә юк. Без күптән түгел генә ашадык. Белмим тагы, Зөһрәнең аппетиты яхшы, бәлки ул ашар,– дип караса да:

– Йә, аштан зур булмассың, утыр, азрак капкаларсың,– дип, Гафурины да утырталар. Шулай итеп, без тамак ялгап кайтып китәбез.

Сәламәт көе эшсез тору авыр. Мин, Гафуридан, аена ике сум түләп бару шарты белән, аяклы машина алдырдым. Табигый, минем машина алганны Нижегородка хатыннары көне белән белеп алып, миңа күлмәкләрен китерә дә башладылар. Ләкин аларның:

– Менә, хәерче шәкерткә барды да, хәзер тегү тегеп тамагын туйдыра инде,– дигән сүзләре мине гарьләндерә. Мин шуннан соң ул халыкка: «Тегү текмим, машинаны үземә тегү тегәр өчен алдым», – дим. Ләкин Сәрби әбигә:

– Әби, миңа эш тап, ләкин бер кеше дә белмәсен,– дим.

Ул толчок кибетенә данәсен дүрт тиен белән тегәргә ирләр күлмәге китерә башлады. Төнлә китереп, төнлә алып киткәнгә, моны бер кеше дә белми. Шулай итеп тормыш аз-маз рәтләнә, тамак та туя. Үзем көндез укыйм, мәгълүматымны арттырырга тырышам. Чөнки үземнең уем белән берәр мәктәпкә мөгаллимә булып керергә ният булса да, Гафури:

– Укы әле, берәр рәте табылыр,– ди торган иде.

1911 елның август аенда мин II класслы башкорт приютына укытырга кереп, аена ун сум вазифа ала башладым.

## *Тукай Уфада*

1912 елның җәе. Бер көнне мин базардан кайткан чакта, миңа кемдер «Тукай килгән бит, ишеттегезме?» дип сорады. Мин өйгә ничек кайтып җиткәнемне белмим. Гафури әле эшләми, өйдә язу-сызу белән мәшгуль иде. Мин ишектән керү белән кычкырып:

– Гафури, сөенче, Тукай килгән! Мин хәзер өйләрне җыештырам, син аны үзебезгә алып кил. Нигә башта ук безгә төшмәде икән,– дидем. Гафури тиз генә киенде дә, Тукайны алырга чыгып китте. Ул киткәч, мин өйләрне тазартып, күрше бакалея кибетеннән, әүвәлгеләре белән

нибары сиксән биш тиен бирәчәк була дип, ике кадак ак күмәч, ярты кадак ак май, ярты кадак варенье алып чыгып, өстәлгә әзерләп, Гафуриның кайтканын көттем. Алар бик озак тордылар. Мин самавырга берничә тапкыр ут салсам да, алар кайтмадылар. Әллә берәр кеше икесен кунакка алып киттеме икән, дигән уйга төштем. Урам тәрәзәсеннән карый-карый күзләрем талып бетте. Бер өч сәгать торганнан соң, Гафури үзе генә кайтып керде. Мин:

– Нигә Тукайны алып килмәдең? Мин сый әзерләп көтеп тордым,– диюгә, Гафури, елмаеп: «Бичара, нәрсә белән сый әзерләдең?» дип, өстәлдәге ашамлыклар өстенә япкан газетаны күтәреп карады, соңыннан: «Зөһрәкәй, Тукай безнең өйгә килмәскә булды. Гаиләле кешегә барырга уңайсызланам. Әгәр сыйласың килсә, берәр гостиницага алып барырсың, дип әйтте,– диде Гафури, миңа карап.

– Әллә әнә ул минем кышкы пальтоны астагы Габдерәхим бабайдан саттырабызмы? Мин барыбер аның тегелүен яратмыйм. Кышка тикле берәр рәте табылыр әле,– диде дә Тукайны ничек тапканын сөйләргә тотынды.

– Иң элек өйдән чыгып китеп «Сибирский гостиница» номерына бардым. Анда булмагач, янындагы номерга кердем. Анда да юк. Шуннан «Нур» номерына киттем. Белгән кеше дә юк. Неужели «Сарай»га төшәр дип, анда киттем. Юк бит, булса, алар белерләр әле, дигән уйга килдем дә «Сабах» магазинына бардым. Мин керү белән приказчик малае әкрен генә: «Мәҗит агай, Тукай килде бит», – диде. «Кайда төшкән соң ул, мин иртәдән бирле эзләп йөрим инде», – дидем мин. Ул тагы, тавышын акрын гына чыгарып: «Бездә ул, әнә артта», – диде. Мин, ышанмыйча, кибет артындагы запас китаплар торган бүлмәне ачып карадым.

Аптырап киттем. Китап яшникләре өстенә юка гына бер келәм җәеп, ике кулын баш астына куеп, бәләкәй генә мендәргә Тукай чалкан ятып тора иде. Мине күрүгә торып утырды да бик нык ютәлли башлады, һәм, ютәлләп бетәр-бетмәс, бик нык сагынышкан дусларча кочаклашып күрештек.

– Нихәл, Мәҗит? – диде. Мин исәнләшеп, хәзер алып китәргә килгәнемне әйттем.

– Фатир бәләкәй булса да, таза, җылы, Зөһрә дә анда көтеп калды, – дидем. Шуннан ул әзрәк алдына карап бармакларын аралаштырып утырды да:

– Мәҗит туган, мин гаиләле җиргә бара алмыйм. Уңайсызланам. Әгәр теләсәң, берәр җирдә кунак итәрсең, – диде.

Бабайдан пальтоны өч сумга саттырып, Гафури Тукайны сыйларга китте. Тукайны кунак итеп кайткач, болай сөйләде:

– Мин барып кергәндә, Тукай баш астындагы мендәрен стенага бастыра биреп куеп, уң терсәге белән шуңа таянып, чәй эчеп утыра иде. Мин кергәч, ул елмаеп:

– Чәй эчеп утырам, әйдә, эчәсеңме? – диде.

– Бик рәхмәт, Тукай әфәнде, чәй эчеп кенә килдем, папирос тартам, әгәр һава бозыла димәсәң, – дидем мин.

– Сул кулың селтәп тарт! Мин бозык һавага өйрәнгән инде, – диде ул. Аның өстәлендә бер газета кисәгенә бераз французский булка теленеп куелган. Шуның янәшәсендә азрак колбаса ята. Дүрт почмаклы бәләкәйрәк калай савытта төрле төстәге ландрин тора иде. Ул әлеге ландрин савытын миңа сузып:

– Ал әле шуларны, бу Казан ландрине, төрлесеннән төрле тәм килә. Мин гадәттә шикәр салып эчәргә яратмыйм. Яшьтән өйрәнмәгәнгәдер инде, – диде.

– Мин дә андый татлы нәрсә белән дус түгел дә, сез тәкъдим иткәч, алам инде дип, берсен алып авызыма каптым. Ләкин шунда ук тешкә дә килеп бәрелде. Тукай күрмәгәндә генә алып кесәгә салдым. Ябышып калмасын тагы, – дип, кесәсеннән кара йонга буялып беткән сары кәнфит кисәген помой чиләгенә илтеп салып килде дә тагы сөйли башлады. – Шуннан соң ул җайлап кына торды да: «Бүген һава матур булырга охшый», – диде.

– Һава бик матур, җылы, әйдә, Тукай әфәнде, әзрәк үзеңә Уфаны күрсәтеп алып кайтыйм, – дидем мин. Ул

эндәшми генә киенде дә, без икәүләп чыгып киттек. Ул ишектән чыккач, тезелеп чиратта торган извозчикларга карап алды да: «Болар күп алалармы?» — диде.

— Әйдәгез утырабыз, аның хакы пустяк,— дидем мин. Шулай итеп, без, атка утырып, Александр урамы белән югары менеп киттек. Пушкин белән Центральныйга да җитмәдек:

— Мәҗит, төшик әле, минем камыт бавы кыса башлады,— диде Тукай. Чөнки извозчикның арба тәгәрмәче тимер шинлы булып, сәламәт кешегә дә йөрү авыр иде. Бигрәк тә Уфаның урамы, эре ташлар җәелгән урыннары бөтен эчләрне селкетә. Шунан соң без җәяүләп Пушкин урамы белән бераз төшеп, бер сыраханәгә кереп утырдык.

Күп тә үтмәде, безнең өстәлгә каршы мескен бүрек кигән ике толчокчы кереп утырып, сыра эчәргә тотындылар. Боларның кулларын бутый-бутый безгә карап эчүләреннән Тукай шикләнә башлады. Ул әкрен генә миңа:

— Мәҗит, моннан чыгып китик әле,— диде. Мин сәбәбен сорасам да, чыккач сөйләячәген аңлатты. Ул чыккач:

— Безнең Казанда менә шундый кешеләр кереп утыралар да, безнең халыкны күреп, чыккач кирәгеңне бирәләр. Болар да безгә бик карап утырдылар,— дип, артына карап алды да: — Әйдә, берәр аулаграк җиргә барыйк, — диде. Шуннан соң без Иске Уфага таба «Собачий переулок» дигән җирдәге сыраханәгә кереп утырдык. Анда мин әйбәт кенә өч блюдодан обед алдым. Ләкин Тукай бернәрсә дә ашамады. Шуннан чыгып, губернатор бакчасы аша кайтып, бакчада бераз утырдык. Ләкин Тукай бер сүз дә сөйләми, миңа күзләре белән генә карап утырды. Тукай Уфадагы тәэсирләрен Казанда чыга торган «Ялт-Йолт» журналына язды. (...).

*1937*

*Гафури З. Безнең тормыш // Мәҗит Ғафури тураһында замандаштары: Истәлектәр.— Өфө: Башкорт. китап извоһы, 1961.— 92—122 б.*

*Миргазиз Укмасый*[1]

## Казанда очрашулар

Мәҗит Гафури «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 1905 елда килде. Ул мәдрәсәнең алдынгы корпусында, өске катта, коридордан кергәч, сул якта беренче бүлмәдә тора иде (ул бүлмәне Гафури бүлмәсе дип исемләргә дә ярый). Бу елны мин мәдрәсәгә соңрак килдем. Мин килгәндә Казан кайный, һәр җирдә – революция дулкыны. Монархия нык куркынган, яшь буыннар шатлыкларыннан күккә сикерәләр иде. Шушы елның беренче ноябрендә «Казан мөхбире» газетасы чыга башлады. М. Гафури шушы газетага, беренче буларак, тәбрик шигырен бастырып, шуның белән мәйданга басты. Без әле Гафурины яхшы танымый идек. Безнең мәдрәсәдә мондый көчле каләмле бер шагыйрьнең булуына безнең исебез китте. Мин шигырьләр язу белән маташканга, аның үткер каләмен күргәч, хәйран калдым. Шул мәдрәсәдә укучы Тәхәү Туйбактиннан Мәҗит белән таныштыруын үтендем. Таныштык. Мәҗиттә бу вакытта искиткеч энтузиазм, революцион рух бөркелә иде. Мәҗит белән без һәр кичне очрашабыз, ул миңа яңа язган шигырьләрен укып күрсәтә иде. Без якын дуслар булып киттек. Кичләрдә сөйләшеп утырганда, ул укуларның начарлыгыннан, белемебезнең юклыгыннан, аңыбызны схоластика белән агулауларыннан зарлана, мәдрәсәләр бу тәртип белән барганда, киләчәкнең өметсез, җансыз, юлсыз икәнен күреп көенә иде. «Укмасый,– ди, – менә бу революция безгә ни дә булса бер нәрсә бирмәсме», – ди.

[1] Миргазиз Каюм улы Укмасый (Зәбиров) (1884–1947) – татар шагыйре, драматург, балалар өчен хикәяләр, замандашлары турында кызыклы истәлекләр авторы.

Шуңа күрә Мәҗит көрәшеп, тартышып, революцияне ничек тә югары күтәрергә, җиңүгә алып чыгарга бөтен күңеле белән тели иде. Мин авылдан күптән түгел килгәнгә, ул миннән авыл крестьяннарының настроениеләрен сораша, аларның да революциягә канат булуларын көтә иде. Без дус булып калабыз. Бөтен эч серләребезне яшерми уртаклашабыз. Мәҗит миңа Троицкида язып бастырган «Себер тимер юлы» шигырен бүләк итә. Бу аның 1905 ел революциясенә тиклем язган шигыре иде. Мин аны хәйран калып укыйм, Мәҗитнең атаклы шагыйрь булып калачагына шиксез ышанам. «Сарай» номеры залында чәй эчеп утырганда, Мәҗиткә сорау бирәм: «Мәҗит! Син шигырьләреңне нигә казакъ стилендә язасың?» – дим. «Мин Акмулла шигырьләрен бик яратам, ул миңа үз шигырьләре белән хәлфә, шуларны укып, мин шигырьләр яза башладым, аның теле бик гади, үткер, байларга камчылы, аның шигырләрен укып мин сокланам», – диде. Шуңа күрә Мәҗит, һәр юлы унбер басымнан дүрт юллы казакъ стилендә булган форманы ул вакытта еш кына кулланып килде. («Шатлык», 1905 елда чыга башлаган «Казан мөхбире» газетасына тәбрик, «Инсаф вә иттифак», «Вакыт җитте тикшерергә», «Шигырь», «Иптәшләрем шәкертләргә» шигырьләре һ.б.)

«Болгар залында Казан мөселманнарының мәҗлесе булды» (нәсер), «Европа – Азия», «Алар алай, болар болай» шигырьләре һәм нәсерләре бер-бер артлы мәйданга чыга тордылар, халык боларны йотлыгып укыды. Ул инде халыкның сөекле шагыйре санала, язу мәйданында танылып килүче шагыйрьләрнең берсенә әверелеп бара иде. Уральскидан Г. Тукай шигырьләре килә башлагач, Мәҗит Тукай шигырьләренә сокланып карый башлады. Тукайның зур шагыйрь икәнен танып, аңа зур ихтирам бирде. «Укмасый! – ди,– бу Тукай Акмулладан да көчлерәк яза бит», – ди. Минем бүлмәмә Тукайның «Иске мәдрәсә шәкертләре» дигән шигырен алып төшкән дә, минем алдымда артистларча декламировать итә, үзе шаркылдап көлә.

«Менә бу – без инде, – ди, – син бу язучыны beләсеңме, зур үсәчәк егет бу, – ди.

Мәҗит салмак, уйчан, биш үлчәп бер кисүчән, тормышы авыр булса да, тешен кысып сызучан, монархиягә, буржуазиягә зур нәфрәт саклаучы, вакыты җиткәнче сызучан бер кеше иде.

1906 елның язында Мәҗит Гафури, мин һәм танылмыйча калып яшьтән үлгән татар шагыйре Хәбиб Исхакый Әстерхан губернасының Бүкәй Урдасы казахлары арасына балалар укытырга киттек. «Надежда» компаниясенең «Христофор Колумб» исемле пароходында, өчебез бер каютага урынлашып, өченче класста бардык. Мәҗит монда бөтенләй үзгәрде. Шат, көләч, күп сөйли, күп җырлый иде. Без Саратовка тиклем барып, аннан Покровскига чыгып, поездга утырдык, Савинька дигән бер авылга тиклем, аннан кырык чакрым ераклыкта булган Бүкәй Урдасының казахы Тычканбайга ат яллап киттек. Бу минем элек укыткан таныш казахым иде. Хәбиб Исхакый да электә укыткан казахына китте, Тычканбай Мәҗит Гафурины Ир атлы казахка урынлаштырды. Атна-ун көн узганнан соң, Гафури белән Исхакый минем янга кайттылар. Бу – болай булган. Исхакый Мәҗит янына килгән булган. Ләкин Мәҗиткә бу казахларда тору бик ямансу булганга, ул аннан китәргә карар биргән икән. Исхакыйның аны җибәрәсе килми, шуннан алар миңа килгәннәр. Без Тычканбайның куен ашап, кымызын эчкәннән соң, иркенләп сөйләшү өчен, Карачайдагы күл буена киттек, шунда бик озак сөйләшеп утырдык. Аерылганга аз гына вакыт узса да, бер-беребезне сагынган идек, шунда Мәҗит Исхакыйга әйтә:

– Теге шигырьләреңне Укмасыйга укып күрсәтимме? – ди.

Кесәсеннән бер кәгазь тартып ала да Исхакыйның яңа гына язган шигырен миңа укып күрсәтә. Ул ике шигырь укыды, минем хәтеремдә калганнары шул:

*Безнең чишмә суы борылу-борылу,*
*Борылулары саен бер сылу,*
*Борылып-борылып аккан су буеннан*
*Казлар эзләп килә бер сылу...*

Бу бөтен бер шигырь булып, минем хәтеремдә бары шул өлеше генә калган.

Икенчесе:

*Һич гөнаһсызга гомергә Себер киткән кыз бала,*
*Әй биек тау, әй биек тау, дип гомергә сызлана.*
*Күпме сатмыйлар сылуларны акча-алтын өчен,*
*Әй гөнаһсыз кыз бала! Сезнең өчен соң кем яна?*

Бу да бер бөтен шигырь иде.

Укып бетергәч, Мәҗит әйтә:

— Укмасый, күрәсеңме мондагы картиналарны, — ди, — татар кызларының язмышлары, бөтен трагедияләре белән җанлы килеш күз алдына килеп басалар, — ди, — шигыреңне чын күңелемнән тәкъдир итеп тәбрик итәм, дускай Хәбиб,— диде дә аркасыннан какты. Шуннан соң татар хатын-кызларының хокуксызлыклары хакында, ачынып, байтак кына сөйләде. Аннан үз хәленә кайтып: — Укмасый, мин синең белән күрешергә килдем, кадалып китсен сахрасы, монда мин эч пошудан авырмый үләм,— диде. Ике-өч көннән соң китеп тә барды. Шулай итеп, Карачайдагы Кара күл гомерендә бер тапкыр шагыйрь Мәҗит Гафурины күреп калды.

Башка язучылар да шулай булган кебек, 1908 елда Гафуриның да элекке ялкыны шактый ук басылды, язу дәрте сүнә төште. Столыпин реакциясе Мәҗиткә дә нык тәэсир итте.

Аннан тагы, шушы җәйнең ахырында, Мәҗит белән Казанда очраштык, ул — Уфага, мин Балык Бистәсенә барам. Очрашкач, шатлыктан сүз таба алмый тордык. «Әйдә, Укмасый! Харчевняга кереп чәй эчик»,— диде. Усиновларның харчевнясына кереп, чәй китерергә куштык. Монда озак, иркенләп сөйләшеп утырдык. Инде бу вакыт Мә-

җит ябык, басынкы, сүрән, анда 1905 елгы очкыннар сүрелгәннәр иде. Мин шунда: «Нигә хәзер аз язасың, Мәҗит?» – дип аңа сорау бирдем.

– Настроением начар, күрәсең бит атмосфераны, әй Укмасый, язудан эш чыкмый, бастыручы жуликлар, төрле ялган белән, буш алмакчы булалар, язу өчен вакыт кирәк, вакыт өчен икмәк кирәк. Ул бирән корсаклар син язган әсәрнең маен эчеп, сиңа гөбе төбе дә калмасын, имеш, бу эшмени? – диде.

Мин аның бу сүзләреннән эчем катып көлдем. «Неправда, тормыш болай бармас, моның ахыры булыр», – диде ул бераздан, шактый кызып.

Мәҗитнең сүзе дөрес килде, без якты көнгә чыктык. Без хәзер кайда барганыбызны белеп, шат яшәүче ирекле илнең балалары булып, азат хезмәт белән гомер итәбез.

Мин шунда Мәҗитне Якимскиның «Амур» исемле пароходына утыртып озатып калдым.

*1944*

*Укмасый М. Казанда Очрашулар // Мәҗит Ғафури турaһында замандаштары: Истәлектәр.– Өфө: Башкорт. китап из-воһы, 1961.– 145–149 б.*

*Сәйфи Кудаш*[1]

# Шагыйрьнең үтенече

Һич көтмәгән бер вакытта, мин, үпкәм авырып, аяктан егылдым. Докторлар миңа, шәһәрдән китеп, авыл шартларында, саф һавада яшәргә кискен киңәш бирделәр. Шул сәбәпле мин, 1921 елның язында, газета эшеннән китеп, авылга кайтырга һәм докторлар күзәтүе астында дәваланырга мәҗбүр булдым. Җәйне Москва һәм Уфа газеталарына язышу белән үткәрдем. Көз көне Келәш авылындагы биш комплектлы мәктәпкә мөдир һәм укытучы булып билгеләндем.

1921–1922 елның кышында, мәктәпкә укырга йөри алмый торган балаларны ашханәгә беркетүне юллап, Уфага килгән идем, иң элек, ашыгыч хәбәрне тапшыру өчен, редакциягә кердем. Редакциядә эшләүче иптәшләрне Кара-Якуп волостендагы хәлләр белән таныштырдым. Бу елларда авылдагы кулак элементлары ачлыкны һәм шул уңай белән килеп чыккан һәрбер вакыйганы Совет властена каршы коткы таратыр өчен файдаланырга тырышалар иде. Бигрәк тә муллалар һәм буржуаз милләтче вәлидовчы калдыклар ачлыкны дингә ышанмаучы большевикларга каршы Алла тарафыннан җибәрелгән бер җәза итеп күрсәтергә теләделәр һәм моңа халык массаларын ышандырырга маташтылар. Алар, шул максат өчен, әллә нинди адәм ышанмаслык ялганнар тараттылар.

Сөйләшеп утырганда, Мәҗит Гафури шушы кабартылган хәбәрләрне һәм хезмәт ияләренең ачыгу сәбәпләрен белергә теләде. Мин Кара-Якуп волостенда Совет хөкүмә-

---

[1] Сәйфи Кудаш (Сәйфетдин Фәттах улы Кудашев) (1894–1993) – татар-башкорт шагыйре, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

тенең халыкка күрсәткән зур ярдәмен әйткәч, Гафури янында утырган кешеләргә:

— Хөкүмәтнең ачларга җибәргән ярдәмен, урыннарда күрелгән чараларны өзлексез яктыртып барырга кирәк. Бу үзе генә дә кулак коткысына каршы көчле агитация булып төшәчәк,— диде.

Аннан соң мин яшелчә үстерү белән шөгыльләнгән һәм тамыразыклар чәчкән рус һәм украин крестьяннарының ачлыкка татар һәм башкортлар кебек үк нык бирешмәгәнлекләрен сөйләгән идем, Гафури бөтенләй җанланып китте. Тирән итеп көрсенде дә:

— Нинди ачы бер сабак бу ачлык. Димәк, ачлыкка бирешмәскә дә мөмкин. Моның өчен тамыразыклар чәчү һәм яшелчә үстерүне җәелдерергә кирәк. Моны бит һәрбер хуҗалык булдыра ала. Чөнки һәрбер хуҗалыкның усадьбасында моңа җитәрлек буш урын бар. Без, матбугат эшчеләре, тамыразыклар чәчү һәм бакча үстерү турында өзлексез агитация алып барырга тиешбез,— диде.

Шул көнне кич белән мин, үзенең чакыруы буенча, Гафуриларга барып утырдым. Бу чакта алар Николаевская урамындагы 89 номерлы йортның кечкенә квартирасында торалар иде. Мин Гафуриның язып, Зөһрә апаның тегеп утырган чакларында килеп кердем. Болай эш бүлеп барып керүгә элек үкенсәм дә, уңайсызлану бик тиз бетте. Чөнки Гафури кемгәдер язып утырган хатының азаккы юлларын сызгалады да конвертка салып ук куйды. Зөһрә ханымның ниндидер бер оешмага стандарт бельелар тегүе аңлашылды. Ул өй тутырып ташлаган ак материяне җыеп алды да, авыл хәлләрен сораша-сораша, самовар куярга кереште. Сүз уңаенда мин бер авылның мулласы, яңгыр теләү сылтавы белән кешеләрне котыртып, җәмәгать тарафыннан сатып алынган токым үгезен корбанлыкка чалдыруын һәм тиресен үзенә сәдакага алуын сөйли башлагач, ул, самоварга салырга әзерләгән чыраларын тоткан хәлдә, кире безнең якка чыкты.

Мәҗит Гафури төзеп яткан «Ачлык тырнагында» исемле шигырьләр җыентыгын күрсәткәч, сүзне әдәбият һәм язучыларга карата борып җибәрдек. Ләкин бу турыда сүзне озакка суза алмадык. Зөһрә ханым Гафури белә торган ниндидер элекке сәүдәгәр һәм шәһәр мещаннарының, ангарларында запаслары була торып, ачлар фондыннан алдашып азык алулары турында сүз китереп кыстырды.

Зөһрә ханымның бу хәбәре, утка керосин сипкән кебек, Гафурины кабызып җибәрде. Ул моңа кадәр үк нәрсә турындадыр борчылган, кемнәргәдер ачуланган булырга кирәк. Бу сүзләр аның берүзен генә борчыган кичерешләрен тышка чыгарырга мәҗбүр иттеләр. Эчендә кемнәргә каратадыр янган нәфрәт уты аның йөзенә бәреп чыкты. Гафури – нинди булса да берәр начарлык турында сүз барганда, салкын кан белән генә сөйләшә алмый торган кеше. Шуңа күрә дә ул, үзен үртәгән бу тойгыларны сүндерергә бер чара эзләгән кебек, кулын кесәсенә тыкты да тәмәке чыгарды.

– Бу спекулянт халкыннан да оятсыз, намуссыз һәм ерткыч халык юктыр. Әгәр дә мөмкинлек бирсәң, өстеңдәге актык күлмәгеңне салдырып алыр, «бу ялангач кала бит» дип, аз гына да борчылмас. Ачларга ярдәм күрсәтү комиссиясенә шундый кешеләр оялап алгандыр, булмаса, тук сәүдәгәргә күрәләтә ачлар хакын бирмәсләр иде. Ул комиссиянең составын иртәгәдән калмый тикшертергә кирәк. Димәк, алар хөкүмәтнең һәрбер мыскалы алтын бәрабәренә торган азык фондын шулай хаксыз кешеләргә тараткач, башкача хыянәт эшләмиләрмени инде... Зөһрә, син иртәгә бу мәсьәләне ныклап бел әле, чынлап та шулай булса, газетага язып, ояларын актарырга кирәк,– диде Гафури ачулы караш белән. Моңа каршы Зөһрә ханым:

– Синнән башка да күрерләр әле, кеше белән бәхәсле булып...– дип сөйли башлаган иде, Гафури аның сүзен бүлде:

– Үзең беләсең, минем бервакытта да сәүдәгәр-спекулянтлар һәм халык ризыгын урлаучылар белән дуслык-

ка кергәнем юк. Бәс, шулай булгач, монда һич нәрсә бозылмаячак, бәлки алар тарафыннан бозылган нәрсәләр төзәтеләчәк кенә. Йөрәге белән совет властена каршы кешеләр хөкүмәтнең ачлыкка каршы күргән чараларын дошманлык белән көпә-көндез җимерсәләр, укымышлылар, халыкны ташлап, пылау ашарга Ташкентка китсәләр, без монда хыянәтләргә күзне йомып торсак, ул чагында ни нәрсә? Бу ачлыктан шул сәүдәгәрләр генә исән торып калачак. Менә шуңа күрә дә хәзерге көндә һәрбер мыскал онның дөрес файдаланылуын күзәтергә кирәк. Бүген тәэминат эшләрендәге хыянәтләргә читтә тыныч карап торудан да зур җинаять юк,– диде.

Гафури үзенең кемнәргәдер төрткәләп сөйләвен аңлап җитмәүне сүз уңаенда ук төшенеп алды. Шул сәбәпле ул өстәлнең бер як читендә торган конвертны алды да, шул төшенмәгән мәсьәләләргә аңлатма итеп, миңа сузды. Үзе, мин хатны укып чыкканчы, тәмәке тартып, хатның миңа ничек тәэсир иткәнен күзәтеп утырды. Күптән түгел Уфаның бер төркем интеллигенциясе, ачлык җәфасы күрмәс өчен, Урта Азиягә күчеп киткән иде. Бу хат шуларның Гафуриига да, миңа да таныш булган берсе тарафыннан язылган иде. Мин хатта: «Анда, ачка какланып, үлекләр арасында ятма, монда кил. Бу якта ашарга күп, безнең тамак туйды. Көн дә пылау ашыйбыз...» – дигән юлларны укыдым.

Гафури, шушы минутта үз язмышына бик нык канәгатьләнеп, Ташкентта майлы пылау ашап утырган һәм бу хатны язган кешенең битләрен кызартып оялтырлык итеп карады да зәһәр катыш елмайды.

– Әйдә, монда ачы алабута ашап, шигырь язып ятканчы, пылау ашарга китик... Менә юләр халык: мин дә киткәч, син дә киткәч, монда соң кем эшләр икән? Халык башыннан шундый авыр көннәр үткәргән чакта, ялгыз башыңны алып качу – үзе зур җинаять. Бу бит инде фронт ташлап качкан солдат кебек булып чыга. Ачлыкны халык белән бергәләп көрәшеп җиңәргә кирәк. Анда китеп, ял-

гыз башымны ачлыктан коткарганчы, монда халык белән бергә җәфа чиккәнем артык. Халык һичбер вакытта да үлеп бетмәячәк,– диде.

Ул төнне мин Гафуриларда куна калдым.

Иртәнге чәйне эчеп утырганда, кулларына папкалар тотып, өч кеше килеп керде. Саулык сорашканнан соң, аларның Гафурига электән таныш булган берсе:

– Без ачлык белән көрәшү комиссиясенең членнары булабыз. Ярдәмгә мохтаҗ семьяларның җан исәбен яңадан алып йөрибез. Әлегә кадәр эшләп килгән комиссиянең членнары бу эштә хыянәт эшләгәннәр. Запаслы кешеләргә ашарга биргәннәр. Асылда булмаган кешеләрне исемлеккә кертеп, артык азык алганнар. Хәзер алар, эштән бушатылып, судка бирелделәр,– диде.

Бу хәбәрне ишеткәч, Гафури рухланып китте. Зөһрә ханым бу юлы да үзенең актив хатын икәнен белдерергә өлгерлек күрсәтте:

– Ачлар хакын урлаган ул кешеләрнең үзләрен ачлык җәзасына хөкем итәргә кирәк,– диде.

Комиссия членнары Гафури семьясында ничә кеше барлыгын белергә теләделәр. Ни өчен шушы көнгә кадәр ашарга алмаулары белән кызыксындылар. Гафури, бу кешеләрне кызыксындырган мәсьәләләр турында аңлатма биргән кебек итеп, салкын кан һәм тынычлык белән:

– Туганнар, безнең тагын өч-дүрт көн ашарлык көрпәбез бар әле,– диде.– Сез бүген тарата торган ярдәмегезне менә шушы минутта ангарларында бер генә нәрсәләре дә булмаган кешеләргә өләшегез. Минем Заһретдин исемле бер итекче танышым каты авырып ята. Ашарларына бернәрсәләре дә юк. Миңа тиешле азыкны, зинһар, шул картка бирегез. Өч көннән соң без, бәлки, тагын да берәр төрле итеп, эшне рәтләп җибәрербез. Мин сездән бары бер генә нәрсә турында үтенәм: партия, хөкүмәт һәм халык ышанып тапшырган мондый изге эшне башкарганда, зинһар, хыянәткә юл куя күрмәгез.

Ачларга ярдәм комиссиясенең кешеләре Гафурига тиешле паектан башка да Заһретдин картка өлеш чыгарачакларын әйттеләр. Картның адресын язып алдылар. Ләкин Гафури, картның бик йончыган булуын, өстәмә ашатуга мохтаҗлыгын әйтеп, үз сүзендә калды.

Бүгенге очрашуның истәлеге итеп, Гафури Казаннан яңа басылып килгән «Эшче» поэмасын миңа бүләк итеп бирде.

*Кудаш С. Хәтердә калган минутлар. Истәлекләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.– 286.*

*Гата Исхаков*[1]

## Мәҗит агай белән танышу

1906 елның язы. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә беренче сынаулар үткәреләә. Укучыларның һәрберсенең йөзендә шатлык, һәркем, әзерләнеп, тәүге сынауны үтергә керә. Шулар арасында М. Бикбулатов, Х. Искәндәров, М. Гафури агайлар да бар.

Сынау тыңларга теләүчеләр дә җыелганнар. Троицкидан кайтышлый мин дә шулар арасына килдем.

Сынаулар башланды. Укучылар җавап бирә, эш күңелле бара.

Шул елларда, Һиндстанның югары мәктәбе ысулында югары мәктәп корам, дип йөрүче Һинди Минһаҗ да сынауга килеп керә.

Һинди өчен бу җыелыштан файдаланырга кирәк, ничек тә байларны һәм укучыларны үзенә каратырга, үзен зур күрсәтергә кирәк була. Чөнки ул байлардан акча җыярга дип килгән иде. Шуңа күрә ул укучылар турысында: «Ятлатып кына керткәнсез...» – дип, укытучыларга пычрак ташлый, тавыш күтәрә. Тавыш зур була, сынау гарәп әдәбияты буенча иде. Җавап бирүчеләр арасында Гафури агай да утыра. Минем күз гел аңарда була.

Укыту эшенә һич катнашы булмаган Һиндинең монда тыгылып тавыш чыгаруына укучылар да риза булмыйлар. Дәреслекне Һиндинең үзенә биреп сорарга кушалар. Ул тәүдә китапны алмый, сатулаша торгач, шәкертләр китапны аның кулына тапшыралар. Шунан соң ул сорый башлый. Укучылар аны көчләп мәҗбүр итәләр. Минһаҗ сорый, Гафури җавап бирә... Ахырында Минһаҗ үзе со-

---

[1] Гата Камалетдин улы Исхаков (1885–1939) – язучы, фольклорчы, мөгаллим.

раудан аптырап кала – мәсьәләне төшенеп җитми. Гафури агай гәрәпчәсен татарчага әйләндереп, татарча шигырьләрдән мисаллар китереп күрсәтә. Татар әдәбиятына күчкәч, Минһаҗ бөтенләй авыр хәлдә кала. Барлык укучы аннан көлә. Шулай итеп, Гафури агай гарәп әдәбиятын белүдә өстен булып чыкты, Минһаҗ көлкегә калды. Гафури агайның шул җиңеп чыгуы «Галия» мәдрәсәсе өчен бер күңелле хәл булып калды.

Шул вакыйгадан соң, Мәҗит агайга булган ихтирам тагы да арта төшеп, аны күрәсе, сөйләшәсе килү тойгысы көчәйде. Бу күрешү инде тәү тапкыр гына булмаса да, ничектер, мин үз сүзләремне тулы әйтергә батырчылык итеп бетерә алмадым. Шулай булса да мин аның биреп киткән китапларын укыганымны сөйләп, алдагы кыш мәктәптә (Троицк мәдрәсәсендә) ниләр эшләргә кирәклеге хакында кыскача гына сорый алдым. Ул миңа шул фәннәрне мәктәпкә кертү юлларын сөйләп бирде.

1907–1908 елларда «Рәсүлия» мәдрәсәсендә дә фән укытуны кертүне таләп итеп кыймылдый башлагач, Йосыф Шәркый, Исмәгыйль Юнысовлар белән безне – барысы унике кешене – мәдрәсәдән куарга булдылар. Бу вакыйга соңында Мәҗит агайның мәдрәсәдән китүенең сәбәбен генә түгел, аның башлап киткән юлының дөреслегенә дә төшенгән идем.

Шуннан соң без 1908 елның көзендә күрештек. Монысы инде чын танышып күрешү булды.

1908 ел көз мин дә Уфага «Галия» мәдрәсәсенә килдем. Ишан мәдрәсәсеннән үзебезнең куылу хакында бәләкәй генә пьеса язган идем. Шуны күрсәтү, төзәтешү өчен мин кеше тапмый йөдәдем. Чөнки кемгә күрсәтсәм дә, көләр төсле тоела, куркам. Шулай да мин аны М. Халиков белән карап чыктым. Шул үзем уйлаганча булды: ул кычкырып көлде. Төзәтү ягыннан ул берни дә күрсәтә алмады.

Мәҗит агайны болай яхшы белсәм дә, ул олы кеше, көләр я әрләр, дип куркам. Ахырында түзмәдем, Гафури агайның торган җиренә барып, язманы күрсәттем. Ул

минем эшне бик мактады, ярдәмләште һәм яңадан-яңа төзәтүләр кертеп, бергә эшләдек. Шунда мин Гафуриның чын ярдәмче, башкаларны да үстерүгә юл бирүче кеше икәнлегенә ныклап төшендем. Шуннан соң без аның белән нык танышып, чын дус булып киттек. Һәм соңгы елларда да Уфада иң яратып бара торган кешем шул булды. Шул елларда атай йортыннан куылганнан соң, кунар җирем, сыена торган арка таянычым да шул булып китте. Олы шагыйрь миңа үз янымда булганда гына якын булып калмады, бәлки читтән торып та киңәш бирүче, дәрт тудыручы якын кешем, ныклы терәгем булып әверелде.

Атаем үлгәннән соң авылга кайтып эшләүгә дә мине ул өнди иде. Анда үзләшеп, ныгып китүгә дә ул сәбәпче булды. Авылга кайтканнан соң минем бераз күңелсезләнүемә ул шундый җавап бирде: «Син андагы тормышыңнан бер генә дә зарланма. Син шунда торып, эшеңдә сәбат һәм әкдам[1], гайрәтне кулга алып эшлә...» – диде.

Минем авылда эшләп китүнең үзенә бер тарихы бар.

Ишан мәдрәсәсеннән куылганнан соң, атам хәлле генә кеше булса да, мине карамады. Хәтта, «балам түгелсең» дип, өйгә дә керттермәде. Менә шул вакытта миңа Гафури агайларга сыенып яшәргә туры килде.

Атаем үлгәннән соң, Гафури агайның киңәше белән, мин Абдулла авылына кайттым. Абдуллага кайтканнан соң, атаемның йортына, иске мирас тәртибе белән, мин дә җидедән бер өлешкә булса да, хуҗа булдым.

Өйдә хуҗа булу бик кызыклы тоелды миңа. Чөнки шуннан күпме генә вакыт элек, өйнең ишеген ачарга да ирексез, куылган бер малай көеңә, хәзер шул йортның эчендә хуҗа булып саналу (төбендә әлләни булмаса да) бик зур эш сымак күренде.

Билгеле, бу вакытына карап бер шатлык булып сизелде. Инде бу шатлыкны кем белән уртаклашырга да, кемгә белдерергә?.. Минем өчен Мәҗит агайдан да якын, Мә-

[1] Сәбат һәм әкдам – башлаган эшне тайпылышсыз эшләү, дәвам иттерү.

җит агайдан да кадерле кеше юк иде. Мин кайгымны аның белән уртаклашкан кебек, шатлыгымны да уртаклашасым килде. Шуның өчен мин аны үзебезгә чакырып хат яза башладым. Ул кире какты: «Иртә әле, өйлән, урынлаш, аннан соң күрербез», – диде. Мин ничә тапкырлар язсам, тел белән әйтсәм дә, җавап бер булды.

1915 елда Гафури агайларның өйләре капыл янып, һичбер нәрсәсез урамда калдылар. Шуның белән мин чакыруны катгый куярга булдым. Гафури агай риза да булган иде. Ләкин үз туганнарының кискен чакыруы булганга, алар сүзен ега алмады, 1915 елны инде ул кыштан ук үзенең вәгъдәсен бирде. Һәм менә яз белән ул килергә булды. Көткән яз җитте, без дә Дүртөйлегә барып аларны каршы алырга булдык.

Дүртөйледә мине беләләр. Чөнки атай нык хәлле булуы белән аның дус-якыннары, үзе кебек юан корсаклы купецлары да күпләр иде. Алар минем атаем өеннән куылып, «берәзәк-зимагор» кушаматы белән йөргәнемне дә беләләр.

Мәҗит агай килергә булгач, мин шул юан корсакларга сер бирәсем килмәде. Аны каршы алу өчен, күрше егетнең атын парлап булса да, көймәле арба әзерләттем, кыңгыраулар тагып, зуррак каршыларга тырыштым. Шулай иттем дә.

Мәҗит агай, шул заманның теле белән әйткәндә, ак якалар куеп, европача киенгән иде. Семьясы – Зөһрә апай, Әнвәрләр дә калача киемдә иделәр. Мәҗит агайның пароходтан төшүен карап торган әлеге юан корсаклы күзәтчеләр өчен кием ягыннан тәнкыйть итәрлек хәл булмады. Үзен тоту ягыннан да Мәҗит агай сынатмады. Аларны күрү белән ул, хәлне сизенсә дә, сер бирмәде. Килгән атка оста гына утырып китте.

Ул киткән вакытта, Дүртөйленең шул юан корсакларыннан Йосыф Халиков, Исламгалиев, тирмәнче Степаннар карап калалар. Алар арасында:

– Тапкан икән кеше...

– Берәзәкнең берәзәк булмый тагы...

– Килгән кешесе дә бер аксак малай бит.

– Камалетдин агай исән чакта (минем атайны әйтәләр), мондыйларны эз бастырмый иде дә бит...– дип, төрле сүзләр белән сөйләнеп калалар.

Мәҗит агай, шулай итеп, 1916 елның 20 маенда Абдулла авылына килеп төште. Билгеле, мин аны үз дусларым белән каршы алдым.

Гадәттә, минем янга килеп газета хәбәрләрен укыта, сугыш хәлләрен сораша торган, шул чорның политик хәлләре турысында да сөйләшеп утыра торган авылдагы өлкәнрәк агайларым бар иде. Өфедән кунак булгач, бигрәк тә язучы кеше килгәч, алар тагы да хәбәрләшергә теләп, килүне өзмәделәр генә түгел, бәлки тагы да арттыра төштеләр. Шундый көннәрдә Зөһрә ханым газета укып бирә. Килүчеләр шагыйрьгә дә якыная төшеп, сораулар бирәләр. Шул сорашулар, шул утырулар, бара-бара, политик төскә әйләнеп китә башлады.

Эш шуннан башланып китә: газета укуны тыңларга килүчеләрне мин, аларга электән билгеле булган, «Алтынчы ел васыяте»н язучы Мәҗит агай белән таныштырам. Һәм шунда Мәҗит агайның «Алтынчы елдан җиденче елга васыять», «Җиденче елның җавабы»н укып күрсәтәм. Мәҗит агай үзе дә кыска гына бер шигырь укыды. Бу барыбызга да бик ошады.

Шунда булучы Таһиров белән Вәләй Камалетдинов агайлар түзми, икенче көндә кич, шым гына тагын килеп керәләр. Бу көн алар Нургали агай белән Йосыпов, Шәймәрдәновларны да килергә чакырганнар. Алар төрле яктан килеп керәләр.

Элекке көн кичәдә булган Таһиров агай «Алтынчы елдан васыять»не яңадан укуны сорады. Бу юлы Гафури агайның үзеннән укыттык. Тыңлаучыларга аерым дәрт, аерым җанлылык күренде бүген.

Тыңлаучылар арасында сүз китте:

– Бигрәк килештереп язган!

– Эх, шул кан эчүче бүреләрдән котылырга иде...

– Шулай шул, бүреләрне бетерми торып, сарык рәхәт яши алмас...

Шуннан соң Мәҗит агай, килүчеләрнең чын дәрт белән йөрүләрен, «эчкерсез» булуларын төшенеп ала. Һәм аларга карап:

– Туганнар, хәзер бу – алтынчы ел эше, алтынчы ел васыяте генә җитми. Беләсез, хәзер каты сугыш бара. Хәзергә япон сугышы кебек кенә түгел, 20–30 дәүләт катнаша. Моның сөземтәсе дә япон сугышы ише генә булмас. Бу сугыш соңында инде бүреләргә дә көн калмас. Менә шуны әзерлек белән көтәргә кирәк. 1905 елдагы кебек таркау, йоклап калырга ярамый.

Соңыннан сүз сугыш турысына күчә. Сугышны ничек бетерергә? Нигә сугышалар? Кем өчен сугышалар? Кемнәр сугыша, кемнәр атыла, кемнәр яралана? кебек сораулар китте...

Шуннан Җәләй агай балаларының кайтуын теләп ала. Мәҗит агай аларга «Кем ул?» дигән шигырен укый. Моңа барыбыз да риза булып калабыз. Карт Җәләй агай елауга тиклем барып җитә. Гафури агай бу шигырен үткән елда ук язганын, ләкин бастырмавын сөйләп алды. Һәм монда укуны да сер итеп искәртү ясады.

Тагы шулай икенче вакытларда «Сарыкны кем ашаган?», «Ярлылар», «Үги балалар»ын укып чыктык.

Безнең бу утырулар эзсез калмады. Кешеләрнең еш килүеннән шикләнеп булса кирәк, авылдагы Газизҗан мулла бер төндә килеп басты. Ләкин без дә сер бирми, чәй эчүчеләр булып, эшне үзгәртә алдык. Үзен дә чәйгә утыртып эшне сиздермәдек.

Бу көн шулай тыныч үтсә дә, бу хәл тыныч кына бетмәде; шул елда Исмаил волость урядннигы Климин, кереп, «Урал» газетасын эзләде. Үзе татарча китапларны аера алмагач, ни рәвешле бергә кушылганнардыр, Яңа Мортаза авылының Шакир мулла белән Климин китапларга тентү ясады. Ахырда «Урал» газетасын, «Урал» китап-

ханәсе әсәрләрен эзләүләрен белдереп, минем Троицкида «Хезмәт» китапханәсе аша «Урал» алдырганымны, шуны кайда куйганымны сорый башладылар, Гафури агайның нигә килүен тикшерделәр. Чыннан да минем тулы көе «Урал» газеталары, аның вак брошюралары да бар иде. Ләкин андый нәрсәләр алардан да алдарак башка берәүнең туфраксасына күмелгән иде инде. Шуның белән таба алмадылар, исән калды – әле дә исән.

Менә шул беседаларны авыл кешеләре соңыннан да сагынып сөйләделәр. Мин дә шуны искә алып хатка язганмын. Хатка язуның икенче ягы да булган: мин Мәҗит агайны чакырып йөдәттем. Ул шуны әйтте:

– Син, туган, чакырма инде, чакыргач бармый булмый. Сезнең авыл бик ямьсез урынга утырган: суыгыз начар, якында агач юк, кызыгып йөрерлек таулар да юк. Андый урында ял вакыты әрәмгәрәк китә,– диде.

1916 елда авылга килеп кергәч тә шул сүзне әйткән иде:

– Авылыгыз матур түгел икән, табигатьнең бер генә төрле байлыгы да күренми,– диде. Шуңа өстәп: – Юлда бер авылга килеп җиттек, авыл чокырдарак, шунда мин Зөһрәгә карап: «Гаталарның авыллары шушы булмаса ярар иде инде, бик чокырда, юеш булыр», – дип киләм. Аны үттек. Ул Әсән авылы булды. Тагы шундый чокырдагы бер авылны үттек (Нажы авылын әйтә). Аларыннан котылып, яңадан бер авылга киләбез. Бу авылның суы зур күренә (буа бар), урман да якын. Авылның очыннан караганда өйләр күренми, матур бакча булып тора... Авыл башыннан кергәндә: «Шул авыл булса ярар иде», – дип кердек. Ләкин атлар туктамады, үтеп китте», – ди (бу – Каралачык авылы булды).

Соңыннан янә бер авыл турында: су урынына текә ярлар күренә, урман юк, вак агачлар да күренми. Авылның очына килеп керү белән бөтен авыл ачык – күренеп тора, бер чыбык та юк. Менә шул авылга килдек тә туктадык. Бик кыен булды,– дип көлдерде.

Шулай булса да авылдагы шул утырышларны, картларны искә алып сораша, аларга сәлам җибәрә торган булды.

Кыскасы, Гафури миңа чын киңәшче, иң якын таяныч – атаем булып әверелде. 1934 елның 29 октябренә тиклем без шулай бергә булдык. Әле дә фикерләр бергә калды.

*1937*

*Исхаков Г. Мәҗит агай белән танышу // Мәҗит Ғафури тураһында замандаштары: Истәлектәр.– Өфө: Башкорт. китап из-воһы, 1961.– 145–149 б.*

*Хәлил Маннанов*[1]

# Мәҗит Гафури мине журналист ясады

### *(Яшьлек хатирәләре)*

1924 елда без Башкортстанның төрле почмакларыннан һәм кантоннарыннан җыелган бик күп авыл яшьләре – егетләр һәм кызлар – Уфада укып ята идек. Бүгенге кебек хәтеремдә, Пушкин урамындагы 92 номерлы ике катлы йортның өске катында (ул вакытта обкомолның гомуми торагы) безнең ятак булып, аның бер бүлмәсендә берничә малай тора идек. Анда Стәрлетамак кантоныннан мин һәм Әбделмәнов фамилияле (исеме Әхсән иде бугай) бер егет, Бөре кантоныннан Закир Ирмашев, Бәләбәй кантоныннан Гариф Мөнакәшев дигән егетләр бар иде.

Билгеле, якынрак танышып алгач, үзара дуслаштык. Минем белән янәшә койкадагы иптәшем, озын буйлы ябык малай Әбделмәнов бер көнне үзенең Мәҗит Гафури туып-үскән Җилем-Каран авылыннан булуын, ул гына да түгел, горурланыбрак, Мәҗит аганың якын туганы да икәнен сөйләде. Минем моны ишеткәч, билгеле, колак тора төште, бик кызыксындым һәм тагын да җентекләбрәк Гафурига ничек туган булуын сораша башладым. Моннан соң зур шагыйрьнең туганы булган кеше миңа да якын кебек тоелды һәм аның белән тагын да дуслаштым.

Минем кебек кече яшьтән үк мәктәпләрдә К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Мәрҗани, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Г. Камал кебек атаклы шагыйрь һәм язучыларның әсәрләрен укып үскән, шулар белән тәрбияләнгән кешегә, Гафурины якыннан белгән, хәтта үзен аның туганы дип атаган кешенең очра-

[1] Хәлил Маннанов – журналист.

вы, аның үз янымда ук булуы, ничектер, гаҗәбрәк булып китте. Мин дулкынлана башладым.

Үзем Әбделмәновтан:

– Гафуриның син үзен күргәнең, аның белән сөйләшкәнең бармы соң? – дип сорыйм.

Ул моңа каршы гади генә итеп:

– Нигә булмасын, – ди, – сирәкләп ул безнең Җилем-Каранга да кайта, мине белә ул,– ди. Җитмәсә: – Озаклamый мин аның эшләгән җиренә барам әле, менә шушы урамда гына ул, ерак түгел,– дип куйды. Аның бу сүзләре миңа сәер тоелды. Янымда, янәшә койкада ята торган иптәш нинди кешенең туганы, имеш! Ул миңа бәхетле кеше кебек күренде, һәм шунда ук аңа:

– Алай булса үзең белән мине дә алып бар,– дигәнемне сизми дә калдым. Әбделмәнов минем сорауга шатланып риза булды. Берәр көнне дәрестән соң барырга сүз куештык.

Өченче көнне инде без, икәүләп, Мәҗит абый эшләгән «Яңа авыл» газетасы идарәсенә киттек. Бу елларда редакция Пушкин урамындагы 79 номерлы (хәзерге Верховный Совет урнашкан бинага каршы) ике катлы иске агач өйдә иде әле.

Барганда Гафурины күз алдына китерергә тырышып барам. Ни өчендер, мин аны авылыбызның җәдит мулласы шикелле таза гәүдәле, зур мыеклы, мәһабәт бер кеше итеп күрергә тырышам. Үзем эчемнән генә: «Ул минем белән сөйләшерме икән, сөйләшсә, ничек сүз башларга, укытучылар кебек сораулар бирә башласа, ничек җавап кайтарырга», – дип уйлап барам һәм үзем дулкынланам. Чөнки минем кебек күп меңләгән яшьләр аның революциягә кадәре һәм аннан соң да өлкәннәр һәм балалар өчен бер-бер артлы татарча чыгып торган шигырьләре, хикәяләре, мәсәлләре белән таныш, аларның күбесен мәктәпләрдә укып, җырлап йөрсәк тә, үзен күргәнебез юк иде. Ә менә бүген гомеремдә беренче мәртәбә тере шагыйрьне – безгә китаплар язып чыгаручы кешене күрергә барам!

Бүрәнә өстеннән тышланган такталарның кайчандыр буялган, инде нинди төскә буялганлыгын да әйтүе кыен булган бер бинаның парадный ишегеннән кереп, тар гына текә һәм караңгы баскычтан өскә күтәрелдек.

Без залга барып кергәч тә, иң элек, закусочныйлардагы шикелле бәләкәй генә биек өстәлләр күзгә ташланды. Аларның берсе янында бездән дә биек булмаган гәүдәле, кара чәч-мыеклы, башында түбәтәй, өстенә кара костюм кигән, галстук таккан өлкәнрәк яшьтәге матур гына кеше, аяк өсте баскан килеш, бик җитди рәвештә нәрсәдер эшли иде. Эчке бүлмәләрдә дә кешеләр күренә.

Кергәч тә икәүләп әдәпле генә исәнләштек. Ул кеше күтәрелеп карап мөлаем кыяфәт белән башын гына какты да тагын эшенә керešте. Без аның җитди эше барлыгын аңлап көтә башладык.

Монда мине гаҗәпләндергәне шул булды. Әбделмәнов кергәч тә:

– Исәнмесез, Мәҗит абый! – дип исәнләште. Миңа, зур гәүдәле кеше күрергә ниятләп баручыга, бу бик сәер тоелды. Минем башка келт итеп:

– Бәй, бу Гафури үзе микәнни? – дигән сорау килде. Чөнки алда һич көтмәгән кеше басып тора иде. Биек өстәлдә аның аяк өсте торып эшләве дә аңлашылмый.

Биш минут та үтмәгәндер, ул эшен бетереп, кәгазьләрен җыйгалады да:

– Әйдә, утырыгыз,– дип, безгә зур кешеләрдәй итеп, урын күрсәтте.

Мин бер сүз дә башлый алмый торганда, кыен хәлдән иптәш коткарды.

– Мәҗит абый, без синең янга хәл белергә генә кердек. Монда укырга килдек. Менә бу егет тә безнең якныкы,– диде. Мин баш кагып кына аның сүзен расладым.

Гафури аңа сораулар биреп, нинди укуга килүебез белән кызыксынды, аның ата-аналарын, тагын кемнәрендер сорашты. Аннан соң әкрен генә, йомшак тавыш белән минем кайдан килүем, исемем, атам-анам турында

сорап китте. Аның сорауларына оялып кына җавап кайтарып, үземнең Стәрлетамак кантоны Сәмән авылыннан булуымны әйттем. Безнең авыл исемен ишеткәч, ул җанланып киткәндәй булды:

– Ә-ә... Якташ икәнсең, беләм... теге акча ясаучы Сәмәнме? – диде.

– Әйе, шул Сәмән,– дидем. Мин аның бу вакыйганы белүенә гаҗәпләндем.

Ул вакыйга болай булган: революциягә кадәре, без әле малай чакта ук, авылда бай һәм укымышлы гына Габдрахман һәм Мөдәррис исемле көмешчеләр булган. Алар патша Николай II нең ялган акчасын ясап (кургаштан коеп, көмеш йөгертеп) баеганнар. Ләкин соңыннан, без белгәндә тотылдылар һәм сөргенгә җибәрелделәр. Бу вакыйга заманында бөтен Стәрлетамак өязен шаулаткан иде. Шуннан соң безнең авыл кешеләрен, кая барсалар да, «акча ясаучылар» дип йөртә башладылар.

Мәҗит абый миңа тагын нindidер сораулар биргәләде. Мин исә, шундый зур кешенең безнең кебек авыл малайлары белән үз тиңе кебек итеп сөйләшүен күргәч батыраеп киттем шикелле:

– Мәҗит абый, без синең шигырьләрне бик яратып укыйбыз,– дип әйтеп салдым.

Ул кайсы шигырьләрне укуымны сорады. Аның балаларга карата язган күп шигырьләре, мәсәлләре мәктәп яшендә үк күңелгә сеңеп беткәнлектән, аларны бер-бер артлы: «Кулың бир!», «Кызыл байрак», «Яшь кыз белән карт», «Татарга», «Татар егете», «Хәмергә каршы»...– дип тезеп киттем.

Бер дә көтмәгәндә ул тотты да тагын:

– Сәмәндәге теге ирләр киеме киенеп малайлыкта йөргән Миңнеяр-Хәтимә бармы әле? – дип сорады.

Мин бераз аптырап калдым. Гомумән, ул вакыйганы белсәм дә, Хәтимәнең соңгы язмышы турында белми идем. Ык-мык иттем дә: «Әйтә алмыйм, Мәҗит абый»,–

дидем. Ә үзем аның безнең авылдагы күптәнге вакыйганы белүенә тагын хәйран калдым. Шуннан ул:

– Ул чакта син яшьрәк булгансыңдыр шул,– дип куйды.

Шушы гасырның башларында безнең авылда тагын бер кызыклы вакыйга була: күрше Балыклыкүл авылының Хәтимә исемле яшь хатын, ата-анасы көчләп биргән, яратмаган ирдән котылу өчен, үз киемнәрен авыл уртасындагы зур тирән күлнең яры башында салып калдыра да (суга батып үлгән дип белсеннәр өчен), ирләр киеме киенеп, авылыннан качып китә. Безнең авылга килеп, Ибраһим Абдюшев исемле бер сәүдәгәргә малайлыкка керә. Үзен Миңнеяр исемле, ди. Берничә ел буе авылда батрак булып йөрсә дә, аның хатын икәнен беркем дә белми. Тик авыл яшьләре белән солдатка каралу, метрикә алу мәсьәләсе килеп тугач кына, чын хәл ачыла.

Заманында тирә-якны тагын шаулаткан шушы вакыйга соңыннан бөек әдип Галимҗан Ибраһимовка «Татар хатыны ниләр күрми» повестен язу өчен сюжет һәм Хәтимә образы әсәрнең төп каһарманы булган Гөлбануның прототибы хезмәтен үтәде. Мин яшь чакта Галимҗан ага Солтанмораттан Сәмәнгә һәм Балыклыкүлгә килеп, шул турыда материаллар җыйнап йөрде, һәм аның бу әсәре беренче мәртәбә 1909 елда (китапның беренче варианты) Стәрлетамактагы «Каләм» матбагасында басылып чыкты.

Мәҗит абыйның ул вакытта сорашканы минә шушы әсәрнең тере героинясы Хәтимә турында иде. (Хәтимә апа әле дә исән, Ташкентта, балаларында яши, диләр. – *Х.М.*)

Мәҗит абый белән сөйләшкәннән соң, без, малайлар, шатланып, аның белән хушлашып чыгып киттек. Ул безгә:

– Тагын килегез,– дип калды.

Мәҗит абый белән минем беренче танышуым һәм сөйләшүем көтелмәгәнчә уңышлы чыккач, үзе дә «тагын килегез» дип калгач, миндә хәзер яңа теләкләр, яңа өметләр туды. «Килегез!» димәсә дә, эчтән генә, тагын барырга карар иткән идем инде!

Аның янына бер «юлны» белеп алгач, берәр атнадан соң тоттым да үзем генә киттем. Хәзер инде ул миңа укытучым кебек якын күренә иде. Шуна күрә, йомышым булмаса да, редакциягә кердем.

Ул мине шунда ук танып алды. Исемемне кабатлап сорады, аннан яшемне, ничә сыйныф бетерүемне, комсомолмы дип тә сорашты.

Бу юлы инде мин һичбер тартынмый, үземне иркен тотарга тырышып җавап бирдем.

Ул үзе эшли, үзе миңа әкренләп сораулар бирә торды. Нинди китаплар укуым белән дә кызыксынды. Мин иске, дини китапларның исемнәрен тезеп киттем.

Җавабым аны канәгатьләндермәде, күрәсең:

– Яңа китаплардан нәрсәләр укыганың бар? – дип сорады. Аның нәрсә белергә теләвен хәзер мин дә аңлап алдым һәм революциядән соң, авылда китапханә ачылгач, аннан алып укыган китапларны санап киттем: «Зәки шәкерт», «Татар хатыны ниләр күрми», «Себер тимер юлы», «Күңел җимешләре», «Газазил», «Карт ялчы», «Табигать балалары», «Алмачуар», «Хәят», «Эшче», «Күңелле сәхифәләр»...

Ул миңа туп-туры карады да, тагын:

– Байтак китап укыгансың икән, яңа китаплар хәзер күп чыга шул. Шушындый китапларны күбрәк укырга тырыш! – ди.– Газета, журналлар да укырга кирәк,– дип тә өстәде.

Бу юлы Мәҗит абый белән шундый ныклап танышуыма һәм сөйләшүемә тагын да шатланып кайттым.

Гафуриның мөлаем йөзен, аталарча йомшак сүзен тиз генә оныта алмадым, бер-ике атна үткәч, тагын бардым. Ул ничектер мине үзенә тарта иде.

Бу юлы да ул, исәнлек-саулык сорашканнан соң, миңа төрле сораулар яудыра башлады һәм:

– Синең газетка язганың бармы? – дип сорады.

Мин «Яшь юксыл»да авыл яшьләре турында бер-ике хәбәрем чыгуын әйттем. Моны белгәч, ул:

– Алай булгач, сиңа һәрвакыт язышып торырга кирәк, килешмәгән урыннары булса, идарәдә төзәтерләр,– диде.

Мин: «Хәзер укуда булгач, хәбәрләр юк»,– дидем. Шуны гына көткән кебек, ул өстәл тартмасыннан кечкенә генә форматтагы ике яңа китап чыгарды да миңа сузды:

– Мә, шушыларны бик җентекләп укып чык та, алар турында нәрсә аңласаң, шул турыда фикерләреңне язып миңа китер,– диде.

Мин аптырап калганны күреп булса кирәк:

– Синең инша язганың бармы? Әнә шуның кебек итеп, китаплар турында яз,– диде. Китапның берсе Ленинның балачагы һәм яшьлек еллары турында, икенчесе, ялгышмасам, Куйбышевның эше һәм тормышы турында балалар өчен Казанда басылган китаплар иде. Аларны алып кайтып киттем.

Кадерле китапларны бик игътибар белән укып чыктым да, аларның эчтәлеге, теле, яшьләр өчен аларның файдалы китаплар булуын әйтеп һәм кайсы нәшрият чыгаруын, хәтта оформлениесен, хакларын да күрсәтеп, яшь укучыларга тәкъдим рәвешендә яздым да Мәҗит абыйга алып киттем. Бу ике китапка бер рецензия сыман нәрсә иде.

Гафури язманы укып карады да:

– Син моны «Яшь юксыл»га кертеп бир,– диде.

Аны «Яшь юксыл» редакциясенә кертеп, чем-кара чәчле, тәбәнәк буйлы кешегә бирдем. Бу – журналист Габдулла Сирай иде.

Рецензия «Яшь юксыл»да басылып та килде. Хәбәрнең астында «Хәлил Маннани» дигән имза ялтырап ята.

Моны күргәч, иптәшләремнең күзләре шардай булды. Кайсы мактый, кайсы мыскыллап көлә.

– Син Мәҗит Гафури янына күп йөри башладың. Моны син язмагансың, ул язып биргән,– диючеләр дә булды. Материал иптәшләрем арасында минем «хәбәрче» дигән исемемне таратты.

Икенче көнне газетаны кесәгә тыктым да тагын Гафури янына киттем. Барып керүем белән, ул көлемсерәгән кыяфәт белән:

– Әһә... килдеңмени, автор Маннани? – дип ярым шаярып каршы алды. Ул бу материалны күптән укыган икән. Миңа кесәдәге газетаны чыгаруның кирәге дә калмады.

Аның бу сүзләренә югалыбрак калдым булса кирәк, рәтләп бер сүз дә әйтә алмадым. Ул «Яшь юксыл»ның минем материал басылган санын өстәл өстенә салып куйган икән. Аны алып миңа сузды да:

– Менә нинди шәп чыккан, молодец, болай яза алгач, һәрвакыт язып тор, – диде.

«Автор Маннани» диюдә дә ул хаклы иде. Чөнки мин бу беренче мәкаләмне Гафуриның үзенә һәм фамилияләренең ахры «и» гә беткән башка күренекле кешеләргә охшарга тырышып «Хәлил Маннани» дип куйган идем.

Чыннан да, безнең халыкның борынгыдан, К. Насыйри, Ш. Мәрҗанилардан ук килеп, соңрак М. Гафури, С. Рәми, З. Бәшири, З. Һади, Н. Думави, Г. Сәгъди, М. Укмасый, С. Габәши, М. Фәйзи, К. Нәҗмиләргә күчкән бер традициясе бар. Әле, революциядән соң, 30 нчы елларны да ул традиция Ә. Фәйзи, Җ. Фәйзи, Г. Әмири, Г. Нигъмәти һ.б. исемнәрендә дәвам итте.

Минем фамилиягә килеп кергән «и»нең гомере кыска булды. 1930 елларда журналистикага күчеп, район газеталарында редакторлык вазифаларын үтәгәндә рәсми фамилияне кую зарур булганлыктан, «и» һәм «ский»ләр төшеп калдылар, алар урынына законлы «ов» кайтты.

Мәҗит абыйдан чыкканда мин күтәренке күңел белән, газеталарга туктаусыз язып торырга карар биреп чыккан идем инде. Бу карарым гомерем буе, 45 ел бозылмыйча килде, бүгенге көнгәчә дәвам итә.

1925 елда Уфадан авылга кайтып киттем һәм, Мәҗит абыйның киңәше буенча, авылдан туктаусыз хәбәрләр язып тора башладым. Аларның кайберләре, газетада басуны сорап, Мәҗит абыйның үзенә дә адресланган була иде.

Шундый бер момент хәтердә калган: «Совет лавкасы түгел, Сабит лавкасы» исемле бер хәбәрне «Яңа авыл» газетасына, Мәҗит абыйга адреслап җибәрдем.

Күп тә үтми, хәбәр бик кызыклы, көлкеле карикатуралар белән урнаштырылып, басылып та килде. Шуннан соң лавка эчендә барган эчү, карта уйнаулар бетте. Тик үзем генә Сабит агайның гомерлек дошманы булып калдым.

Уфа мине үзенә нык тартты. Озакламый тагын килдем.

Утызынчы елларга таба мин Мәҗит абыйның нык кына олыгайганлыгын һәм чәчләренә, сакал-мыекларына чал керә башлаганлыгын күрә идем.

Укудан «Яңа авыл» газетасы редакциясенә эшкә күчтем. Күп тә үтми газетаның исеме «Коммуна» дип алмаштырылды (хәзерге «Кызыл таң»).

Бер көнне шулай редакциягә кергәндә, җаваплы редактор Гайса абый Габбасов тотты да миңа редакциягә әдәби сотрудник булып күчәргә тәкъдим итте. Мин дә күп уйлап тормыйча, күптәнге хыялым үтәлгәндәй күреп, риза булдым. Ул вакытта анда шагыйрь Гариф Гомәр («Сәнәк» журналы редакторы), Лотфый Гадилов, Гыйнди Ишмаев, Гыйнди Гозәеров, Рәшит Гобәй, Сәхи Мусин, Баязит Баян, Габдулла Идрисов һ.б. эшлиләр иде.

Бервакыт редакциягә Мәҗит абый килеп керде. Танышлары белән исәнләшеп бетүгә, мине күрде дә:

– Оһо! Син, Маннани, әллә журналист булып киттеңме? – дип гаҗәпләнә калды.– Шәп, бик шәп, нәкъ урынын тапкансың инде,– диде көлемсерәп.

– Журналист булып беткән юк та югын... Гайса абый әйткәч карышмадым,– дигән идем, ул:

– Өлкә матбугатында эшләрлек булгач, журналист буласың инде ул,– дип кистерде.

Редакциягә килгәндә Гафуриның кулында бер папка бар иде. Гариф Гомәр белән сөйләшеп киттеләр. Ул шушы елларда гына язган «Тормыш баскычлары» повестен газетада бастыру турында сөйләшү өчен килгән икән. Ре-

дакциядә эшләүче иптәшләр Гафуриның мине тануына, хәтта фамилиямне дә белүенә гаҗәпләнделәр.

Соңыннан редактор «Тормыш баскычлары»н басарга хәзерләү өчен Гариф абыйга чыгарып биргәч, башлап аның безнең газетада басыласын белдек.

Гафуриның Беренче бөтендөнья сугышы вакыйгаларын чагылдырган бу зур повесте газетада бүлеп-бүлеп басылды һәм хәтсез саннарга сузылды. Моны басканда ул үзе көн дә диярлек редакциягә һәм типографиягә килеп йөрде. Материалның әдәби бүлектән ничек чыгуы, корректурасының ничек укылуы, типография хаталарын булдырмау мәсьәләләре белән якыннан үзе кызыксынды. Повестьның хатасыз чыгуын тәэмин итүне Г. Гомәр, Б. Баян, Р. Гобәй, мин һәм башкалар күзәтеп бардык, һәр чыгачак номерда корректураларын кат-кат укыдык.

Мәҗит абый бу вакытта «Октябрьский натиск» типографиясенә үзе еш йөрде. Анда ул, бигрәк тә, өлкән наборщик Ибраһим Мәҗитов, корректор Рабига Сафина, печатник Гали Исхаковлар белән якыннан эш итте.

Без бервакыт типографиядә корректура укыганда, Мәҗит абый:

– Ченәкәй китеп барды бит әле,– дип куйды. Моны ни өчен әйткәндер, без төшенмәдек (Ченәкәй Казанга киткән иде).

Повесть басылып беткәч тә ул редакциягә сирәкләп килгәләп йөри иде. 1930 елның көзендә Борай район газетасына редактор булып киткәнче, миңа Гафурины еш кына күреп, очрашып, сөйләшкәләп йөрергә туры килде. Аны һәр күргән, сөйләшкән саен күңел күтәрелеп китә иде.

1937 елда яңадан «Коммуна» редакциясенә кайттым. Монда сугышка кадәр культура һәм әдәбият бүлеген алып бардым.

Бу вакытта күңелемдә тирән ихтирам саклаган, миңа яшьтән үк журналистлык юлына кереп китәргә ярдәм ит-

кән Мәҗит ага Гафури юк иде инде. Районга киткәч, кабат аны күрә алмадым.

Ул елларда газетада әдәби сәхифәләрне оештырганда карт әдипләребездән Гариф Гомәр, Сәйфи Кудаш, Җан Локман, Әмир Чаныш һ.б. иптәшләр дә катнашалар иде. Шулай ук ул чакта ук үзләренең шигырьләре, очерклары, мәкаләләре белән М. Сөндекле, К. Даян, С. Агиш, М. Кәрим, Г. Әмири, Б. Бикбай, Ә. Вәли, Әнвәр Гафури (шагыйрьнең улы), Х. Кәрим, Х. Мөхәммәдияров, М. Таҗи, Р. Нигъмәти, С. Кулибай, Б. Мокамай, Н. Нәҗми, Т. Арслан һ.б.лар да читтә калмыйлар иде.

Тугандаш татар һәм башкорт халыкларының сөекле улы шагыйрь Мәҗит ага Гафури турында исемдә калганнар шушылар.

*1970*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге.– 12 ф.– 3 тасв.– 32 эш*

*Кәрим Әмири*[1]

# Мәҗит Гафури

## *I*

Мәҗит абзый Гафури белән беренче очрашуым 1922 елны булды. Аны мин беренче күрүдә үк гаять түбәнчелекле, сабыр, бер күрешүдә үк иске танышлар шикелле сөйләшә торган кеше дип таныган идем һәм шулай булып чыкты да, бу – бер. Икенчедән, шул елны ук, Таткомбинатта (хәзерге Татгосиздат шул исемдә йөртелә иде) сөйләшеп утырганда:

– Совет хөкүмәтенең ныгуы, аның тормышының матурлыгы өчен көрәшмәгән кеше – үз тормышының матурлануын һавадан көтеп ятучы кеше,– дип сөйләп утыруы әле булса хәтеремдә.

Бу карашы аның үлгәнчегә кадәр дәвам итте. Бу карашын, бу сүзен ул практика белән – практик көрәш белән үткәреп килде. Бу турыда кызык, чыннан да әһәмиятле моментлары булганга күрә, аерым тукталачакмын. Сүз башында аңарга тик характеристика бирү өчен генә искә төшерелде.

Бу килүендә ул озак тормады, үзенең әйтүе буенча, Казанны сагынып килүе һәм кайбер әсәрләрен бастырырга бирү өчен килүе иде.

Шунда ул бер нәрсәгә бик ачынып, бик каты кәефе китеп сөйләгән иде. Кемдер аңарга 1920 елны булган имла конференциясе турында сөйләгән. Бу шуннан гыйбарәт иде: 1920 елны кышын хәзерге Щапов урамында, беренче номер Советлар йортында имла конференциясе булып, Г. Ибраһимов доклад белән чыккан иде. Андагы тартыш

[1] Кәрим Хөсәен улы Әмиров (1896–1962) – шагыйрь, драматург, журналист.

сузык авазлар мәсьәләсендә булды. Конференция өчкә бүленде: сузык авазлар мәсьәләсендә 10 сузык авазны, 6 ны, 5 не яклаучыларга бүлендек. 10 чыларның башында Мөхетдин абзый Корбангалиев, 6 чыларның башында Г. Ибраһимов, 5 челәрнең башында С. Атнагулов тора иде.

Бервакытны сузык авазлар мәсьәләсе тавышка куелды: 10 чылар – 14, 6 чылар – 9, 5 челәр 20 тавыш алды. Бу хәл гаҗәп дәрәҗәдә көлке булып чыкты. Сузык авазларны эшкә ашыру комиссиясенә 6 чы һәм 5 челәрдән (10 чылардан берәүне дә кертмәделәр, бу эш Галимҗан тактикасы белән эшләнде) комиссия сайлап, комиссия үзеннән генә 6 итеп куйды. Чөнки революциядән соң Һади Максуди имласына кайту көлке дә, кызганыч та иде. (...)

### *II*

Икенче очрашу шул ук 1922 елны җәен Уфада булды.

Аны мин «Башкортстан» редакциясендә эш вакытында барып таптым. Редакциядә үзенә тигән эшне бетергән, бер яшь язучыга киңәш биреп утыра иде. Урын күрсәтеп, миңа көтеп торырга кушты, миннән элек нинди киңәш биргәндер, мин килгәндә түбәндәге сүзләрне сөйләп утыра иде:

– Эш булсын дип эшләгез, егетләр. Яисә яхшы нәтиҗә биргән эшнең методларын, эшчеләрнең ничек көрәшүен, шул көрәшнең уңыш бирүен күрсәтегез. Бу хәбәрне укып, икенчеләр үрнәк алырлык булсын. Әгәр дә бер җитешсезлек күрәсез икән: хыянәтме, башкамы – аны бөтен фактлары белән күрсәтегез. Әгәр дә ул басылып чыга икән, аның белән генә канәгатьләнеп калмагыз. Шул хәбәр нигезендә оешмалар алдында тикшерүгә куеп, шул җитешсезлекне бетерү өчен көрәшегез. Менә шунда гына газетаның әһәмияте артыр, хәбәрченең дәрәҗәсе күтәрелер һәм тормышның төзәлүенә сәбәп булыр,– дигән киңәше исемдә калган.

Аның белән сүзен бетергәч, миннән Казан хәлләрен сорашып утырды да мине алып чыгып китте.

Мин номерга төшкән идем. Ул аңарга кәефсезләнде, һәм урамга чыккач, номерга барып әйберләрне алдык та, аңарга киттек. Иртәгә ял дигән көн иде. Ашап-эчеп, Дим буена балыкка төшеп киттек.

Ул балыкка йөрергә бик ярата икән. Ул миңа Димдә нинди балыклар булуын, ничек тотуын һәм балыкка барып яхшы ял итүен сөйләп барды.

Дим буена төштек. Матур бер җирдән урын сайлап, кармакларны рәтләп салдык. Брезент алып төшкән идек, ул миңа шалаш сыман нәрсә ясап ут ягарга һәм чәй кайнатырга кушты. Моннан элек төшкән вакытында агымрак җиргә ике метр чамасы суның эченә сирәк кенә читән үргән икән һәм читәннең югары ягына кормушка салды, солыны кайнатып, шуна арыш көрпәсенә бутап, сирәк кенә үргән капчыкка салып алып чыккан иде.

Ул шуларны рәтләде. Мин чәй кайнаттым. Кормушка ике сәгать чамасы торды. Әле кармаклар рәтләп кенә куелган. Без сөйләшә-сөйләшә чәй эчәргә тотындык... Ул миңа Тукай белән очрашуы турында сөйләде. (...)

Шактый ук вакыт үтеп китте. Изүләрен чишеп, яланаяк, үзен шундый иркендә хис итеп, Дим буенда ял итүне Мәҗит абзый әллә нигә дә алмаштырмыйдыр иде инде.

Балыкларның чиртмәве, ара-тирә чиртеп тә селәүчәнне ашап китүләренә дә аның бер дә кәефе китми:

— Әһә, монда рәт булыр, ахыры, чиртә башлады. Бер чиртсә, китә торган иде, котелукка су тутырып утка куй да бәрәңгене әрчи башла,— дип сөйләнә-сөйләнә, кармагына селәүчәнен кидерә. Әгәр яхшырак чиртсә, һөҗүмгә омтылырга торган мәче кыяфәтенә керә, ул аны шундый дәрт, шундый күтәренкелек белән тартып чыгарса, баш бармак зурлыгында юрш булып чыга. Аңарга ди исе китми, шуңа да риза ул. Яр астыннан:

— Бер калҗа ит булды! — дип кычкыра.

Ара-тирә дәүрәкләре эләгеп куйса, бетте инде: ул өзми дә, куймый да, кармак белән балык тотуның техникасын суганлап-борычлап сөйләргә тотына. Нәтиҗәдә, үзе оста

балыкчы булып чыга. Шулай азаплана торгач, кояш баеганчы ярты кадак чамасы вак балыклар тотып, уха пешереп ашадык. Ләкин иртә белән мин йокыдан торганчы, шактый ук тоткан иде. Анда инде мактанырлыгы да булды. Саный киткәч, туйганчы кыздырып ашарлык бар иде.

### *III*

Мәҗит абзый өендә дә тик тора торган кеше түгел иде. Өй эшендә иптәшенә булышып мәш килеп йөри торган иде. Аның өендә һәрбер нәрсә үз урынында тора. Андыймондый тәртипсезрәк бер нәрсә күрсә, ул аны хәзер барып төзәтә иде:

– Өйдә тәртипсезлек күрсәм, иҗат эшемә зарар итә. Күңел белән эшли алмыйм. Бөтен нәрсә урынында булып, күңел тынычланмый торып, кулыма каләм дә тота алмыйм,– дип куя торган иде.

Гаиләсе дә аның шул гадәтенә өйрәнеп беткән. Язган вакытында уена комачауларлык бер нәрсә дә эшләнми. Ул гына да түгел, иҗтимагый тормышта булган кимчелек-җитешсезлекләр дә аның каләм хезмәтен тоткарлап торалар иде. Хәтта кооперативта берәүнең акча туздыруын, яисә башка төрле хыянәтен ишетсә:

– Үзенә-үзе аяк чала, үз тормышын үзе харап итә, совет җәмәгатьчелегенә кара яга бит,– дип борчыла, аның өчен яна, ниһаять, эшли алмаслык хәлгә килеп җитә иде. Кыскасы, совет җәмәгатьчелеге тормышында һәм үзенең семья тормышындагы начар хәл аның каләмен начар хәлгә китерә иде. Әгәр инде тынычлыкны күрсә – ул өстәл яныннан кузгалып китә алмыйча яза иде.

Моны түбәндәге бер факт белән дә ачыклап була. Мәсәлән, 1930 елны аңарда шундый бер кичереш булды.

Мәҗит абзый, елдагыча, Дим буендагы Кара-Якуп дигән авылга кымызга бар. Ул анда барып урнашканда, нәкъ урак өсте була. Бервакытны биш-алты көн генә тора да, ялын ташлап, кире Уфага кайта.

Мин шул вакытны Казаннан Уфа аркылы Новосибиргә кайтып бара идем. Бер-ике көнгә Уфага туктадым.

– Мәҗит абзый кымызда,– диделәр. Ләкин кайсы авылда икәнен ачык белмәделәр.

Мин, аның янына барып килергә уйлап, ачык адресын күршеләре белә торгандыр әле дип, өенә киттем. Барсам, Мәҗит абзый өендә кайчы белән самасатка тәмәке ваклап утыра.

– Бу ни хәл, Мәҗит абзый, сине кымызда дигәннәр иде ич! – дип күрештем.

– Минем гадәтне беләсең ич инде, ял итә алмыйча кайттым,– диде.

Сәбәпләрен сорашканнан соң, ул миңа шулай дип сөйләде:

– Аерым хуҗалыклар арыш урагын бетереп киләләр. Ә колхозның шулай ята. Иртән һәм кичке салкында гына урмасаң, коела. Шулай була торып та хатын-кызлар уракка чыкмыйлар. Чөнки өсләренә кияргә күлмәкләре юк. Кооператив кешеләре эчеп йөриләр. Колхозчыларны бер нәрсә белән дә тәэмин итмәгәннәр. Шул хәлне ничек карап торасың да, ничек инде тынычлап ял итәсең. Беләсең ич, андый хәлне күрсәм, эшли дә алмыйм, ял да итә алмыйм. Бүген шуның артыннан йөреп аякларым калмады. Ләкин эзенә төштем. Шул авылга җибәрелгән мануфактур хыянәткә очраган. Ә анда совет хөкүмәтенә үпкәләп яталар,– дип, үзенең ял итә алмый ташлап кайту тарихын сөйләп алды.

Шулай ук тартырга тәмәкесе бетсә дә эшли алмый иде. Әгәр дә кичкә тынычлап керсә, ул төн буена рәхәтләнеп яза һәм берәр язган нәрсәсен укып, тынычлап-иркенләп эшләвен сөйләп ала торган иде.

Ул үзе гаять простой, гаять түбәнчелекле, сабыр табигатьле кеше булса да, әнә шундый кимчелекләрне күрсә, борчылып, сәбәбенә керешә, аны төзәтергә чаралар эзли башлый иде. Аның белән булган әңгәмәнең эшлекле-де-

ловой характерга әйләнүе дә, бәлки, аның шундый табигатьле булуыннан килгәндер.

### *IV*

1925 елны Мәҗит абзыйның юлга чыгуыннан телеграм алынды. Аның килеп җитү көнен чамалап, каршы алырга машина белән төштек. Шуның өчен ул нишләргә дә белмәде.

– Әй егетләр, әллә ниләрне искә төшердегез әле бу каршы алуыгыз белән. Иске вакыттагы кадерсез булып яшәүләр искә төшеп, әрнеп куйдым,– дип сөйләнеп алды.

Мәҗит абзый килү хөрмәтенә ясалган мәҗлестә Г. Ибраһимов та булды. Ул вакытта әле урамнар чокырлы-чакырлы иде. Мәҗлестә шул мәсьәләне күтәреп:

– Казанның бер генә җимерек урынын да күрәсем килми. Нигә шуны шәһәр советы алдында күтәрмисез. Телегез булмаса, кулыгызда каләмегез бар,– дип, Галимҗанга терәп әйтте.

Бу сүз Галимҗанга бер дә ошамады.

– Хөкүмәт эшенә асраулар да катнашырга тиеш, дигән сүзне кем әйткәнне нигә хәтерегездән чыгарасыз,– дип, Галимҗанны бик каты орышып та алган иде.

Ул бу килүендә озак тормады. Әсәрләрен бастыру эше белән килгән иде. Һәм хөкүмәт, һәм язучылар аны җылы каршы алып, кунак итеп озаткач, ул миңа түбәндәге хатны язды:

«Кәрим туган!

Мин сезнең яннан аерылгач, пароходка утырып, акрынлап, Волга буйлап түбән төшеп киттем. Якын күргән иптәшләрдән аерылып китү күңелсезлегеннән бүтән күңелсезлек юк иде. Мин тик шул яктан гына ятим идем. Каютада ялгыз калгач, Казанны тагын да күңелдән уйлап чыктым. Шуннан соң Казанның яхшы тәэсир калдыргапын белдем. Тормышның җил-давылы була, шуның кебек минем Казандагы 11 көнлек хәятымда аз-маз җил-давылга очрау булгандыр, ләкин алар аның кояшлы көннәренең

матурлыгы астында югалганнар. Казанның мине аз гына көннәр булса да ачык йөз белән каршы алып, җылы кочагында асравына рәхмәт әйтми булмый. Кеше, артык якын күргән иптәшләре арасында һәм артык шатлык вакытында, вак-төяк «әдәп», «гореф-гадәтләр» ригая итүне оныта яки артык нәзакәтләнергә лазем тапмый. Мин дә Казанда үземне шулай хис иттем. Аз гына вакыт эчендәге матур шатлык мине язгы чәчәкләр арасында иркен йөргән бер кош кебек булып йөрергә мәҗбүр итте. Уфада мин менә хәзер шуларны уйлап, тыныч кына эшкә керештем. Асылда мин бит һәрвакыт шулай шат йөри алмыйм. Казан мине шулай артык шатландырган иде. Монда «кызыл шәрыкъләр» дә юк. Булса да, бик сирәк була.

Безнең Уфа хәяты – кешегә тынычлык, икенче төрле әйткәндә, рухны йоклата торган хәят. Шулай да әлегә минем өчен Уфа тормышы мәслихәт.

«Кызыл Татарстан»дагы Тагорга ияреп язган «Ленин юлыннан»ны бик яратып укыдым. Матур булып чыккан.

Уртак иптәшләргә сәлам әйт. Галиәсгар абзый, Кутуйларны калдырма!

Вакытың булса, хат яз. Минем адрес: Гоголь урамы, 24 нче номерлы йорт.

Саулык теләп: Мәҗит.

1925–9–25».

### *V*

Мәҗит абзый белән тагын да 1926 елны Уфада очраштык. Мәҗит абзый зур энтузиазм, көчле дәрт белән эшли иде.

Бу вакытта Уфада сабантуй иде. Икәүләп сабан туена киттек. Юлда барганда:

– Тукта әле, Кәрим, сабан туеның беренче шартын онытып җибәргәнбез ләбаса без,– дип, бер кечерәк кибеткә кереп китте дә, озак та тормый, бер пакет вак чикләвек алып чыкты. Үзе сөйләнә-сөйләнә чыга:

– Сабан туенда да сатарга тиешләр, анысыннан авыз итү – әлбәттә инде, барганда чиртеп барсаң, сабан туена баруны үзе үк күрсәтеп тора ул, – ди.

Эрбет чикләвеген чиртә-чиртә сөйләшеп бара торгач, сабан туена җиткәнне сизми дә калдык.

Сабантуй башланмаган иде әле. Ләкин тирә-як авыллардан килгән авыл егетләренең гармунга биюләре Мәҗит абзыйны үзенә тартты. Һич шул тирәдән аерып алып китеп булмый.

– Менә бит аның гармун уйнавы гына ни тора. Кыйланып уйнавына мең сум бирерсең бит. Әйтерсең дөньяда ул гына, – ди. Ә үзе тирә-якта йөгергәләп йөргән малайларга чикләвек өләшә...

– Үтте бит, Кәрим туган, гомерләр, – ди тагын. Ул яраткан иптәшләренә, дусларына – якын итеп, яратып «туган» дип эндәшә иде. Авылның үзенә хас үзенчәлеге белән үтәлгән җыр, гармун һәм бию кебек нәрсәләрне ишетсә яисә күрсә, Мәҗит абзыйны аерып алып китү читен иде.

Без аның белән көн буе шулай ял итеп, күңел ачып йөри торгач, курайчы башкорт картына очрадык. Аны инде һич үзе яныннан җибәрмәде. Аны сыйлый-сыйлый курай уйнатты. Актыгында:

– Әйдә, бер генә мәртәбә булса да курайда бию көен уйнап, егетләрне, кызларны биет әле, – диде. Үзе картка күпмедер акча суза.

Күңелен тапкач, карт та киреләнми, Мәҗит абзыйның биргән бер заказын үти тора.

Бер вакыт:

– Атлар килә, атлар! – дигән тавыш күтәрелде. Курай да, биюләр дә онытылды.

– Әйдә, Кәрим туган. Минем иң яраткан номер килә! – дип, халык артыннан аксаклап йөгерә башлады.

Бер вакыт дулкынланып торган арыш арасыннан тузан күтәрелде. Ак төстәге бер ат, башкаларны ярты километр

чамасы ташлап, атылып очкан кош шикелле йомылып чаба...

— Әнә, күрәсеңме, Кәрим туган,— ди Мәҗит абзый, ә үзенең ике күзеннән яшь атылып чыккан...

Мәйданга атлар килеп кергәндә, Мәҗит абзый чын мәгънәсе белән җылый иде.

— Бу күз яшенең серен аңлыйсыңмы, Кәрим туган? Бу яшь — шундый ләззәтле, шундый тәмле күз яше бу! — ди. Чыдамады, халык арасыннан кысыла-төртелә эчкә кереп, алдан килгән атның муеныннан сөйде.

Кайтканда шул күз яшенең серен тагын да ачыкландыра төшеп:

— Хәтерләмим, элек алай түгел идем бугай. Хәзер үзебезнең дөнья бит. Үзебезнең уңыш. Уңышны күргән саен мин шатланып елыйм. Чөнки бу уңышның астында көрәш фронтларында корбан булган каһарманнарның каны ята. Әгәр дә тимер юлда поездның ажгырып килгәнен күрсәм дә шулай. Ике күземнән яшь атылып чыга, ә үзем: — Без йөртәбез бит моны,— дип горурланып куям,— ди. Өйгә кайтып җиткәнче шул темага сөйләп кайтты.

## *VI*

Икенче көнне Уфаның үзәк урамнарының берсеннән китеп барабыз. Бер зур гына гастрономия магазинына килеп җиттек. Зур тәрәзәсенең төбенә һәр төрле сорттан эчемлекләр тезеп куйганнар. Шуның турысына килеп җиткәч, тезелеп торган шешәләргә карап торды да:

— Кара әле, Кәрим туган, бигрәк матур тезелеп торалар бит, Мәҗит агай, бер-икене кереп ал инде, дигән шикелле торалар бит. Ничек кызыкмассың инде боларга,— дип сөйләнә-сөйләнә, магазинга ияртеп алып кереп китте.

Без ул кибеттән ике шешә коньяк алып чыктык та күршедәге фотографиягә кереп рәсемгә төшәргә булдык. Ике шешә коньякны кая куярга?

— Бер дә аптырама,— ди Мәҗит абзый. Ә үзе экран алдына рәттән утыртып маташа.

— Нигә, аларны да төшерәсеңмени? — дим.

— Төшми торсыннар әле. Төшәселәре килсә, безнең эчкә төшәрләр,— ди ул.

Ике шешәне артына куеп утырды. Мин аның янына идәнгә бер кулым белән таянып яттым.

Рәсемгә төштек тә өйгә кайтып киттек. Өйдә аш әзер иде.

Өстәл янына килгәч, Мәҗит абзый, сөйләнә-сөйләнә, шешәнең пробкасын ача.

— Бер вакытны Казанда Тукай белән сыраханәгә кереп утырдык. Бездән алда «Сөембикә» журналының редакторы Якуп Хәлили килеп керде дә бер шешә кара сыра алды. Шуны чемчекләп кенә эчкәч, аның теле бәйләнә башлады. Ул шуның белән кәефләнеп чыгып киткәч, Тукай аның артыннан карап:

— *Ниәт дөнья әкъвален минәм кәллили.*
*Кара сыра эчеп исерде Якуп Хәлили,*—

дип калган иде. Без бу коньяк белән, һәрхәлдә, Якуп Хәлили булмабыз әле,— ди, үзе кеткелдәп көлә.

Аштан соң күләгәгә чыгып яттык. Һаман сүз бетми, сөйләгән саен күбәя генә тора. Җитмәсә:

— Әсәреңне эшләр алдыннан, планыңны ничек эшлисең, Мәҗит абзый?— дип сорау да биреп өлгергән идем.

— Үз гомеремдә язма план эшләгәнем юк, Кәрим туган,— диде Мәҗит абзый. Ул сүзен дәвам итеп: — Теманы тапкач, аның эчтәлеген һәм планын башта гына эшлим, бер вакытта да кәгазьгә язганым юк. Язмас борын тулы итеп сөйләп чыгуы да авыр булмый.

Күңел тыныч, андый-мондый борчылу булмаса, төн минеке... Йокы да кача, рәхәтләнеп утырам. Кич белән язганга караганда, көндез авыррак эшлим. Күңел төрле якка йөгерә, чыгып кермәсәң, шәһәрдә әллә нәрсә бардыр, яңа хәбәрләр белән тулгандыр төсле була да уема зарар итә. Хәтта эшли алмаслык хәлгә дә килеп куям...

Мәҗит абзыйның иҗат юлы әнә шундый кызык иде. Ул күңелле вакыйгалар белән тулган, матур агымлы тормыш эчендә язарга яратты.

Аның җәмәгатьчелек тормышында да, гаилә тормышында да күңелле итеп эшлисе, күңелле итеп кенә торасы килә иде.

### *VII*

Мәҗит абзый белән актык мәртәбә очрашу 1930 ел җәен, шул ук Уфада булды.

Җәйге ялын ташлап кайту вакыйгасын яздым, бу вакыйга шул елны иде. Бу елны да шул ук күңелле Мәҗит абзый иде. Ләкин бу очрашуда исемдә калган нәрсә бары шул гына булды.

– Иске Себер тимер юлын язган идем. Инде яңа Себерне – Себернең яңа төзелешләрен, гигантларын күреп, шулар белән танышып, бер яңа нәрсә бирәсем килә – зур капитальный әсәр калдырасым килә,– дип сөйләп утырды.

Мин аңарга Новосибир һәм Кузбасс гигантларының төзелешен сөйләгәч:

– Әлбәттә барам, күрәм, танышам,– дип калган иде һәм сүзендә торды да. Шул ук елны көз Новосибирск шәһәренә барып чыккан. Тик хәбәрләшә алмау аркасында Себердә очраша алмадык. Мин командировкада калдым.

Соңыннан «Яңа авыл» газетасында Себер турында озын мәкаләләре басылып чыкты. Ләкин Советлар Себере турында әдәби әсәр тудыру теләге эшкә аштымы, юкмы – анысын белә алмадым.

*1941*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге.– 12 ф.– 3 тасв.– 23 эш*

# ХАТЛАР

## Кәрим Әмиригә

Кәрим туган!

Мин сезнең яннан аерылгач, пароходка утырып, акрынлап, Волга буйлап түбән төшеп киттем. Якын күргән иптәшләрдән аерылып китү күңелсезлегеннән бүтән күңелсезлек юк иде. Мин тик шул яктан гына ятим идем. Каютада ялгыз калгач, Казанны тагын да күңелдән уйлап чыктым. Шундан соң гына Казанның яхшы тәэсир калдырганны белдем. Тормышның җил-давылы була, шуның кебек, минем Казандагы унбер көнлек хәятемдә аз-маз җил-давылга очрау булгандыр, ләкин алар аның кояшлы көннәренең матурлыгы астында югалганнар. Казанның мине аз гына көннәр булса да, ачык йөз белән каршы алып, җылы кочагында асравына рәхмәт әйтми булмый. Кеше артык якын күргән иптәшләре арасында һәм артык шатлык вакытында вак-төяк әдәп, гореф-гадәтләргә ригая[1] итүне онытa яки артык нәзакәтләргә лөзүм[2] тапмый. Мин дә Казанда үземне шулай хис иттем. Аз гына вакыт эчендәге матур шатлык мине язгы чәчәкләр арасында иркен йөргән бер кош кебек булып йөрергә мәҗбүр итте. Уфада мин, менә хәзер шуларны уйлап, тыныч кына эшкә керештем. Асылда мин бит һәрвакыт шулай шат йөри алмыйм. Казан мине шулай артык шатландырган иде. Монда «кызыл шәрекъләр» дә юк. Булса да бик сирәк була.

Безнең Уфа хәяты – кешегә тынычлык, икенче төрле әйткәндә, рухани йоклата торган хәят. Шулай да әлегә минем өчен Уфа тормышы мәслихәт. «Кызыл Татарстан»-да Тагорга ияреп язган «Ленин юлыннан»ны бик яратып укыдым. Матур булып чыккан.

---

[1] Ригая – игътибар.

[2] Лөзүм – кирәк.

Уртак иптәшләргә сәлам әйт. Галиәсгар абзый һәм Тулумбай, Кутуйларны калдырма. Имашка хат язган идем. Сәляхи Кара бармакка (...) нәрсә белән хат җибәргән идем. Калганын иртәгә җибәрәм. Муафикъ[1] күргән урыннарын, ихтимал, «Кызыл Татарстан»да басарлар.

Уфадагы танышларың исәннәр. Даут Юлтыйга хатыңны бирдем. Гаиләңә сәлам. Вакытың булса, хат яз. Минем адрес: Гоголь урамы, 24 нче номерлы йорт.

Саулык теләп: Мәҗит.

*25.09.1925, Уфа*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 2 тасв., 14 эш*

[1] Муафикъ – риза, ризалык.

## Хәбибрахман Зәбиригә[1]

Зәбири туган!

Сиңа бик сагынып сәлам. Шулай ук Мәрьям ханымга, Фатыймага сәлам әйтерсең.

Үзем бер көенчә исән-сау гына яшим. Зөһрә һәм Халит тә исән-саулар. Сезгә сәлам әйтәләр. Сиңа күптән бирле хат язарга ният булса да, туры адресыңны белмәгәнлегемнән хат яза алмый утырдым. Борынгы танышлар белән хат язышып, исән-саулыкны белдерешеп торасы килә.

Үзем өйдә генә торып, барына канәгать итеп, кәеф ару чакта язу-сызу белән мәшгуль булып вакыт үткәрәм. Уфа сиңа мәгълүм бит. Монда чыгып йөрергә рәтле урын да юк. Шуның өчен һәрвакыт дип әйтергә өйдә торырга туры килә. Тик җәйнең матур һәм сандугачлар сайраган вакытларында гына берәр айга авылга барып торып кайтудан бүтән эш юк. Аның соңында яшь тә байтакка җитеп, битләр җыерчыкланып, чәчләр агару арта бара. Шуларның рухка тәэсире дә булмый калмый инде, әлбәттә. Табигать үзенең теләгәнен әйтми калмый икән ул. «Картларны яшәртү» дигән эше булмаса да, ул безгә туры килмәс инде. Андый соңгы яшьлектән файда да булмас. Соңра ул эш артыннан йөрмимче, вә шунысы да монда юк ичмаса.

Шулай, сиңа картлыктан шикаять итеп киттем бугай. Үткән гомерләр искә төшкәч, шулай язасы килеп китте.

Үзең ни эшләр бетерәсең? Хәзер мин синең кайда эшләвеңне дә белмим. Тик шул матбугат тирәсендәдер дип уйлыйм. Казан матбугаты тирәсендә нинди яңалыклар бар? Иренми генә хат язсаң, шулар хакында хәбәр итәрсең әле.

---

[1] Хәбибрахман Габделвәли улы Зәбири (1881–1942) – күренекле татар мәгърифәтчесе, журналист, дәреслекләр авторы.

Казанга барып кайту ниятендә булсам да, бу җәй, белмим, барып булмас ахыры. Һаман шул акча ягы инде. Зөһрәнең дә Казанга барасы килсә дә, «менә быел булмаса, киләсе ел барырбыз» дигән сүзләр белән җуатып киләм.

Борынгы уртак иптәшләргә сәлам әйт. Әгәр дә туры килеп, борынгыча очраша торган булсагыз.

Бу хатны Гариф абзый артыннан җибәрдем. Ул йомыш белән бара бугай. Урамда гына очрап, шулай аңлатты. Мин дә аның баруын форсат белеп, шушы хатны яздым. Үзеңнән хат көтәм...

Мәҗит Гафури. 20 нче апрель.

Адрес: Уфа, Гоголь урамы, йорт номеры 24.

*(Бу хат 1923 нче елда язылган булса кирәк. Х. Зәбири)*[1].

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 2 тасв., 3 эш*

---

[1] Соңрак язып кушылган кушымта.

## Һади Такташның Мәҗит Гафурига язган хаты

Мәҗит абый!

Хөрмәт йөзеннән сиңа Такташ хат яза!

Казанга килеп киткәнеңдә бәхетсезлек безне очратмады. Күрәсе килгән иде, Мәҗит ага, сине, күрешербез әле. Сезнең Уфа якларына әле тормыш сукмакларым алып чыкканы юк. Чыгармын (әле).

Хатымны ташлар кебек башлыйм.

Исәнме? Соңгы вакытларда матбугатта сирәк күренә башладың. Мин синең имзаны газета битләреннән эзлим һаман.

Безнең Казан газета-журналлары сезнең шигырьләрне көтәләр.

«Авыл яшьләре» журналында эшләвем сәбәпле, мин сезгә аерым рәвештә бу нәрсәне әйтәм. Авыл яшьләренә әйтәсе сүзләрегез күптер, Мәҗит ага, җибәрерсез дип ышанам.

Безнең Казан үз күчәрендә, яшисе кешеләр яшиләр. Мин әле яңа гына авылдан кайттым. Пенза авылларына өч айга командировать ителгән идем. Авыллар кызык, пролетариатлаша, крәстиян җегетләренең күбесе заводларга агылалар. Комсомоллар үсә. Адымнар җитез.

Синнән җавап көтәм.

Сөйләшәсе уртак сүзләр булырга тиеш безнең арада.

Мин шулай уйлыйм. Хуш.

Һ. Такташ

*10 август, 26 ел, Казан*

*Такташ Һ. Әсәрләр: 3 томда: 3 т: драматургия, биографик материаллар, хатлар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.– 228 б.*

## Һади Такташка

Такташ туган!

Сиңа сагынып сәлам. Шулай ук иптәшең белән кечкенә балаңа да. Үзем Казаннан Иж санаториясенә, аннан авылга кымызга барган булып, тагын Уфага кайтып тора башладым.

Мин сиңа «Ачлык тырнагында» дигән нәрсәмне җибәрермен дигән идем бугай.

Шушы сәлам хаты мөнәсәбәте белән шуны да җибәрәм.

Уфада артык язар нәрсә юк. Кирәксенсәң, Ченәкәй сөйләр әле. Сораган иптәшләргә сәлам диген. Мин аларны һәм Казанны сагынам. Әллә бу сирәк барып киткән өчендер дә...

Вакыт тапсаң, хат язгалап ташла.

Адрес: Гоголь урамы, 24 нче номерлы йорт.

Хөрмәт белән Мәҗит Гафури.

*31 август, 27 ел, Уфа*

*Такташ Һ. Әсәрләр: 3 томда: 3 т: драматургия, биографик материаллар, хатлар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.–287 б.*

## Зариф Бәширинең[1] шигырь белән язган хаты

### Авыр көннәр хатирәсе

*(Мәсләк дустым[2] Мәҗит Гафурига)*

Әй авыр соң безнең үткән көннәр,
Авырлыгы күбрәк көннәрдән,
Авыр көннәр биргән җилкәләрне
Өстерәп килдек баткан юллардан!

Тәмле сүзләр, ямьле караш белән
Сыйпалганмы безнең йөрәкләр?
Ишеткән тик безнең ут колаклар:
Әй, сәнәктән булган көрәкләр!

Шулай!
Сәнәк идек, гөлләр төреп өйдек,
Гөл ис чәчеп, чүпләр янган учакка
Гомеребезне китереп терәдек!

Әйдә, кагыйм бөкре җилкәңне мин,
Сөйим җанлы-тере тарихны,
Нигә үптең кайнар дуслык белән,
Сиңа иш ул – Сукыр Зарифны!

Макташу да, күңел таплашу да
Булмады ул бездә, булмас та!
Шуңа шат мин: ачык юл өстендә
Иренем тиде синең кулбашка.

---

[1] Зариф Шәрәфетдин улы Бәшири (1888–1962) – татар шагыйре, язучы, тәрҗемәче, публицист һәм этнограф.

[2] Мәсләк дустым – фикердәшем.

Авыр көннәр бирде бөкре җилкә,
Ләкин күз яшемне һичбер сыкмады
Бүгенгедәй шатлык белән, ләкин
Тамчы яшем чәчрәп чыкмады!

Әйдә, ташлыйк мактап җырлашуны,
Өч-биш еллыкларга, өч-бишкә!
Шушы көнне күрү җитә безгә,
Авыр көннәр тарткан дус-ишкә!

Әй авыр соң безнең үткән көннәр,
Ачлык, кимсетүләр чорналган,
Шул көннәрнең ләкин фахирәсе[1] бар:
Ил яңгыраткан җырлар – җырланган!

Сагынам ләкин үткән көннәремне,
Анда тәҗрибәләр тапкан җилкәгә,
Тарих җелеген сөрер яшьләр, шунда
Бүген булмаса да, иртәгә!

*Зариф Бәшири*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 2 тасв., 9 эш*

[1] Фахирә – горурлык.

# Мәҗит Гафуриның егерме еллык иҗат юбилеена бәйле материаллар

## Г. Ибраһимовның котлау хаты

Мәҗит агай!

Синең бәйрәмең булачагын ишетеп бик шатландым. Син икенче дәвер татар әдәбиятының бүген исән булган шагыйрьләренең иң карты, иң күп эшләгәне һәм мәсләге буенча тарихның әмәлләренә килеп ирешкәне булганга, пролетариат революциясе вакытында һәрбер эшче-крестьян баласы синең юбилееңа чын күңелдән катнашачак.

Егерме еллык туктаусыз әдәби хезмәт – бу үзе генә дә бик зур бер бәхеттер. Ләкин синең бәхетең – халыкка хезмәт юлында чиккән газапларыңнан туган бәхетең. Бу хезмәтләреңнең эчке мәгънәсе, мөндәриҗәсе белән тагы да тирәнәя, тарихи кыйммәт ала.

Син, хәзерге әдәбиятыбызның олыгайган буыннарының башкалары кебек, кадим, дин, схоластика эчендә тудың, яшь гомереңне шуның эчендә үткәрдең. Соңра мөтәрәккъкый буржуазиянең милләтчелек, яңа динчелек баскычын үтеп чыктың. Каты реакция, империализм сугышлары синең фикер күзең алдында яңа дөньялар, яңа мәгънәләр ачты, шуңа күрә февраль революциясен син зиһене, акылы, йөрәге милли буржуазия әмәлләре эчендә туңып каткан бәндәләр белән түгел, бәлки эшче-крестьян сафында каршы алдың, пролетариатның кызыл байрагын җырлап, сыйнфый сугышта безнең гаммә ягында булдың.

Февраль вакытында «кызыл» күренгән, «революционер» күренгән күп бәңдәләр, Октябрьның, канлы гражданлык сугышларының, авыр террорларның рәхимсез көннәрендә пролетариатны ташлап, капитал ягына чыктылар. Син бу хурлыкка төшмәдең, үзеңнең үсүеңдә дәвам

иттең: үзеңнең йомшак күңелле булуыңа карамастан, канлы көрәш вакытларында һаман революция ягында калдың.

Татар әдәбияты тарихында син менә шул бер-бер артлы килгән фикри-әдәби-иҗтимагый зур үзгәрешләрдә башкалар кебек бер баскычта туктап калмадың, һаман үсә бардың, һаман алга бардың, шуңа күрә син, шәхси хәятыңның гадәттән тыш авырлыгына карамастан, үзеңне бәхетле санарга тиешлесең.

Феодализм хәрабәләре эчендә тәрбияләнеп тә, төрле баскычларны үтә-үтә, туктаусыз үсә-үсә, коммунист пролетариат сафына килеп ирешү – актык көчне шул көрәшче пролетариат белән бер сафтан торып, инсаният дөньясының олуг әмәлләре өчен сарыф кылу – бу һәркемгә насыйп була торган бәхет имәс.

20 еллык әдәби хезмәтең белән, бу хезмәтнең әнә шундый олуг әмәлгә юнәлгән булуы белән ихлас күңелдән тәбрик итәм.

Галимҗан Ибраһимов.

Казан матбугатында мәкалә язачакмын. Уфага башка нәрсә бирә алмадым. Газыймга, Мусага, Давытка, башкаларга сәлам сөйлә. Аларга әйт: минем бу мәктүбемне синең юбилей көнендә газетада чыгарсыннар.

*Г.И. 1923 ел, 16 май*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 2 тасв., 10 эш*

## Ф. Әмирханның котлау хаты

Мәҗит иптәш!

Сезгә сәламнәрем!

Мин авырып урын өстендә ятам. Шуңар күрә Сезнең әдәби хезмәтегезгә егерме ел тулу вакыйгасын, әле бары кичәге көн, 5 июньдә, ягъни юбилей көненнән ике тәүлек соң ишетеп белдем. Менә инде бер ай газеталар кулыма ала алмыйм, бөтен дөнья әхваленнән гафил ятам. Бүген бераз кәефем яхшырудан истифадә итеп, «Көч булса да, һәч улмас» дигән төрек мәкаленә буйсынып, Сезгә шушы мәктүпне язарга утырдым. Башым аз эшли, мәктүп буталчык һәм кытыршы булыр. Ләкин зарар юк, мин бары, бу мәктүп белән Сезгә үземнең сәлам һәм тәбригемне юллап, егерме еллык әдәби хезмәтегезне тәкъдир итүчеләрнең берсе икәнемне генә язып калырга телим.

Егерме ел диегез! Безнең кыска гомерле, 35–40 та үлеп бетә торган буын өчен аз гомер түгел.

Мин әле хәтерлим Сезнең мәдрәсәи «Мөхәммәдия»дә әүвәлге шигырьләрегезнең нинди сөелеп укылганлыгын. Үткән гомергә әйләнеп карасаң, күз ачып йому шикелле. Шул әүвәлге шигырьләрегезнең укылуына егерме ел да үтеп киткән. Ә бит инде:

«Ак, кара катыш чуар бернәрсәгә әйләнде баш!» Ие, чуар бернәрсәгә әйләнде инде. Әле күптәнме соң ул башлар Сезнеке кап-кара, минеке коп-коңгыр иде!

Сез соңгы елларда шактый нәрсә язып өлгердегез – бу шагыйрь өчен зур бәхет, менә мин һаман әле гомеремнең шул дәверенә килеп чыга алмыйм. Бары соңгы елларда гына үземнең «амплуамны» табып алдым, соңгы елларның соңгы көннәрендә генә чын-чынлап яза башлау дәверемне башлап китәм бугай, ә бит минем дә яза башлавыма

унҗиде ел тулып киткән икән инде. Бүген уйлап чыгардым әле аны.

Менә мин хәзер инде арыдым да; мин плеврит белән авырыйм, хәзер инде терелеп киләм. Миңа, терелеп җитү белән, кымыз эчәргә барырга туры килә. Шуңар күрә мин 18–20 майда (?) Уфага барып чыгып, анда кымыз эчү мәсьәләсен караячакмын. Өмет итәм, Уфага баргач, анда Сезне күрермен, һәм шул вакытта Сезнең белән озак бер мосахәбә итәрбез.

Хәзергә яңадан бер кат Сезне әдәби хезмәтегезнең егерме еллык бәйрәме белән тәбрик итеп, яңадан озак елларга шул хезмәтегезнең дәвам итүен теләп калам.

Сәлам һәм хөрмәт белән Фатих Зариф угылы Әмирхан (Фатих Әмирхан).

*Казан. 1923 ел, 6 июль*

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 2 тасв., 8 эш*

*Сәйфи Кудаш*

## Алтын сәгать

Авылда Гафуриның егерме еллык әдәби эшенә багышлап әзерләнгән кичәне ике көн алдан үткәрдем дә тизрәк Уфага китәргә ашыктым.

Мәҗит Гафуриның Уфада РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты һәм Халык Комиссарлары Советының карары белән үткәрелә торган юбилее татар һәм башкорт халыкларының культура тормышларында беренче вакыйга иде.

Халык шагыйре Тукайның «Йолдыз» газетасында язуына караганда, 1910 елда «Сәйяр» труппасы артистлары драматург Галиәсгар Камалның ун еллык юбилеен билгеләп үткәннәр. Ләкин урындагы власть органнары бу тантананы үткәрергә рөхсәт бирмәгәннәр. Галиәсгар Камалның юбилее вакыйгасы халыкның күпчелегенә алдан билгеле булмый. Бу хакта театрга якын торган тар даирә кешеләре генә беләләр. Шул сәбәпле ул көнне театрга җыелган кешеләр чираттагы гади спектакльне карау өчен генә килгән булалар. Бары тик азактан театр коллективы һәм «Мәгариф» издательствосы тарафыннан Галиәсгар Камалга котлау адресы тапшырылгач кына, бу спектакльнең юбилей постановкасы икәнлеге аңлашыла.

Хәзер эшләр бөтенләй башкача тора. Бүген Гафуриның юбилеен бер төркем артистлар гына түгел, бәлки ил белән җитәкчелек иткән большевиклар партиясе һәм совет хөкүмәте үзләре оештыра. Димәк, аңа бөтен совет халкы катнаша. Менә шуның өчен дә без бу юбилейны сабырсызлык белән көтеп алдык.

Юбилей тантанасы булачак көнне көтеп, «Комклуб» бинасы алдыннан берничә тапкыр үттем. Октябрь революциясенә кадәр бу бина дворяннар клубы булып хезмәт итте. Аны кешеләр гади сөйләшү телендә «Дворянское собрание» дип кенә йөртәләр иде. Хәзер бу клуб хезмәт халкы-

ның уртак милке булып санала. Элек без аңа нәфрәтле күз белән карап үтә идек: анда керү безгә рөхсәт ителми иде. Хәзер без бу бинага үз өебезгә кергән кебек кыю атлап килеп керәбез. Башкорт һәм татар совет әдәбиятларына нигез салучыларның берсе, сөекле Мәҗит Гафуриның егерме еллык бәйрәм җыелышы бүген менә шушы бинада булачак.

Кичке сәгать алтыга клуб залы халык белән шыгрым тулган иде инде. Менә бервакыт клуб алдына җиңел автомашина килеп туктады. Машина эченнән Мәҗит Гафури килеп чыгу белән оркестр шатлыклы марш уйнап җибәрде. Гафури, машинадан төшеп, берничә адым атларга өлгермәде, аны бала кебек итеп күтәреп алдылар да икенче этажга алып менеп киттеләр. Музыка, көчле алкыш күкрәве астында Гафури сәхнәгә күтәрелде.

Сәхнәгә чыгып баскач, ул, алкышларга игътибар итмәскә һәм бирешмәскә тырышкан кебек, тыныч торды. Аннары өзлексез дәвам иткән алкыштан кыенсына башлады. Кемдер аңа утыргыч тәкъдим итте. Ул, ни эшләргә белмичә, кесәсеннән яулык алды да маңгаен сөртергә тотынды.

Гафуриның тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладтан соң, Башкортстан хөкүмәтенең Гафурига «халык шагыйре» дигән почётлы исем бирү турындагы карары игълан ителде. Советлар республикасының ерак һәм якын почмакларыннан килгән бик күп котлаулар укылды. Адреслар тәкъдим ителде. Бүләкләр тапшырылды.

Бүләкләр арасында күп кенә кыйммәтле әйберләр бар иде. Барыннан да бигрәк чылбырлы зур алтын сәгать кешеләрнең игътибарын үзенә тартты.

Ләкин Гафури бу сәгатьне кулына алмады. Тантаналы утырыш соңында, аның Уфа нэпманнары тарафыннан бирелүе билгеле булуы белән, шунда ук сәгатьне тәрбиячесез калган ятим балаларга Ярдәм комиссиясенең председателенә бирдерде. Иртәгесен бу турыда Башкортстан газетасы редакциясенә ачык хат язып тапшырды.

*Кудаш С. Хәтердә калган минутлар. Истәлекләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.– 286*

*Гыйбад Алпаров*[1]

## Мәҗит абзый кем?

Мәҗит абзый – ярлы ил шагыйре. Ул – явыз урыс хөкүмәте тарафыннан мәрхәмәтсез рәвештә изелгән, урыс колонизаторлары тарафыннан икътисади тапталган бер илдә туып, шунда алар белән бергә бөтен авырлыкларны, бөтен изелешләрне бергә татып яшәгән ил баласы.

Шуңа күрә ул беренче мәртәбә мәйданга чыккан көненнән башлап шул ярлы, изелгән илнең кайгыларын җырлаучы, аларның моңын көйләүче булып чыкты, шул юлында үзгәрмичә дәвам итте, әле дә шул башта алган эзе белән бара.

Ул кирәк тезмә, кирәк чәчмә шигырьләрендә булсын, башта ук ярлылар тормышын күреп, аларның моңын-зарын мәйданга чыгара башлады.

«Фәкыйрьлек белән үткән тереклек», «Ярлылар», «Үги балалар», «Ятимләр», тагын башкалар… Шулай булгач, аның авыл ярлысыннан килеп чыккан «Эшче»сенә гаҗәпләнү ярамый. Мәҗит абзый шул ярлылар өчен җылаган, шулар өчен әрнегән арада «Милләт мәхәббәте» белән «Милли шигырьләр» дип әйткән нәрсәләре булмаса да, бу гына аны милләтчеләр сафына кертә алмый. Чөнки ул вакыт башка: без ул чакта милли изелә идек, аның белән бергә сыйнфый да изелә идек. Ул шул изелүнең икәвен дә күрә, сизә иде.

Ул вакыт бөтен әфкяр вә гаммә[2] милли богаудан котылуны тели, өстләренә басып, канларын суырып торган урыс албастысыннан котылса, аның ярлылары иркенрәк тын алыр, сыйнфый изелүдән дә котылыныр кебек күренә иде.

Инде милли азатлык мәсьәләсе революциядән соң рәсми рәвештә хәл ителгәч, Мәҗит абзыйга ярлылар хакын-

---

[1] Гыйбад Хәбибулла улы Алпаров (1888–1936) – татар тел белеме галиме, орфография, морфология, синтаксис өлкәсенә караган хезмәтләр авторы.

[2] Гаммә – гомум.

дагы фикерен, ныклап, берәүдән дә курыкмыйча, шартлатып әйтүгә мөмкинлек туды.

Милли фикер элгәре югары, зыялый мохиттән алынган, читтән кереп аралашкан нәрсә сыманрак күренә. Ул башкалар белән шул дәверне уртак, кушылып алып бара. Ләкин ярлылар, фәкыйрьләр хакында язышы аның үзенә башка, махсус алып барган юлы иде.

Мәҗит абзыйның соңгы юлы ул вакыт мохит кушмаганга күрә генә, ачык, көчле булып җәелеп китә алмый иде. Ул элгәре дә шул ярлылар хәятен шагыйрьләргә генә хас булган ысулы, үзәкләргә үтә торган үткен каләме, һәрбер татар-башкорт ярлысы төшенерлек садә теле белән әйтте, әле дә шуны әйтә. Моннан ары да шуны әйтәчәк. Башкача булырга мөмкин түгел.

Мәҗит абзыйны бүген безнең юбилейлар ясап аның кыйммәтен күтәреп утырганыбызның хикмәте дә шунда, шул ноктадан карап. Аның теле, өслүбе[1] дә баштан ук садә, илнең үзе сөйли торган теле. Шуның өчен аны ярлы татар-башкорт халкы башта ук ялан тәпиле, ыштансыз малаеннан башлап байга эшләп биле бөкрәйгән картына кадәр аңлап үз итеп укый, аның белән бергә кушылып әрнешә башлады. Әле дә Мәҗит абзыйны халык шулай аңлап килә, ул да халыкны шулай күрә, шулай аларга җырлап бирә.

Шагыйрьлеге хакында шуны гына әйтим: Мәҗит абзый – кеше төшенми торган тирән фәлсәфәләр сатучы күк шагыйре түгел, ул җир, тормыш, мохит шагыйре. Ул үзенә мәузугны[2] чын, җанлы тормыштан, илнең хәятеннән чүпләп ала. Ул әлегә чаклы шул изге юлыннан аерылмый килде, моннан соң да шул юлында дәвам итүе катгый. Менә шуңа күрә, Мәҗит абзый, мин сине «ярлылар шагыйре» дип атыйсым килә. Ерактан синең юбилееңны котлап, сине сагынып:

Гыйбад Алпар, Ташкент.

*Алпаров Г. Мәҗит абзый кем? // Башкортостан. – 1923. – 3 июнь. – № 58*

[1] Өслүб – ысул, рәвеш, стиль.

[2] Мәузуг – тема.

*Гата Исхакый*

## Карт шагыйрь

Карт шагыйребез Мәҗит иптәш Гафури җанәбләренең язуга керешүе 1902 ел «Ишан шәкертләренә» дигән шигырь һәм «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек», «Себер тимер юлы» дигән әсәрләре белән, шулай ук 1903 ел «Тәрҗеман» бабайның 20 еллык юбилеена карап язган шигырьләре белән башланмыш иде.

Мәҗит иптәш шул көннән бирле бер машина кебек армас-талмастан эшләп килде. Әле һаман да эшләмәктә. Аның тоткан юлын карасак, шул вакыттан алып бу көнгә кадәр бер эз, бер юл – юклар хәлен ачып бирү, ничек генә булганда да ачларга ярдәмгә кул сузу – иптәш чакыру күрелә. Инде тагын шул ишан шәкертләренә революция (агитация) белән башлый, шуннан килеп «Суллардан да сул» «Эшче»сен яза да «вөҗданым миңа, Инҗил миңа, Коръән миңа...» ди.

Монда сүзне күп озынга сузып тормый әйткәндә, карт шагыйребез Мәҗит иптәш хәзерге көнгә кадәр 20–21 еллар бер юлда, бер уйда хезмәт итеп килгән һәм шул юлда һаман хезмәт итмәктә. Менә инде без – аның әсәрләрен укып файда күрүчеләр – адәмнең шул кадәр хезмәтенә каршы тәкъдир итү кирәк дип белсәк, Мәҗит иптәшнең 20 еллык шул зур эшен күрергә тиеш идек. Бүген ясалмакта булган Мәҗит ага юбилее татар-башкорт эшчән гаммәсенең бу хезмәтне тәкъдир итә алуын, өстебездәге мәгънәви бурычыбызны үти алуыбызны күрсәтәдер.

Тагы күп еллар эшен күрсәк иде дип, 20 еллык бәйрәме белән карт шагыйрьне тәбрик итәм.

*Исхакый Г. Карт шагыйребез // Башкортостан.– 1923.–3 июнь.– № 58*

*Муса Йосыпов*[1]

# Шагыйрь Мәҗит Гафури

Моннан егерме биш еллар элек Мәҗит абзый Гафури шигырь, назыйм вә әсәрләр яза башлый. Моннан нәкъ егерме ел элек беренче мәртәбә аның язганнары матбугат дөньясына чыга.

Менә шул көннән бирле Мәҗит Гафури шагыйрь һәм әдип булып саналып килә. Ул татар-башкорт халкының түбән, иң түбән катлавыннан чыгып, шул катлау белән берлектә алга тәгәрәде, югарыга үрмәләде.

Мәҗит абзый беренче дәверендә татар дөньясының милләтчелек украсы кабарып торган дәверенә туры килгәнлектән, ул милләтне зурлыкка, азатлыкка, башка милләтләр белән тиңлеккә өндәде. Сыйнфый аерымлыклар әсасында[2] көрәшкә чакыручыларга «зинһар, туганлар, шул гадәтне ташлыйк» диде.

Үзе шул ул вакыт «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек», «Себер тимер юлы», «Ачлык елда сатылган кыз» һәм «Ярлылар» дигән әсәрләрне яза. Менә болар Мәҗит аганың кем булып яшәгәнен, нәрсә әйтергә теләгәнен, кулына каләм алып әсәр, назыйм вә шигырьләр язуына нәрсә сәбәп булганны бик ачык күрсәтәләр.

Ул асылда әсәрләре белән чыннан-чын ярлылар әдибе булып күтәрелә. Алар тормышын тасвир итә. Ләкин ул чакта аңарда сыйнфый аң булмаганлыктан, ул аерылышмакка, аерылышу гадәтләрен ташларга киңәш бирә. Әгәр дә ул чынлап та милләт берлеген сакларга тырышучы, ягъни вак, эре сәүдә капиталының язучысы булса, ул

[1] Муса Габдрахман улы Йосыпов (1896–1937) – сәясәтче, журналист. Татар педагогия институты директоры (1933–1934), Татар дәүләт академия театры директоры (1934–1937).

[2] Әсас – нигез.

вакыт, ул «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек», «Ярлылар» һәм «Ачлык елда сатылган кыз»лары урынына, вак буржуа язучылары кебек, берәр байга сатылып, газета мөхәррире булыр иде.

Фатих Әмирхан һәм Гаязлар шулай булдылар бит. Яхуд шул вак Фатих Әмирхан, Гаязлар кебек «Хәят», «Ялгызлыкда очрашу», «Яшьләр», «Тормышмы бу?», «Мөгаллимә» кебек вак буржуа идеологиясен җанландырырга тырышу иде. Ләкин без моны Мәҗит абзыйда күрмибез. Аның «Милли шигырьләр» дигән мәҗмугасында да кара реакция дәверендә «кисәләр телеңне татар» дип, реакциягә каршы чыкканын күрәбез. Бу вакыт инде 1905 елдагы «кып-кызыл социалистлар» бар да яшелле-сарылы булып, милли байга һәм капиталга, шуның аша монархияга чукынганнар, шуннан китә-китә, монархия һәм капитал җимерелгәч, шуны торгызырга дип чыккан Колчакка тагылып илдән себерелделәр.

Кыскасы: Мәҗит абзый Гафуриның теле «Фәкыйрьлектә үткән тереклек» белән ачылып, «Кызыл байрак», «Эшче» һәм «Ачлык тырнагында» дигән саф сыйнфый, саф пролетарский әсәрләр бирүгә килеп җитте. Нигә? Чөнки Мәҗит ага үзе чыккан түбән катлау шул баскычка килеп менде. Шул гаммәнең[1] шагыйре Мәҗит ага алар эчендә кайнаганга, ул коллективның башындагы фикерләрне, йөрәкләрендә урнашкан тойгыларны ак кәгазьгә төшерде.

Ул Русиядә 1906 елларда реакция күтәрелгәч тә, милләтчеләрнең дөрест йөзләрен күрә алды. Аларның кайда барганлыгын аңлады. Ләкин боларны язарга аңа ирек юк иде. Шулай да ул дәшми тормады. Бик матур, бик нечкә сүзләр, мәгънәләр белән аларны аңлатты. Реакциягә каршы көрәште.

1913 елларда Русиядә тагы да эшчеләр хәрәкәте үсә башлаганда инде ул: «Кайда ярлы, кайда зарлы, кайда моңлы күп була, мин шулар янында булам, алар белән

[1] Гаммә, яисә гамь – гади халык массасы.

килешеп була», – ди. «Аларда да тәкәллеф[1], эч сере дигән нәрсәләр юк. Эшләре керле булса да, аларның эч кере юк», – ди. Һәм: «Аерса тәңре байларны фәкыйрьләрдән Кыямәтдә». (...)

1914 елларның сугышын ул каһәрләп каршы алды. Һәм аның нәрсә өчен барганын халыкка, ягъни үз халкы эшче-крестьянга аңлатырга тырышты. «Бөтен кодрәтеңне алган алтын-көмешкә багламас һәм көчледән көчсезне өздермәс идек». Шигырьләре моны бик ачык исбат итәләр.

Хәтта солдатларны сугышмаска чакыра. «Синең ул дошманың түгел. Син аны үтереп, дөньяда тыныч яши алмыйсың. Элек син үз иркеңә үзең хуҗа бул. Аннан дөнья иркен булыр», – ди. Йә моны кем әйтә алган? 1905 елның социалистлары әйтә алганмы? Моны лашманчы Гаяз әйтә алмады. Бәлки мескен илләрдән җыйналган ярлы сарт, казакъ, кыргызларга командир булып, аларны үгетләп, төче телләнеп, мылтык, туп ядрәләре астына алып кына барды. Шуның белән 1905 елгы гөнаһасын Николай каршында җуярга тырышды. Болар, Гаяз кебек лашманчылар, бик күб булдылар. Гыйсмәти кебек ахмаклары сугышка китүче мөселман солдатларына Һәфтияк һәм догалыклар итеб таратыб ятдылар. Кайберәүләре Фатыйх Кәрими, Һади кебек дистәләб милләтчеләр Николайга сәдакать[2] күрсәтеб, сугышка ярдәм итү өчен мөселман комитетлары төзеб йөрделәр.

Мәҗит абзый сизгер йөрәкле эшче-крестьян шагыйре булган. Мәҗит абзый бу пычраклыкларга, бу ваклыкларга төшмәде. Төшмәде генә түгел, алардан нәфрәтләнде, чиркәнде. Дүрт күз белән көткән шагыйрьнең үз иркеңә үзең хуҗа булу вакыты – революция туды. Мәҗит абзый «Кызыл байрак» күтәреб бөтен дәрде һәм кувәте белән: «Кузгал, эшчеләр, дошман җиңелсен!» – диб каршылады. Шундан соң ачыкдан-ачык: «Бетсен сугыш диб кычкы-

[1] Тәкәллеф – көнкүрештә, эштә табигыйлектән үтеп, күрсәтү өчен көчләнеп эшләү; ясалмалык; кылану.

[2] Сәдакать – тугърылык.

рыйк!» – диде. «Әгәр дә бик кирәк булса, әнә үзләре барсыннар сугышка!» – диде Мәҗит абзый.

Менә шул фикер, шул иман белән Октябрьне каршылады. Ул «эшчеләрнең һәммәсе белән таш дивар[1] ватылды, бөтен дөньяга эшче үз кодрәтен күрсәтде» дип, бөтен вөҗүде белән рәхәтләнеп сөенеп, учын уа-уа Октябрьне мәдехли»[2].

Икенче көндә үк ул байларга отчёт кәгазе бирә. «Бүген хисаб бир. Бүген йәвемле[3] хисаб», – ди.

Үз тәгъбиренчә[4] революциягә каршы «аждаһалар» (контрреволюция) күтәрелгәч, Мәҗит абзый хөррият маршын чала. Набат кагыб, «аждаһаларга» каршы көрәшкә илне чакыра. Кызу гражданлар сугышы вакытында ул Кызыл гаскәргә, эшче-крестьянга рух орып тора. «Батыр эшче һәм Кызыл яуның кулын битеннән артык күреп үбеп, тәбрикли».

Илне ачлык фәлякәте[5] баса. «Аждаһалар» тагы да күтәрелергә уйлыйлар. Эшче-крестьян һәм Кызыл гаскәрне ачлыкдан саклау өчен, соңгы байлык – мәчет һәм чиркәүнең кыйммәтле нәрсәләре алына башлый. Муллаларның, попларның күбесе «аждаһалар» булыб каршы төшәләр. Безнең мөселман мөфтисе Риза казый белән Тихин, чиркәү һәм мәчет нәрсәләрен алу ярамый, дигән булып, ач илне һәм Советны хараб итү уе белән фәтвәләр чыгаралар. Мәҗит абзый шул вакыт: «Миллионлап эшче-крестьян кырылганда, кызганыч булсын, имеш, бәрхет паласы, алтын тәре!» – ди. Бу фронтта да көрәшкә ташлана.

Мәҗит абзый инде сыйнфый революция атлы көрәш сафында сәяси һәм икътисади теләкләр өчен генә көрәшеб, аларны кулга алыб бетү белән генә тукталыб калмады. Ул идеология фронтында да алга атлады. Ул бу фронтта

---

[1] Дивар – стена.

[2] Мәдехли – мактый.

[3] Йәвемле – көндәге; көндәлек; көнлек.

[4] Тәгъбир – күзаллау; аңлау.

[5] Фәлякәт – бәла; бәхетсезлек; кайгы.

да иске, пычрак һәм ялган сәхифәләрне, үзенә көчләнеп тагылганлыкны белеп, аларны ертып ташлап, яңаларны, үз иркенә үзе тәмам хуҗа булгач, эре итеп язып куйды: «Калган битләренә язып куйдым, «яңа иман», «яңа көч» сүзен. Бөтен инсанларга[1] нәҗат[2] биргән, «чын туганлык», «изге эш» сүзен», – дип.

Менә Мәҗит абзый элекке идеологияләрдән тәмам арчынып, яңа иман, яңа көч белән сөекле эшче-крестьянына хезмәт итәргә вәгъдә бирә. Димәк, шагыйрь, карт шагыйрь, татар-башкортларның хәзерге шагыйрьләренең атасы, әдәбият, матбугат дөньясының карт юлбашчыларыннан берсе Мәҗит абзый Гафури, моңарчы эшче-крестьян белән бергә үсеп, кайгысын, шатлыгын бергә уртаклашып килгән; хәзер дә килә, моннан соң да эшче-крестьяннан аерылмаска йөрәк каннарына манып язган шигырьләре белән ант итә.

Менә шуңарга күрә дә без аңар бүген 20 еллык эш бәйрәме ясыйбыз. Менә шуңарга күрә дә без аны бөек эшче-крестьян халкы шагыйре дибез. Менә шуңарга күрә дә без аны хезмәт каһарманы саныйбыз. Менә шуңарга күрә дә без аны һәм аның 20 еллык хезмәтен тәкъдир итә белгән һәм шундый карт үз шагыйре булган башкорт-татар юксылларын бәхетле дибез.

Сәлам сиңа, чал шагыйрь, егет йөрәкле, батыр ирекле, хөр табигатьле, сизгер шагыйрь! Яшә, бөек шагыйрь! 20 еллык бәйрәмең белән тәбрик итәбез. Һәм тагы да күп хезмәтләреңне көтәбез!

*Йосыпов М. Шагыйрь Мәҗит Гафури // Башкортостан.– 1923.– 3 июнь.– № 58*

[1] Инсанларга – кешеләргә.
[2] Нәҗат – котылу.

*Гыйлемдар Баймбәтов*[1]

# Мәҗит ага

## *I*

1907 елның ноябрь-декабре.

Бервакыт «Галия»дә югары тип түгәрәк оештырырга туры килде. Түгәрәк зур-зур шәкертләр арасында авторитетлы булсын өчен, зур шәкертләр арасыннан күренгән, алга чыккан кешеләрне өндәргә кирәк иде. Мәҗит аганы иң ышанычлы иптәш итеп күрсәттеләр.

Беркөнне кич бер иптәш белән Мәҗит агага киттек. Мәҗит ага Казарменный урамның толчоктан ерак түгел бер чатындагы кечкенә бер йортта бер иптәш белән тора икән. Күрдек, күрештек. Без кергәндә, Мәҗит ага, янындагы утыргычка аякларын бөкләп утырган көйгә, кәгазь калфаклы лампа яктысына табарак сузылып, кулларын да итәгенә җыеп, әллә нәрсә укый иде.

Мәҗит аганың иптәше безнең белән бик тәкеллефләнеп[2], назланып күреште. Мәҗит ага бик гади генә, иренеп кенә, ялкау гына итеп кулын сузды. Миңа бу беренче күрештә Мәҗит ага: «Бу җегетләр нәрсә генә инде тынычлык бозып, болай кичкырын килеп йөриләр эш калдырып»,– дигән төсле күренде.

Бик аз сүзле. Сүз барганда ара-тирә сөальләр[3] генә кыстыргалап куя. Үзенә карый башласаң, бер дә озаклап туры карамый. Ул мине әллә нинди ярты юлда калган бер «школьник» дип уйлап куйды бугай.

---

[1] Гыйлемдар Солтан улы Баембәтов (1886–1933) – язучы, драматург, сәясәтче.

[2] Тәкәллеф – көнкүрештә, эштә табигыйлектән үтеп, күрсәтү өчен көчләнеп эшләү; ясалмалык; кылану.

[3] Сөальләр – сораулар.

Шулай да чәйгә кадәре көчләнә-көчләнәрәк сөйләшкәләдек. Мәҗит аганың шигырьләре хакында сораштык. Ул кайбер кулъязмаларын укыды. Чәйдән соң чыгып киткәндә басылган әсәрен дә биреп җибәрде бугай. «Яшь гомерем»ен түгел идеме икән?

Мәҗит ага гаять дәрәҗәдә үз-үзенә бикләнгән кеше күренде. Тик кайвакыт кына минем кайбер сүзләремнән йөзе ачылып, колаклары шомраеп китеп, боегыбрак, терсәге белән өстәлгә таянган көйгә маңгаен тотып, миңа таба озак-озак карап тыңлый да күзләрен читкә алып куя. Миңа ул аз сүз катты. «Бу инде фидаидер. Кызыллар кайда барырга, нәрсә эшләргә кушсалар, бу мескен җегет шунда бара торгандыр. Йөри әрәм булып, белер-белмәс көенчә...» дигән кебек бер мөнәсәбәттә булынудан бөтен утырышу буенча чыкмады.

Иптәшем бер гимназист иде. Мәҗит ага аңа бөтенләй башка мөнәсәбәттә күренде. Аның белән күбрәк сөйләште. Аның укуларын сорашды. «Французча беләсеңме, ул телне өйрәнү читендер...» – дип тә куйды. Кыскасы, Мәҗит ага иптәшемә, бәхетле икән бу, дип карагандай күренде. Миннән дә, үзеннән дә канәгать түгел кебек тоелды.

Чәйгә мүк җиләгеннән, арыш икмәгеннән башка нәрсә куелмады. Чәй мәсьәләсен дә ничектер Мәҗит аганың иптәшеме, әллә минме китереп чыгардым. Мәҗит ага үзе теләр-теләмәс эчергән кебек булды. «Әйдә, ник... үзебезнең дә кичке чәй эчәргә вакыт җиткән, сез дә берәрне эчәрсез», – дип, читкә караштырып гына өндәп куйды. Мәҗит ага – һичбер вакытта да үзе канәгатьләнмәгән, үз күңеленә килешмәгән бер нәрсә белән кешене канәгатьләндерергә яратмый торган бер кеше.

Без чәй янында байтак утырдык. Ләкин мин Мәҗит аганы түгәрәккә чакыру турында сүз башларга уңай таба алмадым. Сәгать кичке җиделәрдә барган кешеләр сәгать унларда күрешеп чыгып киттек. Ләкин Мәҗит аганың югарыда әйтелгән вакыйгаларга мөселман җәмәгатенең, олугъ хәзрәтләр партиясенә бүлгәләнеп дошманлашу-

ларына карашын белә алмадык. Чыгып китәр алдыннан гына үзебезнең эшләр тирәсенә сүзне бордым. Мәҗит ага «Галия»нең зур шәкертләре өчен безнең югары тип түгәрәк барын белә икән. Мин: «Сезне дә чакырабыз»,– дидем. Мәҗит ага «вакыт булса» дигән кебек итеп, вәгъдә биреп калды.

## *II*

1910 ел майның ахырлары иде. Илдархан Чанышев микән, кемдер инде Мәҗит аганың «Милләтем» дигән шигырь мәҗмугасы өчен төрмәдә утырып чыкканын сөйләде. Шул хәбәрдән соң мин Мәҗит аганы мотлакан[1] барып күрергә булдым. Берничә кат бардым, очрата алмадым, көтәргә булдым.

Мәҗит ага әллә нинди бер иптәше белән кайтты. Инде ул миңа тышкы хәрәкәтендә, кыяфәтендә күп үзгәргән, хәяткә[2] кергән төсле күренде. Үзенең һәрвакытдагы гадәтенчә сөйләмәде. Сорашкалап утырды. Хәтта әсәре өчен төрмәгә ябылып чыгарылу вакыйгасын да бик кыска аңлатты. Бу күрешүдә Мәҗит ага миндә тагы да яхшы хис калдырды. Ул ягымлырак, җылырак күренде.

Уфадан киткәнче берничә урында мин Мәҗит ага хакында сөйләштереп, сораштырып карадым. Уфа даирәләре аның турындагы сүзне «ык-мык» итеп бетерәләр иде. Уфаның Мәҗит агага андый мәзәк сөкетле[3] бер мөнәсәбәтен мин ул вакыт аңлый алмадым.

1913, 1914, 1915 елларда, 1916 ел башларында Мәҗит ага белән мин бик якыннан таныштым.

Байларны, голяманы , мирзаларны Мәҗит аганың пәрие сөйми иде. Мәҗит ага турылыкны, хакыйкатьне, чын кешелекне сөя торган бөек вә вөҗдан иясе. Кешедәге кечкенә бер фальшь, кечкенә бер ялган, җанның кечкенә бер

[1] Мотлакан – һичшиксез; абсолют рәвештә.

[2] Хәяткә – тормышка.

[3] Сөкет – дәшмәү; тынычлык; тынлык.

хиляф[1] борылышы Мәҗит агада ул кешегә кызганыч уята, яхуд[2] җан ачуы белән кайнап ташкан дошманлык хисен кузгата.

Мәҗит ага – бөтен табигате белән , хәяттән алган ачы тәҗрибәләре, күргән, белгән, өйрәнгәннәре белән дөньяның ул чактагы иҗтимагый төзелешенә каршы кеше. Аңа дөньяда чын кеше кирәк. Чын инсанният[3] җәмгыяте кирәк.

Менә шундый бер кешене сез мөселман җәмгыяте арасына кертеб, аның гомуми эшләрен «милләт, дин» тәрәккый[4] итдереш хәрәкәте тирәсенә кертеп куеп карагыз инде!

Мәҗит аганың бик күп мәшһүр мөселман җәмәгать хадимләре[5], язучылары, руханилары, ханым, әфәнделәре белән танышканы, белешкәне, көрешкәне, сөйләшкәне бар.

Депутат мирзадан алып стражник мирзага, мөфтидән алып мулла-мөәзингә, миллионер байдан алып гади, вак буржуа сәүдәгәрләргә, Фатыйх Кәримовлардан, Гаязлардан алып Батталга, Әхтәмовлардан алып Гомәр Терегуловка кадәре, һәрберсенең фальшасын, ялганын бер-ике сүз белән туп-туры үзләренә аңлатып биргән кеше ул Мәҗит ага.

Ләкин Мәҗит ага кеше алдында, җәмәгать алдында, бик тар даирәдә генә булмаганда, кешенең саф алтын итеп күрсәтергә тырышкан кара кургашын йөзенә бәреп әйтергә яратмый. Ул аны мөнәсәбәт килү, уңай чыгу белән әйтә, ләкин әйтә хакыйкать өчен, чын кешелек дөньясы өчен әйтер вакыты җитсә, һич төрле кәеф, хәтер сакламый, тарелка тотмый әйтә.

---

[1] Хиляф – каршылык.

[2] Яхуд – шулай ук.

[3] Инсанният – кешелек.

[4] Тәрәккый – прогресс; алга үсү.

[5] Хадимләре – хезмәткәрләре.

## *III*

Менә шул хакыйкатьләре өчен Мәҗит аганы мөселман җәмәгате яратмый, хәтта күрә алмый иде. Хайван табигатьле кешеләр ул булган урыннарда чыдап тора алмыйлар иде.

Мәҗит ага «тәрәккый пәрвәр» исеме күтәргән байларның пәрәмәч мәҗлесләренә йөрмәде. Яңлыш килеб чыкканда мәҗлес ахырына кадәре утырмады. Гел күңеле рәнҗеп, ачуы килеп кайтып китәр булды. Җәмгыяте хәйрия-фәлән җыелышларына да йөрмәде, яңлыш барып чыкса да, бер сүз катмады. Бераз тыңлап утырды да, берәр ялган, берәр фальшь күренеп калу белән, яхуд җәмәгать алдына берәр кара шәхес килеп чыгу белән, кулын селтәп, дәшми-тынмый, баш иеп кайтып китәр булды.

Мәҗит аганың зур җыелышда бөтен җәмәгать алдында бер генә мәртәбә каты кычкырып, зал яңгыратып үз иманын тәлкыйн[1] әйткәне бар. Гаязлар, киләчәк белән Уфадан качканда, беркатлы мөселман агай-энене җыеп, большевикларга – коммунистларга, Совет властена каршы лекцияләр сөйләгән, докладлар ясаганнар. Гаяз, коммунистларга каршы үзенә махсус шакшылар катнаш ялганнар оешып, Колчакның азау айгыры кебек кешнәп, иһаһай-миһаһайланып, бикәләргә[2] карап сүзен бетереп төшүгә, Мәҗит ага әллә кайдан, арткы рәтләрдән калкып скамьяга баскан да «ялган сөйләп эт кебек өреп йөрмәгез, хакыйкать большевиклар ягында!» дип кычкырган. Менә Мәҗит аганың үзенең хакыйкате дә большевиклар ягында шул. Ак җегетләр, контралар ягында түгел. Мәҗит ага шул хакыйкате белән бөтен гомерен эшче, ярлы арасында, эшче, ярлы, мәзлум[3] белән бергә кайгырып, бергә шатланып үткәрде. Мәҗит аганы Уфаның бөтен эшчесе, бөтен ярлысы белә һәм үз итә. Чөнки Мәҗит ага Уфа

[1] Тәлкыйн – үлекне күмеп, озатучылар киткәч, руханиның үлекне исенә төшерү өчен иман укуы.

[2] Бикәләргә – хатын-кызларга.

[3] Мәзлум – кимсетелгән.

ярлысының, эшчесенең гомуми ихтыяҗ вә кайгыларын гына түгел, ул аларның гаиләви кайгы вә шатлыкларын да уртаклаша.

Сез Мәҗит аганы Уфаның Галиләр, Садрилар, Суфилар, Сөнгатьләр, Сәлимләр, Гафурлар һәм Ибрайлар кебек карт эшчеләреннән, бөтен мәзлум фәкыйрь-фөкарәсеннән[1] сорагыз. Алар сезгә әйтерләр: «Без 15 нче еллардан бирле байларыбызга, самодержавияга каршы бөтен ялган голямага, кара мирзаларга каршы Мәҗит ага белән бер фронт тотып көрәшеп килдек. Мәҗит ага ул – безнең кеше!» – диярләр.

Октябрь инкыйлабының беренче дәверендә Уфаның бөтен зыялы дип әйтерлек буржуасы, алпавыты белән бергә укмашып, Советка, большевикларга каршы бердән чукындылар. Архиерей мөфти белән бергә чукынды. Ак татар офицерлары җыйналып, имеш, милли полклар төзеп, Дутов белән бергә союзга кереп, корал күтәрергә хәзерләнгәндә, Мәҗит ага «Көрәш»тә үзенең мәшһүр «Хисап көн»ен язып чыгарды. Шул вакыт бөтен Уфаның мөселман җәмәгате дигән контрреволюционный даирәләре Мәҗит аганы тотып ашарга җитештеләр. Кыйнатырга, үтерергә йөрделәр. Ак җегетләр бармак селкеделәр.

Мәҗит ага тик Октябрь инкыйлабыннан соң гына үз хакыйкатьләрен кычкырып тәлкыйн итәргә зәмин[2] тапты. Ул үз хакыйкатьләрен хәзер бөтен дөньяга кычкыра һәм Октябрь инкыйлабы сеңдергәнче, үзенең җисмани көче җиткәнче ул кычкырыр әле:

*«Бирегез чын кешелеккә юл!*
*Бетсен җир йөзендә җәбер-золым һәм ялган!*
*Яшәсен хезмәт һәм чын инсани мәхәббәт!*
*Яшәсен кызыл байрак!»*

дияр.

---

[1] Фөкарә – ярлылар, фәкыйрьләр.

[2] Зәмин – нигез; җирлек.

Биредә шуны да әйтеп китәргә кирәк. Мәҗит ага Зөһрә ханымны да нәкъ үзе итеп тәрбияләгәнме, әллә Зөһрә ханым да табган Мәҗит агага тартыммы? Зөһрә ханым күп еллар мөгаллимлек итте. Аның байлар, мирзалар, миссионерлар, бикәләр белән сугышкан берничә еллары минем күз алдымда үтте.

Ул мөдһиш[1], караңгы елларда якты йолдыз булып яна торган Мәҗит ага, Зөһрә ханым кебек кешеләр аз иде.

*Баймбәтов Г. Мәҗит ага // Эшче.– 1923.– 9 июнь*

[1] Мөдһиш – куркыныч.

## Хатирәләр дәфтәреннән[1]

Бу «Хатирәләрем» дигән дәфтәргә үземнең хатирәләремне язганда кайсы бит ачылса, шунда яздым. Айлар, еллар үзләренең тәртипләре белән ригая[2] ителеп барылмады. Шуның өчен кайбер битләр ак калдылар. Кайсы җөмләнең нинди елдагы алынган тәәссерат[3] буенча язылганы (лөзүм күренгәндә[4]) шул җөмлә яки тәәсссератнең ахырына язылып барылды.

Изге күңлем кагъбәсеннән көн дә бер таш җимерелә.
Ахыры бик күп калмагандыр инде актык гомеремә.
Яндырып күңлем шәмен эзләп маташтым изге юл.
Каршыдан искән каты җилдән вакытсыз сүнде ул.

*1922 елда язылган. Уфа*

Татар дөньясының күге болытлы, төннәре айсыз һәм йолдызсыз бер вакытларда, алдагы көннәренең якты булуына, аларның мәдәни халыклар рәтенә керүләренә өмит багълап, киләчәк тарихларының якты булуларына күз тотып, янган йөрәгемдәге чаткыларны караңгылык уртасына чәчеп, үземә һәм иптәшләремә юл табу уе белән назым һәм шигырьләр яза башлаган идем. Минем йөрәгемнән чыккан сүзләргә бәһа куелыр, киләчәк көндәге кешеләр моңа илтифат күзләрен салыр, дигән фикерләр күңелемдә юк иде. Бер ягымда – бик еракта мәдәният нурлары балкып, фән-белем гасры өстебезгә эре адымнары белән кил-

[1] Шагыйрьнең 20 еллык иҗат бәйрәмен котлап, Башкортстан нәшрияты һәм китап сәүдәсе ширкәте «Башкнига» истәлекле көндәлек дәфтәре бүләк итә. Әлеге язмалар шул дәфтәрдән алынды.

[2] Ригая – карау, игътибар итү.

[3] Тәәссерат – сизем, сиземләү.

[4] Лөзүм күренгәндә – кирәкле күренгәндә.

сә, икенче ягымда албасты кебек наданлык, хорафат тора иде. Мин шул наданлык дөньясыннан сискәнеп, мәгърифәт дөньясына күз тегеп, йөрәгемдә барны ихтыярсыз рәвештә дөньяга чыгарырга теләдем. Язган нәрсәләремә мөкафәт булырын, аларның тәкъдир ителүен күңелемә кертеп тә чыгармадым.

Бу эш 19 нчы гасырның ахырларында иде.

Заманның сәхифәләре бәрәм-берәм ачылып, гомернең юллары берәм-берәм күздән үтә башлады. Еллар үтү белән Шәрыкъ дөньясы, Идел, Урал буйларында аз-маз таң галәмәтләре сызылып, таң әтәче кычкырды. Кайдадыр, бер җирдәге сандугачлар өмит җырларын җырладылар. Мин үземне якты дөньяга барган кебек хис итә башладым. Күңелдә өмит нурлары барган саен арта барды. Коллык богаулары чылтырап төшә башладылар. Милләт уянган кебек булды. Бу мине чиксез шатландырды. Милләт җегетләре, аның сылу кызлары яңа юлга төшкән кебек булуларын күреп, гайрәт һәм киләчәккә өмитне тагын да арттыра төшерделәр. Ләкин тирә-ягымдагы болыт, өстемдәге караңгылык таралып, яктылык даирәсе киңәйгән саен, мин милләт балалары арасында да ямьсез сыйфатлар, комсыз гәүдәләр, нурсыз күңелләр күрдем. Шушы манзара фикеремне үзгәртте. «Милләт» эченнән генә хакыйкать таба алуның мөхаль[1] икәнен күз алдына китерде. Тәти җегетләр, матур туташлар, купшы ханымнар, юан байларның бәхетләре, аларның минем кебек татар һәм бер милләттән булулары гына җанга азык бирә алмаулары күз алдына килде. Һәм шушы дөньяның эчендәге серле пәрдәләр ачыла башлады. Болар миңа якын булган саен, мин алардан нәфрәтләнеп, ерагая башладым. Мин эшчеләр, ярлылар, аһ-зарлылар эчендә булган ләззәт һәм аларга хезмәт итүне иң изге эш икәнен аңлый башладым. Башта язган нәрсәләрем шушы юлга китереп мендерү өчен баскычлык хезмәтен иттеләр.

[1] Мөхаль – мөмкин булмаган.

Йөз кызарырлык, күңел уңайсызланырлык булган кай нәрсәләрем өчен тәәссеф итсәм дә[1], аларны шул юлга төшүемә баскычлык хезмәте итүләре өчен икәнлекләрен уйлап, бераз тәсәлла итә[2] һәм шуларга кәффарәт[3] өчен үзем тапкан изге юлда хезмәт кыла башладым.

«Фикрән артка китсәм, иң зур кайгы булыр иде, әле мин алга – хакыйкатьне эзләү юлына барам бит әле» дигән уй белән күңелне юатып, яшьлек һәм аңсызлык белән эшләнгән кайбер эшләрдән гыйбрәт алып, яңа эз, якты юл эзләргә бөтен көчемне сарыф иттем. Ачлык, салкынлыкларга сабыр итүне, вөҗданым кушкан юл белән генә баруны иң беренче маягым итеп алдым. Шушы юлда баруымнан ләззәт һәм тәм таба башладым.

Еллар берсеннән соң берсе үттеләр. Җиһан сугышлары булып, җир йөзе эшче-крестьян каны белән сугарылды. Ятимнәрнең, толларның күз яшьләре яңгыр кебек акты. Көчсезләр, көчләнеп, җәһәннәм машиналарына каршы алып барылдылар.

Бу фаҗигаләрне күрү күңелгә бетмәслек әрнү, гомерлек ачу, мәңгелек ләгънәт тудырдылар. Кемгә каршы?

– Капитал һәм кеше көче белән генә рәхәт көн күрергә өйрәнгән байлар дөньясына каршы.

Жиһан сугышы капитал дөньясының зарарына хезмәт иткән зур гамил[4] булып чыкты.

– Ник сугышабыз, нигә һәм кем өчен кан түгәбез?! дигән сөальләр чыга башлады.

Эшче-крестьян күкрәгенә каратылып куелган утлы кораллар сугышка сәбәп булган кешеләрнең күкрәкләренә таба каратылдылар.

[1] Тәәссеф итү – үкенү, ачыну.

[2] Тәсәлла итә – юату, күңел юану.

[3] Кәффарәт – гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш.

[4] Гамил – хезмәт итүче, фактор.

Каты куллы эшчеләр тиз көн эчендә таш диварларны ватып, патшаны, аның ялчыларын тәхетләре, сарайлары белән йөзтүбән җибәрделәр.

17 нче ел революциясе булды.

Бу эш миңа яңа рух, яңа көч бирде. Талган беләк кире күтәрелеп, янган йөрәк үзенең чаткыларын ирекле рәвештә чәчәргә кереште,

Эшче-крестьянның азатлыгы!

Бу бит дөнья яратылганнан бирле беренче мәртәбә дөнья үзенең бөтен сурәте белән тәҗәссем итү[1]?!

«Кызыл байрак» ялтырады. Ул бөтен дөньяга үзенең нәрсә икәнен күрсәтте.

Кара көчләр куркып, кайда барырга белми качтылар...

Ирекле каләм үзенең теләгән ирекле рәвештә игълан итә башлады.

Хәзер соң дәрәҗәдә шатлыгыннан ул, май аенда килгән сандугач кебек, һәр нәрсәгә карап, канат кагып сайрый. Хәзер ул шат: фабрик-заводларның торбаларыннан чыккан төтеннәрне, аның эчендә тавышланган машиналарны, чүкеч тавышларын ишетеп, күреп шатлана. Эшчеләрнең, хосусый кешеләрнең коллыкларыннан котылып, гомум халыкның ирекле әгъзалары булып эшләүләрен фикер итеп, күңелендәге дәрте, киләчәккә булган өмите арта.

Күп көннәр үтмәс, бөтен дөнья, бөтен Җир шары ирек җырын җырлар, «син», «мин», «сез», «без» калмас. Без шуны ышанып көтәбез. Мин шуларны җырлыйм, язам, шуның белән генә рух күтәрәм. Шул уйлар белән җаныма азык табып, дөньяда торуымның мәгънәсен шунда, дип уйлыйм.

Мин революциядән соң гына дөньяда торуның мәгънәсен аңладым. Кешеләрнең азатлык юлында корбан булулары белән генә бәхеткә ирешүләренә ышандым. Барган саен шушы ышануым 1923 елның матур язына килеп чыкты. Мин хәзер җәнүб[2] ягыннан килгән кош кебек шат.

[1] Тәҗәссем итү – гәүдәләнү, күләме белән зураю.

[2] Җәнүб – көньяк.

## *II*

Төрле тәэссератлар астында язылган нәрсәләремне яза башлавыма 20 еллык бәйрәм ясыйбыз, диделәр. Бу сүзне ишетү башта миңа бик авыр булды. Мин үземнең хезмәтләремдә бәйрәм ясарлык, минем бәйрәмем белән кешеләрне мәшгуль итәрлек нәрсә табу, яки моның өчен мөкяфәт[1] һәм хөрмәт күрүне башыма сыйдыра алмадым һәм:

– Кирәк түгел иде, мин моннан оялам, – дидем.

– Ул ягын уйлау ихтыярыңда булса да, башкасында синен эшең юк, рас эшче-крестьян арасыннан чыккан кешеләр бәйрәм ясарга телиләр, алар үз эшләрен үзләре бик беләләр, урынсыз җиргә йөрмәүләрен дә бик нык аңлыйлар...– дип җавап бирделәр.

Мин сүзне озайтырга уңайсызланып, каршы торуны урынсыз таптым:

– Алай булса ихтыярыгыз,– дидем.

## 20 еллык юбилей – бәйрәм

1923 елның 3 июнендә 20 еллык юбилей ясауны газеталарда игълан итеп, моның өчен махсус комиссия сайланганын күргәч, эшнең чынга әйләнгәнен белдем.

Комиссия әгъзаларының шушы эш артыннан җитди рәвештә йөрүләрен, аларның бу эшкә әһәмият бирүләрен күрү мине бик уңайсызландыра иде. Алар минем хакта сөйли башласалар, тиз генә чыгып китә торган булдым.

## Юбилей

Юбилей көннәре минем өчен бик авыр тоелды. Юбилей була торган көндә мин бөтенләй өйдән чыкмадым. Һәркемнең, очраган бер танышымның тәбрик итүе мине бик уңайсыз хәлгә калдыра иде.

[1] Мөкяфәт – хезмәт бәрабәренә бирелгән премия, бүләк.

– Ник соң инде бер кешенең юк-бар хезмәте өчен бу чаклы кеше вакыт әрәм итеп йөрергә?

Безнең эшче-крестьяннарның һәрберсе бит эшләп көн үткәрәләр. Аларның эшләүләре үзләре өчен генә булмый, бәлки бөтен халык өчен бит. Шулай булгач, безнең алардан юбилей ясатырлык нәрсә артыклык бар инде? Кирәкмәс иде дә, бер башлангач рәд кылуы[1] уңайсыз бит.

Мин юбилей көнне берәр якка чыгып китәргә дә уйлаган идем – булдыра алмадым. Үземнән бигрәк, минем өчен йөргән иптәшләргә күңелсез булыр, дип уйладым.

1923 ел, 3 июнь.

Мин бу вакытта Уфаның читке урамында – Никольский урамда тора идем. Төштән соң сәгать 6 ларда үзем белән гаиләмне автомобильдә килеп алдылар. Шофёрдан башка, Газыйм иптәш Касыймов та бар иде. Эшчеләр почмагыннан автомобильгә утырып китү бик авыр тоелды. Үз гомерләрендә дә автомобильгә утырмаган балаларым белән Зөһрә генә бу эштән кызыксыналар иде. Мин электә автомобильдә бераз булса да йөргәнгә күрә, артык исем китмәде.

Юбилей була торган Эрмитажда безне бик зурлап каршы алдылар. Кием салып, югары менә башлау белән «ура» кычкыру башланды. Мине ике ягымнан култыклап хөрмәт белән алып кереп, гаиләм белән бергә махсус урынга утырттылар.

Ярты сәгать көткәннән соң, сәхнәдә юбилей комиссиясе һәм анда тәбрик итәр өчен төрле оешма һәм мөәссәсәләрдән[2] килгән вәкилләр янына мине күтәреп мендерделәр. Меңләгән халык алдындагы бу хөрмәт мине тагын да уңайсыз бер хәлгә калдырды. Мин үземнең үткән тарихымны күздән үткәрә башладым.

– Ни өчен болай? – дигән сөальләренә җавап бирергә керештем.

---

[1] Рәд кылуы – кабул итмәү, кире кайтару.

[2] Мөәссәсә – оешма, учреждение.

Минем тәрҗемәи хәл сөйләнде. Тәбрикләр булды. Бүләкләр бирделәр. Боларның миңа вакытлы тәэсире булса да, мәңге онытылмый торганы: эшче-крестьян алдында аз гына хезмәтнең тәкъдир ителүе күз алдыма килеп, аларга мәңге хезмәт итүне уйлап, вәгъдә бирүем булды.

(Юбилейнең тәфсилле хисабы булганга күрә, ул хакта язып тормыйм.) Үз хакымда булган нәрсәләр хакында язарга һичбер ихласым юк. Тик мин ярлы эшче-крестьян сыйныфының башында йөргән иптәшләрнең ихласлык белән сузган кулларына кулымны түбәнчелек белән сузуны, аларның тәбрик һәм хөрмәтләрен шул ук халык исеменнән бик зур шатлык катыш оялу белән кабул итүемне язмый үтә алмадым.

Минем хезмәтләрем аз була торып та, шундый зур хөрмәтләргә каршы тәшәккер итми калу минем тарафымнан бик зур җинаять булыр иде.

Юбилей тантанасы төнге сәгать 3 ләргә чаклы дәвам итеп, мине һәм гаиләмне хөрмәт белән озатып куйдылар.

Юбилейга гаид бөтен нәрсәләр үземдә сакланганга күрә, аларның тәфсилен язып тору кирәксез инде.

1923 ел июнь. Уфа.

Шәхесемә гаид булган бу җөмләләрне монда язарга тиешле күрсәткән эш, шушы дәфтәрләрне шул юбилей мөнәсәбәте белән бүләк итеп бирүләре булды. Шуның өчен беренче дәфтәрем башының бераз урынын бу хактагы хатирәм белән чубарлап куйдым.

*Ошбу дәфтәрләрдә күпме «истәлекләр» сакланыр,*
*Күпме урыны тапланыр да, күпме урыны ак калыр?..*
*Кайсы битләргә барып туктар минем гомерем очы,*
*Кай вакыт ташлап очар бу дөньяны гомерем кошы?*
*Бу сөальләргә биреп булмый хәзер катгый җавап...*

– Миңа юбилей ясадылар... Ни өчен икәне һәркемгә мәгълүм, минем күптән күреп йөргән бер иптәш эшчем бар. Ул хәзер алтмыш яшьтә булып, шул озын гомеренең кырык биш елын эштә – төрле шахта, заводларда үткәр-

гән. Асылда, бу юбилей менә шул ярты гасырга якын гомерен турыдан-туры эштә үткәргән картка тиеш иде.

Мин шуларны күреп газапланам.

Бу хакта, бу дәфтәрнең ахырында бер мәкалә бар. Шуны кушып укыган кеше минем соңгы фикерләремне белер дә, «юбилей»ләргә карашымны да аңлар.

— Эш – бик мөкаддәс нәрсә. Ләкин аның мөкаддәслеген бик күп сөйләүчеләрнең куллары бик тиз кабаручан була.

Әле миңа кичә шимбә өмәсеннән (субботник) кайтып килүче бер танышым очрады. Ул мине күрү белән хариколгадә[1] бер вакыйга булган кебек, үзем аның кайдан баруын сорамыйча ук:

— Менә әле өмәгә бардым. Ике сәгать эшләдек, куллар кабарып бетте!..– диде. Мин көлдем:

— Синең ике сәгать эчендә кулың кабаруы бер дә «кара эш» эшләмәвеңне күрсәтә. Шуның өстенә, син ике сәгать эшләвеңне бик зур вакыйга итеп, миннәт кылып[2] сөйлисең. Минем бер эшче танышым бар. Ул егерме биш елдан бирле кулыннан чүкеч төшергәне юк. Шулай да аның үзенең эш белән мактанганын, сөялле кулларын күрсәтер өчен миңа каратып сузганын күргәнем юк...– дидем.

— Алар бит үрәнгәннәр!..– ди.

— Үрәнгәннәр шул...

23 нче ел

***

Син тәэмин ителдең, яхшы фатирларда торасың, пенсия аласың, диләр миңа бик күп кешеләр.

— Күрмиләр алар минем йөрәгемне. Болар һәммәсе дә – минем өчен авыр йөк.

Минем күңелле һәм тыныч хәятым ике бүлмәле йортта, шәһәрнең читендә торган вакытта иде.

---

[1] Хариколгадә – гадәттән тыш.

[2] Миннәт кылып – берәүгә иткән яхшылыкны һаман искә төшереп сөйләү.

— Күрәсең, бу халыклар бөтен бәхетне кешеләрдән яхшы торуда, акчаның мул булуында дип беләләр.

— Соң мин бер сынык икмәк таба алмаучыларны күрә торып, үземнең тук булуымнан ләззәт таба аламмы соң?.. Эшче-крестьяннән һәм эш таба алудан гаҗиз булып хәйран йөрүчеләрдән тәмле ашау — минем өчен агу икәнен белмиләр...

***

Бүген мин ике урында булдым.

Берсе сәүдә белән торучы бер танышым йортында иде. Аның өстәлендә бал, май, алма бәлешләре өстенә мин исемнәрен белми торгән ашамлыклар бар иде.

Ул мине көчләп «кунак итәргә» кереште. Дөньясыннан зарлана башлады: сәүдә акрын, файда аз, налог күп, ди, аһ ора... Аның сүзләре мине ялкытты. Аптырагач:

— Бу арада күпме файда иттең? — дип сорадым.

— Юк, бик аз...— ди.

— Шулай да? — дим.

— Соңгы айда өч-дүрт сумлап бар,— ди.

Сүз килешмәде, чыгып киттем.

Кайтышлый таныш бер эшче алып керде. Бу җөмләләрне язганда бу кеше исән булганга, исемен атамаган идем. Бу кеше Чишмә волосте Ар авылының Гани исемле сапожник карт иде. Бу кеше, карт булуына карамастан, иске аяк киемнәре тегеп, шуның белән гаиләсен тәрбияләп тора торган кеше иде.

— Ну, кәсепләр ничек? Бик авыр түгелме? — дидем.

— Бик шәп, бик шәп... Бу айда 30 сум акча эшләдем. Болай барса, өч айга туксан сум була бит ул...— ди. Үзе шат. Карчыгы өйдә юк иде. Үзе самовар куеп ташлады. Өстәлгә икмәк кисеп куйды. Сөт китерде, шикәр китерде.

Моның икмәгендә, чәендә тәм бар иде, ашадым, эчтем. Бик озак гәпләшеп утыргач, чыгып киттем.

Юлда бу ике кеше арасындагы кешелекне уйлап кайтам.

Менә боларның кайсысын яклап һәм мактап сөйләргә кирәк инде?..

***

Бер-бер артлы шырт кебек үскән күңелнең талларын
Сындырып салдым да үттем мин бу тормыш сазларын...
Саз гына булса тагын бер хәл... Тирә-як күк томан...
Анда һичбер шәй күреп булмый... Көнем нәкъ төн сыман.
Шунда ачтым күкрәгемне. Чыкты аннан чаткылар,
Ул томаннан һәм дә сазлардан алып чыкты шулар.

*26 нчы ел*

***

## Эчем пошканда

*(Халык җыры буенча)*

Болыннарны чабу җиңел.
Әрем чабулар авыр.
Башка авырулар бик җиңел,
Йөрәк янулар авыр...
Күк күгәрченнәр гөрли,
Үзе кайда?.. күренми.
Салкын сулар сибү белән
Янган йөрәк сүрелми...

***

Беркөн бакчачының яз көнендә алмагачларын тәрбия итүен карап утыра идем. Бакчачы кайбер ботакларын кисеп ташлады.

– Нигә кисәсең? – дидем.

– Алар картайганнар, – диде.

– Аһ, картайганнар!..

Мин үземне уйладым: яшь иллегә якын. Картаю галәмәтләре күренеп тора. Мин дә шул алмагачның карт ботаклары кебек булганмын инде, дидем дә бик авыр суладым.

Бу авыр хәсрәттән соң булган тәэссоратны үзегез уйлап карагыз.

***

## Хакыйкатькә таба барганда

Хакыйкатькә барам дип мин, күрәмсез, ниндәен беттем,
Туры сүз сөйлимен дип, дусларым дошман ясап беттем.
Берәр файдасы булгандырмы, юктырмы бу сүзләрнең...
Үзем әмма хисапсыз күп җәфа күрдем, газап чиктем.
Көнем хәсрәт, төнем төрле фикер-уйлар белән үтте,
Күңелдән чаткылар чәчтем. Күземнән яшьләрем түктем.

***

Ах, мин нигә булдым уйланучан,
Нигә булдым болай янучан?!
Көн-төн димәй, һичбер сүнми һаман
Нигә яна икән минем җан?..

Һаман болай янып тормас иде...
Уттан яратылган җандыр ул?..
Шул ут белән алга барырмын мин...
Алга барыр өчен җитә шул.

Ничек туры юлдан барыр идем
Җаным янган уттай булмаса...
Карт көенчә ничек янар идем,
Күкрәгемдә дәртләр булмаса.

*26 нчы ел*

***

Таңын һаман күрә алмыймын төнемнең.
Читен һаман күрә алмыйм диңгеземнең.
Нигә янам?.. Нигә мин шат түгелмен?
Нигә соң яктысы аз көндеземнең?

Янам мин тик йөрәктән. Һич тә түзмим.
Өмитләр зур. Өмитне һич тә өзмим,
Җәберләнгән кешеләрне күрәм дә
Янам, һаман шуларның бәхтен эзлим.

Барам алга, кулымда якты шәм бар,
Шулай мин бик биек тауларга үрлим.
Булыр бер көн бөтен дөнья бәхетле:
Комиссарга тигез булыр кучер, дим.

Кучер көтмәс аны төнге урамда,
Каты салкын, күз ачмаслык буранда...
Тигез тезгән матур, зур бер букеттай
Булыр бөтен халыклар бер заманда...

Беләм: бу сүз авыр хәзер сөйләргә,
Сөйләүчене исәпләрләр җүләргә...
Туры юлдан адашкан ул – Мәҗит!.. дип,
Керешерләр алар миннән көләргә...

*26 нчы ел*

***

## Күреп кенә калдым

Каршы яктан яшьлегем килде минем тулкынланып,
Алланып, гөлдәй булып һәм кып-кызыл уттай янып.
Килде дә бирде сәлам һәм китте барды кузгалып,
Калдым артыннан карап мин бу яшьлегемнең сызланып.

Соңра уйлыйм: яшьлегем – гомерем минем –
нәкъ бер яшен.
Ах, минем үтте гомер?..
Шул уй белән акты яшем...

***

## Нәсер

Халык ике төрле:
Берсе һәрбер эшнең яхшы якларын гына күрә.
Икенче бер төрлесе начар якларын гына күрә.
Һәр ике якны тигез күреп, туры юл белән баручылар аз:
Ябалак – көндез, карга төнлә күрә алмый.

## Иранның мәшһүр шагыйрьләреннән Гомәр Хәйямнан

1 – Чөн лалә бә-нәүруз кадәх гир бә-дәст,
Ба лаләрөхи әгәр ту-ра форсат һәст?
Мәй нуш бә-хөррәми ки ин чәрхе кәбүд
Нагяһ ту-ра чү хакь гәрданәд пәст...

Тәрҗемәсе:

Нәүрузда аткан чәчкә кебек кадәхне кулыңа ал. Мөмкин булса лалә кебек матур яңаклы (битле) бер гүзәл белән гыйш-гыйшрәткә тал. Шәрабны шатлык белән эч. Чөнки барыбер сине бу фәләк җир белән тигез ясаячактыр.

2 – Мәй хурдән вә шад будән айине мән-әст,
Фаригъ будән зи көфр-ү дин дине мән-әст.
Гөфтәм бә-гарусы дәһер: кябин чист?
Гөфта: диле хөррәме ту кябине мән-әст.

Тәрҗемәсе:

Шәраб эчеп шатлану – минем гадәтемдер; көфер һәм диннән азат булу – минем динемдер.

– Дәһәр (...) килененә синең мәһәрең нәрсә? – дип сорадым.

– Синең шат күңелең минем мәһәремдер... – диде.

3 – Чөн һушйарәм тараб зи мән пәнһан-әст.
Вә гәр мәст шәвәм дәр худәм ноксан-әст.
Халист мийане мәсти-йу һушйари,
Мән бәндәи ан ки зиндәгяни ан-әст.

Тәрҗемә:
Аек булган вакытымда-заманымда шатлык миннән кача.
Исерек булсам – гакылыма кимчелек килә.
Исереклек белән аеклык арасында шундый матур (күңелле) бер халәт бар ки,
Менә мин шуны яратам, чын шат тормыш шундадыр...

4 – Гөл гөфт: бә-әз ликаи мән руйи нист.
Чәндин ситәм гөлабгәр бари чист.
Бөлбөл бә-зәбане халь ба-у мигөфт:
– Йәк руз ки хәндид ки сали нәгәрист.

Тәрҗемәсе:
Гөл чәчкәсе:

– Минем йөзем чаклы матур бер йөз бу дөньяда юк була торып та, мине бу кимиягерның[1] эскәнҗәсе[2] ни өчен кысуының мәгънәсен белсәм иде?!

Шунда сандугач халь теле белән болай җавап бирде:

– Дөньяда бер генә көлүенә каршы бер ел җыламаган кем бар соң?

*26 нчы ел*

---

[1] Кимиягер – алхимик.

[2] Эскәнҗә – тиски, кыса торган җайланма.

***

Монда иркен...
Дөньяның бар җиреннән монда иркен:
Очалар төрле кошлар төркем-төркем.
Үзләре кайда тели, шунда кунып
Чыр кубып сайрашалар шунда төн-көн...

Сандугачы йөри үз теләгәнчә очып,
Үзе сөйгән матур чәчкәләрне кочып...

***

«Хорафат» дип, уйланган нәрсәләр арасындагы хакыйкать белән «хакыйкать» дип уйланган «хорафат»лар арасындагы аңлашылмауларны бетерер өчен, хәзерге вак көчләр генә җитми әле.

Мин хәзер бер көйгә ару гына тормышта, матур гына бәр халәттә торам. Шәхси хәятым өчен кайгырырлык түгел.

***

Әй Мәҗит, син бер көндә калырсың
Япа-ялгыз, бетәр бар дус-иш.
Алар синнән бизәр, син – алардан.
Калмас ике арада уртак эш.
Ялгыз калсаң да син чикмә хәсрәт,
Ачуланып йөрмә, кысма теш,
Йөрәк майларыңның бер тамчысы
Калганчы син янарга тиеш.
Соңгы тамчы маең беткәч кенә
Тынычланып, ятып үләрсең.
Шул вакытта гына табигатьтән
Алган бурычыңны түләрсең.

*26 нчы ел*

***

Рас, синең чүплек икән төшкән җирең,
Рас, синең чүп-чар икән үскән җирең.
Рас сине чын дусларың да алдагач,
Һич кешегә ышанырга жир калмагач.

Эч пошудан кайчан акылдан язасың,
Шундый чакта менә боларны язасың.

***

1. Без үзебезне зур дип уйлап йөрибез. Әмма каткан куллы эшчеләр аркасында тамак туйдыруыбызны онытабыз.

2. Җир-күк фәлсәфәләрен тикшергәндә бер күлмәк белән бер туярлык икмәккә мохтаҗ икәнлекләрен истән чыгарырга ярамый,

Икмәк белән күлмәкне эшләп чыгаручылар кемнәр?..

***

## Робагыйлар

Бер хәсрәт бетте, дия торганда,
Аннан да зур хәсрәт килә дә,
Кара болыт кебек өстне каплап,
Була шатлыгыңа күләгә.

Кайберәүләр арып, хәлдән таеп,
Ятып үлә олы юлда да...
Кайберәүләр кара урманнарны
Ярып үтә, үлми шунда да...

Ачык йөзе белән килеп кайбер таныш,
Утыра ул синең янда нәкъ якын дус
Төсле булып... Соңра синең яннан киткәч,
Төрле җирдә ясап йөри өстән донос.

(Бу мисрагълар озын вәзенгә язылган)

***

Соңгы вакытларда кайберәүләр
Никтер миңа кырын карады.
Борын якын күргән танышларым
Берәм-берәм китеп таралды.
Танышларның шулай таралуы
Бер җәһәттән миңа ярады.
Хәзер ялгыз гына өйдә торып
Ямыйм йөрәктәге яраны...

***

## Хатирә дәфтәренең башына кушымта

Шушы дәфтәрнең башында мин үземә гаид[1] юбилейны (әйтергә яраса) бер уңайсызлык белән каршы алганымны язган идем. Бу язуның мәгънәсе еллар узган саен ачыла барды. Еллар үткән саен томаннар күтәрелеп, риакар[2] кешеләрнең йөзләре ачылды. Мин үзем «юбилей ясап, мине тәкъдир итүләренә масаеп, үземне югары күтәреп йөрүләренә» артык исем китмәде. Аңа карап, һичбер вакыт та югарыланмадым, бәлки табигый рәвештә түбәнләдем. Кучерны комиссардан, комиссарны (хәзерге тәгъбир белән) кучердан артык күрмәдем. (Эшләре җәһәттән түгел, үземнең аларга ихтыяҗым төшү, яки мөнәсәбәт баглау ягыннан.) Минем каршымда һәркем бертигез күренде. Шуның белән бергә, хәзерге көннәрнең (21 нче елдан башлап 28 нче елларга чаклы вакыт алынды) ялгыз Россиянең эшче, крестьяннары гына түгел, бәлки бөтен дөнья эшче-крестьяннарының бик зур имтихан көннәре икәнен уйлап, чынлап төшенеп алганнан соң, революциядә «уңлык» «суллык» яки, бер әйбер дә уйламый, «безгә арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит» дип йөргән, бу эшләрдә ифрат яки тәфрит[3] киткән кайбер ахмакларга каршы төшеп,

[1] Гаид – кагылышлы.
[2] Риакар – икейөзле.
[3] Тәфрит – эшнең очына чыкмау.

авыр сүзләр (бу сүзләр төрлечә тәһдит итүләргә[1] чаклы булды) ишетергә мәҗбүр булдым. Шул туры сүзләрем аркасында кешеләргә «мәхәббәтсез үрдәк баласы» кебек күренә башладым. Ләкин аларның миңа булган «матур» карашларына да, «ямьсез» «карашларына» да исем китмәде. Мин һәрвакыт, никтер, иркен советларның, саф күңелле, дәрәҗә-мәрәҗә уйламый, саф йөрәк белән эшләүчеләр, эшләүләрендә дәрәҗәгә күтәрелүне уйламый хезмәт итүчеләр ягында булдым. Кыскасы бу көнге көн өчен генә «суллашып» иртәге көн өчен «уңлашып», монафикланып[2] йөрүче һәм бөтен дөньяны азатлыкка чыгару юлын алып барган эшчеләр партиясенең тоткан юлларын үзләренең бүгенге мәнфәгатьләренә фида итүчеләргә һәрвакыт каршы төшәм.

Бу «Хатирәләрем» дигән дәфтәргә, үземнән хатирәләремне язганда, кайсы бит ачылса, шунда яздым. Айлар, еллар үзләренең тәртипләре белән ригая ителеп барылмады. Шуның өчен кайбер битләр ак калдылар. Кайсы җөмләнең, нинди елдагы алынган тәэссорат буенча язылганы (лөзум күрелгәндә) шул җөмлә яки тәэссоратның ахырына язылып барылды.

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 26 эш*

---

[1] Тәһдит итү – куркыту, янау.

[2] Монафикъ – икейөзле, эчкерле.

# М. Гафуриның үзе исән чакта чыккан әсәрләре библиографиясе[1]

## *1917 елга кадәр китап булып басылганнары*

### Шигырьләр

1. Замана шигырьләре («Сөбателгаҗизин» ысулында). Беренче басма.– Уфа: «Шәрекъ» типографиясе, 1909.– 24 б. *(Татар телендә, гарәп графикасында)*

2. Яшь гомерем. Беренче басма.– Казан: «Шәрәфләр» нәшр., 1906.– 69 б. *(Татар телендә, гарәп графикасында*)

Яшь гомерем. Икенче басма.– Казан: «Шәрәфләр» нәшр., 1908. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Яшь гомерем. Өченче басма.– Казан: «Сабах китапханәсе» нәшр., 1913.– 45 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

3. Кызларга махсус милли шигырьләр. Беренче басма.– Уфа: «Кәримов, Хөсәеновлар» нәшр., 1910. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Кызларга махсус милли шигырьләр. Икенче басма.– Уфа: «Кәримов, Хөсәеновлар» нәшр., 1912.– 32 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында)*

Кызларга махсус милли шигырьләр. Өченче басма.– Уфа: «Борадәран Кәримовлар» нәшр., 1914.– 32 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

4. Милли шигырьләр. Беренче басма.– Казан: «Шәрәфләр» типографиясе, 1907.– 56 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

---

[1] М. Әмиров тарафыннан 1945 елда төзелгән әлеге библиография М. Гафури фондында саклана. Кыскартып бирелде.

Милли шигырьләр. Икенче басма.– Уфа: «Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте» нәшр., 1908. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Милли шигырьләр. Өченче басма.– Уфа: «Вәлиев» нәшр., 1909. (*Татар телендә, гарәп графикасында*.

Милли шигырьләр. Дүртенче басма.– Уфа: «Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте» нәшр., 1911.– 40 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Милли шигырьләр. Бишенче басма.– Казан: «Сабах китапханәсе» нәшр., 1913.– 37 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында)*

Милли шигырьләр. Алтынчы басма.– Уфа: «Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте» нәшр., 1914.– 32 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

5. Милләт мәхәббәте. Беренче басма.– Казан: «Шәрәфләр» типографиясе, 1907.– 56 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Милләт мәхәббәте. Икенче басма.– Уфа: «Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте» нәшр., 1911.– 60 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

6. Моң вә зар. Беренче басма.– Уфа: «Борадәран Кәримовлар» нәшр., 1914.– 32 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

7. Менла Һибәтулла бине әш-шәйхе Зәйнулла ән Нәкшбәнди хәзрәтләренең мәрсиясе.– С.-Петербург: Мөгаллим Мөхәммәтхәким Мөхәммәтзариф улы нәшре, Илияс мирза Бораганский типогр-се, 1903.– 10 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

8. Мәхәббәт хатлары.– Уфа: «Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте» нәшр., 1912.– 31 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

9. Мәҗит Гафури шигырьләре. Беренче басма.– Казан: «Шәрәфләр» нәшр., 1909.– 46 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

10. Себер тимер юлы, яки Әхвәле милләт. Беренче басма.– Оренбург: «Хезмәт ширкәте» нәшр., 1904.– 15 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

11. Тәэссератым (Әдәбияттан бер кисәк).– Уфа: «Кәримов-Хөсәеновлар» нәшр., 1910.– 40 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

12. Адәм вә Иблис. Беренче басма.– Уфа: «Шәрекъ» типографиясе, 1910.– 24 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

13. Әмсал (Җанварлар арасында). Беренче басма.– Казан: «Сабах китапханәсе» нәшр., 1913.– 36 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

**Хикәяләр**

14. Ачлык ел, яки Сатлык кыз.– Казан: «Шәрәфләр» нәшр., 1907.– 46 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

15. Заятүләк белән Сусылу. Беренче басма.– Уфа: «Кәримов-Хөсәенов ширкәте» нәшр., 1910.– 24 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

16. Заятүләк белән Сусылу. Икенче басма. (*1917 елдан соң чыккан хикәяләрдән кара)*

17. Исәпсез байлык.– Уфа: «Кәримов-Хөсәенов ширкәте» нәшр., 1911.– 36 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

18. Онытылган җинаять. Беренче басма.– Казан: «Борадәран Кәримовлар» нәшр., 1909. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Онытылган җинаять. Икенче басма.– Казан: «Борадәран Кәримовлар» нәшр., 1911.– 52 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

19. Үги балалар. Беренче басма.– Казан: «Шәрәфләр» нәшр., 1908.– 72 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

20. Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек. Беренче басма.– Казан: «Ибраһим Терегулов» нәшр., 1904.– 32 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек, яки Аракы эчүченең үлеме.– Казан, 1908.– 32. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

21. Хәмитнең хәяте, яхуд Ләйлә вә хәятем.– Уфа: «Кәримов-Хөсәенов ширкәте» нәшр., 1911.– 100 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

22. Әдәбият кисәкләре. Беренче басма.– Уфа: «Кәримовлар» нәшр., 1914.– 43 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

23. Ярлылар, яки Өйдәш хатын.– Казан: «Борадәран Кәримовлар» нәшр., 1909.– 112 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

### Башкалар

24. Земство-намә.– Уфа: Уфа губернасы земствосы нәшр., 1912.– 51 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

25. Хәзрәте рәсүл вә дүрт хәлифә.– Уфа: «Чулпан» китапханәсе нәшр., 1912.– 41 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

## *М. Гафуриның 1917 елга кадәр журналларда басылган шигырь, хикәя һәм мәкаләләре*

### Шигырьләр

1. Без //Аң.– 1913.– № 23.– 411 б.
2. Бәхет эзләү //Аң.– 1913.– № 8.– 300 б.
3. Гомер //Аң.– 1915.– № 16.– 259 б.
4. Гаиб хәзинә //Аң.– 1915.– № 23–24.– 395–398 б.
5. Игътираф //Аң.– 1915.– № 2.– 36 б.
6. Ишет, тәңрем //Аң.– 1914.– № 3.– 61 б.
7. Көндезге шатлык //Аң.– 1916.– № 1.– 2 б.
8. Кайвакытта // Шура.– 1911.– № 2.– 39 б.
9. Күрдек // Шура.– 1910.– № 5.– 152 б.
10. Кыйсас //Аң.– 1915.– № 21.– 73 б.
11. Кыямәт //Аң.– 1914.– № 22.– 299 б.

12. Мин вә хыял // Шура.– 1909.– № 20.– 627–628 б.
13. Мәхәббәт //Аң.– 1914.– № 8.– 1 /149/ б.
14. Саф күңел //Аң.– 1914.– № 1.– 5 б.
15. Чуар тел // Шура.– 1911.– № 13.– 399 б.
16. Хикмәт // Шура.– 1911.– № 18.– 557 б.
17. Торасың шунда... // Шура.– 1911.– № 18.– 556 б.
18. Үлгән йөрәкләр // Шура.– 1910.– № 12.– 700 б.
19. Халәте тәрәддед //Аң.– 1915.– № 3.– 49 б.
20. Халәте тәэссорда //Аң.– 1914.– № 24.– 425 б.
21. Хакыйкать // Шура.– 1911.– № 13.– 409 б.
22. Саңгырау // Шура.– 1910.– № 24.– 753 б.
23. Шәйхе Шамил рәсемен күргәндә // Шура.– 1908.– № 7.– 220 б.
24. Юктырсың ла, Алла //Аң.– 1915.– № 20.– 341 б.

**Хикәяләр**

1. Арыш башагы // Шура.– 1912.– № 8.– 242–243 б.
2. Бер чәчкәнең наләсе // Мәгълүмәте җәдидә.
3. Бу кемнең кабере? (Тарихи бер мәкбәрә янында) // Аң.– 1913.– № 20.– 388–399 б.
4. Зәйнәп сабыр иткән иде, ниһаять сабыр итә алмады // Шура.– 1911.– № 11.– 350–352 б.
5. Тәэссорат / Җәй көннән төнгә... //Аң.– 1913.– № 17.– 286–287 б.
6. Хан кызы Алтынчәч //Аң.– 1914.– № 16–17.– 291–293 б.
7. Хайваннар арасында // Шура.– 1912.– № 16.– 487–490 б.

**Мәкаләләр**

1. Чуар тел // Шура.– 1911.– № 13.– 398–399 б.
2. Сүз һәм эш // Шура.– 1909.– № 1.– 9–13 б. / «Әлһилал» мәҗәлләсеннән алынган.

## *М. Гафуриның 1917 елга кадәр газеталарда басылган шигырь, хикәя һәм мәкаләләре*

### Шигырьләр

1. Алмашыну // Казан мөхбире.– 1905.– № 7.– 1–2 б.

2. Башка мәмләкәтләрдә мөселманнарның хәле // Казан мөхбире.– 1906.– № 57, 69.– 4 б.

3. Бу көн (Корбан гаете мөнәсәбәте белән) // Тормыш.– 1916.– № 521.– 1 б.

4. Багыш (Матбугат көне мөнәсәбәте белән) // Тормыш.– 1916.– № 390.

5. Вакыт җитте тикшерергә // Казан мөхбире.– 1905.– № 15.– 1–2 б.

6. Европа–Азия // Казан мөхбире.– 1906.– № 30.– 2 б.

7. Эч пошу // Казан мөхбире.– 1906.– № 49.– 2 б.

8. Ике кошны ябып куйсак бер читлеккә // Йолдыз.– 1906.– № 4.– 4 б.

9. Инсаф вә иттифак // Казан мөхбире.– 1905.– № 10.– 3–4 б.

10. Иптәшләрем шәкертләр // Казан мөхбире.– 1906.– № 26.– 2 б.

11. Ятим бала зары //Бәянелхак.– 1907.– № 244.– 3–4 б.

12. Көч. Мәсәл // Тормыш.– 1916.– № 541.– 2 б.

13. Күңелсез бәйрәм // Тормыш.– 1916.– № 491.– 1 б.

14. Мал өчен // Казан мөхбире.– 1906.– 139–140 б.

15. Мәнзум сүзләр (Гасырлар үтте, уян да, милләт, каты йокыңнан...) // Йолдыз.– 1906.– № 30.– 4 б.

16. Мәнзум сүзләр (Вакыйга булды Русиягә...) // Йолдыз.– 1906.– № 46.– 3–4 б.

17. Ничә йөз ел изелгән татар яшьләре // Казан мөхбире.– 1906.– № 20.

18. Таң яктысы // Ил.– 1914.– № 1.

19. Телеңне киссәләр // Вакыт.– 1910.– № 689.– 2 б.

20. Түгелгән яшь // Йолдыз.– 1912.– № 883.

21. Тәрәкъкый // Казан мөхбире.– 1905.– № 13.– 2 б.
22. Тәэссер // Тормыш.– 1913.– № 1.– 1 б.
23. Алар алай, болар болай // Казан мөхбире.– 1906.– № 6.
24. Алар // Казан мөхбире.– 1906.– № 175.
25. Фидаи мәхбүс авызыннан // Казан мөхбире.– 1906.– № 153.
26. Шигырь // Казан мөхбире.– 1906.– № 20.– 2 б.
27. Шигырь (Уфада 11 декабрьдә әдәбият кичәсендә укылган шигырь) // Вакыт.– 1909.– № 557.
28. Җавап // Тормыш.– 1915.– № 34.– 2 б.

**Хикәяләр**

1. Бер мосафирның мөселман карьяләренә сәяхәте // Бәянелхак.– 1908.– № 266–271.

**Мәкаләләр**

1. Авылларда вак бурыч җәмгыятьләре // Вакыт.– 1915.– № 190. – 2 б.
2. Авылларда мәктәп вә школа // Вакыт.– 1915.– № 1617.
3. Авыл халкы өчен файдалы китаплар вә земстволар // Йолдыз.– 1912.– № 784.– 2–3 б.
4. Бер еллык тәрәкъкый // Әл-галәме ислам.– 1906.– № 39.
5. Бәләбәй өязе «Н» авылыннан // Вакыт.– 1916.– № 2069.
6. Вафат // Йолдыз.– 1912.– № 775–776.
7. Зур хезмәтләр // Бәянелхак.– 1908.– № 267.– 3 б.
8. Җир сатучы агайлар тирәсендә // Йолдыз.– 1911.– № 758.– 3 б.
9. Земство нәрсә? Земство ниләр эшли вә ни өчен кирәк? Земство һәм аның бүлемнәре // Йолдыз.– 1912.– № 836.
10. Казакъ, кыргызлар хакында // Казан мөхбире.– 1905.– № 38.– 3 б.

11. Катай башкортлары // Вакыт.– 1911.– № 772.– 2–3 б.
12. Кыргызлар // Казан мөхбире.– 1907.– № 201.
13. Надан халыкларның ваба турындагы фикерләре // Вакыт.– 1910.– № 664.– 2 б.
14. Онытылган җинаять (фельетон) // Вакыт.– 1910.– № 657.– 2 б.
15. Уфада земство // Йолдыз.– 1911.– № 775.
16. Уфада кызларга махсус мәдрәсә салыну мөнәсәбәте белән («Г. Фури») имзасы белән // Йолдыз.– 1911.– № 740.– 2 б.
17. Уфадан (уку-укыту эшләре турында ясалачак киңәш мәҗлесе өчен язылган 116 юллык хәбәр // Ил.– 1913.– № 6.– 3–4 б.
18. Таләбәләрә даир // Казан мөхбире.– 1906.– № 96.– 2 б.
19. Татар җырчысы (Мөхәммәтҗан Гобәйдуллин турында) // Вакыт.– 1910.– № 680.– 4 б.
20.Тәэссерле вафат (Суфиябикә Җантурина турында) // Йолдыз.– 1912.– № 96.– 2 б.
21. Хәлебез ничек вә ни кылырга уйлыйлар // Бәянелхак.– 1907.– № 259.– 3 б.
22. Халык теләге // Вакыт.– 1911.– № 718.– 2 б.
23. Шәкертләр хакында // Казан мөхбире.– 1906.– № 29.– 3 б.
24. Эш вә акча (170 юллык Уфа хәбәре) // Ил.– 1915.– № 75.– 1 б.
25. Юк өчен баш ватучыларга (Муса Бигигә карата) // Вакыт.– 1910.– № 674.– 2 б.
26. Гаҗәпләнмәгән идем, гаҗәпләндем // Вакыт.– 1910.– № 671.

### *М. Гафуриның 1917 елга кадәр альманах, хрестоматия һәм уку китапларына кергән әдәби хезмәтләре һәм аның катнашы белән язылган китаплар*

1. Анам каберендә (Нәсер) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 65–66 б.

2. Заятүләк белән Сусылу (Хикәя) // Белек йорты. I китап.– Уфа. 1913.– 48 б.

3. Ике чебен (Шигырь) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 27 б.

4. Җәйге көннең иртәсе (Шигырь) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 15–16 б.

5. Карт белән Әҗәл (Шигырь) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 26–27 б.

6. Кыш фасылы (Шигырь) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 23 б.

7. Маймыл вә күзлекләр (Шигырь) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 27 б.

8. Укырга китүем. (Нәсер) // Белек йорты.– Уфа. 1913.– 1 б.

### *М. Гафури турында 1917 елга кадәр газета һәм журналларда язылган тәнкыйть һәм хәбәрләр*

1. Г. З. Әһле дианәт дикъкатенә. («Аң» журналының 1914 ел 20 нче санында басылган «Юктырсың ла, Алла» дигән шигыре өчен М. Гафурига һәм «Аң» журналына протест) // Дин вә мәгыйшәт.– 1916.– № 4.– 56–58 б.

2. Габдел-Салих Габдуллаҗан. Тәэссеф илә бәян («Юктырсың ла, Алла» шигыренә протест) // Дин вә мәгыйшәт.– 1916.– № 16.– 197–199 б.; № 17.– 208–209 б.; № 18.– 219–220 б.

3. Габди. Әдәбият («Хәмитнең хәяты» әсәренә) // Йолдыз.– 1912.– № 783.– 3 б.

4. Камал Гәлиәсгар. Үги балалар («Үги балалар» әсәренә) // Йолдыз.– 1908.– № 243.– 2 б.

5. Кызларга махсус милли шигырьләр (Тәнкыйть) // Вакыт.– 1910.– № 698.– 4 б.
6. Милли шигырьләр (Рецензия) // Вакыт.– 1908.– № 268.– 3 б.
7. Милләт мәхәббәте (Рецензия) // Вакыт.– 1907.– № 171.– 3 б.
8. Моң вә зар. (Игълан һәм рецензия) // Вакыт.– № 999.– 1 б.
9. Мөгаллимсез укыту юллары (М. Гафури әдәбиятка хезмәт итүчеләр арасында санала) // Мәктәп.– 1914.– № 1.– 16 б.
10. Мөхәммәт Фатих мулла Мөхәммәди Гафуриga җавап буларак түбәндәге шигырьне яздым. («Юктырсың ла, Алла» дигән шигыренә карата) // Дин вә мәгыйшәт.– 1916.– № 6.– 91–92.
11. Насиб Х. М. Гафури әсәре («Милләт мәхәббәте» хакында) // Йолдыз.– 1907.– № 126.– 2 б.
12. Нугайски. Авыллар арасында (М. Гафуриның «Туган авылым Җилем-Каран турында» ) // Вакыт.– 1911.– № 844.– 3–4 б.
13. Нугайски. Земство тарафыннан мөселманнарга мөһим әсәр. (М. Гафуриның «Земство нәрсә?» дигән әсәре турында) // Вакыт.– 1912.– № 913.– 4 б.
14. Нугайски. Мәҗит әфәнде Гафури (М. Гафуриның кайбер шигыре өчен судка барелүе һәм полиция нәзарәтында булганнан соң, 29 октябрьгә аның нәзарәтыннан чыгуы турында) // Вакыт.– 1911.– № 875.– 3 б.
15. Уфада әдәбият кичәсендә М. Гафури шигырьләре укылу (22 юллык шигыре урнаштырылган) // Вакыт.– № 557.– 6 б.
16. Уфа тикшерүләр нәтиҗәсе вә конфисковать ителгән китаплар (Алар арасында М. Гафури әсәрләреннән «Үги балалар» һәм «Яшь гомерем») // Вакыт.– 1912.– № 933.– 3 б.

17. Программа вә китаплар (М. Гафури. Земство карамагындагы башлангыч (ибтидаи) мәктәп китапларын карау комиссиясе нәтиҗәсе // Вакыт.– 1912.– № 933.– 3 б.

18. Төхфәтулла. Мәҗит Гафурига. («Аң»дагы шигыренә җавап // Дин вә мәгыйшәт.– 1916.– № 8.– 133–114 б.

19. Хәмитнең хәяты, яки Ләйлә вә хәятым (Белдерү) // Вакыт.– 1911.– № 769.

## 1917 елдан соң чыккан әсәрләре

### *Басылган китаплары, сайланма әсәрләре һәм җыентыклары*

#### Шигырьләр

1. Ачлык тырнагында. Беренче басма.– Уфа: Башкнига., 1923.– 41 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Ачлык тырнагында. Икенче басма.– Казан, 1928.– 31 б. (*Татар телендә, латин графикасында*)

2. Кызыл байрак. Беренче басма.– Уфа: «Вәрәсәи Хөсәиния» нәшр., 1917.– 24 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Кызыл байрак. Икенче басма.– Казан: Татарстан Дәүләт нәшр., 1922.– 29 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

3. Кызыл тәлгәшләр. Беренче басма.– Мәскәү: Кооператив нәшр., 1925.– 47 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

4. Мәҗит Гафури. Шигырьләр. Беренче басма.– Уфа: Башгиз., 1934.– 109 б. (*Башкорт телендә, латин графикасында*)

5. Төнге смена. Беренче басма.– Казан: «Гажур» нәшр., 1927.– 40 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

6. Эшче. Поэма. Беренче басма.– Казан: Татарстан Дәүләт нәшр., 1921.– 48 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Эшче. Күчмә уку китаплары рәтеннән икенче китап.– Казан: Татарстан Дәүләт нәшр., 1922.– 36 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

7. «Эшче» операсының либреттосы.– Уфа: Башгиз., 1935.– 74 б.

8. Янган йөрәк. Беренче басма. Уфа: «Борадәран Кәримовлар» нәшр., 1918.– 31 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

**Хикәяләр**

1. Алтынчәч. Беренче басма.– Казан: «Мәгариф» нәшр., 1919. (*Татар телендә, гарәп графикасында)*

Алтынчәч. Икенче басма.– Казан: «Мәгариф» нәшр., 1921. (*Татар телендә, гарәп графикасында)*

2. Без бәләкәй чакларда. Беренче басма.– Уфа: Башкнига һәм Башнаркомпрос, 1927.– 47 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Без бәләкәй чакларда. Икенче басма.– Уфа: Башюниздат, 1934.– 33 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

3. Заятүләк белән Сусылу. Икенче басма (Беренче басмасы. 1910 елда Уфада басылган).– Казан: «Яңалиф» нәшр., 1927.– 31 б.

4. Кара йөзләр. Беренче басма.– Казан: «Гажур» нәшр., 1927.– 140 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Кара йөзләр. Икенче басма.– Уфа: Башгиз., 1933.– 108 б.

5. Кыр казы. Балалар хикәясе.– Уфа, 1920.– 24 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

6. Тормыш баскычлары. Беренче басма.– Уфа: Башгиз., 1930.– 101 б. (*Татар телендә, латин графикасында*)

7. Урал тауларында. Аучы карт / Балалар өчен хикәя / Күчмә уку китаплары сериясеннән.– Казан, 1922.– 14 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

8. Хәзер ансат ул, элек кыен иде. Беренче басма.– Мәскәү: Центриздат, 1927. (*Татар телендә*)

Хәзер ансат ул, элек кыен иде. Икенче басма.– Уфа: Башгосиздат., 1934.– 24 б.

9. Шагыйрьнең алтын приискасында. Беренче басма.– Казан: Татгосиздат, 1931.– 100 бит. (*Татар телендә*)

Шагыйрьнең алтын приискасында. Икенче басма.– Уфа: Башгиз, 1932.– 68 бит. (*Башкорт телендә, латин графикасында*)

10. Югалган Актырнак. Беренче басма.– Казан: «Яңалиф» нәшр., 1930.– 59 б. (*Татар телендә, латин графикасында*)

Югалган Актырнак. Икенче басма.– Уфа: Башгосиздат., 1934.– 66 б.

11. Солдат хатыны Хәмидә. Беренче басма.– Уфа: «Вәрәсәи Хөсәиния китапханәсе» нәшр., 1917.– 60 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

12. Ялчы. Беренче басма.– Уфа: «Виләят төрек халыклары шөгъбәсе» нәшр., 1921.– 12 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Ялчы. Балалар хикәясе.– Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1922.– 11 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

Ялсы.– Уфа: Башгосиздат., 1934.– 16 б.

### Башкалар

13. Кызыл йолдыз / Үзгәреш һәм төзү көннәре. Пьеса 4 пәрдәле. Беренче басма.– Уфа: Башкнига., 1925.– 71 б. (*Татар телендә, гарәп графикасында*)

## *1917 елдан соң журналларда басылган шигырь, хикәя һәм мәкаләләр*

### Шигырьләр

1. Алтын җирдә ятмас // Безнең юл.– 1928.– № 11, 12.– 6 б.

2. Ат // Октябрь.– 1934.– № 2.– 20 б.

3. Бай кеше // Октябрь.– 1934.– № 2–3.– 18 б.

4. Бай һәм хезмәтче // Октябрь.– 1934.– № 2–3.– 18 б.

5. Безнең дуслар килделәр // Керпе.– 1929.– № 2–3.– 13–14 б.

6. 1905 ел революциясе хакында истә калганнар // Белем.– 1925.– № 11–12.

7. Болытларга // Яңалиф.– 1927.– № 2.– 1 б.

8. Диңгез янында (1929) // Совет әдәбияты.– 1931.– № 3.– 40 б.

9. Дәрдемәндне укыгач (1930) // Совет әдәбияты.– № 3.– 41 б.

10. Игътираз // Октябрь.– 1934.– № 11–12.– 14 б.

11. Инкыйлаб // Яңа юл.– 1923.– № 5–6.– 46 б.

12. Ирекле көннәр // Аң.– 1917.– № 3.– 33 б.

13. Иске авыл // Белем.– 1926.– № 9–10.– 38 б.

14. Ертылган сәхифәләр // Яңа юл.– 1923.– № 2.– 42 б.

15. Ертылган сәхифәләр // Октябрь.– 1934.– № 2–3.– 20 б.

16. Күк җырлары // Яңа юл.– 1923.– № 5–6.– 44–45 б.

17. Карт тарихның соңгы көннәре // Яшь эшче.– 1924.– № 22.– 9–10 б.

18. Кошлар киткәндә // Чичән (Сәсән).– 1927.– № 1.– 1 б.

19. Кояш баеды // Безнең юл.– 1928.– № 11, 12.– 6 б.

20. Мин кайда // Октябрь.– 1934.– № 2–3.– 19 б.

21. Нигә кирәк иде? // Совет әдәбияты.– 1927.– № 3.– 39 б.

22. Рисаләт // Аң.– 1917.– № 5.– 2 б.

23. Иртәнге смена // Белем.– 1926.– № 2–3.– 40 б.

24. Ул кем иде? (Бабич) // Уфа.– 1922.– № 2.

25. Ул үлмәде // Яңа юлда.– 1933.– № 3.

26. Утыз ел : [шигырь] // Совет әдәбияты. – 1932. – № 3. – Б. 5.

27. Хисап көне // Октябрь.– 1934.– № 2–3.– 2 б.

28. Элекке «ул» инде кеше булды // Яңа юлда.– 1934.– № 57.

29. Янгыр // Аң.– 1917.– № 2.– 1 б.

30. Яңа көчләр // Яңа юл.– 1923.– № 5–6.– 25 б.

**Хикәяләр**

1. Бишенче ел революциясе хакында истә калганнар// Белем.– 1925.– № 11–12.– 16–18 б.

2. Исерек Гайфулла. Фельетон // Сәнәк.– 1926.– № 12.

3. Йөзгә йөз каршы килгәндә // Октябрь.– № 11–12.– 12–13 б.

4. Май бәйрәме алдыннан / Балалар өчен // Керпе.– 1929.– № 2–3.– 2–8 б.

5. Үз башына үзе җитте // Чичән.– 1928.– № 9.– 6–8 б.

6. Фәкыйрьлек белән үткән тереклек / Шул исемдәге хикәядән өзек // Октябрь.– 1934.– № 2–3.– 15–18 б.

7. Шагыйрьнең алтын приискасында // Октябрь.– 1930.– № 1–4.– 6–8 б.

**Мәкаләләр**

1. Гражданнар сугышы. Язып нәшер итү турында. Бу зур эшкә Башкортстан якыннан катнашырга тиеш // Октябрь.– 1931.– № 8–9.

2. Караңгы төннәрдә чыра яктысында // Белем.– 1926.– № 8.– Б. 30–32.

3. Мәҗит Гафури үзе турында. Биография // Чичән.– 1929.– № 2–3.

4. Фатих Әмирхан үлде // Белем.– 1926.– № 2–3.– Б. 47–48.

## *1917 елдан соң газеталарда басылган шигырь, хикәя һәм мәкаләләр*

**Шигырьләр**

1. Адашкан // Яңа авыл.– 1926.– № 150.– 4 б.

2. Адашканнар // Башкортстан.– 1924.– № 10.– 2 б.

3. Азатлык хөрмәтенә // Тормыш.– 1917.– № 608.– 4 б.

4. Ак кәҗә // Коммуна.– 1930.– № 55.– 1 б.

5. Алтын тәре, бәрхет палас // Урал.– 1922.– № 33 / 100.– 1 б.

6. Ат // Коммуна.– 1933.– № 12.– 3 б.

7. Бай кеше // Коммуна.– 1934.– № 51.– 2 б.

8. Балаларга // Яңа авыл.– 1926.– № 101.– 3 б.

9. Балалар бәйрәме // Шәрык ярлылары / М.Г. имзасы белән.– 1920.– № 107.– 2 б.

10. Берегез анда, берегез монда // Башкортстан.– 1934.– № 265.– 3 б.

11. Беренче бөтен Башкортстан Совет язучылары съездына котлау һәм сәлам // Коммуна.– 1934.– № 53.– 2 б.

12. Бер ел тулды, диделәр // Яшь юксыл.– 1924.– № 2–3.

13. Бер төндә // Тормыш.– 1918.– № 832.– 2 б.

14. Болытсыз күк күкрәгәндә // Коммуна.– 1933.– № 25.– 4 б.

15. Бетсен империализм сугышы /Өзек // Эшче.– 1923.– № 6.– 3 б.

16. Бөтен Башкортстан Совет язучыларының беренче съездына котлау һәм сәлам // Башкортстан.– 1934.– № 63.– 3 б.

17. Болар кемнәр // Урал.– 1922.– № 22 / 11.

18. Беренче май сәламе // Урал.– 1921.– № 9.

19. Бу вакыт // Идел.– 1917.– № 31.

20. Бу вакыт // Ирек.– 1917.– № 31.

21. Гарзы хәл // Яңа авыл.– 1925.– № 9.

22. Диңгез артында / «Ильяс» имзасы белән // Урал.– 1921.– № 64.

23. Диңгез артында // Яңа авыл.– 1927.– № 17.– 5 б.

24. Диңгез буенда // Урал.– 1922.– № 70.

25. Диңгез буенда // Башкортстан.– 1926.– № 250.– 3 б.

26. Дошманнарга капма-каршы // Коммуна.– 1934.– № 51.– 2 б.

27. Дошманнарга капма-каршы // Башкортстан.– 1934.– № 61.– 3 б.

28. Дәртле яшьләр // Башкортстан.– 1934.– № 256.– 3 б.

29. Зур җиңүләрнең көчле авазлары // Башкортстан.– 1934.– № 44.– 4 б.

30. Зур җиңүләрнең көчле авазлары // Коммуна.– 1934.– № 34.– 3 б.

31. Зариф иптәш Бәширигә // Яңа авыл.– 1927.– № 121.– 5 б.

32. Инвалидлар // Башкортстан.– 1923.– № 138.– 3 б.

33. Ир-егеткә // Башкортстан хәбәрчесе.– 1922.– № 99.– 2 б.

34. Иске завод // Кызыл Башкортстан.– 1934.– № 286.

35. Йөзгә йөз каршы килгәндә // Коммуна.– 1930.– № 128.

36. Җырлыйм, җырлыйк // Урал.– 1922.– № 107.

37. Ертылган сәхифәләр // Коммуна.– 1934.– № 51.– 2 б.

38. Елыйлар // Урал.– 1922.– № 13 / 80.– 2 б.

39. Элекке «ул» инде кеше булды // Коммуна.– 1933.– № 31.

40. Капитал дөньясында этләр, эшчеләр, арзан товарлар, демонстрация һәм ачлык походлары // Коммунист.– 1932.– № 144.

41. Кем ул? // Коммуна.– 1934.– № 51.– 2 б.

42. Колхоз фронтында җиңүчеләргә // Коммуна.– 1933.– № 40.– 4 б.

43. Күз бәйләш, сукыр тәкә // Татарстан.– 1926.– № 227.– 3 б.

44. Карт батыр теләге // Яшь юксыл.– 1924.– № 2.– 3 б.

45. Корбаннар. Лена вакыйгасында үтерелгән иптәшләргә // Башкортстан.– 1923.– № 40.– 3 б.

46. Курыкмагыз // Тормыш.– 1917.– № 613.– 3 б.

47. Кызыл Армия // Яңа авыл.– 1926.– № 23.– 3 б.

48. Кызыл тактага // Эшче.– 1923.– № 98.– 3 б.

49. Ленинизм минем маягым // Башкортстан.– 1934.– № 265.– 3 б.

50. Ленин һаман безнең истә // Яңа авыл.– 1926.– № 22–11/1 б.

51. Май // Яңа авыл.– 1926.– № 50.– 3 б.

52. Матәм аһлары // Башкортстан.– 1924.– № 12.– 3 б.
53. Нинди бәйрәм бар соң... // Башкортстан.– 1922.– № 117.– 3 б.
54. Нур // Урал.– 1920.– № 70.
55. Очар идем. Инвалидлар // Башкортстан.– 1923.– № 148.
56. Очар идем // Башкортстан.– 1923.– № 87.– 5 б.
57. Санаториядә // Башкортстан.– 1934.– № 265.– 3 б.
58. Чит ил кунаклары // Яңа авыл.– 1926.– № 111.– 3 б.
59. Чукынырлар // Яңа авыл.– 1927.– № 107.
60. Тантаналы бәйрәм // Эшче.– 1927.– № 215.
61. Тарихи ун ел // Яңа авыл.– 1929.– № 32.– 3 б.
62. Тау-ташлар уяндылар // Башкортстан.– 1923.– № 149.– 7 б.
63. Тәнбиһ // Кызыл Башкортстан.– 1922.– № 136.– 1 б.
64. Алар кемнәр? // Коммуна.– 1923.– 27/X.
65. Үткән еллар // Яңа юлда.– 1924.– № 30.
66. Хисап көне (1918) // Коммуна.– 1934.– № 51.– 2 б.
67. Хәят чишмәсе // Башкортстан.– 1922.– № 132.– 2 б.
68. Сукырлар // Яңа авыл.– 1927.– № 107.– 3 б.
69. Сыер белән сарык, кәҗәнең протесты // Коммуна.– 1933.– № 38.– 2 б.
70. Шанхай // Яңа авыл.– 1927.– № 36.– 2 б.
71. Элекке «ул» инде кеше булды // Коммуна.– 1933.– № 31.– 4 б.
72. Эшкә, эшкә... // Яңа авыл.– 1927.– № 9.

**Хикәяләр**

1. Ике күренеш // Яңа авыл.– 1924.– № 30.
2. Мәскәүдә сөйләшәләр, монда кул чабалар // Яңа авыл.– 1927.– № 54.
3. Чикләнмәгән елларга таба // Яңа авыл.– 1927.– № 128.
4. Тормыш баскычлары // Яңа авыл.– 1927.– № 119.– 120–122 б.

5. Фәкыйрьлек белән үткән тереклек (Шул исемдә 1902 елда язылган хикәядән өзек) // Коммуна.– 1934.– № 51.– 2 б.

## Мәкаләләр

1. Агачларны саклау – безнең уртак эш (Ленин иптәш өчен ачуланган) // Яңа авыл.– 1929.– № 55.– 3–4 б.

2. Ачларга ничек ярдәм итәргә // Урал.– 1921.– № 43.

3. Авылларда спектакль һәм төрле кичәләрне юлга куярга кирәк (М.Г. имзасы белән язылган) // Яңа авыл.– 1925.– № 20.

4. Авыл радио тели (М.Г. имзасы белән язылган) // Яңа авыл.– 1929.– № 25.

5. Авыл хуҗалыгы белемен ничек алырга // Яңа авыл.– 1924.– № 50.

6. Авыл хуҗалыгы бурычы ширкәтләреннән... // Яңа авыл.– 1925.– № 8 /58.

7. Аягында чабата, аркасында капчык // Башкортстан.– 1923.– № 23.– 23/XII.

8. Басулар арасында // Яңа авыл.– 1928.– № 121.– 3 б.

9. Башкортстан гыйльми оешмаларының хезмәте // Башкортстан хәбәрләре.– 1922.– № 83.

10. Башкортстан идарәсеннен («Яшь юксыл»ның бер еллыгына котлау) // Яшь юксыл.– 1924.– № 2–3.

11. Без аның 30 еллык хезмәте аркылы беләбез, ерактан торып тәбрик итәбез (М. Корбангалиев турында) // Яңа авыл.– 1925.– № 143.– 4 б.

12. Беренче адымнар // Ирек.– 1917.– № 9.

13. Борынгы дошманнарның туганлашкан җирендә // Коммуна.– 1932.– № 32, 33, 35.

14. Борынгы матбугат // Башкортстан.– 1923.– № 47.– 3 б.

15. Бөтен Россия мөселманнарының Мәскәүдә булган съездларыннан алынган тәэссорат («Ильяс» имзасы белән язылган) // Безнең тавыш.– 1917.– № 1.

16. Болар да «пролетариатлар», имеш // Яңа авыл.– 1925.– № 135.

17. Вәгазьләр, вәгазьләр... («Лачын» имзасы белән язылган) // Башкортстан.– 1934.– № 24/1.

18. Гармун тавышы // Яңа авыл.– 1926.– № 99.

19. Гигантлар тезмәсе (очерк) // Коммуна.– 1930.– № 113, 115, 116.

20. Гыйльми мәркәз. («Әдип» имзасы белән язылган) // Башкортстан хәбәрләре.– 1922.– № 140.

21. Горбәттә йөргән милли ялчылар // Яңа авыл.– 1929.– № 69–70.– 2–3 б.

22. Диңгез артында («Ильяс» имзасы белән язылган, фельетон) // Урал.– 1921.– № 60.

23. Денщик Мәхмүт // Коммуна.– 1931.– № 25 / II.

24. Дәртле егетләр // Яңа авыл.– 1927.– № 111.– 4 б.

25. Иген, печән, туй, кунак, налог // Яңа авыл.– 1926.– № 13.

26. Иске авылга алмашка яшьләр яңа авыл алып киләләр // Яңа авыл.– 1924.– № 54.

27. «Яшь эшче» // Башкортстан.– 1924.– № 98.– 4 б.

28. «Яшь юксыл» газетасы // Башкортстан.– 1923.– № 2 / VII.

29. Кешелек дөньясының олы бер агасы (В. И. Ленинның үлеме һәм аның көрәш юлы турында) // Яңа авыл.– 1929.– № 9.– 1 б.

30. Кооперативны үстерү әгъзалар кулында (М.Г. имзасы белән язылган) // Яңа авыл.– 1929.– № 14.

31. Җәнүби Урал музее ачылды (М.Г. имзасы белән язылган) // Урал.– 1921.– № 34.– 3 б.

32. Канлы тарихларга чик куярга кирәк (Нәсер) // Яңа авыл.– 1928.– № 50.– 2–3 б.

33. Кызыл әтәчләр оча башладылар // Яңа авыл.– 1925.– № 52.

34. Каюм Насыйри мәҗмугасы // Башкортостан хәбәрләре.– 1922.– № 104.

35. Матбугат дөньясы // Урал.– 1921.– № 64.

36. Матбугат дөньясында (Каюм Насыйри мәҗмугасы) // Башкортстан.– 1922.– № 104.– 1 б.

37. Матбугат тирәсендә (Башкортстан гыйльми оешмалары хезмәте) // Башкортстан хәбәрләре.– 1922.– № 83.– 4 б.

38. Матбугат хәзинәсе (Башкортстан үзәк китапханәсе турында // Яңа авыл.– 1928.– № 52.– 2 б.

39. «Мыштым» журналы // Башкортстан.– 1924.– № 98.

40. Мәҗит Гафуриның «Башкортстан»га җавабы. // Башкортстан.– 1928.– № 137.

41. Мәңгегә киттеләр // Башкортстан.– 1924.– № 99.– 2 б.

42. Октябрь революциясе һәм шәрык халыклары // Башкортстан.– 1927.– № 128.

43. Октябрь революциясенең таңында // Яңа авыл.– 1927.– № 29.– 3 б.

44. Уфа вилаяте мөселманнарының гомуми съезды // Ил.– 1917.– № 13, 15.

45. Уфада басмаханә эшләре // Башкортстан.– 1922.– № 113.– 2–3 б.

46. Уфада беренче май бәйрәме (М.Г. имзасы белән язылган)

47. Уфадан Казанга // Татарстан.– 1925.– № 219–226.– 5 б.

48. Уфа сәхнәсендә Гамлет // Башкортстан.– 1924.– № 45.– 3 б.

49. Чикләнмәгән елларга (Нәсер) // Яңа авыл.– 1927.– № 128.

50. Читкә озатылган балаларны кайтару чараларын күргергә вакыт түгелме // Башкортстан хәбәрләре.– 1922.– № 77.– 1 б.

51. Совет мәктәпләрен бозык укытучылардан чистартырга кирәк (М.Г. имзасы белән язылган) // Яңа авыл.– 1929.– № 21.

52. Чулпан йолдызы (Каюм Насыйриның үлеменә 20 ел тулуга бәйле) // Башкортстан хәбәрләре.– 1932.– № 85.– 1 б.
53. Тарихи бөек көрәшләр алдында безнең бурычларыбыз // Коммуна.– 1934.– № 43, 44.
54. Татар-башкорт матбугаты элек һәм хәзер // Яңа авыл.– 1925.– № 4.
55. Татар китапханәчеләре кайда югалдылар икән? // Урал.– 1922.– № 88.
56. Тырыш укытучыларны – тәкъдир, начар укытучыларны тәнкыйть итәбез // Яңа авыл.– 1929.– № 51.
57. Ул вакытта шулай бөтенесе дә искечә иде // Яңа авыл.– 1926.– № 128.– 5 б.
58. Урал моңнары // Урал.– 1921.– № 64.
59. Шам-шәриф һәм Сурия тирәсендә // Яңа авыл.– 1925.– № 130.– 2 б.
60. «Эшче» операсы турында // Кызыл Татарстан.– 1930.– № 28/II.
61. Әдәбият карагы // Башкортстан.– 1924.– 5 б.
62. Юнанстанның зур теләге җимерелде (М.Г. имзасы белән язылган) // Башкортстан хәбәрләре.– 1922.– № 91.– 1 б.

### *М.Гафуриның 1917 елдан соң вафатына кадәр альманах, хрестоматия һәм уку китапларына кергән шигырь, хикәяләре һәм аның катнашы белән язылган китаплар*

1. Анасын көтә. Шигырь //Азат мәктәп (Уфа).–1920.
2. Аучы карт. Хикәя // Күчмә уку китабы.– 1920.
3. Авыл эшчесе // Уку китабы (Казан).– 1923.– 182–183 б.
4. Буяулы йомырка // Азат мәктәп.– 1920.– 19 б.
5. Вөждан. Шигырь // Әдәбият юллары (Казан).– 1920.– 61–62 б.

6. Гарзы хәл. Шигырь // Яшь буын (Уфа).–1926.– 303–305 б.

7. Гомер. Шигырь // Әдәбият юллары. (Казан).–1920.–62 б.

8. Гает көнендә. Шигырь // Бәйрәм шигыре мәҗмугасе. (Уфа).– 1916.– 2 б.

9. Заводта. Шигырь // Уку китабы. (Казан).–1925.–185–187 б.

10. Заводта. Шигырь // Яшь буын (Уфа).– 1926.– 264–266 б.

11. Златоуст. Шигырь // Әдәбияттан хрестоматия.–1928.– 87–89 б.

12. Җәйге эшләр. Шигырь // Азат мәктәп.– 1920.–33 б.

13. Яшь гомер. Шигырь // Мәктәптә милли әдәбият дәресләре (Казан).–1919.– 55–58 б.

14. Көз көне бакчада. Шигырь // Уку китабы (Уфа).–1923.– 134 б.

15. Канлы якшәмбе. Шигырь // Уку китабы (Уфа).–1934.– 48 б.

16. Карт түгел. Шигырь // Әдәбият юллары (Казан).–1920. –64 б.

17. Корбаннар. Шигырь // Яшь буын (Уфа).– 1926.–312–313 б.

18. Корыган агачлар. Хикәя // Ун ел эчендә татар әдәбияты.– 1930.– 252–279 б.

19. Кошларга. Шигырь //Азат мәктәп.– 1920.– 24 б.

20. Кыш. Шигырь // Беренче башкортча уку китабы (Уфа).– 1924.– 23 б.

21. Кыш. Шигырь // Азат мәктәп.– 1920.– 14 б.

22. Маймыл һәм күзлекләр. Шигырь // Туган тел.–1918.

23. Руза бәйрәме. Шигырь // Бәйрәм шигырьләре мәҗмугасы (Уфа).– 1916.– 31 б.

24. Рәсүлебез Мөхәммәд Галәйһиссәләм // Бәйрәм шигырьләре мәҗмугасы (Уфа).– 1916.– 21–22 б.

25. Саф калебле дустым. Шигырь // Әдәбият юллары (Казан).– 1920.– 63–64 б.

26. Совет матбугаты. Шигырь // Матбугат көне (Уфа).– 1928.– 12 б.

27. Чәчкәләр арасында. Шигырь // Уку китаплары.– 1923.– 50 б.

28. Тәәссеф. Шигырь // Әдәбият юллары (Казан).– 1920.– 62 б.

29. Шагыйрь Г. Тукай вафатыннан соң // Әдәбият юллары (Казан).– 1920.– 63 б.

30. Шахтада. Шигырь // Яшь буын (Уфа).– 1926.– 259–261 б.

31. Шәйхе Шамил рәсемен күргәндә. Шигырь // Әдәбият юллары (Казан).– 1920.– 63 б.

32. Электрик фонаренә хитап. Шигырь // Мәктәптә милли әдәбият дәреслеге (Казан).– 1919.– 62–63.

33. Эшче. Шигырь // Яшь буын (Уфа). 1926.– 261–264 б.

34. Эшче уйлары. Шигырь // Яшь буын (Уфа). 1926.– 266 б.

35. Яз башында. Шигырь // Татарча уку китабы. М. Корбангалиев, Г. Баттал. – 1919.

36. Яңа көчләргә. Шигырь // Яшь буын (Уфа). 1926.– 463–464 б.

*М. Гафури фонды // Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Музыкаль һәм язма мирас үзәге бүлеге, 12 ф., 1 тасв., 47 эш*

# Мәҗит Гафури тормышының һәм эшчәнлегенең төп даталары

**1880 ел, 1 август** (яңа стиль – 20 июль). Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстанның Гафури районы) Җилем-Каран авылында хәлфә гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Әтисе – Нургани, әнисе – Мәрзия).

**1887 ел.** Авыл мәктәбенә укырга бирәләр.

**1892–1895 еллар.** Күрше Үтәш авылы мәдрәсәсендә сабак ала.

**1892 ел.** Бер-бер артлы әтисе һәм әнисе үлә.

**1896 ел, сентябрь**. Укуын берәр зуррак мәдрәсәдә дәвам иттерү теләге белән, җәяүләп, Уфага китә, ләкин, ярлы булуы аркасында, кала мәдрәсәләренең берсенә дә керә алмый. Кайтышлый Уфадан ерак булмаган Кыешкы (хәзерге Кырмыскалы районы, Иске Кыешкы авылы) мәдрәсәсенә туктала һәм декабрь аена кадәр шунда укый.

**1897 ел.** Авылына кайта. Җамалетдин исемле яшь мулладан дәресләр ала һәм аңа балалар укытуда булыша.

**1897–1898 еллар.** Балалар укыта, төрле урыннарда яллы хезмәттә, «Лапашты», «Зигәзе» һәм «Француз» заводларында эшли.

**1898 ел, җәй.** 450 чакрым чамасы араны җәяүләп үтеп, Троицк шәһәрендәге Зәйнулла ишан мәдрәсәсенә («Рәсүлия») барып урнаша.

**1899–1901.** Җәйге каникул вакытларында, кышлык акча юнәтү өчен, төрле яллы эшләрдә йөри: урак ура, Яушевларның – торф, Рәмиевләрнең алтын чыгару рудникларында эшли, казакъ балаларын укыта.

**1901 ел, март.** Троицкидан 130 чакрым ераклыкта булган кыргыз авылына бара. Балалар укыта.

**1902 ел, яз.** Мәдрәсә тәртипләреннән көлеп, «Ишан шәкертләренә» дигән сатирик шигырен язып тарата, шуның аркасында хәлфәләр, карт шәкертләр белән низагка керә. Бу вакыйгадан соң мәдрәсәне ташлый.

**1902 ел, җәй.** «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» исемле беренче проза әсәрен, «Себер тимер юлы, яки Әхвале милләт» исемле күләмле шигырен яза.

**1904 ел.** Беренче әсәрләре — «Себер тимер юлы, яки Әхвале милләт» исемле шигырьләр җыентыгы Оренбургта һәм «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» хикәясе Казанда китап булып басылып чыга.

**1905 ел, яз һәм җәй айлары.** Казакълар арасында мөгаллимлек итә.

**1905 ел, август башы**. Троицкига кайта, әмма монда да уку-укыту эшләрендә бер дә яңалык сизелмәгәнлектән, Иж-Буби мәдрәсәсенә юл тота, тик бу уку йорты да аны канәгатьләндерми, биредә бер атна чамасы гына тора.

**1905 ел, август ахыры.** Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлый.

**1906 ел.** Уфаның «Галия» мәдрәсәсенә күчә. Анда бер ел рәсми укый.

**1906 ел**. «Яшь гомерем» җыентыгы басыла.

**1907 ел.** «Милләт мәхәббәте» җыентыгы чыга.

**1907–1908 еллар.** «Галия» мәдрәсәсендә ирекле тыңлаучы.

**1907 ел.** Ахыргы тапкыр казакълар арасында балалар укыта.

**1908 ел.** «Шура» журналының (Оренбург) тәүге санында шигырьләре басыла. Уфадагы «Шәрекъ» типографиясендә дә, беренче китап буларак, аның җыентыгы («Милли шигырьләр») басыла.

**1909–1912 еллар.** Иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Казан, Уфа нәшриятларында әдипнең дистәгә якын шигырь китабы, тугыз хикәя җыентыгы, газета-журналларда күп кенә публицистик мәкаләләре басыла.

**1909 ел, август.** Зөһрә исемле кызга өйләнә.

**1910 ел.** «Адәм вә Иблис» поэмасын яза.

**1910 ел.** Улы Әнвәр туа.

**1911 ел.** «Шагыйрь Мәҗит Гафуриның милләт мәхәббәте нам әшгаре» исеме белән басылган шигырьләре патша цензурасына эләгә.

**1911 ел, яз.** Губерна земство идарәсенең халык мәгарифе бүлеге каршындагы китапханә комиссиясе составына керә һәм Уфа земствосы эшендә актив катнаша.

**1911 ел, 11 февраль.** Уфадагы «Шәрекъ мәтбагасы»нда жандармерия тентү үткәрә. Шагыйрьнең «Үги балалар» һәм «Яшь гомерем» җыентыкларын «аеруча хәтәр китаплар» исемлегенә кертеп конфискацияли.

**1911 ел**. «Шура» журналында уздырылган «Кәлям мөсабәкасы – Тел ярышы» бәйгесендә «Болгар кызы Айсылу» хикәясе белән җиңүче була.

**1912 ел, яз – 1917 ел, октябрь.** Уфада Кәримовларның «Шәрекъ» матбагасында корректор булып хезмәт итә.

**1912 ел, җәй.** Уфада Г. Тукай белән очраша.

**1915 ел, июль.** Губерна земствосы идарәсе башлангыч рус һәм рус булмаган мәктәпләр өчен язылган дәреслекләрне карау максатында оештырган өлкә киңәшмәсендә катнаша.

**1916 ел**. Сәгыйть Рәмиев, Җамал Вәлидиләр белән берлектә, татар теленең алынмалар сүзлеген төзүдә катнаша.

**1917–1920 еллар.** «Ирек», «Безнең юл», «Шәрекъ ярлылары», «Башкортстан» кебек матбугат органнарында бик күп публицистик мәкалә, шигырь бастыра.

**1919 ел.** Улы Халит туа.

**1920 ел**. «Эшче» поэмасын иҗат итә.

**1921 ел.** Корректор булып торудан чыгып, «Шәрекъ ярлылары» һәм «Башкортстан» газеталарында язышучы булып эшли башлый.

**1921 ел.** «Ачлык тырнагында», балалар өчен «Ялчы» әсәрләрен яза.

**1922 ел.** Кырым совнаркомы исеменнән Гәрәй Сәетгалиевнең чакыруы буенча Кырымда бер ай торып, дәваланып кайта.

**1922–1928 еллар.** «Башкортстан» газетасында, соңрак «Яңа авыл»да хәбәрче булып тора.

**1923 ел.** Егерме еллык иҗат бәйрәме зурлап уздырыла. Шул уңай белән «Башкортстан АССРның халык шагыйре» дигән шәрәфле исем бирелә.

**1926 ел**. «Кара йөзләр» повестен тәмамлый.

**1926 ел.** «Кызыл йолдыз» драмасын яза.

**1927 ел.** «Тормыш баскычлары» әсәрен яза.

**1928 ел.** Сәламәтлеге начарлану сәбәпле, газетада эшләүдән туктап, язучылык эшләре белән генә шөгыльләнә башлый.

**1929 ел.** «Шагыйрьнең алтын приискасында» әсәрен тәмамлый.

**1929 ел.** Кырымда бер ай дәваланып кайта.

«Кызыл йолдыз» пьесасы Башкортстан Мәгариф халык комиссариаты оештырган конкурста беренче дәрәҗә премия белән бүләкләнә.

**1930 ел, сентябрь.** «Башкортстан», «Коммуна» газеталарының хәбәрчесе буларак делегация составы белән Новосибирскига бара. Анда «Азат Себер» газетасы редакция хезмәткәрләре белән очраша.

**1930 ел, февраль ахыры.** «Эшче» операсының премьерасы була. (Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши, Василий Виноградов муз.)

**1932 ел.** Казанда «Мәҗит Гафуриның сайланма әсәрләре» җыентыгы чыга.

**1933 ел, март.** Г. Ибраһимов «Яңалиф» журналында Мәҗит Гафуриның яңа китабы турында «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» дигән рецензиясен бастыра.

**1934 ел.** СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

**1934 ел, 28 октябрь.** Уфа шәһәрендә вафат була.

**1935 ел.** Улы Халит үлә.

**1938 ел.** Хатыны Зөһрә вафат була

**1940 ел, 23 ноябрь.** Шагыйрьнең 60 еллык юбилее уңаеннан Красноусол районы Гафури исеменә алыштырыла.

**1954–1957 еллар**. Башкортстан китап нәшриятында әдипнең башкортча тәрҗемәдә алты томлык әсәрләр җыентыгы чыга.

**1957 ел.** Красноусол авылында һәйкәл куела. Скульпторлары: Т. П. Нечаева, В. Г. Морозова, арх. Арсланов.

**1958 ел.** Җилем-Каран авылында шагыйрьгә бюст куела. Скульпторы В. Г. Морозова.

**1971 ел**. Башкорт дәүләт академия драма театрына М. Гафури исеме бирелә. Аның алдындагы мәйданчыкка шагыйрьнең һәйкәле куела.

**1977 ел.** Улы Әнвәр вафат була.

**1980–1984 еллар.** Татарстан китап нәшриятында дүрт томлыгы дөнья күрә.

**1982 ел.** Гәрәй Рәхим, «Кара йөзләр» әсәренә нигезләнеп, либретто иҗат итә.

**1984 ел.** «Кара йөзләр» әсәренә нигезләнеп иҗат ителгән «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы өчен, иҗат коллективына Г. Тукай премиясе бирелә. Либретто авторы – Гәрәй Рәхим. Композитор – Бату Мөлеков, дирижер – В. Васильев, төп рольләрне башкаручылар – З. Сөнгатуллина һәм Х. Бигичев.

## Эчтәлек

*Дания Заһидуллина.* «Гасырларча хөкем сөргән җиһангир без татарлардыр...»: татарның талантлы улы Мәҗит Гафури . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
*Диләрия Абдуллина.* Мәҗит Гафури: иҗатка багъланган тормыш, халыкка багышланган иҗат (1880–1934) . . . . . . . .28

### *Мәҗит Гафуриның әдәби әсәрләре*

#### Шигырьләр

Өндәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
«Ничә йөз ел изелгәнгә татар юаш...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Ике кош . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Мәкъсуд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Татар милләтенең лисане хәле илә шикаяте . . . . . . . . . . . . . 63
«Үзенең гаклына татбикъ итеп...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Алар бездән оялганнан...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Бер татар шәкертенең Казанда мәшһүр Хан мәсҗеденең манарасыны күргәндә иншад итдеге шигыредер . . . 67
«Сәгадәткә ирешмәк әсбабын күрмәк йөгермәкләр...» . . . . 68
«Бәңа бу көн мәхәббәт булды михнәт...» . . . . . . . . . . . . . . 69
«Милләтем улганга татар, бән дә улдым бер татар...» . . . . . . 70
«Гафури, сән онытма милләтеңне...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Әтәч белән Сандугач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Алмас ташы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
...гә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Инкыйлаб . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Бакчада... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Үз мөселманым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Балалар теләге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Үрдәк – Лачын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь . . . . . . . . . . . 80
Күңел тарлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Дин вә ислам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Сөембикәнең соңгы сүзләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Телеңне киссәләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Кайвакытта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Итагать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Ана теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

Хәкыйкать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Алладан сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Йолдыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Үгез белән Бүре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Г. Тукай вафатыннан соң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Саф күңел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Исле гөл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Ул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Бәйрәм көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Язмыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Ул кем? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Юктырсың ла, Алла!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .101
Беренче мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Азатлык хөрмәтенә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Татар байрагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Курыкмагыз!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Бер төндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Сәлам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Мин – «исерек» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .110
Җилфердәсен Кызыл байрак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Миң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .112
Барчасыннан син матур . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .113
Гаҗәп эш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .114
Шәүләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .115
Аяклары... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .116
Чәче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117
Бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .118
Көтмәгәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .119
Балалар һәм китап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .120
Ач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .121
Беренче май сәламе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .122
Шатлык белән хәсрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .123
Ир җегеткә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .124
Ул кем иде? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .125
«Изге күңлем кәгъбәсеннән көн дә бер таш җимрелә...» . . .126
Сәйфи Кудашка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .127
Инкыйлаб . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .128
Яңа көчләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .129
Гөлләр бакчасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .130

Җырларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .131
Көндәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .132
Ленинизм минем маягым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .133
Бер истәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .134
«Әй вөҗданым, йөрдем сине сатмас өчен...» . . . . . . . . . . . . .135

**Чәчмә әсәрләр**

Болгар кызы Айсылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .136
Мәхәббәт хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .138
Хәзрәте Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһи вәсәлләм
вә дүрт хәлифә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .158
Бу кемнең кабере? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .185
Тәэссорат. Җәй көненең төнге ай яктысында . . . . . . . . . . .191
Беренче табгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Хан кызы Алтынчәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203

**Публицистик һәм фәнни мәкаләләр**

Үрмәкүчтән гыйбрәт алмалы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .210
Гаҗәпләнмәгән идем, гаҗәпләндем . . . . . . . . . . . . . . . . . . .212
Татар җырчысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .218
Чуар тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
Уфада кызларга мәхсус мәдрәсә
салыну мөнәсәбәте белән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
Авыл халыклары өчен файдалы китаплар вә земстволар . . . 230
Госманлы төрекләрнең әдәбиятларында кафияләр . . . . . . 235
Бер-ике сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
«Себер тимер юлы» дигән әсәрем хакында берничә сүз . . . 247
Гармун тавышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .251
Казандагы «Яңалиф» нәшрият идарәсенә . . . . . . . . . . . . . 255
Тәрҗемәи хәлемнән өземтәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255

***М. Гафуриның иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлегенә галимнәрнең бәя-карашы***

*Мөхәммәт Мәһдиев*. Мәҗит Гафури . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
*Фоат Галимуллин*. Якты идеаллар җырчысы . . . . . . . . . . . . 291
*Хатыйп Миңнегулов*. Татарның олы бер моңчысы . . . . . . . . 306
*Равил Рахмани*. Мәҗит Гафури – балалар шагыйре . . . . . . . 324
*Гульназ Азаматова*. Общественная деятельность Ма-
жита Гафури в 1907–1916 гг. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
*Радик Хөснетдинов*. «Шура» журналы һәм Мәҗит Гафури . 345
*Миркасыйм Госманов*. Мәҗит Гафури мирасыннан . . . . . . . .351

### *Замандашларының бәясе, тәнкыйть мәкаләләре*

*Габдулла Тукай*. Мәкаләи махсуса . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 358
*Гаяз Исхакый*. «Үги балалар» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 365
*Фатих Әмирхан*. Татар шагыйрьләре . . . . . . . . . . . . . . . .372
*Габдрахман Сәгъди*. Мәҗит Гафури . . . . . . . . . . . . . . . . 377
*Габдрахман Сәгъди*. Мәҗит Гафури – символист . . . . . . . . 382
*Кәрим Тинчурин*. Мәҗит Гафуриның драматургиядәге урыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 385
*Муса Җәлил*. Мәҗит Гафуриның иҗаты турында . . . . . . . . . 387

### *Мәҗит Гафури турында истәлекләр*

*Зөһрә Гафури*. Безнең тормыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 408
*Миргазиз Укмасый*. Казанда очрашулар . . . . . . . . . . . . . . 438
*Сәйфи Кудаш*. Шагыйрьнең үтенече . . . . . . . . . . . . . . . . . 443
*Гата Исхаков*. Мәҗит агай белән танышу . . . . . . . . . . . . . 449
*Хәлил Маннанов*. Мәҗит Гафури мине журналист ясады . . . 457
*Кәрим Әмири*. Мәҗит Гафури . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 468

### *Хатлар*

Кәрим Әмиригә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 480
Хәбибрахман Зәбиригә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 482
Һади Такташның Мәҗит Гафурига язган хаты . . . . . . . . . . . 484
Һади Такташка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 485
Зариф Бәширинең шигырь белән язган хаты . . . . . . . . . . . . 486

### *М. Гафуриның егерме еллык иҗат юбилеена бәйле материаллар*

Г. Ибраһимовның котлау хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 489
Ф. Әмирханның котлау хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 491
*Сәйфи Кудаш*. Алтын сәгать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 493
*Гыйбад Алпаров*. Мәҗит абзый кем? . . . . . . . . . . . . . . . . . 495
*Гата Исхакый*. Карт шагыйрь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 497
*Муса Йосыпов*. Шагыйрь Мәҗит Гафури . . . . . . . . . . . . . . 498
*Гыйлемдар Баймбәтов*. Мәҗит ага . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 503
Хатирәләр дәфтәреннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .510
М. Гафуриның үзе исән чакта чыккан әсәрләре библиографиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 528

*Китапта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кульязма һәм музыкаль мирас үзәге «Мирасханә»дә саклана торган Мәҗит Гафури фондыннан, шулай ук Татарстан республикасы Дәүләт архивы, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И. Лобачевский ис. Фәнни китапханәсе, Россия Фәннәр академиясе Казан Фәнни үзәге китапханәсеннән алынган чыганаклар файдаланылды.*

16+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. №436–ФЗ

Научно-популярное издание

Мазит Гафури

Ответственный за выпуск: *Фуат Рафиков*
Дизайн обложки: *Григорий Эйдинов*
Художественное оформление: *Рамиль Миннуллин*
Компьютерная вёрстка: *Йолдыз Нуриева*
Каллиграф: *Альфия Исхакова*
Корректор: *Нурзида Нотфуллина*

Формат 84x108 1/32. Усл. печ. листов 29,4
Бумага офсетная. Тираж 1500 экз. Заказ № ??

Оригинал-макет подготовлен с помощью
пакета программ Jahat™.

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленного электронного оригинал-макета в типографии
филиала ОАО «ТАТМЕДИА» ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. e-mail: idelpress@mail.ru

9 785902 783541